Әсирлектән кайткан әкиятләр

Әсирлектән кайткан әкиятләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК398
ББК 82.3(2Рос-Тат)-6
Ә71

Төзүчесе, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы *Ленар Җамалетдин*
Рәссамы *Рушан Шәмсетдинов*

Ә71 Әсирлектән кайткан әкиятләр: Татар халык әкиятләре.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.—343 б.

Бу китап әкият сөючеләргә шактый гына яңалыклар алып килә. Биредәге 56 әкиятнең 40 ка якыны бездә моңарчы нәшер ителгән җыентыкларның берсендә дә басылмаган. Аларның бер өлеше, гомумән, беренче тапкыр дөнья күрә.

ISBN 5-298-01038-5
© Татарстан китап нәшрияты, 2002

Әкиятләрнең дә үз язмышы...

Бу китап әкият сөючеләргә шактый гына яңалыклар алып килә. Беренчедән, биредәге 56 әкиятнең 40 ка якыны бездә моңарчы нәшер ителгән җыентыкларның берсендә дә басылмаган. Әкиятләрнең бер өлеше, гомумән, беренче тапкыр дөнья күрә. Икенчедән, шушы китапка исем биргән әсирлектән кайткан әкиятләр, барысы бергә тупланып, укучыларга тәүге мәртәбә җыентык рәвешендә тәкъдим ителә. Алар китапның беренче бүлеген тәшкил итә. Җыентык барысы өч бүлектән гыйбарәт. Бүлекләр үз чиратында өчәр бүлекчәдән тора (беренче бүлектә генә өченче бүлекчә юк). Беренче бүлекчәгә тылсымлы әкиятләр, икенчесенә көнкүреш әкиятләре, өченчесенә хайваннар турындагы әкиятләр урнаштырылды.

Шулай итеп, беренче бүлек — «*Әсирлектән кайткан әкиятләр*». Мәгълүм булганча, беренче бөтендөнья сугышы чорында (1914—1918) венгр галиме Игнац Кунош (1860—1945) Чехиянең Эгер һәм Венгриянең Эстергом шәһәрләре тирәсендәге лагерьларда тотылган хәрби әсирләрдән, шул исәптән татар солдатларыннан да, халык авыз иҗаты әсәрләрен язып алу белән шөгыльләнгән. И.Кунош — тел белеме галиме, төркиче. Ул төрле төрки халыкларның телләрен һәм шивәләрен (диалектларын) өйрәнгән. Ул туплаган фольклор материаллары арасында Казан татарларыннан һәм мишәрләрдән язып алынганнары күләм ягыннан шактый зур урын алып тора. Алар, нигездә, әкиятләр һәм җырлар. Әмма үзе исән вакытта И.Куношка әсирләр арасында туплаган материалларын бастырып чыгару насыйп булмый. Бары тик мәшһүр «Ак бүре» әкияте генә, галимнең бер китабына кушымта итеп урнаштырылуы сәбәпле, безгә килеп ирешә[1]. Калган материалларының барысы да дистәләрчә еллар дәвамында Венгрия Фәннәр академиясе архивында хәрәкәтсез ята.

Бу кулъязмалар турында беренче булып мәгълүмат бирүче кеше Будапешт университеты профессоры Жужа ханым Какук булды. Аның 1963 елда «Acta Orientalia» журналында басылган мәкаләсе[2] фәнни даирәдә

---

[1] *Dr. Ignace Kunos.* De la Poésie populaire Turque Ouvrage contenant les conférences tenues à ce sujet à l'Université de Constantinople.— Stamboul, 1925.— P.176.

[2] *Kakuk Suzanne.* Poésie populaire tatare recueillie par I.Kúnos//Acta Orientalia Academiae Scientiarum Hungaricae. Tomus XVI, fasciculus I.— Budapest, 1963.— P.83—97.

зур кызыксыну уятты. Әлеге мәкаләдән без Кунош туплаган татар фольклоры материалларының нигездә җырлардан һәм әкиятләрдән гыйбарәт булуын белдек. Туплам ике кисәктән тора икән: казан татарлары фольклоры һәм мишәр фольклоры. Ж.Какук Казан татарларының җырларын 1980 елда аерым китап итеп бастырды[1]. Соңрак шул ук университетның яшь галиме Имре Башки Кунош тупламындагы татар әкиятләренең кулъязмаларын Казанга алып килде. Аларны басмага әзерләгәндә татар фольклорчылары белән киңәшләшү зарурлыгы туган икән. Ниһаять, Казан татарларының әкиятләре дә мөстәкыйль китап булып нәшер ителде[2]. Соңрак бу китаптагы әкиятләр (барысы 14 текст) укучыларыбызга да барып җитте (Мирас.—1993. № 2—7, 9—12; 1994, № 1—4, 7—12). Өстәп шуны әйтергә мөмкин: Будапештта чыккан әлеге җыентыкларда фольклор әсәрләре латин шрифтына нигезләнгән транскрипциядә басылган һәм янәшә үк аларның алман теленә тәрҗемәләре дә урнаштырылган.

Кунош тарафыннан аерым тупланган мишәр фольклоры да 1996 елда аерым бер җыентык булып дөнья күрде. «Мишәр-татар текстлары...» дигән исем белән Сегед шәһәрендә басылган әлеге мәҗмугада[3] 273 җыр (дүртьюллыклар) һәм 7 әкият урын алган.

Безнең бу китапта казан татарларының әкиятләре һәм мишәр-татар әкиятләре бергә урнаштырылды, әмма аларның кайсы тупламга каравы искәрмәләр бүлегендә күрсәтеп барылды. Казан татарлары әкиятләреннән бары берсе — тылсымлы төргә караган исемсез бер фрагмент кына бу китапка кертелмәде. Әмма әлеге өзек «Тылсымлы көзге» дигән шартлы исем белән моңарчы дөнья күргән иде инде (Мирас.— 1994.— № 4, 81—83 б.).

Әйе, кешеләрнең генә түгел, хәтта әкиятләрнең дә үз язмышы бар. Бу бүлектәге әкиятләргә әнә шулай әсирлектә теркәлеп калырга язган икән. Шуннан соң алар озак еллар буе онытылып торган. Аннары игелекле кешеләрнең, төгәлрәк әйткәндә, венгр галимнәренең инициативасы белән алар дөньяга чыктылар, ахыр чиктә, исән-сау туган илгә дә кайтып җиттеләр, һәм бүген сез, хөрмәтле укучылар, шул җәүһәрләрне китап рәвешендә ку-

---

[1] Kasantatarische Volkslieder/Auf Grund der Sammlung von Ignac Kúnos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk (Oriental Studies 4).— Budapest, 1980.

[2] Kasantatarische Volksmärchen/Auf Grund der Sammlung von Ignac Kunos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk und Imre Baski (Oriental Studies 8).—Budapest, 1989.

[3] Mischärtatarische Texte mit Wörterverzeichnis/Auf Grund der Sammlung von Ignác Kúnos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk.— Szeged, 1996.

лыгызга тотып торасыз. Әлеге әсәрләрне укып ләззәтләнү һәркемдә дә зур канәгатьлек хисе калдырыр дип уйлыйм[1].

Китапның икенче бүлеге «*Көттереп килгән әкиятләр*» дип атала. Биредә шулай ук моңарчы бер җыентыкта да басылмаган, күбесенчә төрле архивларда кулъязма хәлендә сакланган текстлар урын алды. Соңгы чорда фольклор һәм диалектология экспедицияләре вакытында җыйналган, яисә һәвәскәрләр үзләре язып җибәргән кайбер әкиятләр дә шушы бүлеккә кертелде. Димәк, болар — укучыларыбыз өчен яңа әкиятләр, көтеп алынган, көттереп килгән әкиятләр. Аларның бер өлеше генә көндәлек матбугатта басылып чыкты.

Янә дә беренче бүлек белән охшашлыкның тагын бер ягы бар. Ул икенче бүлекне башлап җибәргән «Гали, Вәли һәм Гәрәй солдатлар» дигән әкияткә карый. Бу әкият «Мирас» журналында нәкъ менә «Әсирлектән кайткан әкиятләр» дигән баш астында Куношматериалларына кушымта рәвешендә басылып чыкты. Мин аны 1988 елда Татарстанның Баулы районы Бәйрәкә авылында Әнвәр Ильяс улы Яхиннан язып алган идем.

Бу әкиятнең үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: ул да шул ук әсирләр арасында сөйләнгән. Аңа юлыгуыбыз болай булды. Без, ягъни Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының (хәзерге вакытта: Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) фәнни хезмәткәре С.Гыйлаҗетдинов һәм бу юлларның авторы, 1988 елның җәендә фольклор экспедициясе белән йөргәндә Бәйрәкә авылында (хәзерге вакытта ул Ютазы районына керә) пенсионер Әнвәр Яхин белән очраштык. Әнвәр ага байтак еллар комбайнчы булып эшләгән, җор телле, күп укыган, бик кызыксынучан, энергиясе ташып торган мәгълүматлы кеше булып чыкты. Танышкач ук ул миңа: «Һәй, бик әйбәт булды бит әле бу, мин сезгә хат язып ята идем»,— диде. Әлбәттә, аның бу сүзләрен без шаяру дип кабул иттек, әмма ул шунда ук минем кулыма бер кәгазь китереп тоттырды. Анда болай диелгән иде: «*1987 елгы «Казан утлары»ның 8 нче санында Ленар Җамалетдиновның «Ак бүре»нең илгә кайтуы» дигән язмасын укыгач, 1937 нчеме, 1938 нчеме елларда*

---

[1] Кызыксынучыларга Куношның татар әсирләре арасындагы эшчәнлеге бәян ителгән түбәндәге мәкаләләрне тәкъдим итәбез:

Кунош И. Мөселман хәрби әсирләре лагерьларындагы эш турында // Мирас.— 1992.— № 5, 100 б.; *Аныкы ук:* Татар әсирләре янында // Идел, 1995.— № 7.— 36 б.; *Җамалетдинов Л.* «Ак бүре»нең илгә кайтуы // Казан утлары.— 1987.— № 8.— 180 б.; *Аныкы ук:* Венгр галиме татарлар арасында // Казан утлары.— 1990.— № 2.— 156 б.; *Аныкы ук:* Мишәр әкиятләре // Казан утлары.— 1999.— № 8.— 152 б.; *Аныкы ук:* Кем син, Идел егете // Социалистик Татарстан.— 1990.— 22 июль; *Аныкы ук:* Әсирлектән кайткан җәүһәрләр // Шәһри Казан.— 1997.— 31 октябрь.

Бәйрәкә авылының бер очын «Мадъяр очы» дип атарга сәбәпче булган Әхмәтов Закир агайның «Гали, Вәли һәм Гәрәй солдатлар» дип аталган әкият сөйләгәне искә төште һәм, чын-чыннан кабат искә төшереп, шуны язып җибәрергә булдым. Мадъяр — Венгрия бит инде, ә Әхмәтов Закир кайчандыр Венгриядә (аның әйтүенчә, Мадъярда) әсирлектә булган һәм шунда әсир солдатлар арасында йөргән әкиятләрнең берсен сөйләгән иде. Менә мин шуның төп эчтәлеген, аныңча матур сурәтләр таба алмасам да, кыскача гына язарга тырышып карыйм. Ул аны өчме, дүртме сәгать сөйләде, ә язар өчен өч-дүрт көн вакыт кирәктер кебек тоела. Ә минем аңарга түземлегем җитәрме, юкмы, шулай да язып карарга булдым. Әнвәр Яхин. Баулы районы, Бәйрәкә авылы, 1988 ел».

Шушы кереш сүздән соң әкиятнең баш өлеше язып куелган иде. Мин үзем, мәсәлән, Әнвәр ага кебек булдыклы кешенең түземлеге җитмәсенә ышанып бетмәдем, әкият барыбер азагынача язылыр иде. Әсәрнең шунда өзелеп калуына төп сәбәп, әлбәттә, вакыт җитмәүдә. Авыл кешесенең, бигрәк тә җәй айларында, язу-сызу шөгыле белән утырырга һич тә мөмкинлеге юк. Менә без очрашканда да Әнвәр ага әрҗәле мотороллеры белән каядыр барырга чыккан иде. Шуңа күрә әкиятен дә кәгазьдә тукталып калган төштән генә сөйләп китте, ә баш өлешен мин әлеге кәгазьдән күчереп алдым.

Әйе, бу әкиятнең Кунош тарафыннан язып алыну ихтималы да булган. Әмма әкият әсир солдатның үз хәтерендә генә кала биргән һәм 70 елдан соң әлеге әсәрне Закир Әхмәтовның туган авылында миңа язып алырга насыйп булган икән; әлбәттә инде, үз авызыннан түгел, бәлки, аңардан отып калып, дистәләрчә еллар дәвамында күңелендә кадерләп саклаган авылдашы Әнвәр ага Яхиннан. Бу да — язмыш.

Җыр, бәет, мөнәҗәт кебек тезмә әсәрләрне дәфтәрләренә язып саклаучылар еш очраса да, әкият кебек күләм ягыннан зур булган чәчмә әсәрләрне кәгазьгә төшерүчеләр бик сирәк. Шундыйларның берсе — Ырынбур өлкәсендәге Якты Күл авылында яшәүче, бүгенге көндә инде 80 яшен узып киткән Сәйдә әби Сафина. Икенче бүлектә аның да «Җен кызы Гөлбану», «Булдыклы егет һәм Сәмрук патша» дигән ике әкияте урын алды.

Сәйдә әбинең хаты безнең кулга Татарстан радиосы аша килеп керде. Хатында ул үзенең яшь чагында әкиятләр, бәетләр тыңларга яратканлыгын, шуларның истә калганнарын Казанга язып җибәрергә теләвен әйткән. Максаты үтә гади: гәзит һәм журналларда бастыру өчен түгел, бәлки, үзенең истәлеге булып ышанычлы кулларда саклансын өчен генә. Әмма бер кыенлык бар икән — язмаларын ничек җибәрергә белми, конвертка сыймас, дип шикләнә. Хатының азагында, гафу үтенгәндәй, өстәп куйган: «Мин үзем 4 класс кына бетердем,— дигән.— Бик ярлы булганлыктан, укырга мөмкин-

лек булмады. Без укыганда латин хәрефе иде, моны (ягъни кириллицаны.— *Л.Җ.*) үзем генә өйрәндем, бәлки, танырсыз»,— дигән.

И бу берничә генә сыйныф укып калган укымышлы татар әбиләре! Үзлекләреннән өйрәнеп, өч төрле графикада язылганнарны су кебек эчүче һәм шул өч графика белән яза ала торган могтәбәр затларыбыз! Бер генә әлифба-язуны белүче бүгенге дипломлы яшьләргә дә алыштыргысыз бит сез! Сез бит чын галимәләр!

Икенче бүлеккә А.Бессонов (1848—1917) тарафыннан язып алынган ике әкият керде. Бу фидакарьнең XIX гасыр азагында һәм XX гасыр башында Урал төбәгендә татар, башкорт һәм казакълар арасында җыйган әкиятләренең кулъязмалары, дөресрәге, әлеге әкиятләрнең рус теленә тәрҗемәләре, Санкт-Петербургта Рус География җәмгыяте архивында саклана. шулар арасында 61е — татарныкы.

А.Бессонов әкиятләрне үзе эшләгән төбәкләрдә 30 елдан артык вакыт дәвамында туплаган. Ләкин күпме генә тырышмасын, үз гомерендә бер әкиятен дә бастыра алмаган. Шулай да игелекле эшен туктатмаган.

Күренекле тюрколог А.Самойлович А.Бессонов җыйган әкиятләргә югары бәя биргән. Ул шулай ук русчага тәрҗемәләрнең ни дәрәҗәдә дөрес, төгәл булуын да тикшергән һәм канәгатьлек белдергән. Аның бәяләмәсе нигезендә А.Бессоновка әлеге әкиятләр җыелмасы өчен Рус География җәмгыятенең кече алтын медале тапшырыла[1]. Кызганыч, әкиятләрнең милли телләрдәге нөсхәләре югалган. Күрәсең, алар А.Самойловичта калып, шушы олуг галимнең үзе белән бергә 1937 елда юкка чыккан.

Шулай итеп, XIX гасырда һәм XX гасыр башында язылган әкиятләр XXI гасырга аяк басканда гына дөнья күрә башладылар. Әлеге дә баягы — язмыш...

Бу китапның өченче бүлеге *«Сагындырган әкиятләр»* дип атала. Мәгълүмдер ки, кайчандыр үзең күргән-белгәнне генә сагынырга мөмкин. Димәк, биредәге әкиятләр — заманында дөнья күргән әсәрләр. Әмма төрле сәбәпләр аркасында алар кабат басылмаганнар, шунлыктан кайберләре хәтта онытылган да. Менә, мәсәлән, бүлекне башлап җибәрүче «Баһадиршаһ вә гөмбә хикәясе» дигән әсәр. Ул XIX гасырның азагында аерым китап булып басылган булган. Ул китапны бүген кем генә белә икән? Аны укыган кешеләрдән берәрсе бу фани дөньяда калдымы икән? Бу әсәрдә халкыбызның башка әкиятләре буенча таныш сюжетлар янәшәлек итсәләр дә, кешенең гөмбәгә әверелеп, максатына ирешүе белән тыгыз бәйләнгән үзәк сюжет

[1] Бу турыда: *Җамалетдинов Л.* Алтын медальле әкиятләр // Социалистик Татарстан.— 1983.— 29 апрель.

моңарчы без белгән әкиятләрдә очрамый. Әйтергә кирәк, хаксыз онытылган бу әкият.

«Баһадиршаһ...»ның теле дә аның күптәнге әсәр булуына ишарә итә. Әкиятне басмага әзерләгәндә, беренче мәртәбә китап рәвешендә дөнья күргән замандагы рухны саклау ниятеннән, аның телен һәм стилен мөмкин кадәр оригиналдагыча калдырырга тырышылды. Мәсәлән: берлән (белән), егълау (елау), илә (белән), кеби (кебек), максуд (максат) һ.б. сүзләр, әдәбиятыбыз классикларының әсәрләрендә дә еш очраганлыктан, һәркемгә җиңел аңлашылалар. Шуңа күрә әлеге сүзләр иске язылышында бирелде. Аңлавы авыррак булган гарәп-фарсы алынмалары да шул көенчә калды, әмма һәр урында бит астында аларның мәгънәсе күрсәтеп барылды. Димәк, әкиятнең лексикасына бер үзгәреш тә кертелмәде дигән сүз. Бары тик, еш очраганлыктан, текстны артык чуарламау максатыннан, берничә генә сүзгә бәйле фонетик үзгәртү ясалды. Әйтик, төшем килешенең иске варианты яңача бирелде: кызыны — кызын, нәрсәләрене — нәрсәләрне. Бу хәл тартым кушымчаларына да кагыла: баламыз — балабыз, балаңыз — балагыз, хәлемез — хәлебез, хәлеңез — хәлегез. Текстта янә дә шуңа охшаш төзәтү кертелгән тагын берничә сүз очрар: килеңез — килегез, сораңыз — сорагыз, һәркаюсы — һәркайсы һ.б.

Ә менә «Шәйдулла» дигән әкиятнең тарихы тагын да элеккерәк дәвергә карый. Ул 1891 елда «Акмолинские областные ведомости» дигән гәзитнең «Особое прибавление» дип исемләнгән кушымтасында (№ 5, 2—7 битләр) рус һәм кыргыз (казакъ) телләрендә басылган. Русчасына җәя эчендә «татарская сказка» дип, ә гарәп хәрефләре белән басылганына «нугай иртәгесе» (ягъни «татар әкияте») дип куелган. Әкиятне 1888 елда Шемаха шәһәреннән Александр Калашев дигән укытучы язып җибәргән.

«Шәйдулла» уңае белән шуны да әйтеп узыйк: Мәскәү китапханәсендә бу әкиятне табып, текстны матбугат өчен әзерләп бетергәч, шушы ук сюжетка корылган бер әсәрнең күп еллар элек әзәрбайҗан әкияте дип басылганлыгы мәгълүм булган иде. Әйе, моңа нигез дә юк түгел кебек. Шемаха хәзерге Чиләбе өлкәсендә генә түгел, Әзәрбайҗанда да бар, һәм әзәрбайҗан милләтен руслар элек «татар» дип атап йөрткәннәр. Әкияттәге Ходай образы да шикләндерде, ул, гомумән алганда, татар әкиятләренә хас түгел. Икенче яктан караганда, ярый, шул ук XIX гасырда яулап алынган Шемаха шәһәрендә әзәрбайҗан телен яхшы белгән рус кешесе булсын да, ди, әмма нигә ул әзәрбайҗан әкиятенерактагы казакъ иленең нәкъ менә Акмулла өлкәсендә (ул вакыттагы үзәге — Омски шәһәре) чыга һәм шул өлкәгә хезмәт итә торган гәзиткә язып җибәргән икән? Ә Чиләбе төбәгендәге Шемаха исә Акмуллага шактый якын, җитмәсә, шул ук төбәктә нугайбәкләр

дип йөртелгән керәшен татарлары оешып яши (Александр Калашевны да бу очракта керәшен дип фараз кылыйк), һәм казакълар «нугай» дип әзәрбайҗаннарны түгел, ә татарларны атыйлар. Әкиятнең теле дә татарча, «нугай иртәгесе» дигән тәгъбирдән башка, анда «саф казакъча» ничә генә сүз бар икән?

Татар «файдасына» сөйли торган тагын бер факт бар: шушы ук сюжетка корылган «Әшлексез кеше» дигән әкият 1940 елда Г.Толымбай тарафыннан Татарстанның Буа районында язып алынган. Бу китапта әлеге әкият «Шәйдулла» белән янәшә үк урнаштырылды (Г.Толымбай вариантының соңгы тапкыр дөнья күрүенә дә кырык елга якын вакыт узган).

Гомумән алганда, төрки халыкларның әкиятләрендәге охшашлык — табигый күренеш, әмма вак детальләргә кадәр тәңгәллекләр игътибарны аеруча җәлеп итә һәм җентекле тикшерүне сорый. Киләчәктә, әлбәттә, бу әкиятләрнең сюжеты тәфсилләрәк өйрәнелер.

Өченче бүлектәге «Тимеркендек» әкияте (В.Радлов язмасы) соңгы тапкыр 1956 елда эшкәртелеп басылган иде. Бу китапта исә, әсәргә йилбегән (диюгә охшаган мифик зат) образы кире кайтарылып, текст Радловтагыча беренчел шәкелен алды.

«Тимеркендек» кебек үк күптәннән кабат дөнья күрми яткан бүтән әкиятләрнең басмалары XX гасырның 40—70 нче елларына карый.

Бу бүлеккә тагын берничә әкият исемнәре үзгәрү сәбәпле кертелде. Хикмәт шунда: әлеге әсәрләрдән кайберләренең исемнәре җисемнәренә туры килми, яисә берничә әкият бер үк исем белән йөри. Соңгылары укучыларга да, тикшеренүчеләргә дә билгеле бер уңайсызлык тудыра. Мәсәлән, «Кәҗә белән Сарык», «Салам-Торхан», «Камыр батыр», «Үги кыз» исемнәре белән әллә ничәшәр текст басылган.

Тикшеренүчеләр исә, К.Насыйри варианты, Г.Толымбай варианты, Г.Бәширов яисә Ш.Маннур варианты дип, бу кыен хәлдән чыксалар, гади укучы анысыннан да мәхрүм. Беренче карашта моның әллә ни әһәмияте дә юк шикелле. Әмма алай түгел шул. Бер үк исемдәге кешеләрне дә берберсеннән аеру өчен нинди дә булса кушамат тагалар. Бер үк сюжетка нигезләнгән әкиятләрдә дә һәр текстның үз исеме булырга тиеш. Шулай җайлы. Дөрес, бу эш моңарчы да барды: мәсәлән, кайбер текстлар җыентыкларда «Кәҗә тәкәсе белән Сарык тәкәсе», «Салам-Торхан һәм Төлке» исемнәре белән басылды. Мәгълүм ки, төп герое (геройлары) бер үк булса да, текстларда нинди дер аерымлыклар, үзенчәлекләр булмый калмый. Шуннан чыгып, исем кую белгечләргә йөкләнергә тиеш. Шул чагында гына тәртип булачак.

«Камыр батыр» әкиятенә килсәк, бу исем белән күп мәртәбәләр басылган һәм дәреслекләргә дә кертелгән Г.Бәширов варианты киләчәктә дә шул

ук исемдә калыр. Ә «Халык иҗаты» җыентыгында (Казан, 1940) чыккан текст «Чукмарлы Камыр батыр» дип, 1977 елда кабатлап басылган Г.Рәхим варианты «Камыр батыр һәм Сәмруг кош» дип аталачак (әлеге әкиятләр бу китапка кертелмәде). 1946 елда ук «Камыр батыр» исеме белән басылып чыккан һәм шуннан бирле кабат дөнья күрмәгән Г.Толымбай варианты исә бу китапка «Мичтә туган Камыр батыр» исеме белән керде.

«Салам-Торхан» турында берничә сүз. Беренче булып шушы исемдәге әкиятне К.Насыйри бастырган. Игелекле эшкә керешкән Каюм бабага хөрмәт йөзеннән бу әкиятнең исеме үзгәрешсез калсын. Ә Ш.Маннур варианты 1989 елда «Салам-Торхан һәм Төлке» исеме белән басылып чыккан иде инде (ТХӘ, 1989, 36 б.). Бу китапка кертелгән Г.Толымбай язмасы (ул бүген, популяр вариант буларак, балаларга адресланып, аерым китап рәвешендә дә нәшер ителә тора), эчтәлегеннән чыгып, «Кәҗәле Салам-Торхан» дип аталды. Балалар өчен дә бу исем кыен түгел, киресенчә, мавыктыргыч булырга мөмкин.

Бу китапта әлеге сюжетка нигезләнгән тагын бер вариант очрар. Ул «Салам-Торхан һәм алтын пароход» исеме белән, китап төзелеше принцибына туры китереп (ягъни моңарчы басылмаган текст буларак), икенче бүлеккә урнаштырылды.

«Искәрмәләр»дә, һәр әкиятнең паспорты белән бергә, шул әкияткә бәйле өстәмә мәгълүматлар да биреп барылды, әйтик, текстларның беренче яки соңгы абруйлы басмасы аталды (бу очракта абруй төшенчәсе текстка карата гына кулланыла), әкиятнең исеме үзгәртелгән очракта, аның соңгы басмадагы элекке исеме дә күрсәтелде. Шуның өстенә текстларның үзгәртүләрсез диярлек басылуы (кайбер сүзләрнең төрле әкияттә төрлечә язылуы да шуннан килә, мәсәлән: җылый-елый, җигән-җөгән-җүгән-йөгән, пич-мич һ.б.), бу кереш мәкаләдәге аңлатмалар, ахыр чиктә, әкиятләргә тәртип саны куелу — җыентыкның бер үк вакытта фәнни басма булуын да күрсәтеп тора.

Инде өстәп шуны да әйтик: әкиятләр белән эш итүче зат, ягъни бу әсәрләрне үзенең хезмәтләрендә файдаланучы, бигрәк тә теге яки бу максатта дөньяга чыгаручы автор текстның бары тик соңгы басмасын гына алырга тиеш. Югыйсә кайбер әкиятләрнең төзәтелгән тексты булуга карамастан, иске басмалардан алынган камил булмаган текстлар әледән-әле чыга тора. Нәшер итү белән бәйле ихтыяҗ булганда иң яхшысы — белгечләргә мөрәҗәгать итү. Кешеләрнең генә түгел, әкиятләрнең дә үз язмышы барлыгын онытмасак иде.

Ленар Җамалетдин

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Әсирлектән кайткан ӘКИЯТЛӘР

I

1. Патшаның өч улы

Борын заманда бар иде бер патша, аның өч улы бар иде. Боларның бар иде алма бакчалары. Бу бакчада һәр көн бер алма пешә торган иде дә шул ук көнне югаладыр иде. Патша бакчага сакчылар куйды. Сакчылар никадәр йокламаска тырышсалар да, таң алдыннан йокы басадыр иде дә йоклап китәләр иде. Күзләрен ачуга алма да юк буладыр иде.

Сакчылар бу эшне булдыра алмагач, патшаның олы улы, атасына әйтеп, бер кичне сакларга кереште. Патшаның олы улы төн буенча йокламады, таң алдында бик йокысы килгәч, чыдамады, черем итте — алманы бу да югалтты.

Нәүбәт икенче улына килде. Бу да, атасыннан сорап, бакчаны сакларга кереште, бу да, агасы кебек төн буенча чыдап, таң алдыннан йокыга китеп, алмадан колак какты.

Инде нәүбәт кечкенә улына җитте. Кечкенә улы көндез йокысын бик ныгытып, төнне сакларга кереште. Таң атар алдыннан гына бер бик матур алтын кебек ялтыраган кош килә дә алманы алып китә. Бу бик ачык күреп кала һәм ни күргәнне атасына кереп сөйли.

Аталарының бу кошны бик күрәсе килә. Бу малайлар өчесе дә, аталарының боерыгы белән атларның бик яхшыларын сайлап алып, алмас кылычны билгә тагып, кирәгенчә алтын алып, юлга чыгып киттеләр.

Бара торгач, болар өч аерымлы юлга очрыйлар. Юлларның башына тактага: «Уңга киткән уңар; уртага киткән йә уңар, йә уңмас; сулга киткән кире кайтмас»,— дип язып, кадакланып куелган иде. Болар шобага салыштылар. Олысына уңга, уртанчысына уртага, кечкенәсенә сулга китәргә чыкты. Болар, саубуллашып, үзләренә чыккан юл белән киттеләр.

Кечкенә туганнары ай китте, ел китте, бара торгач, бер убырлы карчыкка очрады. Йә мин, йә син» дип, алмас кылычны алып карчыкны чапкан иде, карчыкның башы өзелеп җиргә төште.

Бераз баргач, очрады бер бүрегә. Егет бүрегә килеп җиткәч тә, бүре моның атын бәреп ташлады һәм егеткә:

— Атыңны бирәсеңме, җаныңны бирәсеңме? — диде.

Егет атын биреп, «җан булса, ат та булыр» дип, җәяү китте. Бара торгач, әйләнеп караса, бүре тагы моның артыннан килә. Егет, «инде атымны ашады, үземне ашарга килә икән» дип, бүренең килеп җиткәнен көтеп торды. Бүре килеп җитте дә:

— Әй, егет, син мин әйткәнне тыңладың, инде синең ни үтенечең бар, әйт,— дигәч, егет эшнең ничек икәнен сөйләп бирә.

Бүре тыңлап торып:

— Ай-һай, егет, бик кыен эшкә тап булгансың икән, ул бик ерак бит,—диде,— әйдә, атлан минем өстемә,— дип, егетне үз өстенә атландырып китә.

Бара-бара болар бер шәһәргә барып җитәләр. Бүре егеткә:

— Фәлән сарайда алтын койрыклы, көмеш яллы бер ат бар, шул атны алып чыга алсаң, шуңарга атланып китәрсең, ләкин җигәненә тимә, җигәнсез генә алып чык,— дип, егетне өйрәтеп җибәрә.

Егет, ничек кирәк алай, атның сараена барып керә. Сарайда көмештән кыйммәтле, алтыннан бәяле ташлар белән эшләнгән җигәнне күреп бик кызыга, «җигәнне дә алып чыгарга кирәк» дип, җигәнгә кулын тигергән иде, патшаның сакчылары егетне тотып алдылар да патша янына алып китерделәр.

Патша:

— Ни өчен болай эшләдең? — дип егеттән сорый.

Егет патшага эшнең ничек булганын, үзенең патша баласы икәнен сөйләп бирә.

Патша:

— Алай булгач, мин сиңа айгыр бирәм, ләкин кайтышлый кире китерерсеңме? — дигәч, егет, күнеп, айгырны бик яхшылап иярләп һәм җигәнләп, атланып чыгып китә.

Бүре дә юлда гына көтеп тора икән, егетнең сау-сәламәт атны алып чыкканын күреп, бик куана. Бүре:

— Әйдә инде, егет,— дип, егет атлы көенчә, бүре моның яныннан — юл белән юртып китәләр.

Озак бара торгач, бер патшаның шәһәренә барып җитәләр.

Бүре егеткә:

— Инде, иптәш, кош шушы шәһәрдә, патшаның сараенда, алтын читлектә. Читлек янында бер кыңгырау бар, ул шылтыравыкка тия күрмә. Кошны читлеге белән ал да чык,— дип, егетне кертеп җибәрә.

Егет, кереп, кошны читлеге белән кулга алгач: «Һәй, бу шылтыравыктан берни булмас, басып чыгыйм»,— дип, шылтыравыкка баскан иде, шылтыравык шундый каты шылтырап та китте. Егетне, төрле яктан килеп камап алып, тотып алдылар да патша янына китерделәр.

Патша:

— Ни өчен болай урлыйсың? — дип сорашты.

Егет үзенең патша баласы икәнен сөйләп, эшнең ничек икәнен аңлата.

Патша:

— Кошны сиңа бирәм, тик бер шартым бар. Фәләнчә шәһәрдә бер патша бар, аның бик матур бер кызы бар, шул кызны китереп бирсәң, кош синеке булыр,— диде.

Егет, күнеп, башын түбән салып, сахрага килеп чыкты. Бүре дусты, егетне каршы алып:

— Ни булды? — дип сораша башлады.

Егет:

— Иптәш, эш кыен, менә фәләнчә патшаның кызын китереп бирергә куштылар,— дигәч, бүре:

— Һәй, ул бик ансат эш, менә мин шул кызның тап үзе булырмын, син мине алып кереп, «килдем» дип, кертеп бирерсең дә, кошны алып юлга чыгып барганда: «Әй, бүре дустым кая икән?» — дип, исеңә төшерсәң, мин шул сәгать янында булырмын,— диде дә, бүре патшаның менә дигән кызы булды.

Егет бу кызны патшага алып кереп бирә. Патша егеткә бик күп рәхмәтләр укып һәм бик яхшы кунак итеп, кошны биреп юлга озата.

Бүре, бераз торгач, патшага:

— Мин бераз бакчага чыгып йөрер идем,— дигәч, патша рөхсәт бирә.

«Кыз», бакчага чыгуга яңадан бүре булып, коймадан сикереп чыгып, егетне куып җитә.

Егет бүрегә:

— Инде ул кызны да үзебезнең шәһәргә алып кайтыйк,— ди.

Бүре, «ул да булыр» дип, егеткә:

— Менә фәләнчә бакчада фәлән тирәкнең астында бер тәхет булыр, кыз хәзер шунда йоклап ята. Син атыңны коймадан сикертеп кер дә кызны, әкрен генә атыңның өстенә салып, тагы коймадан сикертеп алып чык. Кара, үзең егылып төшмә,— дип, өйрәтеп, егетне кертеп җибәрә.

Егет бүре әйткәнчә керә дә кызны алып чыга. Болар өчәүләшеп, кызны да алып, юлга төшеп китәләр.

Бара торгач, бүре:

— Инде мин монда калам, тик сиңа киңәшем шул: фәләнчә урманны үткән чакта, зинһар, йоклама,— дип, үгетләп, озатып җибәрә.

Егет бик күп юл барганнан соң, урманга барып кергән иде, бик йокысы килә башлады, һич чыдарга әмәле калмады. Булдыра алмады, атыннан төште дә, бераз гына яткан иде, йокыга китте.

Күп вакыт та үтмәде, егетнең ике абзасы моның тап өстенә килеп чыктылар. Болар атны да, кызны да, кошны да күреп, энеләренә бик көнчелекләре килеп, икесе үзара сөйләшеп, «әгәр бу алып кайтса, безгә бик хурлык булыр» дип, кылычларын алып, энеләренең башын кисеп төшерәләр дә, атны, кызны һәм кошны — барын да алып китәләр.

Юлда барганда, кызга:

— Сине без таптык, дип сөйләрсең, юкса син дә харап буласың,— диделәр.

Зур куаныч белән өйләренә кайтып керделәр дә аталарына китереп бирделәр.

Болар кызның туен итәргә хәзерләнеп ятсыннар, менә бер заман йөреп торгач, бүренең күзеннән кан тама башлай. Бүре: «Шул иптәшемә берәр хәл булмаган микән»,— дип, урманга килеп эзли башлый. Йөреп торгач, дусты — егетне таба. Башы бер якта, гәүдәсе бер якта. Бүре бер мәчене тотып ала да үле суы белән тере суы алып килергә куша. Мәче тиз генә алып китереп бирә. Бүре, суны сибеп, егетне терелтә дә аңа барлык нәрсәне сөйләп бирә. Һәм егеткә:

— Өч тапкыр мин әйткән нәрсәгә каршы килдең, бар, кайт инде. Кыз сезнең сараегызда булса да, җылаудан башы чыкмый. Кош та сайрамый, ат та печән, җим ашамый. Алар бар да сине көтәләр,— ди.

Егет, бик куанып, күп рәхмәтләр укып, бүре белән саубуллашып, кайтып китә.

Егет шәһәрләренә кайтып, сарайларына барып кергән иде, кыз аның муенына килеп асылынды. Кош чут-чут итеп сайрый башлады. Ат, кешнәп, моның янына сараеннан чабып чыкты. Патша күрде дә хәйран калды. Абзалары да күреп, бер сүз әйтә алмыйча телсез калдылар. Патша эшне кечкенә улыннан сорый, улы барын да сөйләп бирә.

Атасы ике олы улына:

— Сез энегезгә мондый хыянәт кылгач, сездән дөньяда башка яхшылык көтәргә урын юк,— дип, икесенең дә башын кистерә.

Шуннан соң патша үзенең бөтен патшалыгын кечкенә улына биреп, кызны егеткә никахлап, кырык көн туй, кырык көн уен ясап, әле дә булса матур гына яшәп яталар, ди.

2. Батман бабай

Бар иде бер бай, аның бар иде өч кызы, Амата исемле бер улы. Бай үзе үлгәндә Аматага мирас итеп бер таяк һәм бүрек калдырды һәм: «Нинди хәерче килсә, кызларны шуңарга бирерсең»,— диде. Бай озак авырып ятмыйча җан бирде. Амата атасын кадерләп, күп акчаларны өләшеп күмде.

Иртәгесен, намаздан кайтып килгәндә, Амата капка төбендә бер хәерчегә очрады һәм аны өенә алып керде. Хәерчегә:

— Инде, бабай, минем атамның сүзе буенча бирәчәк нәрсәм шул,— дип, олы тәтәсен картның кулына китереп тоттырды.

Карт күп рәхмәтләр укып, кызны алып чыгып китте. Капканы гына чыкканнар иде, карт җиргә күтәрелеп бәрелде дә җитмеш биш башлы дию булды.

Икенче көнне икенче хәерче килде. Егет ул хәерчегә тагы:

— Сиңа бирәсе нәрсәм шул булсын, атабызның да сүзе шулай,— дип, икенче тәтәсен китереп тоттырды да,— инде моннан соң син хәерче булып килмәссең, кияү булып килерсең,— диде.

Бу хәерче дә капканы чыгып җиргә бәрелде дә егерме биш башлы дию булды.



Өченче көнне өченче хәерче килгән иде, аңарга кече тәтәсен биреп җибәрде. Кече кияү дә, капканы чыгуга җиргә бәрелеп, тугыз башлы дию булды. Егет, исе китеп, артларыннан карап калды. Туталарын кызганса да, атам белмичә әйтмәгәндер дип, үзен-үзе басып калды.

Соңра егет өендә берүзе генә калды. Бик эче пошкач: «Тукта, мин барып, аларның тормышын күреп кайтыйм»,— дип, бүреген башына киеп, таягын кулына алып, бер юл белән чыгып китте. Урамга чыккач та, моны һич кеше күрмәс булды. Бераз баргач, хәле бетә башлагач, таягын аяк арасына куйган иде, таяк җилләндереп алып та китте.

Озак бармады, олы тәтәсенә барып та җитте. Өйләренә кереп, тутасы белән исәнләшеп, аның хәлен сорашты. Тутасы үзенең тормышыннан разый иде.

Болар сөйләшеп утырганда дию дә кайтып керде. Тутасы, куркып, энесен яшереп куйды. Дию кайтып керүгә, борынын күтәреп:

— Фу, адәм исе килә, кем бар, әйт тизрәк? — диде.

Тәтәсе никадәр әйтмәскә тырышып караса да булдыра алмады:

— Энем монда,— диде.

Дию:

— Ник син аны яшерәсең, чыгар, кунак итик,— диде.

Егет чыгып утырып, дию белән күрешеп, хәл-әхвәл сораштылар.

Дию:

— Кая барасың? — дип сорагач, егет:

— Сез киткәч озак үтмәде, төшемдә бер кыз күрдем, шуны эзләп барам,— диде.

Дию:

— Соң син ул кызның кайсы шәһәрдә икәнен беләсеңме? — диде.

Егет:

— Беләм, Пыяла шәһәрендә,— диде.

Дию:

— Син бит анда бара алмассың, ул патша кызының бер кошы бар, ул кош шәһәргә һичбер кемне якын җибәрми, авызыннан ут чәчеп кешене һәлак итә. Менә мин өч көндә бөтен дөньяны әйләнеп чыгам, алай да барырга кыймыйм,— диде.

Егет:

— Ни булса да булыр, мин барып карыйм әле,— дигәч, җизнәсе:

— Алай булса, мин сиңа бер ак яулык бирәм, ашыйсың-эчәсең килгәндә шул яулыкны җәеп, үзеңнең тамагыңны туйдырырсың,— диде.

Егет, күп рәхмәтләр укып, таякка атланып юлга чыгып китте.

Берничә көн барганнан соң, уртанчы тәтәсенә барып җитте. Өйләренә кереп сөйләшеп утырганда җизнәсе булган дию кайтып җитте. Тәтәсе, күрсәтмәскә тырышып, энесен яшереп куйды.

Дию өйгә кергәч:

— Адәм исе килә, тиз әйт, кем бар? — диде.

Кыз әйтмәскә тырышып караса да, булдыра алмады, бик кыстагач:

— Энем бар,— диде, энесен чыгарып, дию белән таныштырды.

Егетнең җизнәсе:

— Яхшылыкка яманлык итмик, син безгә яхшылык иттең,— дип, кунак итеп,— кая барасың? — дип сорады.

Егет:

— Пыяла шәһәренә барам,— диде.

Дию:

— Белмим, анда барып җитә алырсыңмы икән, ул моннан бик ерак, мин дөньяны алты көндә әйләнеп чыгам, шулай да анда барганым юк, аның кошы беркемне дә якын җибәрми,— диде.

Егет:

— Ни булса да булыр, инде анда бармыйча каласым юк,— диде.

Чыгып киткәндә дию бер кызыл яулык биреп озатты. Амата өйдән чыгуга, таякка атланып, күздән югалып китте.

Берничә көн үткәч, егет кече җизнәсенә барып керде. Кече җизнәсе дөньяны тугыз көндә әйләнеп чыга ала иде. Аларда олы җизнәләрендә кунак булган кебек кунак булды. Кече җизнәсе яшел яулык бирде. Чыгып киткәндә Амата, бер стакан су тутырып биреп:

— Әгәр дә бу су кызыл булса, мин исән булмам, теләсәгез, мине эзләргә чыгарсыз,— диде.

Амата берничә көннәр шәһәргә таба китте. Шәһәргә җитеп барганда каршында ут тавы күрде. Моннан үтеп булмас, дип, бер агач аударып, өстенә атланып, судан йөзеп китте. Суда барганда моны ут кимәсендәге кешеләр күреп тотып алып, патшаның кызына илтеп тапшырдылар.

Патша кызы үзенә тотып китерелгән һәр кешене таш зинданга яптырып куя иде, моны да шулай яптырды. Зинданда барлыгы өч йөз кадәр кеше бар иде. Амата алар янына барып кергәч тә, алардан күпме ятуларын сорашты. Алар төрлесе төрлечә яталар иде: кайсы биш ел, кайсы өч ел, кайсы бер ел, айлап, атналап — төрлечә ятучылар бар иде. Боларга эчәргә бер стакан су, тәүлегенә бер уч арыш биреләдер иде.

Амата, болардан бу сүзләрне ишеткәч: «Юкка аптырамагыз»,— дип, ак яулыкны чишеп җибәргән иде, бөтен зиндан эче тулы мәҗлес булып, музыка да уйнарга тотынды. Бөтен зинданда булган кешеләр, бар кайгыларын онытып, күңел ачтылар.

Кыз, музыка тавышын ишетеп: «Бу Ходай органнар ни кыланып яталар»,— дип, сарайны ачтырып карады. Ачып карасалар, бөтен ябылган кешеләр ашау-эчүдә, уйнау-көлүдә. Һичбер нәрсә исләрендә дә юк. Кыз, аптырап, боларны бу сарайда гына тоту аз икән дип, чуен сарай эшләтеп, боларны шунда яптырып куйды. Тирә-ягына сакчылар куеп: «Уйнамасыннар, эчмәсеннәр!» — дип боерды.

Сакчылар берничә көн торып, болар тагы уйныйлар. «Болар зинданның ни икәнен дә белмиләр»,— дип, кызга сөйләделәр. Соңра кыз, инде болардан бөтенләй котылмыйча әмәл юк дип, чуен сарайның тирәсенә утын өйдереп, ут төрттерде. Сарайның стеналары кып-кызыл булып кызды.

Амата ак яулыкның бер нүвешен[1] чишеп җибәргән иде, бөтен зиндан эче су булып, төрле җәнлекләр суда йөзеп йөри башладылар. Утның кызуын бар дип тә белмәделәр.

Кыз, ике-өч көн үткәч, утыннар янып беткәч: «Инде сөякләре көл булгандыр»,— дип, тегеләрне чыгарып ташларга кушты. Ишекне ачып карасалар, бөтен төрмә эче су, балыклар, җәнлекләр йөзеп йөри. Андагы кешеләр һичбер нәрсә булмаган кебек ашап-эчеп, сөйләшеп-көлешеп утыралар.

Бу күренешләрне күреп, кызга килеп сөйләделәр. Кыз: «Инде боларны ни эшләтим?» — дип, кире таш сарайга яптырды.

Амата кызыл яулыкны чишеп җибәргән иде, бөтен сарайны тетрәтеп музыка уйнарга тотынды. Төрмә эчендәге кешеләр бар да сикерешеп торып, култыклашып алып, биергә тотындылар.

Кыз, музыка тавышын ишетеп:

— Музыкаларын миңа биреп торсыннар,— диде.

Аматага килеп сөйләделәр, ләкин Амата әйләнеп тә карамады: «Үзе килсен»,— диде.

Кыз, музыкага бик кызыгып, сорарга үзе килде. Амата кече җизнәсе биргән яшел яулыкны чиште. Кыз, чыдый алмыйча, биергә тотынды. Соңра музыканы туктаттылар. Кыз никадәр ялынып сораса да, Амата бирмәде:

---

[1] *Нүвеш* — почмак.

— Үзең миңа килмәсәң, һич бирәсем юк, үзең ят та, мине дүрт батыр синең өстеңдә күтәреп торсыннар,— диде.

Кыз, музыканы аласы килеп, күнде. Амата яулыкны башкасына биреп:

— Ярты сәгатьтән соң ике нүвешен чишәрсең,— диде.

Аматаны кыз өстендә бер сәгать тотып торырга булдылар. Ун минут калганда, яулыкны чишкәч, Аматаны тоткан кызлар, Аматаны кыз өстенә ташлап, үзләре биергә тотындылар. Соңра кыз — Аматаныкы, Амата — кызныкы булды. Кыз: «Инде син минеке»,— дип, туй ясап, Аматага барды.

Амата кыздан:

— Бу тоткыннарың күпме яталар? — дип сорады.

Кыз:

— Төрлесе төрлечә яталар,— диде.

Егет, ул тоткыннарны чыгарып, һәммәсенә берәр кыз табып өйләндереп, музыка уйнатып, туй ясап, өйләренә кайтарып җибәрде. Кызны, инде син бераз ул тоткынлыкның тәмен татып кара, анда яту ничек икәнен бел, моннан соң кешене рәнҗетмә, дип, ике тәүлеккә зинданга салды. Кыз бер тәүлектән соң чыдый алмады, Аматага бик ялынып, чыгарырга сорады. Амата: «Инде белдеңме?» — дип, бер тәүлектән соң чыгарды.

Кыз, зинданнан чыккач, үзенең бер дустына кунаклый барырга сорады. Амата риза булып, кыз җыена башлады. Кыз киткәндә Аматага балчык белән сылап куелган унөч сарайның ачкычын биреп, унөченчесен ачмаска кушты.

Егет, берничә көн чыдагач, ни булса да булыр дип, сарайны ачып җибәрде. Сарайда җитмеш башлы бер дию күрде. Аны җитмеш чылбыр белән богаулап, җитмеш тимерче аның башын тукмап торалар иде. Дию, егетне күргәч:

— Әй, егет, мин сине егерме елдан бирле шушы сарайда көтеп торам. Инде мин сине күргәнемә сөенгәнемнән ни эшләргә белмим, инде син миңа, зинһар өчен, бер мичкә генә су китереп бирсәнә,— дип сорады.

Егет кырык чиләкле бер мичкә су алып биреп, дию бер тын алуда эчеп бетерде дә янәдән бер мичкә су сорады. Егет, моның сүзен тыңлап, янә берне китереп бирде. Шулай итеп, егет өч мичкә су эчерде дә, диюгә бераз хәл керде. Дию бер тыпырчынды да җитмеш чылбырны өзеп, җитмеш тимерчене үтереп, чыгып китте дә, егеткә:

— Инде, егет, яхшылыкка яманлык булмасын, мин сине өч үлемнән коткарырмын, әгәр дә дүртенчесенә калсаң, ул вакыт миңа үпкәләмә, мин сине коткара алмам. Хәзер инде кыз минеке, син аны алырга батырчылык кыла алмыйсың,— диде.

Кыз кайтып кергән иде, ни күзе белән күрсен, сарай ачык, дию юк. Егеткә:

— Инде хәзер нишлибез, әйттем бит мин сиңа ачма дип, син тыңламадың, инде мине дә харап иттең, үзең ничек булса да кач инде, хәзер ул мине алыр. Мин кыз чагымда аны тотып бәйләп куйган идем,— дип әйткән иде, дию, йортка[1] чыгып, боларның сөйләшкәнен күреп, ачуланып, кызны алып кереп, егетне куып чыгарып җибәрде.

Егет чыгып китеп бер өч көн йөргәннән соң, бер ат табып, дүртенче көнне кызны диюдән урлап алып китте. Бу диюнең бер дуңгызы булып, җир астында җиде кат тимер ишек белән бикләп куйган булган. Егет кызны урлап киткәндә дуңгыз, диюне уятып, хәлне белдерде. Диюне өстенә атландырып, кызны куып киттеләр, барып та җиттеләр, Дию кызны ат өстеннән бәреп тә төшерде, алып та китте.

Егеткә:

— Менә инде мин сине бер үлемнән коткардым, әгәр икенче кат эләгә калсаң, миңа үпкәләмә,— диде.

Егет өч көннән соң кызны яңадан барып урлап китте. Дуңгыз янә уятып, өстенә атландырып, тагын куып җиттеләр дә кызны алып кайттылар. Дию, егеткә:

— Инде ике үлемнән коткардым, моннан соң йөрмә,— диде.

Егет янә урлап, өченче тапкырда да тотылды. Дию, кайтып: «Инде егет килмәс»,— дип, дуңгызны иске урынына бикләп куйды.

Егет дүртенче тапкыр яңадан килеп урлап китте. Дуңгыз сизеп, янә диюне уятты. Дию дуңгызга:

— Инде без аның артыннан кайчан җитәрбез? — диде.

Дуңгыз:

— Кайчан без иген чәчеп, булдырып, урып, сугып, тарттырып, он ясап, икмәкне ашасак, шул вакыт җитәрбез,— диде.

Дию, дуңгызның әйткәне буенча, игенне чәчеп, булдырып, урып, учмага салып, бау ясап, көлтә бәйләп, кертеп кибәнгә салып, чабагач белән алтылап сугып, җирдән җилгә орып, җирдән соскыч белән кап-

---

[1] *Йорт* — ишегалды.

чыкка салып, ат урынына кәҗә җигеп, арба белән шыгырдатып, җирдән дөбердәтеп, өч тәгәрмәч, бер тәртә белән тирмәнгә[1] алып бардылар. Тирмәнгә кертеп капчыктан чиләккә салып, чиләктән иләккә салып, иләктән мөшкәгә салып, әз-мәз төшереп, таш белән издереп, он ясадылар. Лардан капчыкка соскы белән төяп, төйгеч белән төеп, чүмәләдәй өеп, тирмәнчегә «әй»ләп, капчыкны мунчала белән бәйләп, арбага чыгарып салдылар. Онны алып кайтып, арбадан төшереп, көч җитмәгәч, җирдән эшереп, алты карчык, бер карт иңгә алып, өйгә керттеләр. Өйгә кертеп, чакма ташын корычка сугып, чаткы чыгарып кулга төшереп, курай белән көйрәтеп, чырага үрләтеп, утын юнәтеп, пичкә яктылар. Икмәкне изеп, әвәләп, сәкегә тезеп куйдылар. Пичне булдырып, күмерен уздырып, пумала белән себереп, кисәү белән эшереп, көрәккә салып, пичкә тыгып, тезеп куйдылар. Икмәк пеште, өсте көйде, уртасы чи калды. Тартып чыгарып, кыры белән суынырга тезеп куйдылар. Икмәкне алдылар, өстәлгә салдылар, бау белән бәйләп, теш белән чәйнәп, ничек кирәк алай ашказанына озаттылар.

Дуңгыз сарайдан дию алдына кереп:

— Әй, хуҗам, сез бик озак кунак буласыз, ашау-эчү җитәр, инде юлга чыгарга вакыт җитеп бара,— диде.

Алдылар чыбык, киттеләр чыгып, башның уе белән, чокырның буе белән, тузан туздырып, гомер уздырып, җир тетрәтеп, күк күкрәтеп барып җиттеләр бер күлнең читенә. Күлгә җиткәндә Амата аты белән суга кереп барадыр иде. Атның алгы аяклары суда, арт аяклары корыда калып, дуңгыз артыннан килеп җитеп, атның койрыгыннан кабып, егетне артка тартып төшерде. Дию, дуңгыз өстеннән төшеп, егетне икегә аерып ташлады. Егет шунда үлеп калды. Дию кызны үзенең тора торган шәһәренә алып китте.

Болар кайта торсын, без килик егетнең җизнәләренә. Җизнәләре бердән бер көнне җәелеп, чүмәләдәй өелеп утырганда, стаканга күз салдылар. Карасалар, су урынына стакан кан белән тулы. Болар шул ук заман каен энеләренең үлгәнен белеп, өчесе өч якка эзләргә чыгып киттеләр. Һавадан очып, җиргә төшеп, бер биек тау башына менеп утырдылар. Үзләре торган турыда — түбәндә, сазлыкта бер төркем карга күрделәр. Болар каргалар артыннан ни булса да бардыр, йә берәр кеше үләндер дип, кече баҗаларын карарга җибәрделәр.

Бу килеп күз салды, егетне танып алды. Шул ук вакыт бер хәйлә

[1] *Тирмән* — тегермән.

белән бер карганы тотарга уйлады. Җирдән үрмәләп барып, ничек җитте алай бер карга баласын тотып алды да икегә аерып ыргытты. Карга баласының анасы килеп:

— Әй, егет, ник минем баламны ботарлап ташладың? — диде.

Егет каргага:

— Әгәр дә үле суы белән тере суы китереп бирсәң, ул вакыт балаңны терелтербез, әгәр китермәсәң, ул вакыт үзеңне дә тотып ашармын,— диде.

Карга, ике кечкенә шешә алып, канат астына кыстырып, диңгезгә барып үле суы белән тере суы алып килде.

Карга баласын терелтеп, ул очып киткәч, егет каен энесен дә су сибеп торгызды да, караса — җизнәсе башын яңлыш[1] күзләрен артка каратып ябыштырып куйган икән. Егет алга атлыйм дисә, кысла кебек артына таба китә. Соңра җизнәсе, янә кылыч белән башын кисеп, яңадан дөресләп ябыштырды.

Егет торгач, исәнлек-саулык сорашып, җизнәсе моны баҗалары янына тауга алып менде. Елаштылар, көлештеләр, җизнәләре моның үз шәһәренә кайтып патша булуын теләделәр һәм, патшаның кызын алып бирергә сүз куеп, кайтырга димләделәр. Егет күнмәде. Шул вакыт егеткә өч аяклы бер тай табып, сынган кылыч тагып, егет үз юлына, кызны алырга дип чыгып китте.

Чокырның буе белән, үзенең уе белән урман буйлап бер сукмактан барганда бер бүре килеп чыгып:

— Әй, егет, атыңны бир миңа, хатыныңны алырсың,— диде.

Егет бүрегә карап торды да, сикереп төшеп, тайның койрыгыннан тотып, тиресеннән итен тартып чыгарды да атын бүрегә ташлап китте.

Бара-бара барып керде бер йортка. Анда тора иде бер кортка. Йорты шундый яхшы: салам белән япкан, әйләнәсенә ут капкан, өч почмагы янып беткән, бары бер почмагы гына калган иде. Егет өйгә кереп күрде: карчык утырган урыныннан һич тә тора алмыйдыр иде. Егет әби белән исәнләште. Әби:

— Әй, егет, монда ни эшләп йөрисең, әнә шунда чөйгә элеп куйган бер камчы бар. Шуны алып миңа бер-икене сук,— диде.

Егет камчыны алырга дип барган иде, күтәреп кузгата да алмады. Карчык бу эшне күреп:

---

[1] *Яңлыш* — ялгыш.

— Әй, улым, әле син көчкә утырып җитмәгәнсең, әнә тәрәзә төбендә өч шешә бар, шуның барысыннан да алып, берәр чокыр эч.

Егет бер чокыр эчте — камчыны кузгата башлады, икене эчте — әйләндерә башлады, өчне эчте — кулында уйната башлады. Егет камчыны күтәреп карчыкка бер сукты — селкенә башлады, ике сукты — әйләнә башлады, өч сукты — торып йөри башлады.

Шуннан соң карчык егеткә:

— Әй, егет, син бу хәлләрнең нидән икәнен беләсеңме? — диде.— Синең хатыныңны алган егет минем улым була, ул мине кыйнап бу хәлгә калдырып китте. Инде, минем сарайда берничә биям бар, син шунда бар да саклап тор. Кайсы әүвәл колын китерсә, шунысын барып кочакла да һич җибәрмә,— диде.

Егет, сарайга кереп, саклап торып, кайсы бия элек колынлаганын карап торды. Ярты төннәр булганда бер бия колынлады да, егет йөгереп барып, тайның муенына асылынды. Тай, сарай түбәсеннән чыгып, һавага алып менеп китте. Тай ничек булса да егетне үтерергә тырышып карады, ләкин булдыра алмады. Егет тайга бер сукты — түбән төште, икенче сукты — җиргә төште, өченче сукты — күтенә утырды.

Тай егеткә:

— Менә син егет икәнсең, мин сине болай булырсың, дип уйламаган идем. Инде сиңа хезмәт итәчәк ат мин булырмын. Инде син тимерчегә бар да җитмеш потлы ияр ясат, җитмеш тарткысы[1] булсын,— диде.

Егет тимерчегә барды, куйдылар тимерне тездереп, ут кебек кыздырып, җиде тимерче җиде яктан чүкеч белән, чүкеч җитмәгәне йодрык белән, тайны куйдылар бастырып, җитмеш потлы иярне астырып, җитмеш җирдән каптырып, иярләп-йөгәнләп бетергәннән соң, егет менеп утырды, аю кебек үкерде. Егет киерелеп тайга бер сукты — җилегенә җитте. Тай китте, китте һавага очып, җиде кат тибрәнде, җитмеш тарткысы өзелде. Егет, эшне сизеп: «Бу мине үтерә»,— дип, тайның җилкәсенә менеп утырды, ияре җиргә төште. Тай һаман югары очты. Егет, тайга ачуланып, камчы белән башына өч кат суккан иде, тай янә җиргә төште. Тай егеткә:

— Инде мин сине белдем, син чын егет икәнсең, моннан соң мин сиңа гомерлек юлдаш булырмын,— диде.— Инде без барыйк урманга, җыйыйк утын, очырып кош-кортның котын.

---

[1] *Тарткы* — аел, ияр бавы.

Утынны җыйдылар, бер җиргә китереп өйделәр. Егет тайга менеп, алты кылын алып, өемнең арт ягына чыгып, көтеп торды. Дию, бүре булып, егеткә таба килде. Өемне аша сикереп чыгам дигәндә, егет атка бер сукты, бүрегә бер сукты, бүре ятты өем өстенә, тай — бүре өстенә. Егет, сикереп төшеп, чакма кагып, барабан сугып, чыра белән үрләтеп, курай белән көйрәтеп ут якты. Бүре дә янды, тай да янды.

Егет көлне очырып, тузан итеп туздырып, алды чыбык, китте чыгып. Ай китте, ел китте, артына әйләнеп караса, кашык буе җир китте.

Ничә көннәр барганнан соң, кызның шәһәренә барып җитте. Егет барып керде өйгә, ни күзе белән күрсен: ашау да эчү, уйнау да көлү; ни ашасаң шул юк, барының да тамагы тук; торсаң — кияргә, ятсаң — ябынырга юк.

Егет кызга:

— Йә инде, матурым, без никадәр аерылып тордык, инде рәхәтләнеп бергә көн күрик,— диде.

Кыз:

— Син нинди кеше, мин сине күргәнем юк, күрсәм, таныганым юк, монда нишләп йөрисең? — диде.

Егет ачуланып чыгып, бер сыерны алып килеп җиргә салып, дүрт аягын бәйләп, муенына пычак салып, каның агызып, кара җиргә тамызып, эч-карыннарын чыгарып, кызның ишек төбенә алып килде дә кызны, чәченнән өстерәп алып чыгып, сыерның эченә терелә́й салып, энәҗебен алып, корсагын җөйләп куйды. Сулу алырга кабырга арасыннан бер тишек калдырып: «Инде син менә шунда торырсың»,— дип, сыерны өч арбага төяп, өч эт, бер куян җигеп, карбыз кагып, барабан сугып, бер яр буена илтеп ташлады. Каргалар очып килеп ашый да башладылар.

Егет, сыерның кырыккартасын алып, башына салып, алды чыбык, китте чыгып, барып чыкты бер патшаның җиренә. Ике артка, бер алга басып, барып чыкты бер шәһәрнең янына. Ул шәһәр булган өчен, очып китмәсен дип, шәһәрне бер кат кыл белән, биш кат җеп белән һавага тарттырып куйганнар.

Барып керде егет бер өйгә. Ул өй булган читтә, ишекләре чыпта, өч тәрәзә, бер ишек, өйнең әйләнәсе бар да тишек, җил кунар җир булмагач, әйләнәсенә чыбык кадап куелган. Керде өйгә, утыра бер карчык, тоткан кулына кырык ямаулы капчык, энә белән кое казып, җирдән су чыгарып, судан ут чыгарып. Пычак кайрап, балта чарлап, өч айгыр әтәчне дагалап утыра иде.

Егет барып кергәч, әби торып егеткә урын күрсәтте. Күрсәткән урыны шул иде: яшь шайтанны урындык ясап, карт шайтанны өстәл ясаган иде. Ашый торган аш белән өстәл тулы, ашыйм дисәң бер дә юк, ашамасаң да тамак тук. Ике кабып, бер чәйнәп, егет тамагын туйдырды. Утыра торгач, карчык белән сүзгә башлап, егет:

— Әй, әби, бу нинди патшаның җире? — диде.

Әби:

— Бу шәһәр Атҗитмәс, җәяү барсаң — Узмас патшаның шәһәре,— диде.

Егет:

— Әби, бу шәһәрдә ник бу кадәр халык җыелган? — диде.

Әби:

— Монда җыелган кешеләр бар да патшаның кияве буласы килгән халыклар,— диде.

Бу патшаның өч кызы бар иде, шулкадәр матурлар иде, һичбер тел белән әйтеп бетерерлек түгел иде. Ул кызлардан беренчесе егерме дүрт яшьтә булып, икенчесе егерме бердә, өченчесе унсигездә булганнар. Патша, болардан кайсысын алдан бирергә дип уйлап, аптырап торганда, шул шәһәрдә булган туксан бер яшьтәге Батман исемле бер карт исенә килеп төште. Патша шул арада әлеге картны үзенә чакырып алды.

Карт килгәндә, ике атлап бер йөгереп, абына да ыспотикатса[1] егыла, күтләренә ком тула. Аһ-аһ итеп килеп, патша алдына егылды да сүзгә тотынып:

— Әй, патша, ни боерасыз, туксан бер яшемә җиткәндә минем сезнең өчен бер начар эш эшләгәнем юк иде,— диде.

Патша:

— Әй, бабай, мин сине начар эшләгән дип чакырмадым; яхшылыгыңа күрә чакырдым. Менә минем бер сүзем бар, әгәр дә син шул сүземә сүз кайтарсаң, мин сиңа мең алтын хәер бирәм,— диде.

Карт:

— Әй, патша, ни сүзегез бар, сөйләп карагыз, әгәр дә булырлык булса, җавап бирермен, булмаслык булса, мине гаеп итмәссез. Инде минем вакытым узган, туным тузган, башымда уй калмаган,— диде.

Патша, сүзгә керешеп:

— Менә минем буйга җиткән өч кызым бар, аларның өчесенең дә

---

[1] *Ыспотикатса* (*урысча: спотыкаться*) — абыну.

кияүгә чыгарга вакыты җиткән. Белмим кемгә бирергә, кемне кияү итәргә. Инде синнән теләгем шул: син кайсын кемгә бирергә тиеш икәнен аерып бир,— диде.

Бабай куеныннан өч алма чыгарып өстәлгә куйды, һәм патшага:

— Әй, минем Тәңре тиң ханым, менә сезгә өч алма, берсе череп беткән, икенчесе яртылай черегән, өченчесе вакытлы гына — кып-кызыл. Менә бу черегән алма — зур кызың, бу алманың вакыты үткән шикелле, олы кызыңның да вакыты узган. Яртылай черегән алма икенче кызың кебек, аның да вакыты узып бара. Өченчесе кып-кызыл булып җиткән, анысы — яшь кызың,— диде.— Инде аларны бирер өчен бер зур йорт салдыр, аның балконнары чыгып торсын. Кызларыңның кулларына үзләренең алмаларын тоттырып, әлек зур кызыңны, аннан икенчесен, иң соңрадан кечесен чакырып утыртырсың. Кызлар чыгып утыргач, җыярсың бар халыкны: бае-ярлысы, аксагы-сукыры, чулагы-кулсызы, кәкресе-бөкресе... Ат чапкан җирдән ат чаптырып, якыннан тай чаптырып, тай йөрмәгән җирдән кәҗә сикертеп, халкыңны җыеп бетергәч, аларны берәм-берәм кызларның алдыннан үткәрерсең. Кызлар үзләренә охшаган кешегә алма белән бәрсеннәр. Кемгә бәрсәләр, ул аңарга кияү булыр, үзе сайлап алганнан сиңа үпкәсе булмас,— диде.

Патша шул вакыт бар кебек балтачыны, пычкычыны, чүкеччене җыеп эшләтә башлады бер сарай. Җирне көрәп, һавага терәп, шундый йорт салдырды — өстенә карарга чама да юк: ятып карасаң — бүрек төшә, торып карасаң — кызуыннан кабыргалар пешә. Ул йорт өч ел да бер көндә тәмам булды. Тирә-ягына күз күренмәс халык тулды: олысы-яше, бае-ярлысы — бар да килеп җыелдылар.

Халык җыелып киткәч, патшага кереп әйттеләр. Шул вакыт патша үз сараеннан барабан кагып, быргы кычкыртып, күк күкрәтеп, җир тетрәтеп ишектән чыкты да, халыкка карап:

— Әй, җәмәгать, гафил булмагыз, минем өч кызым бар, кулларында алмалары, әгәр дә киявем буласыгыз килсә, алар янынннан берәм-берәм үтегез. Кызларым кулларындагы алма белән кемгә бәрсәләр, ул кеше киявем булыр,— диде.

Кызлар чыгып утырды. Халык, югарыга таба карап, сарык кебек берәм-берәм үтә башладылар. Халык яртылай узганда олы кызы кулындагы алмасы белән бер байның малаена бәргән иде, шул ук вакыт егетне кияү дип тотып, сарайга алып керделәр. Икенчесе тагы берникадәр ха-

лык үткәч, бер ясаулның[1] улына китереп бәрде. Аны да кулларыннан тотып, ирегенә куймыйча, сарайга алып кереп киттеләр.

Бу халык арасында безнең Амата да бар иде. Кече кызы, еректан күз салып, башындагы картасына карамыйча, йөзенең матурлыгын күреп, аңарга бәрергә сагалап торды. Халык узып бетә язды. Амата иң арттан, ике генә кеше алдыннан үтәргә киләдер иде, кыз, Амата килеп җитүгә, тотты да алмасы белән Аматаның башына бәрде. Алма Аматаның башына килеп бәрелгән иде, икегә ярылып китте. Тегендә карап торган патша балалары:

— Бу яңлыш бәрде, бу безнең җирнең кешесе түгел, яңадан бәрсен,— диделәр.

Кыз яңадан бәрергә күнде, халыкны яңадан кыз яныннан үткәрделәр. Кыз тагы Аматага бәрде. Өчкә кадәр бәрделәр. Кыз һаман Аматага бәрде. Патша: «Үзе егылган бала еламас»,— дип, кызының Аматага баруын ошатмыйча, карт[2] мунчага илтеп ябарга кушты. Шул ук сәгать тотып алып, кыз белән Аматаны мунчага илтеп яптылар. Олы ике кызын, шул сарайда калдырып, матурлап җыештырылган вә бизәгән бүлмәләргә, сыгылмалы урыннарга илтеп яптылар.

Өч көн уй итеп, тугыз көн туй итеп, ашау да эчү, уйнау да көлү, ачтан кырылу, ни ашасаң, шул юк. Шулай итеп туй уздырганда, кыйбла ягыннан көчле бер җил исеп, өч йөз мең гаскәр, унбиш батыр белән Аттартмас патшаның улы шәһәргә якын бер җиргә урынлашып, чатыр кордылар. Бу патшаның улыннан илче килеп, патшага: «Кызыңны миңа бирәсеңме, бирмәсәң, бүген минем белән сугышка чык»,— дип язылган хат биреп, җавап көтеп торды. Патша, хатны укып, вәзирләрен җыеп, ике киявен чакырып:

— Шундый-шундый эшләр, бара-тора нишләр, ничек теләсәгез, шулай итеп хатыннарыгызны дошманнан коткарып алып, дошманны куып җибәрегез,— диде.

Ике кияве, бик яхшылап киенеп, алмаз кылычлар тагып, барабаннар кагып, сугышка җыендылар. Олы кияве һәммә-һәммә гаскәргә баш булды.

Амата, үзенең хатынын атасына җибәреп:

— Бар, син дә бер ат сора, мин дә сугышка барыйм,— диде.

---

[1] *Ясаул* (*урысча: есаул*) — патша армиясендә казак офицерлык дәрәҗәсе, пехотадагы капитанга тиң, шушы дәрәҗәдәге шәхес.

[2] *Карт* — иске.

Гөлсылу атасына:

— Әткәй, яшь киявегез дә бер ат сорый, сугышка барырга дәрте бар,— диде.

Атасы, Гөлсылуга:

— Әй, кызым, андый диванадан ни чыксын, монда мине борчып йөрмә, хайванны гына әрәм итәр. Моннан соң миңа аяк басып, күземә чалынма,— диде.— Шулай булса да йөгәнен тотып азбарга[1] китсен дә нуктасын чылтыратсын, кайсы ат аңарга караса, шул атка менәр,— диде.

Гөлсылу Аматага килеп әйткәч тә, Амата, йөгәнен кулына тотып, кырыккартасын башына киеп, азбарга барып йөгәнне шалтыратты. Аңарга азбарда алтмыш колачлы ала бия әйләнеп карады. Амата бияне тотып, өстенә менеп, тышкары таба артына карап утырды да, койрыгыннан тотып чыгып китте.

Шәһәрдән бер читкә чыгып бакалы күлгә килеп җиткәч, атыннан төшеп, койрыгыннан тотып тиресен тарткан иде, кабы суырылып чыкты да, итен каргаларга ташлап, үзе күлгә кереп бакаларга каршы сугыш ачты.

Бераз вакытлардан соң патша, кияүләре белән, артларыннан гаскәрләрен ияртеп, моның турыннан узып баралар иде, моны күреп, көлештеләр дә патша, Аматага:

— Әйдә, җүләр, безнең белән ичмаса берәр кеше үтерерсең, ул да табыш булыр,— диде.

Амата:

— Бара торыгыз, минем монда үземнең сугышым бик яхшы,— диде.

Патша, кияүләре белән күздән югалгач, Амата, күлдән чыгып, үлгән атының кылларын кулына алып көйдерде. Шул ук вакыт Аматаның аты бөтен сугыш киемнәре белән һавадан килеп тә төште, Аматаның алдына килеп тә басты. Амата атының бер колагыннан кереп, икенче колагыннан чыкты да дөньяда беренче батыр булды. Кырыккартаны башыннан салды, кылыч вә сугыш киемнәрен өстенә киеп алды, атына бер сукты — күз ачып йомганчы патшалар алдына барып та төште. Дошманнарын күрүгә, куй арасына кергән бүре кебек, солдатлар арасына барып та керде, бер баштан кыра да башлады. Бераз гына вакыт эчендә бөтен гаскәрне кырып бетерде, бары унбиш батыр гына калды, аларны да ике-

---

[1] *Азбар* — абзар.

өч сәгать арасында ыргытты. Дошман гаскәренең башлыгы булган патша баласына:

— Инде син моннан соң бу тирәгә килеп күзгә күренмә, бу юлга сине үз иркеңә куям,— диде.

Патша улы әйләнеп өенә кайтып китте. Амата, атын борып алып, тагы патшаның алдына килеп басты.

Патша моңарга:

— Әй, егет, син безгә бу кадәр зур хезмәт күрсәттең, бу күрсәткән изгелекләрең өчен син безгә кунакка бар, үзеңне хәлдән килгән кадәр кунак итәрбез,— диде.

Амата:

— Минем сезгә барып кунак булып ятарга вакытым юк, сугыш бер монда гына түгел, бүтән җирләрдә әле яңа башланып килә. Мин болай да үз кунагыгыз,— дип, атын борып янә үз юлына китте.

Егет, элеккечә, атын күл буена җибәрде. Кырыккартасын башына киеп, тагын бакалар белән сугыш ачты. Патшалар моның янынннан узып киткәндә, җүләр җүләрлеген итә дип, көлешеп киттеләр.

Патша шәһәргә кергәч тә, Амата, алтмыш колачлы ала биянең тиресен өстерәп алып кайтып, мунчага килеп керде дә, Гөлсылуга:

— Без әлегә кадәр коры тактада ятадыр идек, моннан соң бераз йомшак булыр,— дип, идәнгә түшәп куйды. Сугышкан атын үзенең киемнәре белән үз иркенә очырып җибәргән иде.

Берничә көннәр генә үткән иде, икенче яктан Тиктормас патша, гаскәр җыеп, боларның өстенә килергә юлга чыкты. Патша бу эштән хәбәр алуга, кияүләрен чакырып, киңәш корды. Икенче көнне патша кияүләре хәзерләнеп, бар гаскәрен җыеп, азыклар төйнәп, казылыклар тутырып, икмәкләр пешереп, күп вакытлар уздырып, сугышка дип чыгып киттеләр.

Амата бу хәбәрне ишетеп, Гөлсылуны атасына ат сорарга җибәрде. Гөлсылу атасына барып ат сораган иде, атасы, ачуланып:

— Инде үз имгәгең бит, азбардан корчаңгы атны алсын,— дип әйтеп җибәрде.

Гөлсылу кайтып әйтүгә, Амата, мунчадан чыгып, челемен кулга алып, пыш-пыш төтен чыгарып, корчаңгы биягә кире атланып, башын түбән идереп, койрыгын югары күтәреп капкадан чыгып китте. Бака күленә барып җитте. Атыннан төшеп, койрыгыннан тартып тиресен сыдырып чыгарды да, итен каргаларга ташлап, үзе күлгә кереп китеп, тагын бакалар белән сугышырга тотынды.

Патшалар, узып барганда, моны да сугышка чакырдылар.

Амата:

— Минем монда әле үз сугышым бик көчле,— дип, аларга таба карамыйча, бакаларны бәреп үтереп калды.

Патшалар күздән югалгач та, әлеге атының кылларын көйдереп, аты янә сугыш кораллары белән Аматаның алдына килеп басты. Амата шул ук сәгать кырыккартасын салып, кылычын кулга алып, билбауларын бәйләп, калканын иңбашына күтәреп, патшаларны узып китте дә, дошман гаскәре каршысына барып җитте дә, бер баштан сугышырга тотынды. Алар белән берничә сәгатьләр сугышып кырып бетергәннән соң, бары егерме хәтле батыр калды. Берничә сәгатьләр алар белән тартышып, соңыннан аларны да дөмектереп, янә патшалар янынннан узып китте. Патша, күрсәткән эшләре өчен, тагын моны кунакка чакырды.

Амата: «Мин сезнең кунагыгыз»,— дип, тагын узып китте дә, күлгә килеп төшеп, бакалар белән янә сугышырга тотынды.

Патшалар, кайтышлый, моның янынннан үтеп барганда: «Бу җүләр һаман монда чәбәләнеп ята икән»,— дип сөйләшеп узып киттеләр.

Алар шәһәргә кереп киткәч тә, Амата, атын җибәреп, корчаңгы биянең кабын алып кайтып, тагын мунчага кертеп җәйде.

Патшалар, кайтып җитүгә, бөтен шәһәрнең халкын җыеп, зур бер туй ясап, музыкалар уйнатып, кошлар сайратып, күңел ачтылар.

Амата, Гөлсылу катына кереп, үзләренең көнлек азыкларын ашап, бераз йөрәк ялгадылар да ятып йокладылар.

Иртә торып бит-баш юуга, тагын бер патшаның болар өстенә килүен ишеттеләр. Ул патша өч йөз мең гаскәр һәм утыз батыр белән килә иде. Моның бер батыры биш батырга тора торган иде.

Патша, Гөлсылуны чакырып:

— Инде, кызым, киявеңә әйт, гаскәр дә, мал да бирермен, теләсә ничек коткарсын,— диде.

Гөлсылу, кайтып, Аматага: «Әти шулай әйтә»,— дип, атасының әйткән сүзләрен сөйләде.

Амата, баҗаларына барып:

— Сез дә миңа өмәгә барыгыз,— диде.

Болар:

— Син җүләр артыннан йөреп бетәр хәлебез юк әле, үзебезне дә бер яшь егет коткарды,— дип сүгеп чыгардылар.

Патша, вәзирләрен җыеп:

— Без патшалыкны бу җүләр кулына биреп харап итәрбез, булмаса, үзебез дә барыйк,— дип, юлга хәзерләнә башладылар.

Аматага да бер ат бирделәр. Ул кире атланып чыгып китеп, атын үз көенчә җибәреп, үзе күл катына утырып калды.

Патша:

— Бу җүләргә ышанып әле дә ярый өйдә калмадык. Моңарга ышансак, бөтенләй харап буласы икәнбез,— диде дә, узып киттеләр.

Амата, алар узып китүгә, сызгырып атын чакырып алды да сугыш киемнәрен киенде.

Аты, Аматага:

— Инде, хуҗам, бүген сак бул, бу сугыш куркынычлы сугыш булыр,— диде.

Амата, атына менеп патшаларны узып китеп, алар барып җиткәнче өч йөз мең гаскәрне кырып бетерде. Патшалар барып җиткәндә бары батырлары гына калган иде. Патшалар килеп җиткәч тә, аларның күз алдында егерме тугызын үтерде. Азаккы батыр белән алышканда диюнең батыры моның уң кулын яралады. Патша, төшеп, яулыгы белән Аматаның ярасын бәйләгәндә, Амата сул кулы белән диюнең башын чабып төшерде. Патша Аматаны никадәр инәләп кунакка чакырса да, Амата: «Мин үз кунагыгыз»,— дип, тагын атын чаптырып күл буена килеп утырды.

Патша: «Инде моннан соң, бәлки, сугыш булмас, тыныч торырбыз»,— дип, кайтып, янә туй ясап, күңел ачтылар.

Берничә көннәр үткәч тә, патша бер сырхауга тап булды. Имчеләр, аңарга:

— Аккошның уң кабыргасын ашасаң, терелерсең,— диделәр.

Патша, ике киявен чакырып:

— Аккош табып китерегез,— диде.

Аматага сүз бирмәделәр. Шулай да Амата боларның эшләрен барын да белеп торадыр иде.

Икенче көнне ике кияве атка менеп, кылыч тагып, аккош эзләргә сахрага чыгып киттеләр. Амата алардан соң чыгып, бер болынлыкка барып, яшел яулыкны чишеп, музыка вә башка ашау-эчү нәрсәләрен күреп, күңел ачып утырадыр иде, ике баҗасы моның янына килеп, Аматага баш ордылар. Амата, сәламнәрен алып, икесен дә чатырына алып кереп:

— Нишләп йөрисез? — дип, йомышларын сорады.

Болар:

— Аккошның итен эзләп йөрибез, патшабыз авыру, бер нәрсә дә ашамый-эчми, аккош ите сорыйдыр, син табып бирә алсаң, без сиңа ни теләсәң, шуны бирер идек,— диделәр.

Амата:

— Мин сораганга күнсәгез, мин сезгә табып бирермен,— дип, беренең аркасыннан үргечен ярып алырга, икенчесеннән уң кулының чәнчә бармагын кисеп алырга сорады.

Болар, Аматаның сораганына күнеп, бирергә булдылар. Амата берсенең үргечен, берсенең бармагын кисеп алды да, аккошка карап: «Сул ягың агу булсын, уң ягың дару булсын»,— дип, атып алды да боларга китереп тоттырды. Болар сызланып кайтып киттеләр.

Баҗалары киткәч, Амата яулыгын җыеп алды да үзе белән тагы бер аккош алып кайтты. Аккошны Гөлсылуга биреп:

— Мә, пешер, атаңа илтеп бирерсең,— диде.

Гөлсылу аккошны әрчеп, пешекләп, тазартып, пешереп, атасына илтеп бирде.

Патша:

— Олы кияүләрем алып кайтканны ашап сырхавым гына артты, тагы бу җуләрнең алып кайткан нәрсәләрен ашап агуланып үләр хәлем юк,—диде.

Гөлсылу елап әйткәч, патша берәр капты. Шул ук сәгать бераз хәл алып, икенче көнне йөри башлады.

Бердән бер көнне, хатыны белән сөйләшеп утырганда, патша:

— Әле дә ярый карт кияүләрем аккош алып кайтып ашаттылар. Алар алып кайтмаган булсалар, мин терелмәгән булыр идем,— диде.

Хатыны:

— Юк, карт кияүләрең алып кайткан ит эшкә ашмады, яшь киявеңнең даруы килеште, әгәр дә ул алып кайтмаса, эшең кыйты[1] иде,— диде.

Болар, ирле-хатынлы бераз тарткалашып, сүзгә килеп, әрләшеп алдылар.

Бердән бер көнне патша хатыны: «Безнең кияүләр ничек яталар икән?» — дип, тынга барды. Барса, олы кияве туңкаеп яткан, хатыны бер якта елап утыра. Моның аркасы сызлыйдыр иде. Икенче киявенә барса, ул да, бармагын авызына кабып, ыңгырашып ятадыр иде. Патша хатыны: «Тукта инде, тегеләрне дә барып карап кайтыйм»,— дип, мунчага китте.

Мунчага барып тәрәзәсеннән караган иде, мунчаның эче оҗмах бүлмәсе

---

[1] *Кыйты* — начар.

кебек, уен-көлке, гөлт итеп яктыртылган... Аматаның башыннан кырыккартасы төшкән, алтын кебек бөдрә чәчләре ут яктысында ялт итеп тора. Гөлсылу белән кочаклашканнар, телләрен телгә тигереп, үбешеп утыралар. Мунчаны тетрәтеп, музыка гөрләп уйнап тора.

Патша хатыны, бу хәлләрне күреп, һушсыз булып, берәр сәгать мунча янында авып калды. Исенә килгәч, телен авызында тешләп, өенә кайтып, патша катына барып ятты.

Амата иртәнчәк торгач, күзен-башын югач, ашагач-эчкәч, Гөлсылу белән үбешеп-кочышып исәнләшеп:

— Мин бераз кырга чыгып керим әле,— дип, кырыккартасын башына киеп, чыгып китте.

Бер сахрага барып, атының кылын көйдергән иде, аты килеп төште. Атының бер колагыннан кереп, икенче колагыннан чыгып, менә дигән бер батыр булып, патша катына килде дә, патшага:

— Менә минем качкан ике колым бар, билгеләре шул: берсенең аркасыннан үргече ярылган, икенчесенең бер бармагы кисек, әгәр дә табып бирмәсәгез, ул вакыт иртәгә минем белән сугышка килегез,— диде.

Патша, бу сүзгә күнеп, гаскәрләрен җыеп, моның үзенә карарга кушты. Амата берәм-берәм карый башлады. Кайсының күлмәген салдырып карады, кайсының бармагын карады — бар халыкны карап чыкты, таба алмады. Иң соңыннан патшаның ике киявен дә алып килделәр. Амата олысының аркасын ачып караган иде — үргече юк, икенчесен караган иде — бармагы юк. Шул ук заман Амата икесен дә, сугышка өмәгә бармаганнары өчен, дар агачына асып куйды.

Амата бу эшләрне бетереп, борылып сахрага китеп, атын җибәреп, үзенең кырыккартасын башына киеп, мунчасына кайтып китте. Бу эшне Гөлсылу да, башкалар да белмәделәр.

Икенче көнне патша үзенең хатыны белән, бераз йөрергә дип, бакчага чыктылар. Амата картасы белән сарайга кереп, патшаның ефәк яулыгы белән җәрәхәтен бәйләгән кулын күрсәтеп, патша урынына ятты. Моның кереп киткәнен бер вәзир күреп, патшага чыгып:

— Теге җүләр, сезнең урыныгызны былчыратып, картасы белән кереп ятты,— диде.

Патша кереп, бәреп төшерим дигәндә, үзенең ефәк яулыгын танып, тез чүкте дә, Аматага:

— Янлышлык миндә, мин сезнең кулда, мине теләсәгез нишләтегез,— диде.

Амата, урыныннан торып:

— Сез әле мине бүген беләсезме, мин сезгә никадәр хезмәт иттем! — дип, патша өстенә бер кычкырган иде, патша өч көн истән китеп ятты.

Шуннан соң Амата, бөтен шәһәр халкын җыеп, зур бер туй ясап:

— Инде мин моннан соң — сезнең патшагыз,— дип, бөтен халыкка белдерде.

Амата, патша киемнәрен киеп, Гөлсылу янына мунчага китте. Гөлсылу, моны күргәч, танып, муенына асылынды.

Сарайга кайтып, Амата — патша, Гөлсылу — патша хатыны булып, тугыз көн туй ясап, ун көн уй ясап, ашау да эчү, уйнау да көлү, ачтан кырылу... Без дә булдык туйларында, эчтек буза: кеше эчә чиләк белән, без эчтек иләк белән — авызга тимәде, мыектан агып төште. Ике чокыр чәй ашап, бер кисәк икмәк эчеп, тамакларны туйдырып, җаннарны тындырып, туйда кеше көлдереп, җыр җырлап, агач сырлап, кайтып китеп, туйны искә төшереп һаман да булса җырлап утырабыз!

3. Карт бабай

Бар иде борын-борын заманда бер патша. Бу бик усал, бик үткер кеше иде. Моның бар иде бер улы. Бу патша шундый кеше иде, дөньяда һичбер эшне куймады, хәзердә дә ни эшләргә белми. Бер көнне, бөтен дөньяны сөрдереп, бакча чәчәргә уйлады. Бу уен җиренә җиткерү өчен бер көнне, сансыз ялчылар яллап, җирне сөрдерергә тотынды. Сөрдереп һәм тырмалап карбыз, кавын, һәртөрле яшелчәләр чәчтеләр. Бакча бик матур булып тишелеп, чыгынтылар үсеп килә. Патша, бу бакча болай әрәм булып, урлап бетерерләр, дип каравылчы куярга уйлады. Үзенең кул астындагы бар кебек халкын җыеп, сайлап сакчылар куйды. Бакча бик яхшы өлгереп килә.

Бер көнне патша: «Мин бер туй ясамакчы булам»,— дип, үзенең якыннарына белдерде, һәм туй көне килеп җитте. Патша, юлга киенепясанып, атка атланып, камчысын кулына алып, күбәсен[1] биленә тагып, кылычын кабыргасына асып, авызына челемен кабып, бакчага юнәлеп китте. Бакча катына килеп җитте. Бу чагында сакчылар дүртесе дүрт җирдә аптырашып, йончып карап торалар иде. Патша ду туздырып, уен белән бакчаның читенә килеп төште. Күтәрелеп бакчага күз атты. Бакча

[1] *Күбә* — вак металл боҗралардан эшләнгән сугыш киеме.

эчендә кара җирдән башка нәрсә күрмәде. Патша шул ук сәгать: «Бу ни эш бу?» — дип, сакчыларны үз катына чакыртты. Сакчылардан:

— Бу нәрсә өчен болай булды? — дип сорады.

Сакчылар, бик куркышып, тезләре калтырап:

— Кичтән бакча бөтен иде,— дип җавап бирделәр.— Иртәнчәк торуга без үзебез дә аптырап киттек, бакчаны бу рәвештә күрдек,— диделәр.

Патша сакчыларга:

— Сез сакчылар түгел, этләр икәнсез, сезне сакларга дип куйдым, сез эштән чыгарып куйгансыз,— диде.

Патша чырайларын сытып, күзләрен акайтып, сакчыларны кудырды һәм бу җирдә үзенең вәзирләренә:

— Инде бу эш болай булды, шул ук эшне мин икенче төрле эшләп карамакчы булам,— диде.

Шулай да булса боларның туйларының яме китте. Күңелләре төшеп, салмак кына атлатып, акрын басып, кире өйләренә кайтып киттеләр. Шулай итеп, бу ел карбыз, кавын, кабак, кыяр, чөгендер, кишер ашамыйча калдылар.

Озак үтмәде, үтәсе көн үтте, гомер акрын гына сызып югалып тора. Сулар акты, бозлар эреде, җирләр ачылды, үләннәргә яшел төс керде. Кошлар ерак җирләрдән үзләренең көзен ясап калдырган ояларына, сагынышып, матур тавышлары белән сайрап, канатларын кагып, башларын бер якка салып, иске йоннарын коеп, күбесе шыр ялангач калып, кире килеп җиттеләр. Болар белән бергә, һәркемнең көткән матур вакытлары белән яз көннәре дә килеп җитте.

Инде патша бу ел яңадан бакча утыртырга уйлады. Янә сакчылар яллап, аксак-туксакларын җыйнап, корчаңгы атларын сабанга җигеп, тай-толакларын арттан ияртеп, бакчага сукаларга сукачыларын чыгарып җибәрде. Ялчылар бик тырышып, көн ашамыйча, төн йокламыйча, һич китеп, бөтенләй китеп, иртә китеп, кич китеп, майламаган сабаннарын шыгырдатып, бакчаның эшен бетереп, патшаның йортына кире кайтып киттеләр. Боларның кайтуларына патша үзе каршы чыгып, болардан:

— Бакчаны яхшы эшләдегезме? — дип сорый.

Ялчылар:

— Әй, патшам, бик яхшы эшләдек,— дип җавап бирүләренә патша ышанмыйча, тиз генә сараена кереп бер чагыр[1] күзле вәзирен чакыртып,

---

[1] *Чагыр* — кылый.

бакчаны үзе карап кайтырга уйлап, ике кәҗә, бер бәрән җигеп, маэмайны арттан ияртеп, каһрән-җәбрән бакчаның читәненә барып җиттеләр. Патша үз күзе белән чәчкән орлыкларны карады һәм кирәгенчә тапты.

Азмы-күпме вакыт үтте, болар кайтырга чыгып киттеләр. Кайтып, патша янә үзенең кул астындагы кешеләрне җыеп, үзенә ошаган сакчыларны сайларга тотынды. Арады-арады, соңга арды. Беренче кешеләрне сайлыйм, дип, иң начар кешеләрне билгеләп куйды, үзенчә бу кешеләргә ышанды. Күңеленнән: «Инде болар һичбер кеше кертмәсләр, бакча бөтен булыр»,— дип үзен-үзе юатты.

Янә үзенең байлыгы белән бөтен кешене кинәндерә торган ямьле вакытлар килеп җитте. Бакча кешенеке кебек ямь-яшел булып үсеп килә. Патша җәй көнендә бакчаның ямьле чагында бер туй ясап, күңел ачарга уйлады.

Азмы-күпме үтмәде, туй көннәре якынлашты. Патша: «Үзем барам, бакчаны яхшы карагыз»,— дип сакчыларның колакларына бик нык тукып куйган иде. Шулай да булса туйга кадәр патшаның йөрәге түзмәде. Бер төнне шыпырт кына җәяүләп, челемен кабып, таягын кулга тотып, бакчага юнәлеп чыгып, чокырның эче белән, челеменең көче белән бакчага китте. Аягын артына бәреп чабып, артына карап шәүләсеннән өркеп, ничек җитте алай бакчага барып җитте. Үз күзе белән күрде: сакчылар бакчаны кирәгенчә карап йөриләр. Бакча сәламәт, үсемлекләр мөлдерәп үсеп утыра. Патша сакчыларга бер сүз дә әйтми, тын гына өенә кайтып китте. Кайтып шатланып, хатынына мактанып: «Эш без дигәнчә булыр»,— дип сөйләде.

Күп вакыт үтмәде, рәхәт төннәр үтте, көн булды. Патшаның уйлаган туй көннәре якынлашып бара. Бердән бер көнне туйга барырга дип җыена башладылар, һәм сакчыларга: «Фәләнчә көнне фәлән сәгать бакчага барабыз, аң булып торыгыз»,— дип каты бер хәбәр җибәрде. Күп вакыт үтмәде, патша, вәзирләре белән тавыклар кыткылдатып, күркәләр голдырдатып, казлар гайгылдатып, бар кебек җәнлекләрен җыеп, дөньядагы аламаны калдырмый алып чыгып киттеләр. Юлда барганда төрле таулар, урманнар, сулар үтеп, барып җиттеләр бакчага. Бакчага барып кергәннәр иде, ни күзләре белән күрсеннәр, сакчылар да юк, яшелчә дә юк, калган кара туфрак та ихата.

Калганнарын сөйләргә әле иртә. Курайларны көйләрбез, тора-бара сөйләрбез.

Бакчага кереп бернәрсә дә күрмәгәч, туп-туры сакчыларның куышы-

на киттеләр. Барып керсәләр, куышның эче буш, тирә-ягы буш. Патша бу хәлне күреп, үзенең зәһәрлегеннән ни эшләргә белмичә, һавага бер күтәрелеп карап, үзен-үзе җиргә атып ташларга теләде. Бу вакытта патшаның иң якын күргән бер вәзире:

— Патша, солтаным, иске чабата олтаным, бу эш болай ачулану белән булмас, җаен карарга кирәк,— диде.— Бу эшләрнең җаена кайткач сөйләшербез,— дип, патшаны сарайга алып кайтып киттеләр.

Бу патша, ни булса да кеше эшләмәгән бер эшне эшләргә дип уйлап йөри торгач, иң түбән бер игенче эшли торган эшне дә эшли алмады. Үзенең исенә килеп, моннан соң үз сүзе белән генә йөрмичә, киңәш итеп эш күрергә кирәк икәнен төшенде. Шулай булуда бакчасын өченче тапкыр чәчтерергә теләүне башыннан чыгара алмады. Янә ялчылар яллап, бу ялчыларны инде тикшерергә ярамас, һәркем үз җае белән эшләсен, дип, боларны агач аргамакларга атландырып, үзегез белеп эшләрсез, дип, күңелләрен басып җибәрде. Ялчылар, бу патша ни эшләгән дип уйлашып, сөйләшеп, үз җайлары белән бакчаны чәчәргә киттеләр. Патша, ни булса да булыр, инде үзләре карап булдырсыннар, мин катышмыйм, булса булыр, булмаса юк, дип, өеннән чыгарга уйламады.

Ялчылар бакчаны сөреп-тырмалап, түтәл ясап, чокырлар казып, туңган җирдән су чыгарып, орлыклар чәчеп, утыртып бетерделәр. Яшелчәләр тишелеп чыгып үсеп киттеләр. Инде боларны саклар өчен кем дә булса кирәк, дип, патшага хәбәр җибәрделәр. Патша бөтен кул астында булган җан иясен җыйдыртты да: «Инде каравылчыларны үзем сайламыйм, теләгән кешеләр булыр әле»,— дип, үзләреннән сорарга төбәп куйды. Патшаның боерыгын ишетеп, бөтен җан иясе абына-сөртенә, ава-түнә, тора-йөгерә килеп җиттеләр. Кешеләр шулкадәр күп булдылар — җирдәге чүпкә сан бар, кешегә сан юк. Шуннан соң патша чыгып:

— Инде минем кул астымдагы кешеләр бар да килеп җиттеме? — дип сорады.

— Күп кешеләр килеп җиттеләр,— дип кычкырдылар.

Бөтен кешеләрнең артында таягының булышлыгы белән басып торган сукыр, чулак, биртелгән, ак сакаллы, кызыл борынлы бер карт ай кебек якты башы белән, үзенең карылган тавышы белән:

— Минем күршемдә бер кеше калды,— дип кычкырды.

Ләкин бу кадәр халык арасында андый тавыш түгел, бугазын киереп акырган куштаннарның да тавышы ишетелмәклек түгел иде.

Ничек җитте алай кычкыра-кычкыра, бу карт үзенең тавышын пат-

шага җитештерде. Патша бу картны үз янына чакырды. Карт патшаның янына ава-түнә килде. Картның ике күзе дә юк, сөйләргә сүзе дә юк. Кигән киеменең бер итәге җирдән, бер итәге гүрдән, өс-баш алама, хәтта картның бар кебек хәзинәләре дә тышка чыгып торадыр иде. Шулай да булса патша моның сүзен җөпләде. Калган кешене алып китерергә кушты.

Эт чапты, бет чапты, тузан тузды, борча очты, дөбердәп, шатырдап картның өенә барып керделәр дә, картның ай-ваена карамыйча, җилтерәтеп, ике кулыннан тотып, артына тибеп, шул ук сәгать патшаның янына алып килделәр. Патша бу картны күреп, моны сөйләгән алама карттан да тегеләйрәк гайрәте чикте. Аның күзе түгел, күзенең урыны да юк. Патша бу эшкә бик аптырап, эченнән генә: «Бу урынга бу карт кешеләрнең бер дә керәге дә юк»,— дип уйлады.

Патша шул ук вакыт халыкның тавышын басып: «Кем бакчага сакчы булырга тели?» — дип кычкыртты. Халыклар, бакчаның хәлен белгәнлектән, берсе дә бакчаны сакларга батырлык кыла алмадылар. Патша бер әйттерә, ике әйттерә, өч әйттерә — һичбер тавыш-тын чыгаручы юк. Бу вакыт бакча булып киләдер иде. Патша җавап ала алмагач, ни эшләргә белмичә аптырап торганда, әлеге иң соңыннан килгән күзсез карт:

— Бакчаны сакларга мин муеныма алам,— дип кычкырды.

Моның тавышын ишетеп, җыелган халык, бу карттан нинди эш чыксын, дип исләре китеп, көлешеп бот чаптылар.

Бу вакыт патша үзенең зәһәрлегеннән ни эшләргә белмәде, бүтән кеше чыкмагач, аптырап, картка янә бер күтәрелеп карап, эченнән генә: «Барыбер минем бу эшем эш булачак түгел, җуелса бакчасы да, карты да бергә җуелсын»,— дип, картны куярга уйлады. Картка карап:

— Инде, бабай, җитәрлек картайгансың, вакытың узган, туның тузган, яшең җиткән йөз дә кырыкка, сиңа берәр иптәш кирәк булырмы? — диде.

Карт, барлык тамагын киереп:

— Миңа һичбер иптәш кирәкми, Аллаһ — иптәш,— диде.

Патша, башка кеше таба алмаганлыктан, шикләнеп кенә картны бакчага озатты.

Карт патшага:

— Әй, патшам, син үзең бакчага барып, үз күзең алдында бакчаның уртасына бер куыш ясаттырып бир, бакчадан бер нәрсә дә җуелмас, әгәр җуелса, башымны кисәрсең,— диде.

Патша: «Синең башың бер карбызга тормый»,— дип, моның сүзенә колак салмыйча, бер сүз дә әйтмичә, кайтып, хәлен хатынына сөйләп күрсәтте.

Карт үзе белгәнчә бакчага җитәкләтеп барып, үзенә җайлы иттереп куышын бакчаның уртасына кордырды. Бакча елдагыча бик матур булып үсеп киләдер иде.

Бер вакытны патшаның исенә бакча килеп төшеп, бер хезмәтчесен бер атка мендереп, карарга җибәрде. Хезмәтче бакчага барып, картка сәлам биреп, исәнлек-саулык сорашып торганда, карт моңарга бик каты тавыш белән:

— Син, энекәем, рөхсәтсез нигә минем бакчама кердең? — дип кычкырды.

Хезмәтче:

— Мин патшаның ялчысы, патша мине бакчаны карарга җибәрде,— диде.

Шулай булса да карт бу хезмәтчегә:

— Син түгел, патшаның үзе килсә дә миннән рөхсәтсез керә алмас, бакча өлгергәч, мин үзем патшага хәбәр бирермен, монда болай вакытлы-вакытсыз килеп, мине борчып йөрмәгез,— диде.

Хезмәтче кире борылып кайтып китте. Бу хәлләрне патшага кереп сөйләде, патша көлде дә калды.

Бераз вакыт үтмәде, үткән елларда булган туй көннәре килеп җитте. Инде уйнау, өченче туйга хәзерләнү бит, җыенып йөргәндә кисәктән патшага карттан «Иртәгә сәгать алтыдан калмыйча килеп җитсен»,— дип хәбәр килеп җитте. Патша картны яратмаса да, бакчаны яратканлыгыннан, иртәне ничек җиткерергә белмичә, бер ягыннан икенче ягына әйләнеп, йокламыйча төнне үткәрде.

Иртән яктырып та җитмәде, барабаннар суктырып, быргылар уйнатып, этләрен җигеп, мәчеләр ияртеп, җирдән җиләннәрен өстерәтеп, бакчага чыгып китте. Әйтелгән вакытка патша бакчаның читенә барып терәлде. Бакча күзгә күренми, юлдан кызыл тузан тузган иде. Ипләп карасалар, бакчаның уртасында куыш тирәсендә ике кеше көрәшеп-алышып йөриләр. Әлеге сукыр картның янына янә бер карт килгән. Ул картның озынлыгы егерме аршын, юанлыгы илле аршын, сакалы җирдән өстерәлеп йөреп тузан тузган икән. Бу вакытта патшаның тавышын ишетеп, безнең сакчы картыбыз барлык гайрәте белән борып, тегене җиргә екты. Шул ук вакыт көннәр ачылып, тузаннар басылып китеп, бакча ап-ачык

булып калды, ямь-яшел түтәлләре тулы үсемлек гөрләп утырадыр иде. Патша бакчаны күрде: бакча бөтен. Сакчы карт батырга чыгып, теге картның өстенә менеп утырган. Патша бу хәлне күреп, үзе белән бергә килгән сакчыларына:

— Бу кешене тиз моннан алып ташлагыз, карт ял итсен,— диде.

Сакчылар әйтеп бетергәнне дә көтеп тормадылар, картны кулыннан тотып, артына тибеп, сакалыннан өстерәп алып китәргә хәзер тордылар.

Сакчы карт:

— Аны сез булдыра алмассыз, патша кая илтергә кушса, үзем шунда илтеп ташлармын,— диде.

Патшага килеп, сакчы картның сүзен сөйләделәр. Патша шәһәрдә булган чуен сарайга алып кайтып ябып куярга кушты. Карт, патшаның сүзен ишетүгә, үзенең дошманын җилтерәтеп алып китте дә шәһәргә алып кайтты. Карт бакчадан чыгып кына киткән иде, патша: «Инде бу туйны гомеребездә беренче тапкыр күрүебез»,— дип, зур шатлык белән бакчаның уртасына табын кордылар. Картны көттеләр, карт кайтмады.

Шул вакыт алты куш эт җиктереп, артыннан эттереп, бер су арбасын җигеп, картка каршы җибәрделәр. Озак та бармадылар, карт боларга каршы очрады. Карт көчкә тын алып, мәлҗерәп киләдер иде. Картның каршыга килгән кешеләрне күзе күрми, колагы ишетми иде. Картны, кулыннан тотып, җитәкләп арбага алып килеп утыртып, патшаның туена китерделәр. Карап-карап тордылар. Бу картны патшаның мәҗлесенә түгел, әбрәкәенә дә кертерлек түгел иде. Шулай булса да, күрсәткән хезмәте өчен, табынга утырттылар. Патша ачык чырай белән каршы алып, үз янына утыртты. Патша карттан хәлен сорашты. Карт, патшага:

— Мин бер нәрсә дә белмим, бер нәрсә дә күргәнем юк. Бу эшләр үтеп бетсен дә, актыктан үзеңә генә сөйләрмен,— диде.

Шулай итеп ничә көннәр үткәреп, ашап-эчеп, туй итеп, тук бер йәбәр[1] суеп, ашау да эчү, уйнау да көлү, ачлыктан кырылу, туклыктан егылу, ит тә мит, ашыйм дисәң, икмәк тә юк, шундый зур туй булды. Туй бик күңелле үтте. Патша кайтырга җыенды. Бакчада калган нәрсәләрне, яшелчәләрне шундагы халыкка җыйнап алырга кушты. Үзе кайтып китте, картны да су арбасына утыртып, шәһәргә алып киттеләр.

Кайткач, патша, картка:

---

[1] *Йәбәр* — симез ат (*И.Кунош искәрмәсе*).

— Инде, бабай, мин синең хезмәт ялына ни бирим, ни телисең? — диде.

Бабай:

— Миңа үзем күтәрә алганча алтын бирсәң, мин синнән бик разыймын,— диде.

Карт үзе күтәрә алганча алтынны алып, өенә кайтып китте.

Күп вакыт үтмәде, патшаның күңеленә, келт итеп, сарайга япкан карт исенә килеп төште. Картны чакырып китертеп, аңардан ничек эшләргә кирәк икәнен сорашырга кирәк, дип сакчы картны алырга җибәрде. Картны әлеге су арбасына утыртып алып килделәр. Патша карттан бу эшләрне ипләп кенә сораша. Карт патшага хәлләрне берәм-берәм сөйли башлады:

— Бу ябылган карт ике ел синең бакчаңны корытты, өченче елны миңа килеп капты, инде бу картны яңадан дөньяга чыгарырга ярамый. Әгәр дә чыга калса, ул вакыт мине дә, сине дә сау калдырмас, барыбызны һәлак итәр, үз хөкемеңне үзең бир дә аны шунда бетер,— диде.

Патша, картның сүзләрен тыңлап торды да:

— Ярый, бик яхшы, мин аны астыртып, кистерермен,— диде.

Сакчы карт тагын үзенең өенә кайтып китте. Патша бу карак картны үтерергә таган корып, халыкны җыярга уйлады.

Көннәрдән бер көн патшаның бердәнбер улы чуен сарай буенда ук, җәясен кулына тотып уйнап йөргәндә бер угы чуен сарайның мөрҗәсеннән сарайның эченә барып төшә. Бу, бала булганлыктан, ничек булса да угын алырга уйлап йөри. Малай сарайның ишек төбенә килеп, әйләнеп йөри. Шул вакыт малайның аяк тавышын ишетеп, карт, эчтән, малайга:

— Әгәр дә син ишекне ачсаң, мин сиңа угыңны алып бирермен. Мин болай да алып бирер идем, күрәсең бит, ишек бикле. Мин ача алмыйм,— диде.

Малай:

— Соң, бабай, аның ачкычы миндә юк бит, мин аның кайда икәнен дә белмим,— диде.

Карт малайга:

— Ачкычны син белмәсәң, мин беләм, ул ачкыч синең анаңның уң як күкрәк кесәсендә, әгәр дә анаңнан шул ачкычны алып сарайны ачсаң, угыңны алырсың,— диде.

Малай ачкычны алу өчен өенә төшеп, анасы тирәсендә сырпаланып йөри торгач, бервакыт анасы бөгелгән арада анасын кочаклаган булып,

ачкычны эләктереп алды да шыпырт кына сарайга барып, кеше күрмәгәнне сагалап торды да сарайны ачып җибәрде. Ишек ачылуга, карт атылып чыгып та китте. Малай үзенең кирәген алып сарайдан чыгып, буш сарайны яңадан бикләп куйды, ачкычны, бер җайлы вакыт табып, анасының кесәсенә салып куйды.

Берничә вакытлар үткәч, патша, сакчы картның сүзе буенча, бу сарайдагы картны инде үтерергә кирәк, дип бердән бер көнне таган кордырып, кул астындагы кешеләргә шул көнен җыелырга, дип язу җибәрде. Таган хәзер булды, төрле яктан кешеләр килә башладылар. Патша, кешеләр җыелып беткәч тә хатыныннан ачкычны сорап алды да, бөтен халыкка ни өчен җыйганын сөйләп, сарайны ачарга дип барып, йозакка ачкычны тыгып, ачып җибәрде. Ишек төбендә йөзләрчә кеше коралланып, карт чыгып китмәсен, дип саклап торалар иде. Сарайны ачтылар — карттан җилләр искән. Патша үзенең ачуыннан ни эшләргә белмичә, хатынын чыгарып алып җавапка тартты. Патша, хатынына:

— Ник ачып чыгардың, мин сиңа ачкычны үземнән башка һичберкемгә бирмәскә куштым бит. Әйт тизрәк, юкса башыңны кисәм,— диде.

Хатын антлар итеп, җылап:

— Мин бер кешегә дә ачкыч биргәнем юк,— дип, патшаның аяк астына егылды.

Патша:

— Әйт, әйтмәсәң сиңа котылу юк,— дип кылычын кынынннан тартып чыгарып, хатынның башын чабып төшерим дигәндә генә, малай йөгереп килеп, кылыч астына барып керде. Җыелган халыкның исе китеп, тыннарын да алмыйча, ни булыр икән дип, эшнең соңын көтеп торалар иде. Патша, кылычын түбән төшереп, малайга:

— Ни сөйлисең бар, сөйлә, юкса анаңны моннан соң күрә алмассың,— диде.

Малай:

— Бу турыда минем анамның тырнак кадәр дә гаебе юк, мин әниемне бик яхшы беләм, ул бер кешегә дә ачкычны биргәне юк, эш алай түгел, менә болай,— дип, үзенең ук атып, угы мөрҗәдән сарайга төшеп, аны алыр өчен ачкычны анасыннан тойдырмыйча урлап алып, угын алыр өчен сарайны ачкан чагында картның чыгып киткәнен — барын да ачык иттереп сөйләп бирде.

Патша, күзләрен канландырып, йөзен чытып, мыегын тырпайтып, колакларын чөгендер кебек кызартып, чигә тамырларын бүртереп,

чыдамсызлык белән малайның сөйләгәнен тыңлап торды да, малайның башын кисәм, дип кизәнгән иде, вәзирләре патшаның кулын тотып калдылар.

Патша:

— Алай булгач, үтермәсәм үтермәм, шулай да бу баланы мин янымда тотар хәлем юк, барыбер кол итеп берсенә биреп җибәрим,— диде.

Вәзирләр:

— Патша булган кешегә болай кылыну килешми, алай булса син аны, мал биреп, үз иркенә кая булса да чыгарып җибәр,— дип киңәш бирделәр.

Патша, вәзирләре әйткәч, теләсә-теләмәсә дә, булдыра алмады, малайны чыгарып җибәрергә булды.

Иртәгесен бер арбага бер ат җиктереп, ике кол биреп, аларны алга утыртып, малайны артка утыртып, үзе озатырга өйдән чыкмыйча, чыгарып җибәрергә кушты. Вәзирләр җыелган халыкны таратып җибәрделәр. Халык: «Инде бу патша үзенең бу кызулыгы белән ниләр эшләп калыр икән, безне юкка гына җыйды»,— дип таралып киттеләр. Халык таралып беткәч тә, арбага ат җигелеп, ике кол билгеләнеп, малайны юлга озатырга вакыт җитте. Малай җылап анасы белән күрешкәч, атасы белән дә күрешмәкче булган иде, патша малаен күрешергә кертмичә дә, чыгып киткәне юкмыни, дип ачуланып: «Хәзерге сәгатьтә монда булмасын»,— диде. Вәзирләр калтыранып, җылашып малайны чыгарып җибәрделәр. Малай капканы чыгып китеп, кырга чыккач, борыла-борыла карап, күзеннән яшьләр агызып, Аллага тапшырып, шәһәрдән чыгып югалды.

Берничә вакытлар барганнан соң, алга утырган коллар малайның өстеннән патша киемнәрен салдырып алып, үзләре киделәр дә, малайны алга утыртып, олы юл белән тузан туздырып, атның аякларын берсеннән-берсен уздырып, ал көпчәкләр артыннан арт тәгәрмәчләрне тәгәрәтеп, күзләре караган якка киттеләр. Ай киттеләр, ел киттеләр, ничә көннәр баргач, бер шәһәргә барып җиттеләр.

Шәһәрдән үтеп барганда, шәһәр башлыгының сарае турыннан узганда шәһәр башлыгы күреп, бу нинди патшалар, дип, үзенә кунак булырга чакырып кертте. Болар килеп керделәр. Малай йортка[1] барып керүгә, кузладан[2] сикереп төшеп, атны туарып, җарау алдырырга[3] лапаска кер-

---

[1] *Йорт* — ишегалды.

[2] *Кузла* (*урысча: козлы*) — арба яки чананың алгы өлешендәге ат тотучы (кучер) утыру өчен махсус ясалган урын.

[3] *Җарау алдыру* — ял иттерү.

теп, өрлеккә тезгене белән башын күтәртеп, боҗрага бәйләп куйды. Коллар, патша малайлары булып, туры сарайга кереп киттеләр. Патша аларны һичбер аера алмады, чынлап та патша дип белеп, кулыннан килгән кадәр боларны кунак итәргә тырышты. Патша үзенең бүлмәсенә алып кереп, бер өстәлдән, бер табактан аш ашатты.

Бу вакыт малайны, тамагын туйдырыр өчен, ялчылар өенә алып килделәр. Малай түбән генә, аяк астына карап, болар артыннан акрын гына, ирекле-ирексез генә атлап, күңелләре тулып, күзе мөлдерәп яшь белән тулып барып керде. Малай карарга матур, һәркемнең күзенә чалынырлык түгәрәк йөзле, матур борынлы, йомры иякле иде.

Әмәлгә[1] каршы, патшаның өч кызы бар икән. Бу кызларның ике олысы әлеге патша бүлмәсендә кунак булып утырган ике егеткә күзләре төшеп, күкрәкләре, табаннары кызып, кая басарга җир тапмыйча, кызган табадагы борчак кебек сикергәләнеп йөриләр. Алай да булса, патша үзе боларның матурлыгына карамыйча, төпчек кызын бик якын күрә иде. Озак та үтмәде, патша эшне сизде, ике кызын бу ике егеткә биреп зур туй ясап, кырык тәвә чалып, ат казылыклары туттырып, тавыклар кыткылдатып, дөмбер-дөмбер барабан кагып, сарайны селкетеп, кунаклар чакырып, никах укытып кияү бүлмәсенә яптылар. Бу вакыт ат башында утырып килгән малай күзен түбән төшереп, кашын-кабагын җимереп, ни эшләргә, кая барырга белмичә, тинтәк сарык кебек әйләнеп йөри иде. Тинтерәп йөрми нишләсен, туй булып үтте.

Ничә көннәр акрын гына су агымы кебек агып киттеләр. Моңардан, күңеле өчен берәү булсын, килеп бер сүз сорашучы булмады, әмма кияүләрдән патша үзе, хатыны, вәзирләре көне-төне сорашып, кай җирлек, кайсы патшаның балалары икәнен сорашып күңелләрен табарга тырышалар иде. Олы кызларның туйлары узды, туннары туза башлады.

Бердән бер көнне кече кызы, анасына:

— Әни, мин болар белән килгән малайны яратам, әгәр дә сез күнсәгез, мин аңарга барыр идем,— диде.

Анасы:

— Ай-һай, балам, синең ул эшең килешмәс, мин атаңа андый сүзне сөйләргә куркам, шулай да булса җае белән бервакыт атаңа сөйләп карармын,— диде.

Яшь кызның алма кебек җитлеккән чагы иде. Туталары кияүләре

---

[1] *Әмәл* — күрәчәк.

белән кочакланышып, телгә-телне терәп, берсен-берсе суырып үбеп, ефәк кебек ишелеп ятканда, бу кызның да алар кебек ятасы киләдер иде. Ике-өч көн чыдады, анасыннан җавап көтте, анасы һаман моңарга бер сүз дә сөйләмәде. Бу кыз җиңелчә генә уйлады да, атасын бер җайлы урында туры китереп:

— Әти, мине дә инде җизниләрнең ат башы булып килгән егеткә бирегез,— диде.

Атасы кызыннан бу сүзләрне ишетергә уйламаган иде, ишетмәгә бик аптырап китте:

— Ярый, киңәш итәрбез,— дип, кызын юатып, борып җибәрде.

Патша, тыныч кына ятканда аяк астыннан бәла килеп чыкты, дип, берничә көннәр үз-үзеннән уйлап, башын ватып йөрде. Көн кич булды. Патша хатыны белән түшәгенә килеп яттылар. Патша үзе сүз башлап, хатынына кызы турысында сөйли башлады:

— Әгәр дә без кызыбызны әлеге егеткә бирсәк, күзебезне ачырмаслар, бөтен кул астында булган халык безне яманлап сөйләрләр. Инде син ничек булса да кызга әйтеп кара, йөрәген баса алмасмы, безгә ничек булса да эшне басарга кирәк. Син аның колагына ярамаган якларын бераз тукы.

Иртә торуга патша хатыны, кызын чакырып:

— Кызым, бу патша кызларына килешә торган эш түгел, бу эшкә атаң да күнми, минем дә күңелем тартмый, сабыр ит, сиңа да үзеңнең тиңең табылыр, патша баласы килеп чыгар,— дип үгетләп карады.

Кыз:

— Сез минем сүземне тыңламасагыз, мин дә сезнең сүзегезне тыңлый алмыйм, йә яшертен барам, йә муенымны чабып, башымны өзәм, әмма аңарга бармыйча калмыйм,— дип, үз сүзендә нык торып, анасына җавап бирде.

Бу вакыт патша, болар ни эшли икән, анасы кыз яклы түгел микән, дип, койма аша ярыктан тыңлап торды. Кызның бу сүзләрен ишетеп хәйран калып, бирми булдырып булмас инде, дип, юллар эзли башлады да, боларга белдермичә генә, мәче кебек аяк очы белән генә басып, өсләренә килеп керде.

Кыз, атасын күргәч, барып атасының муенына асылынды да:

— Әти, мин шулай ат башындагы малайга гашыйк булдым. Инде ни эшләтсәгез дә эшләтегез, мине аңарга бирегез, юкса мин үз башыма үзем җитәм,— дип, атасына икенче кат үзенең теләген сөйләп бирде.

Патша, кызына:

— Инде, кызым, эш болай булгач, җаен карарбыз, мин сине шул малайга бирермен, тик малайга берничә нәрсәләр сөйлисем бар. Әгәр дә ул мин әйткәннәрне булдыра алса, ул вакыт мин бу эшкә күнәм,— диде.— Беренче шартым шул,— диде,— иртәгә иртә торуга мин ул малайга йөз баш куй биреп җибәрермен, кичкә хәтле ашатып-эчертеп, корсакларын гөптәй, аякларын җептәй иттереп, аларны ике йөз башка җиткереп алып кайтсын,— диде.

Төн үтте, таң атты, яктырды, кояш чыкты. Патша малайга йөз баш куй санап җибәрергә кушты. Малайга патшаның боерыгын җиренә җиткереп, йөз баш куй санап биреп, үзенә чыбыркы тагып, капкадан чыгарып җибәрделәр. Бу вакыт патшаның кияүләре яңа гына юрган астыннан, канат астыннан башларын калкыткан кош балалары кебек, башларын калкытып торып, тәрәзәдән бу малайның башын түбән салып, куйлар алып чыгып барганын күреп, үзара көлешеп калдылар. Малай урам буе күңелсез генә куйларны әйдәп алып китеп, кырга чыгып ашатырга таратып җибәрде дә, үзе аяклары талганга җиргә утырып, кулындагы таягы белән җирне чукып тора башлады, куйларга да карап ала. Алар һаман ашауларында, арткан нәрсә күренми. Малайның башында зур кайгы бар.

Утыра торгач, малай артына борылып карады, күрде: юлдан тузан туздырып, аякларын берсеннән-берсен уздырып, сакалын сәлперәйтеп, ләһелдәп бер картның килгәнен күрде. Бу картның һичбер кешегә охшаган җире юк иде. Карт якынлашты, килеп малайны кочаклап алды. Малай картның кем икәнен белмәде, ә карт малайны таныды. Бу карт, малайны үз янына утыртып, хәлен сораша башлады.

Малай:

— Әй, бабай, минем көнем начар,— дип, үзенең тормышыннан бик зарланды.

Карт:

— Балам, син һичбер нәрсә өчен кайгырма, әлек тамагыңны гына туйдыр,— дип, кесәсенә кулын тыгып, бер яулык тартып чыгарды да җиргә җәйде.

Шул ук сәгать яулык эчендә төрле ашамлыклар булып, эскәтер тулы кара ит, кисәр карасы юк, кабар калҗасы юк, даңгырдаган бер сеңер, икәүләшеп кимерергә тотындылар. Ашаган арада малай куйларга күз салып та, арткан нәрсә күренми.

Бабай:

— Балам, ни өчен аларга карыйсың, алар бер җиргә дә китмәсләр, күрәсең, йотлыгып кештер-кештер үлән ашап йөриләр,— диде.

Малай:

— Әй, бабай, менә минем эшем болай, мине шул куйларны кичкә кадәр ашатып, туйдырып, кич булгач, йөз башны ике йөз баш итеп алып кайтырга куштылар,— дип, үзенең хәлен сөйләп бирде.

Бабай:

— Әй, балам, әле син мине белмисең, мин сине бик беләм бит, син мине зур үлемнән коткардың, анаңның күкрәк кесәсеннән ачкыч урлап, чуен сарайны ачып чыгарып җибәрдең, инде синең яхшылыгыңа каршы мин сиңа, үзем дөньяда исән булган чагымда, кулымнан килгән кадәр булышырмын,— дип, үзен-үзе малайга танытты.— Куйларың өчен дә кайгырма, аларның әмәлен табарбыз, аны мин сиңа эшләрмен, алар ике йөз түгел, өч йөз дә булыр,— дип, малайны юатты.

Аш өстеннән торып, бабай малайның башын-күзен сыпырып, куйларга таба карап киттеләр.

Куйлар янына барып җиттеләр. Бабай малайга куйларны санарга кушты. Малай йөзне саныйм дип, ике йөзне санап күзеннән үткәрде. Бу вакыт кич булып киләдер иде.

Бабай:

— Балам, инде куйлар ике йөз булды, син боларны алып кайтып азбарга[1] җибәрерсең, әле эш моның белән бетми. Иртәгә тагы ул сиңа ике йөз биреп дүрт йөз итеп алып кайтырга кушар, әмма син аның өчен бер дә кайгырма, менә мин бу урынга таягымны кадап китәм, куйларыңны шунда гына әйдәп китерерсең дә, мин тагын шунда килеп җитәрмен,— диде.

Малай куйларны куып кайтып китте. Бабай да таягын кадап, үз юлына атлап китте.

Малай куйларны каулап[2] алып кайтты. Куйларны санап карадылар, нәкъ ике йөз булып кайтканнар. Патшага кереп сөйләделәр. Патша, ышанмыйча, үзе чыгып санап карады, куйлар дөп-дөрес ике йөз иде. Патша, бу эшкә аптырап китте, әмма кыз шатланып, уйнаклап йөридер иде.

Патша кереп кияүләренә хәлне сөйләгән иде, алар да аптырашып, үзләренә пошым керде.

---

[1] *Азбар* — абзар.
[2] *Каулау* — куалау.

Кияүләр патшага:

— Инде эш моның белән генә бетмәсен, иртәгә ике йөз биреп җибәреп, дүрт йөз алып кайтырга куш,— диделәр.

Патша, бу сүзне колагына салып, иртә торуга ике йөз биреп җибәрергә куша. Иртә торуга патшаның аткан ук кебек әйткән сүзе җиренә җиткерелә. Малай чыбыркысы белән куйларны куып алып китә дә төнәге[1] урынга алып барып таратып җибәрә. Озакламыйча карт та килеп җитеп, малай белән күреште, исәнлек-саулык сораштьп. Малай хәлне белдереп, утыра.

Бабай:

— Балам, куйлар өчен кайгырма, элек тамагыңны туйдыр,— дип, тагын яулыкны җәеп, тамакны туйдырып алдылар.

Кояш батарга якынлашып барадыр иде. Карт малайны тагы куйлар янына алып барып, санарга кушты. Малай санап карады, куйлар дүрт йөз баш булып чыкты.

Бабай:

— Иртәгә сиңа тагы дүрт йөзне алты йөз итеп алып кайтырга кушарлар, әмма син аның өчен кайгырма, мин исән булганда бар да булыр, тагы шул урынга алып килеп таратырсың, гомерем булса, мин дә килермен,— диде.

Малай, куйларны алып кайтып, санап кулларына бирде. Патша һәм кияүләре бу эштән тагын шикләнә башладылар. «Инде иртәгә дүрт йөзне алты йөз итеп алып кайтырга боерыйк»,— дип, сүз беректереп куйдылар.

Иртә торуга дүрт йөз куй санап биреп, малайны тагы ярты икмәк, бер тырык су биреп, кырга чыгарып җибәрделәр. Малай куйларны алып китеп, үткән көндәге урынга таратып җибәрде. Куйлар ашый башладылар.

Озак үтмәде, бабай тагын малай янына килеп җитте дә, болар күрешеп сораштылар. Бу юлы бабайның кулында бер капчык белән зур гына нәрсәсе бар иде. Бабай, малай янына килеп, капчыкны җиргә куйды да үткәндәге кебек малайга ашарга-эчәргә хәзерләде. Малай куанып ашарга утырды. Малай бераз гына капкаларга тотынган иде, бабай малайга китереп куйган капчыкны җирдән күтәреп алырга кушты. Малай тиз генә уйлап, капчыкны бер якка китереп ташларга уйлады. Барып күтәрергә дип көчәнеп карады — кузгата да алмады. Малай кызарып килеп, оятыннан берни эшләргә дә белмәде. Бу болай булмый икән дип, беләкләрен

---

[1] *Төнә* — кичә.

катырып, тез буыннарын ныгытып, яңадан чынлабрак тотынып күтәреп карады — тезенә кадәр күтәрде. Бабай капчыкны ташлатып, малайны тагы ашарга-эчәргә утыртты. Малай янә ашый гына башлаган иде, бабай малайны урыныннан торгызып[1], капчыкны күтәреп карарга кушты. Малай, баягыча бар көчен җыеп, капчыкны күкрәк авызына кадәр күтәрде. Бабай янә капчыкны куярга кушып, малайны ашарга-эчәргә утыртты. Малай бик яхшылап аш ашап, су эчеп, тамакны туйдырып, картның алдында басып торды.

Бабай малайга:

— Йә, балам, инде синең белән минем бүген актыккы күрешүебез, моннан соң инде каршы килеп дөньяда күрешә алмабыз,— дип, капчыкны җирдән һавага чөеп җибәрергә кушты.

Малай иплә кенә тотып, капчыкны алып, һавага чөеп җибәргән иде, капчык үзеннән-үзе күтәрелеп китеп, күздән югалды. Берничә вакытлар үткәннән соң, капчык пырылдап җиргә килеп төште. Шул вакыт бабай малайга:

— Йә, балам, кич була, куйларны сана, кайтырга вакыт җитә,—дип, малайга куйларны санарга кушты.

Малай санады, куйлар алты йөз булды. Бабай малайга куйларны санап бетергәч тә:

— Инде сиңа бүләгем шул,— дип, бер яулык белән бер балдак бирде.— Яулыкны җәйсәң, ашарга хәзер булыр, кирәк вакытта аптырамассың, әмма балдакны үзеңә кирәк вакытта авызыңа куеп сызгыртсаң, шул вакыт бер акбүз аргамак бар кебек сугыш кирәк-яраклары белән алдыңда басып торыр,— диде дә бабай, малай белән исәнләшеп, аркасыннан сөеп,— инде күрешә алмабыз,— дип, җылашып, аерылышып киттеләр.

Малай куйларны алып, шәһәргә кайтып китте. Яулык белән балдакны кесәсенә бәйләп салды, куйларны алып кайтып, санап тапшырды.

Патшага кереп әйттеләр. Патша аптырап китте. «Инде һичбер әмәл юк, кызны бирергә туры килер, ахры»,— дип, үз-үзеннән уйланып-уйланып йөри башлады.

Кыз атасының егеттән көткән нәрсәләрнең җиренә җиткерелгәнен күреп: «Мине инде бирегез»,— дип, атасын җөдәтә башлады. Патша инде: «Әйткән сүз — аткан ук, авыздан ычкынды»,— дип, туйга хәзерләнә башлады.

---

[1] *Торгыру* — торгызу.

Көн үтте, көн артыннан төн үтте, туй көне килеп җитте. Патша, бар кебек кул астындагы кешеләрен җыеп, үзенең актык туен бик шәп иттереп уздырырга уйлады. Халыклар җыелды, барабан кагылды, быргы кычкыртылды, ашъяулыклар җәелде, табак-кашыклар тезелде, кәндиләргә[1] кымызлар тутырылды, җитмәгәнне үгезләрне савып, сабаларга алдан хәзерләп куйдылар. Егетне киендереп, туйга, табынга керергә чакырдылар, ләкин егет:

— Мин бер хезмәтче, анда керергә оят булыр, миңа монда аш өе дә ярый,— дип, анда керергә кыймады.

Инде көчләп бер эш тә эшләп булмас дип, егет өчен аш өен аннан-моннан җыештырып, чаршаулар корып, кашагалар кагып, чыбылдыклар асып, ике кат түшәк җәеп, кирәк булган табак-савыт, ләгән-комганнарны җылы су белән тутырып, хәзерләп куйдылар. Кызны киендереп, чулпыларын тактырып, колак алкаларын астырып, иннекләр буятып, кершән ягындырып, теш кара яктыртып, бизәндереп-төзәндереп башына чәчрәткәсен[2] кидереп, чәчләрен толымлап үреп, муенсалар кидереп, изүле күлмәкләр кидереп, читек-башмак кидереп, бер битен ай, бер битен кояш кебек нурландырып, егетнең янына алып килеп керттеләр. Егет белән кыз кавышты, икесе дә рәхәт табышты.

Төн үтте, егет — кияү, кыз — бикәч булды. Шулай итеп, туй көннәре үтте, болар ирле-хатынлы көн күрергә тотындылар. Егет кызга үзенең кем икәнен яхшыдан-яманнан бернәрсә дә сөйләмәде.

Көн күргәндә, ашаганда-эчкәндә, бердән бер көнне патшага капыл гына бер хат килеп төште. Хатны алып укыдылар, укып карасалар, шаккаттылар, аңладылар: шул якын көннәрдә егерме дүрт башлы бер дию пәрие моңарга сугыш белән килгәнен белдергән иде. Патша моны ишетүгә бик зур хафага төште, көннәрнең рәхәте үтеп, патша сугышка хәзерләнергә тотынды. Бөтен кул астындагы халыкны җыеп, кораллар хәзерләп, дөньяны кыйратып алып-биреп йөргән чакта, кече кияве:

— Мин урманга барып агач кисеп йорт салмакчы булам, монда тору безгә килешми,— дип, хатынын атасына кертеп җибәрә.

Кыз атасына барып сөйләгәч тә, патша:

— Хәзер өй кайгысымыни миндә, юк нәрсә сөйләп йөрисең,— дип,

---

[1] *Кәнди* — кечкенә табак.
[2] *Чәчрәткә* — чәчкә куела торган тәңкәләр белән бизәлгән тасма.

кызын кыздыра. Шулай булса да: «Барса-барсын, киртәдән бер корчаңгы атны алсын»,— дип, рөхсәт бирә.

Егет бу чакта егерме биш яшьтә иде. Бик гайрәтле, көчле, бик матур, бик чибәр, күрсәң гайрәтең чигәрлек булып үсте.

Патша үзенең ике кияве белән гаскәр җыйнап, бик хафаланып сугышка чыгып китә.

Шул чакта егет патша алырга әйткән атны су чанасына җигеп, артка таба карап утырып, капкадан сикертеп чабып чыгып, барып керде бер чүплекнең арасына. Анда тулы эт көтүе иде. Шул җирдә корчаңгы атны алга таба этеп, артка таба койрыгыннан тотып, тиресен тартып чыгарды да итен, җылы көе ашагыз дип, этләргә ташлады. Үзе чүплекнең бер читенә чыгып, кесәсеннән яулыгы белән балдакны кулына алды.

Бу вакытта патша дию пәриенең гаскәре белән дөнья кырып, уңга килгәнен уңга алып, умрау сөяген ватып, сулга килгәнен сулга алып, кабыргаларын ватып, сугышып ятадыр иде. Егет балдагын авызына кабып бер сызгырып җибәргән иде, һавадан бер ак аргамак бөтен сугыш киемнәре белән каршына килеп басты. Егет хәзернең эчендә аргамакка атланып алып, сугышка таба очырып барып, сугышка да кереп китә. Уңга-сулга кылычын селтәп, дию пәриләрен тиземе белән ура башлады.

Озак сугыша торгач, егет дию гаскәрен кырып та бетерә һәм очып китеп тә югала. Моны тотып, кем икәнен белер өчен кудырып, артыннан кешеләр җибәрәләр. Куучылар куып, артларын уып, күрә дә алмый калалар.

Бу егет әлеге чүплек янына кайтып төшә дә, кесәсеннән балдагын алып, сызгыртып, атны тагы һавага очыртып җибәрә дә, баягы этләргә ташлаган үләксәнең сөякләрен теркәп, яңадан башы белән чанага таба каратып җигә дә, утырып, өйгә кайтып китә. Моңарга юлда сугыштан кайтышлый патша каршы очрый. Бик күңеле кырылып, моның өстенә карар-карамас кына яныннан үтеп китә. Патша йортына кайтып керүгә, бу да артларыннан кайтып керә дә корчаңгы атын туарып, киртәгә җибәрә.

Патша куанычын эченә сыйдыра алмый, хатынына:

— Безнең эш бик начар иде, әле дә талигыбыз[1] бар икән: әллә кайдан бер егет килеп чыгып, безгә булышып, дошман гаскәрен кырып китте. Тик шунысы үкенечле булды, кем икәнен белә алмый калдык,— дип мактанды.

---

[1] *Талигъ* — бәхет.

Дию пәрие яңадан хәбәр җибәреп, сугыш белән киләсен белдертте. Патша тагы кайгыга төшеп: «Инде берсеннән котылган идек, монысыннан ничек котылырбыз»,— дип, гаскәрен җыйдырды да сугышка чыгып китәргә хәзерләнде. Шул арада кече кияве: «Тагын урманга барам, кискән бүрәнәләр ызбага җитешми»,— дип, хатынын атасына ат сорарга җибәрде. Кыз барып, тагын атасыннан ат сорады.

Патша:

— Җан кайгысы белән йөргәндә, сез диваналар ат артыннан йөрисез,— дип, бераз тиргәп, яңадан әвәлге корчаңгы атны алырга кушты.

Патша гаскәрләре белән сугышка дип чыгып китте. Кияү корчаңгы атны җигеп, зәренә[1] балтасын кыстырып, чанага утырып, болар артыннан чыгып китеп, тагын чүплеккә барып, баягы кебек атны этеп егып, итен этләргә ашарга бирде. Кесәсеннән балдакны алып сызгыртып җибәрде дә, күз ачып йомганчы, акбүз ат моның каршына килеп басты. Егет атка атланып янә сугышка китте. Гаскәрләр бу вакытта кырылышып сугышып яталар иде. Егет барып та керде, бер селтәүдә унарунбишәр кешене берьюлы аяктан екты.

Берничә көннәр үткәннән соң егет, сугышны бетереп, дию гаскәрен кырып, яңадан арадан чыгып югалды. Патша моны белми калуына үкенеп, җиңүенә куанып, тагын өенә кайтып китеп, хатынына кереп мактанды:

— Әле дә безне Алла ташламый, үткән юлдагы егет бу юлы да килеп безгә булышып, дию пәриен кырып бетереп, күздән югалды,— диде.

Янә болар барын ашап, югын бар итеп, барын юк итеп, азмы-күпме рәхәт кенә яшәгән чакта дию пәриеннән өченче тапкыр сугышка дип хәбәр килеп төшә. Патша моны ишетүгә тетрәп-калтырап, кая басарга урын тапмыйча, ни эшләргә белмичә, дөнья күзенә күренмичә, кызу табага баскан кебек сикергәләп йөреп, вәзирләрен җыеп, кияүләрен чакырып, киңәш итәргә кереште. Бар да беравыздан: «Тагын гаскәр җыеп, каршы барырга кирәк, анда баргач янә Алла булышыр, җае табылыр»,— дип, сугышка барырга хәзерләнделәр.

Шушы чакта кече кияве тагын: «Мин җитмәгән җиргә бүрәнә кисәргә барыр идем, ат бирмәсләр микән»,— дип, кызны атасына кертеп җибәрде. Кыз атасына барырга курыкса да, киявен җаны-тәне белән яратканлык-

---

[1] *Зәр (зәәр)* — бизәкле тукымадан яки шнурдан үреп эшләнгән билбау.

тан, аның сүзен аяк астына салмый, ни күрсәм дә күрермен дип, батырланып атасына кереп, киявенең сүзләрен сөйли. Атасы бу сүзләрне ишетүгә кашын-кабагын җимереп:

— Бу нинди эш, кеше җан биреп илне коткарырга йөри, ул урманга барып, келәү акчасына[1] тормаслык бүрәнәләр кисәргә китәргә йөри,— дип ачулана да, ни теләсә шуны эшләсен, инде кеше көлдерүдән туктамас кеше бар икән, дип, әлеге корчаңгы атны алсын, ул барыбер безнең кирәккә ярамый, дип, кызын яныннан чыгарып җибәрә.

Кыз, кайтып, киявенә эшнең ничек икәнен сөйләп бирде.

Егет азбарга барып, корчаңгы атны алып, чанага җигеп, урманга дип чыгып китте. Егет чүплек башына барып атын төртеп егып, итен этләргә ташлап, кесәсеннән балдагын алып, сызгыртып җибәрде. Алдына акбүз ат бар кебек киемнәре белән килеп басты.

Егет атланып, патшаларның сугыш мәйданына таба карап, юыртып барып җитә дә күрә: патшаның бар кебек гаскәре кырылып беткән. Кизү патша белән вәзирләргә килеп терәлгән. Егет килеп тә җитә, сугышка кереп иң әлек дию пәриенә барып бер кылыч сала, бер чабуда унбиш башны өзеп төшерә.

Кырышып-сугышып йөргән чакта егетнең уң кулы җәрәхәтләнә. Моны патша күреп, егетнең катына барып кесәсеннән ефәк яулыкны тартып чыгарып, егетнең ярасын бәйли. Егет белән артык сөйләшеп, сорашып торырга вакыт юк. Кулын бәйләтүгә, барып сугыш башлап, барын да кырып бетереп, егет үз уңаена күздән китеп, каядыр югала. Патша яңадан, бу юлы да күрә алмадым, сорый да алмадым, дип, бик үкенә һәм, инде мин бу егетне моннан соң кайда гына туры китереп сөйләшермен, дип, эченнән генә уйлый.

Егет янә чүплек башына кайтып, акбүз атын җибәреп, корчаңгы атын җигеп кайтып керде дә, хатыны каршы чыгып, эшнең ничек икәнен сораштылар. Егет: «Инде бер өйгә җитәр, Аллаһ теләсә, өй салырбыз»,— дип күңелләрен басты.

Егет үзенең өенә кереп ашады-эчте дә:

— Мин бик арыдым, инде ял итәргә вакыт килде, мин ял итәргә ятам. Җиде көн, җиде төн үтмичә торып мине уятма,— дип, бар кебек киемнәрен баш очына салып, бишмәтен ябынып, йокларга ятты.

Күп вакыт үтмәде, җир тетрәтеп, күк күкрәтеп, музыкалар уйнатып,

---

[1] *Келәү акчасы* — сәдака акчасы.

авызын ерып, патша үзенең сараена кайтып керде. Хатыны вә сарайда калган кешеләр дә куанычлык белән каршы алдылар. Ашау-эчү, уен-көлү, көн дә бәйрәм, төн дә туй башланды. Егетнең ятканына өч көн үтеп, дүртенче тәүлеккә чыкканда йокысы белән киерелеп китеп уң кулын сузып җибәрә. Җәрәхәтенә бәйләгән яулыгы чыгып күренүгә, кыз бу яулыкның атасыныкы икәнен танып алды да йөгереп менеп анасына күргәнен сөйли башлады.

Кыз:

— Әни, мин кияүнең беләгендә әтинең ефәк яулыгын күрдем, каян алгандыр,— диде.

Анасы тыңлап бетерер-бетермәс тиз генә кереп, патшага сөйләде. Патша ышанмыйча йөгереп төшеп, барып тәрәзә аркылы карады да, үзенең яулыгын күрүгә, танып, язылган исемен күрде дә һушсыз булып егылды. Шуннан патшаны кулга алып, күтәреп кертеп, урынга салдылар. Сорашып карыйлар, патша эндәшми, телсез-авызсыз булып ятадыр иде.

Шул ук вакыт имчеләр чакыртып, ни булганын сорый башладылар.

Имче, патшаны карап:

— Моңарга бу җирдә яраклы дару табар хәл юк, моңарга Сәмруг кошның уң як имчәк сөте килешсә килешер,— диде.

Имчедән бу сүзләрне генә ишеткәннәр иде, өч кияүне дә дару эзләргә атлар иярләтеп, күрешеп: «Ерак вә куркыныч юлларга китәсез, инде төрле хәлләр булгандыр, бездән разый булыгыз»,— дип, юлга озатып җибәрделәр. Болар өч баҗа бергә олы юл белән чыгып киттеләр.

Ай киттеләр, ел киттеләр, карыш буе җир киттеләр, барып җиттеләр өч аерымлы бер юлга. Анда багана утыртылып, аңарга такта кадакланып: «Уңга киткән уңар, уртага киткән уртача булыр, сулга киткән туңар»,— дип язылган иде. Болар укып карадылар да сулга таба берсенең дә барасы килмәде. Кече кияү: «Ярый инде, сез анда барырга курыксагыз, шобага салырга теләмәсәгез, мин шобагасыз, үзем теләп китәм»,— дип, шул юл белән китәргә аягын салып, урап кияргә дип, бераз утырып калды. Баҗалары шатлык белән икесе ике юлга кереп киттеләр.

Алар китеп күздән югала башлагач, егет торды да, яулык белән балдакны алып сызгырып җибәргән иде, акбүз ат моның алдына килеп тә басты. Егет менеп атланып, тузан туздырып, юыртып, алга таба очып китте. Юлның ике ягындагы агачлар авып кына калалар иде.

Байтак сәгатьләр барганнан соң, барып керде бер кара урманга. Анда

берсе-берсе бер өй калынлыгында юан тирәкләр үскән иде. Егет тирәкнең төбенә барып, атын бер ботакка бәйләп куйды, үзе арлы-бирле аякларын язып йөри башлады. Крута гына[1] башын күтәреп караган иде, тирәк башында ике кош баласы күрде, аларга таба карап торды. Кош балалары телгә килеп:

— Әй, егет, монда нишләп йөрисең? Монда син исән калмассың, исән вакытта китеп кал. Без дә түбән төшеп җир йөзен күрәсебез юк, монда җиде башлы бер җиз аждаһа бар, ул озакламый килеп җитәр инде,— диделәр.

Егет:

— Беткән баш бетсен, килеп карасын, соңра күрербез, ул җиңәрме, мин җиңәрменме, алышып карарбыз,— диде.

Шул көенчә сөйләшеп торганда чыкты давыл, купты җил, тетрәде җир. Егет артына борылып караса, ялтырап килгән аждаһаны күрде дә, алмаз кылычын тартып алып, килеп җиткәнен көтеп торды. Аждаһа килеп җиткән иде, егет кылыч белән бер селтәп, еланның биш башын өзеп төшерде, икенче селтәүдә калган ике башын да чабып төшерде дә, итен турап, бер җиргә өеп куйды — бер тау кадәр булды.

Шул вакыт кош балалары җиргә төшеп егеткә күп рәхмәтләр укып, сөйләшеп торалар иде. Бер канатын күктән, бер канатын җирдән өстерәтеп, сыдырып, Сәмруг кош кайтып килде дә тирәк башына кунды. Тирәк тирә-ягы белән селкенеп китте. Ояда балалар юк иде. Сәмруг кош җиргә караса, балалары җирдә, бу егет белән сөйләшеп торалар. Кош җиргә төшеп, авызын ачып егетне йотарга дип килә иде. Бер баласы анасының авызын каплады. Сәмруг кош эшнең ничек икәнен сорашты.

Балалары:

— Күрмисеңмени, әнә ул — тау түгел, безне әлегә кадәр җәфалап яткан елан, әгәр дә бу егет килмәсә, без әле һаман шуңардан җәфаланып торган булыр идек,— диделәр.

Сәмруг кош егеткә:

— Инде, егет, без аңардан ничек котылырга белмидер идек, син безне коткардың, сиңа бу хезмәтең өчен ни бирик? — диде.

Егет:

— Миңа бернәрсә дә кирәкми, тик уң имчәгеңнән сөт кенә савып бир,— диде.

---

[1] *Крута гына* — кинәт кенә.

Сәмруг кош:

— Ул минем өчен зарарлы, аннан соң мин бала китерә алмыйм, шулай да булса, булган балаларымның рәхәтен күрергә язсын,— дип, бирергә күнде. Ике шешә алып, ике имчәгеннән дә сөт савып бирде.

Егет, куанып, күп рәхмәтләр укып, атына атланып, кайтырга юлга чыкты.

Күп көннәр кайтканнан соң, аерылып киткән аерымларына килеп җитте. Килеп җиткәндә үзләренең сүзләре буенча ике баҗасы моны көтеп торалар иде. Аларга җитәргә бераз калганда акбүз атны җибәреп, үзенең атын эзләп алып, атланып болар янына килеп җитте дә атыннан төшеп хәл-әхвәл сораштылар.

Егет баҗаларына:

— Таптыгызмы? — диде.

Баҗалары:

— Без таба алмадык, син таптыңмы? — диделәр.

Егет:

— Мин таптым, сезгә дә бирим, буш кайтмагыз,— дип, боларга да бирергә булды.

Баҗалары:

— Соң син аның каршысына ни сорыйсың? — диделәр.

Егет:

— Мин аңарга ни сорыйм, сырт үргечләрегезне ярып бирерсез,— диде.

Баҗалары күнеп, сырт үргечләрен ярып, сөт алып, бергәләшеп кайтып киттеләр.

Егет кайтып, үзенең өенә барып керде. Баҗалары берсеннән-берсе узышып, туры сарайга кереп киттеләр дә, патшага: «Барып алып кайттык», дип, сөтне алмаш-тилмәш биреп ирексезләп йоттырдылар. Үләм дип ята торган патша бөтенләй хәлсезләнде. Ике-өч кенә суларга калды. Шул вакыт кече кияве килеп, үзе алып кайткан сөттән бер тамчы эчерде. Патша селкенә башлады. Икенче эчерде — торып утырды. Өченче эчерде — торып йөри башлады. Патша, инде егетнең кем икәнен белеп:

— Ни эшләтсәң дә эшләт, мин бүгенге көннән синең кулда,— дип, киявенә тапшырылды.— Бу көннән мин сиңа үземнең патшалыгымны бирәм, үз урыныма сине патша итеп куям,— диде.

Олы кияүләре тетрәшеп бер читтә торалар иде. Патша киявен аш өеннән алдырып сарайга кертте. Икенче көнне бөтен кул астындагы

халыкны җыеп, патша кешеләрнең күз алдында үзенең бар кебек патшалык эшләрен киявенә тапшырырга булды. Патша яшь киявеннән нинди кеше икәнен сораша башлады.

Егет:

— Мин монда бер үзеңә генә сөйләмим, халык җыелгач, халык алдында сөйләрмен,— диде.

Халыкны җыеп бетерделәр.

Патша, халыкка карап:

— Инде мин картайдым, моннан соң минем урыныма менә бу кече киявем булыр,— диде.

Халык, беравыздан күнеп, яңа патша белән танышырга теләделәр. Яңа патша каршыга чыгып, үзенең кем икәнен болай сөйләргә тотынды:

— Менә моны сезнең дә ишеткәнегез бардыр, моннан берничә айлык җирдә бер зур патша бар. Ул бик гайрәтле, көчле, үзсүзле, үзен бик зур тота, теләгән нәрсәсен, күңеленә төшкән эшне эшләми калмый. Ул бервакыт бакча чәчтерергә уйлап, күп еллар хәзерләнде, ләкин бер чәчтерде — эше уңмады, ике чәчтерде — уңмады, аны бер карт карак килеп урлады. Өченче тапкыр чәчкәндә исә, ачуланып, бөтен халкын җыеп сакчы куярга теләде. Ләкин батырчылык кыла алмадылар. Һичкем разый булып чыкмады. Әүвәлгеләрендә көчләп куйган иде. Бу юлы халыкның үз теләге белән куярга уйлады. Күп сорый торгач, арадан бер карт чыгып, бакчаны сакларга үз өстенә алды, каракны да тотып тоткынга салды. Мин кечкенә вакытымда ук атып уйнап йөргәндә угым зинданга төшеп, аны алыр өчен зинданны ачтым, карак чыгып качты. Атам аны үтерергә дип сарайны ачкач, карак юк булып чыкты. Атам моны миннән күреп, мине чапмакчы булды, тик вәзирләр коткарып калдылар. Шуннан соң атам мине күрә алмады. Ике кол биреп юлга чыгарып җибәрде. Минем колларым мине талап, үзләре минем киемнәремне киеп, мине малай иттереп йөрттеләр. Бу көнгә кадәр мин аларның малайлары булып йөрдем. Хәзер алар минем урынымда калдылар, алар патшаның кияүләре булдылар. Менә актык минутта да алар алдарга, ялганга керешеп, мин тапкан сөтне үзебез таптык дип, алып кайтып бирделәр. Әгәр дә сез аларның ялганын тотасыгыз килсә, мин сезгә аларның аркасын күрсәтим, дип, баҗаларын янына чакырып, аркаларын ачып халыкка күрсәтте.

Егет үзенең баҗаларына:

— Үргечләрегезне кая куйдыгыз? — диде.

Бажалары:

— Сөт сатып алдык,— дип җавап бирделәр.

— Соң, ник патшага үзебез таптык дип сөйләдегез? — диде дә, ялган-бозык кешеләр дөньяда яшәргә тиеш түгел дип, шул ук сәгать икесенең дә башын чаптырып өздерде.

Шуннан соң халык таралып, яшь патшага күп рәхмәтләр укып, аңардан күңелләре булып, киләчәктә аның белән бергә көн күрергә сүз биреп, кайтып киттеләр.

Берничә көннәр генә үткән иде, боларга бер кайгылы хәбәр иреште. Патшаның күршесенә Заль патша сугыш белән килә икән. Берничә көннәр үткәч тә, Заль патша күрше патшага килеп сугыш ачты. Болар: «Анда килгәч, монда да килеп җитәр, бу куркынычтан вакытында котылып калыйк»,— дип, һәм үзенең кем икәнен Заль патшага белдерергә уйлап, болар да Заль патшага сугыш игълан итеп, шул ук көн гаскәр җыярга кереште. Бер-ике көндә гаскәрнең барын кулына җыеп алып, гаскәренә болай дип сүз башлады:

— Әүвәлге патша заманында аңарга ничек тырышып хезмәт иттегез, инде мин дә сездән ул вакыттагы кебек хәзерге куркынычтан котылу өчен җаныгыз-тәнегез белән тырышуыгызны үтенәм.

Гаскәр моның авызыннан чыккан сүзне ишетүгә, беравыздан:

— Әлегә кадәр син безгә зарарга йөрмәдең, инде моннан соң да безнең файдага тырышырсың, без тугрылык белән хезмәт итәргә күнәбез,— дип җавап бирделәр.

Гаскәре моның нинди кеше икәнен вә нинди сугыш һөнәрләре бар икәнен — барын да беләләр иде.

Азмы-күпме вакыт үтте. Заль патшага каршы сугышка дип, җыр җырлап, барабан кагып, тузан туздырып, юлга чыгып киттеләр. Бара-бара барып җиттеләр бер урманның кырыена. Урман кырыена барып җитүгә, патша гаскәрләрен ял итәргә туктатты. Бу вакытта сугыш урыны да ерак түгел, бер-берсенә кычкырышкан тавышлары ишетелә иде. Гаскәрләр ял итәргә дип ятып калдылар. Патша үзе белән ике күзәтче алып: «Миннән башка бер яры да китмәгез»,— дип боерып, күздән югалды.

Бераз барганнан соң патша сугыш урынына барып җитте һәм күрде: Заль патшаның гаскәре бик көчле. Бу патшаның гаскәре аларны җиңәрлек түгел иде. Шуларны күзәтеп, үзенең гаскәре янына кире кайтып, сугышның ничек икәнен, юлларын ачык сөйләп, үзе артыннан ияртеп алып китте. Сугышка барып җитүгә:

— Миннән башка сугышка кермәгез, мин үзем алдан керермен, мин кергәч, артта калмагыз,— дип, гаскәренә сөйләде.

Үзе кульяулыгы белән балдагын алыйм дип кесәсенә тыгылган иде — яулык та юк, балдак та юк. Буш кулын кесәсеннән тартып алып, күңеле кителеп, гаскәренә:

— Инде эш без дигәнчә булмады, мин бер кайгыга очрадым, кире өйгә кайтырга тиеш, әмма сез сугыша торырсыз,— дип, баш вәзиренә эшне тапшырды да үзе кире өенә кайтып китте.

Юлда вакыт үткәрә алмыйча, ничек кирәк алай өенә кайтып керде. Өйгә кайтуга өйдәге хатын-кыз, моның сүрән төсен күреп, ни әйтергә дә белмәделәр.

Шул ук сәгать моның артыннан ук баш вәзирдән: «Гаскәрнең эше начар, кырылып бетеп киләбез», дип, хәбәр килеп төште. Патша үзенең ник кайтканын да әйтергә өлгерә алмады, бу хәбәрне ишетүгә, анда-монда карамый, калган гаскәрләрне җыйнатып сугышка җибәрергә дип, күз йомып күз ачканчы җыеп сугышка озатты да үзе өйгә кереп, хатынына:

— Мин үзем дә белмим, минем кесәмдә бер яулык белән балдак бар иде, хәзер кесәмдә юк, кайда икәнен сез белмисезме? — диде.

Бөтен өйдә булган кешеләр бу сүзләрне ишетеп күңелләре тараеп, йөзләре каралып, ни әйтергә дә белмәделәр. Инде ни эшләргә дә эш калмады, үзе дә кайдан эзләргә белмәде. Аптырагач, гаскәре артыннан атка атланып, сугышка дип ашыгып чыгып китте дә, барып җитте.

Бу вакытта ничә айлар сугыш булган иде. Болар ягының гаскәрләре шактый какшаган, бетәргә якынлашкан иде. Үзе киткәндә өйдә калган вәзиренә үзеннән соңга калган гаскәрләрне сугышка җыйнап җибәрергә кушып калдырган иде. Шул гаскәрләр җыйналган, чыгып китәргә дип кенә торалар иде, патшадан «бик тиз килсеннәр», дип хәбәр килеп төште. Патшаның язуын укыр-укымас алга атлап чыгып та киттеләр. Болар барып җиткәнче, йөрәге чыдый алмый, сугышка үзе кереп китте.

Берничә көннәр сугышып, күп кешеләр кырып, берүзе Заль патшаның гаскәрен какшатып килгәндә, үзе сульяк иңбашыннан җәрәхәтләнде. Аның ярасын бәйләп яткан вакытта, сакта яткан солдатлар да килеп җиттеләр дә туп-туры сугышка кереп киттеләр. Патша, ярасы зур, куркынычлы булганлыктан, кире өйгә кайтып китте.

Кайтып керүгә, хатыннарыннан тагы:

— Яулыкны тапмадыгызмы? — дип сорады.— Хәзер эш аларга терәлеп калды, ничек булса да табарга кирәк,— диде.

Патшаның хатыны бик белгеч, бик укыган, бик күпне күргән, итмәгән этлеге калмаган бер кыз иде.

Хатын, патшага:

— Инде безгә юл шул: калган, патшалыгыбызда булган бар кебек хатын-кызны, карчыкларны җыйдырырга кирәк,— диде.

Шул ук вакыт төрле якка хәбәр таратып, барлык карчыкны, хатын-кызны сарайга җыйдылар. Соңра патша мәйданга чыгып, үзе җәрәхәтле көенчә, хатыннардан:

— Сезнең арагызда югалган нәрсәләрне белә торган кеше бармы? — дип сорады.

Патшаның бу сүзенә каршы яхшыдан-яманнан, белгәннән-белмәгәннән, күргәннән-күрмәгәннән бер ләм-мим дип әйтүче булмады. Патша, болай да булмагач:

— Килмичә калган хатын-кыз юкмы? — дип икенче кат сорады.

Аңарга каршы һич хәбәр бирүче булмады. Арттан гына бер карчык безелдәгән черки кебек кычкыра башлады. Патша бу карчыкның тавышын ишетеп, янына чакырып алды да карчыктан сорашырга тотынды.

Карчык:

— Фәләнчә урманның буенда тирән чокырның кырыенда Кара Мунча авылында гына бер карчык калды, аңардан башка бар да монда килеп җиткәннәр,— диде.

Патша, бу сүзләрне ишетүгә, ул карчыкны алдырырга ат җиктереп, малай утыртып:

— Бик тиз алып килегез,— дип, капкадан чыгарып җибәрде.

Бара торгач урманга барып җиттеләр. Урманны чыгып, чокыр буйлап киттеләр. Бара торгач, кич булып киләдер иде, еракта елтырап бер ут күренде. Болар, бу — кеше тора торган җир дә түгелдер, бу — убырдыр дип, куркышып торалар иде. Боларның артыннан патшаның яңадан җибәргән кешеләре килеп җиттеләр дә, боларга:

— Тизрәк барып җитегез, безнең арттан патша үзе килеп җитә,— диделәр.

Болар атларга сугып, көпчәкләрне тидергән җирләрдән тидереп, тидермәгән җирләрдән сикереп, казылма чокыр, уйдык-убындыкларны тикшермичә, утка барып җитсәләр, бер тау күренә. Тау өстенә тау үскән, тау башына таш үскән, таш өстенә йон үсеп, мүкләнеп-чүпләнеп, черепчүбекләнеп беткән. Тау башында өй утыра, өй читтә, ишеге чыпта. Бер теше идәнгә тигән, бер теше түбә тактага тигән бер карчык түрдә поч-

макта җеп эрләп утыра иде. Килеп тә керделәр, карчыкка эшнең ни икәнен сөйләп тә бирделәр. Карчык әң-сәң итә, бармаска тели:

— Мин бу мөлкәтемне ташлап китәр хәлем юк,— диде.

Әбинең бар байлыгы шул иде: борынсыз комган, сапсыз-баусыз дегет лагуны иде. Шулай итеп чәбәләнеп торганда патшадан өченче бер кеше килеп тә җитте, тизрәк, дип каударлап, әбине тыкырдатып өйдән алып чыгып, су арбасының драгаларына[1] артка таба каратып утырттылар да чокыр буеннан киттеләр чабып, йөз белән авып, торып, җыйналып, ничек кирәк алай абына-сөртенә патшаның сараена кайтып җиттеләр.

Патша бу карчыкны күрде. Бу карчык кырык убырлы карчыкның кырык беренче анасы иде. Карчыкның бер теше күктә, бер теше җирдә, битләренә[2] кеше аты-арбасы белән төшеп югалырлык иде. Патша аның битенә карарга куркып китте. Шулай да булса, патшаның башына бәла төшкәнгә, теләр-теләмәс, карчыкның янына барып сөйләшергә карар кылды. Патша әбигә эшнең ничек икәнен сөйләп:

— Шул югалган яулык белән балдакны таба алмассыңмы? — диде.

Әби:

— Утка янып көл булмаган булса, табармын, көл булган булса да табып булыр, ләкин көл файда китермәс,— диде.

Патша бу сүзләрне ишетеп, бераз җайланды. Әбине йортка алып килделәр. Әби өй эченә кергәч, иснәнеп куенын актара башлады да куеныннан шайтан тырнакларын, сихер капчыкларын чыгарып өстәлгә салды да китабын ача башлауга:

— Кияүләре үлгән тол хатыннарны монда китерегез,— диде.

Күз ачып йомганчы әбинең каршысына китереп бастырырга! Әби бу киленнәрнең эчләрендәге серләрен белде.

Әби:

— Сез патшаның кесәсеннән кульяулыгы белән балдагын кая куйдыгыз, шул минут минем алдыма чыгарып куегыз, юкса һәлак булырсыз,— диде.

Тол хатыннар алай иттеләр, болай иттеләр, ычкынырга тырышалар. Әби: «Хәзер табып бирегез!» — дип, боларны кыса башлады. Болар, бер-берсенә карашып, куркышып телдән яздылар. Аннары:

---

[1] *Драга* — бу урында: үрәчә.
[2] *Битләренә* — битләрендәге җыерчыкларына.

— Патша хатыны белән мунчага кергән чакта аның тун кесәсеннән алып, кер юарга төшкән булып, диңгез төбенә ыргыттык,— диделәр.

Әби йөгереп диңгезгә китте. Әби күп уйлап тормый, җиргә казык кагып, башындагы барлык чәчен йолкып алып аркан итеп, арканның бер очын казыкка бәйләп, бер кулы белән икенче башын тотып, үзен-үзе диңгезгә ташлады.

Өч көн үткәч, әби диңгезнең төбеннән килеп чыкты. Авызында яулык белән балдак. Әби тиз генә киемнәрен киде дә патшага йөгереп кайтты. Патша яулык белән балдакны күрүгә, хәлдән таеп, җиргә егылды.

Озак та үтми, патша исенә килеп сикереп торуга, баш вәзирдән: «Гаскәр бетте, харап булдык»,— дип, бер язу килеп төште.

Патша әбине сарайдан чыгарырга кушмыйча, үзе тиз генә шәһәрдән җәяүләп чыкты да кесәсеннән балдакны алып сызгырып җибәрде. Шул ук вакыт акбүз ат бар кебек сугыш киемнәре белән килеп тә төште. Патша киенер-киенмәс, бик ашыгыч кына сикереп менде дә атка бер сукты. Күз ачып йомганчы сугышка барып җитте. Бакса, гаскәр беткән, эшләр бик начар. Бер минут туктап тормыйча, сугышка кереп кыра башлады, дошманның гаскәре бетте.

Заль патшага: «Каяндыр бер батыр килде, орышына түзәр хәл юк, күз ачарга ирек бирми»,— дип хәбәр җибәрделәр. Патша: «Бу нинди кеше икән, үзем барып карыйм әле»,— дип, ат иярләтеп атланып, кеше сүзенә ышанмыйча, юлга чыгып китте. Гаскәр янына барып җитте, бар да кырылып беткән.

Заль патша ни эшләргә дә белмәде, батырны да күрә алмады, чөнки батыр, атын болынга җибәреп, үзе калган гаскәре белән кырын ятып ял итә иде. Урыныннан торып, калган гаскәр белән Заль патшаның үзен, хатыны белән бала-чагасы, тавыклары-чебешләре белән барып алырга кирәк, дип, киңәш итеп бетерделәр дә, урыннарыннан торып, атларына атланып куып киттеләр. Заль патша, боларны күрүгә, тәхетенә кайтып утырды.

Күп вакыт үтми, болар шәһәрне чолгап алып, сарайга ук ата башладылар. Тәхетенең башына бер-ике ук барып төшүгә, Заль патша, сарае башына ак әләм элде дә, үзенең бирелүен белдерде. Болар кереп, патшаны тәхете белән килеп алдылар, ук ату басылды, гаскәр җыйналды. Хәзер гаскәрне ял итәргә тараттылар. Патша үзе дә бик арып, ял итәргә дә утырмыйча, Заль патша моңарга үзенең тәхетен биреп, бөтен халкы белән баш ора кереп, зур туй ясады.

Сүз иярә сүз чыгып, болар бер-берсен сораша башладылар.

Заль патша:

— Сез нинди батыр буласыз, әлегә кадәр сезнең кебек патшаны ишеткәнем юк иде,— диде.

Егет аның сүзенә каршы:

— Менә фәләнчә сарайның мөрҗәсенә ук атып төшергән малай мин идем. Угымны ничек алыйм икән дип торганда, сарайның эченнән бер кеше эндәште: «Ишекне ачып булдыра алсаң, угыңны алып бирермен»,— диде. Мин ары сикердем, бире сикердем — ача алмадым. Ул миңа ачкычның кая икәнен өйрәтте.

Заль патша бу сүзләрдән генә бернәрсә дә аңлый алмады, малайны танымады. Аның өчен бик картайган, башында әүвәлге кебек зиһен калмаган, усаллыгы сәбәпле бар да чыгып беткән иде.

Егет һаман сүзен сөйләп:

— Мин, кереп, ачкычны әнинең кесәсеннән алып сарайны ачкан идем, анда булган карт чыгып китте,— диде.— Мин яңадан бикләп, ачкычны кертеп, әнинең кесәсенә салып куйдым. Бераз вакытлар үткәч, картны астырырга булдылар. Мин ул чакта бернәрсә дә белмичә йөрдем, халыклар җыелып беткәч, сарайны ачтылар — карт юк. Патша, ачуланып хатынын чакыртып, башын чапмакчы булды. Мин гаебемне сөйләп, анамны коткардым: «Мин бу эшне үзем эшләдем»,— дип әйтүче мин идем.

Патша, бу вакыт, үткән эшләрен уйлап карап, бераз шәйли башлады.

— Соңра ачуың белән миңа кизәнеп, башыңны өзәм, дигәндә, вәзирләр кулыңны тотып мине коткардылар. Шулай да булса, син минем үзәгемә үттең. «Күземә күренмә»,— дип, мине чыгарып җибәрдең. Минем дөньяда күрмәгән нәрсәм калмады, илдән биздем, дөнья гиздем. Хәзердә каршыңда утырып торган егет — синең улың булам,— диде.

Патша, бу сүзләрне ишетеп, хатыны белән икесе дә истән авып, елый-елый икесенең дә күзләре сукыраеп, кайгылы катыш куанычларыннан елап, йөрәкләре ярылып, җан бирделәр.

Егет, ата-анасын җирләп, атасының кул астындагы кешеләрне җыеп, үзенең хатыннары янына кайтып китте.

Кайтып керсә, әби моңарга каршы чыгып, көлгән булып куанычын белдереп, барлы-юклы күзләрен чалшайтып, сарайга алып кереп, зур бер куаныч туе ясадылар. Әмма ике тол хатынга бик зур кайгы. Башларында тирмән[1] ташы әйләнгән кебек, миләре әйләнеп кайный, кай сәгатьтә

[1] *Тирмән* — тегермән.

безне үтерер икән дип, үзләренең үлемнәрен көтеп йөриләр иде. Патша, тол хатыннарны бер якка куеп, әбинең күңелен табарга тырыша. Әби белән ике тол хатын күптән эшне беректереп куйганнар иде. Ашадылар-эчтеләр, куаныч туйлары үтте, гаскәрләр таралды, бары үзләре генә калды.

Патша, әбигә:

— Инде, әби, синең хезмәт ялына ни бирим? — диде.

Әби, озак уйламады:

— Минем үземнең өем тора торган тауга хуҗа ит, ул тауның башына түгел, янына һичбер кеше килмәсен, мине борчымасыннар,— диде.

Патша:

— Соң, әби, алтын-көмештән күпме бирим? — диде.

Әби:

— Алтын-көмеш алмыйм, инде эшләр шатлык белән үтте, тол хатыннарны ни эшләтәбез? — диде.

Патша, үз-үзенә: «Әле бит алар бар, инде ни эшләтергә, аларга җәза бирми булмас»,— дип уйларга тотынды. Патша әбинең бу соравына җавап бирә алмады, җавап бирергә өч көн мөддәт[1] сорады.

Өч көн өч сәгать урынына үтте. Патша боларны башкача җәзаларга юл таба алмады, башларын кистерергә дип уйлап куйды.

Әби, патшаның бу сүзенә каршы:

— Инде, патша, эш куаныч белән үтте, сүзегез булды, адәм каны түгү җитәр, аларны тере көе калдыр да миңа биреп җибәр, үзем аларны карап торырмын, алар да миңа хезмәт итәрләр,— диде.

Патша:

— Инде мин аларны дөньяда исән йөртергә уем юк иде, үзеңнең хезмәтең тигәнгә күрә, сүзеңне тыңламый ярамый,— дип, бирергә күнде.

Әби шул вакыт, ике кулына ике тол хатынны җитәкләп, патша белән: «Инде без моннан соң күрешә алмабыз»,— дип, саубуллашып чыгып китеп, өенә кайтып, үзенең тавын тирә-ягыннан күз күренмәс җирне җирдән күккә терәтеп чуен койма белән койдырып, шул хатыннар белән бергә көн үткәрә.

Инде бу вакыт сарайда башка бер эш дөньяга чыгып баш күтәреп киләдер иде. Егетнең бабасы булган патшадан егет сугышта чакта туган бер ир бала бар иде. Ул бу вакытларда сигез-ун яшьләренә килеп җи-

---

[1] *Мөддәт* — вакыт.

тәдер иде. Исеме — Алпамшаһ. Бу бала өйдә үги булганлыктан, монда тора алмады, ил кыдырырга чыгып китте. Бу малай туталарын исендә тотып, ничек булса да бервакыт аларны коткарып алырга уйлап йөридер иде.

Бернәрсә белмичә, яшь көенчә аптырап шәһәрдән чыгып киткәндә, юлда барганда артына әйләнеп караса, балта сабы буе җир киткән. Бара-бара алдына еракта елтыраган бер ут күзенә чалынды. Бала бу утка таба карап, алга таба китте. Барып керде бер өйгә. Аның эчендә утырадыр иде бер карчык. Малай сәлам биреп өйгә керде.

Әби, малайдан:

— Каян килдең, син нинди кешенең баласы, монда ничек сорамыйча килеп кердең? — дип сорады.— Әле яхшы — бәхетең бар икән, сәлам биреп кердең, юкса икегә өзеп, бер кабуда йоткан булыр идем,— диде.

Малай:

— Йотсаң йотарсың, инде мин синең кулда, мин — синеке, син дә минеке бул,— диде.

Әби бу малайдан мондый тәмле сүзләр ишетеп, янына чакырып алып утырта да, малай башыннан ни үткәнен барын да сөйләп бирә. Әби бу малайны үзенә ул иттереп, йөкләп[1] кабул итә. Әби белән малай бергә-бергә тора башлыйлар.

Әби малайдан:

— Балам, без бергә торабыз, мин синең атыңны белгәнем юк, син ни атлы? — диде.

Малай:

— Мин Алпамшаһ атлы,— диде.

Болар азмы-күпме вакыт үткәрделәр, Алпамшаһ әбинең җир йөзендә беренче сихерче карчык икәнен белде.

Бердән бер вакытта әби, Алпамшаһка:

— Балам, берәр һөнәр беләсеңме? — диде.

Алпамшаһ:

— Юк, әби, мин бер һөнәр дә белмим,— диде.

Әби:

— Дөньяда һөнәрсез кеше яши алмый, берәр һөнәр өйрән,— диде.

Алпамшаһ әбидән һөнәр өйрәнергә башлады.

Ничә көннәр үтеп киткәч, әби бер көндә Алпамшаһка җиде бозау

---

[1] *Йөкләп* — хуп күреп.

биреп, далага ашатырга чыгарып җибәрде. Алпамшаһка таяк-чыбыркы тоттырып:

— Балам, карап ашата күр, качырып җибәрмә, аннан соң башларын таба алмабыз,— диде.

Алпамшаһ бозауларны алып яланга чыгып китте. Капканы чыгып, бер агачлык арасына барып кына җитте дә бозаулардан күз язды. Алпамшаһ ни эшләргә дә белмичә, аптырап еларга тотынды. Моның өстенә бер карт килеп чыгып:

— Әй, балам, ник елап утырасың? — диде.

Алпамшаһ:

— Әй, бабай, бик зур зарарга очрадым. Менә мин әбидә торам, ул миңа бозаулар биреп чыгарган иде. Мин аларны бу куаклыкларга җиткәч тә югалттым,— диде.

Бабай:

— Юк өчен елама, күзләреңне бетләтмә, менә сиңа бер янчык бирим, әгәр дә син аны ачып карасаң, үзеңә кирәк һәр нәрсәне анда күрерсең,— диде.— Алар бозаулар түгел, җеннәр,— диде дә үзе күздән югалды.

Алпамшаһ кулына янчыкны алып ачып караган иде — эче тулы пәри икән.

Хәзер Алпамшаһка:

— Ни кушасың? — дип, каршысына басып тордылар.

Алпамшаһ:

— Минем хәзергә әллә ни кирәгем[1] юк, җиде бозавым югалды, шуларны табып килә алмассызмы? — диде.

Пәриләр бу сүзләрне ишеткәннәр иде, җиде кызыл бозау булып, Алпамшаһның каршына бастылар. Алпамшаһ калган пәриләрне урыннарына салып куеп, янчыгын кысып бәйләп, бозауларны чыбыркы белән куып алып китте.

Әби, аптырап: «Бу ни эш, бу ничек бозауларны алып кайтты, моның белүе минекеннән зур икән»,— дип, үзе куркырга башлады. Бозауларны кертеп яптылар да, өйгә кереп, Алпамшаһны ашатып-эчертеп, ятарга урын җәеп бирде. Алпамшаһ ятуга гырылдап йокыга китте. Әби, уйга чумып: «Инде бу малайдан ничек котылырга кирәк»,— дип уйлап утырды.

---

[1] *Кирәгем* — кирәк нәрсәм.

Төн үтте, таң атты, тирә-як яктырды, әбинең күзе тоздай булып, ялтырап карап тора. Алпамшаһка һичбер сүз кушмый. Алпамшаһ, әби эндәшмәгәч, үзе сүз башлап:

— Әби, бу көн нинди эш бар? — дип сорады.

Әби:

— Башка эш хәзергә юк, төнәге кебек яңадан шул бозауларны ашатырга барырсың,— диде.

Алпамшаһ бозауларны алып чыгып урманга керә дә, бозауларны үз ирекләренә куеп, бер зур тирәкнең төбенә барып киемнәрен салып, баш очына куеп ятып йоклый. Кич булганда уянып китеп, янәдән җиде бозауны бастырып алып кайта. Әби моның кайтып килгәнен күреп, үзе өйдән чыкмый, тәрәзә күзеннән генә башын тыгып: «Шунда азбарга яп»,— дип кычкыра.

Алпамшаһ өйгә кереп, тамагын туйдырып, тагын йокларга ятты. Әби йоклый алмыйча утырып, малайдан котылырга юллар эзләде.

Яктыра башлагач, Алпамшаһ торып аякка басты, киенеп, билен буып, ыштырын киндерәсе белән урап, бияләйләрен билгә кыстырып, әбинең каршысына барып:

— Ни эш бар? — диде.

Әби:

— Башка эш юк, тагын бозауларны алып бар, әгәр дә аларны җуймый алып кайта алсаң, мин сиңа җаның ни теләсә, шуны бирермен,— диде.

Алпамшаһ бозауларны алып чыгып, янә янган агач төбенә барып, ятып йоклады. Кич булгач, бозауларны алып кайтты. Әби тагын ни эшләргә белмичә төн үткәрде. Иртә торгач:

— Йә, улым, инде мин сиңа ни бирим, җаның ни тели? — диде.

Алпамшаһ:

— Мин белмим, үзең белеп бир,— диде.

Әби Алпамшаһның кем икәнен сизенде. Әбинең өч көтү елкысы бар иде. Әби:

— Шуларның арасыннан үзең теләгәнен сайлап алырсың,— диде.

Алпамшаһ әби белән бергә көтүгә ат сайларга китте. Бер чокырның битләве[1] белән бер тугай җиргә барып төштеләр. Өч көтү елкы бер

---

[1] *Чокырның битләве* — чокырның бите.

җиргә тупланып торалар. Әбинең килгәнен күреп, көтүче бик тиз генә әбигә каршы килеп:

— Ни боерасыз? — диде.

Әби:

— Менә бу егеткә бер ат сайлап алырга килдек,— диде.

Әби көтүдә булган бер атны бирмәскә уйлады. Бирмәскә теләгәнен Алпамшаһка белдермәде. Алпамшаһ, әбинең сүзе буенча, атлар арасына кереп китеп карап йөри башлады. Атлар бар да бер төсле иде. Алпамшаһ арада бер яхшы ат барын белде дә, ат телгә килеп:

— Әй, егет, мин синеке булырмын, син әбигә кайт, мин алдыгыздан үткәндә чатанлап үтәрмен,— диде.

Алпамшаһ борылып әбигә кайтты.

Әби:

— Кайсы атны тамгаладың? — диде.

Алпамшаһ:

— Мин берсен дә таный алмадым, инде аларны алдыбыздан үткәр дә күземә чалынганны алырмын,— диде.

Әби: «Бик яхшы»,— дип, Алпамшаһның кулына җөгән тоттырып, үзе атларга таба китте. Барып, җил җитмәс җирән атка: «Син Алпамшаһның алдыннан үткәндә аксап үтәрсең»,— дип, барын да өркетеп җибәреп, Алпамшаһның алдыннан үткәрә башлады. Атлар берәм-берәм үтә башладылар. Иң арттан бер аксак җирән ат чатанлап килә иде. Ат Алпамшаһка якынлашты. Алпамшаһ йөгәнен кулына тотып, атның каршысына барып башына кигезде.

Әби, йөгереп килеп:

— Нигә исән ат тотып алмадың, үзеңә бер аксак ат аласың? — диде.

Алпамшаһ:

— Әй, әби, алар бик яхшы, мин үзем бозау көтеп йөри торган бер малай, миңа шул чатан ат та ярар,— дип, көтүченең куышына таба атлатып киттеләр дә, әби:

— Бу ат ни өчен аксады? — дип сорады.

Көтүче:

— Инде ул күптән шулай исән түгел,— диде.

Ат бер аягын күтәреп, башын түбән салып, боегып тора иде. Алпамшаһ: «Инде булган булган, үз бәхетем үземә»,— дип, боларның сүзләрен озак тыңлап тормый, чатан атны атлатып, саубуллашып китте. Әби куыш янында казык кебек катты да калды.

Әби күздән югалгач та, ат, җиргә ятып аунап, торып, селкенеп тәкләрен кагып, менә дигән ат булды. Шул ук сәгать Алпамшаһ өзәңгегә басып, сикереп менеп утырды да үкчәсе белән бер типте. Ат пошкырып, танауларын киереп телгә килеп:

— Йә, егет, күзеңне йом, юкса син без үтәсе җирләрне күрсәң, чыдый алмассың — башың әйләнеп, күз алдың караңгыланып, егылып төшеп үләрсең,— диде.

Егет, күзен йомып, бераз барган иде, ат туктап:

— Инде күзеңне ач, мин сөйләгән җиргә килеп җиттек,— диде.

Алпамшаһ күзләрен ачып җибәргән иде: бер кара урманның эченә барып кергәннәр.

Ат:

— Монда бераз ял итеп ал, мин дә хәл җыйыйм, моннан соң барасы җиребез тагы да куркынычлы,— диде.

Алпамшаһ тезгенен атның башына урап, үзе җиргә ятып:

— Әле син үтәсе җирне куркынычлы дисең, бераз тыңлап тор, мин дә сиңа сөйлим,— дип, Алпамшаһ үзенең уйларын сөйләргә тотынды.— Менә мин бер патшаның баласы идем, минем ике тутам бер тауның артында бер убырлы карчыкта тоткын булып яталар. Минем аларны коткарасым килә,— диде.

Җил җитмәс җирән ат:

— Инде, егет, без бергә, ни күрсәк тә уртак, мин сиңа үлгәнче хезмәт итәргә сүз бирәм,— диде.

Болар вакытны үткәрми — кояш калыкмас, көн батмас, төн булмас якка таба карап киттеләр. Җиде тәүлек барып, урманның бары яртысына килеп җиткәннәр иде, боларга егерме атлы кешеләр очрады. Болар, Алпамшаһка сәлам биреп, узып китәргә теләделәр. Араларында кайсылары ирек бирмичә, аны тотып алып, үзләре тора торган җиргә алып киттеләр. Болар кырык бер каракның ялчылары икән.

Болар җиттеләр бер зур чокырга. Чокырда зур йортлар, киртә тулы маллар күрделәр. Бер җирдән сукмак табып түбән таба төштеләр.

Ат егеткә:

— Инде, егет, син үзеңне сакла, кем икәнең белдермә,— диде.

Атларны бәйләп, өйгә керделәр. Өй эчендә кырык бер каракның башлыгы булган кырык икенче карак тора иде. Болар барып керүгә: «Хуш килдең, кунак»,— дип, аш хәзерләргә куштылар да, үзе сораша башлады. Алпамшаһ, эшне башыннан аягына кадәр сөйләп биреп: «Мин

кеше эзләп йөрим»,— диде. Караклар чыгып киттеләр, болар икәү генә калды. Алпамшаһ карт карактан дөньяда ни бар, ни югын сораша башлады.

Карак:

— Белмим, алар моннан ерак түгел, кая торганнарын беләм, әмма туталарыңны күрә алырсыңмы-юкмы, анысын әйтә алмыйм, аларның икесенең ике диюләре бар, шул диюләр белән торалар, мин анда якын бара алмыйм, үзең йә баш, йә мал дип барырсың,— диде.

Егет, вакытны качырмыйк дип, атка атланып чыгып китте. Урманны чыккач, чуен койма белән әйләндереп алган тауны күреп, керер өчен юл тапмыйча кире кайтты.

Бераз гомер кичергәннән соң, егет үзенә көн күрергә уйлый башлады. Бердән бер көнне атын иярләп чыгып, әлеге тауга карап китте. Урманны чыкты, һавадан елтырап тора торган бер ут күрде. Карый: ут тау башында бер өйдә. Ул өй чуен койма белән әйләндереп алынган, керергә капкасы юк. Бераз уйлап йөргәч, капканың кайда икәнен белде. Атын җибәреп, капкага китте. Капканың ике ягында дүрт сакчы торадыр иде. Аларга күренмичә капкадан кереп, бер сарайга китте. Тәрәзәдән караса, эче тулы кеше элеп куйганнар. Аннан өйгә китте. Бер тутасын күрде дә, сөйләшергә юл таба алмады. Аннан соң карчыкка барып, аның башын чабып өзде. Озакламый дию пәриләре кайтып керделәр. Аларны саклап торып, аларны да үтерде. Туталарына керергә юл тапмагач, өйнең бер почмагыннан күтәреп, туталарын коткарып алып чыкты. Туталары моны танымадылар, тик сөйләп биргәч кенә белделәр.

Туталарын утыртып, туры урмандагы каракларга киттеләр. Анда бераз кунак булып, Алпамшаһ аларны да җае белән барын да кысты. Аларның өенә ут төртеп, урманнан чыгып киттеләр.

Бер шәһәргә барып керделәр. Ул шәһәрдә патша кызының көрәш туе иде. Кызны кем екса, ул аладыр иде. Җыелган егетләр кызны ега алмадылар. Алпамшаһ мәйданга кереп, көрәшеп кызны екты. Шул ук көн туй ясап, кызны егеткә бирделәр. Алпамшаһ туталарын да башка кешеләргә бирде.

Патша үзенең патшалыгын Алпамшаһка биреп, үзе тәхеттән төште. Алпамшаһ патша булып, үзенең батыр хатыны белән әле дә булса рәхәтләнеп торалар иде.

4. Айсылу

Әүвәл заманда бер хатын булып, аның бердәнбер Айсылу исемле кызы булган. Бервакыт күрше кызлары аны су керергә чакырганнар. Айсылу күрше кызлары белән бергә барып җитә алмаган.

Айсылу үзе генә су янына барып җиткәндә, теге кызлар судан чыгып киләләр иде. Айсылу ялгызы су кереп кырыйга киенергә чыкканда, күлмәгенә бер зур елан ятканын күрде. Айсылу бер таяк алып еланны сугып үтерергә теләде. Елан, телгә килеп:

— Әгәр син миңа кияүгә килергә разый булсаң, мин синең күлмәкләреңне бирәм, әгәр разый булмасаң, хәзер үтерәм,— диде.

Айсылу никадәр котылырга теләсә дә, барырга ризалык күрсәтмичә торып, котыла алмады. Елан Айсылуның ягымлы сүзләрен ишеткәч, күлмәкләрен биреп, бер атнага өенә кайтарып җибәрде. Айсылу кайгылы йөз белән кайтып кергәч тә анасына ни күргәнен барын да сөйләп бирде.

Анасы:

— Бу өеңдә түгел, төшеңдә күргәннәреңдер,— диде.

Анасы ышанмаса да, кыз бик кайгыда торды.

Бер атна үтүгә, Айсылу белән анасы урам тулы еланнарның килгәннәрен күрделәр. Айсылу куркып чувал[1] өстенә менеп, анасы да тәрәзәләрне томалап, үзе сәке өстенә менеп сандык артына яшеренде. Еланнар боларның өен табып, берсе өстенә берсе үрмәләп, тәрәзәләрне ватып өйгә кереп, Айсылуны эзләп табып, алып чыгып киттеләр.

Айсылуның анасы кызының артыннан барды. Еланнар туп-туры күлгә барып, Айсылуны да суга алып кереп киттеләр. Айсылуның анасы кире өенә кайтып: «Мин кайтканчы кызымны инде буып үтергәннәрдер»,— дип, хәсрәтеннән бернәрсә дә эшләми елап утырды. Башка балалары булмаганлыктан, юатучысы юк иде.

Өч елдан соң Айсылуның анасы бер хатынның килгәнен күрде: кулында бер ир бала булып, берсен җитәкләгән иде. Хатын туры бу өйгә килеп керде. Сөйләшә башлагач, бу хатын Айсылу булып чыкты.

Соңра анасы кызыннан:

— Син кайда торасың, кызым? — дип сорады.

Айсылу:

— Су патшасы булган еланда торамын,— диде.

---

[1] *Чувал* — мич.

Анасы:
— Соң, кызым, коры җирдә торсаң яхшымы яисә суда яхшымы? — диде.
Кызы:
— Суда яхшырак,— диде.
Әнкәсе:
— Кызым, соң син анда ничек кайтып керәсең? — диде.
Кыз:
— Мин күлнең читенә барам да: «Бикбау! Мин килдем, чыгып ал»,— дип кычкырам, минем тавышымны ишетеп, ул мине чыгып ала.
Әнкәсе кызының бу сүзләрен ишетеп:
— Бу көн бездә кунып китәрсең,— диде.
Кыз:
— Мин бер генә көнгә рөхсәт алдым,— диде.
Шулай да булса, анасы бик ялынгач, кунарга булды. Болар ятып озак сөйләшкәннән соң, Айсылу йокыга китте. Анасы кулына балта алып чыгып китте дә су янына барып:
— Бикбау! Мин килдем, чыгып ал,— диде.
Елан судан башын гына чыгарган иде, хатын балта белән аның башын чабып төшерде һәм үзе өенә кайтып китте.
Иртә торып ашап-эчкәннән соң, балаларын киендереп, берсен күтәреп, берсен җитәкләп, Айсылу анасы белән саубуллашып чыгып китте. Су кырыена барып:
— Бикбау! Мин килдем, мине чыгып ал,— дип бик озак кычкырды, судан бернәрсә дә чыкмады.
Иплә6рәк караса, су өсте кызыл кан булган, Айсылу, ирем үлгән икән инде дип, балаларына таба карап:
— Балалар, сезнең атагыз булмагач, анагыз да булмасын,— дип, улына: — Улым, син атаң өстендә карлыгач бул; кызым, син дә сандугач булып сайрап йөр; мин күке булып кычкырып йөрим,— дип, өчесе өч төрле кош булып, очып киттеләр.
Әле дә булса очып йөриләр бугай.

5. Алтын чәчле кыз

Борын заманда бер патша булып, аның алтын чәчле бер хатыны булган. Болардан алтын чәчле бер кыз туган. Болар күп гомер иткәннән соң, бер көнне патшаның хатыны үлем хәленә җитәрлек авырган.

Хатын, патшага:

— Әгәр мин үлсәм, миннән соң да минем шикелле алтын чәчле һәм матур хатын ал,— дигән.

Хатын бер ай чамасы авырганнан соң үлгән.

Патша хатынының сүзе буенча алтын чәчле хатын эзли башлаган. Бөтен дөньяны эзләтеп тә андый хатын таба алмагач, үз кызын алмакчы булган. Кыз һич тә бу эшкә разый булмаган. Кызга, башкалар:

— Син атаңнан өч төрле күлмәк сора, берсе ай, берсе йолдыз, берсе кояш тик булсыннар. Әгәр атаң шул күлмәкләрне тапса, ул вакыт барырсың, дигәннәр, барасың килмәсә, качарсың.

Кызы атасына бу сүзләрне әйткәч, патша бу күлмәкләрне кызы әйткәнчә хәзерләгән. Патша бу эшләрне эшләгәч, кыз, моның белән алдырып булмады, дип, үзенең күлмәкләрен алып, атасы белмәгән бер вакытта өйдән чыгып китә.

Күп җирләр йөреп, чит илләргә чыгып, бер зур шәһәргә барып кергән. Мондагы патшаның шәһәргә килгән кешеләрне, кирәк ир булсын, кирәк хатын булсын, үз күзеннән үткәрү гадәте булган. Кыз бу патшаның күзеннән никадәр ычкынырга теләсә дә, булдыра алмаган, ахырында моны да патша катына алып барганнар. Патша бу кызны күргә, үзләренә алып кайтырга кушкан:

— Бу безнең сарайда ашчы булып торыр,— дигән.

Кызны патша йортына алып барып куйганнар. Кыз үзенең алып барган нәрсәләрен күрсәтмичә, башында алтын чәч икәнен белмәсеннәр дип, башын һәрвакытта бәйләп йөргән.

Күп айлар үткәч, патша бердән бер көнне бер зур бәйрәм ясаган. Табында күп кешеләр булган. Күп кенә чит илләрдән ирләр һәм хатыннар килгәннәр. Шул вакытта бу кыз аш пешереп йөргән. Халыклар әүвәле һәртөрле уеннар уйнаганнар, соңра табын-табын булып ашарга утырганнар. Кыз үзенең искерәк күлмәкләрен киеп, югары катка аш менгереп йөрткән. Бер савытка үзенең бер бөртек чәчен дә салып керткән. Аш ашалып беткәч, төптән бер бөртек алтын чәч килеп чыккан. Моны күреп гаҗәпсенәләр.

Кыз икенче ашны биреп төшкәч тә, ай кебек күлмәген киеп, кунаклар янына кергән. Кунаклар барысы да аяк өстенә торганнар. Бу патша белән әз генә сөйләшкән дә төшеп киткән. Моны һичкем кайдагы икәнен белмәгән. Кыз, бу күлмәген салып, үзенең көндәлек күлмәген киеп, тагы аш меңгергән. Ашны биреп төшеп, йолдыз кебек күлмәген киеп, кунаклар янына кереп, янә патша белән әз генә сөйләшеп чыгып киткән.

Төшеп янә күлмәген алыштырып аш керткән, янә төшеп кояш кебек күлмәген киеп, башын ачып, кунаклар янына барып кергән. Моның өстенә һичкем карый алмыйча күзләре чагылган. Патша белән сөйләшеп, кыз чыгып киткән. Бу күлмәген салып, янә иске күлмәген киеп, аш бирен чыгып киткәндә, патша туктатып, кызның башыннан яулыгын тартып алган. Кызның алтын чәчләре ялт итеп бөтен бүлмәне яктырткан.

Патша, моны үз янына утыртып:

— Син кай җирнеке? — дип сораган.

Кыз:

— Мин фәлән җирдәге каһарман патшаның кызы идем, минем анам алтын чәчле иде. Үзе үлгәндә этигә үзе кебек алтын чәчле хатын алырга әйтеп калдырды. Атам бик күп җирдән эзләп караса да, җир йөзендә алтын чәчле хатын тапмагач, мине үзенә алмакчы булды. Мин аңардан өч төрле күлмәк сорадым, ул бу күлмәкләрне китергәч, качып чыгып киттем. Менә минем чыгып монда килүемнең сәбәбе шул,— дигән.

Бу патшаның хатыны үлгән икән. Патша бу кызны үзенә хатынлыкка алырга рөхсәт сораган. Кыз да разый булып, зур шатлык белән зур туй ясап, бер-беренә кавышканнар.

Кыздан үзе кебек алтын чәчле балалар туган.

6. Әби белән бабай

Бар иде әби белән бабай. Аларның бар иде бер улы. Бервакыт аларның улын кәрванчылар үзләре белән алып китәргә әби белән бабайдан сорый башладылар. Бик кыстап сорагач, әби белән бабай разый булып, улларын биреп җибәрделәр.

Болар чыгып китеп бер сахрага барып төштеләр дә малайны, качмасын дип, бәйләп куярга теләделәр.

Малай:

— Минем сез бәйләмәсәгез дә качарга ниятем юк,— диде.

Кәрванчылар малайның сүзенә ышандылар да иркенә куйдылар. Алар ашап-эчеп йокларга яткач, малай, як-ягына карап, ерак түгел бер урман күрә. Малай күп уйламый, тора да урманга карап китә. Барып җиткәч, урманда бик күп җиләклеккә очрый, җиләк җыя-җыя бу малай юлын адашып, урманның эченә кереп китә. Йөри торгач, бер сукмакка килеп чыга.

Бу малай шул сукмактан бара торсын, без килик кәрванчыларга. Кәрванчылар уянып карасалар, малайдан җилләр исә. Аннан эзләп, моннан эзләп карадылар, таба алмадылар да үз юлларына киттеләр.

Малай, шул сукмактан бара торгач, барып керә бер өйгә. Өйнең эчендә берәү дә булмый, учакта ут янып тора. Барып караса, казанда ит тә пешеп өлгергән. Малайның бик ашыйсы килгән иде. Бер кисәк ит алып ашады да пич астына кереп ятты.

Менә бервакытны өйгә бер күгәрчен, бер лачын һәм бер козгын килеп керделәр. Болар канатларын кагындылар да менә дигән япь-яшь егет булдылар.

Козгын:

— Адәм исе киләдер,— диде.

Иптәшләре аңарга каршы:

— Үзең адәм ите ашап кайтасың да соңра адәм исе килә дисең,— диделәр.

Болар пешкән итне ашадылар да казанга янә ит салып чыгып киттеләр.

Болар киткәч, бу малай итнең пешкәнен көтеп кенә тора да, бер кисәген алып ашый да, пич артына кереп, янә урынына ята. Баягыча әлеге егетләр кайтып керәләр дә ит ашарга утыралар. Козгын һаман иснәнә. Иптәшләре адәм исе килә дигәненә ышанмыйлар. Козгын: «Туктале, итне мин үзем салыйм»,— дип, шыпырт кына санап, казанга унбиш кисәк ит сала. Болар өчесе дә чыгып китәләр. Бу малай баягыча тора да, итне ашап, тагы пич артына кереп ята. Болар тагы кайтып керәләр дә ит ашарга утыралар. Козгын санап караса, итнең бер кисәге юк. Козгын:

— Менә әйттем бит, адәми зат бар дип,— ди.

Шуннан соң болар өчесе дә өйне тенти, карый башладылар.

Малайны пич артында күреп:

— Син адәми затмы, пәри затмы, монда чык! — дип кычкырдылар.

Малай:

— Мин чыгам, ләкин әүвәл сез миңа тимәскә ант итегез,— диде.

Болар тимәскә ант итәләр.

Бу малай чыга да үзенең монда адашып килгәнен барын да баштанаяк сөйләп бирә.

Болар:

— Ярый, син безгә хезмәтче булырсың, без сине һөнәргә дә өйрәтербез,— диләр.

Бу малай беравыздан риза була да боларның эшләрен эшли башлый. Тора торгач, бу егеткә һәртөрле сарайларның ачкычларын да бирәләр, ләкин ачып карамаска кушалар.

Бу егет, болар чыгып киткәч, бервакытны уйлап тора да: «Туктале, бер ачып карыйм, бу сарайда нәрсәләр бар икән»,— дип, сарайларны ачып карый башлаган иде, шул вакыт өч егет кайтып керделәр дә, сарайларның ачылганын күреп, малайдан:

— Ник бу сарайларны ачтың? — дип сорадылар.

Малай:

— Туктагыз, әүвәл миннән җавап алыгыз. Менә мин сарайларыгызны ачып карадым да эчендә ни бар, ни югын күрдем, әлегә кадәр мин аларның эчендә ни барын белмидер идем. Моннан соң ачмам да, карамам да,— диде.

Егетнең бу сүзләрен ишетеп, кичерәләр, соңра егетне сахрага алып чыгып йөртеп, һөнәргә дә өйрәтеп алып кайталар. Өйгә кайткач, болар, малайга:

— Әйдә, иптәш, көрәшеп карыйк,— диделәр.

Малай:

— Әүвәл үзегез көрәшеп карагыз,— диде.— Минем белән көрәшсәгез, әле мин сезне ексам, сез гарьләнерсез дә миңа зарар итәрсез. Әгәр дә сез миңа тимәскә ант итсәгез, мин көрәшәм,— диде.

Болар ант иттеләр.

Малай әүвәл күгәрчен белән көрәшеп, аны екты, батырга каршы икенче булып лачын чыкты, өченче — козгын чыкты. Козгынны малай күтәреп бәргән иде, козгынның бик ачуы килеп, малайның күзен чукырга омтылды. Шул вакыт иптәшләре:

— Тик тор, антың башыңа җитәр,— диделәр.

Козгын бу эшеннән тукталды, шулай да козгын батырга бик оят булды. Шуннан соң козгын, малай белән дуслашып:

— Син, энем, өеңә кайтасың киләме? — диде.

Малай:

— Кайтуын кайтыр идем дә, бу көнгә чаклы бар да үлеп беткәннәрдер инде,— диде.

Козгын:

— Юк, үлмәгәннәр, алар бар да исән, мин күреп килдем,— диде.

Малай кайтырга разый булып, кошлар, дүртесенә дә дүрт капчык алтын алып, дүртәүләшеп, малайның авылына очып киттеләр. Авылга

очып барып төштеләр дә, малайны калдырып, кайтып китәр чакта малайга бер кызыл яулык бирделәр:

— Без исән булсак, бу яулыктан сөт тамар,— диделәр.

Малай боларга бер ак яулык биреп:

— Шулай ук мин исән булмасам, бу яулыктан кан тамар, шул вакыт мине эзләргә чыгарсыз,— диде.

Малай үзләренең өен эзләп таба да анасыннан, барып, кунарга урын сорый.

Әби:

— Монда йөрмә, моннан әүвәл улымны кәрванчылар алып китеп, башын югалттылар,— диде.

Шулай да малай:

— Мин бит кәрванчы түгел, мин берүзем генә,— дип, күп сорый торгач, әби егетне кертте.

Болар чәй эчеп утырганда, сүздән сүз чыгып, малай турысында сөйләшә башлыйлар. Малай әбигә:

— Әби, әгәр дә син улыңны күрсәң, таныр идеңме? — диде.

Әби:

— Танымыйммы, башы белән пичкә керсә, артыннан таныр идем,— диде.

Малай:

— Әй, әби, бернәрсә дә танымыйсың, тик сөйлисең генә, менә мин каршыңда утырган — улың бит,— диде.

Алар кочаклашып күрешәләр, бик җылашалар.

Бу егет, берзаман ишегалдына чыгып, атасының бердәнбер булган корчаңгы таен күрде һәм атасыннан:

— Бу тайны бирсәгез, мин бер җиргә барып кайтыр идем, менә фәләнчә патшаның фәрманын ишеттем, аның кызы бар икән, кем дә кем шул кызның бүлмәсенә кереп, алмаз кылычны алып кайтып патшага бирсә, патша кызын аңарга бирә, имеш,— диде.

Атасы:

— Әй, улым, бу корчаңгы тай белән кая барырсың? — диде.

Шулай да, егет бик ялынып сорагач, разый булды.

Бервакытны егет патшаның сараена барып җитеп:

— Менә мин алмаз кылычны китереп бирәм,— диде.

Кешеләр бу корчаңгы тайны күреп бик көләләр. Бу малай рөхсәтне алып чыгып китә.

Күп тә бармый, моның аты бер чокырлы җиргә абынып тәгәрәп китә, үзе күгәрчен булып, атын ташлап очып китә. Патша кызының сарае өстендә очып йөри. Патшаның кызы бу күгәрченне күреп бик соклана, бу күгәрченне тотарга теләп, тәрәзәне ачып, тәрәзә төбенә җим сала. Күп вакыт үтми, күгәрчен ачык тәрәзәдән кереп, җимне ашый башлый. Бераз ашагач, шапшоп итеп кагына да егет була. Кыз алмаз кылычны алып чабарга кулын сузганда гына егет тиз генә атасының хатын биреп өлгерә:

— Син миңа тимә, мин синеке, син минеке буласың,— ди.

Кыз:

— Соң синең нинди һөнәрләрең бар, миңа күрсәт? — диде.

Егет, күгәрчен булып, кызның башына кунды. Кыз тиз генә канатының бер читен кисте дә яулыгына төенләп куйды. Егет икенче мәртәбә лачын булды, өченче мәртәбә козгын булды, соңра: «Минем һөнәрләрем шул»,— дип, алмаз кылычны сорады. Кыз кылычны биреп, өстенә бер алтын балдак та кидертеп, киткән вакытта:

— Юлда барганда бик йокың килер, йоклама,— диде.

Егет исәнләшеп очып китә. Бераз җир очып баргач, егет чыдый алмады, йокларга ятып, бик каты йокыга китте. Бу патша кызының көтүчеләре шул кырда йөриләр икән. Бу егетне күреп таныйлар да, урлап алган дип белеп, алмаз кылыч белән егетнең башын чабалар да ташлыйлар. Алмаз кылычны алып кайтып патшаның кулына тапшыралар. Патша кылычны күреп кем алып килгәнне белгәч, кызын көтүчегә бирергә сүз куеп, ашарга-эчәргә утырдылар.

Егет сахрада өч көн яткач, әлеге лачын, күгәрчен, козгыннар килеп, егетнең үлеп ятканын күреп, моны терелтергә чара эзли башладылар. Шул вакыт козгын бер ат тоягын табып ала да, шуның эченә кереп ята. Күп тә үтми, бер ала карга килеп тоякның өстенә куна. Козгын аны эләктереп ала да:

— Тизлектә мәңге суын алып кил,— ди.

Ала карга разый була. Шул ук сәгать мәңге суын китереп, бу суны егетнең өстенә сибеп җибәргәннәр иде, егет сикереп торып:

— Һай, бик күп йоклап киткән икәнмен,— диде.

Болар:

— Әй, йоклаган идең, без килмәсәк инде син мәңгегә йоклаган идең, килеп терелтмәсәк, харап булган идең,— диделәр дә саубуллашып очып киттеләр.

Бу егет тора да китә. Китә торгач, барып җитә бер шәһәргә. Йөри

торгач, начар гына өйгә килеп керә дә үзенә йокларга урын сорый. Монда берәр көн торгач, өй хуҗасы әбидән сорый:

— Йә, әби, сездә нинди хәбәрләр бар? — ди.

Әби:

— Менә патшабыз үзенең кызын алмаз кылыч алып кайткан егеткә бирәчәк, туй ясарга хәзерләнеп торалар,— дип сөйләп бирә.

Соңра егет әбидән:

— Әби, синең берәр сазың юкмы? — диде.

Әбинең үлгән улыннан калган бер скрипкәсе бар икән. Бу скрипкәне алып, егет уйный башлый. Әби, моның уйнаганын бик яратып:

— Патша туйга уенчыларны җыячак, син дә бу скрипкәне алып сарай алдына барып уйнап тор,— диде.

Бу, әбинең сүзен тыңлап скрипкәне алып, сарай алдына барып уйный башлады. Патшаның хезмәтчеләре күреп, патшадан бу егетне дә алып керергә рөхсәт сорадылар. Патша рөхсәт бирде. Егет сарайга керүгә скрипкәне уйный да башлады. Кунакларның нәүбәте белән бу да биргән шәрабны кире какмый эчте.

Бу егет шул мәҗлестә кияү булачак егетне дә күреп танышты һәм аңардан:

— Сезнең бу дәрәҗәгә ирешерлек нинди һөнәрегез бар иде. Шуны миңа сөйләп бирегез,— диде.

Кияү:

— Мин көтү көткәндә чыбыркы белән сугып сыгырларның[1] сыртларын яра идем, аннан кан чыга иде. Икенче һөнәрем: чыбыркының төбен калын, очын нечкә ишә торган идем,— диде.

Егет тагы:

— Нинди һөнәрең бар, яшермә, сөйлә,— дигәч, кияү, җырлый беләм һәм бии беләм дип, җырлап, биеп алды.

Патшаның кызы ишек артыннан боларның сөйләшкәнен тыңлап торадыр иде. Бу кияү, кунаклар үтенгәч тә, шулай ук кунакларга да җырлап, биеп, һөнәрен күрсәткән булды. Инде нәүбәт егеткә килде. Кунаклар егеттән дә һөнәрен күрсәтүне үтенделәр. Егет әүвәл скрипкә уйнап, кунакларның исен китәрде, соңра:

— Икенче һөнәремне күрсәтәм, ләкин патшаның кызы да монда чыксын,— диде.

---

[1] *Сыгыр* — сыер.

Кыз килеп чыккач, егет кызның тирәсендә әйләнде дә, күгәрчен булып, кызның башына кунды. Шул вакыт патша кызы яулыгын чишеп, кисеп алган канатларның очын атасына күрсәтеп:

— Менә минем киявем, алмаз кылычны да алган шушы егет булыр,— дип, кунакларга да күрсәтте.

Егеттән эшнең ничек булганын сорашып белгәчтән, көтүче ялган кияүне баганага асып, тиресен энә белән тунап, җәзалап үтерделәр.

Егет белән кызны икесен шул ук сәгать кияү өенә яптылар. Кияү җиңгәсе мин үзем булдым, кияү бик яшь икән — алма кебек егет, түшәкнең өстенә кара чикмән җәйдереп, маңгай чәчен тешләп, айгыр шикелле кешнәп, берничә кичне кундылар.

Икенче көнне кияүнең хәлен белергә патша, хатыны белән кереп, күрешкәч, егет патшадан кәләшен үз йортына алып кайтырга рөхсәт сорады. Патша рөхсәт биреп, алтын һәм гаскәрләр биреп, егетне озатып җибәрделәр.

Берничә вакытлар юл йөреп, үз илләренә кайтып ата-анасы белән күрешеп һәм киленне күрсәтеп таныштырып, икенче көнне бу йортларын сүттереп, сарай салдыра башлады. Моның сарае шәһәрдәге бөтен өйләрдән артык булып[1] чыкты. Егетнең болай күтәрелүенә исләре китеп, дуслар шатланып, дошманнар көенделәр.

Бу егет шул шәһәргә баш булды. Ун көн туй итеп, җиде мең шешә буза эчеп, мең чокырча кымыз эчеп, исереп, егетне мактый-мактый кунаклар таралдылар. Мин дә шунда булдым, бузаларының тәме әле дә авыздан китми.

7. Әбекәй

Бер бар икән, бер юк икән, тауга тары чәчкәндә, саескан гаскәр алганда, елан йомыртка[2] салганда бар иде бер пәри. Ком ашап, ком т... иде.

Әбекәйнең бердәнбер улы булган, аның улы бик укымышлы булган. Болар байның килгәнен күреп, кабакны[3] тутырып ачып, ачык йөз, татлы сүз белән каршы алдылар. Йортка килеп кергәч тә, атларын туарып

[1] *Артык булу* — яхшырак булу.

[2] *Йомыртка* — йомырка.

[3] *Кабак* — капка.

алып, үзен өйгә алып керделәр. Малай анасына кунакка самавар куярга кушты. Самавар кайнады, эскәтер җәелеп, чәй урыны хәзерләнде. Чәй янына килеп утыргач та, бай, сүз кузгатып, карчыктан малае турысында сорашырга тотынды. Ярлылыкларын күреп, малайның укымышлы икәнен белеп, малайга кызыгып, бай, бу карчыкка:

— Әби, улыңны миңа бирмәссеңме? — диде.

Әби:

— Малаемны бирер идем дә, аның бәһасе сезнең өчен кыйбат булыр; аның өчен аның укымышы бик зур,— диде.

Бай:

— Шулай да булса, күпме сорыйсың? — диде.

Әби:

— Елга өч йөз тәңкәдән дә ким бирмим,— диде.

Бай шул бәһагә разый булып, алдан йөз илле тәңкә ярәш акчасы биреп, малайны өч көнгә кадәр анасы янында калдырып, үзе кайтып китте. Өч көн үткәч тә малай үзенә кирәкле киемнәрне, зыбыннар[1], итек, камзул тектереп, байга барам дип, анасы карчык белән бәхилләшеп, елашып, юлга чыгып китте.

Ай барды, көн барды, балта сабы буе җир барды, бара-бара бер зимләнкәгә барып җитте. Барып кереп сәлам бирде, базда булган әби сәламне алып каршы алды һәм:

— Сәламең булмаса, бердән кабар идем, урталай өзеп йотар идем,— диде.

Малай, әбинең бу сүзен ишетеп:

— Чү-чү, әбекәй, йота күрмә, мин үзем дә дөнья куып йөримен,— диде.

Соңра әбекәй сүзгә башлап, малайдан:

— Кая барасың, син нинди кешенең баласы? — дип сораша башлады.

Малай әбекәйгә:

— Өч көннән элек кенә мине бер бай яллап киткән иде. Без үзебез әнкәй белән, тормышыбыз бик ярлы,— диде.

Әби:

— Әй, улым, алай икән, анда барганнарны күп күрдем һәм күп ишеттем, тик кайтканнар юк,— диде.

---

[1] *Зыбын* — чикмән.

Малай әбинең бу сүзләреннән куркынып китеп:

— Ник кайтмыйлар? — дип, сәбәпләрен сорый башлады.

Әби, аңарга сүз кайтармыйча:

— Минә моннан ерак түгел яланда бер базда тора торган минем тутам бар, сиңа ул әйтер, аңардан сорарсың,— диде.

Әби, үзенең гадәте буенча, малайга самавар куеп чәй эчереп кунак итте.

Ашап-эчеп туйганда кич булган иде. Әби, малайга, кунып чыгарсың дип, икесенә бергә урын түшәде. Малай карап торып шикләнеп китте һәм әбигә:

— Әби, нигә син үзең белән бергә җәясең, мин синең белән ятмам бит, миңа аерым түшә,— диде.

Әби, аңарга:

— Юк, улым, мин бу базда утыз елдан бирле торам, ир заты күргәнем юк, син бүген минем белән бергә кунарсың,— диде.

Малай, әби чакыргач та бераз шикләнеп торгач, соңра барып ятмый хәле калмады. Болар ятуга бераз дөньяның теләгенчә гашрәт иткәч тә, әби торып бердәнбер йорт хайваны булган кысыр тавыгын чалып, егеткә пешереп ашатты да яңадан ятып йокладылар. Иртә булгач, торып янә ашап-эчеп, егет, әби белән саубуллашып, үз юлына чыгып китте.

Егет киткәндә, карчык:

— Минә син моннан ерак түгел тора торган минем абыстама барырсың, ул анда сиңа барын да сөйләп бирер, ул син бара торган җирдә нәрсәләр булганын барын да белеп торадыр,— диде.

Егет чыгып китте. Шул киткәннән ай китеп, ел китеп, кашык буе җир китте. Бара торгач, әби тора торган зимләнкәгә барып җитеп, сәлам биреп өйгә керде.

Әби, аның сәламен алып:

— Әгәр дә, улым, сәламең булмаса, мин сине бер кабар идем, икедә йотар идем,— диде.

Егет:

— Тукта, әби, ашыкма, мин үзем дә дөнья куып йөри торган егетмен,— диде.

Әби янә сүзгә керешеп:

— Кайда йөрдең, кайдан киләсең? — диде.

Егет:

— Мин шулай байга ялландым, эшкә барам,— дип җавап бирде.

Әби:

— Беләм, улым, беләм, анда барганнар күп тә, кайтканнар юк,— диде.

Әби, кунакка самавар куярга кирәк дип, самавар куеп чәй эчерде. Соңра кич булып, әби, егеткә: «Кунып китәрсең»,— дип, урын җәяргә тотынды.

Әби егет белән йоклап торганнан соң, бар кебек булган итен казанга салып, ашатып-эчереп, егетне сыйлап озатырга чыкты һәм:

— Инде син сәгать уникегә кадәр бер суга кадәр барырсың, анда юл өстендә бер тал булыр, шул талның астына утырып көтеп тор. Озак тормаслар, ул бумага[1] син бара торган байның биш кызы, күгәрченнәр булып, су коенырга килерләр. Алар су коенганда йоннарын салып куярлар, әмма төпчек кызы йонын аерым салыр. Син башкаларын карамый, шул төпчек кызның йонын алып калырга тырыш,— диде.

Егет, әби белән исәнләшеп китеп, ерак та бармады, әлеге бумага килеп җитте. Озак та тормады, күгәрченнәр килеп су коенырга төштеләр. Егет шыпырт кына барып төпчек күгәрченнең йонын алып, янә тал төбенә килеп утырды. Кызлар моны күреп, куркышып судан чыктылар да, киенеп, өйләренә очып киттеләр. Әмма кече кыз кая да бара алмый, үзенең йонын эзләргә тотынды. Йөри торгач, тал төбенә утырган егетне күреп, аңардан сорады.

Егет:

— Йонын миндә,— диде.

Кыз аның нинди егет икәнен сорашып белгәннән соң:

— Безгә барасың икән, әмма анда барган күп, кайткан юк,— диде.

Шуннан соң егет:

— Син миңа андагы тормышларны сөйлә, мин анда ничек барып керим? — диде.

Кыз:

— Син бу суны узуга, сиңа каршы унике башлы бер аждаһа килер, сине йотарга теләр, аңардан котылыр өчен менә мин сиңа бер тимерчыбык бирим, син шуны кадарсың да артында сакланып торырсың, ул чыбыкны иснәр дә, адәм түгел икән дип, кире китәр. Шулай итеп, аңардан котылырсың. Аннан соң безнең йортка барып керерсең. Безнең йорт тулы төрле ерткыч хайваннар булыр, алар сине капкадан керүгә

[1] *Бума* — буа.

өзгәләп ыргытырга торырлар. Аның өчен мин сиңа бер яулык бирим, капканы кергәч тә ике якка шул яулык белән селкерсең, алардан да котылырсың. Аннан соң атам янына кереп сәлам бирерсең. Аннан соң буласы эшләрне анда баргач сөйләрмен, минем синнән аерыласым юк,— диде.

Кыз, егеттән киемнәрен алып, өенә китте. Кыз биргән тимерчыбык белән яулыкны алып юлына төште. Байтак барганнан соң, моңа каршы юлга аждаһа килеп чыкты. Егет чыбыкны кадап, үзе аның артына сакланып торды. Аждаһа килеп иснәп караган иде, кеше түгел икән дип, кире китте. Соңра йортка барып кергәч тә кыз әйткәнчә эшләп, ерткыч хайваннардан да котылып, өйгә барып кереп сәлам бирде. Бай, моның килеп керүенә исе китеп, үзенә бер өй биреп, дүрт көн ял итәргә рөхсәт бирде.

Бай малайга аш илтергә кушкач, кызлар, кемгә нәүбәт чыгар дип, шобага салыштылар. Бәхеткә каршы, төпчек кызга килеп чыкты. Кыз ашарга-эчәргә илткәндә егет белән сөйләшеп:

— Дүрт көннән соң әти сине сарайдагы унике башлы аждаһаны сугарырга җибәрер,— диде.— Моннан ерак түгел унике сажин тирәнлегендә бер бума бар, әмма аждаһаны тотып алып баруы бик кыен. Ул тотарга килгәндә, ишекне ачуга кешене дә — ни очрады аны йотадыр. Син аңардан курыкма, сарай ишеген ачкач та шунда бер лом булыр, шул тимерне ал да маңгаена өч тапкыр сук, аннан соң басылыр да, кереп җүгән[1] кигезерсең дә бүгеткә[2] алып барырсың. Ул туп-туры күлнең уртасына барып керер, бер чумар да соңра һавага сикерер, әмма син бер дә курыкма, тик ялын тот та кулыңны ычындырма,— диде.

Вакыт үтте, рәхәт көннәр кичте. Бай малайга кыз әйткән эшләрне эшләргә кушты. Егет тә кызның өйрәтүе буенча барын да кирәгенчә эшләп, җиренә җиткерде. Байның исе китеп:

— Син өйдә вакыт ни белән эш иттең? — диде.

Егет:

— Мин өйдә шундый нәрсәләр белән вакыт кичердем,— диде.

Соңра бай егеткә янә дүрт көн ял итәргә чик бирде. Бу дүрт көн дә ашау-эчү, йоклау белән үтеп китте. Бишенче көндә янә моны бай чакырып, аждаһа эчереп кайткан күлне киптереп, күл төбенә ашлык чәчеп,

[1] *Җүгән* — йөгән.
[2] *Бүгет* — буа.

булдырып, урып-сугып, суырып, киптереп, тарттырып, он ясап, чувал[1] салып, квашна[2] ясап, апара изеп, ачы камыр белән ачытып, яхшы йомры иттереп әвәләп, шул чувалда пешереп, иртә сәгать сигезгә кадәр байга китерергә кушты. Бай, егеткә күлне бушатыр өчен, бары ике кечкенә чиләк бирде. Эшнең ничек буласын моңа кыз электән сөйләп куйган иде. Бу эшләр адәм баласының кулыннан килмәгәнлектән, кыз моңа бер балдак биреп, шуны сызгыртып үзенә ярдәмгә пәриләрне чакырырга кушкан иде. Егет байның сөйләгәнен тыңлап бетергәннән соң:

— Ярый, бик яхшы, кулдан килгән кадәр тырышырмын,— дип, Аллага тапшырып, үз юлына чыгып китте.

Бу вакытта кич сәгать унбер иде. Егет тиз генә күлгә барып, балдакны кулына алып, сызгыртып җибәргән иде, бөтен дөньяда булган аксактуксак, сукыр, сулагай, чукрак, чагыр[3], биртелгән бөтен дөнья пәрие моның янына килеп җыелдылар да: «Ни боерасыз?» — дип, хәзер тордылар. Егет эшнең ничек икәнен пәриләргә сөйләде дә, үзе, бер түмгәк башына утырып, чилем тартырга тотынды. Пәриләр җан тиргә төшеп, күз ачып йомганчы күлне бушатып иген чәчеп, булдырып, хәзернең эчендә икмәкне пешереп, егеткә китереп тоттырдылар. Бу вакытта кояш чыгып кына киләдер иде.

Егет икмәкне кулына тотып байга кайтып килгәндә сәгать нәкъ сигез иде. Егет байга кереп, икмәкне кулына китереп тоттырды. Бай моңа таң калып каршы алды, чөнки бу һичбер адәм баласының кулыннан килә торган эш түгел, дип уйлый иде. Бай егеткә күп рәхмәтләр укып, янә берничә көннәр ял итәргә рөхсәт бирде.

Төнлә йокларга ятканнан соң, хатыны белән сөйләшеп ятканда бай, хатынына:

— Син караганың бармы, безнең кызларыбыздан берәрсе аның янына барып сөйләшеп йөрмиләрме? — диде.

Хатын чыгып кызларны тикшереп караган иде, төпчек кызы урынында юк. Анасы тышка чыгып барганда, баскычта очрады да анасының: «Кая бардың?» — дигән сүзенә: «Тышка чыктым»,— диде. Анасы, ышанмыйча:

— Син егет янына баргансың,— диде.

---

[1] *Чувал* — мич.
[2] *Квашна* — куәс чиләге.
[3] *Чагыр* — кылый.



Кыз:

— Мин анда ни эшләргә барыйм, куркуымнан ишек төбенә генә утырып кердем,— диде.

Хатын, ире янына кереп:

— Кече кызың анда юк иде, миңа «тышка чыктым», дип җавап бирде,— диде.

Бай:

— Сиңа әллә кайчан ук карарга кирәк иде,— дип, бераз тиргәп алды.

Икенче көнне хатын янә барып караган иде, кыз янә урынында юк. Соңра сизеп белделәр ки, кыз егет янына барып йөри, имеш. Инде кыз белән егетне икесен дә асарга сөйләштеләр. Кыз бу сүзләрне тыңлап торды да таң алдыннан егеткә барып сөйләде.

Егет:

— Инде без монда торсак, безне үтерерләр, без качыйк,— диде.

Шул ук минут егет белән кыз, җыенып, чыгып киттеләр.

Иртән торгач, кызларны чыгып карасалар, кече кыз юк. Кечкенә өйгә барып карасалар, хезмәтче дә юк. Соңра белделәр ки, болар икәү бергә качып киткәннәр. Бай шул ук сәгать олы кызын диюгә атландырып, куарга җибәрде.

Кыз диюгә атланып олы юл белән киткән иде, озак бара торгач, кечкенә генә бер сарык көтүенә очрады. Аларны көтеп, бер картрак кына көтүче читтән чыбыркысын шартлатып йөридер иде. Кыз боларга килеп җитте дә, көтүчедән:

— Бер кыз белән бер егет күрмәдегезме? — дип сорады.

Көтүче:

— Юк,— дип җавап бирде.

Кыз диюе белән өйгә кире кайтып китте, һәм атасына:

— Таба алмадым,— дип җавап бирде.

Атасы, кыздан:

— Ни күрдең? — диде.

Кыз:

— Тик бер кечкенә генә көтү белән көтүче күрдем,— диде.

Бай:

— Алар шулар иде инде, ник аларны алып кайтмадың? — диде.

Соңра икенче кызы чыгып киткән иде, озак бара торгач, бер урманга барып керде. Урманга барып кергәч тә кыз, тәтәсен күреп, үзе аучы булып, егетне бер эт сурәтенә куеп, җилкәсенә мылтык күтәреп бер куянның эзе белән барып ятадыр иде. Тәтәсе килеп җитте дә аучыдан янә:

— Шундый кыз белән егет күрмәдеңме? — диде.
Аучы:
— Мин андый кешеләргә очраганым юк, әле куян куып йөрим,— диде.
Икенче кызы да атасына буш борылып кайтты.
Соңра өченче кызын җибәрде. Кыз, өченче тәтәсенең килгәнен күреп, янә кырыктартмачы сурәтенә кереп, егетне ат итеп җигеп, юлдан барадыр иде. Тәтәсе килеп җитүгә, янә сорады да кире кайтып китте.
Аннан соң бай дүртенче кызын җибәрде. Дүртенче тәтәсенең килгәнен күреп, кыз кәрванчы кыяфәтенә керде. Бу да сорашып кына кире кайтып китте.
Соңра бай, кызларына ачуланып, үзе чыгып китте. Кыз, атасының килгәнен күреп, егетне су ясап, үзе шул күлдә чуртан булып йөзеп йөридер иде. Бай килеп җитүгә: «Бу Ходай орган монда икән»,— дип, үзе сазан булып, чуртанны куарга тотынды. Никадәр куып йөрсә дә, тота алмады. Аннан соң күлнең уртасына бер тимерчыбык кадап, аның башына агач башмак илтеп куйды да:
— Син минем сүземне тыңламасаң, шул чыбык әнә булганчы, башмак яфрак кадәр нечкә калганчы, шул күлдә йөзең кара булып йөзтүбән йөр,— дип, каргап кайтып китте.
Соңра кыз, егетне кире үз кыяфәтенә куеп, өенә кайтарып җибәрде. Үзе атасы билгеләгән вакытны шунда йөзеп үткәрергә калды. Егет кыз белән саубуллашып кайтып китте. Өенә кайтып кергән иде, анасының һушы китеп ауды. Соңра һушына килеп торды да малае белән күрешеп, сөйләшеп, бергә шатлык белән көн итә башладылар. Егет өйләнеп иген игә башлады.
Берничә еллар үткәч, бер бакчага карбыз алырга барган иде, бакчаның хуҗасы карчык:
— Үзеңә ошаганнарын сайлап төя дә акчасын зимләнкәгә китереп бирерсең,— диде.
Егет, бер йөк карбыз сайлап төяде дә, акча бирергә дип, зимләнкәгә барды. Карчык матур бер кыз булып, бер бите ай, бер бите кояш булып утырадыр иде. Егет килеп карап шаккатты.
Кыз, аңа:
— Әй, егет, син мине таныйсыңмы? — диде.
Егет, шул ук вакыт, хәтеренә үткәннәрне төшереп, исәпләп:
— Таныйм, син фәлән кызсың,— диде.

Соңра егет белән кыз бергәләшеп өйгә кайтып киттеләр. Авылда боларны күреп исләре китмәгән кеше калмады.

Бу вакыт егетне кырда өмәсе күтеп торадыр иде. Өмәчеләр бик озак азык көтеп торгач, ашарга да, эчәргә дә китерүче булмагач, аптырашып өйгә кайтып киттеләр. Өйгә кайтып керсәләр, өйдә ду туздырып туй ясап яталар иде.

Егет:

— Хуш кайттыгыз,— дип, боларны каршы алды. Болар килен белән котлап, бәхет теләделәр. Егет тәмам бер атна туй ясап, якыннарын сыйлаганнан соң, кунаклар үзләренең өйләренә кайтып киттеләр.

Килен озак та тормады, аны төрле яктан карарга килделәр. Бөтен тирә-якка исеме таралды. Боларга карарга килүчеләр һичбер тынычлык бирмәделәр. Соңра бер көнне торып карасалар, килен бер карчык сурәтенә кергән. Егетнең бер иптәше киленне карарга дип килгән иде. Егет аңа карчыкны күрсәтте. Бу кунак үзенең иптәшен бу карчык белән торган өчен бераз әрләп:

— Ничек торасың? — дип, янә үзенә кайтып китте.

Егет, аңарга каршы:

— Ул төрле сурәткә керә аладыр, бу көн болай, иртәгә тегеләй,—диде.

Кунак аңа каршы:

— Әй, шул япь-яшь гомереңне шундый җадау[1] белән үткәрәсең икән,— диде.

Берәр атна үткәннән соң, карчык янә кыз булды. Шулай итеп, болар рәхәтләнеп тора башладылар.

8. Патша улы

Бердән берәү бар иде. Бер патша бар иде, аның өч кызы, бер улы бар иде. Патшаның хәзинәләре хисапсыз.

Патша, улына:

— Мин үлгәчтән, мине җир астына күммәгез, шул бүлмәгә тәхетем белән куегыз. Мин үлгәчтән, калган хәзинә сарайларын берсеннән башка барын да ач, әмма берсен ачма, аны ачсаң, үз башыңа бәла килер,— диде.

---

[1] *Җадау* — ябык, арык.

Патша картлык көнендә үлде, үзе үлгәннән соң улы бөтен васыятьләрен җиренә җиткереп, үзен җиргә күммичә, тәхете белән бер бүлмәгә куйдылар.

Аталарының үлүенә бик эчләре пошып, бер көнне өч кыз, бер малай азрак күңел ачарга сахрага киттеләр. Яхшы гына утырганда, һавадан өч кош килеп, бу егетнең өч тәтәсен дә күтәреп алып киттеләр. Малай, күңелсезләнеп, өйгә кайтып анасына булган вакыйганы сөйләде:

— Тәтәләрне кошлар алып, белмим, каядыр киттеләр,— диде.

Аннан соң бу малайның бик эче поша башлады. Көннәрнең берендә малай анасына:

— Әни, без әтине җир астына күмик, монда күз алдында булганлыктан бик эчне пошырадыр,— диде.

Анасыннан рөхсәт алып, күмгәннән соң, малай бер вакытта атасының тәхетенә яткан иде, түбә тактада бер кызның сурәтен күрде. Андый кызны гомерендә дә күргәне юк иде. Бу егет аны күрүгә гашыйк булды һәм анасына:

— Әни, аны эзләргә барырга рөхсәт бир? — диде.

Анасы:

— Әй, улым, аны син каян табарсың? — диде.

Күп сорый торгач, анасы улына рөхсәт итте. Шуннан соң егет, атын иярләп, юлга чыгып китте. Ничә вә ничә көннәр барганнан соң, бер шәһәргә барып җитте. Ул шәһәрнең эчендә беркем дә юк иде, бары патшаның сараеннан бер кыз багып торадыр иде. Егет шәһәрдә күп әйләнеп йөргәннән соң, сарайга килеп җитте дә, кызга карап:

— Син адәмме, җенме? — диде.

Кыз:

— Адәммен,— диде.

Егет:

— Син адәм булсаң, мин дә адәм баласы, минем бик карыным ачты, миңа ашарга бирәр нәрсә бир,— диде.

Кыз:

— Бирүен бирер идем, минем яныма керергә һичбер юл юк,— диде.

Егет:

— Алай булса, син тәрәзәдән бер җеп суз да, мин шуңарга тотынып менәрмен,— диде.

Кыз җепне сузды. Егет атыннан төшеп, җепкә тотынып, үрмәләп менеп китте. Соңра кыз егеткә ашарга биреп, карыны туйганнан соң,

сорашып белештеләр. Бу кыз егетнең олы тәтәсе булып чыкты. Сөйләшергә башлаганда гына кыз:

— Мин диюдә торам, хәзер кайтып киләдер, күрсә, үзеңне ашар,— дип, сихер белән егетне энә ясап, тәрәзә качагына[1] кадап куйды.

Дию, кайтып керүгә, кызга:

— Адәм исе киләдер, кем бар, энең килдеме? — диде.

Кыз, юк, дип караса да, дию кыстап:

— Бар дигәч бар, кая, чыгар? — диде.

Кыз нишләргә белми, сулсум[2] укып, энәне янә егет ясап куйды. Егет дию белән күрешеп таныштылар. Дию, егетне түренә алып кереп, сорашырга тотынды:

— Әй, каене, син монда ни эшләп йөрисең? — диде.

Егет:

— Мин монда усаллык белән йөрмим, менә атамның бүлмәсендә бер сурәт күрдем, шуны эзләргә чыктым,— диде.

Дию:

— Аны син түгел, без, өч агайне, никадәр тырышып карадык, ала алмадык. Инде аны син генә ала алмассың,— диде.

Соңра егет:

— Алсам-алмасам да, тапмыйча калмыйм, йә алам, йә үләм,— диде.

Дию:

— Инде алай булса, син аны бу ат белән таба алмассың, монда бер аргамак бар, мин сиңа шуны бирәм,— диде.

Егет дию-җизнәсенең бу эшенә күп рәхмәтләр укып чыгып китте.

Озак бара торгач, янә бер шәһәргә килеп җитте. Бу шәһәрдә баягы кеби бер кеше дә юк иде. Күп йөри торгач, егет янә бер сарай тәрәзеннән бер кыз күреп:

— Син адәми затмы, пәриме? — диде.

Кыз:

— Адәми зат,— диде.

Егет:

— Адәми зат булсаң, минем карыным ач, минем карынымны тук ит,— диде.

Кыз:

---

[1] *Тәрәзә качагы* — тәрәзә яңагы.
[2] *Сулсум* — әфсен.

— Минем урыным тирәли бикле, монда керергә юл юк,— диде.

Егет:

— Тәрәзәдән җеп суз да, мин җеп буенча үрмәләп менәрмен,— диде.

Кыз җеп сузды. Соңра егет, җептән үрмәләп, тәрәзәдән бүлмәгә керде. Кыз егетне ашатты-эчерде, соңра танышып сөйләштеләр. Кыз моның икенче тәтәсе булып чыкты. Кызып кына сөйләшергә тотынганнар иде, дию кайта торган тавыш ишетелде. Кыз, куркып, дию күрсә зарар китерер дип, сихер белән энә ясап, егетне тәрәзә яңагына кадап куйды.

Дию, кайтып керүгә:

— Фу, адәм исе килә, монда кем бар? — диде.

Кыз:

— Монда нинди адәм исе булсын, үзең адәмнәр арасында йөреп кайттың, үзеңнән килә торгандыр,— диде.

Дию, кызга ышанмыйча:

— Чыгар! — диде.

Кыз, ни эшләргә дә белмичә, диюдән куркуыннан егетне янә, сихерен кайтарып, егет ясады. Егет дию белән күреште.

Дию:

— Бик яхшы, каене, рәхмәт искә төшереп килүеңә, һәм монда ничек килеп адаштың? — диде.

Егет моңа:

— Шундый сурәт күрдем, шуны эзләргә чыктым,— диде.

Дию:

— Әй, шурин[1], аны син таба алмассың, менә без никадәр тырышып та таба алмадык, менә миндә бер аргамак бар, тапсаң шуның белән генә таба алырсың,— дип, егеткә аргамакны иярләп бирде. Егет, атланып, җизнәсенә күп рәхмәтләр укып, бу шәһәрдән чыгып китте.

Ничә көннәр барганнан соң, бер шәһәргә барып керде, анда бер кеше дә юк иде. Бары сарайда бер кыз утырадыр иде. Егет барып, кызга сәлам биреп:

— Син адәми затмы? — диде.

Кыз:

— Адәми затмын,— диде.

---

[1] *Шурин* — каене.

Егет:

— Алай булса, минем карыным ач, карынымны тук ит,— диде.

Кыз:

— Минем яныма керергә юл юк,— диде.

Егет:

— Тәрәзәдән җеп суз,— диде.

Кыз җеп сузды, егет үрмәләп кызның бүлмәсенә керде. Күрештеләр, сөйләштеләр. Бу кыз егетнең кече тәтәсе булып чыкты. Болар сөйләшеп утырганда, диюнең тавышы ишетелә башлады.

Кыз:

— Дию сиңа зарар китерер,— дип, сихер укып, егетне энә ясап кадап куйды.

Дию, кайтып кергәч:

— Адәм исе килә, монда кем бар? — диде.

Кыз:

— Бер кеше дә юк, үзең адәм арасыннан кайттың,— диде.

Дию:

— Сиңа бернәрсә дә булмас, чыгар,— дигәч, кыз, сихерен кайтарып, энәне янә егет ясады.

Күрешеп сөйләшкәннән соң, дию:

— Әй, шурин, ни эшләп йөрисең? — диде.

Егет:

— Бер сурәт таптым, шуны эзләп йөрим,— диде.

Дию:

— Без өч агай, өч табаннан[1] эзләдек, алай да таба алмадык, менә миндә бер аргамак бар, аны бирсәм, бәлки, табарсың,— диде.

Егет, күп рәхмәтләр укып, исәнләшеп янә чыгып китте. Егет киткәндә, аңа җизнәсе:

— Ул моннан алты айлык юлда, әмма бу аргамак сине өч көндә җиткерер,— диде.— Үзең бик арысаң, ял иткәндә ияре белән йөгәнен ал да үзен җибәр. Кайчан кирәк булса, ул вакыт йөгән белән иярне кулыңа тотарсың да ул үзе килер. Юлда барганда син аңарга бер дә сукма, өч көндә җитәрсең. Өч көн барганнан соң, бер кара урманга җитәрсең, ул урманның эчендә бер сарай булыр, шул сарайга җитәр вакытта син аңа бер сук, тиресен ярып, итен ярып. Сөягенә җитсен. Шуннан соң ул сарайның эченә сикереп төшәр,— диде.

---

[1] *Өч табаннан* — өч яктан.

Егет бер көн, бер төн барганнан соң, арып, бик йокысы килде. Атыннан төшеп, иярен, йөгәнен алып, баш очына куеп, йокларга ятты. Иртә торгач, ияр белән йөгәнен кулына тоткан иде, ат егет янына килеп басты. Егет, атланып, янә китте. Бер көн, бер төн барганнан соң, бер кара урманга барып керде. Урман белән бер көн, бер төн барганнан соң, җәүһәр ташлар белән бизәлгән бөтен урманны яктыртып тора торган бер сарай күрде. Сарайга өч чакрым калганда атына бер суккан иде, аты, гайрәткә килеп, сарайның коймасын сикереп, эченә барып төште. Егет, атың йортта[1] калдырып, үзе сарайның эченә кереп китте.

Йөри-йөри бу бер бүлмәгә барып керде. Анда кыз яткан, янында кырык кәнизәк басып торадыр иде. Егетне күрүгә кәнизәкләр бар да кыз янынннан качып киттеләр. Егет, кызны күрүенә шатланып, кыз белән сөйләшергә тотынды.

Кыз егеткә:

— Тукта, сабыр ит, мин фал китабымны алып күрим,— диде.

Кыз алып караса, фал китабында кызның янына бу егет киләчәк дип язылган иде. Кыз, бакканнан соң:

— Әй, егет, инде мин сиңа, син миңа булачак икән, күрешик,— дип, сөйләшергә башладылар, һәм икесе дә теләгән моратларына ирештеләр.

Егет шунда калып тора башлады. Боларның көннәре кызыклы гына булып үтеп торадыр иде. Берничә вакыт үткәннән соң, болар сахрага чыгып йөри башладылар.

Күп вакытлар үткәннән соң, кыз үзенең шәригеннән хат алды. Хатта шәриге кызны үзенең туена чакырган иде. Кыз, хатны укып, киявенә:

— Менә мин шәригемнән хат алдым, ул мине үзенең туена чакыра. Инде син миңа кырык көнгә туйга барырга рөхсәт бир,— диде.

Кияве рөхсәт иткәннән соң, кыз, киемнәрен киеп, туйга барырга хәзерләнә башлады. Хәзерләнеп тәмам булганнан соң, киявенә унбер сарайның ачкычын биреп: «Унысын ач, берсен ачма»,— дип, чыгып китте.

Кыз киткәч, егетнең эче поша башлады, чыгып сарайларны ачып карый башлады. Караса, кайында[2] алтын-көмеш тутырылган иде. Күп эче пошып йөри торгач, егет, бу сарайда нәрсә бар икән дип, унберенче сарайны ачып карады. Анда стенага бер дию кадакланып куелган иде. Дию, егетне күрү белән, аңарга ялынып:

---

[1] *Йорт* — ишегалды.
[2] *Кайында* — кайсында.

— Миңа бер икмәк белән бер чиләк су бир,— дип сорап алды.

Егет, аңардан гына бернәрсә дә булмас дип, китереп бирде. Дию эчеп-ашады. Шул вакыт маңгаендагы кадак котылып[1] китте. Дию тагы сорап алып ашады, эчте — кулындагысы ычкынды. Шулай итеп, егеткә ялынып биш чиләк су белән биш күмәч сорап ашады да бөтенләй котылып китте. Сарайдан чыгып егет янына килде дә:

— Инде, егет, син мине бәладан коткардың,— дип, бер аягыннан тотып ыргытып җибәргән иде, егет һушсыз булып, олы тәтәсенең йортына барып төште.

Иртә торып, тәтәсе тышка чыкса, йортта бер үлек күрәдер. Өйгә кереп, диюгә:

— Йортыбызда бер адәм үлеге бар,— диде.

Дию белән чыгып карадылар, кем икәнен таный алмадылар. Каннарын юып карасалар, бу — кызның энесе булып чыгадыр. Шуннан соң моны дарулап, һушына китереп торгызалар.

Егет, торганнан соң:

— Мин бик ерак килгәнмен икән,— диде.

Дию:

— Әйе, әле син моннан да еракка киткән булыр идең, бәхетең бар икән, монда килеп төштең,— диде.

Соңра өйгә алып кереп ашарга-эчәргә утырттылар вә егеттән күргәннәрен сораша башладылар. Егет ни күргәнен баштанаяк барын да сөйләп бирде. Моның сүзләрен ишетеп, җизнәсе орыша башлады:

— Без аны стенага кадаклаганчы кырык ел гомер үтте, син аны ычкындырып җибәргәнсең,— диде.

Егет җизнәсенең сүзләрен тыңлап торды да:

— Хафаланмагыз, мин анда барыбер барачакмын,— диде.

Дию:

— Белмим шул инде, бара алырсыңмы икән, инде безнең анда бара торган аргамакларыбыз юк,— диде.— Инде, син, фәлән урманга бар, анда бер карчык тора, аңарда безнең аргамакларыбызның тәтәсе аргамак бар. Әгәр дә ул сиңа шул аргамакларны бирсә, син аның белән барып җитәрсең, һәм ул әйткән сүзләрне барын да эшлә, аңарда берничә аргамак булып, яхшысы да булыр, кыйтысы[1] да булыр, әгәр дә бирсә, син иң кыйтысын ал,— диде.

---

[1] *Котылу* — ычкыну.

[2] *Кыйты* — начар.

Егет, бу сүзләрне ишетеп, юлга чыгып китте. Юлда барганда очрады өч каргага. Алар бер куянны тотканнар да өчесе өч якка тартып торалар иде. Егет барып җитте дә, бу каргаларның тартышларын күреп, аларга тип-тигез иттереп куянны бүлеп бирде. Янә үз юлы белән киткәндә, моның каршына олы җизнәсе килеп җитте дә:

— Ни күрдең? — диде.

Егет:

— Өч каргага очрадым, алар куянны тотып бүлә алмыйча тартышып торалар иде. Мин аларга шул куянны тигезләп бүлеп бирдем,— диде.

Җизнәсе:

— Бик яхшы, юл кешесе икәнсең, юлың уңсын,— диде дә үзе китте.

Бара-бара, егет бер урманга барып керде. Анда аңарга урман иясе шүрәле килеп чыкты. Егет, аны күреп:

— Мин сине үтерәм,— диде.

Шүрәле:

— Әй, егет, син мине үтермә, бәлки, мин бер кирәгеңә ярармын,— диде.

Егет, шүрәлене җибәреп, янә үз юлы белән китте. Бераз барганнан соң, бер бүрегә очрады. Егет, аны да тотып:

— Мин сине ашыйм,— диде.

Бүре, телгә килеп:

— Әй, егет, син мине ашама, бер-бер кирәгеңә ярармын,— диде.

Егет аны да җибәрде дә үз юлы белән китте.

Берничә вакыт барганнан соң, бер зур күлгә барып очрады. Ул күлнең кырыенда бер балык коры җирдә ятадыр иде. Егет балыкка килеп җитте дә, балык, телгә килеп:

— Әй, егет, мине шул күлгә алып барып сал,— диде.

Егет балыкны күлгә илтеп салыр өчен күтәреп караса, һич тә күтәрерлек түгел. Шуннан соң егет, барып ике агач кисеп, шул агачларны салып, балыкны агачлар буенча тәгәрәтеп җибәрде дә, балык күлгә барып төште. Егет, үз юлы белән китеп, бер сарайга барып керде. Сарайда һичбер кеше күрмәде, бары бер карчыкны күрде. Аңарга барып сәлам бирде. Карчык, аңарга каршы:

— Әгәр дә, егет, бу сәламең булмаса, мин сине ашар идем,— диде.

Егет:

— Бисмиллаһ әйт,— диде.

Карчык:

— Минем бисмилла әйтә торган гадәтем юк,— диде һәм,— монда ни эшләп йөрисең? — диде.

Егет:

— Улы юкка ул булам, колы юкка кол булам,— диде.

Карчык:

— Бик яхшы, бул, сораган нәрсәңне бирермен,— диде.

Карчык бик яхшы ашатты-эчерде дә:

— Мин сиңа өч төрле өч күнлек эш кушам,— диде.

Иртә торгач, карчык, егеткә җиде бозау биреп:

— Шуларны ашатып китер,— диде.

Болар җидесе җиде кыз иде. Егет ашатырга алып китте. Кабакны[1] чыгып киткәннәр иде. Җидесе җиде якка таралып, чабып киттеләр. Егет ялгызы гына калды. Егет, аптырап, бер урманга барып керде дә, бер туйра төбенә утырып, җыларга тотынды.

Шул вакытта аның янына шүрәле килеп чыкты да:

— Әй, егет, ник җылыйсың? — диде.

Егет:

— Мин әбигә керешкән[2] идем, ул мине бозаулар ашатырга җибәрде. Капканы чыгуга бозаулар төрлесе төрле якка чабып, таралып киттеләр,— диде.

Шүрәле:

— Әй, егет, алар өчен син бер дә кайгырма, ят та йокла, без аларны кич булгач, карчыкның йортына илтеп куярбыз,— диде.— Алар хәзер буш агач эчендә,— диде.

Егет, бу сүзләргә шатланып, кайгысын бетереп, ятып йоклады. Уянып китсә, кояш батарга якынлашкан иде.

Шул вакытта шүрәле килеп:

— Әйдә, егет, бозауларны йортка илтеп куйыйк, вакыт җитте,— диде.

Егет, торып, шүрәле белән икәү бозауларны алып кайтып, әбигә тапшырды. Әби:

— Йортка җибәр дә үзең ашарга кер,— диде.

Егет ашарга керде, әби аш бирде. Егет ашарга тотынды, әби йортка чыгып китте. Егет, әби артыннан чыгып тыңлап торса, әби кызларны, ник кача алмадыгыз,— дип, сукып[3] әрли.

---

[1] *Кабак* — капка.

[2] *Керешү* — эшкә керү, берьюлы берничә эш башкару.

[3] *Суку* — сугу, кыйнау.

Кызлар, аңарга:

— Без качкан идек, агач эченнән шүрәле белән барып тапты,— диделәр.

Карчык, яңадан кереп, егетне ашатып-эчертеп, йокларга яткызды.

Иртә торгач, әби егеткә шул бозауларны биреп җибәргән иде, капканы чыгуга җидесе җиде яры таралып, чабып киттеләр. Егет, тагы урманга барып, туйра төбенә утырып, җыларга тотынды.

Шул вакыт бүре килеп егетне туктатты:

— Ятып йокла, кич булгач, без аларны барып табарбыз. Ул кызлар хәзер бер базда утыралар,— диде.

Егет ятып йоклады. Уянып китсә, кояш батып барадыр иде.

Шул вакытта бүре килеп:

— Әйдә, егет, бозауларны илтик,— диде.— Юлда барганда бүре егеткә: — Соңра, егет, әби ята торган өйгә ятма, башка җиргә ят,— диде.

Бүре белән егет бозауларны алып кайтып, йортка кертеп җибәрделәр. Әби:

— Бик яхшы, әйдә, ашарга кер,— диде.

Егет ашарга-эчәргә утырды. Әби йортка чыгып китте, егет тә аның артыннан чыкты, әби кызлар янына барып:

— Ник качмадыгыз? — дип, кызларны суктырырга тотынды.

Кызлар:

— Без качып бер базга кергән идек, ул базны бүре белән барып тапты,— диделәр.

Егет, яңадан өйгә кереп, утырып ашарга тотынды.

Әби егеткә:

— Инде, улым, бу көн өйдә ятарга сиңа урын юк, йортка чыгып башсыз-табансыз келәткә ятарсың,— диде.

Әби анда урын җәеп бирде дә, егет чыгып урынына ятты. Шуннан соң әби, өйгә кереп, үз-үзенә сөйләнергә тотынды. Егет аны тыңлап торды. Әби: «Инде бу көн бу егеткә үлем»,— диде. Егет бер талай[1] урынына килеп ятып торганнан соң, келәттән янтыкка[2] чыгып ятты. Егет тыңлап ятадыр иде, сәгать берләрдә әби чыгып егет ята торган урынга өч таш бәрде. Ул ташлар караватларны туздырып, идәннәргә

---

[1] *Бер талай* — берникадәр вакыт.

[2] *Янтык* — башка урын.

кадәр сындырып бетерделәр. Таң беленгәндә егет янә урынына барып ятты. Әби чыгып караса: егетне исән килеш тапты. Әби, егетне күреп:

— Нихәл, улым, исән йокладыңмы? — диде.

Егет:

— Аллага шөкер, әби, үзең исәнме, ләкин бик тыныч йоклый алмадым, төнлә белән каяндыр берничә таш төшеп бераз кабыргаларымны авырттырды,— диде.

Егет киенеп, ашап-эчкәннән соң, әби тагы бозауларны биреп җибәрде. Бозаулар капканы чыккач та җидесе җиде якка киттеләр. Егет ялгызы калды.

Егет, күл буена барып утырып, җыларга тотынды. Ул җылап утырганда күлдән бер балык килеп чыгып:

— Әй, егет, ник җылыйсың? — диде.

Егет:

— Җыламый ни эшлим, әби җиде бозау биреп җибәргән иде, бар да качып киттеләр,— диде.

Балык:

— Иә, егет, юк өчен кайгырма, алар бар да табылыр, ят та йокла,— диде.— Алар бозаулар түгел, кызлар, хәзер дә алар күл төбендә камышка тотынып торалар. Кич булганда без икәү алып барып йортка җибәрербез,— диде.

Балык янә:

— Егет, сине төнлә белән әби эшкә кушар, аның кырык чиләкле казаны бар, ул сине шул казанны кайнатырга кушканнан соң казан янына ятма, барып янтыкка ят,— диде.

Егет, бу сүзләрне ишеткәч, күл буенда ятып йоклады. Кич булганда уянып, балык белән икәүләп бозауларны йортка кертеп җибәрделәр.

Егет:

— Бозауларны алып кайттым,— диде.

Әби:

— Бик яхшы, шунда җибәр дә ашарга кер,— диде.

Егет ашарга кереп утырганнан соң, әби чыгып янә кызларны суктырырга тотынды.

Кызлар:

— Без су төбендә качкан идек, ул үзе генә түгел, аның балыгы да бар, балык белән икәүләп таптылар,— диделәр.

Соңра әби егеткә:

— Инде, улым, бу эшләремне эшләдең, рәхмәт, тагы бер йомышым бар,— диде.
Егет:
— Ярый, әби, бик яхшы, хәлдән килсә, эшләрмен,— диде.
Әби:
— Менә йортта бер казаным бар, шул казанга су тутырып, миңа юынырга су җылыт.
Егет, казанны куеп, су ташып тутырды да астына ут куеп якты. Казан берничә вакытлардан соң кайнап чыкты.
Егет, әбигә кереп:
— Кайнап чыкты,— диде.
Әби:
— Бик яхшы, шул казан янына ятып йокла,— диде.
Егет: «Ярар»,— дип чыгып китте дә, бераз ятканнан соң, үз урынына бер чурбан[1] куеп, өстенә үзенең киемен ябып куйды да, үзе янтыкка барып ятты. Әби тагы төнлә чыгып, казандагы бар суны егетнең өстенә түкте дә, үзе кереп китте. Егет таң алдыннан янә урынына килеп ятты. Егет иртә торып киенергә тотынды.
Шул вакыт әби чыгып:
— Йә, егет, нихәл, исәнме, ничек йокладың? — диде.
Егет:
— Яхшы йокладым, бары казанны кемдер актарган, әллә үзе ауган,— диде.
Әби:
— Яхшы, ул берни түгел, әле гомерең бар икән, әгәр дә синең өстеңә түгелгән булса иде, ул вакыт сөягеңдә итең калмаган булыр иде,— диде.
Иртә белән ашап-эчкәннән соң әби егеткә:
— Йә инде, егет, рәхмәт, бик яхшы хезмәт иттең, менә унбер аргамагым бар, шулар эченнән үзеңә ошаганын, күңелең ятканын сайлап ал,— диде.
Соңра әби аргамакларны берәм-берәм чыгара башлады.
Әби:
— Берсен ал,— диде.
Егет:
— Мин боларны җиңә алмам, болар бик көчле,— диде.

---

[1] *Чурбан* — бүкән.

Иң арттан бер бик арыгы чыкты да, егет шуны сорап алып иярләде. Соңра, чыгып киткәндә, әби:

— Егет, син аргамакка бер дә сукма, ни морадың бар, шуңа ирешерсең. Урманга кереп сарайга җиткәч, шул сарайны өч тапкыр әйлән, шуннан нәрсә ишарәт итсә, аны үзең аңла,— диде.

Егет ничә көннәр, ничә төннәр барганнан соң, сарайга барып җитте, өч тапкыр әйләнде. Кыз шул вакытта диюне итәгенә яткырып, сакалыннан бет багадыр иде. Кыз егеткә кояш баешы ягына таба ишарәт итте. Егет бернәрсә дә аңлый алмады. Ул бераз уйланып торды да, гайрәткә килеп, ни булса да булыр дип, атын аягы белән кысты да, ат сикереп сарай эченә барып төште. Егет атны бәйләп, үзе аралык[1] белән кереп китте. Бераз баргач, бер шкаф күрде, ачып карады, бер шешә аракы, аракы эчендә кара коңгыз йөзеп йөридер иде. Егет шешәне алып аракысын түкте, коңгызны кулына тотты. Егет коңгызны бераз кыскан иде, дию бик каты кычкырып җибәрде. Шуннан соң егет коңгызны аяк астына салып таптады. Бу коңгыз диюнең җаны иде. Шул сәгать дию кызның итәгендә җан бирде. Соңра, егет кыз янына барып, күрештеләр. Кыз егеткә күп рәхмәтләр укыды:

— Мине коткардың, минем гомерем әрәм үтә иде, инде морадың хасил булды — мин синеке,— диде.

Шуннан соң, бу диюнең кисәкләре җир өстендә калмасын дип, тураклап утка яндырып, көлен күккә очырдылар. Соңра кыз белән егет бик рәхәтләнеп тора башладылар.

Бердән бер көнне кыз:

— Сиңа ни булды? — дип егеттән сорашырга тотынды.

Егет:

— Син туйга киткәннән соң, бик эчем пошып, сарайларны ачып карап йөрдем,— диде.— Унберенче сарайны да ачкан идем, дию телгә килеп, миннән ашарга-эчәргә сорап алды «Мин синең изгелегеңне онытмам», диде. Шулай итеп, мин аңа ышанып, биш көндә биш чиләк су белән бер күмәч бирдем,— диде.— Ул шуларны ашап-эчкәннән соң, кадакларыннан ычкынды да мине тотып һавага атты. Мин күземне ачып карасам, үземне олы тәтәйнең йортында күрдем,— диде.

Шуннан соң кыз:

— Мин сиңа әйткән идем бит, син, хатын-кыз сүзе дип тыңламыйча, үз башыңа бәла алдың,— диде.

---

[1] *Аралык* — мич һәм стена арасындагы урын.

Берничә вакытлар торганнан соң егет, кызга:

— Инде без монда күп тордык, үз йортыбызга кайтыйк,— диде.

Кыз да риза булып, болар үз йортларына кайтырга җыена башладылар. Сарайлардан күп алтын-көмеш алып, икесе ике аргамакка атланып, кайтырга юлга чыгып киттеләр. Юлда килгәндә кызның янында бер фал китабы бар иде. Кыз, шул китапка карады да егеткә әйтте:

— Без юлда кече тәтәңә керербез, алар сине бер сиртмәле урынга утыртып, мине синнән күпсенеп, үтерергә теләрләр. Син анда утырма, үзгә урынга утыр,— диде.

Озак та китмәделәр, кече тәтәләренә килеп керделәр. Тәтәсе белән җизнәсе сиртмәле урынга утырырга кушты.

Егет:

— Бу безгә бик югары булыр,— дип, ул урынга утырмады.

Дию үзе барып сиртмәле урынга утырды. Тәтәсе моны күреп, сиртмәне борып җибәргән иде, сиртмә диюне урталай өзеп һәлак итте, әмма егет, тәтәсе, кыз исән калдылар. Тәтәсе егеткә күп рәхмәтләр укып, өчесе бергә кайтырга юлга чыктылар. Кыз, тагы фал китабына карап:

— Без тагы кунакка керербез, анда да сине сиртмәле урынга утыртырга теләрләр, син аңа утырма, һәлак булырсың,— диде.

Озак та үтмәде, барып керделәр. Җизнәсе белән тәтәсе шатлык белән чыгып каршы алдылар. Бүлмәгә кереп, җизнәсе урынга утырырга кушты.

Егет:

— Рәхмәт, без ул урынга утырырга лаек түгел, мин анда утырмыйм,— диде.

Шуннан соң дию үзе барып утырды. Тәтәсе сиртмәне борып җибәргән иде, дию өзгәләнеп барып төште. Моны да тураклап яндырдылар. Ике тәтәсе белән кайтырга чыгып киттеләр. Кыз, тагы фал китабына карап:

— Олы тәтәңә кергәч тә шундый хәл булыр. Син алар әйткән җиргә утырма,— диде,— алар сине һәлак итәрләр,— диде.

Монда килеп кереп, баягы кебек җизнәсен үтереп, өч тәтәсе, хатыны бергә үз шәһәрләренә кайтырга чыктылар.

Боларның шәһәрләре үзләре киткәндәгечә сау-сәламәт иде. Анасы да исән иде. Боларны каршы алып бик шатланыштылар. Бу егет атасы урынына патша булып утырды, тәтәләрен зурларга[1] бирде. Әле дә торалар, ди.

---

[1] *Зурлар* — дәрәҗәле кешеләр.

9. Мөгезле кеше

Борын-борын заманда бер карт белән карчык бар иде. Боларның һичбер бала-чагасы юк иде. Бары үзләре генә торалар иде.

Бу картның гадәте шул иде ки, көндез көн буена йоклап, төнгә каядыр китеп йөридер иде. Карчык янында һичбер төн йокламыйдыр иде. Бу карт, алтмыш яшьләренә җиткәч, үзенең карчыгына, бер кич:

— Сау бул инде, бәхил бул,— дип әйтеп, өйдән чыгып йортның[1] бер читенә барып ятты.

Карчык карап торып бер нәрсә дә аңлый алмады. Карт шул вакыт кычкырып җан бирде. Карт җан биргәч тә картның авызыннан бер бүрек кадәр ут чыгып, карчыкка таба тәгәрәп килә башлады. Карчык куркып, белгәннәрен укып, ишек-тәрәзәләрен ябып куйды.

Шуннан соң әлеге убыр ишектән дә, тәрәзәдән дә керә алмагач, тәрәзә төбенә килеп:

— Әй, карчык, мин синең картыңны алтмыш ел буенча авызына кереп убыр итеп йөрттем. Бервакыт синең дә авызыңа кереп, сине дә убыр итәрмен,— диде.— Мәгәр дә миннән шул вакыт кына котыла алырсың, кайчан картыңның гәүдәсен моннан өч йөз чакрым ерак җиргә илтеп ташласаң.

Карчык бу төнне һичбер йоклый алмыйча, берьялгызы өйдә утырып чыкты. Иртә берлә таң аткачтын күршеләренә әйтеп: «Шундый-шундый хәл булды»,— дип сөйләп, картның гәүдәсен илтергә кеше эзли башлады, ләкин бер дә баручы таба алмады.

Бу хәбәрне авылда яңа гына хезмәттән кайткан бер аскәр[2] ишетте һәм карчыкка килеп:

— Хезмәт ялына ниләр бирәсез? — дип сорады, аның өчен[3] аскәрнең бер тиен дә акчасы юк иде.

Карчык аскәргә:

— Әгәр дә син картымны өч йөз чакрымга илтеп куйсаң, ул вакыт мин сиңа алты ат, бер көймәле арба, алты йөз тәңкә бирәм,— диде.

Аскәр шуңа разый булып, алты атны һәм арбаны хәзер алып, алты

---

[1] *Йорт* — ишегалды.
[2] *Аскәр* — гаскәри.
[3] *Аның өчен* — чөнки.

йөз тәңкә акчаны кайткач алырга булып, атларны җигеп, картны йөзтүбән салып, арканнар белән бәйләп, Аллага тапшырып, бер якка таба чыгып китте. Иртәдән кичкә кадәр атларын ашатмыйча барып, кич булганнан соң карт, арбада селкенә башлап, шул вакыт арбаны алты ат тарта алмаслык булып, көпчәкләре җиргә бата башладылар. Аскәр бу хәлне күреп, атларны туарып, алтысын алты якка куып җибәреп, үзе дә бер якка юлсыз-нисез йөгереп китте.

Ерак та түгел бер урманга барып җитеп, урманның кырыенда үскән өч зур имән агачларына очрап, шуларның берсенең очына, куркып менеп утырды. Караса, арбадагы карт терелеп, кып-кызыл ут булып, моның артыннан «аскәр» дип кычкырып килә башлады. Моны күргәч, аскәр, белгәннәрен укып, куркып утырып торды. Карт килеп җитте дә агачны төбәннән тешләре белән кисә башлады. Аскәр бу хәлне күреп куркып утырганда искәрмәстән генә агач шатырдап ава башлады. Аскәр тиз генә икенче агачның ботагына эләгеп калды. Карт барып караса, агач ауган җирдә аскәр юк, ул икенче агачның башында утыра. Убырлы карт моны күреп, икенчесен дә кисә башлады. Аскәр өченчесенә килгәч: «Әй, аскәр, бик хәйләкәр икәнсең»,— дип, аны да кисә башлады. Моны кисеп бетергәнче әтәч кычкыра башлады, шул ук вакыт убырлы карт та юк булды.

Аскәр шуннан соң агач башыннан төшеп, атларын эзләп табып, яңадан арбага җигеп, көн озын алга таба китте. Карт әүвәлгечә үз урынында үлгән көе ятадыр иде. Кичкә кадәр барып, карт яңадан селкенә башлагач та, атларын тугарып алтысын алты якка куып җибәреп, үзе күзе караган якка йөгереп китте.

Азмы-күпме барса, бер юлга очрап, шул юл белән бер урманга барып керде. Караса, артыннан, төнәге[1] кебек, карт: «Аскәр, аскәр»,— дип, йөгереп киләдер иде. Аскәр, юл белән бара торгач, бер кечкенә генә өйгә туры килде дә аны-моны карамый пичкә кереп утырды. Карт та аның артыннан килеп кереп: «Аскәр, аскәр»,— дип кычкырып, аскәрне эзли башлады. Шул вакыт өйнең сәке астыннан ике зур эт чыгып, убыр белән талашырга тотындылар. Күп алыша торгач, убырлы карт ике этне буып үтерде.

Бу егет өйгә кергән вакытта аны-моны күрмәгән иде. Бу өйдә бер адәми зат булып, аның маңгаенда бер бик зур мөгезе бар иде. Этләрнең үлгәнен күреп, бу кеше сәке өстеннән төшеп, убырлы карт белән алыша

[1] *Төнә* — кичә.

башладылар. Егет бу вакыт Аллададан ярдәм сорап ятадыр иде, картны җир убып, ул җир астына төшеп югалды.

Убырны җир упканнан соң, бу кеше:

— Йә инде, егет, убырыңны җир упты, хәзер чык,— дип кычкырды.

Егет, һаман убыр кычкыра торгандыр дип, куркып чыкмый ятты. Берничә кат кычкырганнан соң, чыгып караса, ни күзе белән күрсен: өйгә чак сыешып йөри торган бер кеше тора, маңгаеның нәкъ уртасында гына бер мөгезе бар.

Аскәр, бу кеше белән исәнләшкәч, бу кеше аңа:

— Йә инде, аскәр, син хәзер убырыңнан котылдың, ләкин мине генә харап иттең, чөнки убыр үтергән ике этем, минем телемне белеп, миңа ни кирәк булса, шуны китерәләр иде. Әмма мин үзем бу өйдән чыга алмыйм, чөнки минем мөгезем тәрәзәдән дә, ишектән дә сыймыйдыр. Инде мин хәзер ничек торыйм? — диде.

Аскәр үзенең хәлен, бер тиен дә акчасы булмаганлыгын сөйләп бирде, картны кая алып барасын сорады.

— Инде, аскәр, син барып атларың җик тә юл белән миңа таба кил, юлда бер зур чокыр күрерсең, шунда картны төртеп төшер дә, үзең атларың белән монда кил, мин сиңа бер йомыш кушармын, син шул йомышымны үтәсәң, мин сиңа мең тәңкә акча бирермен,— диде.

Егет: «Әүвәлге сәфәрем дә уңып тора, ике көннән котылам, Аллага тапшырам»,— дип, урманнан арбасына кайтты. Атларын эзләп табып, арбага җикте. Карт һаман үз урынында бәйләгән көенә ятадыр иде. Егет урманга килеп, картны арбадан төртеп төшереп, үзе мөгезле адәмнең өе янына килеп, атларын туарып, үзе өйнең эченә килеп керде.

Мөгезле адәм үзенең хәлен егеткә сөйли башлады:

— Әй, егет, мин үзем фәлән шәһәрдәге бер карчыкның улы, атам мин яшь вакытта үлгән, әмма анам бер сихерче карчык иде. Мин үзем яшь вакытымда бик шаян идем, балалар белән уйнап йөргән чакта анамның бер йомыркасын урлаган идем. Анам шул эшкә ачуланып, мине сихерләп яныма ике эт куеп: «Гомерең шунда адәм төсе күрмәсен»,— дип, шушы урманга китереп ташлады. Бу өйгә килеп бераз торгач, мөгезем һаман үсте дә үсте. Шул көннән бирле ишектән чыга алмыйм, ике эт баласы янымда үсеп, минем телемне аңлап, миңа нәрсә кирәкне белеп, ит кирәк булса ит, су кирәк булса су китерәләр иде. Инде алардан да коры калдым. Инде сиңа үтенечем шулдыр: безнең шәһәргә барып анам

карчыкны табып, миңа аңардан ризалык алып кил; әгәр дә шуны эшли алсаң, мин дә сиңа үземнең әйткән тәңкәләремне бирермен,— диде.

Аскәр, шул ук вакыт бу адәмне кызганып, өч атын җигеп, өч атын урманда калдырып, егетнең шәһәрен эзләргә чыгып китте. Ничә айлар, ничә көннәр сорашып йөри торгач, күп мәшәкать белән боларның шәһәрләрен табып, сорашып, туп-туры бу егетнең анасына килеп, капканы ачып керде, атларын туарып, үзе ашап-эчеп базарга чыгып китте. Аннан карчыкка берничә нәрсәләр алып кайтып, аңарга бүләк иттереп бирде һәм карчыктан хәлен сораша башлады:

— Әй, әби, мин сезгә моннан әүвәле дә килгәнем бар иде, ул вакыт синең бер үсеп килә торган балаң бар иде, хәзердә ул кая, монда күренмидер? — диде.

Карчык егеткә:

— Юкны сөйләмә, минем һичбер балам булганы юк,— диде.

Шуннан соң базардан алып кергән бүләкләрен карчыкка биреп, яңадан чынлабрак сораша башлады. Карчык та, күңеле йомшап:

— Дөрес әйтәсең, минем бер балам бар иде, тәүфыйксызга чыкты да, соңра мин аны бер калын урманның эченә илтеп бер өйгә куйдым, инде ул шунда маңгаена бер мөгез үсеп, дөнья рәхәте күрми, адәмиләр белән сөйләшми гомер итәдер,— диде.

Егет, аңа каршы:

— Әй, әби, инде шул көннән бирле үз бәласе үзенә җитәр, син аңардан разый булсаң булмасмы? Әгәр дә син разый булсаң, мин сиңа йөз тәңкә акча бирер идем.

Карчык:

— Мин аны эшләдем, инде мин аңардан разый булсам, ул вакыт ул кайтып, үзем һәлак булачакмын,— диде.

Аскәр:

— Әй, әби, һичбер нәрсә булмас, син дә исән булырсың, ул да кайтып, сиңа хезмәт итәр,— дигәч, әби өч мәртәбә ихлас белән: «Разый булдым»,— дип әйткән иде, шул сәгать авызыннан ак күбекләр килеп, җан бирде.

Әбинең һәлак булганын күргәч, аскәр, әбине бер чүпрәккә төреп сәке астына тыгып, үзе биргән нәрсәләрен кире алып, атларын җигеп, яңадан урманга мөгезле егет янына килә.

Егетнең анасы разый булган минуттан башлап, маңгаеннан мөгезе төшеп, өйдән чыгып йөри башлап, атларын эзләп табып, аларны аша-

тып-эчертеп йөридер иде. Аскәрне күрүгә, аны каршы алып, өйгә алып кереп, әйткән мең тәңкәсен биреп, икесе дә атларны җигеп, бергә утырып урманнан чыгып киттеләр. Күп заманнар бергә утырып китә торгач, мөгезле егет үз шәһәренә җиткәч, шунда төшеп калып, аскәр дә үз шәһәренә кайтып китте.

Мөгезле егет, үз өенә кайтып, агай-энесе белән күрешеп, сәке астында үлеп ята торган анасын кадерләп күмеп, башкалар шикелле рәхәтләнеп дөнья көтә башлады.

Аскәр дә ничә көннәр үткәчтен үз шәһәренә кайтып, карчыктан тиясе акчаны алып, үзенең өенә кайтып, ата-анасы белән күрешеп, бик матур кәләш алып, бер көймәле арба, алты ат, алты йөз тәңкә белән әле дә булса баеп ятадыр, ди.

10. Кол малай

Әүвәл заманда бар иде шундый кешеләр: кол сатып, кол алалар иде.

Бер шәһәрдә бер фәкыйрь генә кеше бар иде, аның — бер малае. Ул малаен ун яшенә кадәр мәдрәсәдә укытты. Ярлылыгы бик зур булганлыктан, артык укыта алмады. Малае мәдрәсәдән кайткач та, өйдә бер нәрсә дә эшли алмаганлыктан, атасына:

— Әти, фәкыйрьлегебез зур, инде мине укыта алмыйсың, эшләргә эшебез дә юк, һич булмаса мине кол итеп сат,— диде.

Атасы, бер генә улы булганлыктан, аны сатасы килмәде. Өч көн сораганнан соң, бер көнне ашадылар-эчтеләр дә ата илә улы базарга чыгып киттеләр. Базарга барып бастылар. Шул вакытта биек буйлы, зур сакаллы, калын корсаклы бер бай:

— Кем кол сата? — дип кычкырып йөридер иде.

Бу кеше:

— Мин улымны сатам,— диде.

— Күпме сорыйсың? — дип, сәүдәләргә тотынды.

Бу кешенең улы үзенең үткерлеге белән йөз тәңкә сорарга кушты. Бу кеше йөз тәңкә сорады. Бай да риза булып, малайны алып китте. Өенә алып кайткач, бай малайны ашатты-эчерде дә, йокларга яттылар.

Иртә тордылар. Бай малайны үзе белән бергә арбага утыртып алып китте, арба артына бер сугым бәйләде. Шәһәрдән кырык чакрым ераклыгында бер җәүһәр тавы бар иде. Болар шул тауның төбенә барып,

сугымны суйдылар, эчен арчыдылар да, бай малайны туш эченә кертте дә корсагын җөйләп куйды.

Соңыннан, малайга:

— Менә сине туш эчендә кошлар тау башына менгерерләр. Син, анда менгәч, туш эченнән чыгарсың да тау башында булган җәүһәр ташларын миңа ыргытырсың,— диде.

Малай разый булды. Бай үзе, атын-арбасын алып, бер туйра төбенә барып ышыкланды. Бай читкә китүгә, тау башыннан кошлар төшеп, тушны тау башына алып менеп киттеләр. Тау башына менеп җиткәч, тушны куеп ашарга тотындылар. Кабыргасындагы итләре бетеп, малайга яктылык төште. Шуннан соң малай, кесәсендәге пәкесен алып, тушны ярып чыкты да, кошлар аңардан куркып, ашап бетерә алмыйча очып киттеләр. Шуннан соң малай ташлар ыргытырга тотынды. Бер талай[1] заман ыргытканнан соң:

— Абзый, җитәрме? — диде.

Бай:

— Бик яхшы, җитәр,— диде.

Малай:

— Инде мин моннан ничек төшим? — диде.

Бай:

— Теләсәң ничек төш, инде син миңа кирәкмисең,— диде.

Бай ташларны төяп өенә кайтып китте. Малай тау башында җылап утырып калды.

Күп җылап утырганнан соң, малай: «Болай утырып, эш булмас»,— дип, тау башыннан тәгәрәргә тотынды. Өч көн, өч төн каталаганнан[2] соң бер сукмакка килде. Ул сукмак белән барып, бер зур урманга керде. Урманда бераз барган иде, бер бик зур сарайга килеп очрады. Сарай төбенә килеп җитте, бер кеше күренмәде. Малай кычкырып сәлам бирде.

Аның сәламен эчтән берәү алды да:

— Адәмимесең, пәримесең? — диде.— Монда кер! — Моны бер карт адәм кычкырды.

Малай, барып, сарайга бабай янына керде.

Бабай, керүгә:

— Йә, егет, нишләп йөрисең? — диде.

---

[1] *Бер талай* — берникадәр.

[2] *Каталау* — тәгәрәү.

Егет:

— Колсызга кол, улсызга ул булам,— диде.

Бабай:

— Кол булганчы, улым бул, минем улым-кызым юк, икәү торырбыз,— диде.

Болар берничә вакытлар торганнан соң, бабай егетне бик ярата. Көннәрнең берендә, бабай:

— Мин кырык көнлек кунакка китәм, бар малым синең кулыңда кала, менә сиңа унике сарайның ачкычы, унберен ачарга рөхсәт бар, әмма берсен ачарга рөхсәт юк, аны ачма, ачсаң, башыңа бәла килер,— диде.

Бабай китте. Берничә көн үткәннән соң егетнең эче пошып, сарайларны ачып карый башлады. Бердән бер көнне, бик эче пошканлыктан, уникенче сарайны да ачкан иде: сарай эчендә зур күл. Ул күлгә ике күгәрчен төшеп, кызлар кыяфәтенә кереп, коенырга тотындылар. Егет боларны күреп, бу кызларга гашыйк булды. Кызлар юынып чыктылар да күгәрчен булып очып киттеләр. Егет аларны күз алдына китереп, көне-төне уйлый башлады.

Кырык көн булганнан соң, бабай кунактан кайтып килде, малайдан исәнлек-саулык сорашты; малайның кәефе яхшы түгел иде. Бабай моны күреп, малайдан:

— Ник эчең поша? — дип сорады.

Малай:

— Әй, бабай, харап булдым, сүзеңне тыңламадым, уникенче сарайны ачтым да анда ике кыз күрдем һәм аларга гашыйк булдым. Инде, бабай, син теләсәң ни эшлә, мине аларга кавыштыр? — диде.

Бабай:

— Әй, егет, мин монда җитмеш елдан бирле шуларны саклап торамын, алай да тота алганым юк,— диде.

Егет:

— Бабай, теләсәң ни эшлә, синең хәлеңнән килә, мине кавыштыр? — диде.

Шуннан соң бабай егеткә бер кыз киеме бирде, һәм:

— Син сарайны барып ачарсың, шул вакытта анда күгәрченнәр килеп төшәр. Син шул берсенең киемен ал да аңарга бирмә,— диде.

Егет барып сарайны ачты, күгәрченнәр килеп төштеләр. Егет үзе гашыйк булган күгәрченнең киемнәрен алды. Күгәрченнәр килеп чыкты-

лар, берсе киенеп очып китте, әмма киемсезе никадәр ялынса да, егет аңарга бирмәде. Кыз, никадәр ялынып та бирмәгәч:

— Ярый инде алай булса, кыз киеме бир дә, чыгам — диде.

Егет кызны киендереп, бабай янына кулыннан тотып китерде дә:

— Бабай, тоттым, инде безгә никах укып бир,— диде.

Бабай никах укып бирде дә, кыз белән егет кавышып тора башладылар.

Берничә еллар торганнан соң, егет аталарын исенә төшереп сагына һәм бабайдан кайтып китәргә рөхсәт сорады.

Бабай:

— Бик яхшы, кайтып китәрсез,— диде.

Болар ирле-хатынлы хәзерләнә башладылар. Болар хәзер булып җиткәннән соң, кошларның патшасы булган бабай кошларын җыйды да:

— Менә сезгә әманәт, шул егет белән кызны өйләренә илтеп килегез,— диде. Һәм, егеткә: — Син күгәрчен тунын кулыңнан ычкындырма, әгәр дә ычкындырсаң, ул вакыт башыңа бәла килер; кайчан ул ир бала тудырса, шул вакытта бирерсең,— диде.

Бабай егет белән кызны ике кошка утыртып озатты. Кошлар, телгә килеп:

— Күзегезне йомыгыз,— диделәр.

Болар күзләрен йомдылар. Егет уң канатына, кыз сул канатына тотындылар. Озак та очмадылар, үзләренең шәһәрләренә кайтып җиттеләр. Өйләренә кайтып кергәч тә ата-аналары бик шатландылар.

Берничә көн торганнан соң, егет үзенең өен яңадан корырга тотынды. Өен эшләтеп бетергәчтен, бер сандык ясатып, кызның күгәрчен тунын шул сандыкка бикләп куйды. Болар бик яхшы гына тора башладылар.

Кыз, бер көнне:

— Инде син үз рәхәтеңне таптың, мин дә бер генә чыгып, йортка сәер[1] идем,— дип, күгәрчен тунын сорый башлады.

Күп сорый торгач, егет чыдый алмады, бердән бер көнне тунын бирде. Кыз тунны киеп ишектән чыгып китте дә үзенең өй башына кунып гөрләргә башлады. Егет аны карап торадыр иде, шул вакытта күгәрчен:

[1] *Сәер* — читтән карау.

— Инде мин синең белән тордым, моннан соң мин сине күрмим, син мине күрмә. Мин җәүһәр патшасының кызы буламын. Инде син анда барып җитә алмассың, кырык еллык юл,— диде дә очып китте.

Егет җылап карап калды.

Берничә көннәр үтте, егет һаман кызны онытмады. Егет, тагы атасына:

— Мине кол итеп сат,— диде.

Атасы:

— Инде мин сине ни эшләп сатыйм, хәзер дәүләтебез бар,— диде.

Күп сорый торгач, атасы моны чыгарып базарга куйды, тагы моны алган бай килеп, кол сорады. Малай аны таныды, әмма бай танымады. Бабай, сатам дигәч, бай:

— Күпме сорыйсың? — диде.

Бабай:

— Ике йөз тәңкә,— диде.

Бай разый булды. Егет тагын бер шарт куйды:

— Бер кич кызың янында йоклатырсың,— диде.

Бай аңарга да разый булды.

Егетне өенә алып кайтты, ашадылар-эчтеләр дә, егет кыз янына кунарга керде. Төн буе уйнап-көлеп үткәрделәр.

Бай, иртә торгач, егетне, янә бер сугым алып, җәүһәр тавы янына алып китте, янә шул рәвешчә атны суеп, егетне тектереп, калдырып китте. Кошлар килеп күтәреп алып киттеләр дә җәүһәр тавы башында яңадан ашарга тотындылар. Кабырга арасыннан яктылык күренгәннән соң, пәке белән ярып, егет килеп чыкты да, кошлар куркып очып киттеләр.

Егет, байга карап:

— Инде, агай, син миннән җәүһәр көтмә, теге вакытта син мине алдадың, инде мин сине алдадым,— диде дә үз юлына китте.

Егет янә тау башыннан тәгәрәп китеп, өч көн, өч төн тәгәрәгәннән соң, янә бер сукмакка туры килде. Шул сукмак белән китеп, янә сарайга килеп керде дә бабайга сәлам бирде. Бабай белән күрешеп җылаштылар, соңра егет бабайга ни булганын баштанаяк сөйләп бирде. Бабай:

— Мин сиңа бирмәскә әйттем бит, ник бирдең, әле ни эшлисең инде? — диде. Шуннан соң бабай: — Инде хәерле булсын, миңа бер ел хезмәт ит тә, аннан соң ни дә булса эшләрбез,— диде.

Егет хезмәт итәргә башлады, вакыт бик тиз үтеп китте. Ел үткәннән соң, егет, бабайга:

— Йә инде, бабай, елыбыз тулды, рәхим ит,— диде.

Шуннан соң бабай «Рәхим бездән булсын», дип, бөтен таудагы кошларны бер төркемгә җыйды да, кошларга:

— Минем агайның фәлән җирдә булган сараен беләсезме? — диде.

Кошлар барысы да:

— Белмибез,— диделәр.

Бабай:

— Соң сез барыгыз да мондамы? — диде.

Кошлар:

— Барыбыз да монда юк, Сәмруг кош калды,— диделәр.

Бабай:

— Аны да йәшеп[1] китерегез,— диде.

Кошлардан берсе аны йәшергә китте. Озак үтмәде, Сәмруг кош килеп җитте.

Бабай, аңардан:

— Син минем агайның йортын беләсеңме? — диде.

Сәмруг кош:

— Беләм,— диде.

Бабай:

— Бик яхшы, менә бу егетне анда илтеп куярсың,— диде.

Шуннан соң бабай, егеткә бер кара йомгак биреп:

— Бу йомгак сиңа кирәк булыр,— диде.

Егет, бабайга күп рәхмәтләр укып, Сәмруг кош өстенә утырып, йорттан чыгып китте.

Озак та үтмәделәр, сарайга барып төштеләр. Егет, барып төшкәчтән бабайга барып сәлам бирде. Бабай:

— Син адәмме, пәриме? — Ни эшләп йөрисең? — диде.

Егет:

— Улсызга ул, колсызга кол булам,— диде.

Бабай:

— Бик яхшы, бер ел хезмәт ит,— диде, һәм егет бабай биргән хатны кесәсеннән чыгарып бабайга тоттырды.

Бабай хатны укыды. Ул хатта: «Шул егетне кыз янына тапшыр»,— дип язылган иде. Бабай:

— Әй, улым, инде мин бу урында сиксән ел торам, күрү түгел,

---

[1] *Йәшү* — дәшү.

ишеткәнем дә юк,— диде.— Шулай да булса бер ел хезмәт ит әле, аннан соң, бәлки, җае табылыр,— диде.

Егет бер ел хезмәт итте, соңра:

— Инде елым тулды,— диде.

Бабай:

— Бик яхшы, рәхмәт, яхшы хезмәт иттең,— диде.

Соңра бабай, үз кул астындагы кошларны җыеп:

— Минем агайның сараен беләсезме? — диде.

— Безнең арабыздан белгән кеше юк, бары бер кош монда юк, бәлки, ул белә торгандыр,— диделәр.

Бабай аны да алып килергә кушты. Кошлар алып килделәр. Ул кош:

— Беләм,— диде.

Бабай:

— Белсәң, менә бу егетне агайның сараена илтеп куй,— диде.

Кош егетне илтеп куярга булды. Бабай егет белән күрешеп, аңарга бер сары йомгак белән хат бирде. Соңра егет, сәламләшеп, кошка утырып китте.

Берничә вакыт барганнан соң, кош бу егетне бабайның сараена илтеп төшерде. Егет сарайга кереп сәлам бирде. Бабай, сәламне алды да:

— Адәмме син, пәриме? Монда кер,— диде.

Егет кереп күреште.

Бабай:

— Әй, егет, нишләп йөрисең? — диде.

Егет:

— Улсызга ул, колсызга кол булам,— диде.

Бабай:

— Бик яхшы,— дип, егетне ашарга утыртты.

Егет ашарга утырганнан соң, куеныннан хатны чыгарып бирде. Бабай укып карады да:

— Әй, улым, мин монда инде йөз ел торам, андый кызны күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде. Шулай булса да бер ел хезмәт ит, бәлки юлын табарбыз,— диде.

Егет разый булып, хезмәт итәргә башлады.

Бер ел хезмәт иткәннән соң, егет:

— Бабай, инде хезмәтем тулды,— диде.

Бабай:

— Бик яхшы, улым, рәхмәт, яхшы хезмәт иттең,— диде.

Шуннан соң бабай үзенең кул астындагы кошларны җыеп:
— Җәүһәр патшаның шәһәрен беләсезме? — диде.
Кошлар:
— Без, мондагылар, белмибез, бер кош юк, бәлки ул, козгын, белә торгандыр,— диделәр.
Бабай аны чакыртып китертте, һәм аңарга да:
— Җәүһәр патшаның шәһәрен беләсеңме? — диде.
Ул козгын өч йөз ел яшәгән иде:
— Беләм,— диде.
Бабай:
— Шул егетне җәүһәр патшасына илтеп куй,— диде.
Кош:
— Илтергә мөмкин түгел, аның өчен ул алты еллык юл, шулай булса да кырык көндә җиткерер идем, тик юлыннан үтәр хәл юк. Аның юлы өстендә урманлык, ут таулары, сулар бик күп, шунлыктан барып булмас,— диде. Егеткә таба карап:
— Синең ни нәрсәләрең бар? — диде.
Егет:
— Миндә ике йомгактан башка бернәрсә дә юк,— диде.
Козгын:
— Алай булса, яхшы, инде бабайдан тагы бер кызыл йомгак сора,— диде.
Бабай егеткә кызыл йомгакны бирде дә, козгынга:
— Исән-сау илтеп җиткерә күр,— диде.
Шуннан соң егет козгын өстенә утырып, бабай белән исәнләшеп, юлга чыгып китте.
Ун көн барганнан соң бер бик кара урманга барып керделәр. Шул кара урман белән көн ярым барганнан соң, козгын:
— Канатларым бик талды, кара йомгакны ыргыт,— диде.
Егет шул ук минут кара йомгакны ыргытып җибәргән иде, козгын яңадан һавага күтәрелеп китте. Янә ун көн барганнар иде, бер диңгезгә барып керделәр. Диңгез белән көн ярым барганнан соң, козгын янә егеткә:
— Канатларым бик талды, су тарта, син сары йомгакны ыргыт,— диде.
Егет ыргыткан иде, козгын янә күтәрелеп китте. Янә ун көн барганнар иде, бер ут тавына барып керделәр. Бер көн ярым барганнан соң, козгын янә:

— Канатларым бик талды, кызыл йомгакны ыргыт,— диде.

Егет ыргыткан иде, козгын янә күтәрелеп китеп, янә ун көн бардылар. Соңра тау-таш арасына барып керделәр, аннан шәһәр дә күренәдер иде.

Шул вакыт козгын:

— Инде, егет, миннән сау бул, үзең белгәнне эшлә,— диде дә, егетне төшереп, үзе очып китте.

Егет берүзе генә шәһәргә таба атлап китте.

Бервакыт җәүһәр патшаның кызы бу егетнең килгәнен сизде дә кәнизәкләрен бу егетне эзләргә җибәрде. Кәнизәкләр таралып киттеләр, икесе егеткә тугры килеп:

— Син адәми затмы? — диделәр.

Егет:

— Адәми затмын,— диде.

Кәнизәкләр:

— Адәм булсаң, безнең белән бар,— диделәр.

Егет болар белән бергә китте. Барып шәһәргә керделәр, сарайга барып җиттеләр. Кыз үзенең бүлмәсеннән каршы чыкты да үзе белән бергә алып керде, күрештеләр, җылаштылар, хәл-әхвәлне сораштылар.

Кыз:

— Инде, егет, мин синең монда килүеңне көтмәгән идем, ничек килеп чыктың? — диде.

Егет үзенең башыннан үткәнен, аермачык иттереп, барын да сөйләп бирде.

Кыз:

— Инде алай булгач, бу кадәр мәшәкатьләр күргән өчен мин синеке, син минеке бул, гомеребезне шатлык белән үткәрик,— диде.

Шуннан соң кыз атасына:

— Әти, миңа адәми заттан гашыйк булып бер егет килде, мин дә аны яратам, никах укытыйк,— диде.

Ата-анасы бу эшкә разый булып, никах укыттылар, туй ясадылар. Шуннан соң егет белән кыз шатлык белән көн күрергә башладылар.

Берничә көннәр үткәч, егет бераз күңелсезләнә башлады.

Кыз:

— Ни булды, күңелсез йөрисең, нәрсә уйлыйсың? — диде.

Егет:

— Мин үзем монда рәхәттә булган белән, минем атам-анам бар, алар

исемә төшәдер, аларны күрәсем киләдер, атаңнан барырга сорыйк,— диде.

Кыз да разый булып, юлга хәзерләнә башладылар. Бер көнне күп мал, җәүһәрләр биреп, егет белән кызны кунаклый озаттылар. Болар, Аллага тапшырып, юлга чыгып киттеләр. Корыдан барганда ат белән, судан барганда утлы көймә белән кайтып китәләр.

Берничә вакытлар үткәннән соң, үзләренең шәһәрләренә кайтып керделәр. Ата-анасы белән күрешеп җылаштылар. Бу вакытка кадәр һич хәбәрсез алты ел үткән иде.

Егет шул көннән башлап, алып кайткан маллары белән бик яхшы табыш итәргә башлады. Көнкүрешләре яхшырып, ирле-хатынлы ата-аналары янында калып, шатлык белән гомер сөрделәр.

11. Ак бүре

Борынгы заманда бар иде бер патша. Аның дүрт улы бар иде. Бу патшаның хатыны беренче дәрәҗәдә чибәр иде. Бер заманда патша, хатыны белән икәү, яхшы атлар, яхшы арбалар җигеп, ялан-япан сахрага чыктылар. Сахрада яткан вакытларында, төннең бер мизгелләрендә, боларның чатырларын бик каты җил исеп күтәреп ташлады. Шул ук вакыт һавадан бер дию патшасы пәйда булып, моның куенындагы хатынын күтәреп алып китте. Шул сәгать патша уянып, куенындагы хатынының юклыгын белеп, тиз генә кучерын уятып, икәүләп эзләргә киттеләр. Болар шул төнне эзләп, хатынны таба алмыйча, таң аткач үзләренең шәһәренә кайттылар. Патша ат җиткән җиргә ат җибәреп, хат җиткән җиргә хат җибәреп, төрле якка эзләүчеләр җибәреп, хатынны эзләргә тотынды.

Хатынның югалганына тәмам бер ел булган вакытта, патшаның өлкән улы укуын бетереп атасы янына кайтты, һәм атасына әйтте:

— Инде, әти, мин укуның чигенә чыктым. Син инде миңа әнине эзләргә бер елга рөхсәт бир? — дип.

Атасы моңардан сорады:

— Рөхсәт иттем, сиңа ниләр бирим? — дип.

Атасыннан үзенә юлдашка бер йөз солдат алып, бер елга җитәрлек акча, азык-төлек алып, анасын эзләргә чыгып китте. Киткәннән киттеләр, ай китеп, ел китеп, әйләнгән җирдә әйләнмә үсеп, тулганган җирдә кызыл

тубылгылар үсеп, ташка тары үскәндә, бозга бодай үскәндә, аны шатыр-шотыр урып ятканда, болар барып җиттеләр бик куе бер урманның эченә. Шул урманның эче белән, беләк буе трубканың куышы белән барып яткан вакытта, килеп җиттеләр бер суның буена — сахралык җиргә.

Шунда патшаның улы уйлады: «Без шунда берәр көн ял итеп, атларыбызны ашатып китәрбез»,— диде. Иптәшләре, атларыннан төшеп, куышларын корып, шул ук сәгать су эзләргә киттеләр. Суны алып килеп, ашларын пешереп, ашап утырган чакта, патша улының чатырына бер Ак бүре килеп сәлам бирде, һәм әйтте:

— Әй, ахмаклар, кем рөхсәте белән минем урманыма кереп, үләннәрне таптап йөрисез? Рөхсәтем юк, хәзер чыгып китегез,— диде.

Патша улы:

— Син үзең кайдан килдең, шунда кит. Менә минем йөз солдатым бар, хәзер аттырырмын да үтерермен,— диде.

Бу сүзләргә Ак бүренең ачуы килеп, һаман да боларга моннан чыгарга кушты һәм куды. Куган саен чыкмагачтын, Ак бүренең ачуы килеп, боларга карап бер дога укып өргән иде, бар да тораташ булып каттылар.

Инде без килик патшаның үзенә. Биш айдан бирле улыннан хәбәр көтте, алты ай көтте — улыннан һичбер хәбәр-хәтер юк. Бер елдан соң укый торган ике уртанчы улы укудан кайттылар. Исәнлек-саулык сорашканнан соң, болар да аталарыннан рөхсәт сорадылар:

— Без дә әнине эзләргә чыгыйк,— диделәр.

Патша, боларга таба карап:

— Олы абзагызның киткәненә инде бер ел булды, һичбер хәбәр-хәтере юк. Инде мин, сездән дә аерылып, берүзем нишләрмен? — диде.

Болар аталарының ай-ваена карамыйча, һәр көнне рөхсәт сорыйлар иде.

Бердән бер көнне боларның аталары, бик күп сорый торгачтын, боларга да бер елга рөхсәт бирде.

— Ләкин бер елдан артык йөрергә рөхсәт юк,— диде.

Һәм болар да, аталарыннан йөзәр атлы солдат алып, бер елга акча, азык-төлекләр алып, агай-эне, аталары белән хушлашып, ике йөз дә ике кеше булып юлга чыгып киттеләр. Шул чыгып китүдән ич киттеләр, вич киттеләр, иртә киттеләр, кич киттеләр, арт итәкләре җирдән китте, түгерекләре билдән китте, ат өстенә ятып, агач мылтыклар атып, муеннары аладай булган чакта, битләре турадай булган чакта барып җиттеләр багы урманның бер як читенә.

Боларга да бик яхшы су, үләнлек очрап, ял итәргә туктадылар. Һәм атларыннан төшеп, чатырларын корып, су эзләп алып килеп, аш пешереп ашарга утырган чакта, баягы Ак бүре килеп җитеп, баягыча:

— Кем рөхсәте белән килеп, бу чаклы солдат, атлар белән урмандагы үләннәрне таптап килеп кердегез? — диде.— Һич рөхсәтем юк,— дип боларны да куа башлады.

Бу патшаның улы ике йөз атлы гаскәренә таянып, бүредән алайрак ачуланып:

— Син үзең кайдан килдең, шунда кит,— диде.

Боларга яхшылык белән берничә әйткәннән соң да тыңламагач, Ак бүре баягыча бер әфсен укып өргән иде, болар да тораташ булып каттылар.

Инде без тагын патшаның үзенә килик. Иң өлкән улына ике ел, уртанчыларына бер ел булган чакта төпчек улы мәдрәсәдән укудан кайтты. Кайтып керүгә атасыннан исәнлек-саулык һәм абыйларын сорашып, хәбәр-хәтердән соң патша, моңарга:

— Менә иң өлкән абыеңның китүенә ике ел, уртанчыларына бер ел булды, һичбер хәбәр-хәтерләре юк,— диде.

Моны ишеткәч, төпчек улы:

— Инде алар кайтмады, берәр хәл булгандыр. Миңа да рөхсәт бир дә, мин дә китим,— диде.

Патша:

— Мин синнән дә аерылгач, кемгә карап торырмын, югалганнар югала торсын, әмма сиңа һич рөхсәтем юк,— диде.

Бу атасына көн-төн ирек бирмичә сорый торгач, атасы моңа да рөхсәт бирсә дә бирде, бирмәсә дә бирде. Атасы моңа рөхсәт бирмәскә теләгәч, ул:

— Әти, мин синнән гаскәр сорап, азык сорап борчымыйм бит, миңа бары бер елга, кая барсам да җитәрлек итеп, акча гына бир,— диде.

Моңа каршы атасы җитәрлек акча бирде.

Бер бик яхшы атка яхшы ияр салып, Аллага тапшырып, юлга чыгып китте. Шул көннән соң, күп айлар, күп көннәр, сәгатьләр, күп минутлар киткәннән соң, әлеге абзалары яткан урманның читенә бу да ялгызы барып җитте. Бу да урманны үтәргә теләп бара ятканда, юл буенда бер бик һәйбәт аланга очрады. Һәм: «Бик күп көннәрдән бирле мин атымны ял иттергәнем юк, тукта, монда бераз туктап ашатыйм»,— дип, атыннан төшеп, бер зур тирәкнең ботагына атның башын югары күтәреп бәйләп куйды. Муенындагы мылтыгын корып, үзенә ашарга берәр кош атып

килә алмаммы икән дип, урманның эченә кереп китте. Бер ун адым гына киткән иде, баягы Ак бүре килеп очрады һәм әйтте:

— И, егет, син монда нишләп йөрисең, кая барасың, кайдан килдең? Монда минем рөхсәтемнән башка үләннәрне таптавың җитмәгән, тагы урмандагы кошларны атарга барасың,— диде.

Егет бүрегә:

— Әнә ул күренә торган кошны атып алып, үземә жаркой пешереп ашарга уйлаган идем. Бик арыдым, талдым. Бик ерак җирдән килдем. Инде алай булгач, синең рөхсәтеңнән башка мин монда бер эш тә эшләмим, кошыңны да атмыйм, атымны да ашатмыйм. Әнә күрәсең, атымның башын югары күтәреп бәйләп куйдым. Чыгам да китәм,— диде.

Бүре аңа каршы:

— Инде, егет, мин сине күрәм, үзең күркәм, сүзең тәмле, һичбер каршы килгән җирең юк. Алай булгач, мин сиңа бөтен урманымда йөрергә, атыңны ашатырга, кошларымны атарга рөхсәт иттем. Теләгәнеңне эшлә. Тик менә бу күренгән кошны атма син. Әнә теге зур тирәкнең артында бер зур кош бар, тирәкнең башында утыра. Бар да шуны күкрәгенә төзәп ат. Бер атуда егылыр да төшәр. Аннан соң алып кайт та тазартып, пешер. Аш ашарга мин дә килермен,— дип әйтте дә үз юлына китте.

Егет, бүренең сүзен тыңлап, тирәккә якын барып, кошны күреп, күкрәгенә төзәп мылтыгының чакмасын сугып җибәргән иде, кошның нәкъ күкрәгенә барып тиде дә әйләнеп төште. Соңра егет, аты янына алып кайтып, арчып куйды. Үзенең чатырын корып, аш хәзерләп, атын үләнгә җибәреп, әлеге Ак бүрене көтеп калды. Моның чатыры янына искәрмәстән генә бер яктан бер яшь кенә егет килеп чыкты да моңа сәлам бирде. Егет тә, якты чырай белән каршы алып, хәзер булган ашны куеп, чатырга моны да ашарга чакырды. Кунак егет тә, сүзне тыңлап, чатырга кереп утырып, ашый башладылар. Карыннары бик ач булганга күрә, хәзерләнгән ашны тәмам ашап бетерә яздылар. Шул чакта келт итеп патша улының исенә Ак бүре килеп төште, һәм: «Аңа куярга инде ашым азайды, бетеп үк бара, килә калса, ни куярмын»,— дип йөрәгенә курку төште.

Кунак егет, моның уйлаганын күреп:

— И, дустым, яхшы гына, күңелле генә утырган чакта әллә ни күңелсезләнеп киттең. Нәрсә уйлыйсың, ник эчең поша? — дип сорагач, егет кош атуын, Ак бүренең очраганын, аның белән бергә ашарга вәгъдә куюларын — барын да аермачык иттереп баштанаяк сөйләп:

— Инде хәзер шул Ак бүре килсә, ни ашатырмын икән дип уйлый башладым,— диде.

Кунак егет аңа каршы:

— Әй, егет, син аның өчен бер дә кайгырма. Ул бүре булып күренгән нәрсә мин идем. Минем җитмеш төрле һөнәрем бар, җитмеш төрле сурәткә керә алам,— диде.

Шуннан соң егетнең кайгысы бетеп, башка нәрсәләр сөйләргә тотынып, үзенең каян, ни өчен юлга чыгуын, анасының югалуын, агаларының аны эзләргә китеп тә юлда югалып калуларын — барын да баштанаяк сөйләп бирде.

Аңа каршы, Ак бүре:

— Йә, егет, син ул агаларыңны хәзергә көндә исән-сау дип уйлыйсыңмы? — диде.

Егет аңа каршы:

— Мин, әлбәттә, аларны исәннәр дип уйлыйм. Чөнки алар бер бозык юлга, яман уй белән киткән кешеләр түгел, өч агам өчесе дә йөзәр атлы солдат белән һәм акча, азык белән чыгып киткәннәр,— диде.

Ак бүре моңа каршы:

— Соң син ул агаларыңны хәзер күрсәң таныр идеңме? Әйдә әле монда, мин сине бер җиргә алып барыйм,— дип, иң олы агасының тораташ булып каткан җиренә алып китте. Алып барып, өстенә күклеяшелле мүк үсеп беткән таш янына китереп:

— Менә бу нәрсә, син таныйсыңмы? — дип күрсәтте.— Алай булгач, син белмәсәң, мин әйтим: менә бусы синең олкән агаң, әнә ул янында яткан ташлар аның батыр солдатлары. Алар минем сүземә каршы килделәр дә, мин аларны менә бу сурәткә керттем,— диде.

Егет, бу ташларның агасы һәм гаскәрләре икәнен белгәч, күңеле нечкәреп елап җибәреп, Ак бүредән аларны яңадан әүвәлге кыяфәтләренә кайтаруын сорап, ялына башлады.

Ак бүре егеткә:

— Ярый мин синең сүзеңне тыңлап, аларны әүвәлге кыяфәтләренә кайтарыйм. Мәгәр синең бу агаң һәм гаскәрләре синең эшкә вә сиңа юлдаш булырга ярый торган кешеләр түгел. Терелгәч тә син аларны тиз генә шәһәрегезгә кайтарып җибәр,— диде.

Шуннан соң Ак бүре, тискәре якка карап, озын бер дога укып, ташларның өсләренә өргән иде, бар да сикереп торып, үзләренең иске

кыяфәтләренә кереп, кайсы мылтыгын тота, кайсы атын иярли, кайсы тәмәке төрергә башладылар. Боларны күреп, патша улы:

— И, егетләр, тизрәк булыгыз. Без бик озак йоклаган икәнбез. Тизрәк үз юлыбызга китик,— дип кычкырган иде, бу ике егет, сәлам биреп, бик һәйбәтләп күрештеләр.

Патшаның өлкән улы, әлбәттә, боларны танымады. Энесе, агасына үзенең кем булганын сөйләп:

— И, агай, мин синең иң кечкенә энең булам. Сез мин укыган чакта әнине эзләргә дип чыгып киткәнсез һәм, ничә еллардан бирле әти сезне көтсә дә, сездән һичбер хәбәр булмагач, елый-елый күзсез калган. Инде мин дә сезнең арттан, әтидән рөхсәт сорап, әнине эзләргә дип чыктым. Бу урманга килеп шушы бүрегә очрадым. Сез, аңарга карышып, үзегезне, үзегез һәлак иткәнсез. Әмма мин, аның белән дуслашып, сорашып, сезнең монда икәнегезне белдем һәм аңардан сезне әүвәлге сурәтегезгә кайтаруын үтендем. Ул да, мине кызганып, сезне аякка торгызды. Инде сез сау-сәламәт көенчә кире өйгә кайтып китегез,— диде.

Бу сүзләрне ишетеп, агасы гаскәрләре белән бергә үз шәһәренә кайтып китте.

Соңра уртанчы агалары янына барып, аларны да әүвәлге сурәтләренә кайтаруын Ак бүредән үтенде. Ак бүре тыңласа да, болардан һичберсен үзенә юлдаш итеп алырга ярамаганлыгын белдерде:

— Бик кирәк булса, үзең теләсәң, бары үзеңнән бер яшь зур агаңны гына алып калырсың. Башкалары синең эшкә ярамаслар, алар кайтып китсеннәр,— диде.

Бүре, баягы кебек бер дога укып, боларны да тергезде һәм болары да, олы агасы кебек саубуллашып, үз шәһәрләренә кайтып киттеләр. Әмма егет үзеннән бер генә яшькә олы агасын үзенә юлдаш итеп алып калды.

Соңра бу егет, агасы һәм Ак бүре белән өчәүләп, чатырларына кайтып киттеләр.

Чатырга кайтканнан соң бу егет Ак бүрегә:

— Йә инде, Ак бүре, мин юл кешесе, юл кешесенең юлда булуы яхшы, син мине тотма, урманыңнан чыгып китәргә рөхсәт бир,— диде.

Ак бүре аңарга каршы:

— Ярый, мин сезгә рөхсәт бирәм. Мәгәр мин сезне, бу урманнан чыгып киткәнче, үзем озатып җибәрим. Аның өчен бу урманда бик зур ерткыч җанварлар бар, алар сезгә зарар китерерләр дип куркам,— диде.

Соңра чатырларын бозып, атларына атланып, үз юлларына өчәүләп йөри бирделәр. Юлда барганда, Ак бүре егеткә:

— Йә, егет, син озак юл кешесе, мин белгәнем кадәр юлларыңны өйрәтим, бәлки, минем әйткәннәрем сиңа файда булып төшәр. Менә бу минем урманым. Шул җирдән өч көн, өч төнлек юл. Шул минем урманымнан чыгып, өч көн, өч төн киткәннән соң, дию патшасының җиренә барып чыгарсыз. Ул дию җиреннән өч көн, өч төн барганнан соң, бер алтмыш колач юанлыгы алтын тирәккә очрарсыз. Ул алтын тирәкнең астында бер кечкенә генә күл булыр. Ул күлгә җиткәч, аның янына бер зимләнкә казып, абзаңны шул зимләнкәдә калдырырсың. Үзең тирәкнең бер ягына баз казып, үзеңне, үзең күмәрсең, тик ике күзең генә калсын. Берничә сәгатьләр үткәннән соң, бу күлгә бер көтү елкылар килеп су эчәрләр. Алар менеп киткәч, бер сәгатьләрдән соң, күк күкрәтеп, җир дөбердәтеп, өермәләр өереп, алтмыш чакрымнан аяк тавышлары ишетелеп, бер алтмыш колачлы ала айгыр килер дә алтмыш колачлы алтын тирәкнең бер ягына ялын ышкый башлар. Ышкып арганнан соң, бик сусап, әлеге күлнең суын бөтенләй эчеп бетерер дә, әлеге агачка килеп, икенче як ялын ышкырга тотыныр. Шул вакытта, күлдә су беткәнлектән, күлнең төбендә булган балыклар барысы да җыелышып калырлар, агаң шуларны үзенең базына ташып куйсын. Алар аңарга азык булыр. Айгыр, озак ышкына торгач, әлеге алтмыш колачлы алтын тирәкне сындырыр. Аның шатыр-шотыр ауган тавышына син базыңнан сикереп чык та тиз генә әлеге алтмыш колачлы ала айгырга атланырга тырыш. Атлана алмасаң, ялына ябышырга, ялына ябыша алмасаң, койрыгына ябышырга тырыш. Әгәр дә син аңарга эләгә алсаң, бәлки, анаңны таба алырсың. Инде бер аңарга эләксәң, ул утка керсә — утка кер, суга керсә — суга кер, ябышкан җиреңнән кулыңны ычкындыра күрмә. Әгәр дә ычкындырсаң, шул вакыт һәлак булырсың. Шушы михнәтләргә түзә алсаң, анаңны табарсың, чыдамасаң, анаңны таба алмассың,— диде.

Егет:

— Инде мин, ни күрсәм дә чыдарга, анамның юлында корбан булырга җиттем, һәммәсенә түзәчәкмен,— диде.

Ак бүре аңа каршы:

— Ярый, егет, мин синең анаңны табуыңа да ышанамын. Анаңны табып, шәһәрегезгә кире кайтканда, минем яныма керми китә күрмә. Урманымның теләсә кай җирендә туктап, атыңны ял иттереп, үзең теләгәнне аша. Әмма миндә кунак булмыйча китәргә һич рөхсәтем юк. Инде

бер килеп урманыма төшкәч, кайда туктасаң да, мин сине үзем табармын,— диде.

Егет, Ак бүре белән исәнләшеп, аның урманыннан чыгып китте.

Бүре әйткәнчә, өч көн, өч төн барганнан соң, дию патшасының җиренә килеп, әлеге әйтелгән алтын тирәкнең янына барып җиттеләр. Икәүләп, тиз генә күл буена берәр баз казып, җир өстендә күзләрен генә елтыратып калдырып, үзләрен күмеп куйдылар. Азмы-күпме ятканнан соң, бер көтү елкы килеп, бүре әйткәнчә, су эчеп, үлән ашарга менеп киттеләр. Бер сәгать үткәннән соң, зилзилә кубарып, күкне күккә орып, җирне җиргә орып, өермәләр өердереп, алтмыш колачлы ала айгыр алтын тирәкнең төбенә килеп, ялын ышкып, су эчәргә төшеп, күлдәге бар суны эчеп бетереп, янәдән икенче як ялын ышкырга тотынды. Шул заманда, бик каты ышкуга чыдый алмыйча, алтмыш колачлы алтын тирәк шартлап төбеннән сынды. Тиз заман егет, үзен-үзе баздан атып ташлап, ала айгырның ялына ябышты. Бик биек булганлыктан, өстенә менеп утыра алмады. Шул ук заман айгыр, ялына адәм заты ябышканын белеп, җилтерәтеп, бер җиргә, бер күккә, бер тауга, бер ташка орып алып китеп, җиттеләр ут тавына. Ала айгыр ут тавының янына туктап, егеткә:

— И, егет, инде син миннән кулыңны ычкындыр. Мин хәзер бу ут тавының аргы ягына чыгачакмын. Аның аркылы чыккан вакытта синең һәммә җирең көеп, янып бетәр,— диде.

Егет аңа каршы:

— И, айгыр, мин янган-көйгән җирдә син дә исән калмассың. Синнән кулымны ычкындырмыйм,— дип, кулын ычкындырмады.

Ала айгыр шул сәгать егетне өстерәп утка алып кереп китте. Ут эчендә егетне өч сәгатьләп бутап йөрткәннән соң, аргы ягына барып чыктылар. Егетнең тәннәре пеште, куырылды һәм бик әрнеде. Соңра егет артына әйләнеп караса, әлеге ут тавы беткән, бернәрсә дә калмаган.

Егет үз-үзенә: «Бу атның сөйләгәне рас түгел икән, бу бер шәһәр генә икән»,— дип, курыкмыйча, атның ялына тагын да катырак ябышып алды.

Алтмыш колачлы ала айгыр егеткә янә:

— И, егет, инде кулыңны миннән ычкындыр,— диде.

Егет:

— Юк, минем синнән ычкындыра торган кулым юк, теләсәң кая бар, мин дә шунда барам,— диде.

Шулай итеп низаглашып, болар бер диңгезгә барып җиттеләр.

Ала айгыр:

— Инде, егет, кулыңны ычкындыр, син ут тавыннан котылсаң да, бу диңгездән котыла алмассың. Авызыңа-борыныңа су тулып, шунда гарык булырсың, мин аның аръягына чыгачакмын,— диде.

Егет:

— Инде минем синнән аерыласым юк. Син кая барсаң, мин дә шунда барырмын. Минем авызыма-борыныма су тулганда, синекенә дә тулар. Үлсәк, бергә үләрбез,— диде.

Ат, ачуланып китеп, егетне диңгезгә алып кереп китте. Өч көн, өч төн йөзгәннән соң, ат белән егет диңгезнең аръягына чыктылар. Чыккан вакытта ат егетне, үлсен дип, башын суга тигезеп, болгап чыгарды. Ләкин егеткә һичбер зарар килмәде.

Бераз коры җир белән барганнан соң, бер бик куе урманга җиттеләр. Бу урман аша чыпчык үтәрлек тә юл юк иде.

Алтмыш колачлы ала айгыр, егеткә:

— Әнә, күрәсең, нинди кара урман. Мин шул урманны ватып-җимереп аръягына чыгачакмын, инде син, исән вакытыңда, миннән кулыңны җибәр. Син аннан чыкканчы җибәрмәсәң, бары ялыма ябышып кулларың гына калыр. Башка һичбер җирең калмас,— диде.

Егет:

— Ычкындырасым юк, үлсәм үләрмен, һич ычкындырмыйм, мин ботарланган җирдә син дә коры калмассың,— дигәч, ала айгыр, ачуы килеп, егетне урманга алып кереп китте. Урманның куе агачлы бер җирендә егетне арлы-бирле агачларга сугып харап итмәкче булды. Әмма егеткә һичбер зарар килмәде.

Өч көн, өч төн үткәннән соң, мең мәшәкать белән болар урманның аргы ягына барып чыктылар. Азмы-күпме киткәннәр иде, бер бик биек тау-таш араларына килеп җиттеләр.

Ала айгыр:

— Йә инде, егет, хәзер кулыңны миннән ычкындырып, шул җирдә кал,— диде.

Әмма егет:

— Үлсәм үләрмен, һичбер ычкындырасым юк,— дигәч, ала айгыр ачуланып, моны бер тауга, бер ташка орып, өч көн, өч төн киткәчтен, бер ялан җиргә барып чыктылар.

Ала айгыр:

— Инде, егет, син хәзер күп нәрсәләр күрдең. Бу сулар, утлар,

таулар, ташлар бар да дию патшалыгыннан адәм үтмәсен өчен эшләгән эшләр иде. Инде афәттән котылдың, өстемә менеп утыр да, мин сине бара торган җиремә кадәр алып барыйм,— диде.

Шуннан соң ала айгыр, егетне атландырып, өч көн, өч төн барганнан соң, күп япан җирләр үтеп, бер бик зур ком тавына килеп җиттеләр. Шунда җиткәннән соң, ат, егеткә таба карап:

— И, минем дустым, юлдашым, инде мин өстемнән бурычымны төшердем. Миңа моннан ары барырга рөхсәт юк. Син инде минем өстемнән төш тә бу ком тавының аргы ягына чыгарга тырыш. Ул ком тавының артында — Каф тавы. Каф тавының аръягында яман диюләр, усал арысланнар, аждаһалар яталар. Алар янына чыга алсаң, анаңны табарсың,— диде.

Егет моңарга күп рәхмәтләр укып, өстеннән төшеп, тау итәгендә калды. Алтмыш колачлы айгыр үз юлына китте.

Бу егет, шул ук сәгать азрак тамагын туйдырып, тауның өстенә чыгарга теләп, тауга менә башлады. Бераз менгән иде, ком ишелеп янә түбән төште. Никадәр менәргә тырышса да, ком ишелеп, һичбер менә алмады. Бик арып-талып, күңеле тулып, анасы исенә төшеп, елап, аптырап утырганда, һавадан бер кара болыт кисәге төшеп килгәнен күрде дә куркып китте. Карап торды, болыт һаман төшә дә төшә. Төшеп җитә башлагач, егет күрде — бу бер кош, пырылдап әйләнеп, моның янына килеп төште дә:

— И, егет, әйдә минем өстемә менеп утыр. Мин сине бер җиргә алып китим,— диде.

Егет утырырга да, утырмаска да белмәде. «Утырсаң да һәлак итәр, утырмасаң да һәлак итәр»,— дип шикләнеп, Аллага тапшырып, менеп утырган иде, шул сәгать бу кош күз күреме җиргә алып менеп китте.

Егет һавага менгәннән соң курка башлагач, кош:

— И, егет, син куркасыңмы? — дип сорады.

Егет, билгеле:

— Мин куркам,— диде.

Кош, моңа:

— И, дустым, син мин барында курыкма. Син үзеңнең егетлегең аркасында әллә нинди куркынычлардан котылдың. Инде мин сине: «Ала айгыр белән бу ком тавына кадәр килгәндер дә, анда менә алмый торгандыр»,— дип кызганып, сәмрут кош сурәтенә кереп килдем. Мин — күптәнге дустың Ак бүре. Мин сине хәзер Каф тавының башына илтеп

куярмын, аннан ары барырга миңа рөхсәт юк. Үзең ничек булса да чыгарсың да анаңны табарсың,— диде.

Шулай итеп сәмруг кош егетне Каф тавы башына китерде дә:

— Инде миңа монда озак торырга ярамый. Тизрәк үз юлыма китим. Сау бул. Алла ак юл бирсен,— дип саубуллашып, үз юлына очып кире китте.

Егет тау башында бик күп ат вә адәм сөякләре күреп, хәйран-вәйран булып торганнан соң, ике кулына ике ат сөяге алып, таяк итеп таянып, тауның бер ягына таба төшеп китте. Өч ай дигәндә тауның аргы ягына төшеп җитте. Бераз бара башлагач, бер көтү арыслан чыгып, бу егеткә ыргылдылар. Тәмам ашарга дигәндә генә, араларыннан берсе чыгып, боларга: «Ашамагыз!» — диган кебек итеп, барын да егеттән куып җибәрде.

Шулай итеп, бу бәлаләрдән азмы-күпме котылып ятканда, янә бер кечкенәрәк кенә тауга очрады. Тауның башына менеп караса, ерактан бер ялтыраган нәрсә күреп: «Бу нәрсә икән?» — дип, шул ялтыраган нәрсәгә карап китте. Ялтыраган нәрсәнең янына килеп җитсә, дөнья зурлыгында эшләнгән бер бакыр сарай булып чыкты. Бакыр сарайның бер тәрәзәсеннән караса, ни күрсен: кырык бер кол кыз озын өстәлгә салып адәм итләре юып яталар иде. Бу егет шуларны күреп, күңеле нечкәреп, куркып: «Минем итемне дә шул кызлар бу өстәлгә салып юарлар, мин дә бу җирдә харап булырмын»,— дип, кычкырып елап җибәрде. Елый торгач: «Елаудан файда булмас»,— дип, егет гайрәткә килеп, батырланып ишек янына килеп сәлам бирде.

Шул минутта бер бик сылу, матур, кызыл битле, кара кашлы бер кыз ишекне ачып, егетнең сәламен алды:

— И, егет, син адәми затмы, пәри затмы? — диде.

Егет, аңа каршы:

— Адәми затмын,— диде.

Кыз егеткә:

— Ат килсә тоягы көя, кош килсә канаты көя торган җиргә син адәми зат булып ничек килеп җиттең? — диде.

Егет аңа каршы:

— Минем күп заманнан бирле ашаганым юк, бик ачмын, мине сарайга алып кереп, бераз ашарга бир, тамагым туйдыр,— диде.

Кыз моңа каршы:

— Алай булса, син бераз туктап тор. Минем абыстам адәми заттан —

диюнең хатыны. Мин аңардан рөхсәт сорап чыгыйм. Ул ни әйтсә, мин шуны эшләрмен,— дип кереп китте һәм абыстасына барып: — И, ханым-солтаным, ишек төбенә бер адәми зат килгән. «Кертеп, бераз ашатыгыз!» — дип ялынадыр. Кертергә рөхсәт итәсезме? — дип сорады.

Абыстай:

— Адәми зат булса, керт, ашат, рөхсәт,— диде.

Кыз, моны ишеткәч, ишеккә барып, егетне кертеп, абыстай янына алып килде. Егет сәлам биреп, абыстай белән күреште. Шуннан соң абыстай, бер урынга утыртып, кызга ашарга китерергә кушты. Кыз шул заман төрле кош итләре куырып китереп егетне сый-хөрмәт итте. Егет ашаганнан соң, абыстай аның янына килеп:

— И, егет, син кайдагы кеше буласың, ни җирлек? — дип сорады.

Егет:

— Мин фәлән җирнең бер патша улымын. Мин укуда вакыт анам югалган иде, мин, атамнан рөхсәт алып, анамны эзләргә дип чыгып китеп, бу җиргә килеп җиттем. Инде моннан соң кая барасымны үзем дә белмим,— диде.

Абыстай аңа каршы:

— Инде, егет, ерак җирләрдән күп михнәтләр күреп килгән икәнсең. Әгәр дә анаңны табып кайта калсаң, минем сараема кереп кунак булмый китмә. Бу сарайның иясе җиде башлы дию тугыз айлык юлга китте. Әгәр дә тиз көннән кайта калсаң, һич курыкма, минем сараема сугылмый китмә,— диде.

Егет тә керергә вәгъдә кылды.

Абыстай янә:

— Мин синең коры сүзеңә ышанмыйм. Син анаңны тапкан шатлыгыннан мине онытырсың. Син онытмасаң, шуны онытмассың — менә мин сиңа шул үзеңә ишек ачкан кызны никахлап бирим дә, ул монда калсын. Син дә аны исеңә төшереп, минем яныма керерсең,— диде.

Егет тә шунда разый булып, агасы исенә килеп төште дә:

— Мин монда рәхәттә ятам, минем агамның ашый торган азыгы бетеп, аптырап ята торгандыр. Инде мин бара торган җиремә барып җитим,— дип, абыстайдан рөхсәт сорап, юлга азыклар алып, бикәсе белән исәнләшеп, юлга чыгып китте.

Бу бакыр сарай буйлап өч көн, өч төн барганнан соң, бер көмеш сарайга килеп чыкты. Көмеш сарайның тәрәзәсеннән караган иде: баягы кебек, кырык бер кол кызның өстәлләргә салып адәм итләре юып торга-

нын күрде. «Минем дә итләремне шул өстәлләргә салып, шул кызлар юарлар микән?» — дип куркып китте.

Янә гайрәткә килеп, ишеккә барып сәлам бирде.

Баягыдан да матур бер кыз чыгып, моның сәламен алып:

— Адәми затмы син, пәри затмы син? — дип сорады.

— И, кардәш, адәми затмын. Бик күптәннән бирле юлда йөреп, ачыгып киттем. Кертеп бераз ашатсана,— диде.

Кыз моңа каршы:

— Минем өлкән абыстам бар. Аңардан кереп сорыйм,— дип кереп китте. Һәм абыстасына барып: «Юлдан арып бер адәми зат килгән, кертеп бераз ашатырга сорыйдыр»,— диде.

Кыз да, абыстасының сүзен тыңлап, егетне кертеп, баягы кебек хәл-әхвәл сорашып, егет боларга анасын эзләргә чыкканын, патша баласы икәнен сөйләгәч, абыстай:

— Бик яхшы,— дип сыйлап,— кайтканда курыкмый-нитми минем сараема кер, керми китмә,— диде.— Син болай гына онытырсың. Менә мин үзеңә каршы чыккан кызны никахлап бирим, аны исеңә төшереп керерсең,— диде.

Абыстай кызны никахлап бирде.

Егет янә өченче кич кунганда, агасы исенә төшеп: «Бу җирдә озак торырга ярамас»,— дип, янә кәләше белән исәнләшеп, үз юлына китте.

Көмеш сарай буйлап өч көн, өч төн үткәннән соң, күрде: бер бик зур алтын сарай янына бик зур вә матур итеп бакчалар корылган. Егет бераз карап, хәйран булып торды һәм, алтын сарайның тәрәзәсеннән килеп караса, баягы кебек кырык бер кол кызның өстәлгә салып адәм ите юганын күрде. Баягы кебек янә ишеккә барып сәлам биргән иде, баягыдан да матур, сылу, бер бите ай, икенче бите кояш кебек бер бик матур кыз килеп моның сәламен алды, һәм:

— Адәми затмы, пәри затмы? — дип сорады.

Егет, кызның матурлыгына хәйран калып, бераз карап-карап торды да, исенә килгәч, адәми зат икәнен белдерткәч, бу кыз да абыстайдан рөхсәт сорап, егетне сарайга, туры абыстай янына алып керде.

Абыстай белән күрешеп, күрсәткән урынга утырып, китергән кош итләрен ашап, китергән эчемлекләрне эчкәч, егет, абыстайга карап:

— И, абыстай, син кайсы шәһәрдән буласың? — дип сорады.

Абыстай моңа:

— Мин фәлән патшаның хатыны, фәлән шәһәрдән килдем, мине

урлап шушы дию бу җиргә алып килде. Инде минем югалганыма фәләненче ел булды. Минем дүрт улым бар иде. Инде алар да үсеп, синең кадәр була торганнардыр,— диде.

Егет аңа каршы:

— Соң улларыңнан берсе синең яныңа килсә, син аны таныр идеңме?— диде.

— Әлбәттә, таныр идем, кеше үз баласын танымыймы,— диде.

— Соң алай булгач, мин кем булам? — диде.

Абыстай:

— Белмим,— диде.

Егет:

— Алай булса, мин синең улың булам. Мин фәләнчә айлардан бирле сине эзләп монда килеп җиттем. Аллага шөкер, синең нурлы йөзеңне күрдем,— дип, муенына барып асылынды. Сорашып, шатлыкларыннан елаштылар.

Атасының исәнлеген, ике агасының юлдан кайтып киткәнлеген, үзеннән бер генә яшь олы абзасының күл буенда базда калганын — барын да аермачык сөйләп бирде. Сүзләре тәмам булгач, абыстай улын алып чыгып, бер сарайның ишеге төбенә алып килде дә, сарайның ишеген ачып, алдан улын кертеп җибәрде. Сарай ачылгачтын, егет сарайның уртасында биш йөз пот авырлыгында бер шар күрде. Анасы шул шарны егеткә алып чыгарга кушты. Егет, шарны алып чыгыйм дип, барып тотынып караган иде, урыныннан да кузгата алмады. Шуннан соң анасы улына:

— Синең кавырсының да катмаган икән. Диюебез унике айлык юлга киткән иде. Киткәненә инде ике ай булды. Тагын ун айсыз кайтмаячак. Ул дөньяда адәм итләре ашап кинәнә, өйгә дә алып кайтадыр. Диюнең шундый бер баг бакчасы һәм бер күле бар. Шул алма агачының алмасын ашап, күленнән су эчкән кеше дөнья йөзендә беренче батыр булачак. Син өч ай иркенләп шул алмагачтан алма ашап, күленнән су эч. Шуннан соң мин сине яңадан, теге шарны күтәртеп, сынап карармын. Бу көйгә син батыр түгел әле. Сиңа ышанып юлга чыгарга ярамый,— диде.

Егет, анасының сүзен тыңлап, өч ай шунда ашап-эчеп ятканнан соң, янәдән килеп кергәч, анасы моңа шарны яңадан күтәреп карарга кушты һәм:

— Диюнең һөнәре шул иде, буш вакытларында шул шарны алып чыгып, менә шул биек тауның башына ыргытып җибәреп, шар төшкән

чагында яңадан бер кулы белән тотып алып, һавага ыргытып җибәрә иде,— диде.

Егет анасыннан ишеткән сүзләргә гарьләнеп, шарны ачу белән алып, тау башына ыргытып җибәреп, тәгәрәп төшкәндә тотып алыйм дигәндә генә, шарны тота алмыйча, шар егетне бәреп егып, тагын да үз юлына китеп, тау итәгенә барып төште.

Анасы, бу хәлне күреп:

— Балакаем, инде кавырсының яңа гына ката башлаган икән, тагын берничә айлар ирек алсаң, үзеңә бераз көч керер,— диде.

Егет, яңадан алма ашап, бакчада тора башлады. Егет шунда ай ярым торганнан соң, анасы:

— И, балакаем, инде тагын бер сынап карыйм, вакытлар кыскарып бара,— дип, егеткә яңадан шарны ыргытырга кушты. Егет, анасының сүзен тыңлап, әлеге шарны ыргытып җибәреп, шар төшкән вакытта бер кулы белән генә тотып, яңадан биек тауның башына сыңар кулы белән ыргытып җибәрде. Икенче кат тагын тотып алып, ыргытып җибәрде. Шулай итеп уйнаганнан соң, анасы, улына:

— Инде хәзер көчең диюнеке белән тигезләнде. Дию аңсыздан[1] кайтып керсә дә, көрәшерлек көчең бар,— диде.

Анасы улын җитәкләп өйгә алып кереп:

— Йә инде, улым, җитәр, кыз куеныннан чык, аңсыздан дию кайтып керсә яисә туганнарыннан берсе килсә, харап булырбыз,— диде.

Шуннан соң анасы, тагын бер сарайга алып барып, ишеген ачып, икәүләшеп шунда булган һавада очып йөри торган бер зур иске машинаны алып чыгып, ватылган җирләрен төзәтеп, тузаннарын кагып, юлга китәргә әзерләп куйдылар. Кереп, ашап-эчеп туйганнан соң, сарайдан кырык бер кызны да, кәләшен дә үзләре янына утыртып, югарыга күтәрелеп киттеләр.

Киткән чакта егетнең анасы бер әфсен укып, алтын сарайларны һәм бакчаларны юк итеп, бер алтын күкәй итеп йомарлап, кесәсенә салды. Алтын сарайларның, бакчаларның беленмәслек булып бәгъзе[2] урыннары гына калды. Шул машина белән иртәдән кичкә хәтле генә очканнар иде, килгәндә очрап кунак булып киткән көмеш сарайның турысына килеп җиттеләр.

---

[1] *Аңсыздан* — кинәттән, көтмәгәндә.
[2] *Бәгъзе* — кайбер.

Егет, анасына карап:

— Әни, без бераз монда туктыйк әле. Син машинаның телен бор. Монда минем тагын бер кәләшем бар. Аны да алып чыгарбыз,— диде.

Анасы, егетне тыңлап, машинаны борып, көмеш сарайга килеп төштеләр. Анда боларны бик тансыклап көтеп торалар иде. Каршы алып, ашап-эчеп, ял итеп, кунак булып, бу сарайны, алтын сарайлар кебек көмеш йомырка ясап, кесәләренә салып, эчендәге кырык кол кызны һәм үзенең хатынын алып, тагын алга таба очып киттеләр.

Шунда чак кына очып барганнар иде, бакыр сарай турысына килеп җиттеләр. Бу чакта бакыр сарайның диюе кайткан иде. Болар килеп төшкәннән соң, каршы һичкем чыгып алмады. Анасы, егеткә карап:

— Улым, без моннан китик. Күрәсең, монда безне каршы чыгып алучы юк. Боларның диюләре кайткандыр. Әгәр дә кереп китсәң, ул вакыт безгә зыян китерерләр,— диде.

Егет, анасына карап:

— Әни, монда кермичә китәргә һич ярамый. Монда минем өченче хатыным бар. Шулкадәр алмалар ашап, сулар эчеп, инде бу диюдән куркып торыр хәл юк,— дип, машинадан төшеп, бакыр сарайның ишегеннән кереп китте.

Ни күзе белән күрсен, монда диюнең хатыны һәм кол кызлары үкереп елап каршы алдылар һәм егеткә:

— Бәхетебез юк икән, диюебез кайтты. Җир астында фәлән сарайда йоклап ята. Тора калса, сине дә, безне дә үтерер,— диделәр.

Егет, диюнең хатынына карап:

— Кайсы подвалда йоклый? — дип сорап, подвалның ишеген ачып кереп китте.

Керсә, ни күрсен, тугыз башын тугыз якка салып, бернәрсә белмичә, җәйрәп йоклап ята. Кергәч, алмаз кылычын чыгарып, бер башын кисеп төшерим дигәндә, исенә килеп: «Тукта әле, йоклаган кешене кем дә үтерә. Мин моны уятыйм да көчемне сынап, сугышып карыйм. Үлсәм, хак үлем булыр»,— дип, диюнең баш очына килеп бераз утырды. Дию һаман уянмады.

Соңра сарайга кереп, диюнең хатынына:

— Бар, диюегезне уят. Мин аның белән көрәшеп, сугышып, көчемне сынап карар идем,— диде.

Диюнең хатыны:

— Адәми зат килгәндә аны уята торган бер без бар. Син шул безне

ал да табан астына кертеп бетереп бута. Шуны сизеп, ул уяныр. Уянгач та сиңа тәмле сүзләр сөйли башлар. Әмма син, аның алай йомшак сөйләвенә карап, алданма. Ул бик хәйләкәр. Йомшак торган саен, син каты тор. Юкса ул алдар. Кара, алданырга тырышма! — диде.

Егет безне алып диюнең бер табанына тыгып бутаган иде, дию бернәрсә дә сизмәде. Икенче табанына ныграк тыгып бутаган иде, дию сизеп уянды да хатынына кычкырды:

— Кая, адәми зат килгән икән. Нигә кунак итмисез? — диде.

Егет аңа каршы:

— Мин ач түгелмен. Мин бары синең каныңа сусап кына килдем. Кая, тор, әйдә, чыгып алышыйк,— диде.

Дию, егетнең бу сүзләренә гарьләнеп, урыныннан сикереп торып, шул ук сәгать мәйданга чыгып, алышырга тотындылар. Шулкадәр алыштылар ки, тигез җирләр түмгәккә, түмгәкле җирләр карашакка әйләнеп беттеләр. Озак алыша торганнан соң, егет диюне күтәреп алып ыргытып җибәргән иде, дию килеп тезенә кадәр җиргә батты. Диюнең ачуы килеп, сикереп торып, егетне тотып җиргә күтәреп бәргән иде, биленә кадәр җиргә батты. Соңра, егетнең ачуы килеп:

— Юк, бездә алай бәрмиләр, менә болай бәрәләр,— дип, диюне күтәреп алып җиргә бәргән иде, бил кадәр җиргә батты.

Шулай итеп, нихәтле алышсалар да, берсен-берсе җиңә алмады. Соңра дию:

— И, егет, инде без никадәр алыштык, бер-беребезне җиңә алмадык. Мин бик ачыктым, бераз ашап чыгыйм,— диде.

Егет, диюгә:

— Оятсыз, үзең генә ашарга оят түгелме? Мин дә арыдым, хәлем бетте. Мине дә алып кер,— диде.

Дию, разый булып, егетне дә өйгә алып керде.

Диюнең өендә ике өстәл бар иде. Берсенә үзе генә утырып ашыйдыр иде. Икенчесенә килгән кунакларны утыртадыр иде. Дию хатыныннан ашарга аш, эчәргә су сорады. Диюнең ике төрле суы бар иде — берсе хәл кертә торган, икенчесе — хәл китәрә торган. Диюнең хатыны эшне аңлап, диюгә хәл китәрә торган суны, егеткә хәл кертә торган суны салып биргән иде, дию эчүгә бөгелеп төште. Әмма егет гайрәтләнеп, батырланып китте. Шул ук сәгать дию эшне сизеп, хатынына карап:

— Сез мине бүген харап итәсез икән,— диде. Үтерергә теләсә дә, егеттән куркып, хатынын үтерергә кыймады.

Соңра дию белән егет, сахрага чыгып, тагын алыша башладылар. Егет диюне күтәреп бер ыргытып бәргән иде, дию башларына кадәр җиргә батты. Шул вакыт егет, алмаз кылычын чыгарып, диюнең тугыз башын тугыз җиргә кисеп ташлады да үзе сарайга керде. Хатын һәм кызлар, бу хәлне күреп, егеткә күп рәхмәтләр укып:

— Бу көнне дә күрәсебез бар икән,— дип, бик шатландылар.

Соңра егет:

— Әйдәгез, инде моннан китик,— диде.

Аңа каршы хатыны:

— Тукта, монда тагын безнең кардәшләребез бар, аларны да коткарыйк,— диде.

Егеткә ачкычларны биреп, сарайларны тикшерергә киттеләр. Бер сарайны ачып җибәргәннәр иде, күрделәр: сарай тулы картлар икән. Бу картлар диюнең гадәтен белеп: «Симезебезне тотып ашар инде»,— дип, куркышып кача башладылар.

Егет, боларның курыкканын күреп:

— И, картлар, сез миннән курыкмагыз, мин дә сезнең кебек адәми затмын. Мин сезне диюнең кулыннан коткарам. Әйдәгез, чыгыгыз! — диде.

Соңра тагын бер сарайны барып ачкан иде, анда карчыклар яталар икән. Алар да куркышып: «Монысы симез, монысы симез»,— дип, берсен-берсе күрсәтә башладылар.

Аларга егет:

— Курыкмагыз, әйдәгез, чыгыгыз, мин сезне коткарам,— диде.

Аннан соң бакыр сарайның каршысында янә бер зур сарай бар иде.

Хатын егеткә:

— Инде, егет, диюнең үләксәсен шул сарайга илтеп куйыйк. Ул сарай диюнең тегермәне иде. Ул, шул тегермәндә әлегә хәтле ничә меңнәрчә адәмнәрне тарттырып, азык итеп ашады. Хәзер инде үзе җәзасын күрсен,— диде.

Егет күтәреп киткәннән соң хатын тегермәнне кузгатып җибәргән иде, бераздан соң өстәлләргә кырык табак белән тулы төйгән итләр, ашарга яраклы булып, суганы, борычы сибелеп, килеп тезелделәр. Хатын, тегермәнне туктатып:

— Менә, инде күрәсез, бу дию ничә еллардан бирле никадәр кешенең башына җитте. Ул болай булыр дип гомерендә бер мәртәбә уйлаганы юк иде,— дип, сарайга кереп ашарга утырдылар.

Ашап туйганнан соң, егет, үзенең кош ата торган мылтыгын алып, ерак та түгел бер куе урманга кошлар атарга дип, ауга китте. Ләкин егетнең киткәнен берсе дә сизми калдылар.

Егетнең анасы:

— Монда инде бик озак тордык,— дип, тизрәк ашыктырып, кызларны утыртып, машина белән югары күтәрелеп киттеләр. Өч хатыннан берсе дә егетнең кайда калганын белмәделәр.

Бу сарайда берәү дә калмады. Ике көн киткәннән соң, һава көймәсен тикшереп карасалар, күрәләр: егет көймәдә юк. Болар кире кайтырлар иде, диюнең нәселеннән берәрсе очрап һәлак итәр дип куркып, алга таба йөрделәр дә, бер зур шәһәргә җиткәнче берничә чакрым җиргә туктап, алтын вә көмеш сарайларын җәеп, егетне шул җирдә көтеп калдылар.

Егет, урманда бераз йөреп, төрле кошлар атып, кесә һәм кәләпүшләренә җиләкләр җыеп кайткач, «хатыннарыма булыр» дип шатланып бакыр сарайга кайтып керсә, ни күзе белән күрсен, бакыр сарайның эчендә һичкем калмаган.

Ашыйсы килеп, бүлмәләрне карап йөргән чакта, бер кечкенә генә бүлмәгә туры килде. Аның уртасында бер кечкенә генә өстәл торадыр иде. Аның өстендә зәңгәр күк белән бер генә карыш буйлыгында бер чыбык ятадыр иде. Егет, барып, аптырап чыкбыкны кулына алып: «Бу ни эшкә ярый икән?» — дип, күккә бәреп караган иде, моның каршысына бер гыйфрит килеп:

— Ни кушасыз? — диде.

Егет шул ук вакыт, чыбык белән күктә хикмәт барлыгын сизеп, гыйфриткә карап:

— Минем аналарым моннан киткәннәр икән. Мин берүзем калганмын. Инде мине күпме вакытта аналарым артыннан илтеп җиткерерсең? — диюенә каршы, гыйфрит:

— Өч көндә илтеп җиткерермен,— диде.

Егет, моны озаксынып, чыбык белән күккә яңадан суккан иде, гыйфритнең икенчесе, моннан шәбрәге килеп чыкты да:

— Ни боерасыз? — диде.

Егет моңа да:

— Мине аналарым артыннан күпмедә илтеп җиткерерсең? — диде.

Гыйфрит аңарга:

— Бер көндә,— дигән иде, егет тагын озаксынып бер сукты.

Өченче гыйфрит килеп:

— Ике сәгать эчендә җиткерермен,— диде.

Егет, шатланып, моның өстенә менеп утырды да, гыйфрит шул ук вакыт китереп җиткерде.

Егет «Инде мин туры сарайга барып керсәм, килешмәс, алар мине кызык иттеләр, мин дә аларны кызык итим» дип:

— Инде син мине туры сарайга илтмә, шәһәрнең читенә илт,— диде.

Гыйфрит, егетнең сүзен тыңлап, шәһәрнең читенә илтеп ташлады да, үзе шунда ук юк булды.

Егет шуннан җәяүләп шәһәргә кереп китте дә бер картның артыннан барып җитте. «Карт кая барыр икән?» дип, артыннан сынап карады.

Карт бер өйгә барып керде. Егет тә аның артыннан керде. Карт кергәч тә бер шешә эчемлек алып эчте дә чыгып китте. Картның артыннан күрә-күрә егет тә китте. Карт, тагын каранып, калган акчасын алып, яңадан кереп эчеп чыкты. Соңра бер өйгә барып керде. Аның артыннан егет барып керсә, күрде: карт бер итекче икән.

Егет, картка карап:

— И, бабай, син бер яхшы итекче икәнсең. Моннан соң син болай хезмәт итеп тереклек итмәссең. Тик минем бер сүзем бар. Шуны эшләсәң, мин сиңа бер мең тәңкә акча бирермен,— диде.

Карт:

— Кулымнан килерлек булса, мөмкин,— диде.

Шуннан соң егет картка:

— Беләсеңме, шәһәрнең читендә ике сарай бар. Шунда минем күреп гашыйк булган бер кызым бар. Син шуңарга яучы бул,— диде.

Карт, егетнең сүзен тыңлап, шәһәрнең читенә чыгып, сарайга туры китте. Кыз да, бүген үзенә бер кеше киләсен төшендә күреп, сизеп торадыр иде. Шул арада сарайга килә торган картны күреп, аны каршы чыгып алып керде. Карт та, егет әйткән кыз шул булырга кирәк дип:

— И, кызым, миндә бер кунак егет бар. Ул сине күреп гашыйк булган һәм мине сезгә яучыга җибәрде. Инде сез ни дип әйтәсез? — диде.

Кыз картка:

— Ярый. Тик минем калымым бик зур бит. Адәм кулыннан килә торган эш түгел. Әгәр дә булдыра алса, мин аныкы, ул минеке,— диде.— Калымым шул: бер ефәк күлмәк. Аның һичбер җөе булмасын, өстемә таман гына да булсын. Нечкәлектә бармактагы балдактан үтәрдәй булсын. Кечкенәлектә, йомарлагач, учка сыярлык булсын. Тагын бер калуш. Аның һичбер кадагы булмасын. Аягыма тап-таман булсын,— диде.

Һәм үз-үзенә: «Әгәр дә боларны эшли алса, ул минем ирем булыр»,— дип уйлады.

Карт:

— Бик яхшы,— дип, кайтып егеткә әйтте.

Егет картка:

— Ярый, син шунда торып тор, мин барып алып килим,— дип, сахрага, эт тавышы ишетелмәслек җиргә китеп, кесәсеннән тылсымлы таякны алып күккә суккан иде, бер гыйфрит килеп җитте.

— И, хәзрәт, ни боерасыз? — диде.

Егет тә гыйфриткә:

— Әлеге күлмәк белән калушны ничә сәгатьтә табып китерерсең? — диде.

Гыйфрит:

— Өч сәгатьтә табып китерермен,— диде.

Өч сәгать көтүе озак булыр дип, егет икенче кат суккан иде, икенче гыйфрит килеп:

— Бер сәгатьтә китереп җиткерермен,— диде.

Егет, моңа да разый булмыйча, өченчесен чакырган иде, анысы:

— Ярты сәгатьтә китереп алдыңа куярмын,— диде.

Егет:

— Мин урынымда көтеп торырмын,— дип, гыйфритне эзләргә җибәрде.

Гыйфрит, урыныннан торып, алтын сарайга кереп, кызның янына килеп, буен-иңен үлчәп, кушылган буенча табып китерде. Егет шул заманда чокырда көтеп утырганда, гыйфрит килеп егеткә күрсәтте. Егет, карап, бик ошатып, бик күп рәхмәтләр укып, күлмәк белән калушны алып кайтып, картка китереп тоттырды.

Карт алып, сарайга илтеп, кызга китереп бирде. Кыз алып киеп, үлчәп караган иде, үзе әйткәнчә тап-таман булып чыккан. Бик яратып: «Бу эшләрне дию мәмләкәтендә булмаган бер кеше эшли ала торган түгел, шул минем киявем икән, дип, кичкә килсен»,— дип, картка вәгъдә биреп җибәрде.

Кич булгач, егет карт белән икәү сарайга килеп керделәр. Боларны кол кызлар, анасы чыгып каршы алдылар. Егет күреп, анасы белән күрешеп, бик куанышып, шул минутта ашап-эчеп, алтын-көмеш сарайларны бер йомырка ясап кесәгә салып, үзләре шарларына утырып, картка бирәсе акчасын биреп, анасы киленнәренә:

— Инде улым һәркемнән алда менеп утырсын,— дип, әмер бирде. Һәм, егетне алдан утыртып, барысы бергә очып киттеләр.

Бераз көннәр яланда очып килгәннәр иде, агасының калган чокырына җиттеләр. Агасы боларның килгәнен күрде, тик кем килгәнен генә белмәде. Болар килеп төшкәннән соң, агасы боларны каршы алып, сөйләшеп, шул ук вакыт аны да шул шарга утыртып, шәһәрләренә таба кузгалып киттеләр.

Тагын бераз килгәннән соң, Ак бүренең урманына килеп җиттеләр дә бер бик әйбәт аланга килеп төштеләр. Болар шардан төшеп ашап-эчеп утырганда, Ак бүре боларның килгәннәрен белеп, ул да болар янына килеп җитте. Бик матур егет сурәтенә кереп, болар белән килеп күрешкән иде, бөтен кызларның күзләре ут шикелле янып, аңардан күзләрен алмадылар. Шуннан соң егет моның Ак бүре икәнен белеп, танышып-күрешеп, бик ныклап сыйлап, эчереп, Ак бүрегә карап:

— И, дустым, Ак бүре, менә сиңа сүзем шулдыр: (өч кызны күрсәтеп) менә болар минем хатыннарым, (янә өчне күрсәтеп) боларын агаларыма багышладым. Шул алты кыздан калганнарыннан үзегезгә ошаган берсен сайлап алыгыз,— диде.

Бүре сайлап алганнан соң, кыз да: «Бигрәк матур егеткә туры килдем»,— дип, бик шатланды.

Соңра болар, саубуллашып, янә үзләренең шәһәрләренә очып киттеләр.

Ничә көннәр очып киткәннән соң, бер зур шәһәргә туры килеп, шул зур шәһәрне көмеш сарайның хуҗасы — унике башлы диюнең хатыны:

— Бу минем шәһәрем,— дип, егеткә күп рәхмәтләр укып, үз шәһәренә төшеп калды.

Бу хатын шул шәһәрнең патша хатыны иде. Кайтып керүгә, үз патшасы белән күрешеп, бик шатланып үз йортларында рәхәтләнеп тора башладылар.

Янә аз гына очып барганнар иде, тагын бер зур шәһәрнең турына килеп җиттеләр.

Тугыз башлы диюнең хатыны бу шәһәрне:

— Бу минем шәһәрем,— дип, егеттән рөхсәт сорап, күп рәхмәтләр укып, төшеп калды.

Егет шулай үзенең хатыннарыннан һәм агаларына атаган кызлардан башкасын, үзләренең теләүләре буенча, барысын да азат итеп, бу шәһәрдә калдырды.

Бу шәһәрдән озак бармадылар, үзләренең шәһәрләренә кайтып җиттеләр. Шәһәргә биш чакрым кадәр калганда, көн кич булгач, инде иртә белән керербез дип, шунда туктап калдылар. Егетнең анасы кесәсенә йомырка ясап салган сарайларны, бакчаларны чыгарып, нәкъ дию шәһәрендәге кебек итеп корды. Шуннан соң хатынның ике улы, үзләренең бүлмәләренә хатыннарын алып кереп, ятып йокладылар.

Шуннан соң егетләрнең анасы, тышка чыгып, диюдән алып кайткан балдагын бармагыннан алып, сызгыртып җибәргән иде,— җирдәге чүпкә сан бар, гыйфриткә сан юк,— шулкадәр күп гыйфритләр килеп, моның катына җыелдылар.

— Ләббәйкә, хәзрәт, ни боерасыз? — диделәр.

Хатын, боларга:

— Менә бу сарайдан шәһәргә хәтле таң атканчы бер алтын күпер эшләгез. Ул алтын күпернең ике ягыннан ике елга — берсе анда, берсе монда агып торсын. Ул елгалар өстендә күз күрмәгән, колак ишетмәгән үрдәкләр, казлар йөзеп, бакылдашып, каңгылдашып торсыннар. Елганың ике читендә алма агачлары үсеп торсын. Алмалары пешеп, суга өзелеп төшеп торсын. Аны йөзеп йөри торган кошлар ашап торсын. Ул күпернең өстендә җигүле бер тройка ат булсын. Арбасының көпчәкләре алтыннан булсын. Өстенә утырган чакта селкенерлек булмасын. Ул атларның дилбегәләрен тоткан кеше куркырлык — чуеннан да кара, бер зур мыеклы гыйфрит булсын. Шуларны таң атканчы тәмам итегез,— диде дә үзе йокларга ятты.

Хатын берничә сәгатьләр генә яткан иде, гыйфритләр килеп моның ишеген кактылар. Чыгып караган иде, бар да үзе дигәнчә тәмам булган. Соңра, гыйфритләрне үз юлларына җибәреп, бераз торган иде, таң да атты.

Таң атып яктыргачтын, патша, урынынннан торып, ишектән чыккан иде, ишек төбеннән сузылып киткән алтын күперне күреп «Ах, харап булганбыз икән — ишек төбенә кадәр су баскан», дип, йөгереп кереп китте дә, вәзирләренә:

— Әйдәгез, тизрәк чыгыгыз,— диде.

Вәзирләр чыгып карасалар:

— И, падишаһым, ялгышкансыз. Бу — су түгел. Озакламый бер хәбәр булыр. Йә хатының, йә балаларың кайткандыр, дип, патшаны сөендерделәр.

Патша, шатланып, үзенең киемнәрен киеп, тәхеткә утырып көтеп торганда, патшаның хатыны хат язып, гыйфрит аны патшага китереп тапшыр-

ды. Хатта болай язылган иде: «Хөрмәтле патша хәзрәтләре, сезгә сәламнәрем бәгъдендә үтенечем шулдыр: Аллага шөкер, без исән-сау кайтып җиттек; сәгать унда шушы күпернең башында кардәш-кабилә, мулла-мәзиннәр белән көтеп торыгыз. Шушы гыйфрит сезне безгә кунаклый алып килер».

Сәгать унга кадәр патша, агай-энеләрен җыеп, яхшы киемнәрен киеп, көтеп тора иде, гыйфрит килеп болар янына туктады да:

— Әйдәгез, утырыгыз,— дип, боларны утыртты һәм шул ук минут әлеге алтын сарайга китереп җиткерде.

Патшаның уллары һәм киленнәре, боларны каршы алып, бик зурлап, ашатып-эчертеп, аш тәмам булганнан соң, килгән кунакларга кайтырга рөхсәт бирелеп, алар өйләренә гыйфрит арбасына утырып кайтып киттеләр. Монда патша бары мулла-мәзиннәр, уллары белән үзе калып, патшаның кечкенә улы атасына анасын сау-сәламәт алып кайтканын әйтеп һәм аны яңадан никахлап алуын үтенеп, аңа патша да разый булып, шул ук сәгать никах укытып, ун көн уен ясап, тугыз көн туен ясап, тумаган туры бияне суеп, кисәр карасы юк, шаңгырдаган бер сөяген патша үзенең хатыны белән көн дә тотып кимерә иде, ди.

Шуннан соң патша хатынын үзенең өенә алып кайтып, бергә тора башладылар. Егет янә агаларына дигән кызларына да, аларны никахландырып, утыз көн уен ясап, кырык көн туен ясадылар. Агалары да хатыннарын үз өйләренә алып кайтып тора башладылар. Әмма егет үзенең хатыны белән шул алтын сарайда утырып калды.

Тыныч кына торган вакытта тугыз башлы диюнең һәм унике башлы диюнең хатыны, егеткә хат язып, хатыннары белән кунаклый килүен үтенделәр. Шул ук сәгать егет, өч хатыны белән боларга кунакка барып, алар да егетне бик зурлап каршы алып, бик күп бүләкләр биреп, кадерләп, кире сараена озатып җибәрделәр.

Егет үзенең сараена кайтып, өч хатыны белән үз сараенда әле дә булса рәхәтләнеп торалар, ди.

12. Дию патшасы әкияте

Борын заманда бар иде бер кеше. Аның бер таз улы бар иде. Таз малай егерме биш яшенә җиткәчтен, атасы үлде.

Малай, анасыннан йөз сум акча сорап алып, базарга чыгып китте.

Базарда йөз сумга бер көчек сатып алып өенә кайтты. Көчеккә кәҗә савып сөт эчерәдер иде.

Икенче атна булгач, тагы да анасыннан йөз тәңкә акча алып, базарга китте. Сибирски мәче сата торган бер кешегә очрады.

— Күпме сорыйсың? — дигәч, мәче иясе:

— Йөз тәңкә,— диде.

Таз йөз тәңкәгә мәчене дә алып кайтты. Йортта башка хайваннары юк иде.

Өченче атнада тагы, йөз тәңкә акча алып, базарга китте. Ул акчага бер бака сатып алды.

Кайтканда, ярты юлга җиткәч, бака егетнең кулыннан сикереп төшеп, унҗиде яшендәге бер кыз булды.

Таз:

— Мин сине йөз сумга бака дип сатып алдым, син кыз булдың,— диде.

Кыз аңарга каршы:

— Мин бака түгел, фәлән шәһәрдәге Ризван патшаның кызы идем, мине, унҗиде яшемә җиткәч, бер дию өйдән урлап, бака итеп, базарга чыгарып йөз сумга сатты. Инде мин синнән үз атама илтеп тапшыруыңны үтенәмен, мин сиңа үземнең алтын балдагымны бирәм,— диде.

Таз, риза булып, кызны, патша тора торган шәһәргә алып барып, атасына тапшырды.

Атасы, бик шатланып:

— Бу хезмәтең өчен сиңа ни бирим? — диде.

Егет:

— Миңа бернәрсә дә кирәкми, кызыңны бирсәң була,— диде.

Патша:

— Кызымны бирмәм, биш мең сум акча бирәм,— диде.

Егет, биш мең сум акчаны алып, өенә кайтып китте.

Бер-ике атна торгачтын, егет үзенең анасын, башкода итеп, патшаның кызын сорарга җибәрде. Анасы, барып, патшага:

— Мине малаем кызыңны сорарга җибәргән иде,— диде.

Патша:

— Кызымны бирермен, әмма минем сараемнан өегезгә хәтле тимер юл булып, икенче класс йөреп торсын, юлның ике ягында җиләк-җимеш бакчасы булсын, бакчада алмалар пешеп салынып торсын, бакчаның

эчендә бер зур күл булсын, күлдә алтын үрдәкләр йөзеп йөрсен. Шул вакыт мин кызымны бирермен,— диде.

Анасы кайтып улына сөйләгәннән соң, егет кич белән чыгып йөзеген сызгырткан иде, шул вакыт шайтаннар килеп:

— Ни боерасыз? — диделәр.

Таз, анасы сөйләгәнчә:

— Патша сараеннан өемә хәтле тимер юл булып, анда икенче класс йөреп торсын, юлның ике ягында җиләк-җимеш бакчасы булып, алма агачларында алмалар пешеп салынып торсын, бакча эчендә зур күл булып, анда алтын үрдәкләр йөзеп йөрсен,— диде.

Шайтаннар бу сүзләрне ишетеп, шул вакыт эшкә башладылар. Төн үткәнчә ясап бетереп, башлыклары, Тазга:

— Хәзер булды,— дип, кереп әйтте.

Иртә торгач, егет янә анасын утыртып, патшага башкодага җибәрде. Тазның анасы, патшага барып:

— Солтаным, мин кичә әйткән эшләрегезне барын да җиренә җиткереп, кызыгызга башкода булып килдем,— диде.

Патша, сораган һәр нәрсә булганын күреп, кызын бирмәкче булып, егетнең үзен күрәсе килеп, Тазны үзенә чакыртты. Тазга анасы кайтып сөйләгәчтен, Таз, торып машинага утырып, патша сараена үзе китте. Патшага сәлам биреп:

— Васыятең нәрсә, әйт? — дип сорады.

Патша:

— Мин сиңа кызымны бирәм,— дип, шул сәгать мулла алдырып, никах укытып, Таз белән кызны келәткә яптылар.

Таз шунда хатыны белән дүрт ай тордылар да соңра өйләренә кайтып киттеләр.

Өйгә кайтып кергәннән соң, хатын берзаман Тазны яратмый башлады: «Мин, патша кызы булып, шул тиле Тазга килеп, хатын булып торамын!» — дип, үз-үзен тирги башлады. Болар шул көенчә бер ел тордылар. Бер елдан соң хатын бер ир бала тапты. Шуннан соң хатын Таз белән түгел, үзенең улы белән юанып тора башлады.

Тазның хатыны бервакыт суга барганда үзенең әүвәлдә таныш булган дию пәриен күрде.

Дию, хатынны күрүгә:

— Син гомереңне шул Таз белән үткәрмә, әйдә минем белән,— дип, хатынны янәдән үзе белән алып китте. Ярты юлга җиткәч, ул кыздан:

— Тазның йөзеге кайда, аны урлап булмасмы? — дип сорады.
Хатын:
— Аның йөзеге бармагында. Алай булгач, без кире кайтыйк та, төнлә мин аның йөзеген урлармын,— дип, кире өйгә кайттылар.
Кич кайткач, баласын имезеп ятты. Таз йоклагач, аның бармагыннан йөзеген урлап чыгып китте.
Икенче көнне кызын күрергә дип патша үзе килсә, ни күрсен: оланы калган, кызы юк. Патша, Тазга:
— Кызым кая? — дип, аяк тибеп кычкырды.
Таз аңа каршы, куркып:
— Мин кызыңның кая икәнен үзем дә белмим,— диде.
Патша:
— Сез минем кызымны үтергәнсез,— дип, анасы белән Тазны төрмәгә илтеп япты. Үзе, оланны алып, өенә китте.
Иртә белән дию пәрие, йөзекне алып сызгырып, шайтаннарны җыйды да:
— Тазның кушып кордырган тимер юлларын, бакчаларын — барын да кырып ташлагыз, берсе дә булмасын! — диде.
Шайтаннар шул вакыт барын да туздырып ташладылар, бары кара җир калды.
Таз белән хатынны хайваннары булган мәче, көчек эзләп йөреп таба алмадылар.
Соңра мәче көчеккә:
— Әйдә әле, барып карыйк, төрмәдә юк микән,— диде.
Төрмә янына барып өч кат әйләнеп йөргәннән соң, Таз, мәчене күреп чакырып алды да:
— Минем бик ашыйсым киләдер, кибеттән барып калач алып китерә алмассыңмы? — диде.
Мәче, Таз яныннан үрмәләп төшеп, эшне эткә сөйләп биргән икән. Барып, кибеттән бер бөтен калач алып китереп, Тазга ашаттылар. Шуннан соң Таз мәчегә:
— Сез минем йөзегемне табып китерә алмассызмы? — диде.
Мәче:
— Табуын табам, ләкин бик авыр булыр,— диде.
Мәче, төшеп, эшне көчеккә сөйләде. Көчек риза булып:
— Әйдә, барып карыйк, бәлки, табарбыз,— диде.
Шул сүзләрдән соң мәче белән эт, чыгып китеп, бик зур бер суга

барып җиттеләр. Судан көчек йөзеп чыга аладыр, мәче чыга алмый. Мәче, көчеккә:

— Инде минем болай чыгарга хәлемнән килми, син мине атландырып алып чык,— диде.

Көчек, мәченең сүзен тыңлап, алып чыкты.

Икәүләп барып, дию пәрие тора торган шәһәрне табып, диюнең өенә барып керделәр.

Мәче көчеккә:

— Син салам төбенә ятып тор, мин кечкенә генә мәче баласы булырмын, өй тирәсендә сикереп йөргәннән соң, алар мине алып керерләр,— диде.— Төнлә, дию йоклаганнан соң, мин йөзекне урлап чыгармын, шуннан соң без чыгып качарбыз,— диде.

Мәче мәче баласы булып өйгә кереп караса, йөзек хатынның бармагында юк. Хатын, куркып, авызына кабып яткан. Мәче моны белеп, хатынның янына барып, борынына койрыгын тыгып җибәрә. Хатын төчкереп җибәргән иде, авызыннан йөзек килеп чыкты да, мәче йөзекне алып чыгып китте.

Мәче, көчек белән икәүләп, кайтырга чыгып киттеләр. Су янына килеп җиттеләр. Көчек, мәчегә:

— Суны чыкканда йөзекне мин кабыйм,— диде.

Мәче, бирәсе килмичә:

— Синең тешләрең бик сирәк, төшереп калдырырсың,-диде.

Көчек:

— Әгәр дә бирмәсәң, мин сине алып чыкмыйм,— диде.

Мәче куркуыннан көчеккә йөзекне бирде дә көчек өстенә атланып чыгып китте. Суның яртысына җиткәчтен, көчек, су кабам дип, авызын ачкан иде, йөзекне төшереп җибәрде.

Мәче, чыккачтын:

— Мин сиңа тешләрең сирәк дип әйттем, тыңламадың, инде без, икәү ике яктан эчеп, бу суны киптерик,— ди.

Суны эчәргә тотындылар. Мәчегә бер балык килеп чыкты да:

— Ни эшлисез? — дип сорады.

Мәче:

— Алтын балдагыбыз суга төшкән, әгәр дә шуны чыгарып бирмәсәгез, хәзер суыгызны киптерәбез,— диде.

Балык, китеп, башка балыкларга әйткән иде, хәзер табып мәчегә чыгардылар. Мәче йөзекне авызына кабып кайтып, төрмәгә илтеп, Тазга тоттырды.

Таз, төнен янә йөзекне сызгыртып:

— Тагы юллар искечә булсын! — диде.

Шайтаннар, шул вакытта ук эшләп, Тазга килеп әйттеләр.

Патша чыгып караган иде, юллар искечә икәнен күреп, килеп Тазны төрмәдән чыгарды.

Таз:

— Кызыңны дию пәрие урлаган, хәзер мин эзләргә барам, миңа кырык мең аскәр[1] бир,— диде.

Патша аскәр бирде. Таз, китеп, егерме ике тәүлектән соң дию пәриенә барып җитеп, чорнап алдылар да, диюне үтереп, кызны алып кайттылар. Кайткач, патша Тазга:

— Инде сез өегезгә кайтмагыз, минем йортымда торырсыз, дип, ярты байлыгын биреп, Тазны үзенә варис ясап калдырды.

Әле дә шунда торалар, ди.

13. Бер байның әкияте

Борын заманда булган бер бай. Байның ике улы булган. Ул үзе читтә сәүдәдә йөргән. Бай киткәч, аның хатыны башка бер егет белән йөри торган булган.

Кайтканда бай бер күгәрчен алып кайткан. Күгәрченнең канат астына: «Кем башын ашаса — патша була, кем йөрәген ашаса — алтын төкерә»,— дип язган булган.

Бай тагы киткәч, хатынның йөри торган егете килеп күгәрченне күрде дә:

— Моны кайдан алдыгыз? — дип сорады.

Хатын аңарга:

— Ирем алып кайтты,— диде.

Егет хатынга:

— Бу күгәрченне суеп ашыйк,— диде.

Хатын:

— Аны суеп ашасак, мин иремә ни җавап бирермен? — диде.

Егет:

— Аңардан курыкма, «малаең чыгарып җибәргән», диярсең.

---

[1] *Аскәр* — гаскәр.

Хатын, егетнең сүзен тыңлап, аш пешерүчегә күгәрченне суеп, мичкә кыздырырга куярга кушты.

Малайлар мәдрәсәдән кайттылар. Олы малае күгәрченнең башын, кече малае йөрәген алып ашадылар да үзләре чыгып киттеләр.

Бераздан хатынның егете килеп:

— Шул күгәрченне китерегез, ашыйк,— диде.

Аннан соң пешекче күгәрченне алып бирде. Егет караса, күгәрченнең башы белән йөрәге юк.

Егет:

— Бу күгәрченнең башы белән йөрәге кая? — диде.

Пешекче:

— Белмим, ихтимал, малайлар алган, пичне малайлар ачып карады,— диде.

Аннан соң малайларны чакырып китерделәр.

Олы малай:

— Мин башын ашадым,— диде.

Кечесе:

— Мин йөрәген ашадым,— диде.

Аннан соң малайлар чыгып киттеләр.

Егет:

— Алай булса, малайларны суеп, мин олы малайның башын, син кече малайның йөрәген ашыйк. Мин патша булырмын, син, алтын төкерерсең. Әгәр риза булмасаң, без аерылабыз,— диде.

Хатын:

— Малайларны суйсак, мин иремә ни җавап бирермен? — диде.

Егет:

— Син аңа аптырама, малайлар мәдрәсәдән кайткач, күгәрченне куркытып ызбадан чыгарып җибәрделәр дә, мин аларны шелтәләдем, алар мин орышкач чыгып киткәннәр иде, шуннан бирле кайтканнары юк,— дип әйтерсең.

Егетнең бу сүзләренә хатын разый булды.

Хатын иртә белән пешекчегә:

— Син бер пычак алып, малайларга каршы бар, мәдрәсәдән өйгә алып кайтма, җиләккә дип, урманга алып бар,— диде.

Пешекче малайларны үзе белән бергә урманга алып китте.

Малайлар:

— Кая алып барасың? — диделәр.

— Җиләк җыярга,— диде пешекче.

Урманга барып җиткәч, бер агач төбенә барып утырдылар. Пешекче малайларга әйтте:

— Ну, энеләрем, сезгә сүзем шул, сезне анагыз үтерергә җибәрде, мин сезне үтермәм, менә сезгә бер әпәй, шул юл белән теләсәгез кая барыгыз,— диде.

Малайлар, бу сүзне ишеткәч, бик җылашып, пешекче белән бәхилләшеп, бер юл белән киттеләр. Бара торгач, ике аермалы бер юлга җиттеләр.

Агасы:

— Энем, син сул юл белән кит, мин уң юл белән китәм,— диде.— Аллаһ язган булса, шәт, бер күрешербез,— диде.

Агай-эне икәү сулкылдашып җылаштылар да икесе ике юл белән киттеләр.

Олысы бара-бара бер шәһәргә барып җитте. Ул шәһәрдә патша сайлыйлар, ди. Аларның сайлавы шул иде: бер күгәрченне очырып җибәрәләр дә, шул күгәрчен кемнең башына өч тапкыр кунса, шул кеше патша була. Бу малай да җыелган халык арасына барып чүгәләде. Күгәрченне очырып җибәрделәр. Күгәрчен малайның башына килеп кунды. Өч тапкыр җибәрделәр, өчесендә дә бу малайның башына килеп кунды. Шуннан соң малайны, патша ясап, тәхет өстенә утырттылар, патшаның кызын бирделәр. Шунда бу малай бер-ике ел патша булып торадыр.

Кече эне, сул яктагы юлдан китеп, бер шәһәргә бара да бер ипи пешерүчегә күмәч сатарга керешәдер. Күмәчләрне алып чыгып, ярлы-ябагайга бер тиенсез бүлешәдер. Үзе корзинкага төкерәдер дә алтын алып керәдер.

Карчык:

— Улым, бик бәяле саткан икәнсең,— ди.

Көннәрнең берендә бу малай шәһәргә кичкырын сәгать тугызда чыгып китәдер. Күрә, бер йортка язулы такта суккан: «Кем теләсә, кереп карта уйнарга ярыйдыр»,— дип. Бу Мучы батыр анда кереп, патшаның өч кызы белән уйнап бик күп акча оттырып, ашап-эчеп төн уздырдылар. Иртә белән кайтты да тагын күмәчләрне, базарга алып чыгып, акчасыз бүлеште. Үзе тагын корзинкасына алтын төкереп, өйгә кайтты. Кичлектә тагы патша кызлары карта уйнаган төшкә барып керде.

Патшаның зур кызы:

— Син, егет, мине үзеңә хатынлыкка ал,— диде.

Егет, риза булып, аны хатынлыкка алды. Патша үзен варислыкка куеп, ике ел торды. Ике елдан соң өенә күрергә кайтырга сорады. Өенә кайтырга дүрт айга рөхсәт бирделәр.

Мучы өйгә кайтмыйча, агасын эзләргә китте. Агасын эзләп тапты. Агалы-энеле патшалар кочакланып күрештеләр дә кечесе агасына:

— Үгә[1] кайтып карыйк, үдә ничек торалар икән,— диде.

Кайтып тәрәзәдән карадылар, ни күрсеннәр: аналары теге йөри торган егет белән бергә чәй эчеп утыралар. Аталары бер якта утыра. Шул вакытта болар, тәрәзәне шакылдатып, кунарга сорадылар. Боларны кунарга керттеләр. Болар кергәч, пешекче боларны таныды. Болар: «Син әйтмә»,— дип, пешекчегә күз кыстылар. Мучы, белмәгәнгә салышып, атасыннан:

— Улларың бармы? — дип сорашты.

Атасы:

— Ике улым бар иде, бер күгәрчен алып кайткан идем, шуны чыгарып җибәргәннәр иде, аналары орышкач, чыгып китеп югалдылар,— диде.

Шуннан соң болар, сикереп торып, анасы янында утырган егетнең башын чабып өзделәр. Зур агасы, кылычын чыгарып, анасының башын чабып өзде.

Пешекчене аталарына хатынлыкка биреп, болар үзләренең патша булып тора торган шәһәрләренә киттеләр.

14. Патша малае әкияте

Бардым базарга, арка-ерка язарга, алдым бер сөяк ит, сөйләп торма — моннан кит.

Булган бер патша. Патшаның булган бер улы, егерме бер яшендә.

Атасы улына:

— Улым, мин сине өйләндерәм,— дип әйтте,— ат җигеп, үзеңә бер кыз эзлә,— диде.

Патша малае ат җигеп китте дә бер шәһәргә барып җитте. Шәһәрдә бер тимерчегә барып керде. Бу вакытта тимерченең өч кызы чәй эчеп утыралар иде.

Кызлар, моны күргәч:

---

[1] *Ү* — өй.

— Син ник килдең? — диделәр.

Патша малае кызларга:

— Мин берегезне хатынлыкка алырга килдем,— диде.

Олы кыз:

— Әгәр дә мине алсаң, мин бөтен патшалыктагы кешегә кием җиткереп торырмын,— диде.

Уртанчысы:

— Әгәр дә мине алсаң, мин бөтен патшалыктагы кешене аш белән туйдырып торырмын,— диде.

Кечесе:

— Әгәр дә мине алсаң, мин бер елга унике малай китерермен, һәркайсының куллары, бармаклары алтыннан булыр,— диде.

Патша улы бу сүзләрне ишетеп, боларга бер сүз дә әйтмичә, өенә кайтып китте.

Кайтып керүгә моңардан атасы:

— Улым, ниләр күрдең? — дип сорады.

Малай атасына:

— Әти, мин бер шәһәрдә бер тимерченең өч кызын күрдем. Олы кызы: «Әгәр дә мине алсаң, мин бөтен кешеләреңне киемгә туйдырып торырмын»,— диде; уртанчысы: «Әгәр дә мине алсаң, мин бөтен кешеләреңне ашатып-туйдырып торырмын»,— диде; кечесе: «Әгәр дә мине алсаң, мин бер елда унике малай тудырырмын, аларның куллары, бармаклары — бар да алтыннан булыр»,— диде.

Атасы:

— Син патша баласы, ул тимерче кызын ничек барып аласың, сиңа патша кызлары да бетмәгән,— диде.

Аңарга каршы малай:

— Әти, син теләсәң ни эшлә, әмма мин кече кызын барып алам,— диде.

Атасы аңа каршы:

— Ярый, улым, теләсәң ни эшлә, аласың килсә, файтун[1] җик тә барып ал,— диде.

Малай, атасыннан рөхсәт алгачтын, файтун белән килеп, тагы теге шәһәрнең тимерчесенә барып керде.

Һәм тимерчегә:

---

[1] *Файтун* (*фаэтон*) — көймәле арба.

— Мин кече кызыңны алырга килдем, хәзер мулла китер дә никах укытып алып китәм,— диде.

Мулла килеп никах укыгачтын, кызны алып кире кайтып китте.

Кыз килгәннән дүрт айдан соң авырга калды.

Патша малае читкә сатуга китеп, бер ел йөрде. Шул вакытта кыз унике малай тапты, һәр малайның куллары, бармаклары алтыннан иде. Тапкан кичен үк унбер малаен шайтан карчыгы урлап китте. Хатын, күзен ачып караса, янында бер баласы гына калган. Хатын: «Унике малай китерәм дип сөйләгән идем, бары бер генә малаем калды, ирем кайткачтан аңа ни әйтермен»,— дип, бик курыкты.

Бер елдан соң патша малае әйләнеп кайтты. Аңарга каршы анасы чыгып:

— Улым, хатының бер малай тапты, алтын куллы, алтын бармаклы,— диде.

Патша малае, кереп, хатынына:

— Син миңа «Унике малай китерәм», дип сөйләгән идең, ник берне генә китердең, алдадың? — диде.

Шуннан соң хезмәтчесенә кычкырып, бер шикәр мичкәсе китерергә кушты:

— Хатынны малае белән мичкәгә салып, кадаклап, Иделгә агызып җибәрәм,— диде.

Мичкәне китереп куйдылар, аның эченә бер елга җитәрлек әпәй куйдылар да, малай белән хатынны кертеп утыртып, кадаклап агызып җибәрделәр.

Хатын белән малай бер ел агып баргачтын, малай, анасыннан:

— Без кая барабыз? — дип сорады.

Анасы малаена:

— Мине, синең белән икебезне, атаң агызып җибәрде, инде без суда агып барабыз,— диде.

Малай, анасына:

— Әни, мин мичкәнең өстен пычак белән әз генә уйыйм әле,— диде.

Малай әз генә тишеп караса, күрде: мичкә бер куаклык арасына кереп туктаган. Моны күргәч, малай, анасына:

— Әни, мин бу чыбыкларга тотынып чыгам әле,— диде.

Анасы малаена:

— Бар, улым, чык та мине дә кулымнан тартып ала алмассыңмы,— диде.

Малай мичкәдән куаклыкка басып чыгып китте дә дилбегә белән

мичкәне дә тартып алды. Шуннан соң малай анасы белән, икәүләп барып бер урманга кереп, бер зур аланга барып утырдылар.

Малай анасына:

— Әни, син шунда берсәк[1] утырып тор, мин ашарга нәрсә булса да табып килә алмаммы,— диде.

Анасы рөхсәт бирде.

Малай китте, көн китте, бер төшкә барып җитте. Ул төштә бер эскәтер тапты. Эскәтергә барып тотынган иде, аның эченнән төрле ашамлыклар килеп чыкты. Малай эскәтергә: «Җәел!» — дигән иде, эскәтер җәелде, «җәел!» дисә, җәелә, «җыел!» дисә җыела торган булды. Малай бу эскәтерне анасы янына алып кайтып, эскәтергә «җәел!» дигән иде, эскәтер, җәелеп, төрле ашамлыклар хәзер булды. Анасы белән икәү ашадылар-эчтеләр дә, малай эскәтерне анасы янында калдырып, үзе тагын рөхсәт сорап чыгып китте.

Йөри-йөри тапты бер балта. Ул балта, «чабыл!» дисә, чабылып, биек йортынчалар[2] салынадыр. Аны да алып кайтып анасына күрсәтте.

Анасы малаена:

— Бик яңгырда торабыз, үзебезгә бер ызба салыйк,— диде.

Малай чыгып агачка балта белән чаба башлаган иде, чапкан бер агачы киселеп, үзе буралып, бик яхшы ызба салынды. Ызбаның эченә, нәкъ уртасына, бер зур багана утыртты. Ызбаны бетергәч, малай, тагы анасыннан рөхсәт сорап, чыгып китте.

Йөри-йөри малай бер сибирски мәче тапты. Ул мәчене өйгә алып кайтып җибәргән иде, мәче баганага менгәндә әкият сөйли, түбән төшкәндә җыр җырлый торган булып чыкты. Малай тагы анасыннан рөхсәт сорап чыгып китте.

Йөри-йөри, малай бер тәкә тапты. Тәкәне алып кайтып өйгә җибәрде. Пичкә яккач, тәкә коймак, белен пешереп, майлап китереп куйды. Малай ашаганнан соң тагы чыгып киткән иде, йөри-йөри бер бүрек тапты. Ул бүрекне кигәч, малай һичбер кешенең күзенә күренми торган булды. Бүрекне өенә алып кайтып анасына күрсәтте. Үзе янә чыгып китеп бер үгез тапты, аны да алып кайтып анасына тапшырды. Ул үгез мөгезе белән сөрә, куригы[3] белән чәчә, аяклары белән урып иген игә.

---

[1] *Берсәк* — бераз.

[2] *Йортынча* — йорт-мунча булуы ихтимал.— *Л.Җ.*

[3] *Курик* — койрык.

Малай яңадан чыгып китә. Йөри-йөри тапты бер одеал, одеалга кереп утырып «оч» дисә, очып китеп, теләгән җиргә барадыр. Малай одеалны алып кайтып, анасына күрсәтте дә, анасы, малайга:

— Инде безгә шул байлык җитәр, йөрмә, өйдә тор,— диде.

Бердән бер көнне патшаның улы вәзир белән пароходка утырып йөрергә чыкты. Бер-ике атна йөзеп килгәннән соң, урман эчендә аланда бик яхшы йорт күределәр.

Вәзир белән патша улы:

— Монда әүвәлдә йорт юк иде, әйдә, барып карыйк,— диделәр.

Вәзир белән патша улы йортка кереп, өстәл янына килеп утырдылар. Малай, әмер биреп, үгезне чыгарып җибәргән иде, үгез иген игәргә тотынды. Мәчегә әмер биргән иде, мәче баганага менгәндә әкият сөйли, түбән төшкәндә җыр җырлый. Соңра тәкәне коймак пешерергә кушты. Тәкә, пешереп, майлап, өстәл өстенә китереп куйды. Малай эскәтергә «җәел!» дип кычкырган иде, төрле ашамлык-эчемлек тулы көе, эскәтер килеп кунаклар алдына җәелде. Патша улы вәзире белән: «Бу нинди эш?!» — дип, үләрә китеп[1] карап тордылар. Ашап-эчеп туйгач, саулыклашып[2] чыгып киттеләр.

Малай, бүреген киеп:

— Артларыннан өйләренә барыйм әле, анда ниләр сөйләрләр икән,— диде.

Патша улы кайтып керүгә, анасына:

— Әни, мин шундый йортка ошладым[3], анда үгез иген игә, мәче әкият сөйли, тәкә коймак пешереп өстәлгә куя, эскәтер төрле ашамлыклар белән тулы, «җәел!» дигәч, җәеләдер,— диде.

Анасы малаена:

— Бу кызык түгел, менә мин җир астында унбер малай күрдем, алар һәммәсе алтыннан,— диде.

Тыңлап торган малай бу сүзләрне ишетеп, анасына кайтып сөйләде. Анасы ул сүзгә каршы:

— Алар — синең туганнарың буладыр. Менә мин унике малай тапкан идем, унбересен шайтан карчыгы урлады, бары син генә калдың,— диде.— Инде мин сиңа алтыннан унике бертөсле бүскә[4] ясап бирәм, син

---

[1] *Үләрә китү* — бу гыйбарә безгә таныш түгел, ис китү мәгънәсендә.— *Л.Җ.*
[2] *Саулыклашу* — кул бирешү.
[3] *Ошлау* — очрау, юлыгу.
[4] *Бүскә* — туп.

аларны җиде кат җир астына төшкәч, урман авызына тәгәрәтеп җибәрәсең,— диде.— Унбер малай унбер бүскәне килеп алырлар, син дә алар белән бергә катышып, уникенчесен ал,— диде.— Алар сине кыйный башларлар. Шул вакытта син «Агайлар, мине кыйнамагыз, мин сезнең туганыгыз булам, дип әйт,— диде.— Ышанмасагыз, унике бүскәгә карагыз, алар да бертөсле, без дә бертөсле», дип әйт,— диде.

Соңра малай җир астына төшеп, урман авызына килеп, бүскәләрне тәгәрәтеп җибәргән иде, унбер бүскәне унбер малай килеп алдылар, уникенчесен үзе алды. Малайлар кыйный башлаганнар иде, бу малай:

— Агайлар, сез мине кыйнамагыз, мин сезнең туганыгыз булам, карагыз, унике бүскә бертөсле, без дә барыбыз да бертөсле, мин сезне алырга килдем,— диде.

Шуннан соң туганнары белән күрешеп, аларны одеалга утыртып өенә алып кайтты. Болар кайтып кергәннән соң, аналары белән күрешеп, шатлыкларыннан җылаштылар.

Икенче көнне сахрага чыккан вакытта патшаның хатыны:

— Улым, син күргән йортта булган хатын — синең хатының, балалары да синең балаларың булыр, аларны син ничек булса да алып кайт,— диде.

Патша малае янә бу йортка килеп керә дә вәзир малае белән өстәл янына килеп утырадыр. Кечәге кебек малай барына да әмер биреп җибәргән иде, бар да үзләренең эшләрен эшләргә башладылар. Шуннан соң патша малае:

— Менә мин сезнең атагыз булам, сез минем балаларым буласыз. Инде мин сезне алырга килдем,— диде.

Малайлар:

— Әгәр дә син атабыз булсаң, ник безнең анабызны брактың[1], безнең белән агызып җибәрдең? — диделәр.

Аталары:

— Инде, балалар, хаталык миндә, әйдәгез, өйгә кайтыйк,— диде.

Шуннан соң малайлар, аталык хакы бар дип, аналарына киңәш итеп, бар да бергәләшеп, аталары белән бергә пароходка утырып кайтып киттеләр.

Аталары, өйгә кайтканнан соң, унике улына унике патша кызы алып биреп, әле дә булса торалар, ди.

---

[1] *Брагу* — ташлау.

15. Өч аргамак әкияте

Әүвәл заманда, кәҗә команда, саескан сотник, бака плотник булган заманда бик ярлы гына бер кеше торган, ди. Аның булган өч улы.

Карт үзе хасталанган, үлгән вакытында васыять әйткән:

— Улларым, мин үлгәч, сез өчегез дә минем каберем өстенә барып куныгыз.

Аталары үлгәчтән малайларның кечесе агаларына әйтте:

— Агайлар, менегез атайның кабере янына, васыятен тотыек.

Агалары:

— Ул әҗәл авырлыгы белән әйткән, ул нинди кабер янына барып куну булсын.

Кече улы төнге сәгать уникедә атасының кабере янына китте, ниләр булыр икән дип, түземсезләнеп көтеп тора. Шул вакытта, сәгать берләр булгач, килеп чыга бер аргамак, шомырт кебек кара. Бу егет кара аргамакның маңгай ялыннан тотып ала. Аргамак җиргә өч тапкырлы сугыладыр. Егет аргамакны җибәрмидер. Шуннан аргамак, телгә килеп:

— Җибәрмәдең, егет, мин синеке булдым, минем өч бөртек кылымны ал,— диде.

Егет аргамакның өч бөртек кылын алып кесәсенә тыкты — өенә кайтып җитте.

Икенче көнне агаларына әйтте бу:

— Агайлар, үзегез өчен үзегез барыгыз,— диде.

Агалары тагын бармадылар да, икенче көнне дә үзе китте. Төнге сәгать уникеләрдә, тагын ниләр булыр икән дип, куркынып торганда, килеп чыкты бер җирән аргамак, аргамакның ялыннан чорнап тотты бу. Аргамак өч мәртәбә җиргә бәрелгәч тә, егет ычкындырмады. Шуннан соң аргамак:

— Мин — синеке,— диде.

Аргамакның өч бөртек кылын алып кесәсенә тыкты. Өенә кайтып, кайда булганын, ниләр күргәнен беркемгә дә әйтмәде.

Өченче көнне агаларына тагын:

— Барыгыз, атайның васыятен онытмагыз,— диде.

Агалары:

— Андый җүләр сүзгә ышансаң, бар үзең,— диделәр.

Өченче көнне дә егет үзе китеп, төн уртасында туры аргамак килеп, янына басадыр. Аргамакның ялыннан тотып алды бу. Аргамак өч мәртәбә

күтәрелеп бәрелгәч тә, егет ычкындырмады. Шуннан соң аргамак телгә килеп:

— Мин синеке булам,— диде.

Егет, аргамакның өч бөртек кылын алып, үзен җибәрде.

Боларның өйләрендә булган ике үгезләре. Ул үгезләре зур агаларыныкы булганнар. Бу кече энеләренең бернәрсәсе дә булмаган.

Үзләреннән ерак түгел бер патшаның өч кызы булган. Патша язу тараткан: «Мин өч алма тәгәрәтәм, шул алмаларны кем таба, шуңарга кызларымны бирәм»,— дип. Егетләр бу хәбәрне ишеттеләр дә, зур агалары үгезләрне җигеп киттеләр.

Кече энеләре, кырга чыгып, өч аргамакның да кылларын селкеп җибәрде. Менә өч аргамак моның каршысына килеп бастылар. Берсенә атланып, икесен янына алып китте бу. Агалары янына җитеп, узып китте, агалары моны танымадылар. Ерак киткәч, өч алманы табып кесәсенә тыкты, өенә кайтып китте. Юлда агалары каршы очрадылар. Агаларына үзен танытып, үгезләрен җибәртеп, икесен ике аргамакка атландырып, өчесе дә өйләренә кайттылар.

Икенче көнне патша язу таратты: «Кем минем алмаларымны тапты, алар килсеннәр, кызларымны алсыннар»,— дип. Болар тагын өч аргамакка атланып чыгып киттеләр. Юлда агаларына берәр алманы бирде. Барып җиттеләр.

Патша:

— Кем алмаларны тапты? — дип сорады, алма табучыларга алга чыгарга кушты.

Болар, алмаларны тотып, патша каршысына чыктылар. Патша мәҗлес җыеп, аракы өләшеп йөрде. Кече туганнары аракыны эчте, агаларына эчмәскә кушты:

— Аракыны җиргә түгегез,— диде.

Боларга аракы бирелгәч, олы агалары аракыны аяк аска түктеләр.

Мәҗлестәге кешеләр:

— Патша мәҗлесендә ник болай мәсхәр итеп аракыны түгәсез? — диделәр.

Аракыны бар да башларына күтәрделәр.

Энеләре:

— Без аракыны башка күтәрмибез, безгә аракы да, падишаның кызлары да аяк астындагы булырлар. Без кызларны да аска салып ятырбыз,— диде.



Шуннан соң бер дүрт ай мәҗлес ясап, патша йортында тордылар.

Дүрт айдан соң болар өйгә кайтырга рөхсәт сорадылар. Патша боларны өч айга кырык мең аскәр[1] белән күрергә кайтырга җибәрде. Кече энеләрен баш ясап[2] җибәрде. Кече энеләренең хатыны хатыннарга баш булды. Агалары кече энеләренең баш булуына көнләп, әрләнеп[3], патша ул киявен артык ярата, дип,юлда аны үтермәкче булдылар.

Берничә көн киткәч, бер су янында кырык мең аскәр белән куышлар корып, ял итәргә берничә көнгә туктадылар. Кече энеләре бер куышка хатыны белән икәү генә яткан иде. Ике агасы, ике кылычны кара-каршы бәйләп:

— Ишек төбенә чык әле,— дип кычкырдылар.

Энеләре җитез генә чыгадыр исә, ишек янындагы кылычларга абынып, ике аягы да киселеп төште. Агалары, аскәрне торгызып, җыйдырып, энеләрен калдырып китәләр. Хатыны аяксыз ирен кочаклап җылый да, мылтыкларын, кылычларын аның янына күмеп, алдына икмәк белән су куеп калдырды.

Бу бичара, өч-дүрт көн ач торып аптырагач, аяклары яныннан мылтыкларын тапты.

Менә шул чакта бер таз кеше куян куып килә. Бу кеше шул куянны утырган төштән төзләп атып үтерде. Тазның казанында икәү пешереп, куян итен ашадылар.

Шул чакта килеп чыгадыр бер сукыр. Болар янына килеп сөйләште:

— Без өчәү бергә йөрик,— диде.

Берсе — сукыр, берсе — таз, берсе — аяксыз, җыелып, тазга аяксызны атландырып, өчәү киттеләр. Барып җиттеләр бер йортка. Аның эчендә бик матур бер унҗиде яшендәге кыз тора. Ул икән бер патшаның кызы. Ул кыздан сораштылар:

— Син нинди кыз буласың? — дип.

Кыз:

— Мин бер фәлән патшаның кызымын, мине дию пәрие урлап килде. Сез моннан качыгыз, качмасагыз, ул хәзер кайта, сезне үтерер,— диде.

Шул вакытта дию пәрие кайтып килә. Аяксызны күтәреп чыгарып

---

[1] *Аскәр* — гаскәр.

[2] *Баш ясау* — башлык итү.

[3] *Әрләнү* — гарьләнү.

ишек төбенә утырттылар. Ул төзләп торып, дию пәриен атып үтерде. Кыз шул вакытта аяксызны кочаклап:

— Син мине хатынлыкка ал,— диде.

— Сеңлем, син миңа туганым кебек якын, шуның өчен мин сине ала алмыйм,— диде аяксыз.

Шуннан соң болар дүртәү көн итә башладылар.

Бер көнне аскәр малайлары кырга атышка чыгалар. Үзләре ата белмиләр. Таз аяксызны күтәреп атышка алып барды. Малайлар анда атарга өйрәнәләр.

Өйдә калды таз һәм сеңелләре. Аяксыз киткәндә сеңлесенә:

— Миңа аш пешереп куй,— диде.

Аяксыз киткәннән соң, ишек төбенә килде бер шайтан карчыгы:

— Юан кылыч билдәме? — дип сорады ул.

— Юан кылыч билдә юк,— диде кыз.

— Хуҗакаең өйдәме? — диде карчык.

Шул вакытта таз куркуыннан урындык[1] астына кереп рагужа[2] белән ябынып ятты.

Шул вакытта шайтан карчыгы кереп:

— Башым бик бетләгән, башымны кара әле,— дип, килеп, кызның итәгенә ятып, канын эчеп китте.

Кыз, кансыз калып, суырылып төште, төссез калды.

Кич булды, аяксыз кайтты.

— Ну, сеңлем, син бик суырылган, нәрсә бар — әйт,— диде.

Кыз, карчыктан куркуыннан, агасына бер сүз дә әйтмәде. Сеңлесе әйтмәгәч, таздан сорады:

— Монда кем килде, әйт дөресен генә?

Таз да куркып:

— Бер кеше дә килмәде,— диде.

Иртә торгачтан аяксыз, сукырны өйдә калдырып, тазны үзе белән бергә алып китте:

— Син сукыр, күзең күрмәсә дә кем килгәнне, ни эшләгәнне колагың белән тыңлап тор,— диде.

Аяксыз белән таз киттеләр.

Болар киткәчтән шайтан карчыгы тагы ишек төбенә килде һәм кичәге кебек:

---

[1] *Урындык* — эскәмия.

[2] *Рагужа* (*урысча: рогожа*) — чыпта.

— Юан кылыч билдәме, хуҗакаең өйдәме? — диде.

Кыз:

— Юан кылыч билдә юк, хуҗакаем өйдә юк,— диде.

Сукыр да, куркуыннан, урындык астына кереп ятты. Шайтан карчыгы тагы кереп, кызның итәгенә ятып, тагы канын эчеп чыгып китте.

Агалары кайтып килделәр һәм сеңлесен күреп:

— Син, сеңлем, бүген тагы беткәнсең, сиңа ни булды? — диде.— Әллә өйдәгеләрне кайгыртасыңмы? — диде.— Кайгыртма, сеңлем, өйгә илтермен,— диде.

Шул вакытта сукырдан:

— Ниләр ишеттең, әйт? — дип сорады.

Сукыр:

— Берни дә ишетмәдем, беркем дә килмәде,— диде, әйтергә курыкты.

Иртә торгачтан үз урынына таз белән сукырны җибәреп, үзе, «бер хәл булырга кирәк» дип, өйдә калды. Аяксыз егет утырып торганда, карчык тагы килеп:

— Юан кылыч билдәме, хуҗакаең өйдәме? — диде.

Кыз тагы:

— Юан кылыч билдә юк, хуҗакаем өйдә юк,— диде.

Аяксыз да куркуыннан урындык астына кереп ятты. Карчык янә кереп, кызның итәгенә ятып, канын эчәргә тотынды. Шул вакытта аяксыз, урындык астыннан чыгып, карчыкның чәченнән эләктереп аладыр, үзен бик каты кыйный да кулын-аягын богаулап саладыр.

Шул вакытта таз белән сукыр кайтып өйгә керәләр. Кайтып керүгә сукыр белән таздан бик каты сорау алды:

— Сез миңа әйткән булсагыз, мин кич үк каладыр идем,— диде.

Шул вакытта тегеләр:

— Без бик курыкканнан әйтмәдек,— диделәр.

Шуннан соң аяксыз аларга:

— Давай, пычаклар алыгыз, без хәзер бу шайтан карчыгын суйыйк,— диде.

Шайтан карчыгы боларны күреп:

— Сез мине суймагыз, исән калдырыгыз, мин аяксызыгызны аяклы, күзсезегезне күзле, кызны әүвәлге кебек матур ясыйм,— диде.

Аяксыз:

— Иң элек сукырны күзле яса,— диде.

Карчык сукырны кабып йотып, чирек сәгать эчендә тотты, чирек сәгатьтән соң какырып җибәргән иде, сукыр күзле булып килеп төште. Сукырдан соң кызны йотып, чирек сәгатьтән соң какырып чыгарган иде, кыз әүвәлгедән дә матур булып чыкты. Соңра тазны йотып чыгарды, тазның башы чем-кара булып чыкты. Чират аяксызга җиткәч, аяксыз, куркып, сукырга, тазга һәм кызга әйтте:

— Әгәр дә мине бу мәлгунь карчык чыгармаса, сез моны пычак белән тураклап бетерегез, бөтен җилекләрен актарып, мине эзләгез,— диде.

Карчык аяксызны кабып йотты, вакыт чирек сәгать узды — аяксызны чыгармады. Бер сәгать үтте — һаман чыгармый. Шул вакыт шайтан карчыгын өчәүләп бик каты кыйный башладылар. Карчык һаман чыгармады. Чыгармагачтан өчесе дә өч пычак алып шайтан карчыгын суялар да, ачып, эченнән аяксызны эзлиләр — һичбер җиреннән таба алмадылар. Таба алмаганнан соң сукыр, аптырап, тышка чыгып карады, күрде: бер куакка бер карлыгач килеп кунды да башы белән ишарәт итеп:

— Аның башка җиреннән таба алмассыз, башындадыр, башын карагыз,— диде.

Сукыр, кереп, иптәшләренә:

— Балта белән башын ваклаек,— диде.

Башын ваклаганнар иде, эченнән аяклы көе егет килеп чыкты. Бар да бик кинәнделәр. Шуннан соң шайтан карчыгын чыгарып бер чокырга күмделәр.

Аннан соң болар киңәш итеп аерылырга булдылар.

Аяксыз:

— Кызны аласызмы? — диде.

Таз белән сукыр:

— Үзең ал,— диделәр.

Шуннан соң аяксыз таз белән сукырга ике мең тәңкә акча биреп, чыгарып җибәрде. Аяксыз белән кыз икәү генә калдылар. Соңра кызны, патшаның өенә илтеп, бер дә тимичә, патшага тапшырды.

Патша егеткә:

— Ну егет, син кызымны табып китердең, инде аны үзеңә ал,— диде.

Егет патшага:

— Солтаным, мин хәзер ала алмыйм, дүрт айга күрергә өйгә кайтып китәм,— диде.

Кыз, атасына чыгып:

— Ул әле никадәр кешене үтереп, михнәтләр күреп, мине коткарды, мин аңарга барам,— диде.

Егет, кызга:

— Ну, сеңлем, мин сине ничә айлар сакладым, алай булгач дүрт ай көт тә, мин сине килеп алырмын,— диде.

Шул вакытта патша моңарга бер бик яхшы аргамак бирде һәм кырык мең аскәр белән өенә озатты:

— Әгәр дә аргамак туктаса, син аңа сукма; китсә, туктатма,— диде.

Егет, аргамакка атланып, кырык мең аскәр белән юлга чыгып китте.

Юлда, туктатып, бер җиргә шалаш корып, аскәрне яткызды. Шул вакытта аргамак, егет янына килеп, аяк кырырга тотынды. «Ни булды икән?» — дип, егет, чыгып, аргамакка атланды. Аргамак, күтәрелеп китеп, алдагы агаларының кырык мең аскәре белән туктаган җиренә барып җитте. Егет тәрәзәдән барып караса, ни күрсен, хатыны агаларына пешекче булып йөридер. Шул вакытта хатыныннан кунарга керергә сорады:

— Абыстай, мине кунарга керт әле,— диде.

Абыстай аңа каршы:

— Сез нинди кеше буласыз? — диде.

— Мин шул илнең бер саилче булам,— диде.

— Әнә ике җизни ятканнар, алардан барып сора, кертсәләр, керерсең,— диде кыз.

Егет кунарга рөхсәт сорады. Аңарга:

— Кухняга барып ят,— диделәр.

Рөхсәт алганнан соң, егет кухняга килеп керде, кергәннән соң, егет абыстайдан:

— Ирең бармы? — дип сорады.

— Абзый, син минем иремне белмәссең, аны җизниләр үтереп калдырдылар.

Шул вакытта егет:

— Әгәр дә иреңне күрсәң, син танырсыңмы? Мин — ирең буламын,— диде.

Шуннан соң хатын моның янына килеп яхшырак караса, бу — ире булып чыгадыр. Ире икәнен белгәч, төрле ашамлык ашатып, соңыннан бер урынга икәүләп ятып йокладылар.

Сәгать биштә хатыны торып аш хәзерләмәкче булган иде, ире:

— Торырбыз әле, ят,— диде.

Сәгать җиде булгачтан, абысталары тәрәзәдән килеп карадылар, боларның кочаклашып ятканын күрделәр һәм ирләренә кайтып:

— Сеңлебез хәерче белән яткан,— диделәр.

Җизнәләре хатыннары белән кухняга килеп керделәр.

Җизнәсе хатынга:

— Ник хәерче белән ятасың? — диде.

Аяксыз аңарга каршы:

— Бу — минем хатыным. Менә мин хәзер бер җиргә китәм, әгәр дә аннан кайткачы хатынга тисәгез, барыгызны да бетерермен,— диде.

Егет, кухнядан чыгып аргамакка атланып, аскәре янына килеп, аскәргә әмер биреп, тегеләр янына алып барып, командасын туктатты һәм агаларын чакыртып китерде. Болардан:

— Сез кайдан буласыз? — диде.

Агалары:

— Без Сембер губернасы шул авылныкы булабыз,— диделәр.

Бу, агаларына каршы:

— Мин дә шул авылныкы булам,— диде.

Аның соңында аяксыз, хатынын үз янына китереп, агаларының хатыннарын бик каты әрләде:

— Сез, оятсызлар, минем хатынымны шулай пешекчелеккә куярга ярыймы? — диде.

Хәзер кырык кыз китертеп, егермесеннән кием җөйләтеп, егермесеннән юдырып, хатынына кидерде һәм агаларына:

— Карагыз, агайлар, минем хатыным сезнекеннән җиде өлеш артык бит,— диде.

Шуннан соң аяксыз бер юлдан, агалары бер юлдан кырыгар мең аскәр белән өйләренә кайтып киттеләр.

Агалары өйләренә кайтып кергәннән соң, аналары болардан:

— Кая минем кече улым? — диде.

Агалары аналарына:

— Ул юлда үлеп калды,— диделәр.

Икенче көнне кече энеләре кырык мең аскәр белән кайтып килде. Анасы белән кереп кул алыштылар. Агалары моны күреп:

— Әни, син ят кеше белән кул алыштың, улың юлда үлеп калган иде,— диделәр.

Моны ишеткәч, аяксыз сүзгә башлап:

— Әни, алар минем ике аягымны кисеп, юлда ташлап калдырдылар,— диде.

Анасы боларга:

— Бүген мәҗлес, муллалар чакырам, шунда бу эшне муллаларга сөйләп күрсәтербез, болар сине таныргa теләмиләр,— диде.

Муллалар килгәннән соң, эшне муллаларга сөйләделәр. Муллалар боларны хатыннар белән янәшә бастырып куеп, башларына тәлинкә куярга куштылар. Шул вакытта мулла:

— Югары бер ук җибәрәм, әгәр дә бу кеше сезнең кече туганыгыз булмаса, ул ук аның башына килеп төшәр,— диде.

Мулла укны атып җибәргән иде, ук, кече туганнарының тәлинкәсеннән төшеп, бер урында әйләнеп торадыр. Икенче укны җибәргән иде, олы агасының башына төшеп, тәлинкәне тишеп, агасын үтә тишеп чыкты. Икенче агасын янә ук тишеп үтерде. Соңыннан муллалар:

— Абыстай, инде бу — үзеңнең кече улың,— диделәр.

Шуннан соң агаларының хатыннарын ачу илә[1] үзенә пешекчелеккә алды. Агаларының кырык мең аскәрен кире өйләренә кайтарып җибәрә дә үзе шунда аскәр белән тора.

Әле дә патша кызы белән варис булып торадылар.

16. Җил-пәри әкияте

Әүвәле бер кешенең ике малае булган, аның олы малаеның хатыны булган. Шул малайның хатыны моның энесен бер дә яратмаган.

Бер тапкыр хатыны иренә әйткән:

— Мин авыртам, җибәр энеңне, миңа куян сөтен алып кайтсын.

Хатынның ире әйткән энесенә:

— Бар, энем, урманга.

Энесе әйтә:

— Ярар, абзый.

Мылтыгын ала да энесе, урманга китә. Урманга кергәч, мылтыкны кора. Мылтыкны коргач, куян эзләргә тотына. Куянны күрде дә төзи башлады мылтыкны.

Куян әйтә:

---

[1] *Илә* — белән.

— Зинһар, атма, мин сиңа сөтемне бирермен.
Бу кеше әйтә:
— Ярар алайса.
Куян сөтне бирә дә, бу кеше җиңгәсенә китереп биргән.
Җиңгәсе әйтә:
— Мин моның белән төзәлмим, миңа бүренең сөте кирәк.
Энесе әйтә:
— Ярар, китерербез.
Чыгып китә дә урманга керә. Урманда бүрене күргән дә, бүре моңар ялына:
— Зинһар, үтермә.
Бу кеше әйтә:
— Ярар.
Бүре сөтен бирә дә, бу егет җиңгәсенә китереп бирә. Җиңгәсе моңар:
— Мин моның белән авырудан төзәлмим, миңа төлкенең сөте кирәк.
Егет әйтә:
— Ярар, төлке сөтен китереп бирермен алайса,— дигән.
Иртә торган да тагы урманга чыгып киткән. Урманда төлкене тапкан да, төлке моңар ялына:
— Зинһар, үтермә, җибәр, егет, мин сиңа сөтемне бирермен,— дигән.
Бу кеше әйткән:
— Ярар алайса.
Төлке сөтен биргән дә, бу егет җиңгәсенә китереп биргән. Җиңгәсе әйтә:
— Миңа төлке сөте кирәк түгел, аюның сөте кирәк,— дигән.
Егет:
— Алайса аюның сөтен китереп бирермен,— дигән.
Егет чыгып киткән дә аюны күргән. Аю егеткә әйтә:
— Зинһар, үтермә, мин сиңа сөтемне бирермен,— дигән.
Аю егеткә сөтен биргән дә, егет җиңгәсенә китереп биргән.
Җиңгәсе әйтә:
— Миңа аюның сөте кирәк түгел, арысланның сөте кирәк,— дигән.
Егет иртә торган да чыгып киткән. Урманга кергәч, арысланны күргән. Арыслан егеткә ялына:
— Миңа, зинһар, тимә, дигән, мин сиңа сөтемне бирермен,— дигән.
Егет әйткән:

— Ярар алайса.

Арыслан егеткә сөтен биргән дә, егет җиңгәсенә алып кайтып биргән. Җиңгәсе әйткән:

— Мин моның белән дә төзәлмим. Моны бүре дә, төлке дә, аю да, арыслан да бер нишләтмәде, бар, син энеңне үтер,— дигән.

Моның абзыйсы энесен бау белән бәйләп, урманга илтеп ташлаган.

Энесе анда җылап торганда кинәт җил-давыл чыккан. Бу егет катына җил пәрие килгән. Җил-пәри егеткә әйткән:

— Миңа хезмәткә барасыңмы, юкмы, алайса мин сине монда үтерәм,— дигән.

Егет җил-пәригә әйткән:

— Мин барыбер монда үләм, барсам барырмын,— дигән.

Җил-пәри моның бавын чишә дә үзенә хезмәтчегә алып китә. Җил-пәринең йортына җиткәннәр дә өенә кергәннәр. Җил-пәри егеткә әйткән:

— Менә минем атларым, шуларны туйдырып, ашатып йөрерсең,— дигән. /.../[1]

Ат егеткә әйткән:

— Җитәр, кыйнама, бар, өйгә кер дә, кайрак алып, тарак алып, табак алып, минем янга чык,— дигән.

Егет кайракны, таракны, табакны алып чыга да ат янына китә. Ат егеткә әйтә:

— Өстемә менеп атлан.

Егет атланган да, чыгып киткәннәр.

Шул егетнең китәнен сизгәч, җил пәрие куа башлады. Җитәр-җитмәс булгач та, ат егеткә әйткән:

— Ташла кайракны,— дигән.

Егет кайракны ташлый да, кайрак бик зур тау булып кала. Җил пәрие җитәр-җитмәс булганда, ат егеткә әйткән:

— Ташла таракны,— дигән.

Егет ташлаган да таракны, тарак бик зур урман булып калган. Ат белән бик еракка киткәннәр. Җил пәрие җитәр-җитмәс булганда, ат егеткә әйткән:

— Ташла табакны.

Егет табакны ташлаган да, табак бик зур диңгез булып калган. Ат белән егет котылганнар.

---

[1] Бу урында текстның бер өлеше төшеп калган.— *Л.Ж.*



II

17. Таз әкияте

Борын заманда бар иде бер бабай. Аның өч улы бар иде. Бу малайлар аталары үлгәч, аталарыннан калган малны бүләргә тотындылар. Олы агалары энеләренә дөньяда тырышып көн итү турысында бераз үгет биргәч:

— Миңа ат белән арба булса, мин үз кәсебемне үзем итәрмен,—диде.

Икенчесе:

— Миңа әтидән калган көрәкне бирсәгез, мин пайдан чыгам,— диде.

Болар шулай алырга булганнан соң, Таз:

— Миңа ни калдырасыз? — диде.

Агалары:

— Сиңа бары бер бәйләм юкә кала,— диделәр.

Таз аңарга разый булды:

— Ярый, тик ятканчы мин аркан ишәрмен,— диде.

Олы агалары атны арбага җигеп, үзенең кәсебенә чыгып китте.

Икенчесе дә кулына көрәген тотып чыгып китте. Күп бара торгач, бу

бер бик зур байга очрады. Ул бай игенен җыйнап, җилбәрүгә[1] тора икән. Егетнең кулындагы көрәген күреп, сәүдәләшә башлый. «Күп сорыйсыңмы?» — дигән сүзгә егет:

— Көрәгем күмелгәнче бодай бирсәң, сатам,— диде.

Егет белән бай килешеп, егет җырлый-җырлый бодайны җилбәрә башлады һәм җилбәргән бодайны аерым бер җиргә өя башлады. Бай өелгән бодайларны күреп:

— Бу көрәк миңа бик кыйбатка төшә икән,— диде.

Егет:

— Мин бит сиңа көчләп сатмадым,— диде.

Егет ашлыкны җилбәреп бетерде дә, инде ничек алып кайтыйм, дип кайгыра башлады. Шул вакытта, бәхетенә каршы, олы абзасы ерак түгел юлдан аты-арбасы белән кайтып бара икән. Агасын чакырып алды да, бодайны төяп кайтып киттеләр. Бай бу эшләрне күреп, тик сызгырып калды.

Болар кайткач: «Без тырышып йөрибез, син тик ятасың»,— дип, Тазны әрләделәр.

Таз үзенә тигән юкәне алып, бер күл буена барып, бер агач төбендә ишә башлады. Күп вакыт үтми, судан бер пәри баласы чыгып, Таздан:

— Абзый, нишлисең? — дип сорады.

Таз:

— Күлне күккә асам,— диде.

Пәри баласы:

— Син әүвәл минем белән көрәшеп кара, аннан соң ексаң асарсың,— диде.

Тазның бу сүзгә бик кәефе килеп:

— Әле син минем белән сөйләшәсең, син әүвәл урманга бар да, анда минем карт бабам тора, аның белән көрәш, аны ексаң, аннан соң миңа килерсең,— диде.

Пәри баласы урманга барып кергән иде, каршысына аю килеп чыкты да, моны тотып кара канга батырганчы чигәләде. Пәри баласы ничек кирәк алай көчкә котылып, су төбенә төшеп, анасына:

— Ярый әле мин аның үзе белән көрәшмәдем, бөтенләй үтергән булыр иде, әле картаеп-бөкрәеп беткән бабасы да шундый чигәләде, көчкә котылдым,— диде.

---

[1] *Җилбәрү* — җилгәрү.

— Алай булгач, син аның белән йөгерешеп кара,— диде анасы.
Пәри баласы Таз янына барып, аңарга:
— Әйдә, йөгерешеп карыйк,— диде.
— Синең белән мин түгел, минем камыш арасында ята торган кечкенә бер энем бар, әүвәл аның белән йөгереш тә, аннан соң миңа килерсең,— диде Таз.
Пәри баласы камыш арасына барып:
— Әй, энем, чык, йөгерешеп карыйк,— дип кычкырган иде, камыш арасыннан бер куян чыгып йөгерә башлады.
Пәри баласы «Тукта, тукта», дип кычкыра-кычкыра куян артыннан чабып китте. Куян аның саен каты чаба башлады. Пәри баласы, хәле бетеп, анасына кайтып:
— Мине аның энесе дә җиткермәде,— диде.
— Болай да булмагач, алтмыш колачлы ала бияне күл тирәли өч кат күтәреп йөреп карасын,— диде анасы.
Пәри баласы Тазга чыгып әйткәч тә, Таз:
— Әүвәл үзең күтәреп йөреп кара, мин карап торыйм,— диде.
Пәри баласы бераз күтәреп йөрткәч, Таз:
— Әле син, энекәем, аны күтәреп йөртәсең икән, мин аны бот арасына кыстырып та йөртә алам,— дип, биянең өстенә атланып бер-ике мәртәбә сукты. Бия дулап чабып китте. Пәри баласы атны күреп кызганды, соңра: «Бияне үтерәсең»,— дип, бик ялынып сорагач, Таз туктады. Бия ап-ак күбеккә төшкән иде.
Пәри баласы анасына кереп:
— Ул күтәреп йөрү түгел, бот арасына гына кыстырып очырып йөрде,— диде.— Без аны ризаландырмасак, ул безнең күлебезне дә күккә асар, без аңарга үзе теләгәнчә алтын бирик.
Анасы да бу сүзгә разый булды. Пәри баласы чыгып, Тазга:
— Инде син безнең күлебезне асма, без сиңа үзең теләгәнчә алтын бирик,— диде.
Таз да разый булып, биленнән чишеп алып, капчыгын тотып торды. Пәри баласы алтын ташып, капчыкны тутырып бетергәч, Таз:
— Инде син моны өйгә алып кайтырга да булыш,— диде.
Пәри баласы белән икәү бергә юлда капчыкны күтәреп барганда, пәри баласы Тазга:
— Син һавадагы карганы тота аласыңмы? — диде.
— Аны тотуы бернәрсә дә түгел,— диде Таз.

Шул вакыт Таз аяк астында үлеп ята торган карганы теге күрмәгәндә генә алды да, һавага кулын сузып: «Менә тоттым»,— дип, карганы күрсәтте.

Пәри баласы уйга төшеп: «Моның кулыннан инде ничек итеп котылырга кирәк, бу мине дә харап итәр»,— диде.

Болар кайтып өйгә кергәч, җиңгәләренә:

— Кунак килде, аш пешерегез,— дигәч, җиңгәсе:

— Ни пешерим, олы абыеңның башынмы, әллә кечкенә абыеңның түшенме? — диде.

Таз, пәри баласына күрсәтеп:

— Менә моның башын гына пешерик тә, шул җитәр,— диде.

Пәри баласы чыгып качты. Таз аның артыннан: «Тукта әле»,— дип никадәр кычкырса да, пәри баласы артына әйләнеп карамый, көчкә күлгә төшеп, анасына:

— Үземнең башымны пешереп ашый яздылар,— диде.

Тазның алып кайткан алтыннары белән өч туган өчесе дә яхшы йортлар салып, куанышып көн иттеләр.

18. Беләк буе кайрак

Бар иде борын-борын заманда бер карт белән карчык. Боларның көнкүрешләре бик фәкыйрь иде. Өч улларыннан кече уллары Таз иде.

Бу карт белән карчык, дөньяда күп торганнан соң, бердән бер көнне дөньядан киттеләр. Инде бу өч туган үзләре генә калдылар. Боларның өчесенә бар иде бер киемнәре. Берсе сорашырга чыккан чакта калганнары киемсез утыралар иде. Үзләре суксалар тимер өзәрлек көчлеләр иде.

Бердән бер көнне агалары сорашырга чыгып киткәннән соң, Таз берүзе генә өйдә калып уйларга тотынды. Үз-үзенә: «Без нинди таза егетләр, әгәр дә аерым-аерым торсак, һәркайсыбыз үз-үзебезгә тырышыр идек»,— диде һәм агаларына, кайткач ук, бу сүзләрне сөйләде. Агалары моңа:

— Әй, Таз, дуңгыз, без ни бүлик, атабыздан ни калды, күрәсең, өчебезгә бары бер киемебез бар, инде аны өчкә бүлеп барыбыз да киемсез калаекмы? — диделәр.

Таз ике-өч көн агаларына тынычлык бирмәгәчтән соң, агалары: «Бу Тазның башка чыгасы килә икән»,— дип, бердән бер көнне мулла-мәзин чакырып аш хәзерләп, аш тәмам булганнан соң, мулла-мәзингә үзләре теләкләрен әйтеп:

— Менә безнең энекәшебезнең башка чыгасы килә, инде сез безгә безнең малыбызны бүлеп бирсәгез иде,— диделәр.

Хәзрәтләр:

— Ярый, бүлеп бирик, нинди малларыгыз бар, әйтегез,— диделәр.

Болар:

— Туктагыз әле, без эзләп керик, безнең атабыздан калган бернәрсәбез дә юк,— дип, чыгып киттеләр.

Озак эзли торгач, ишегалдыннан адәм буе алабута арасыннан таптылар, ди, бер агач көрәк.

— Менә безнең малыбыз,— дип, хәзрәтләр алдына китереп куйдылар да тагы эзләргә чыгып киттеләр.

Озак эзли торгач, өйалдыннан таптылар бер бәйләм юкә, аны да китереп көрәк янына хәзрәтләр алдына куйдылар. Янәдән, берәр нәрсә тапмабыз микән дип, эзләргә тотындылар. Озак эзли торгач, Таз пич астыннан бер беләк буе кайрак өстерәп чыгарып, янә көрәк белән мунчала янына китереп куйды һәм хәзрәтләргә әйтте:

— Безнең башка малыбыз юк, безгә шуларны бүлеп бирсәгез иде,— диде.

Хәзрәт малны бүләргә тотынып, иң зурысына солабаш юкәне, уртанчысына көрәкне, Тазга да беләк буе кайракны бирде.

Болар хәзрәтләр биргән нәрсәләргә разый булып, һәркайсысы үзенә тигән өлешне алып, базарга сатарга дип чыгып киттеләр. Өчесе дә: «Базарда сатып, бераз тамагыбызны туйдырырбыз»,— дип уйладылар. Базарга алып чыксалар, солабаш юкәгә ике тиен, өч тиен бирәләр. Көрәкне сораган кеше дә юк, кайракка күз салган кеше дә юк.

Бу туганнарның өлкәне: «Юкәне ике-өч тиенгә сатканчы, аркан итеп ишеп сатам, ун-унбиш тиен акча алырмын»,— дип, ерак та түгел бер су буена барып, тирәк ботагына мунчаласын асып, аркан ишәргә тотынды. Ишеп яткан вакытта күлдән ниндидер бер адәм сурәтле үзе бер карыш, сакалы биш карыш бер нәрсә килеп чыкты да, егетнең янына килеп:

— Әй, егет, нишлисең? Алла куәт бирсен,— диде.

Егет тә аңа каршы:

— Сәламәт бул, сине монда бирсен,— диде һәм,— бу бауны ишеп, күлегезне күккә асмакчы булам,— диде.

Егеттән бу сүзне ишеткәч, теге нәрсә, күлгә төшеп китеп, ата-анасына кайтып:

— Харап булдык, бер адәми зат килгән, күлебезне күккә асмакчы була. Инде бер-беребездән аерылабыз икән,— диде.

Ата-анасы бу сүзләрне ишеткәч, моңа:

— Бар, син бер кат күргән кеше инде, без аны күрергә дә куркабыз, ул безне күлсез калдыра күрмәсен, ни сораса, шуны бирәбез,— диделәр.

Бу, чыгып, яңадан егеткә килеп:

— Әй, егет, инде син безне бу юлга калдыр, күлебезне асма, минем атам-анам бар, ни сорасаң шуны бирәбез,— диде.

Егет:

— Минә минем башымда киез кәләпүш бар, шуны тутырганчы алтын бирсәгез, калдырам,— диде.

Күлнең көеге күлгә төшеп китеп, хәзинә чыгармакчы була. Ул төшеп киткәч тә, егет кәләпүшен салып, төбен пәке белән тишеп биләндә булган капчыгын чишеп җиргә күмеп куйды да капчык авызына тәлпәген[1] куйды. Тегеләр өч агай-эне икән, бик ашыгып алтын ташырга тотындылар, чыгаралар да тәлпәккә салалар. Тәлпәктәге алтын капчыкка агып тора.

Бер талай[2] заманнар ташыганнан соң, боларның хәзинәләре дә бетте. Егетнең капчык белән тәлпәге дә тулды. Шуннан соң су җәнлекләре күлгә төшеп киттеләр. Егет, тәлпәкне читкә алып куеп, капчыгын бик авырлык белән тартып чыгарды, авызын бик ныклап мунчала белән бәйләп куйды. Инде алып кайтыр өчен күтәреп караса, капчыкны күтәрсә, тәлпәкне күтәрә алмый, тәлпәкне күтәрсә, капчыкны күтәрә алмый. Шуннан, аптырап: «Ни булса да булыр, бераз сабыр итәргә кирәк»,— дип, яңадан бавын ишәргә тотынды. Күл җәнлекләре: «Адәми затка ышаныч юк, бар әле, чыгып кара, нишли икән, алып китте микән»,— дигәннәр иде. Бу чыгып караса, күрә: егет һаман бавын ишеп тора.

— Әй, егет, нигә кайтмыйсың инде? — дигәч, егет:

— Күлегезне күккә асам, минә минем бер капчыкта бераз нәрсәм бар, шуны өемә кадәр күтәреп илт тә, китәм,— диде.

Бу җәнлек шул сәгать капчык астына кереп күтәреп, боларның өенә киттеләр.

Җәнлекне ишек төбендә калдырып, үзе кереп, хатынына:

---

[1] *Тәлпәк* — түбәтәй.

[2] *Бер талай* — берникадәр.

— Хатын, мин бернәрсә алып кайттым, син курыкма. Мин сиңа: «Кунак алып кайттым, казан ас!» — дип өч мәртәбә әйтермен, син өченче мәртәбә әйткәндә: «Нәрсә пешерим?» — дип сора,— диде һәм, өеннән чыгып, җәнлек белән капчыкны алып кереп утырдылар. Керүгә хуҗа:

— Йә хатын, ни эшләп торасың, мин кунак алып килдем, казан ас! — дип өч мәртәбә кычкырган иде, хатын:

— Ни нәрсә пешерим? — диде.

Ире аңа каршы:

— Бар, кара әнә келәткә, олы диюнең башы булмаса, кече диюнең түше бардыр,— дигән иде, җәнлек: «Боларның ашаганнары дию икән, мин дә бит дию нәселеннән, мине дә ашарлар»,— дип, өйнең бер почмагын күтәреп, йөгереп күленә китте.

Өй хуҗасы, артыннан чыгып: «Тукта әле»,— дип кычкырып, кул изәп караса да, җәнлек, кая ул туктау, артына да әйләнеп карамады.

Соңра хуҗа, алтыннарын акчага әйләндереп, атасыннан калган өйне җимертеп, яңа өйләр салдырып, бөтенләй башка тормыш белән тора башлады.

Уртанчысы агасының бу эшен күреп, көнләшеп, үзенең көрәгeн җилкәсенә күтәреп, күзе караган җиргә чыгып китте. Бик озак вакытлар барганнан соң, бер тауның башына менде һәм күрде: бер карт, учлары белән өреп, бодай арулап[1] ятадыр. Бу да бабай янына барып, сәлам биреп бабай белән күреште. Көрәкне бер читкә яшереп калдырды, бабайга күрсәтмәде.

Бабай, сәламен алып:

— Әй, егет, каян киләсең, кая китәсең? — диде.

— Әй, бабай, улы юк кешегә ул булам, кызы юк кешегә кыз булам,— диде егет.

Бабай егеткә:

— Әй, улым, егет кеше кыз була алмас, инде менә миңа бер елга кеше кирәк иде, мин ашлык чәчәм, игенем бик уңа, аны аруларга чарасын таба алмыйм, син күпме сорыйсың? — диде.

— Егерме биш үгез тартымы кадәр бодай бирерсең,— диде.

Бабай егетнең сораганына күнеп, икәүләшеп ашлык аруларга тотындылар. Бераз арулагач, бабай:

---

[1] *Арулау* — чистарту.

— Инде мин аш пешерәем,— дип өйгә кайтып китте.

Егет шул вакыт яшереп куйган җиреннән көрәкне алып, көрәк белән ашлыкны бик яхшы җил килгәндә бер минутта тау кадәр арулап алды. Бабай аш булдырып чыкса, ни күзе белән күрсен, егет бер кисәк вакытта ашлык арулап куйган.

Бабай:

— Ничек аруладың? — дип сорагач, егет, кулындагы көрәкне күрсәтеп:

— Менә минем машинам бар, мин аның белән эшләдем,— диде.

Бабай көрәкне күреп:

— Син, егет, моны миңа сат, күпме сорыйсың? — диде.

— Егерме биш үгез тартымы бодай бир,— диде егет.

Карт күпсенсә дә, бик кирәк булганлыктан разый булып, бодайны бирде.

Соңра егет көрәк өчен егерме биш үгез тартымы бодай алып, базарга барып, туксан җидешәр тиеннән сатып, авылына кайтып, агасы кебек бер йорт урыны алып, яхшы өйләр салдырып, яхшы коймалар койдырып, авылның беренче кешеләреннән булып тора башлады.

Инде Таз, агаларының болай баеп китүләрен күреп, үзенең бик фәкыйрьлегеннән зарланып, беләк буе кайрагын җилкәсенә салып, бу да күзе караган җиргә башын бер якка салып чыгып китте. Шул китүдән ничә көннәр, ничә айлар бара торгачтын, очрады бер бик зур йортка. Йортның тәрәзәсеннән барып караса, өйнең эчендә бер кеше дә күрмәде, карыны бик ачканлыктан, берәр нәрсә тапмаммы икән дип, Аллага тапшырып, өйнең эченә кереп китте. Эчендә учакта ут янып тора, казанда һәртөрле җәнлек ите пешеп тора иде, ләкин ашарга кеше юк. Таз бу итләрне күргәч, кайракны бер якка куеп, табакка итләрне салып, бик һәйбәтләп тамакны туйдырды.

Шуннан ишеккә таба барып караса, ишек башында бер сәндерә күрде, менеп караса, сәндерә тулы ястык, мендәр, төрле-төрле киемнәр күрде. Ни булса да булыр дип, кайракны янына алып, сәндерәгә утырды. Бераз гына яшеренеп торган иде, ишектән сөйләнә-сөйләнә кемдер килеп керде. Шул утырган җиреннән бер яктан кергән кешеләрне санап торса, барысы кырык бер кеше булды. Болар керделәр дә, идәнгә ашъяулык җәеп, үзләре тирә-ягына утырып беткәннән соң, араларындагы аксакаллары:

— Йә, егетләр, кем нәрсә алып кайтты, чыгарып куегыз,— дигән иде, бар да үзләренең урлап алып кайткан нәрсәләрен чыгарып куйдылар.

Алларында булган нәрсәләрне, кем күпме алып кайтты икән дип, карап йөргәндә, араларында берсе һәрвакыт аз алып кайта икән, моңа:

— Бүген дә ник аз алып кайттың, син һәрвакыт аз алып кайтасың, әллә урлый алмыйсың, әллә сатып кайтасың,— дип, аны орышырга тотынды.

Моны күреп, Таз, ни булса да булыр дип, Аллага тапшырып, кайракны алып аксакалга төзәп ыргыткан иде, нәкъ аның муенына барып тиде дә, аксакал егылып шундук җан бирде. Калганнары бу хикмәтне күреп, моны Таз бәрде дип белмичә, Алла сукты дип белеп: «Безнең болай кеше рәнҗетеп йөрүебез һич ярый торган эш түгел икән»,— дип, бар алып кайткан нәрсәләрен урыннарында калдырып, бар да өйдән ташлап чыгып киттеләр.

Таз болар киткәннән соң, әйләнеп кермәсләр микән дип берәр сәгать торганнан соң, һичбере килеп кермәгәч, урыныннан төшеп, ач карынын, казанда калган итне ашап, тук итте.

Шуннан соң эскәтердә калган бар алтын-көмешне җыеп алып, атайдан калган мирас дип, кайрагын биленә кыстырып, кайтырга чыгып китте. Ничә көннәр, ничә төннәр дигәндә үз шәһәренә кайтып җитеп, яхшы җирдән кыз әйттереп[1], бу да яхшы йортлар, матур өйләр салдырып, агалары кебек рәхәт тора башлады.

19. Салтыкай

Борын заманда бер картның өч улы бар иде. Үзе яшь чакта ярлылыгы зур иде, тик үзенең тырышлыгы аркасында карчыгы белән көне-төне эшләп, балаларын үстерделәр.

Малайлар үсеп җиткәч тә, аталары боларны һөнәргә өйрәтү исәбе белән, төрле нәрсәләргә яраклы агачлар алып кайтыгыз дип, урманга куып җибәрде. Оланнарның кечкенәсе Салтыкай иде. Моны никадәр кыстап караса да, Салтыкай бармады. Атасының «Ник бармыйсың, сиңа һөнәр кирәкмимени?» дигән сүзенә каршы Салтыкай:

— Мин андый авыр эшләргә өйрәнер хәлем юк, мин ансатрак берәр нәрсә өйрәнәсем килә,— диде.

[1] *Кыз әйттерү* — кыз ярәшү.

Атасы никадәр тырышып караса да тыңлата алмады.

Үсеп буйга җиткәннән соң Салтыкай аннан-моннан урлап, нәрсәләр алып кайта башлады. Атасы, бу эшкә кырын күз белән караганлыктан, Салтыкайның бу эшен бер дә ошатмады вә барып, Салтыкай өстеннән үзе аксакалга зарланды.

Аксакал:

— Салтыкайның бу эшен тикшереп карармын, үзем сынармын, аннан соң хөкем итәрмен, болай торып мин аның хәлен белмим, иртәгә аны минем яныма җибәр,— диде.

Карт кайтып, Салтыкайга:

— Иртәгә сине аксакал чакыра,— диде.

Салтыкай тыныч кына иттереп:

— Ярар, барып сөйләшеп карармын,— диде.

Иртә торуга Салтыкай акрын гына киенеп, пошмыйча гына атлап, аксакалга китте. Барып күренүгә, аксакал моңа:

— Син юк нәрсә белән шаяртып, урлаштырып йөрисең икән, бу эшең бер дә ярамас, моннан яхшылык белән тыел, әлегә кадәр мин үзем күргәнем юк, ишетү белән хөкем итә алмыйм, әгәр хәлеңнән килсә, менә минем өч атым бар, шуларны урлап кара да, соңра хөкем итәрмен,— диде.

Салтыкай:

— Бик яхшы, карап карарбыз,— диде дә кайтып китте.

Кич белән Салтыкай аксакалга барырга дип юлга чыккан иде, юлда барганда бер үләккә очрады. Салтыкай аны алып барып, аксакалның тәрәзәсенә сөяп куйды.

Аксакал бу чакта, килер инде дип, көтеп торадыр иде. Тәрәзәгә таба караса, бер шәүлә күрде, бу Салтыкай булырга кирәк дип, алтатардан атып ташлады. Атып җибәрүгә үле әйләнеп төште. Соңра аксакал үзенең ялчысы белән чыгып, кеше белмәгән борын, кая да булса илтеп ташларга кирәк дип, икәүләшеп үлене кырга күмәргә алып киттеләр.

Болар китүгә, Салтыкай, йортка кереп өч атны җигеп, капканы ачып чанасына утырды да аксакалның хатынына:

— Атларыгызны алып китәм,— диде.

Тегеләр бик арып кайттылар да ятып йокладылар.

Иртә торып абзарга чыгып карасалар, атлардан җилләр исә. Аксакал базарга чыгып, Салтыкайдан сорашты.

Салтыкай:

— Үзең урларга кушкач, мин урладым,— диде.

Аксакал бер сүз дә әйтә алмады. Салтыкай бу юлдан уңып, өч мең тәңкәне кесәгә салып куйды.

Аксакал уйланып торды да:

— Бу көн янә барып алтыннарымны урла,— диде.

Салтыкай үзалдына бераз уйланып йөрде дә, базардан зур бер чабата алып, астына сумала койды. Өенә кайткач, үзенең иске киемнәрен киеп, хәерче капчыгын асып, урам буена чыгып китте. Бераз йөри торгач, аксакал өенә килеп җитеп, ни булса булыр дип, батырланып кереп китте. Бай бу чакта алтыннарын идәнгә тездереп санап ятадыр иде. Салтыкай кереп исәнләшеп:

— Бик өшедем, бераз өй сәкегездә җылынып чыгыйм әле,— дип, почмак ягына барып чыкты.

Анда Салтыкай бераз кулларын җылытып, хатын-кыз белән сөйләшеп, янә түргә килеп чыкты да аксакалның тирәсендә әйләнеп йөри башлады. Бай моның алтыннарны алмаганын күреп, алтыннар арасында йөрүенә исе китмәде. Салтыкай бу вакыт чабата астына байтак кына алтыннарны ябыштырган иде. Соңра исәнләшеп чыгып китте.

Бай иртә торып, төнлә килеп урламады микән дип, санап караса — берничә алтын юк. Базарга чыгып янә Салтыкай белән күрешеп, аңардан сорады.

Салтыкай:

— Мин алдым,— диде.

Инде Салтыкай баеды, туганнарын да бу эшкә өнди башлады, аларга:

— Сез җүләрләр, шундый ансат һөнәр бар чакта бу кадәр азапланып көн күрү акылга сыя торган эш түгел,— диде.

Ләкин агалары бу эшкә колак асмадылар, һәм аларның Салтыкай кадәр хәйләгә осталыклары да юк иде.

Берничә атналар үткәннән соң, байның хатыны аталарына кунакка утырмага кайтып китте. Аксакал үзе генә калгач, эче поша башлады. Бервакыт Салтыкайны күреп:

— Инде, энем, калган алтыннарымны да урла,— диде.

Салтыкай:

— Бик яхшы, карарбыз,— диде.

Салтыкай бер юлчы сурәтенә кереп, аксакалдан җылынып чыгарга рөхсәт сорады. Аксакал кертеп, ашарга-эчәргә бирде. Кич булгач:

— Миңа иптәш булырсың, бүген бездә аулак өй, хатыным кунакта, миңа күңелсез, бергә сөйләшеп ятарбыз,— диде.

Салтыкай ятты. Бай да идәнгә урын түшәп, алтын сандыгын баш очына куеп ятты. Салтыкай белән карт аннан-моннан бераз сөйләшеп яттылар, соңра сүз иярә сүз чыгып, бай Салтыкайга:

— Бәлки син берәр әкият белә торгансың, мин бик әкият тыңларга яратам,— диде.

Салтыкай:

— Беләм, беләм, дөньядагы әкият капчыгы — мин инде,— дип, картка әкият сөйләргә тотынды.

Карт бераз тыңлап яткач та черемли башлады. Салтыкай бераз сөйләгәч тә:

— Тыңлыйсыңмы? — диде.

Бай, тыңлыйм дип ята торгач, йокыга китте. Салтыкай сәндерәдән төшеп, йоклый микән дип барып карады да, урынына менеп ятып, янә сөйләргә тотынды. Бераздан соң йортка чыгып, бер кискә алып кереп, үз урынына яткырды да каплап куйды. Үзе алтын сандыгын алып чыкты.

Бай иртә торып караса — сандыгы юк, барып караса — юлчы ята. Бу урлагандыр дип, ачу белән пычак кадап караган иде, каты бер нәрсә тоелды. Өстен ачып караса, утын кисәге ятадыр иде.

Соңра бай, янә Салтыкай белән күрешеп:

— Инде хатынымны да урла, башка нәрсәм калмады,— диде.

Беркөн аксакал ат җигеп хатынын утыртып, кырга чыгып китте. Салтыкай да алар артыннан барды. Бер урман буйлап барганда болар килеп җиткәндә генә Салтыкай аяклары белән агач ботагына асылынып йөзтүбән торадыр иде. Бай бераз игеннәр карап туктап торган заманда Салтыкай тагы алгарак барып, боларның юл өстенә янә асылынды. Бай күреп:

— Бу Ходай органның башына җиткәннәр икән. Әллә кайчан шулай кирәк иде. Без тегендә дә күрдек бит, анысы да ул иде. Бу ялгандыр. Инде моңардан котылырбыз, чынлап белеп кайтыйк,— дип, арбасыннан төшеп, үзе җәяү генә арттагысын карарга дип киткән иде, Салтыкай төшеп, хатынын да урлап китте.

Шулай итеп, Салтыкайны хөкем итәсе аксакал үзе хур булып калды.

20. Патша улы һәм дию

Бердән берәү бар иде, бер патша бар иде. Ул патша улын өйләндерде. Аның хатыны бик усал булды, көне-төне хурлаша иде. Егет чыдый алмыйча юлга китте.

Юлда барганда бер коега туры килде. Төннең уртасы иде, айның унбишенче кичәсе иде. Коега карады: айның шәүләсе күренә. Борылып өенә кайтты, хатыны белән сөйләште:

— Кое төбендә бер җәүһәр күрдем, ди, әйдә икәү барып алыйк,—ди.

Икәү киттеләр. Кое янына җиткәч, егет арканга бәйләнә башлады. Хатын әйтте:

— Үзем төшеп алыйм.

Хатынын бәйләде, төшереп җибәрде. Хатын төшеп китте. Егет шул вакытта куанды, хатыннан котылдым, дип.

Кое төбендә җитмеш ел яшәгән дию тора иде, ул, теге хатыннан куркып, коедан чыкты.

Егеткә әйтте:

— Ник хатыныңны җибәрдең минем яныма? — ди.

Егет әйтте:

— Ник түзәлмәдең бер көнгә? Мин түздем унике ел.

Дию әйтте егеткә:

— Әшнә булыйк.

Дию белән егет юл белән киттеләр, бер шәһәргә җиттеләр.

Дию әйтте:

— Мин чиркәүләренә барып, калакуннарын[1] сугамын. Шул чакта син аларга әйт: «Чиркәвегезгә зин[2] ияләшкән»,— диген. Алар шул чакта бер багучы эзләрләр, син: «Мин багучы буламын,— диген,— мин ул зинне куалармын»,— диген. Син алардан мең тәңкә акча сора. Алар биргәч, син миңа килеп әйтерсең,— ди.

Дию боларның чиркәүләренә керде, калакуннарын сугарга тотынды. Егет сөйләшеп куйганча эш итте. Шәһәр кешеләре багучы эзләргә тотындылар. Бу егетне таптылар да:

— Егет, шул зинне безнең чиркәүдән куала,— диләр.

— Куалыймын, тик ике мең тәңкә акча бирегез,— диде.

---

[1] *Калакун* (*урысча: колокол*) — кыңгырау.

[2] *Зин* — җен.

Алар акчаны биргәч, егет диюгә барды, акчаларын алдым дип. Шуннан соң алар ул шәһәрдән чыгып киттеләр.

Дию әйтте егеткә:

— Ярар, сиңа акча таптым әле,— диде.

Егет, дию белән бәхилләшеп, өенә кайтып китте.

Дию, янә бер шәһәргә кереп, чиркәүләргә суга башлады. Болар, шәһәргә сугыш килгән дип куркып, төрле якка телеграм суктылар. Бу егетнең багучылык хәбәрен ишетеп, аны да чакыртып алдылар.

Егет шул вакытта, диюнең кыюлыгыннан куркып, уйга калды. Алай булса да барып керде диюнең янына.

Егет әйтте:

— Теге хатын коедан чыккан, сине эзләп йөри,— ди.

Дию әйтте:

— Мин китәм Каф тавының артына, син болардан ике мең тәңкә акча ал инде,— ди.

Дию китте. Егет, акчаны алып, үзенең шәһәренә кайтты, бик һәйбәт хатын алды, бик яхшы итеп торалар.

Төнә[1] бардым, бүген килдем[2], әле дә шулай торалар. Туйларында да булдым.

21. Юсып Минулин әкияте

Әүвәл заманда булган бер Юсып. Ул булган солдат. Егерме бер ел солдатта, дүрт ел (...)[3] хезмәт иткәчтән, срогы тулып өенә кайтып китте.

Юл белән барганда очрады бер баганага, ул баганага язган: «Кем дә кем бу юлдан китсә, аны үтерәләр»,— дип. Юсып, ни булса да булыр дип, шул юл белән китте.

Барып бер зур йортка керде, ул йортта бер карчык егерме адәмгә аш пешереп торадыр иде. Карчык Юсыпны каршы алып ашатты да, Юсып урындыкка[4] менеп ятты.

Кичкырын егерме разбойник, бер атаман кайтып керделәр.

Атаман карчыктан:

— Урындыкта кем ята? — дип сорады.

---

[1] *Төнә* — кичә.
[2] *Килү* — кайту.
[3] Биредә бер сүз төшеп калган.— *Л.Ж.*
[4] *Урындык* — эскәмия.

Карчык:
— Бер солдат килеп керде дә, ашатып-эчереп яткыздым,— диде.
Соңра атаман Юсыпка кычкырып:
— Нишләп ятасың, разбойниклар янына барып бас! — диде.
Юсып куркуыннан караклар янына барып басты.
Атаман аңарга:
— Син кеше ни биргәнне карап тор, син дә шуны эшләрсең,— диде.
Разбойниклар бар да кеше үтереп алган акчаларын атаманга бирделәр. Юсып боларны карап торды. Араларыннан берсе акча китермәгән иде, шуның өчен атаман аның башын чабып өзеп төшерде.
Соңра Юсып разбойниклар белән бергә өстәлгә барып утырдылар. Атаман барысына да берәр чәшкә аракы өләшеп чыкты. Ашаганнан-эчкәннән соң, бар да урыннарына барып яттылар.
Иртә торгачтан, янә чәй эчүгә утырдылар. Атаман тагы разбойникларга берәр чәшкә аракы бирде. Юсыпка ул бер кылыч китереп биреп:
— Менә син бу кылыч белән кеше үтереп, миңа акча китереп бирерсең,— диде.
Юсып бу сүзләрне ишеткәч: «Мин гомеремдә тавык та үтергәнем юк, ничек итеп кеше үтерермен икән»,— дип, бик курыкты.
Ашагач-эчкәч бар да төрле урынга чыгып киттеләр. Юсып та барып бер агач төбенә утырды да бик каты елады: «Әлегә хәтле мин тавык аягын да сындырганым юк иде, инде ничек итеп кеше үтерермен»,— диде. Юсыпның үзенең унбиш тәңкә акчасы бар иде. Юсып инде: «Болай буш кайтып булмас, барыбер үтерерләр»,— дип, үзенең биш тәңкә акчасын алып, калган ун тәңкәсен эчкә салып куйды.
Кичкырын янә бар да кайтып, сәгать җидедә атаман барын да тезде дә:
— Ни алып кайттыгыз, акчаларыгызны чыгарыгыз,— дип, өсләренә кычкырды.
Атаман уң кырыйдан акча җыеп киләдер иде, кайсы ун тәңкә, кайсы биш тәңкә акча чыгарып бирделәр.
Юсыпка килеп җиткәч:
— Ну, багаек, бу күпме алып кайткандыр,— диде.
Юсып шул вакытта биш тәңкә акчасын чыгарып бирде. Атаман аңарга:
— Менә бу ярый, бүген биш тәңкә китергән, иртәгә ул ун тәңкә китерер,— диде.
Барының да акчаларын алып бетергәннән соң атаман туздырып җибәрде дә, болар бар да өстәл янына килеп утырдылар. Ашагач-эчкәч, бар да үз урыннарына барып яттылар.

Иртә торгач, ашап-эчеп, үз юлларына чыгып киттеләр. Бер урманга кереп, зур аланга егермеләп бергә утырдылар. Шул вакыт Юсып иптәшләреннән:

— Бу атаман һәр көнне шулай үтерәме? — дип сорады.

Иптәшләре аңа каршы:

— Әйе, һәр көнне шулай үтереп тора, без кырыклар бар идек, инде бары егерме генә калдык,— дип сөйләделәр.— Берәм-берәм барыбызны да үтереп бетереп киләдер,— диделәр.

Юсып бу сүзләрне тыңлагачтын:

— Әйдәгез, бүген беребез дә акча бирмик тә, барыбыз да бер сүзле булып, үзенең башын кисик,— диде.

Иптәшләре бар да бу сүзгә риза булдылар.

Кич булды, кайтып керделәр.

Атаман тагы:

— Тезелегез! — диде. Болар килеп тезелделәр дә, атаман: — Бүген күпме эшләдегез, акчаларыгызны чыгарыгыз,— диде.

Шул вакытта Юсып кылычын чыгарды да:

— Менә без күпме алып кайттык,— дип, атаманның башын чабып өзде.

Шуннан соң атаманны чыгарып бер чокырга ташладылар да, өстенә бер-ике олау тирес түгеп, таш белән бастырып куйдылар.

Шуннан соң иптәшләре, Юсыпка күп рәхмәтләр укып, төн ката бергә күңел ачып утырдылар.

Иртә торгачтын иптәшләре:

— Инде безгә бер атаман кирәк, кемне сайлыйбыз? — диделәр.

Бар да берсүздән:

— Бу усал кеше барын да булдырыр,— дип, Юсыпны атаманлыкка сайлап, унике сарайның ачкычын Юсыпка тапшырдылар һәм: — Бу уң яктагы кырый амбарның ишеген ачма,— диделәр.

Юсып, баш булгачтын, разбойникларны ике атнага ял итәргә чыгарып җибәрде:

— Миңа бер тиен акча да, бернәрсә дә кирәкми,— диде.

Разбойниклар чыгып киткәннән соң Юсып: «Ник болар бу амбарны ачарга кушмадылар икән, монда бер хикмәт бардыр»,— дип, сарайны барып ачкан иде, ни күзе белән күрсен, сарайда патшаның унҗиде яшендәге кызын аягын-кулын богаулап салганнар да ашарга бары коры әпәй генә куйганнар.



Бу кыз, Юсыпны күргә:

— Зинһар, абзый, минем кулымдагы богауларны алып җибәреп, үземә бер-ике чәшкә чәй китереп эчерсәнә,— диде.

Юсып бу кызны ычкындырып, үзенең бүлмәсенә алып кайтты да, ашатып-эчереп, ничек эләккәнлеген сораша башлады. Кыз сөйләргә башлап:

— Мин фәлән патшаның кызымын, мине күлгә коенырга төшкән җиремнән бер разбойник алып килеп, бу сарайга япты. Инде минем килгәнемә бер ел булды, зинһар өчен, инде син мине ташлама, ярдәм ит,— диде.

Юсып:

— Аллаһ теләсә, мин сине ташламам, ничек тә булса мин сине атаңа илтеп тапшырырмын, кайгырма,— диде.

Шул сүзләрне ишеткәннән соң, кыз шатлыгыннан кулындагы кулчасын[1] Юсыпка салып бирде дә, кочакланышып, бик озак сөйләшеп тордылар.

Юсып:

— Инде хәзер ашар-эчәр вакыт җитә, разбойниклар кайтырлар, син тагы сараеңа барып ятып тор,— дип, кызны яңадан сараена илтеп бикләп куйды.

Озак та тормадылар, разбойниклар кайтып керделәр. Юсып аларны ашарга утыртты. Разбойниклар Юсыпка кайсы йөз тәңкә, кайсы илле тәңкә акча чыгарып бирделәр. Юсып боларның берсен дә алмады:

— Үзегез тотыгыз, миңа кирәкми,— диде.

Разбойниклар бу сүзгә бик шатланышып, Юсыпка күп рәхмәтләр укып чыгып киттеләр. Болар киткәннән соң, Юсып, янә сарайны ачып, кызны үз янына алып килеп ашатты-эчерде һәм кызга:

— Инде без бүген качарбыз,— диде.

Шуннан Юсып китәргә теләп тройка ат җигеп, чумаданга кәгазь акча тутырып, юлга ике кесә алтын алып, сарайларга кирәсин сибеп ут төртеп, кыз белән икәү утырып чыгып киттеләр.

Зур пожарны күреп, разбойниклар: «Бу безнең сарайлар яна торгандыр»,— дип, кайтып керделәр, карасалар — Юсып юк. Шуннан соң Юсыпны куарга киттеләр. Иделгә җиткәндә куып тотарга бары ике чакрым калган иде. Юсып кыз белән арбадан сикереп төште дә, атларга сугып җибәреп, үзе кыз белән ашлык арасына кереп яттылар. Атлар туп-туры Иделгә барып төштеләр. Караклар моны күреп: «Бездән куркып, үзе дә бетте»,— дип, кире кайтып киттеләр.

Караклар киткәннән соң, Юсып торып Идел буенда йөреп бер көймә

[1] *Кулча* — балдак.

тапты. Юсып кыз белән көймәгә кереп утырып, икәү Идел буйлап йөзеп киттеләр. Өч көн ишеп барганнан соң, кыз Юсыпка:

— Инде син бик арыгансың, бераз ял итеп бар, мин үзем ишеп барырмын,— диде.

Юсып ятып йоклады, кыз ишеп барганда артыннан егерме разбойник атаманнары белән кызны пароход белән куып җиттеләр дә кызга пароходка утырырга куштылар.

Кыз:

— Мин утырмам, минем ирем бар,— диде.

Караклар, кызның сүзенә карамыйча, аны тартып алып пароходка утырттылар да киттеләр. Юлда атаман һәммә каракларны үтереп суга ташлады да кызны патшага алып барып:

— Мин кызыңны таптым,— дип, китереп тапшырды.

Юсып йоклап көймәдә йөзеп килгәндә уянып китте, янында кыз юк. Берүзе генә көймәне ишеп пароход туктаган җиргә барып туктады. Килеп тукталгачтын кырыйга килеп чыккан иде, күрде: бер хатын керләр юып торадыр, һәр җиргә яшел флаглар элеп куйганнар.

Юсып бу хатыннан:

— Бүген нинди бәйрәм, ни өчен яшел флаглар астылар? — дип сорады.

Хатын аңарга:

— Бүген бер атаман патшаның кызын табып китерде, шуның бәйрәме,— диде.

Соңыннан Юсып:

— Абыстай, мин бу шәһәрдә патша сараена каршы фатир таба алырмынмы икән? — диде.

Абыстай аңарга:

— Табарсың, сарайга каршы бер хатын, үзе сарайда патшага эшләп йөридер, ул кертер,— диде.

Юсып хатынга күп рәхмәтләр укып, сорашып килеп әлеге номерны табып керде.

Номерда бары бер кыз гына бар иде. Юсып килеп кергәчтен бу кыз анасына барып:

— Әни, бер кеше килде, кертимме? — дип сорады.

Анасы:

— Кызым, керт бер буш номерга,— диде.

Юсып номерга килеп кергәч, кыздан бер чирек аракы сорап алып, эчәргә тотынды. Иртәдән кичкә кадәр үзе йөри, үзе җырлый, үзе елый, үзе эчә. Шулай итеп гомер уздырды.

Кич булгач, хуҗа хатын сарайдан кайтты һәм, егетне күреп:

— Син ник бу кадәр эчәсең? — диде.

Юсып аңарга каршы:

— Әй, абыстай, әгәр дә син минем урында булсаң, ул вакыт син күптән үлгән булыр идең,— диде.

Иртә белән абыстай тагы сарайга аш хәзерләргә китте. Патша кызына:

— Кичә миндә бер егет килеп кунды, килгәч тә эчә башлаган иде, һаман эчә, эчә, «ник болай эчәсең?» дип сораган идем, «кайгы-хәсрәтем бар», диде,— дип сөйләде.

Кыз, кызыксынып:

— Ул нинди кеше икән? — дип, хатын белән бергә барып карарга номерга китте.

Бүлмәгә килеп керсә, Юсып исереп караватка яткан. Кыз Юсыпның йомарлаган кулын ачып карады, караса — үзенең балдагы Юсып бармагында. Моны күреп, кыз Юсыпны бер кочаклап суырып үпте дә, хатын белән икәүләп күтәреп алып барып, кызның үз бүлмәсенә салдылар. Кыз Юсыпның айныганын көтеп, өстәл өстенә аракы, азыклар куйдырып, утырды. Юсып айнып торгач, кыз Юсыпны янә бер кочаклап үпте дә:

— Мине таныйсыңмы? — диде.

Юсып:

— Таныйм, тик, мин монда ничек килдем? — диде.

Кыз:

— Бүлмәңә барып, күтәреп алып килдек,— диде.

Соңра кыз башыннан үткәнне сөйләп:

— Мине, көймәдә килгәндә, син йоклагач, атаман килеп, кулымнан пароходка тартып алды да атама китереп тапшырды. Инде әти атаманга бирер дип бик куркып торадыр идем. Атаман әнә ул бүлмәдә торадыр,— диде.

Шуннан соң кыз атасын чакыртып, башыннан үткәнне сөйләп:

— Мәнә мине ул атаман тапмады, Юсып коткарды,— дип, баштанаяк ничек булганын атасына сөйләп бирде.

Шуннан соң атасы теге атаманны чакыртып башын кистерде дә, кызын Юсыпка биреп, Юсыпны үзенә варис ясап куйды.

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Көттереп килгән ӘКИЯТЛӘР

I

22. Гали, Вәли һәм Гәрәй солдатлар

Борын-борын заманда солдатка егерме биш ел мөддәт[1] белән алганнар.

Гали солдат, Казан якларыннан хезмәткә алынып, егерме биш елын тутырып килә, үзе төптән юан чыккан юантык кына тәбәнәк буйлы; Вәли солдат исә озын буйлы, таза гәүдәле, Ырынбур якларыннан, унбиш еллар хезмәт иткән; ә кыска буйлы, нәзек гәүдәле Гәрәй солдат Сарытау якларыннан, монда ун елын уздырган. Болар өчесе дә бер ротада, бер взводта хезмәт итәләр.

Көннәрдән бер көнне Гали солдатка, мөддәте тулгач, кулына хезмәтен тәмамлаганлыкка язу тоттырып, егерме биш тиен акча биреп, кайтып китәргә кушалар. Унар-унбишәр ел бертугандай яшәгән дусларыннан аерылу кыен булса да, туган җиргә, туган туфракка кайтып китү шатлыгы көчле була. Вәли һәм Гәрәйләр белән саубуллаша да туган якка таба юл тота.

[1] *Мөддәт* — вакыт, срок.

Ул вакытларда әле Казан якларына болар хезмәт иткән урыннан кайту өчен бернинди поезд да юк, пароход белән дә җайлы гына кайту юллары булмый, булса да, егерме биш тиен акча белән кая бара аласың?! Аны ашасынмы, аңа бер ашарга да җитәрлек булмый ул акча. Ләкин нишләмәк кирәк — җәяүләп булса да кайтырга чыгып китә: «Җан биргәнгә юнь бирер әле Ходай, Аллага тапшырдым»,— дип.

Бер тәүлек атлый, җәяүләп әллә ни ерак китә алмый — хезмәт иткән урыннан йөз чакрымнар тирәсендәге генә бер зур булмаган шәһәргә килеп җитә. Шәһәргә килеп керә, әле анда, әле монда каранып йөри торгач, шәһәрнең үзәгендәге кибетләр тирәсенә барып чыга. Бер кибеткә керә дә анда сатылырга куелган нинди нәрсә бар — барысының да хакын сорый башлый. Шулай итеп, ул сатучы агайдан һәммә нәрсәнең хакын сорап чыга да, үзе бер нәрсә дә алмыйча чыгып китә. Шәһәрнең бу тирәсендәге күпме кибет булса, барысына да кереп, һәммә нәрсәнең хакын берәмләп сорап чыга да, бер нәрсә дә алмыйча чыгып, инде башка кибетләр беткәч, кабат беренче кат кергән кибеткә кереп, тагын шулай ук әйберләр хакын сорарга тотына.

Шулвакыт сатучы ир:

— Солдат, сиңа ни кирәк? Бер мәртәбә кереп, бар әйбернең хакын сорап чыктың — бер нәрсә дә алмадың,— ди.

Солдат:

— Мин менә патша хәзрәтләренә егерме биш ел хезмәт итеп, мөддәтемне тутырдым да кайтырга чыктым, ди, ләкин миңа егерме биш ел хезмәт өчен юлга барысы егерме биш тиен акча бирделәр, менә шул акчам янымда исән, миңа әлеге акчаның бер тиене дә үземдә калмаслык, бер тиене дә җитми калмаслык бер әйбер кирәк, ә мин андый әйберне таба алмадым,— ди.

Ә сатучы ир кеше:

— Һи, солдат, башта кергәч тә шулай диләр аны, мин сиңа шундук табып биргән булыр идем, ди. Менә сиңа бер данә биш буынлы беләк буе сабын, мин аларны кисеп тормыйм — бишесен берьюлы бирәм, чөнки син бер генә әйбер кирәк дисең бит,— дип, беләк буе тәһарәт сабыны бирә дә,— солдат, син бу сабыннар белән бәхетеңне сынап кара,— ди.

Солдат:

— Ничек инде сабын белән бәхет сынап булсын? — ди.

Сатучы:

— Була ул, анысын үзем өйрәтәм,— ди.— Менә бу шәһәрнең көньягында, шәһәрне чыккач та урман буенда бик матур бер күл бар. Син шул күлгә бар да, чишенеп, менә шушы сабын белән юын, рәхәтләнеп иркенләп юын, озаклап юын, ашыкма. Ә күлдә юынганда нәрсә күрәсең, нәрсәгә очрыйсың иртәгә минем янга килеп, күргән, очраганнарның барысын да бәйнә-бәйнә миңа сөйләп бирерсең,— ди.

Солдат биш буынлы беләк буе сабынны кәгазьгә төреп ала да, сатучының әйткәннәренә риза булып, чыгып китә.

Шәһәр читенә чыгып, урман буендагы матур күлне табып, сатучы әйткәнчә, чишенеп ташлый да күлнең эченә кендеккә кадәр суга кереп, юынырга тотына.

Ашыкмый гына, кат-кат сабынланып бик озаклап юынып торганда, солдат искәрми дә кала, бер яктан каяндыр фәйтунга[1] җигелгән бик матур юртак атка үзе генә утырган бер чибәр хатын килеп чыгып, солдатның киемнәрен җыеп алып кулына тотып карый да солдатны чакырырга тотына:

— Чык әле, чык монда, солдат,— дип.

Ә солдатка шундый кыен, ул бит шәп-шәрә. Ә чибәр хатын чакыра:

— Чык, чык, тартынма, оялма, чык, сиңа әйтер сүзем бар,— ди.

Солдат исә:

— Әйтер сүзең булса, әйт, чыкмасам да әйтә аласың бит,— ди.

Ә хатын:

— Алай кычкырып әйтергә ярый торган сүз түгел, үзең генә ишетергә тиеш. Ә монда, урманда кеше булып, ишетүләре мөмкин,— ди.

Солдат кыенсынса да, гаурәтен куллары белән каплый да, аптырагач, чыга башлый, кыяр-кыймас кына.

— Курыкма, тартынма, чык әйдә,— дип, хатын һаман чакырып тора.

Шулай кыюландырып чакырып торгач, егерме биш ел хатын-кыз күрмәгән солдат кыюланып чыга.

Хатын:

— Әгәр вакытың булса, минем йортыма кил, минем адресым шулай, оныта күрмә адресымны,— дип, колагына гына диярлек адресын әйтеп чакыра да, киемнәрен ташлап, атын юырттырып китеп тә бара.

Солдат кич булу белән, шул адрес буенча йортны эзләп табып, барып та керә.

---

[1] *Фәйтун* (*фаэтон*) — өсте ачылмалы көймәле арба.



Хатын бик шатланып каршы ала, бик яхшы ашарга әзерләп көтеп торган була. Шулай бик тәмләп ашап-эчеп сөйләшеп утырганда ишек кагарга тотыналар.

— Әй, шәп түгел, ирем кайтты,— ди дә хатын,— син менә шунда ятып тор инде,— диеп, ванна бүлмәсенә кертеп, солдатны ваннага яткыра да, өстенә ак җәймә каплап, ишек ача һәм өйгә ир кеше килеп керә.

Әйбәтләп, ир белән хатын бергә утырып ашыйлар да ятып йоклыйлар.

Иртән ир эшкә китә. Хатын, ир чыгып киткәч, солдатка:

— Мин сине бик уңайсыз урында яткырдым инде, гафу ит. Менә шуның өчен — сиңа егерме биш сум. Бүген кич тагын кил, яме,— ди.

Солдат егерме биш сумны кесәсенә тыгып чыгып китә дә теге кибеткә барып керә. Булган хәлләрне сөйли.

Сатучы әйтә:

— Әйттем бит мин сиңа, бәхетеңне сынап кара, дип. Менә бәхетең бар икән: егерме биш елга егерме биш тиен алган булсаң, монда егерме биш минутка егерме биш сум алгансың,— ди.— Тагы чакырмадымы соң? — ди.

— Чакырды, «тагын кич белән килерсең», дип әйтте,— ди.— Ирле хатын булгач, барырга куркыта. Егерме биш сум акча булгач, хәзер бераз юлны ямщик белән дә кайта алам инде, юлның калганына Алла ни бирмәс тагы, миңа хәзер кайту юлында булырга кирәк,— ди.

Ә сатучы:

— Шундый бай хатын чакырганда нигә бармыйсың? Бар, бар, тагы бер егерме биш сум алсаң, тагы да яхшырак булыр бит,— ди.— Барсаң, нинди хәлләргә очраганыңны тагы да минем янга килеп сөйләп китәрсең, ярыймы? Менә шундый шарт миннән. Бәхетеңне тагын сынап кара инде,— ди.— Бар, бар, әлбәттә, бар,— дип чыгарып җибәрә.

Солдат исә, аңа шул гына кирәк дигәндәй, өндәп тә торучы булмагач, дәртләнеп кич булганын көтә башлый. Нишләсен, егерме биш ел буе хатын-кыз кулы да тота алмаган бит ул, кояшны сугып төшерердәй булып, кичне көтә. Анда сугыла, монда сугыла, пивнойга да кереп чыга, кабакта да булып ала.

Кич булу белән, үз-үзен тотып кына, әйткән сәгате тулыр-тулмаста барып та керә. Хатын тагын да тәмле ризыклар әзерләп көтеп торган була. Әйбәтләп ашыйлар-эчәләр дә үбешергә-сөешергә тотыналар. Кат-кат үбешеп-сөешеп туктаганда гына тагын ишек шакый башлыйлар.

— Тагын ирем кайтты бит, син бүген монда торып тор инде,— дип,

кием шкафы эченә кертеп бастыра да солдатны, шкафны бикләп, ишекне ачып ирен кертә.

Ире, керү белән, өйне тентергә тотына. Иң әлек ваннаны каплаган ак җәймәне ачып ташлый, бөтен җирне карап чыга, ләкин, нишләптер, кием шкафын, бикле булгангамы, ачтырып карамый.

Ир белән хатын ятып йоклыйлар. Ә солдат, тыны бетеп үлә язса да, шкафта басып торып төн чыга.

Иртән ир эшенә китә. Ә хатын, кием шкафын ачып солдатны чыгарып, аңа илле сум акча бирә дә:

— Солдат, бүген тагын фәлән вакытка килеп җитәрсең, яме,— дип, чыгарып җибәрә.

Солдат шәһәрдә тамак туйдыра, әзрәк кәефләнеп алып, урманга чыгып йоклап ала да, тагын кибеткә барып, сатучыга нинди хәлләргә очраганын бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Чыгып китмәкче булганда сатучы:

— «Тагын килерсең», дип әйтеп калды»,— дисең бит, сынаган-сынаган, сына инде бәхетеңне — бүген дә бар,— ди.

Ә солдат:

— Ирле хатын янына бару кыен ул, ире булмаса, бару кыен булмас иде дә, куркыта, бармам инде,— дисә дә, сатучы:

— Бар, солдат, бар, әлбәттә, барырга кирәк. Бар да иртәгә тагын миңа килеп сөйләрсең,— ди.

Солдат тагын, барырга кушып торучы да булгач, кичне көчкә ничек кирәк алай көтеп алып, әйткән вакытка бай хатыны янында була. Бик тәмләп ашыйлар-эчәләр дә бераз сөйләшеп алалар.

— Ничек инде болай ирең өстенә мине чакырасың, куркыныч бит миңа да, үзеңә дә! — ди солдат.

Ә хатын:

— Без ун ел торабыз, балабыз юк, ирем белән сөйләшенгән ул,— ди.

Шуннан үбешергә-сөешергә тотыналар. Үбешеп-сөешеп туйганда ир тагын ишек шакый. Ә хатын:

— Әй, солдат, менә бу сандыкка кереп ятып тор әле,— дип, бер өч аршын буйлы озын олы бер сандыкны ача да, шунда ябып, бикләп тә куя.

Бу сандык акча сандыгы икән. Ярты сандык кәгазь акча да, алтын акча да була. Монда акча икәнен белгәч, солдат нинди урын таба — шунда акча тутыра.

Ә ир, керү белән, өйне тентергә тотына: ванныйны да карый, кием шкафын да актарып бетерә. Ә тимер сандыкны ачтырырга хәтеренә

килми. Шуннан хуҗа, ачуланып, хатынын өйдән куып чыгара да өйне тыштан бикләп тә ала. Аннары хезмәтчеләрен чакырып китерә, янгын командасына да хәбәр итә. Хезмәтчеләргә керосин сибеп өйгә ут төртергә куша. Хезмәтчеләр тыңлыйлар, янгын командасы да килеп баса. Өй янарга тотына, ләкин бай өйне сүндерергә рөхсәт итми. Янгынчылар ут башка йортларга китмәсен өчен генә саклыйлар, ә өйне карап торып яндыра башлыйлар.

Шул вакыт хуҗа хатын кычкырып җибәрә:

— Әй, ирем, ирем, хет акча сандыгыңны гына булса да чыгарт инде,— дип ялварырга тотына.

Ир дә бу ялваруга чыдый алмый: «Чыннан да акча да яна бит»,— дип, янгын командасына кайсы бүлмәдә, кайда нинди сандык барлыгын әйтеп, өйгә кертеп җибәрә. Дүрт янгынчы көчкә сөйрәп алып чыгып, сандыкны янгыннан ерак җиргә, халык җыеныннан артка илтеп куялар.

Ә монда янгын карап торырга шәһәрнең бөтен халкы диярлек җыелган була. Өй яна, ә хуҗа ирнең ишек-тәрәзәләрне күзәтүдән башка эше булмый. Шул вакыт хатын халык артындагы караңгылыкта тимер сандыкны ачып, солдатны чыгарып җибәрә дә үзе сандыгын саклап утыра бирә.

Ә солдат үзенең таныш урманының аулак урынын эзләп табып, шунда йоклап төн уздыра да иртәгесен, кибет ачылгач, төнлә булган хәлләрне сатучыга сөйләргә килә. Башка көннәрдә бу вакытта кибет ачылган булса да, бүген ябык була. Солдат кибетнең ачылганын түземсезлек белән көтеп ала. Кибет шактый соң ачыла, ә кибетченең йөзе нindidер караңгы, нурсыз, зур бер борчылу күренә кибетченең йөзендә. Кибетче белән солдат әйбәт кенә исәнләшәләр.

Кибетче кайгылы йөз белән:

— Ничек, солдат, бардыңмы, бу юлы ниләр күрдең? — ди.

Солдат булган хәлләрнең барысын да сөйләп бирә, ләкин үзенең кайда булганын гына әйтми калдырган була.

— Ә соң син, солдат, кайда калдың өй янганда? — ди.

Солдат үзенең акча сандыгында булуын, акча сандыгыннан булдыра алган кадәр күпме урыны бар, шунда акча тутыруын һәм аннан ничек чыгып китүен сөйләп бирә.

Ә сатучы:

— Син бит минем хатын янына бардың. Мине син малайлымы, кызлымы иткән булсаң, миңа шул җитә, башка бер нәрсәгә үкенмим дә, ачуланмыйм да,— ди.— Менә сиңа тагын бер йөз сум,— дип, йөз сум

тоттыра да: — Шушы минуттан минем күз алдымнан югал, юкса әллә ни булуы бар. Бервакытта да минем күземә күренәсе булма, шушы минуттан шәһәрдән югал. Шәһәр тирәсенә гомереӊ буена да киләсе булма, яӊадан очрашу яхшы булмаячак,— дип, куып чыгарып җибәрә, бернинди дә начарлык эшләми.

Солдат чыгып китә дә: «Бу шикле акча белән нишләргә, кая барырга, тизрәк кайтыргамы, әллә теге Вәли белән Гәрәй янына барып, аларны кунак итеп, сыйлап кайтып китәргәме»,— дип уйлый. Уйлый да шул солдатлар янына кире китәргә була.

Солдатлар янына кире кайта да үзе егерме биш ел буе бергә булган командирларын, иптәшләрен, дусларын урысчалатып көн-төн туктамыйча, аракы белән сыйларга тотына. Көн дә эчкәч, көн дә йокыдан торуга башлары авырта, баш төзәтергә кирәк була. Көн дә иртән баш төзәтеп алгач, көн дә, тәмам исереп бетмичә, эчүдән туктый алмый.

Шулай итеп, күпмедер вакыт үткәч, көннәрдән бер көнне Гали солдатныӊ кесәсендә бер тиен дә акчасы калмаган. Баш төзәтергә дә рәте калмагач, үзенеӊ командирларыннан акча сорап карый әҗәткә. Баш төзәтер өчен кайсысыннан сораса да:

— Юк акчабыз,— диләр.

Тагын да зуррак бер командиры:

— Син нәрсә, кире килеп, айлар буе бөтен ротаны эчереп исертеп, эчүчелек белән шөгыльләнгәнеӊ өчен унбиш суткы гаупбахтыга утыртмаганга рәхмәт әйт, оялмыйча әҗәткә акча сорап торасыӊ тагы. Утыртып куйгалаганчы югалуыӊны гына кара,— ди.

Шуннан соӊ Гали, Вәли белән Гәрәйне үз янына чакырып ала да, хәленеӊ ничек булганын сөйли.

Вәли белән Гәрәй:

— Бездә баш төзәтерлек кенә рәт бар ул барын,— дип, баш төзәтәләр.

Баш төзәткәч, Галинеӊ башына тагын бер уй килә дә, уен Вәли белән Гәрәйгә әйтә:

— Әйдә, без өчәүләп югалаек, таяек моннан,— ди.— Барыбер егерме биш ел хезмәт итсәгез дә, рәхмәт тә булмас, миӊа биргән кебек егерме бишәр тиен бирерләр дә, мине чыгарып җибәргән кебек чыгарып җибәрерләр. Бәхетегезне сынап карарга кирәк. Мин бер мәртәбә сынап карадым инде. Бәхет хәзергә ярыйсы булды. Әйдәгез бергәләп сынап карыйбыз бәхетләребезне,— ди.

Вәли белән Гәрәй моӊа риза булалар да, хезмәтләрен ташлап, өчәүләп

чыгып китәләр. Ләкин боларга илләренә кайтырга ярамый. Анда кайтсалар, Вәли белән Гәрәйне дезертирлыкта гаепләячәкләр, чөнки егерме биш еллары тулмаган икесенең дә. Чыгып китәләр китүен, салган баш белән аны-моны уйламыйча, ләкин кая барырга белмиләр үзләре. Көнчыгыш якка барасы урынга көнбатыш якка юнәлеш алганнар да баралар да баралар. Көн баралар, төн баралар, атна баралар, ай баралар, Вәли белән Гәрәйдә Гали бай чакта биргән акчалары була — шул акча хисабына көн итеп, юлларын дәвам иттерәләр.

Бара торгач, беркөнне кичкә таба бер кара урманга керә болар. Баралар, уңда, сулда берни күренми, алда, артта да берни күренми. Бик озак баргач, алда кара урман эчендә, юлдан да шактый читтә ут җемелдәп күренә башлый. Утка таба борылып керәләр, кунып чыгарга урын булыр дип.

Барып җитсәләр — гел урман арасында ике катлы җиде-сигез генә тәрәзәле матур гына зур булмаган йорт. Һәр тәрәзәсеннән яктылык балкып тора. Ихата капкасын эзләп табалар: ябык түгел — ачык. Өйнең ишеге янына киләләр: ябык түгел — ачык.

— Кем бар, керергә рөхсәтме? — дип, өчесе дә кычкырып бер мәртәбә рөхсәт сорыйлар.

Беркем җавап бирми. Бераз көткәч, тагын сорыйлар. Җавап юк. Кыюланып кереп китәләр, аскы катның бар бүлмәләрен карап чыгалар — беркем юк. Өске катка менеп китәләр — беркем юк. Бүлмәләрдә балкып шәмнәр янып тора. Ә шулай да, бер бүлмәгә керсәләр, өстәл уртасында суынып та җитмәгән бер бәлеш тора, өч кашык, өч стакан һәм бер пычак белән бер шешә аракы. Өстәлнең өч ягында өч урындык та бар.

Солдатлар йортның хуҗаларын көтәләр, кычкырып карыйлар — беркаян бернинди тавыш килми. Байтак вакыт үткәч, Гали бәлешне кисә дә Вәли белән Гәрәйгә:

— Җитешегез, мин бер сынадым инде бәхетне, бу икенчесе булыр, Аллага тапшырып, ашыйк,— ди.

Ашарга һәм шешәдән салып эчәргә тотыналар. Өчесе бер бәлешне ашап, шешәне эчеп бетерәләр дә бүлмәләргә тагын чыгып карыйлар. Карасалар, кергәндә бүлмәләрдә койкалар буш булган булса, хәзер өч бүлмәдә дә койкаларда йомшак итеп урын җәелгән. Гали:

— Мин ардым, егетләр,— ди дә бер бүлмәдәге койкага ята да йоклап та китә.

Вәли белән Гәрәй дә, бүлмәләргә чыгып, койкаларга ятып йоклыйлар.

Иртән торып, ашаган бүлмәләренә чыксалар — өстәлдә тагын бер бәлеш. Суынмаган да. Тагын бер шешә аракы, бер колода кәрт тә бар. Болар иртән тагын бәлеш ашап, әйбәтләп кенә шешәне бушаталар да кәрт уйнарга тотыналар.

Уйнап арыйлар да тагын бүлмәләргә чыгып койкаларга йокларга яталар.

Торсалар — тагын шул хәл. Тагын ашыйлар-эчәләр, тагын дуракка кәрт уйныйлар, тагын арып йоклыйлар.

Шул хәлне ничә мәртәбә кабатлыйлар — анысының да санын белмиләр, ничә көн, ничә төн узганын да белмиләр — шул хәлне дәвам иттерәләр. Бер кайгы юк, бер эш юк, исерек башларга берни дә кирәкми.

Шулай да беркөнне иртән өч ат җигелгән бик матур бер фәйтунда берсеннән-берсе чибәр өч кыз кайтып керәләр йортка. Берсеннән дә исемнәрен сорап тормастан, өчесенең дә исемнәрен әйтеп исәнләшәләр һәм үзләренең дә исемнәрен әйтәләр:

— Мин — Сөембикә,— ди берсе.

— Мин — Мәрьям,— ди икенчесе.

— Мин — Мәдинә,— ди өченчесе.

Танышканнан соң әйтәләр болар:

— Сез, солдатлар, монда бер ай тордыгыз, бер ай торган вакытта бернинди дә начарлык эшләмәдегез, инде менә без кайттык, без сезнең янда өч көн торачакбыз, әгәр дә өч көн буена бернинди начарлык эшләмичә генә, безнең белән матур гына яши белсәгез, без сезнең белән калырбыз. Әгәр дә өч көн буе безнең белән матур гына яши алмасагыз, сез бездән, без сездән аерылачакбыз. Шуңа күрә өч көн бик әйбәт кенә вакыт уздырыйк әле,— диләр.

Болар өч көн бик матур гына уйныйлар, күңел ачалар, ну кичләрен бергә ятмыйлар.

Өч тәүлек тулган вакытта теге Гали солдат чыдаша алмый — Сөембикәгә омтылып карый. Инде Сөембикә сикереп тора да:

— Эшне боздыгыз, сез безнеке, без сезнеке түгел,— ди.

Шуннан кызлар, өч айга дип, боларны калдырып чыгып китәләр. Киткәндә өч айда өчесенә өч тел өйрәнергә кушып калдыралар: берсенә француз теле, берсенә инглиз теле, берсенә немец теле.

— Өч ай бер гөнаһсыз әйбәт кенә яшәсәгез, кайтабыз да бергә торырбыз,— диләр.

Ярар. Кызлар китәләр. Болар өчесе өч тел өйрәнеп карыйлар инде. Өч ай узып та китә. Кызлар кайтып төшәләр.

— Сез, солдатлар, монда өч ай тордыгыз, бернинди дә начарлык эшләмәдегез, без сезнең янга кайттык,— диләр болар.— Менә хәзер без сезнең белән өч көн торачакбыз, әгәр дә өч көн буена бернинди начарлык эшләмичә матур гына яши алсагыз, без сезнең белән калырбыз. Әгәр өч көн буе матур гына яши алмасагыз, без сезнең белән аерылачакбыз,— диләр.

Болар өч көн бик матур гына уйныйлар, күңел ачалар. Өч тәүлек тулган вакытта тагын теге Гали солдат түзми — Сөембикәгә омтыла. Сөембикә сикереп тора да:

— Эшне боздыгыз, сез безнеке, без сезнеке түгел,— ди.— Тик шулай да ярар инде, моңарчы әйбәт торганыгыз өчен гафу итәбез, әмма биредән чыгарып җибәрмичә булмый, чыгып ычкынуыгызны карарсыз,— ди.

Боларны юлга озаталар. Юлга озаткан чакта: «Чүтки[1] яхшылыгыгыз өчен, моңарчы әйбәт булганыгыз өчен бездән әзрәк бүләк тә кирәк булыр бит инде»,— дип, Сөембикә Гали солдатка бер акча янчыгы бирә. Гали солдат ала да кесәсенә тыгып куя инде. Ә икенче кыз Мәрьям Вәлигә бер искереп беткән солдат шинеле бирә. Өченче кыз Мәдинә Гәрәй солдатка аксак кеше таянып йөри торган бер таяк — аксак таягы бирә. Шуннан:

— Сау булыгыз, бүтән сез бу якка борылып карамагыз, үз юлыгызны үзегез карагыз,— дип озаталар.

Болар тагын кая барырга белмичә атлыйлар, атлыйлар, атлыйлар, баралар, баралар, баралар, бервакытны ял итәргә туктыйлар болар. Ял итәргә туктагачыннан, солдат гадәте буенча тәмәке тартырга тотыналар. Тәмәкегә дип кулын кесәсенә тыкса, кулына теге Сөембикә биргән акча янчыгы эләгә. Янчыкны алып карый, янчык искереп беткән. Эчен ачып карый. Караса, эчендә аның бер бакыр биш тиен акчадан башка бер нәрсә дә булмый. Янчыкны селкә башлагач, эченнән алтын акча коела. Селкеп карый — коела, селкеп карый — коела. Әйләндереп карый — бакыр биш тиеннән башка берни дә юк. Тагын селкеп карый, тагын акча коела. «Ярый, бу янчык әйбәт икән, мондый хикмәтле янчык белән яшәргә була»,— диешәләр дә кесәсенә тыгып куя моны Гали солдат.

Вәли солдат:

— Соң инде миңа бер искереп беткән шинель бирде. Янчык әйбәт нәрсә булды инде, ә бу шинель белән мин нәрсә эшлим? — дип, киеп

[1] *Чүтки* (*урысча: все-таки*) — шулай да.

карамакчы була. Киим дисә, Вәли солдат шактый озын, таза гәүдәле, ә шинель бик кечкенә булганлыктан, кия алмый. Шинельне кия алмагач:

— Мә әле, бәлки сиңа ярар,— ди дә Гали солдатка бирә.

Гали солдат киеп карый, шинельне кию белән юкка чыга, күз алларыннан күренмәс була.

— Бәй, кая киттең син? — диләр.

— Бәй, шушында бит мин,— ди,— әллә соң шинельдә микән хикмәт,— ди дә Гали солдат, шинелен сала, шинельне салу белән күренә.— Туктале алайса,— дип, Гали солдат шинельне Гәрәй солдатка бирә.

Гәрәй солдат киеп карый, чынлап та Гәрәй солдат та юкка чыга, күренмәс була.

Шуннан шинельнең хикмәтен беләләр дә болар, «ярыйсы шинель икән бу, моның белән яшәргә була, бик кирәкле вакытта файдаланырбыз», диешәләр дә, шинельне тагын төреп әйбәтләп култыгына кыстырып куя Вәли солдат.

Гәрәй солдат:

— Сезгә әйбәт кенә нәрсә биргәннәр икән, миңа бу таяк белән нәрсә эшләмәк кирәк? — ди дә ыргыта.

Таякны ыргытып, үзләренең тәмәкеләре белән мавыккан арада карасалар: иксез-чиксез сафка тезелгән гаскәр күренә башлый, кем әйтмешли, тешләренә кадәр коралланган, бөтен формалары белән җитешкән гаскәр күренә. Һәм шулар арасыннан берәү килеп чыга да:

— Ни боерасыз, таяк иясе? — дип кычкыра.

Хәзер эшнең нәрсәдә икәнен аңлыйлар да:

— Болай гына, болай гына,— дип, таякны тартып алалар.

Таякны тартып алу белән гаскәр юкка чыга.

Хикмәтле таяк икәнен аңлап алалар инде болар. Шуннан соң бик матурлап сөйләшәләр монда, төрле киңәшләр киңәшәләр.

Гали солдат әйтә:

— Үзебезнең якка кайтырга ярамый инде безгә,— ди,— мин үзем кайтыр да идем, сезгә ярамый бит, хезмәтегез тутырылмаган — сезне кайту белән арестовайт итүләре мөмкин. Киттек, булмаса, Аурупа илләренә таба.

Киңәшәләр дә: «Киттек Франциягә»,— диләр. Тоталар да китәләр Франциягә.

Анда күпме барганнардыр, озакмы-юкмы — ул турыда билгеле түгел, ә Франциягә барып чыгалар болар, Франциянең баш шәһәре Парижга

ук барып җитәләр. «Парижның первоклассный иң зур ресторамы кайда?» — дип сорашып, шул ресторанны эзләп табалар. Шул ресторан янындагы гостиницага урнашалар болар. Әйбәт кенә урнашып, гостиницада йоклыйлар, ә ресторанга кереп ашыйлар-эчәләр, ару гына типтереп яталар болар монда.

Франция патшасының кызы шушы ресторанга ашарга йөри торган була. Көннәрдән бер көнне бу кыз килеп керә дә, монда ашап-эчкәч, лакейга ун тиен акчаны идәнгә ыргыта. Ә лакей алмый акчаны.

— Нигә алмыйсың акчаны? — ди патша кызы.

— Син, патша кызы булып, ун тиен ыргытасың идәнгә, нигә кирәк ул миңа? — ди лакей.— Синең ун тиенеңә бөкерәеп торырга, менә миндә алтын бер кесә,— дип, алтыннарын чыгарып күрсәтә.

— Бәй, каян аласың син алтынны? — ди.

— Менә күрше бүлмәдә генә солдатлар яталар,— ди,— ни урыс түгел, ни француз түгел, телләре дә без аңлый торган тел түгел. Шул солдатлар ашаган саен алтынны учлап кына ыргыталар миңа,— ди.

Патша кызының күзе шар була, аптырый:

— Нинди солдатлар алар, шундый бай? — ди.

— Аларның өсләрендәге киемнәре дә юньле түгел инде, ә акчаны җәлләмиләр.

— Ә син ул солдатлар белән мине күрештереп сөйләштерә алмыйсыңмы? — дип сорый патша кызы.

— Бәй, әйтеп карармын, берәрсе керер, бәлки,— ди.

Чыга да лакей, әйтә солдатларга:

— Вәт, күрше бүлмәдә генә патша кызы сезне үз янына чакыра, кермисезме? — ди.

Шуннан өчесе киңәшләшәләр дә:

— Монда, Гали, син старший инде,— диләр,— син кереп кара, булмаса.

Шуннан Гали керә патша кызы янына. Патша кызы аңа:

— Әйдә, кәрт уйныйбыз,— ди, кәрт уйнарга тәкъдим итә. Акчага.

Уйнарга тотыналар кәрт. Патша кызы белән кәрт уйнау солдатка бик күңелле тоела инде. Һич туктамый, ничек кенә булса да Гали ота. Ота торгач, ике мең тирәсе акча откачыннан, патша кызының акчасы бетә.

— Ярар,— ди,— минем акча бетте, чыгып китәм мин,— ди патша кызы.

Гали солдатның бер дә тегене чыгарып җибәрәсе килми.

— Бәй, менә мин әҗәткә бирәм,— ди,— пожалысты,— ди,— әйдә уйныйк,— ди.

Хәзер әҗәткә биреп, әҗәтне дә ота. Шуннан Гали солдат үзе оттыра башлый. Башта акчаны санап кына чыгара, патша кызының үзеннән алган акчаларын гына. Аннан ары бервакытны ул акча бетә. Хәзер оттырган саен кесә төбендәге янчыкны кага да алтынын учлап кына сала өстәлгә.

Уйный торгачыннан бервакытны карасалар, өстәлгә алтын өелгән, ул инде Галинең кесәсенә сыярлык кына түгел.

— Бәй, солдат, бу алтын каян чыга? Бу нинди гаҗәп хәл? Хәзер кесәңә дә сыймый бит бу алтын.

— Менә бу янчыкның эчендә беркайчан да алтын бетми,— ди Гали солдат, янчыкны күрсәтә.

Акча янчыгын шартлатып тартып ала да хәзер патша кызы:

— Минем янга нинди алама солдат керттегез монда, ни урысча сөйләшә белми, ни французча сөйләшә белми, куып чыгарыгыз,— дип кычкырып җибәрә.

Ул ара да булмый, рестораннан бер хуҗа кеше килеп керә дә: «Бар!» — дип, солдатны, якасыннан әләктереп, чыгарып та җибәрә.

Шуннан нишләргә хәзер? Янчык кызда калды. Кыз шул килеш чыга да кайтып китә.

Гали солдат үзенең иптәшләре янына килеп керә хәзер. Иптәшләренә:

— Эшләр харап бит,— ди.— Мин янчыктан колак кактым,— ди.

— Нәрсә булды?

— Менә патша кызы шулай акча эшенең янчыкта икәнен белгәчннән янчыкны кулымнан тартып алды да кычкырып та җибәрде: «Нинди алама солдат керттегез монда, алып китегез»,— дип әйтеп. Ул ара да булмады, якадан тотып мине чыгарып та җибәрделәр,— ди.

— Бәй, кайгырма, кайгырма, хәзер берәр нәрсә эшләрбез,— диешәләр икесе.— Безнең бит әле тагы әйберләр бар, күрсәтми торган шинель бар бит. Шуның белән берәр хәйлә корырбыз,— диешәләр.

Теге патша кызы кайда тора, башта шуны белешергә кирәк. Хәзер өчесе дә шымчы булып чыгып китәләр. Патша кызының яши торган җирен табарга.

Белеп кайталар. Патша кызы, үзенә махсус салынган йортта аерым бүлмәдә тора икән. Төнлә шунда ял итә инде.

Бервакытны төн җиткәченнән, патша кызы ял итәргә яткачыннан, Гали солдат шинельне кия дә китеп бара. Барып җитә. Патша кызының ишеге төбендә каравылчысы бар. Каравылчысы булса да, ишекне ачканны да сиздермичә солдат кереп китә. Бикле түгел бүлмә.

Керә. Кыз йоклый рәхәтләнеп. Чишенгән. Ә солдат иплап кенә тегене үбәргә тотына. Кыз болай итеп битен сыпыра, тегеләй итеп битен сыпыра... Уяна бу берзаман.

— Төшемме соң бу, өнемме бу, кемдер үпкән сыман тоела,— ди кыз.

— Бу өнең! — ди Гали солдат.

— Бәй, кем соң син? — ди.

— Бәй, мин теге синең белән кәрт уйнаган Гали солдат булам,— ди белер-белмәс, шунда буталыр-бултамас француз теле белән.

Патша кызы тагы:

— Бәй, син күренмисең бит,— ди кыз.

— Бер дә искитәрлек түгел, менә мин,— ди дә шинелен салып куя. Чынлап та Гали солдат монда басып кала. Хәзер:

— Китер янчыкны,— ди.

— Ничек инде мин сиңа янчык бирим, мин синнән янчык алмадым,— диярга тотына теге.

— Юк,— ди, янчыкны бирмичә,— мин синең яннан чыгып китмим,— ди Гали солдат.

Янчыкны бирми бу. Берничек тә бирергә уйламый.

— Ә менә миңа, шунысы гаҗәп,— ди, кыз әйтә,— син ничек монда күренмәс булып тордың да хәзер ничек күренәсең? — ди.

— Һе, аның бер хикмәте дә юк,— ди,— менә тагын күренмәскә уйласам,— ди дә шинельне кия, шинельне кигәчтен, тагын күренми теге.

— Бәй, бу нинди хикмәт, нинди хикмәтле кеше син? — ди кыз.

— Менә бөтен хикмәт шунда инде,— ди,— менә шушы шинельдә,— ди Гали солдат. Шинелен салып торкан була үзе.

Кыз шинельне тартып ала да:

— Нинди алама солдат керттегез монда,— дип, каравылчыга кычкырып та җибәрә.

Хәзер каравылчы керә дә Гали солдатны куып чыгарып җибәрә, артына тибеп. Инде шинельдән дә колак кага бу.

Кайтып китә солдат, баш иеп, тагы. Нишләсеннәр хәзер, акча да юк, сөйләшергә әллә ни рәт тә юк. Ну болай азмы-күпме җыйган запаслары

бар-барын, янчыктан элегрәк каккалап алган. Шуның белән яшәп яталар.

— Давай, булмаса, таяк белән кыйланып карыйбыз,— диләр.

— Давай. Ничек итеп кыйланабыз?

Киңәшәләр өчесе.

— Син инде, Гали, үзең кара. Шәһәрнең читенә чык та таякны ыргыт, гаскәр килгәченнән таякка тиешле боерыкны бирерсең дә, патша сараеның түбәсе күккә очсын беренче атудан. Шундый әмер бирерсең.

Шуннан Гали солдат таякны алып чыгып китә шәһәрнең читенә. Шәһәр читенә чыгып таякны ыргыта. Чынлап та беренче мәртәбә ыргыткандагы кебек теше-тырнагына кадәр коралланган баһадир солдатлар гаскәре пәйда була Гали солдатның алдында. Һәм аларның бер командирыдыр инде, шунда:

— Таяк иясе, нәрсә боерасыз? — ди.

— Менә минем боерыгым шул,— ди Гали солдат,— әнә шәһәрдәге патша сараеның түбәсе бер атуда күккә очсын!

Шәһәрне уратып алгандай булалар да солдатлар тиз генә төрле яктан атып җибәрәләр. Чынлап та патшаның калай түбәсе киселеп оча.

Бу ни хәл! Хәзер патша аптырашта кала. Нәрсә булганын да белми әлегә: яшен яшьнәдеме, күк күкрәдеме, сугыш та игълан иткән кеше юк, бернинди хәбәр юк андый-мондый,— гаҗәпкә кала патша.

Шуннан тып-тын торганда тагын икенче мәртәбә түбәгә аталар, икенче мәртәбә дөбер-шатыр ватыла. Ары чаба патша, бире чаба хәзер — караса, чынлап шәһәрне гаскәр урап алган. «Бәй, бу нинди хәл, беркем, бернинди патша сугыш игълан итмәде, көтмәгәндә генә яшен суккан шикелле генә бу нинди хәл булыр?» — дип пошаманга төшеп йөргәндә, кызы әтисен күрә.

— Әти, нигә пошаманга төштең? — ди.

— Әй, кызым,— ди,— гел көтмәгәндә әллә нинди гаҗәп бер хәл булды бит әле: шәһәрне гаскәр уратып алган, ә менә әле искәрмәгәндә безнең тора торган йортның түбәсе очты бит шуларның аткан утыннан. Менә шуларга каршы гаскәр җыярга кирәк,— ди.

— Тукта, әти, бу, мөгаен, нинди дә булса сугыш башлаган кеше әше түгел, мин белә торган өч алама солдат эше бу,— ди.— Шулай булырга кирәк,— ди.— Шул солдатлар белән сөйләшеп карыйк без,— ди.— Алар белән мин үзем җаен табармын,— ди.

Моңар атасы гаҗәпләнсә дә, кыз йөгереп кайтып китә.

Патша кызы ятьрәк Гали солдат янына бара. Гали солдат бит әле ул шәһәрнең читендә солдатлар янында. Солдатлар белән һаман куркыту эшен эшли, ә кыз гостиницага керә дә ике солдаттан сорый:

— Гали солдат кайда?

Гали солдатны эзләп шәһәр читенә чыга инде. Шәһәр читендә аны эзләп таба.

— Бу синең эшме? — ди.

— Әйе, минем эш,— ди.

— Бу солдатлар синекеме?

— Әйе, минем солдатлар.

— Бу солдатларны каян ала алдың, ничек буйсындыра алдың аларны?

— Һе, бездә гаҗәп нәрсәләр күп инде, син барыбер миннән котыла алмыйсың,— ди.

— Шул котыла алмаганга күрә, мин сиңа кияүгә чыгарга булдым,— ди.— Әллә нинди могҗизалар беләсез, шул могҗизаларыгыз өчен мин сиңа кияүгә чыгарга булдым,— ди.— Солдатларыңны куып җибәр, әйдә киттек, кайтабыз, никахлашабыз,— ди.

Шуннан солдат таякны тартып ала җирдә яткан таякны — гаскәр дә юкка чыга. Кыз моны искәреп кала — ничек итеп юкка чыкканын, нәрсәдән барлыкка килгәнен дә чамалый хәзер кыз моның.

— Әйдә, кайтабыз да менә фәлән чиркәүгә кереп никах укытабыз поптан.

Туп-туры чиркәүгә китәләр болар. Чиркәүгә кереп, хәзер венчаться итәргә әзерләнгән чакта, кыз Гали солдатның кулыннан таякны тартып ала бит! Тартып ала да попка кычкырып җибәрә:

— Синең акылың кая?! — ди.— Шушы алама йолкыш бер солдат белән,— ди,— миңа никах укырга маташасың. Артына тип тә чыгарып җибәр, миңа шушы таяк кына кирәк иде,— ди.

Шулай итеп, Гали солдат таяктан да колак кага. Хәзер кая барырга? Янчыкны алдырды, шинельне алдырды, таякны алдырды. Барын да җыеп алды шул бер кыз — патшаның олы кызы.

Гали солдат башын ия дә: «Чукынып кына китсен дөньясы, болай булгач беттем, инде кайтмыйм иптәшләр янына»,— ди дә шәһәрдән чыга да китә. Бара, бара, кая барганын да белми. Бервакыт бара торгач, урманга барып керә. Кайгысыннан нәрсә уйлаганын да, нәрсә эшләгәнен дә белми инде ул. Ну шулай да корсак ачканын сизә. Корсак ачканын сизеп алай-болай каранса, урманда бик матур алма агачы күрә. Алмалар

җитешкән, матур алмалар бар — алма ашарга тотына. Алма ашаган саен бу, ничектер, мәзәкләнә[1] башлый. «Бәй, әллә бу алма мине мәзәкләндерә микән?» — ди дә алга таба китеп бара.

Моңарга яшьлек керә, ниндидер яшь төс, бу яңадан унсигез-егерме яшенә төшкән кебек җиңеләеп, матураеп китә, янында көзгесе булмаса да көзгегә карамаса да, үзенең яшь егеткә әйләнгәнлеген сизә барыбер. «Һай шәп булды бу алма,— ди дә,— шулай да барыбер күп ашарга ярамый»,— дип китеп бара бу.

Бара торгач, тагын бер алма агачына очрый. Бусының да алмасын өзеп ашый. Бусын ашагач, элекке хәленә кайта.

Шуннан тагы бераз китә. Тагы бер алмагач очрый. Өченче алмагачтан да алма алып ашый бу. Ашагач, үзенең нинди хәлдә калуына төшенә алмый: моның сакаллары озыная, чәчләре озыная, тәнен йон баса, бары берничә минут эчендә. «Мин хәзер җенгә әйләндем, мин хәзер дөньяда яши алмыйм бит инде, болай итеп кешегә ни күзем белән күреним»,— ди бу. Дөньядан юк булырга дип тә уйлап куя. Шулай да исенә төшә бит: «Туктале, бу хикмәт алмадан барлыкка килде бит»,— ди. Кире кайтып, юлдагы икенче мәртәбә очраган алма алма агачыннан ашый. Бу алманы ашаса, тагы кире үз хәленә кайта. Хәзер иң беренче ашаганына килеп җитә дә, анысын ашый. Анысын ашагачтын егерме-егерме дүрт яшьләрдәге егеткә әйләнә. «Мондый могҗизалы алма белән мин тагы патша кызын алдый алам түгелме»,— дип уйлап ала да өчесеннән өч аерым урынга алма җыя. Җидешәр, сигезәр алма эләктереп ала инде өчесеннән дә. Кайтып китә шәһәргә.

Шәһәрдә вак-төяк капчыклар сатып ала. Шул капчыкларның өчесенә өч төрле алма тутыра, тагын вак-төяк шешәләр тутыра. Бер алманы ашап, Гали солдат үзен карт кыяфәткә кертә дә, алма сатучы булып, патша сарае янында кычкырынып йөри башлый:

— Алма сатам, алма сатам, берсе-берсе унар тәңкә,— ди.

— Бәй, бездә алманың килосы бер тәңкә, ә син ник ун тәңкәгә сатасың? — дип сорыйлар моннан.

— Һе, бу алманы ашаса, карт кеше дә яшь кешегә әйләнә шул,— ди,— шуңа да кыйбат ул,— ди.

Шуны ишетәләр дә моны патша кызларына сөйлиләр. Патшаның өч кызы була. Уртанчы кызы моны ишетә дә йөгереп чыгып, бу карттан алма ала.

---

[1] *Мәзәкләнү* — хәл киту, кәефсезләнү.

— Алма ник алай кыйбат? — ди.

— Менә, кызым, син аны ашап кара әле, кире сабый чагыңа килеп төшәрсең,— ди.

Кыз ала да, кетердәтеп ашый-ашый кереп тә китә. Кереп, апалары янында йөри башласа, апалары танымыйлар: «Нинди бәләкәй кыз, нинди яшь кыз килеп кергән»,— диләр.

— Бәй, мине таныйсызмы, мин сезнең сеңлегез бит,— ди.

— Нишләп алай?

— Бәй, әнә урамда бер карт алма сата, шул алманы ашасаң, шулай яшәрәсең.

— Бар әле, сеңелем, бар, бар, алайса миңа да алып кер! — ди олы тутасы, теге Гали солдат белән булган кыз.

Шуннан чыга да теге кыз алма ала. Сатучы карт әйтә моңа:

— Кызым,— ди,— бу алманың әйбәтен генә бирәм мин сиңа,— ди,— сине бөтенләй матурлый торганын бирәм, ди. Тик моны көндез ашарга ярамый, төнлә генә ашарга кирәк, ди. Аны ашагачтыннан, ашаган кешенең нурлары кояш нурларында чагылып ул кеше һәлак булуы бар, — ди.— Шул сәбәпле,— ди,— моны төнлә ашарга кирәк,—ди.

Бу кыз алып керә дә тутасына бирә алманы.

— Сатучы: «Бу алманы төнлә генә ашарга кирәк,— дип әйтте,— ди.— Шулкадәр чибәрләнә, шулкадәр матурлана, кояш нурлары көнләшеп, бу матурлыкны бетерә»,— дип әйтте,— ди.

Төнне көтеп торып, теге кыз ашый алманы. Иртән торуга бу кыз җенгә әйләнгән, йон баскан, бер әллә нинди җыерчыкланып беткән сиксән-туксан яшьлек карчыкка әйләнгән. Чыгыйм дисә, торыйм дисә, хәле дә юк үзенең юньле. Иртән хезмәтче ашарга чакырып карый, юк, бу торырлык түгел, монда кыз юк, бу әллә нинди карчык, әллә нинди җенгә охшаган нәрсә бөтенләй.

Хезмәтче чыга да хуҗаларга әйтә:

— Анда бит,— ди,— әллә нинди бер җен карчыгына охшаган карчык кына бар, бүтән кеше юк,— ди.

Гаҗәпләнеп, патша хатыны кереп китә кызы янына. Кызны таный алмый.

— Бәй, кызым, син кайда соң?

— Бәй, бу мин инде. Мин менә шундый чиргә юлыктым инде,— ди кыз.

Һушлары китеп, кайтып патшаның үзенә сөйли: «Шундый, шундый,— дип,— кызыбыз чирләгән»,— дип.

Патша үзе чыгып карый. Чынлап та кыз бөтенләй кеше хәленә кире кайтмаслык хәлгә килгән, ниндидер бер җенгә охшашлы карчыкка әйләнгән.

Нишләргә хәзер, кызны дәваларга кирәк, дәваламыйча ярамый. Духтырлар эзләргә тотыналар, патша белдерү игълан итә инде: «Менә шулай, шулай, патшаның олы кызы чирләде, шуны дәвалаучы табиб табарга кирәк. Әгәр дә шундый табиб табылса, ул яшь кеше булса, аңа кызымны бирәм, үз урыныма патша итеп утыртам, ди. Ә инде урта яшьләрдәге кеше булса, ярты мөлкәтемне бирәм,— ди,— үземнең янымда яхшы гына яшәтеп, картаймышлы көнемдә үземнең янга тәрбиягә алам бу кешене»,— ди.

Бу игъланнан соң төрле яклардан төрле кешеләр килә башлый монда. Табиблар киләләр дә, карап торалар да:

— Соң бит бу берничек тә дәвалый торган түгел, бу бит карт карчык, моны ничек дәвалыйсың, карт карчыкларны дәвалап, кире кызга әйләндереп булмый инде,— диләр дә китәләр.

Ә Гали солдат читтән генә күзәтеп йөри, тегеләрнең хәбәрләрен ишетергә җай табып шунда.

Шуннан бервакытны Гали солдат килә боларга. Инде патша өмет өзгән була табиблардан, бернинди дә табиб юк икән моңарга, дип. Гали солдат карт кеше рәвешендә килә дә:

— Мин сезнең шундый, шундый зарыгызны ишеткән идем, шул зарыгыз буенча кызыгызны дәвалап карамакчы булып килгән идем,— ди.

— Булдыра алсаң гына! Булдыра алмаганнарның мин башын чабып өздерергә карар бирдем,— ди.

— Тырышып карыйм әле,— ди.— Мин риза барысына да,— ди.

— Инде карт кеше буларак, мин сине үземнең янга тәрбиягә алырмын,— ди.

Шулай итеп, Гали солдат, ягъни табиб инде, риза була дәваларга.

— Иң элек,— ди,— кызыңны күреп чыгам әле,— ди.

Кыз янына патша белән бергәләп керәләр. Кызны карый.

— Ай-ай-ай, моның хәлләре бик авыр икән, бик мөшкел икән, ди.— Моны дәвалау өчен, беләсезме, патша галиҗәнаблары,— ди,— сез, ди,— шәһәрдән читтә аулак урында биеклеге егерме метр, иңе егерме метр, буе егерме метрлы бер сарай салдырыгыз,— ди.— Тактадан гына булса да оештырыгыз,— ди.— Аның эчендәге кешене читтәге кеше күрерлек булмасын,— ди.— Сарай янына беркем дә килергә тиеш түгел. Сарай-

дан бер кырык метр еракльıкта бер чокыр казып куегыз. Шул чокырга бер кеше куегыз, ул мин кычкырганны ишетерлек булсын,— ди.— Минем элемтәче шул булыр,— ди.— Менә шул сарайның уртасына түшәменнән өч чылбыр төшереп шуларга җиде батман су керешле бер казан асып куегыз, ди. Шул казанның астына ут ягып кайнарга куярсыз,— ди.— Ә казанның өстенә тагын ике аршын чамасы биеклектә өстәл тактасы кебек бер такта куегыз, шул тактага кызыгызны бастырып бәйләп куегыз,— ди.— Янына өч аршын саплы бер чүмеч куегыз,— ди.— Шуны эшләгәчтеннән мине чакырырсыз,— ди,— мин әлегә ял итеп торыйм,— ди.

Мондый хәлне кыйландырырга булгачтыннан, патша бик риза була, чынлап та, бәлки, булдыра торган кешедер инде, дип.

Солдат патша сараенда ашап-эчеп тәрбияләнеп ята. Сарайны эшләп, эшен бетереп куялар. Җиде батман су керешле казанны кайнатып, кызны кайнар су өстенә бастырып, бәйләп куйгачтыннан солдатка, табибка инде, эндәшәләр.

Табиб өч төрле алмасын эзләп табып алып бара. Беркем юк инде монда, чокырда гына берәү тора.

Барып керә. Керә дә, өч аршын саплы чүмеч белән казаннан кайнап торган суны алып, өстенә сибеп җибәрә тегенең, кызның инде, җен карчыгының. Җен карчыгы чырылдап, акырып җибәрә.

— Кемгә эләккәнеңне белдеңме инде? — ди.— Кем кулына дәваланырга эләккәнеңне белдеңме? — ди.

— Белдем, белдем, шул Гали солдат бугай,— ди.

— Әйе, Гали солдат, ди. Менә хәзер котыла алмассың инде миннән,— ди.— Менә шушы кайнар су белән пешереп үтерәм дә чыгып качам мин,— ди.— Әгәр дә тереләсең, үз хәлеңә кайтасың килсә, минем янчыкны, минем шинельне, минем таякны бирәсең,— ди.— Шуны бирмичә котыла алмыйсың син миннән,— ди. Шуннан: — Мә,— ди дә, урта яшьләр тирәсенә төшерә торган алманы бирә.— Мә, аша шушы алманы,— ди.

Шул алманы ашагач, бу — кеше хәленә кайта. Урта яшьләр тирәсендәге хатын-кыз хәленә кайта да басып тора инде. Ну шулай да аркасындамы, кай төшендәдер, теге чүмеч белән җибәргән су, йоннар арасыннан үтеп, бераз пешергән, шунысы гына бар.

— Бирәсеңме әйберләрне? — ди, Гали солдат әйтә.

— Мин аларны хәзер ничек итеп бирим,— ди,— мин бит монда,— ди,— бөтенләй борылырлык хәлдә түгел,— ди.

— Бирәсең килсә,— ди,— менә, ди, минем элемтәчем монда,— ди,— мин шуны чакырып алам,— ди.

Чыга да кычкыра:

— Әй, элемтәче! — Элемтәче килә.— Кер әле монда,— ди.

Керә теге.

— Сөйлә сүзеңне,— ди, кызга әйтә солдат.

— Минем үземнең тора торган бүлмәмдә,— ди,— ятагымның баш астында төреп куелган шинель бар,— ди,— янә анда бер таяк та бар,— ди,— таягы-ние белән шул төргән шинельне актармый-нитми алып кил монда,— ди, элемтәчегә әйтә.

— Бар, үтә,— ди Гали солдат.

Чыгып китә элемтәче. Күпмедер вакыттан китереп бирә шинельне. Таяк та бар, шинель дә бар. Актарып карый: шинель эчендә янчык та бар.

— Менә бусы булды болай булгач. «Миннән котыла алмыйсың»,— дип әйттем бит мин сиңа,— ди,— барыбер котыла алмассың,— ди. Менә бу алманы аша,— ди дә, тагын кешенең яшь чагына әйләндерә торган алманы биреп ашата да: — Менә терелдең, күрдеңме? — ди.— Башта мин сине җен ясадым, хәзер кеше иттем,— ди дә чыга да шул килеш югала. Солдат юк.

Кайта да ресторанга керә. Керсә: Гәрәй дә юк, Вәли дә юк. Вакыт күп үткән хәзер. Кая барырга? Тегеләр нишләсеннәр? Алар шул кесәдә булган калдык-постык акчалары белән туенып ятканнардыр да инде, хәзер чыгып киткәннәр.

Шәһәр буйлап аптырап йөри башлый бу хәзер. Йөри торгачыннан: «Туктале, булмаса, бер кабакка кереп, әзрәк күңел ачып чыгыйм»,— ди. Кабакка керсә, Вәли белән Гәрәй солдатлар шунда басып торалар.

— Нишләп торасыз?

— Нишләп торыйк, менә акча бетте, гостиницадан куып чыгардылар, кесәдә калган биш тиенгә рюмка сатып алдык та кабактан аракы алган кешегә рюмка биреп торабыз, шуның хакына безгә закуска бирәләр, бер рюмка каптыралар. Менә шуның белән көн күреп ятабыз,— диләр.

— Ярар, бөтен әйбер кире кайтты, әйдә киттек кире гостиницага,— ди Гали.

Китәләр болар гостиницага. Анда әйбәтләп яңадан элеккечә урнашып, матур гына яши башлыйлар.

Шулай ару гына яшәгән вакытта Франциягә бер ил сугыш башлый.

Чын сугыш башлана хәзер. Сугышка әзерлек начар булгандырмы, Франция бу илгә каршы тора алмый. Шуннан кызы әйтә патшага:

— Әти, булмаса, без теге солдатларга мөрәҗәгать итеп карыйк. Солдатлар барыбер дә бер нәрсә эшләр, аларда могҗиза күп,— ди.

— Нинди солдатларга? — ди патша.

— Бәй, үзең беләсең бит, хәтерендәдер, сарай түбәсен очырдылар ич,— ди,— шулар очырды бит инде,— ди.

— Бәй, аларны каян беләсең?

— Бик яхшы беләм мин аларны, кемнәр икәнен,— ди.— Алар безнең ресторанда ашап-эчеп яталар, гостиницада торалар шунда. Аларның бер эшләре дә юк, кәрт сугалар да кереп сыйланалар. Ә үзләре шундый бик зур могҗизалар эшли торган кешеләр алар,— ди.

— Бәй, алайса, танышың булгач, кызым, барып кара.

Ну сугыш бара. Сугыш Парижга якынлашып килә. Наступайт итә теге сугыш башлаган ил.

Шуннан кыз кереп китә солдатлар янына.

— Вәт шулай, шулай, шундый, шундый хәл. Беләсез, илебезгә фәлән ил сугыш башлады[1]. Шул сугыш менә хәзер Парижга якынлашып килә. Сез безгә ярдәм итә алмыйсызмы дип килгән идем,— ди.

— Кирәк кеше үзе килсен! — диләр болар кызга.

— Бәй, кемгә кирәк булсын, миңа кирәк,— ди кыз.

— Юк, син патша түгел, кирәк кеше үзе килсен.

Шуннан кайта да кыз, әтисенә әйтә:

— Вәт, шулай-шулай әйткән идем: «Кирәк кеше үзе килсен, син патша түгел»,— дип әйттеләр.

— И кызым, патша башым белән шуларга ничек барып ялыныйм инде,— ди.

— Әти, кирәк булса, ялынабыз инде,— ди.

Шулай дигәченнән, Франциянең патшасы мәҗбүр була бу солдатлар янына керергә.

Ә болар ул көнне патша кергәндә эчкәннәр-исергәннәр дә аны-моны белмичә яталар. Начар сүзләр белән сүгеп чыгарып җибәрәләр моны.

Шуннан патшаның зәһәре килеп кайтып китә. Боларны арестовайт итәргә дә уйлый, ну арестовайт иттерми, кайта да тагын кызына әйтә:

---

[1] Әлеге илнең исемен дә әйтеп сөйлидерие ул Закир карт, менә кайсы ил икәнен гел онытканмын.— Ә.Яхин искәрмәсе.

— Ул дураклардан нәрсә көтәсең,— ди.— Алар бит исерек, исеректә акыл буламы? — ди.— Шулардан ярдәм сорарга дип әйтәсең,— ди.

— Әти, аларның исерек чаклары гына туры килгән. Айнык чакта алар начар кешеләр түгел. Барыбер безнең сорауны үтәрләр,— ди.

Шуннан әтисе яңадан китә солдатлар янына икенче көнне. Бу юлы болар айнык булалар. Кич белән була бу. Патша үзенең гозерен сөйләп бирә:

— Һәй, кичке башка караганда, иртәнге баш акыллырак була, бүген соң инде, иртән берәр нәрсә уйларбыз әле,— диләр болар.

Ә теге сугыш инде гостиницага якынлашып килә. Солдатлар чыгып карап торалар да: «Бәй, безгә рәт бетә бит гостиницада ятарга, давай, булмаса, берәр нәрсә кыйланып карыйк»,— диләр.

Бер якка чыгып басалар да таякны ыргыталар. Шул вакыт чынлап та иге-чиге булмаган, санап бетергесез гаскәр барлыкка килә, армия. Тешләре-тырнакларына кадәр коралланган инде полный.

— Ни боерасыз, таяк хуҗасы? — дип сорый командир.

— Менә Парижга килеп җиткән армияне тар-мар итәргә!

Шунда ук болар тар-мар итү эшенә тотыналар. Бер көн үтә, ике көн үтә, өч көн үтә — боларны куып чыгаралар Франциядән.

Франция үзендә ниндидер зур көч барын сизә хәзер. Франциянең патшасы шушы өч солдатка таянып: «Тукта, булмаса, мондый көч барында мин Аурупаны яулыйм»,— дип карар кыла. Үзенең гаскәрләре белән сугыш башлый, әллә ни алга бара алмый башласа, солдатларга эндәшә. Солдатлар үзләренең таякларын эшкә кушалар да тиз генә могҗиза эшләп ташлыйлар, шуннан Франция алга баруын дәвам итә. Болар таякларын алып кайтып китәләр дә тагын ресторанда ята бирәләр.

Шулай итеп, бервакыт Россия җиренә килеп җитәләр болар. Франция Россия җиренә килеп җиткәченнән шактый каршылыкка очрый. Ну монда инде Франция патшасы: «Армиягезне алмагыз» димәкче була. Ә солдатлар, бигрәк тә Гали, тагы бер четерекле нәрсә уйлап таба:

— Өч кызыңны безгә бир. Өч кызыңны да безгә кияүгә бирсәң, без бергә барабыз сугыш белән,— диләр.

Моны ишеткәч, патшаның бик эче поша. Ничек инде бу алама гына солдатларга кыз бирмәк кирәк?! Кайта да бу турыда кызына сөйли. Үзе киңәшләшә торган иң олы кызына. Олы кызы:

— Әти, син элекке вәгъдәләрең буенча барыбер дә мине шуларның берсенә бирергә тиеш идең. Ничек инде ул, шулар бит мине терелтүчеләр.

— Шулай укмыни? — ди патша.

— Шулай булгачыннан, бәлки, риза да булырга туры килер, әти,— ди. Шулай итеп, кыз риза була. Әле бит сеңелләре дә бар.

— Ә минем сеңелләр нишли соң әле? — ди.

— Сеңелләреңне дә ризалатырга туры килер инде,— ди патша.— Солдатлар бит өчебезгә өч кызыңны дип әйтеп сорыйлар,— ди.— Шулай дип әйтеп сорагач, бирмичә булмас инде,— ди.

Боларны чыннан да өйләндереп куялар. Хәзер Аурупаның Россиядән башка өлешен яулап алгачыннан, үзләренә күрә зур мәҗлес тә, туй да ясау була бу. Шул ук вакытта кыз бирү мәҗлесе дә итеп саныйлар моны.

Хәзер Франция гаскәрләре Мәскәүгә килеп җитәләр. Мәскәүгә килеп кергәч, өч кияү үзләре бергә хезмәт иткән урыс солдатларын очратканнар да, аларда кунакта булып, яңадан урысчалатып эчәргә тотынганнар. Шуннан исерешеп, иң элек таякларын югалтканнар, аннары шинельләрен дә югалтканнар. Шулай итеп, дан-шөһрәтләрен югалтып, французларны җиңелүгә дучар иткәннәр.

Французлар җиңелгәч, француз хатыннарын да югалтканнар. Инде акча янчыклары да югалганчы дип, Сөембикә, Мәрьям, Мәдинәләрне эзләргә тотынганнар. Аларны табып, очрашканнар-кавышканнар да, шул шатлыктан тагын урысчалап эчәргә тотынып, исерешеп, янчыкны да югалтканнар.

Шуннан соң бу солдатлар гадәти генә, могҗизаларсыз гына яши торган ил кешесе хәлендә калганнар.

Бүгенге көндә дә, бернигә дә кайгыра белмичә, яшиләр, ди, үзләре. Казанда берсен, Ырынбурда берсен, Әстерханда берсен күргәннәр дип ишетелә ул солдатларның[1].

23. Булдыклы егет һәм Сәмрук патша

Борын-борын заманда бер карт белән карчык яшәгән. Боларның бер малайлары була. Авыл мәктәбен бетергәч, шәһәргә китеп укырга ният итә бу. Ничектер иптәшләренә өлгерәлми дә, үзе генә китә.

Йөри, йөри малай шәһәр буйлап, күп кеше җыелган җиргә барып

[1] Чүтки Закир карт сөйләгәнчә үк итеп сөйли алмадым инде.— *Ә.Яхин искәрмәсе.*

керә, мәктәп шушыдыр инде, дип. Анда карта уйнарга өйрәтәләр икән.

— Нәрсә, егет, карта уйнарга өйрәнергә килдеңме? — диләр.

— Әйе,— ди инде малай, аптырап.

— Бер ел укыйсың, елына йөз сум түлисең, ашау — бездән, кием — бездән,— диләр.

Моның атасы йөз сум биреп җибәргән була, түли дә укый башлый. Ел тулгач кайта бу. Атасы сорый:

— Нәрсә, улым, укыдыңмы? — ди.

— Юк, әти, карта уйнарга өйрәндем,— ди.

Ата кеше нәрсә дисен инде, ачуланмый, икенче елны тагын йөз сум бирә дә:

— Улым, бу юлы укып кайт инде,— ди.

Бара. Тагын шулай шәһәр буйлап йөри-йөри, әдрис тә булмагандыр инде, йөри торгач, тагын шулай күп кеше җыелган җиргә керә, мәктәп шушы булса кирәк дип. Анда керсә, музыка мәктәбе булып чыга бу.

Сорыйлар моңардан:

— Нәрсә, егет, музыкага өйрәнергә килдеңме? — диләр.

— Әйе,— ди малай.

— Бер ел өйрәнәсең, йөз сум түлисең, ашау — бездән, кием — бездән,— диләр.

Уку беткәч кайта да, атасы сорый:

— Нәрсә, улым, укыдыңмы? — ди.

— Юк, әти, музыкага өйрәндем,— ди.

Ата кеше ачуланмый инде, өченче елны тагын йөз сум бирә дә:

— Улым, бу юлы укырга тырыш инде,— ди.

Бу юлы инде мәктәпне белеп барып керә. Тагын шулай йөз сум түли дә укый башлый. Бик яхшы билгеләргә генә укып бетереп кайта. Кайткач атасы сорый:

— Ничек хәлләр, улым, укыдыңмы? — ди.

Бу инде куанып әйтә:

— Укыдым, әти,— ди.— Әти, сат мине базарга чыгарып өч йөзгә,— ди.

Атасы моны базарга алып чыга. Элек заманда шулай кешене дә сата торган булганнар. Бу егетне сәүдәгәрләр сатып алалар.

Бабайга әйтәләр:

— Ике атнадан соң малаең үзеңә кайтыр,— диләр.

Акчаны бабайга бирәләр дә егетне алып китәләр. Егет ике атна рәхәтләнеп күңел ачып, ашап-эчеп йөри. Ике атнадан соң егеткә әйтәләр:

— Хәзер хезмәт итәрсең,— дип.

Бер атны җигеп, берсен тагып, юлга чыгып китәләр. Бик озак барганнан соң, бер тауга җитәләр. Ул тауның башына менеп җитәрлек түгел икән, пыяла төсле шома тау, ди. Тау кырыена барып, тагып килгән атны суеп, эчендәгеләрне алып тазарталар да егеткә әйтәләр:

— Син шунда кереп ятасың да, менә пычак, без тегеп куябыз да, сине кошлар төшеп алып менеп китәрләр дә, җиргә куйгач, син пычак белән ярып чык. Аннан кошлар качарлар. Ә син безгә тау башындагы кыйммәтле ташларны ыргыт, аннан соң без сиңа ничек төшәргә икәнен әйтербез,— диләр.

Бу егет олау тулганчы андагы кыйммәтле ташларны төшерә, олау тулгач, тегеләр китеп баралар. Моңа:

— Ничек менден — шулай төш,— дип кычкырганнар.

Бу бичара ары йөгерә, бире йөгерә, һичбер кайдан төшәргә урын табалмаган. Анда гел адәм сөяге дә, ат сөяге, ди. Шуннан соң бу тау өсте белән бик озак йөгергәннән соң, урман кебек камышлыкка барып кергән. Анда керсә, бер зур гына өй, ди, анда карт белән карчык яши, ди. Карт — йөзьеллык кошлар патшасы икән. Бу егет сәлам биреп барып кергән дә үзенең хәлләрен сөйләп биргән.

— Ярар, улым, без кунакка китәбез, син безнең өйдә каласың,— дигән карт.

Болар киткәч егет андагы нәрсәләрне тамаша кылып йөргәндә, бер күл күрә. Күл сөт кебек ап-ак икән. Ныгытып карап бетерергә дә өлгермәгән, һавадан өч күгәрчен очып килгән. Бу егет күренмичә генә карап торган. Күгәрченнәр киемнәрен салып өч кызга әверелгәннәр дә су коена башлаганнар. Аннары судан чыгып, күгәрчен киемнәрен киеп, тагын очып киткәннәр. Бу егет шуның берсенә күз атып калган.

Берничә көннән бабайлар да кайткан. Егет кыйссаны бабайга сөйли. Бабай әйтә:

— Алар, улым, киләсе ел шушы вакытсыз килмиләр,— ди.

— Бабай, мин аларны көтәрмен инде, бер ел тиз үтеп китәр әле,— ди.

Әкият тизлеге белән бер ел үтеп тә китте, ди. Кызларның килер вакыты да җиткән.

Бабай әйтә:

— Качып кына карап тор, кайсына күзең төшкән булса, шуның күгәрчен киемен яшер дә минем янга алып кер,— ди.

Егет шулай эшли дә: тегеләр суга төшкәч кенә күгәрчен киемен ала, кыз ничек кенә ялынмасын, егет киемне бирми — бабай янына алып керә.

Бабай әйтә:

— Тәкъдир буенча сезгә никахланырга вакыт җитте,— ди.

Бабайларда бераз торганнан соң, кыз да егет авылына барырга риза була. Әлеге күгәрчен киемен киеп, егетне атландырып, очып китәләр.

Кайтып җиткәч, кыз багана башына куна да:

— Бар, син кер,— ди,— кара аны — озак торып онытма, әгәр дә онытсаң, мин Гәүһәрнәки шәһәрендә булырмын,— ди.

Бик озак торып кайткач, ата-анасы да, күршеләре дә уратып алганнар да сорашалар икән. Егетнең исенә төшеп йөгереп чыкса, багана башында җилләр искән була.

Егет атасына әйтә:

— Әти, тагын сат мине,— ди.

Атасы базарга алып чыга улын. Бу егетне шул ук сәүдәгәрләр ала, күп вакыт үткән булганга, моны исәндер дип уйламыйлар да инде.

Тагын шулай баштагы тәртип белән тау башына кошлар алып менеп китә егетне. Болар кычкыралар:

— Шундагы ташларны төшер, аннары без ничек төшәргә өйрәтербез,— диләр.

Егет әйтә:

— Ничек төшәргә икәнен мин сездән башка да беләм,— ди, бер таш та ыргытмый, турыга бабай янына йөгерә.

Барып исәнләшкәч тә, егет үз хәлләрен сөйли:

— Бабай, ярдәм ит инде, ул: «Мин Гәүһәрнәки шәһәрендә булырмын»,— диде, анда ничек барырга була? — ди.

Бабай әйтә:

— Мин ул шәһәрне ишеткәнем юк, минем абзый — ике йөз еллык кошлар патшасы, ул белсә белер,— ди, абзасына хат язып, моны кошка атландырып җибәрә.

Анда баргач, абзасы әйтә:

— Мин андый шәһәрне ишеткәнем юк. Минем абзый өч йөз еллык кошлар патшасы, белсә, ул белер,— ди, хат язып, кошка атландырып җибәрә моны.

Хатны укыгач, абзасы бар булган кошларны җыеп сорый — берсе дә килми. Бер күгәрчен әби әйтә:

— Мин беләм аны, ул бик ерак, кош очышы белән бик озак барырга,— ди.

Шулай булса да, бабай бер кошка атландырып җибәрә егетне. Бик озак очканнан соң, барып җитәләр. Кош әйтә:

— Менә мин китердем, калганын үзең кара инде,— ди.

Егет шәһәр буйлап бара икән, менә өч кыз судан кайталар. Шуның берсе моның кәләше була.

Өйләренә алып кайта да егетне, атасына әйтә кыз:

— Тәкъдир буенча без кушылырга сүз куешкан идек, ул мине эзләп килгән. Әти, риза бул,— ди.

Атасы әйтә:

— Юкны сөйләмә, әле абзаң өйләнмәгән,— ди.

Кыз әйтә:

— Ул бит тимәс таякка ата. Өйләнә дә алмый ул,— ди.

Шуннан бу егет сорый кыздан:

— Нәрсә булды, ничек? — ди.

Кыз әйтә:

— Абзам патша кызына өйләнергә йөри, ә кыз бер генә сорау бирә дә, өч көннән сорауга җавап бирәлмәсәләр, җәзалап үтертә.

Егет әйтә:

— Аның өчен үзем барып карыйммы? — ди.

Кызның җибәрәсе килми:

— Булмас,— ди.

Шулай да егет китә, патша кызы янына кереп хәлен сөйли. Кыз сорау бирә:

— Гөл Сәмрукны нишләткән, Сәмрук Гөлне нишләткән? — ди, өч көн срок бирә.

Бу егет, аптырап, качып китәргә җыена, хатын кайгысы да юк, качарга уйлый. Мылтык алып: «Ауга чыгып керәм»,— дип, урманга китә.

Егет урманда арып, бер агач төбенә ял итәргә ята. Агач башында кош оясы, анда кош балалары — икәү. Егет йокымсырап ятканда, агач буенча үрмәләп аждаһа менеп бара икән. Егет күзен ачып җибәргән дә мылтыктан аткан. Аждаһа сыерылып[1] җиргә төшкән. Озак та үтми, Сәмрәү кош үзе дә очып кайткан. Балаларының исән икәнен күргәч,

---

[1] *Сыерылу* — сыдырылу.

сайрап та җибәргән. Балаларын гел аждаһа ашый торган булган. Аларны бу егет коткарганын белгәч, кош егеткә әйтә:

— Моның өчен мин сиңа нәрсә бирим? — ди.

Егет әйтә:

— Миңа бернәрсә дә кирәкми, миңа ярдәм генә ит. Патша кызы миңа шундый сорау бирде: «Гөл Сәмрукны нишләткән, Сәмрук Гөлне нишләткән?» — ди.

Кош әйтә:

— Анысын мин дә белмим. Сәмрук ул — патша, бик еракта инде ул. Шулай да мин сине анда илтә алам. Калганын үзең карыйсың инде.

Шулай итеп, Сәмрәү кош егетне, өстенә атландырып, Сәмрук патшага алып килә. Кош кайтып киткәндә әйтә:

— Ал йолкып йонымны, бәлагә төшсәң, утка салып яндырырсың да, мин ярдәмгә килермен,— ди.

Егет әйтә:

— Ничек кулым барып йолкып алыйм инде, шушы хәтле ярдәм итеп,— ди.

Кош үзе йолкып бирә.

Бу егет Сәмрук патшага барып керә, ул да бер генә сорау биреп, күп кешене дарга астырган. Егет аңа патша кызы әйткән сорауны бирә.

Патша әйтә егеткә:

— Белеп үлим дисәң, әйтәм: инде үләсең килмәсә, белмичә генә кайтып кит,— ди.

Егет әйтә:

— Үлсәм дә, белеп үлим инде,— ди.

— Алай булгач, әйтәм,— дип сөйли башлый патша.— Мин үзем — Сәмрук, Гөл — минем хатыным. Ул мине ташлап дию пәриенә качып китте. Мин шушы этем белән барып, сугышып алып кайттым. Хәзер мин аны нишләттем? — дип, бер сарайга алып керде.

Ул хатынын тере килеш стенага кадаклап киптергән.

— Менә, егет, үләр минутларың да якынлаша,— ди.

Дар агачы янына күп кеше җыелган. Егетне җәлләп кайсы алтын ыргыта икән, кайсы — көмеш, ыргытканын берсен янчыкка сала бара икән бу. Кешеләр көләләр, ди: «Адәмдә нәфсе[1] диген инде, үләр минутында да мая җыя!» — диләр.

---

[1] *Нәфсе* — нәфес.

Егет әйтә:

— Падишаһым, әллә гүр суыгы алды, зинһар, ут ягып җылыт әле,— ди.

Патша ягарга куша. Асарга биш минут калды дип санап торганда, егет әлеге кош йолкып биргән йонны утка ташлый да, озак та үтми, һавада гөжләгән тавыш ишетелә. Шул арада кош, төшеп, егетне күтәреп ала да очып китә. Халык шау-гөр килеп кала.

Егет кайтышлый ук әлеге кыз янына керә.

— Нәрсә, егет, әллә белдеңме? — ди.

Егет сөйләп бирә. Кыз әйтә:

— Хәзер мин синеке инде,— ди.

Егет әйтә:

— Мин үзем өчен йөрмәдем, минем хатыным бар,— ди.

Кыз әйтә:

— Ярар кем өчен булса да,— ди.

Егет тегеләргә барып кыйссаны сөйли дә, кызны барып алалар, ике туйны бергә ясыйлар.

Анда берничә вакыт торганнан соң, егет авылына кайталар. Озак торырга өлгерәлмиләр, күгәрчен киемен егет яшермәгән була — кыз кия дә очып китә. «Китсәң китәрсең инде»,— дип, бу кабат аның артыннан бармый.

Егет атасына әйтә:

— Әти, мине тагын базарга алып чыгып сат инде,— ди.

Бик ялынгач, атасы риза булып, базарга алып чыга. Анда аны бүтән сәүдәгәрләр ала.

Озак та тормый, сәүдә эшенә китәләр. Дала буйлап бик озак барганнан соң, боларның бик каты эчәселәре килгән. Беркайда да су юк, ди. Дала уртасында өсте япкан бер кое бар икән. Өстен ачканнар шуның. Ничек төшәргә? Кое тирән икән. Аптырап тормыйлар — яңа кешене бәйләп төшерәләр. Егет кычкыра икән:

— Монда су юк, көмеш кенә,— дип.

Боларга олау тулганчы көмеш биргән инде. Чыгам дигәндә генә бауны кисәләр дә, егет коега мәтәлеп төшеп китә. Тегеләр китеп тә бара.

Хәзер бу егеткә үлемнән башка берни дә юк. Караса, кое стенасында — бер ишек. Ишекне ачып караса, анда бер дию көч-хәл белән сулап ята, үләр чиккә җиткән, ди. Караса, бер скрипка эленеп тора икән. Бу егет: «Азак гомеремдә бер уйнап калыйм әле»,— дип әйтеп, кызып-кызып

скрипка уйный башлаган. Бу уйнаган саен, дию хәлләнә икән. Шуннан бөтенләй исәнләнеп торып утырды, ди.

Дию әйтә:

— Әй, егет, моның өчен мин сиңа нәрсә бирим, бу бит — минем җаным,— ди,— әгәр син уйнамаган булсаң, мин үлгән идем,— ди.

Егет әйтә:

— Миңа бернәрсә дә кирәкми, мине моннан чыгар гына,— ди.

Җир асты юлы белән барып, дию бу егетне тегеләрне уздырып та куйган. Мондый хәлне күреп, тегеләр бик аптырап гаҗәпләнгәннәр.

— Менә бит бау начар булган да өзелде,— диләр.

Шулай да бергә киткәннәр. Кәсепләре дә бик уңган. Кайтырга җыенганнар. Бу егетне алдан җибәргәннәр:

— Без әле бер өч көнсез кайтмыйбыз, менә шушы хатны хатынга алып кайтып бир,— дигәннәр.

Кайтып киткән бу. Юлда моның исенә төшкән: «Мин бу хатны укып карыйм әле, ни өчен мин укып йөрдем соң? — дигән. Укып караса, хатта язылган була: «Кайтып керү белән, бу кешене юк итегез, ул безгә күп байлык табып бирде — ул бездән үч алыр»,— дип. Ә бу егет үзе дә төшеп калганнардан булмый, тота да: «Без әле тиз кайтмыйбыз. Кайту белән егетне кызга никахландыр, ул безгә күп байлык табып бирде»,— дип яза. Тегенең язуы белән бер дә аермасы юк, ди.

Тегеләр дә икенче көнне кайтып җиткәннәр. Хатыннан әкрен генә сорыйлар икән:

— Нишләттегез? — дип.

Хатыны әйтә:

— Үзең әйткәнчә эшләдек, әнә кызың белән келәттә кәләштә яталар. Үзең шулай язгансың,— дип, хатны бирә.

Ире караса: үзе язуыннан һич тә аерып булмый, гаҗәпкә калып, аптырап китә. Аннары әйтә:

— Ярар, ничек булса да булган, тора бирсеннәр инде,— ди.

Ярар. Егет кәләшенә әйтә:

— Әнә тегендә нинди ут ул, бер дә сүнми? — ди.

Тегесе әйтә:

— Анда патша карта уйный,— ди.

Егет:

— Мин дә барып карап кайтыйм әле,— дип җыена башлый.

— Барма, ул күпләрнең башына җитте,— ди.

— Мин уйнамыйм, карап кына торам,— дип чыгып китә.

Барса, патша моны бик ачык йөз белән каршы ала:

— Син йөзенче кеше буласың, туксан тугызның башы киселде,— ди.

Шулай да уйнарга тотыналар. Беренче уенда ук бу егет ота. Икенче уенда да ота.

Патша әйтә:

— Син дөрес уйнамыйсың,— ди.

Тагын уйнарга керешәләр, тагын теге егет ота. Патша инде чыгырыннан чыгып ачулана башлаган икән.

Аларның үзләренә күрә кәмиссияләре бар икән, алар: «Инде җитте сиңа, күп кешене әрәм иттең»,— дип, патшаның башын чабып өзәләр дә бу егетне патша итеп куялар. Патшаның кызын да аңарга бирәләр. Бу:

— Минем хатыным бар, миңа кирәкми,— дисә дә:

— Законга каршы киләлмисең,— диләр.

Шуннан соң бу егет тегендә кайтмый, патша кызы белән яшәп, патша булып тора монда.

Бервакыт, патша бит инде бу хәзер, халыкны җыя да үзенең башыннан үткәннәрен сөйли — теге сәүдәгәрләр турында. Шунда кайсылары кычкыра: «Асарга!» — дип, кайсылары кычкыра: «Атарга!» — дип. Патша әйтә:

— Атмыйбыз да, асмыйбыз да, безнең илдән генә чыгып китсеннәр,— ди.

Болар әтисен-әнисен дә яннарына алып килеп, яхшы гына гомер итәләр, ди, әле дә булса.

24. Җен кызы Гөлбану

Борын заманда була бу хәл. Сөләйман пәйгамбәр үзе үлгән вакытта мөселман җен патшасын чакырта да әйтә:

— Мин үлгәч, берничә елдан соң дөньяга берәү туар. Үсеп җитеп, шул бәндә патшалык итәр. Шуңарга миннән бүләк итеп менә шушыларны бирерсең,— дип, бер ат, бер тун бирә.

Пәйгамбәр әйткәнчә, чыннан да берәү дөньяга килә. Әкияттәге гомер бит яшен тизлеге белән үтә. Бу да, үсеп җитеп, патша була. Теге җен Сөләйман пәйгамбәрнең бүләкләрен китереп тапшыра моңа.

Ярар. Патша булгач, вәзире дә була инде; вәзирнең дә, патшаның да

малайлары туа. Ике малай бик дус булып үсәләр. Патша үз малаен ничек тәрбияләсә, вәзир дә, малаен шулай тәрбияли.

Бу малайлар бик тиз үсеп, унсигез яшькә җитәләр. Патша бу егетләрне Сөләйман пәйгамбәр калдырган бүләкләр белән бүләклисе килә.

— Кайсысын кайсысына бирик икән? — дип, хатыны белән киңәшә.

— Әгәр дә атны үзебезнең малайга бирсәк, вәзир малае кимсенер инде,— ди.

Хатыны әйтә:

— Үз балабызны ничек тә көйләрбез, атны вәзир малаена бирик,— ди.

Шулай итеп, атны вәзир малаена, ә тунны үз малайларына бирәләр.

Болар тунның кесәсенә тыгылып карамаган булганнар. Бу егет тыгылып караса, аннан бер мөһер һәм бер кызның фотокарточкасы килеп чыккан. Егет фотога карап бик гашыйк булган. Бу егет көннән-көн саргая икән. Атасы-анасы да тун кесәләрен карамаганга үкенеп беталмыйлар икән.

Беркөнне атасына әйтә бу:

— Әти, миңа рөхсәт бирегез, мин йөреп, әйләнеп кайтам,— ди.

Атасы җибәрсә дә, аптырый, җибәрмәсә дә, жәлли — җибәрергә булалар.

Вәзир малае әйтә:

— Мин иптәшемнән калмыйм, үлсәк бергә үләрбез,— ди.

Атасы боларга гаскәр бирә дә, болар корабль белән суда баралар.

Берничә көн барганнан соң, көчле давыл чыгып, корабльне әйләндереп каплый. Бар да су астына китәләр. Ничектер патша малае өстә кала. Суда йөзә-йөзә бик арый. Су да бик киң, яр да ерак, шулай азапланып йөзә торгач, судан өскә чыгып торган бер карагайны күрә. Шунда йөзеп бара да, ул судан өскә чыгып торган бер таш була, шул таш өстенә утырып хәл җыя.

Бервакыт моның янына зур кара кош килә, моңарга һөҗүм ясамакчы була. Бу егет куллары белән селтәнгәләп байтак утырганнан соң, бер уйга килә: «Ул миңа һөҗүм иткәнче, мин үзем аңарга асылыныйм»,— ди. Теге кош моны эләктерим дигәндә, кошның тәпиләренә үзе асылына бу. Кош моны су өстеннән ярга таба алып оча. Яр да бик ерак калмады — кош та арыды, түбәнәйгәннән-түбәнәя. Хәзер бу егет яртылаш суда бара. Яр якынлаша башлагач, кулын ычкындыра да, кош күтәрелеп китә. Кош, яр башына кунып, егетнең чыкканын көтеп тора, егет тә

судан чыкмыйча тора. Теге кош көтә-көтә дә очып китә. Егет тә, судан чыгып, яр буйлап китә.

Бара, бара, урманга барып җитә егет. Урманга керсә, урман уртасында бер өй күрә, анда барып керсә, бер кыз елап утыра, ди. Бу кыз моңарга:

— Абзый кеше, син моннан тизрәк кит, диюнең хәзер кайтыр вакыты җитә, икебезне дә харап итәр,— ди.

Егет әйтә:

— Ул үзенең җаны кайда икәнен әйткәне булмадымы? — ди.

Кыз әйтә:

— Су төбендә — сандык, сандык эчендә— күгәрчен, шул күгәрчен — аның җаны,— ди.— Аны алыр өчен Сөләйман пәйгамбәрнең мөһере кирәк,— ди.

Егет үзе белән мөһерне дә алып килгән була. Әйдә, киттек,— дип, кыз белән су буена китәләр.

— Сөләйман пәйгамбәрнең хакы хөрмәтенә су астыннан сандык чыкса иде,— дигәч, су ярыла да, сандык килеп чыга; сандык ачылуга, күгәрчен килеп чыга. Шул араны дию дә килеп җитә:

— Теләсәгез нишләгез — җаныма гына тимәгез! — дип ялынса да, күгәрченнең муенын борып ташлыйлар да, дию шунда ук егылып үлә.

Өйгә кереп хәлләрне сөйләп бетергәч, егет фотокарточканы күрсәтә. Кыз әйтә:

— Бу бит — минем дустым Гөлбану, мөселман җен патшасының кызы! — ди.

Егет әйтә:

— Син адәм затыннан булгач, ничек соң син җен кызы белән дус булдың? — ди.

Теге кыз сөйләп бирә:

— Җеннәр бит алар кояш баегач йөри торган булалар. Гөлбануны күтәреп, әнисе безнең тирәгә килгән дә, баласын калдырып, каядыр киткән икән. Гөлбануның бик елавына минем әни чыгып, жәлләп имезгән моны. Әнисе, килгәч, ачуланган, нигә имездең, дип. Сөтне сөт белән кайтарам, дип, аның әнисе мине имезгән. Шуннан без дус булып бергә йөрдек. Бервакыт бакчада күңел ачып йөргән вакытта Гөлбану үзен яшереп өлгерә алды, ә мине дию алып китте,— ди.

Шуннан соң егет белән кыз бу өйдән чыгып китәләр. Урман эче белән озак барганлыктан, боларның киемнәре дә ертылып беткән, ди. Кыз оялмасын диптер инде, егет әйтә:

— Мин синең туган абзаң булам, син минем туган сеңлем бул, икебездә күңел каралыгы булмасын,— ди.

Бара торгач, бер ачыклыкка барып чыкканнар. Ерак түгел юл күренгән. Юлдан кәрванчылар киләләр, ди. Бу егет ерактан кул белән ишарәләп сораган: «Сез мөселманмы?» — дип. Элек заманда шулай сорый торган булганнар. Тегеләр мөселман дип ишарәләгәннәр. Бу егет алар янына барып, хәлне сөйләп биргәч:

— Безне дә үзегез белән алыгыз әле,— ди.

Тегеләр:

— Әйдә,— диләр.

Егет әйтә:

— Мин үзем генә түгел, сеңлем дә бар,— ди.

— Аны да алып кил,— диләр.

Егет аны да алып килә. Сөйләшә торгач, бу кызга әйтәләр:

— Синең атаң белән бертуган абзаң безнең шәһәрнең башлыгы булып тора. Нишлик, кире борылыйкмы? — диләр.

Ничә көннәр килгәннәр, тагы шуның хәтле барасы бар икән. Егет әйтә:

— Вакытсыз чәчкә дә атмый, барасы җирегезгә барып җитик, аннан соң да өлгерербез,— ди.

Кәрванчыларның кәсепләре бик уңа. Боларны да тәрбияләләр, киендерәләр.

Кайткан вакытларында араларыннан берсен патшага сөенчегә җибәрәләр. Патша аны сөенчесе өчен бер зур шәһәргә баш итеп куя. Бу егетне патша үз урынына патша итә.

Патша итеп куйгач, егет аларда тора бит инде. Кызның әнисе аптырый боларга: урынны бергә җәяргәме, аерыммы? Шулхәтле озак гомерләр бергә булгач, бергәдер инде, дип.

Кыз әйтә:

— Әни, күңелегезгә шик китермәгез, ул мине үз сеңлесеннән дә артык саклап алып кайтты. Аның күңеле миндә түгел, Гөлбануда, аны эзләп йөреп миңа юлыкты ул,— ди.

Кояш баткач, җеннәр килеп йөри башлый. Кызның әнисе җеннәргә әйтә:

— Гөлбану килсен, Гөлҗамалны табып кайттылар,— ди.

Гөлбану әбисе белән килә. Гөлҗамал белән елашып күрешәләр. Гөлҗамал шундук бик күңелсезләнә. Гөлбану сорый:

— Сиңа ни булды, күңелсезләндең? — ди.

— Әй, дустым, минем антым бар бит. Мине коткарган егет сине эзләп йөреп, мине коткарды. Синең белән кавыштырам, дип, вәгъдә бирдем.

— Юк, дустым, мин адәми затка бармыйм,— ди Гөлбану.

Шуннан соң Гөлҗамал тагы да күңелсезләнеп, еларга тотына. Гөлбану чыгып китә.

Тәрәзәләрдән карап йөргәндә, Гөлбану яшь патшаны күрә, егетнең инде вәзирләр белән сөйләшеп утыруы була. Егет тә, тәрәзәдәге шәүләне күреп калып, чыгып китә. Анда чыкса, пәрәнҗә ябынган бер кыз басып тора, ди. Егет бара да пәрәнҗәне ачып карый. Теге кыз әйтә:

— Әй, вөҗдансыз егет, нигә минем рөхсәтемнән башка ачып карыйсың? — ди.

Егет әйтә:

— Мин ни нужалар күреп сине эзләп килдем дә, син битеңне ачып карарга да рөхсәт итмисең,— ди.

Кыз әйтә:

— Ярый, безнең сөйләшкәнне беркем дә күрмәсен,— ди дә йөгереп кереп китә.

Керсә, Гөлҗамалның һаман елавы була.

— Ярар, дустым, елама инде, син дигәнчә булыр, ул егет үземә дә бик ошады,— ди.

Шуннан соң барысы да бергә җыелышып киңәш итәләр. Киңәштән соң барысы да Гөлбанулар белән китәләр кыз сорарга.

Кайтып кергәч, карчык картына әйтә:

— Карт,— ди,— Гөлҗамалны табып кайткан егет хәзер патша икән, шул безнең Гөлбануны сорый. Бирсәк ничек булыр икән? — ди.

Карт әйтә:

— Бик яхшы булыр,— ди.

Шуннан соң, бар да бергә җыелышып, Гөлбануның әтисенә китәләр. Боларга серне чишәләр. Атасы якын да килми:

— Мин кызымны адәми затка бирмим,— ди.

Җыйнаулашып ялына торгач, чыдый алмый — риза була.

Шуннан соң бик шәп кенә туй итәләр инде, пәри туе булса да. Кыз белән бергә патшалыгын да бирә атасы. Хәзер бу яшь кенә кешегә ике урында патша булырга туры килә.

Шуннан соң күпме гомер узгандыр — анысы билгесез, бервакыт яшь патшаның вәзирләр белән бергә күңел ачып сәхрәдә, урманнарда

йөрисе килә. Мылтык алып ауга чыгып китәләр. Киткән чакта боларның ишек төбендә сәләмә генә киенгән бер хәерче басып тора икән. Патша өйдәгеләрне дәшеп чыгарып:

— Менә шушы хәерчене ашатыгыз, өстенә кием бирегез,— дип китеп бара.

Күңел ачып бик озак йөргәннән соң кайталар. Кайткач сорый патша:

— Теге кешене ашаттыгызмы, ул кая китте? — ди.

— Китмәде әле, ул монда,— диләр.

— Китерегез минем янга,— ди.

Патша моңардан сораша — теге кеше бәйнәләп сөйләп бирә, каян килгәнен, кем булганын:

— Иптәшемне эзләп йөрим, ди. Сәяхәткә китеп бәлагә юлыктык та бер-беребезнең исәнме-юкмы икәнен дә белмибез,— ди.— Мин — вәзир малае идем, ул — патша малае иде. Исәндерме-юктырмы, мин аны эзләп йөрим,— ди.

Патша әйтә:

— Эзләсәң дә, син аны табалмассың инде,— ди.

Теге әйтә:

— Табалмасам да, мин аның юлында үләрмен инде,— ди.

Патша:

— Син эзләгән кеше мин түгел микән, кара әле яхшылап,— ди.

Теге күрә дә һуштан язып егыла. Байтак ятканнан соң, аңына килеп, тора. Бер туйганчы кочаклашалар, елашалар. Берничә карамыйча, өч көн гүләйт итәләр. Аннары Гөлҗамалны аңарга кияүгә биреп, бөтен халыкны җыеп, туй итәләр. Мондагы патшалыгын да бирә дустына. Үзе хатыны ягына китә.

Ике дус ике патша булып, һаман яшиләр, ди әле.

25. Сәйфелмөлек һәм Фәтхелҗамал

Борын-борын заманда, ханнар яшәгән чорда, булган бер бабай. Ул бабайның бик матур, күркәм йөзле, нечкә билле, тал кебек зифа буйлы Сәйфелмөлек исемле улы булган. Сәйфелмөлекнең әтисе яуларда күп йөреп дан алган, төрле илләрдә, төрле җирләрдә булган, күп кешеләрнең фотопортретларын алып кайткан.

Көннәрдән бер көнне Сәйфелмөлек әтисе бүлмәсенә кергәч, бер фото-

рәсемне күрә, анда бик матур бер кыз була. Сәйфелмөлеккә уй төшә: «Бу кызны эзләп тапсам иде»,— ди. Сәйфелмөлек бу кызга гашыйк була.

Көннәр үтә. Сәйфелмөлек әтисе-әнисенә хәбәр итә:

— Әти-әни, мин сәфәр чыгып дөнья күреп кайтыр идем,— ди.

Әти-әнисе каршы килмичә, рөхсәт бирәләр. Алар егетне юлга хәзерлиләр, әтисе юлына алтын балдак та бирә:

— Улым, төрле куркыныч хәлләргә туры килгәндә менә бу алтын балдак сиңа файда итәр,— ди.

Малай алтын балдакны алып кулына кия.

Егетне әти-әнисе, фатыйха кылып, озатып калалар. Егет чыгып китә.

И китә, и китә, и китә егет, бик күп җирләр үтә. Менә берзаман бер шәһәр күренә. Бу шәһәрдә шундый зур таш йортлар салынган: зәңгәр болытларга зәңгәр таш йортлар терәлгән, ак болытларга ак таш йортлар терәлгән. Ләкин шәһәрдә бер тавыш юк, тып-тын. Тик елганың гына шаулап аккан тавышы ишетелә.

Егет бер зур йортка килеп җитә, биек баскычлардан күтәрелә, ләкин ишек йозаклы була. Ничек ачарга ишекне? Исенә төшә: «Тукта, минем әти биргән алтын балдак бар бит»,— ди. Алтын балдакны зур йозакка тидерүе була — ишек кинәт шылтырап ачылып китә. Егет өйгә керә. Керү белән бүлмәнең нәкъ уртасында, ефәк пәрдәләр эчендә бик матур кыз йоклап ята. Кызны уятып карый, ләкин кыз һич уянырга теләми. Нишләргә? Карый егет: кызның баш астында яшел такта ята. Яшел тактада сүзләр дә язылган була. Яшел тактаны тартып алу белән кыз уянып китә. Кыз уяна да, куллары белән күзләрен угалап:

— Сез адәм егетеме, җен егетеме, монда кошлар да очып килеп җитә алмый торган җирләргә сез ничек килдегез? — дип сорый.

Егет:

— Адәм егетемен,— ди.

Кыз тора, киемнәрен кия, юына. Сөйләшә башлыйлар. Егет кызның монда ничек килүе турында сораша башлый.

Кыз сөйли:

— Мин фәлән ханның иң кечкенә, өченче кызы идем,— ди.— Нәкъ унсигез яшемдә мине бирегә дию пәрие урлап килде. Мин хәзер биредә яшим,— ди.— Ә дию үзе Каф тавы артына, еракка-еракка сәфәргә чыгып китте,— ди.

Кыз егеткә ашлар хәзерли, егет юлдан арып-талып килгән, ашый. Кыз егеттән сорый башлый:

— Әгәр мөмкин булса, мине дә үзең белән алып китсәң иде,— ди.
Ә егетнең түш кесәсендә әтисе бүлмәсеннән алган фоторәсем була. Бу рәсемне кызга тиңләштереп карый егет, ләкин охшамый. Рәсемдәге кыз бу кыз булмый. Егет кызның исемен сорый. Кыз Мәликә икән. Ә егет үзенең Сәйфелмөлек икәнлеген әйтә. Кыз аңлата:
— Менә тиздән дию үзе дә кайта торган көннәр җитә,— ди.
Болар диюне үтерү турында план кора башлыйлар. Егет кызга менә нәрсә ди:
— Мин дию кайтканда идән астына төшеп утырырмын, син сорарсың: «Сезнең җаннарыгыз кайда? — дип.— Менә безнең җаннарыбыз үзебездә, ә безнең ишеткәнебез бар: пәриләрнең, җеннәрнең җаннары чүплек башларында, себерке асларында була, имеш»,— диярсең. Ул ачуланыр, ачуланса да сөйләр,— дип, кызны өйрәтеп куя.
Икенче көн дә килеп җитә. Өйләрне селкетеп, җилләр чыгарып, тузаннар туздырып, дию пәрие кайтып та төшә. Дию пәрие һавадан баскычка төшә, биләндә ачкычлары була. Ачкычларының берсе белән ишегенең зур йозагын ачып өйгә керә. Ә егет Мәликәне элеккеге кебек йоклатып куйган була, яшел язулы тактаны баш астына куеп. Дию пәрие килә дә язулы тактаны алып ташлый һәм Мәликә уяна. Дию пәрие:
— Уф, уф, адәм исе чыга, уф, уф, адәм исе килә,— дия башлый.
Мәликә аңа:
— Һи, үзең адәмнәр арасында йөрисең, адәмнәрне ашыйсың да, үзеңнең авызыңнан чыга торгандыр әле,— ди.
Мәликә диюне ашата. Кич җитә. Сөйләшеп йокларга яталар. Мәликә иркәләнеп кенә:
— Менә без адәмнәрнең җаннары үзебездә; пәриләрнең, җеннәрнең җаннары кай төштә була? — ди.
Дию пәрие тыңлый-тыңлый да:
— Минем җаным сиңа нәрсәгә кирәк?! — дип, бик ачуланып, Мәликәне ятактан сугып төшерә. Кыз тәгәрәп китә.
Елый Мәликә. Берничә сәгатьләр үтә. Дию пәрие бераз йомшара төшә:
— Йә, Мәликә, кил, әйтсәм әйтим,— ди.— Дәрья уртасында бер сандык булыр, ул сандык эчендә кечкенә генә яшел сандык булыр, ләкин ул сандыклар бикле булыр. Яшел сандык эчендә ике күк күгәрчен утыра. Әгәр дә ул күгәрченнәрнең башын борып дәрьяга ташласаң, мин үләчәкмен,— ди.
Болар йоклап китәләр. Алсуланып, кызарып таң ата. Дию пәрие

юлга әзерләнә башлый. Мәликәне йоклатып, ишекне бикләп чыгып китә. Һавага күтәрелеп, пырылдап-зырылдап очып китә.

Хәзер килик Сәйфелмөлеккә. Сәйфелмөлек идән астында дию пәриенең сөйләгән сүзләрен тыңлап яткан икән. Тиз генә идән тактасын күтәрә дә чыга. Мәликәне уята бу. Мәликә белән ерак юлга хәзерләнә башлыйлар. Дию пәриенең байлыгы гаҗәеп була. Мәликә дию пәриенең байлыгын күрсәтү өчен Сәйфелмөлекне амбарлар буенча йөртә. Беренче амбарны ачып караса, анда шундый зиннәтле киемнәр, нәрсә җаныңа кирәк! Бер сандыкка андагы зиннәтле киемнәрне тутыралар.

Сәйфелмөлек Мәликәгә үзенең нинди сәбәп белән юлга чыкканлыгын сөйләп бирә, үзен гашыйк иткән кызның рәсемен күрсәтә.

— Мәликә, менә нәрсә, мин сине дию пәрие кулыннан коткарам, син дә миңа шушы кызны табуда булышсаң иде,— ди.

Мәликә рәсемгә текәлеп карый, озак карап торганнан соң:

— Сәйфелмөлек, бу адәм кызы түгел бит, бу пәри кызы,— ди.

Сәйфелмөлек бер сүз әйтмичә тын алып торганнан соң:

— Юк, мин аны барыбер яратам, барыбер мин аны эзләп табарга тиешмен,— ди.

Мәликә вәгъдә бирә:

— Табармын,— ди,— ул кыз бездән ерак түгел, пәриләр авылында яши, мине дию пәрие урлап китергәч, минем аны күргәнем булды. Ул кызның исемен дә беләм. Аның исеме — Фәтхелҗамал,— ди.

Сәйфелмөлек юл киемнәрен киенә дә, урманда каен тузлары әзерләп, дәрья уртасына керү өчен каек ясарга керешә һәм каекка ике ишкәк әзерли. Амбардан алган сандыкны да каекка куялар. Дәрья бүген, бәхеткә каршы, тып-тын икән. Мәликә көймәнең түренә утыра, ә Сәйфелмөлек ишәргә керешә. Баралар, баралар да болар, дәрьяның уртасына килеп җитәләр. Дәрьяның нәкъ уртасы бераз дулкынланып китә. Йөзекле кулын егет дәрьяның уртасында болгатып ала, шул вакытны зур сандык килеп чыга. Сандык бикле була. Егет сандыкка әтисе бүләк итеп биргән алтын балдакны тидерә — сандык ачылып китә. Сандык эченнән яшел бәләкәй сандык килеп чыга. Ул да бикле була. Аңа шул ук балдакны тигезү белән ул да ачылып китә. Аның эчендә ике күк күгәрчен утыра. Сәйфелмөлек тиз генә күк күгәрченнәрне муеннарыннан борып дәрьяга ата. Дәрья өсте канлана, кызыл төскә керә. Бу вакытны бик көчле күк күкрәгән тавыш килә. Дәрья өсте дулкынлана. Дию пәрие чак кына боларның көймәсе өстенә килеп төшми. Ул калын тавыш белән:

— Ах, Мәликә, ашадың башымны,— дигәнечә дәрья төбенә төшеп тә китә.

Сәйфелмөлек тиз генә көймәне ишә-ишә, болар дәрьяның икенче ягына чыгалар. Көймәдән чыгып, сандыкны алып, юлга китәләр.

Киләләр, киләләр, киләләр. Бер сукмак очрый. Сукмак буйлап китәләр. Боларга Фәтхелҗамалны эзләп табарга кирәк бит. Уңында да, юлның сулында да кеше очрамый. Баралар, баралар, баралар да болар, бер авыл читенә килеп чыгалар. Авылга керәләр. Мәликә, Сәйфелмөлекне авыл читендә калдырып, Фәтхелҗамалларның өен эзләп китә. Нәкъ авылның уртасында бәләкәй генә бер өй була. Мәликә шунда барып керә. Керсә, өстәл янында бик матур кыз утыра. Ул Фәтхелҗамал була. Алар үзара сөйләшә башлыйлар. Мәликә башыннан үткәннәрне сөйләп бирә. Аннан соң Фәтхелҗамал янына ник килүен әйтә:

— Мине дию кулыннан коткарган егет, синең рәсемеңне күреп гашыйк булган, сине эзләп килгән,— ди.

Егетне күреп сөйләшкәч, ул Фәтхелҗамалга ошый. Ләкин Фәтхелҗамал егеткә өч шарт куя, әгәр шуларга риза булса, кияүгә чыгачагын белдерә. Егет риза була.

Шуннан соң болар туган якларына карап юлга чыгалар. Кайталар, кайталар, иң элек Мәликәнең туган авылына килеп җитәләр. Мәликәнең әти-әнисе кызларының кайту шатлыгыннан зур бәйрәм ясый — халык җыя, егеткә рәхмәт белдерә, бүләкләр бирә. Егет, саубуллашып, Фәтхелҗамал белән өйләренә кайтып китә.

Сәйфелмөлекнең әтисе-әнисе малайларын ай көтәләр, тагын да бербер артлы көннәр, айлар үтеп тора. Нәкъ бер ел дигәндә Сәйфелмөлек Фәтхелҗамалны җитәкләп өенә кайтып керә. Әти-әнисе шатланып каршы алалар. Уллары исән-сау кайтканга барча авыл халкын җыялар, тиздән туй булачагын белдерәләр.

Менә әтисенең, әнисенең туган-тумачалары, таныш-белешләре, атлар җигеп, шаулашып-гөрләшеп килеп тә җитәләр. Туй бик күңелле, бик кызык үтә.

Фәтхелҗамал белән Сәйфелмөлек бер-берсен яратып бик тату яшиләр. Шулай итеп, бер еллар үтә. Боларның малайлары дөньяга килә. Бу малайның матурлыгын әйтеп тә килештералмассың, язуга да язып бетералмассың: чулпан күзле, чия иренле, ак йөзле бик мәһабәт малай була ул. Бер яшь тулганда йөгереп йөри башлый, «әти», «әни» сүзләрен әйтә. Ә Сәйфелмөлекнең әтисе картая, үзенең тормышын улына тапшыра.

Көз үтә, менә кыш та килеп җитә. Берзаман өстәл янында аш ашап

утыралар. Шул вакытта ишектән зур гына эт килеп керә. Фәтхелҗамал малаен эткә тешләтә дә ишектән чыгарып җибәрә. Бу хәлне күреп, Сәйфелмөлек Мәликәне ачулана. Шунда ишек ачыла да, малай кире килеп керә.

— Менә бит,— ди Фәтхелҗамал,— улыңа бернәрсә булмаган. Өч шартымның берсен боздың бит,— ди.

Сәйфелмөлек Фәтхелҗамалдан гафу үтенә. Болар яңадан тату гына тора башлыйлар.

Кыш китә. Яз килеп җитә. Язын боларның икенче балалары дөньяга килә. Бу юлы кыз бала була. Кыз да үсә башлый. Бу да бик матур була. Көннәр үтә, айлар үтә. Тагын шулай уен-көлке белән өйдә утыралар. Бу вакытны Фәтхелҗамал зур мичкә ягып куйган була. Ипи саласы бар икән. Мичтә утыннар күмерләнә. Шул вакыт Фәтхелҗамал зур көрәкне ала да кызны, шуңа утыртып, мичкә ыргыта. Сәйфелмөлекнең бик ачуы килә. Ачуыннан хатынына кычкырып куя. Мичкә барып карасa, кечкенә кыз мич эчендә янган күмерләр белән уйнап утыра.

— Менә,— ди Фәтхелҗамал,— син өч шартның икесен боздың,— ди.

Болар шулкадәр ачуланышалар, Фәтхелҗамал бәләкәй кызны үзенә ияртеп, малайны әтисендә калдырып, өйдән чыгып китә. Фәтхелҗамал өйдән чыгуга, җил-давыл күтәрелә. Бәләкәй кызы белән ул һавага очып китә. Һаваларда бер ләгән туры килеп, шуңа утырып, алар дөнья әйләнә башлыйлар.

Фәтхелҗамал ел саен бер мәртәбә үзе беренче тапкыр килен булып төшкән йортны һәм анда калган улын эзләп, әле булса да әйләнеп йөри икән.

Әкиятем дә шунда бетте.

26. Гармунчы егет һәм пәриләр

Берзаман гармунчы егет булган, ди. Гел туйга йөрткәннәр инде аны.

Бервакытны бер кеше бу гармунчыны туйга чакырып килә. Әлеге кеше пәри затыннан икән, бер яхшы ат белән килә бу. Инде моңа хакын да бирергә була:

— Хакын күпме сорыйсың, шулкадәр бирербез,— ди.

Яхшы атка утырта да инде бу, алып китә гармунчыны. Туй буласы авылга хәтле унике чакрым икән, тик кайсы авылга барганын белми инде гармунчы. Ә алырга килгән кешене күргәне бар кебек бервакытны, таныш кеше кебек.

Барып җитәләр һәйбәт кенә. Анда яшьләр җыелганнар инде бөтенесе, кодалар-кодагыйлар да, яшь кияү дә шунда. Моңа уйнарга, биергә

кушалар. Бөтенесе эчәләр, моны да калдырмыйлар инде. Бөтенесе исерә, ә бу исерми, тик эче генә күбә моның, зур булып. Аптырый инде.

Хуҗалар, пич артына барып, шкафтан нәрсәдер алып сөртенәләр. Гармунчы егет күреп кала моны. Бу хәзер еравктан гына күзәтеп тора: тегеләр стаканга бармакларын тыгалар да кашларына нәрсәдер сөртеп куялар. Болар тышка чыккан арада бу гармунчы егет бара да бер күзенә сөртеп калырга өлгерә. Корым сөртәләр икән тегеләр, шулай иткәч башкаларга адәм булып күренәләр икән. Хәзер егет корым сөртмәгән күзен йома да корым сөрткәне белән карый. Караса: болар бик куркынычлы затлар икән! Монысы белән караса: гадәти кешеләр инде, яхшы өйдә утыра. Тегесе белән караса: урманда утыра, түзлек[1] арасында шунда, бик ямьсез җирдә, куркыныч җирдә утыра.

Тегеләр килеп керәләр дә бииләр. Гармунчыга гел уйнатырга кушалар. Бал бирүләрен күзәтә инде бу теге буялган күзе белән: моңа каяндыр сыер эчә торган җирдән китереп эчерәләр, ә үзләре чиста аракы салып эчәләр. Бу шуларның бөтенесен күрә дә теге алып килгән кешегә әйтә:

— Давай мине илтеп куй инде,— ди,— ардым-талдым,— ди,— шулхәтле уйна әле,— ди.— Икенчеләй килмәм дә, илтеп куймасагыз,— ди.

Бу кеше илтеп куярга була инде. Моңа:

— Эш хакын күпме сорыйсың? — ди.

— Күпме бирәсез, бирегез акчагызны,— ди.

Хәзер йөгерешеп китәләр дә болар, янәсе өйдән чыгалар инде, күпме кирәк типкәләп яфрак җыялар да, мишәккә[2] тутырып, китереп бирәләр моңа. Бу буялган күзе белән карый — яфрак, монысы белән караса инде — чын акча.

— Бу акчагыз кирәкми миңа, бу бит — яфрак,— дип әйтеп сала егет,— миңа чын акча кирәк,— ди.

Болар аптырашалар да чын акча табып бирәләр. Моңа чын акча табып бирәләр дә тиз генә, аптырау өсле[3] моны чыгарып яхшы атка утырталар, алып китәләр инде өенә. Бара инде бу яхшы кара ат белән, куруплар[4] белән. Шулай барганда бу корым сөрткән күзе белән караса, ялгашта утырып бара икән, ике пәри сөйриләр моны, бау тагып. Түмгәк араларында бара бу чаптыртып. Ә болай караса — яхшы атта барган

---

[1] *Түзлек* — агач төбе.
[2] *Мишәк* (*урысча: мешок*) — капчык.
[3] *Аптырау өсле* — аптырап.
[4] *Куруп* — тарантас.

кебек була. Ат, тыңлап, үзе белеп барган була. Түзлек араларыннан урманнан алып чыгалар моны. Шулай итеп, өенә кайтарып куялар.

Ярый. Озак та үтми, тагын моны чакырып киләләр. Инде бу корым сөрткән күзе белән карый: апәт[1] шул кеше килгән бит, моны туйга чакырып. Аңа:

— Бармыйм, абый,— ди,— элек тә сез алып киткән идегез,— ди,— урманда йөртеп китердегез,— ди.

Бу чыгып китте ачуланып. Нәрсәдер сизгән инде бу шулай дигәч.

Егет утынга китте моның артыннан. Тау түбән төшә инде бу. Тау түбән төшкәндә аты сөйри алмый, нәрсә инде, тәгәрмәчләр дә әйләнә — ат сөйри алмый! Корым сөрткән күзе белән караса: тагын дүрт тәгәрмәчкә дә ябышып утырганнар болар, пәриләр, аты тарта алмый, ди. Егет утынның бер кисәген ала да давай боларны бәргәли тәгәрмәч астыннан. Бу теге күзе белән күрә бит инде. Ярар, боларны бәргәләде. Арбасына тормоз салып кына төшеп китте.

Теге пәриләр аптырыйлар бит инде бу хәлгә. Кайтып керделәр.

— Бу күрә,— диләр,— ничектер күрә бу. Давай тагын бер сыныйк.

Моны күзәтәләр инде, кая барса да.

Егет иртәгесен тегермәнгә китте. Барды да тегермәнгә, салды зернасын[2]. Шуннан соң милнек[3] белән керделәр инде чәй эчәргә. Берзаман милнек ишетә: тегермән туктап калды кебек. Чыгып йөгерсәләр, күрәләр: чыннан да тегермән туктаган. Милнек аннан карый, моннан карый — бөтенесе төзек, ә тегермән әйләнми.

— Тукта, мин карыйм әле,— ди егет.

Ташларны карап бетерде бу — бернәрсә дә юк. Су күләсәгә[4] төшеп китте. Караса, су күләсәне өч пәри тотып утырган, ди, өсләреннән су ага, ди, аяк терәп утыралар, ди. Милнеккә кычкыра бу:

— Китер әле лом-тимереңне монда, кысылам,— ди.

Теге лом-тимерне бирми:

— Анда нәрсә булсын,— ди.

— Давай тизрәк,— ди.

Егет су өстеннән сугып җибәрә дә бу өч пәригә лом белән, тегермән эшли дә башлый.

---

[1] *Апәт* (*урысча: опять*) — тагын.

[2] *Зерна* (*урысча: зерно*) — ашлык.

[3] *Милнек* (*урысча: мельник*) — тегермәнче.

[4] *Су күләсә* (*урысча: колесо*) — су тәгәрмәче.

II

27. Гөлфарига

Кала бакчасында халык йөри икән. Шул бакчага патша язу ташлаткан. Анда: «Ниәстә[1] каты, ниәстә ачы, ниәстә татлы? Кем әйтер?» — дип язылган икән.

Күпләр әйткән: «Борыч ачы; шикәр, бал татлы; тимер, таш каты». Боларның бер җавабы да дөрес дип табылмаган.

Арада бер карт та була. Ул, өенә кайткач, хәл-әхвәлен, шәһәрдә күргәннәрен унике яшьлек кызы Гөлфаригага сөйли:

— Патша: «Ниәстә каты, ниәстә ачы, ниәстә татлы?» — дип өч сорау бирде, ләкин аңа җавап тапкан кеше булмады,— ди.

Кыз әйтә:

— Әткәй, мин аның җавабын сиңа сөйлим хәзер. Патша янына барырсың, аңа җавабыңны белдерерсең, тик мин өйрәткәнне сиздермәссең, үзем уйлап таптым, диярсең. Менә ул җавап: үлем ачы, ат тоягы каты, өйләнү татлы.

---

[1] *Ниәстә* — нәрсә.

Карт барып патшага әйтә. Аннары:

— Үзем уйлап таптым,— ди.

Патша әйтә:

— Үзең уйлап тапмагансың, син ул кадәр үк зирәк түгел, бу хакта сиңа кемдер җиткергән, ялганлавың өчен сине йә аттырам, йә астырам.

Картның коты алына, атыласы килми:

— Кызым өйрәтте,— ди.

Шуннан патшаның кызны сынап карыйсы килә. Патша үгез бирә картка:

— Шушы үгез җиде айда ике үгез бозау китерсен,— ди.

Карт үгезне алып китә дә өенә елап кайтып керә. Ни булганын сөйләп бирә.

Гөлфарига әтисен тынычландырырга ашыга:

— Әткәй, елама, безгә җиде айга ашарга җитә бу үгез,— ди.

Җиде ай үткәч, картның өенә патшаның вәзирләре килә.

— Карт өйдәме? — дип сорыйлар.

— Карт мунчага китте, улан[1] табарга,— ди кыз.

Вәзирләр патшага кызның сүзләрен кайтып әйтәләр дә кыз янына тагын киләләр.

— Патша безне бик каты орышты. «Ахмаклар, ир кеше улан китерәмени»,— дип сүкте,— диләр вәзирләр.

Кыз аларга болай ди:

— Ә үгез бозау китерәмени?

Кайтып әйтәләр моны патшага. Патша картны чакырта:

— Килгәндә юлга да кермәсен, юлдан да чыкмасын,— ди.

Патшаның шартын ишеткәч, карт аптырап елый. Ләкин кызы бу юлы да аңа ярдәмгә килә — әтисен кәҗә тәкәсенә атландырып җибәрә. Кәҗә тәкәсе тәгәрмәч белән ат тоягы эзе арасыннан, күкрәк булып калган урыннан бара икән.

Карт барып җитә дә әйтә патшага:

— Килгәнемне күрдегезме? Юлга да кермәдем, читкә дә чыкмадым. Мине нигә чакырттыгыз?

— Кызыңны миңа бирәсең,— ди патша.

Карт кайта, әйтә кызына:

---

[1] *Улан* (*олан*) — бала.

— Патша сине чакырды, кәләшлеккә алам, дип әйтә,— ди.

— Ефәктән күлмәк тектереп, тройка ат җиктереп җибәрсә, барырмын,— ди кыз.

Патшага шуны барып әйтә карт. Патша кызның таләбен үтәргә риза була.

Кызны алып китәләр патша янына. Кызга әйтә патша:

— Мин сиңа өйләнәм, тик һичкайчан миннән узып суд ясамассың. Суд ясап, хөкем чыгарсаң, мин сине аерып җибәрермен,— ди.

Беркөнне патша шәһәрдә йөрергә чыгып китә. Шулчак ике җайдак, берсе биягә, икенчесе айгырга атланып, патша өенә килә. Өйдән чыгуларына бия колын китергән икән. Җайдаклар, ике карт, бәхәсләшергә керешәләр.

Бия хуҗасы:

— Бия колынлаган, Ходайга шөкер! — ди.

Айгыр хуҗасы:

— Тот капчыгыңны, көтеп утыр. Айгыр колынлаган! — ди.

Патша хатыны Гөлфарига чыгып, җайдакларның бәхәсен хәл итәргә була:

— Колын — биянеке, айгырныкы буламыни,— ди.

Болар кайтып барганда юлда патшаны очратып сорыйлар:

— Колын айгырныкымы, биянекеме? — диләр.

Патша әйтә:

— Биянеке,— ди.

Бия хуҗасы кычкырып ук җибәрә:

— Патша хатыны да шулай дип әйтте бит! — ди.

Патша кайтып, хатынына әйтә:

— Миннән узып суд ясагансың икән,— ди.— Мин сине аерам, — ди.— Талак! Талак! Талак!.. Җаның ниястә тели шуны ал да кит,— ди.

Гөлфарига моңа күнгәндәй итә:

— Алай булгач, бүген азаккы кич, эчеп-сыйланып, соңыннан искә алырлык итеп күңел ачып калыйк,— ди.

Тәмле сүздән, куәтле шәрабтан, кайнар кочактан патша исермәстәй булса да исерә.

Гөлфарига ямщикка әйтеп тарантаска ат җиктерә дә патшаны утыртып алып чыгып китә.

Бара торгач патша айный:

— Мин сине аерган идем бит! Мине кая алып барасың? — ди.

Моңа каршы җавабында Гөлфарига әйтә:

— Син «Йорт эченнән ниәстә телисең, шуны алырсың»,— дигән идең. Сине теләгәчтен, сине алып чыгып киттем! — ди.

Шуннан соң патша белән Гөлфарига озак бергә торганнар, ди, бер малайлары булган, ди.

28. Сәгъди бабай

Борын-борын заманда Сәгъди исемле бер кеше булган, ди. Аларның балалары үлгәнме, булмаганмы — карчыгы белән икәү генә яшәп картайганнар, ди, болар. Беркөнне карчыгы әйтә Сәгъди бабайның:

— Гомер буе ялкау булдың инде, бер мал табып китерә алмадың,— ди.— Мин орчык эрләп, йон эрләп, тамак туйдырабыз,— ди.— Өзрәк чыгып, кайда булса да берәр кәсеп итеп, берәр эш эшләп кайтырга кирәк инде,— ди. Сәгъди бабайны орыша бу.

Ярар, Сәгъди бабай, берәр эш булмасмы дип, кулына аркан тотып, билен тышау белән бәйли дә чыгып китә.

Бара-бара бу, тегендә бара, монда килә дә пәриләр тора торган җиргә барып җитә. Дию пәриеме, чуртмы дигәндәй, шундыйларның авылына барып керә.

Ярар, барып керә каршыдагы бер йортка. Бик ишле генә гаилә була болар. Уллары, киленнәре, бала-чагалары була. Үзләре дә бик карт булмыйлар әле. Сәгъди бабайны берсе дә моңарчы күрмәгән, белмәгән бит инде.

— Мин,— ди,— сезгә кунакка килдем,— ди, бабай әйтә.

— Ярар,— диләр.

Алар Сәгъди бабайны бик кунак итәләр, ашаталар, эчертәләр.

— Миңа кайда да бер,— дип, Сәгъди бабай болардан китми хәзер, бер кич тә куна, ике кич тә куна, тагы да куна. Ашый-эчә дә ятып йоклый.

Хәзер беркөнне сөйләшәләр хуҗалар:

— Бу китми,— диләр,— йоклагач, түбә тактаны ачыйк та тегермән ташы төшерик, үлсен,— диләр.

Боларның сөйләшкәнен Сәгъди бабай ишетә. Кичтән ята да бу, төн булгач кына урынын күчерә бүтән яры.

Менә бервакытны моның урынына дөп итеп тегермән ташы килеп төшә. «Алай икән»,— ди Сәгъди бабай, тора да тегермән ташы кырыена барып ята хәзер.

Иртән торсалар — Сәгъди бабай исән. «Һы-ы-ы,— диләр,— ничек булды соң әле бу?» — диләр.

— Бабай, берәр төш күрмәдеңме? — диләр болар.

— Әйе,— ди,— бүген төшемдә өстемә инәйнең орчык башы төште,— ди.

Әй, болар хәйран калып: «Ай-һай батыр карт икән! — диләр.— Кара әле, тегермән ташын орчык башы дип кенә хисаплаган»,— диләр. Исләре китә.

Икенче көнне дию пәриләре сөйләшәләр: «Йоклаганда моның өстенә кайнар су койыйк,— диләр. Ярар, киленнәренә кушып, су кайнарлап куялар. Төнлә чиләк белән түбәгә шау кайнар суны алып мендәләр.

Сәгъди бабай ишетеп тора боларны. Тагы урынын күчерә. Менә бабайның урынына кайнар суны шаулатып коеп та җибәрәләр тегеләр. «Бетте инде, бетте»,— диләр, шатланышалар.

Иртән торсалар — Сәгъди бабай исән. Хәйран калалар диюләр.

— Бабай, берәр төш күрдеңме? — диләр.

— Әйе,— ди,— күрдем,— ди.— Җылы гына яңгыр яуды төшемдә,— ди.

Болар, нәрсә дияргә дә аптырагач, көлешәләр.

— Бабай,— диләр,— син бик батыр, ахры? — диләр.

— Батыр мин,— ди.— Бер тибүдә җирнең эчәгеен чыгарам,— ди.

— Алаймы? — диләр.

Сәгъди бабай теге арканны күмеп куйган була. Туфрак чыгып торган йомшаграк урынга.

— Әйдә, чыгар,— диләр.

— Әгәр дә,— ди,— бер тибүдә җирнең эчәгесен чыгарсам,— ди,— сез мине бер капчык алтынмы, көмешме акчалар биреп, үземнең өемә илтеп куярсызмы? — ди.

Дию пәриләре үзара сөйләшеп алалар: «Куйыйк, куйыйк, бу бәладән котылыйк, түлке шул эшне эшләп карасын»,— диләр.

Сәгъди бабай аркан куелган җиргә барып тибә дә, аркан әйләнеп килеп чыга. Хәйран калалар. «И-и-и, батыр бу, бу бездә торса, безне әллә нишләтеп бетерер... Әллә нәрсәләр белә икән, батыр икән, йә бөтенебезне үтереп бетерер, моңардан котылырга кирәк, диләр. Бар кебек акчаларны җыеп бирергә дә тизрәк күтәртеп җибәрергә!» — диләр.

Хәзер моңарга бер капчык акча җыештыралар.

Сәгъди бабай әйтә:

— Мин күтәреп кайта алмыйм аны,— ди.— Үзегез илтеп куегыз,— ди.

Ярар, теге карт пәринең аркасына астыралар да капчыкны, озаталар Сәгъди бабайны.

Кыркапкага җиткәч, Сәгъди бабай әйтә диюгә:

— Син шушында утырып тор, мин сине килеп алырмын,— ди.— Мин,— ди,— карчыгыма: «Кунак алып киләм, аш әзерләп тор», дип әйтеп килим әле,— ди.

Дию пәриен калдыра да бу, үзе кайтып, карчыгына әйтә:

— Безгә,— ди,— бер кунак килә, ди. Мин сиңа: «Кая, карчык, ашларың пештеме?» — дип әйткән оңгайга, болай дип әйт,— ди: «Әллә тугыз дию суеп калдырдыңмы, бер дию пәрие суеп калдырган идең дә, ашап бетердем инде, калмады»,— дип әйт,— ди. Бер бәләкәй генә этләре була боларның: — Этне өстереп җибәр аннары,— ди.

Хәзер үзе китә тегене алырга.

— Әйдә,— ди,— карчыкка әйттем,— ди,— аш әзерләп тора без кайтуга,— ди.

Хәзер акчаларын, алтыннарын күтәреп, дию пәрие бабайны китерә. Өйгә керәләр.

Бабай әйтә:

— Кая әле, карчык,— ди,— кунакны сыйлап җибәрергә кирәк инде, ашың өлгердеме? — ди.

Карчык әйтә:

— Һе,— ди,— нинди аш, әллә тугыз дию суеп калдырган идеңме? — ди.— Бер дию суеп калдырдың да бит, мин син кайтканчы ашап бетердем инде аны,— ди.

«Болар дию ашаучылар икән», ди дә дию пәрие, арты белән ишеккә чигенә, чыгып ычкынырга дип.

Карт әйтә:

— Чыкма кунак, чыкма,— ди.

Мәсьәләне аңлады кунак, чыкмыймы соң! Курка инде, моны да суя бит югыйсә.

Хәзер чыга да бу, капкага таба йөгерә.

— Йә инде, кунак, китмә инде,— дип кычкыра бабай, үзе: — өс-өс-өс,— ди.

Әй теге бәләкәй маэмай чыга да, диюнең чабуына асылынып, талыйталый бара. Әй чаба, әй чаба, әй чаба теге, гыжлап бетә. Чаба-чаба үзенең өенә кайтып керә бу.

— Нәрсә булды, нәрсә булды? Сыйлап җибәрдеме сине? — дип сорыйлар өйдәгеләр.

— Сыйламыймы соң! Әллә нәрсәләр ашатып, сыйлап җибәрде. Әле бер абзыйсы бар икән. Шул, китмә, дип, чабуыма асылына-асылына килә авылны чыкканчы. Көчкә котылдым,— дип әйтә икән бу.

Хәзер Сәгъди бабайлар карт көннәрендә күп акча белән, теләсәләр нәрсә ашап, теләсәләр нәрсә эчеп, тыныч кына яши башлаганнар. Карчыгы да орышмый бабайны, акчаны күп алып кайткач.

Рәхәтләнеп, карт көннәрен бер нужасыз уздырганнар болар. Акчалары тәмам булуга, үзләре дә дөньядан үтеп китәләр.

29. Салам-Торхан һәм алтын пароход

Борын-борын заманда яшәгән бер әби. Бу әбинең бер улы булган. Болар бик ярлы яшәгәннәр. Өйләрендә хәтта ябыныр-ястаныр нәрсәләре дә булмаган. Малай да саламда йоклаган, саламда торган. Шуңа күрә аңа Салам-Торхан дигән исем кушканнар.

Салам-Торхан авылда көтүче хезмәтен үтәп яшәгән. Шулай еллар үткән, малай буйга җиткән. Әби: «Үзем исән вакытта улымны өйләндереп каласы иде»,— дип уйлый икән. Беркөнне ул улы янына килеп утырган да:

— Улым, инде зур үстең, сине өйләндерергә вакыт җитте, күрше авылга кыз яучыларга барырга кирәк,— дигән.

Әби беркөнне кыз күзләргә чыгып киткән. Күрше авылдагы кызларны күзләп чыккан, моңа бер байның чибәр кызы бик ошаган.

Авылга кайткач, кызны яучылау өчен киеп барырга киеме булмау әбине бик борчыган. Ни булса ул булыр дип, бай абыстайлар янына киткән, алардан затлырак киемнәр сорап алган. Шуннан соң ул, әйбәт кенә итеп киенеп, кыз сорарга юнәлгән.

Әби кыз яучылаган авыл елга буена урнашкан икән. Байга килеп кызны сораган, килешкән, киләсе җомгага егет белән киләчәген, алтын пароход әзерләтәчәген, шуның белән киләсен әйтеп, байдан чыгып киткән.



Әби күпне күргән, башлы карчык була. Алтын пароход турында уйлый торгач, ул менә нинди фикергә килгән: кырдан сап-сары саламнар алып кайткан да, шуларны үреп, пароход ясап куйган. Ул кояшта нәкъ алтын төсле күренә икән.

Җомга көнне кызның әтисе, кияү алтын пароходта килә дип, балконга чыгып бинокльдән күзләп тора икән. Менә берзаман елгада алтын пароход күренгән.

Ярый, киләләр болар елга буйлап. Кызның авылына җитәрәк, карчык пароходны яр буена китереп туктата да, малайны анда калдырып, үзе байлар янына йөгерә. Шул арада Салам-Торхан пароходны батырып яр буена чыга. Алар шулай сөйләшеп куйган булалар инде.

Әби бай йортына йөгереп барып, бик кызганыч тавыш белән:

— Көчле җилдә пароходыбыз батты, Салам-Торхан яр буенда калды, киемнәре пычранды,— дип хәбәр итә.

Бай моны ишетеп тиз генә хезмәткәрләренә ат җиктерә, атларның да иң яхшыларын гына һәм егеткә иң асыл киемнәр салып җибәрә.

Кучер белән карчык яхшы атларга утыралар да яр буена китәләр. Килеп җитәләр, әби егеткә шул киемнәрне кияргә куша. Шуннан алар кыз торган авылга китеп баралар. Юлда барганда әби улына өйрәтә:

— Улым, син табын янында утырганда киемнәреңә карап утырма,— ди.

Авылга килеп җитәләр. Кызның әтисе, зур капкаларны ачып, кунакларны каршы ала. Кунакларны аттан төшереп, кунак бүлмәсенә алып кереп тә китәләр. Өстәл өсте төрле сый белән тулган була. Утырталар кунакларны ашарга, тотыналар сыйларга. Егет өстәл янында утырганда үзенең өс-башына карап-карап ала. Әби дә, башкалар да моны күрәләр. Әби өстәл астыннан гына егетнең аягына төртә, егет эчеп утырган чынаягын ук кулыннан төшереп җибәрә. Чынаяк төшеп, икегә аерыла.

Кызның да кунак бүлмәсенә кереп аның аша үтеп киткәне күренә. Кыз да, егет тә бер-берсен ошаталар.

Ярый, шушы ук мәҗлестә туй көнен дә билгелиләр. Егет белән карчыкны авылларына кадәр озатып куялар.

Өйгә кайткач, ничек туй ясау турында баш вата башлыйлар, боларның бернәрсәләре дә юк бит.

Әби беркөнне урманга җиләккә китә. Урман итәгендә җиләк җыеп йөргәндә моның каршысына бер шайтан баласы килеп чыга. Әби куркып калмый, шайтанга сәлам бирә. Шайтан баласы:

— Сугышкамы, көрәшкәме? — ди.

Әби җиләк җыеп йөргәндә бер ябалак тотып, кирәге чыгар, бәлки дип, куенына куйган иде. Ул шайтан егетенә:

— Иң элек, үзебез көрәшкәнче, бетләребезне көрәштерик,— дип, куеныннан ябалакны тартып чыгара.

Шайтан егетнең моны күреп котлары оча, кая анда көрәшү, качу өчен урман да тар булып китә. Барлык көче белән килгән юлыннан кире йөгерергә тотына бу. Әби дә, юл читендәге салам өеменнән салам алып, юл буена шуны сибә-сибә, шайтан артыннан куып китә. Шулай куа торгач, әби шайтаннар яши торган урынга ук килеп җитә. Шайтан баласы су астына төшеп кача. Аларның дөньясы су астында икән. Әби су буена килеп утыра һәм көтә башлый. Беркадәр вакыттан соң, шайтан егете судан башын чыгарып карый да тагын чума. Шуннан соң ул шайтан башлыгына йөгерә, аңа әби бете белән булган вакыйганы сөйләп бирә. Шайтан башлыгы әйтә:

— Бар, чыгып сора, нәрсә кирәк аңа,— ди.

Шайтан егете чыгып әбидән сорый:

— Нәрсә кирәк сиңа? — ди.— Ни теләсәң, шуны бирербез, тик безне һәлак кенә итмә,— ди.

Әби моңардан алтын сорый. Шайтан егете аңа ат башы кадәр алтын чыгарып бирә.

Әби шул алтынны алып кайта да якындагы калага алып барып сата. Меңнәрчә сум акча белән, бик күп байлык җыйнап, өенә кайтып керә. Зур агач йорт та салалар. Бик нык әзерләнеп, зур итеп туй да үткәрәләр.

30. Бай һәм нужа

Ярлы гына бер егет байга барып кергән. Бай моңа:

— Син нинди сәбәп белән йөрисең? — дигән.

Егет:

— Мин нужа артыннан йөрим әле,— дигән.

Бай:

— Ул нужа нинди була соң? — дигән.

Егет исә:

— Син атың белән тарантасыңны, яхшы киемнәреңне, акчаңны ал. Мин сине сахрага алып барырмын, шунда күрсәтермен нужаны,— дигән.

Егет байны тарантасына утыртып алып китә. Баралар, баралар, бара

торгач бер агач күрәләр. Бу агач башында бер карга утыра икән. Егет байга:

— Син киемнәреңне шушында салып куй да агач башындагы карганы тотып алып төш. Мин синең киемнәреңне саклап торам. Аннан нужаның нәрсә икәнен күрсәтермен,— дигән.

Бай агачка менеп киткән. Ә егет байның киемнәрен алып, тарантаска утырып, атка суккан да ычкынган. Бай шыр ялангач калган, ди.

— Менә нужа, менә нужа,— дип, өенә кайтып киткән бай. Шулай итеп, нужаның нәрсә икәнен белгән, имеш.

31. Өч Таз

Моннан бик күп заманнар элек коры, күңелсез сахра уртасында кечкенә, җимерелергә җиткән бер йорт булган, ди. Бу йортта өч бертуган Тазлар гомер иткәннәр: Олы Таз, Уртанчы Таз һәм Кече Таз. Болардан Кече Таз абыйларына караганда кыюрак һәм батыррак булган. Шуның өчен аннан олырак Тазлар көнләшкәннәр һәм аны яратмаганнар.

Көннәр үтү белән, Олы Таз белән Уртанчы Таз, Кече Тазны шушы йортта ялгыз калдырып, үзләре сахра аръягындагы бер шәһәргә качмакчы булып киңәш иткәннәр. Кече Таз моны башта сизмәгән. Тегеләр әкренләп сохарый хәзерләп, зур арыш капчыгына тутырганнар һәм иртәгә китәсе дигән кичне, Кече Таз йокларга дип яткач, болай дип киңәш иткәннәр: «Иртәгә таң белән үк торып, бу Таз торганчы моннан ычкынырга кирәк. Көне буе туктаусыз барып, кичкә сахар аръягы шәһәренә җитәргә, берәр кунача табып, төнгелеккә шунда урнашырга кирәк»,— дигәннәр.

Боларның шушылай сөйләшүләрен Кече Таз, йоклап яткан кыланып, тыңлап яткан һәм шуннан соң үк төрле хәйлә планнары кора башлый. Тегеләр кичтән соң гына ятканлыктан, яту белән бик каты йокыга китәләр. Алар йоклый башлау белән, Кече Таз сикереп тора да корган хәйләләрен берәм-берәм эшли башлый: иң элек үзенең яткан урынына зур агач бүкән салып, аны нәкъ үзе яткан кебек итеп урнаштыра һәм өстенә үзенең каткан сары тунын ябып куя. Капчыктагы сохарыйны тышка алып чыгып бушата һәм, элек капчык торган урынга килеп, капчык

эченә керә дә аның авызын, нәкъ элеккегечә итеп, шул ук бау белән бәйләп куя.

Иртә таңнан Олы Таз белән Уртанчы Таз сикереп торалар да, Кече Таз үлеп йоклый — сизмәс дип ышанып, капчыкларын аркаларына асып, шәһәргә таба сәфәр башлыйлар. Уртанчы Таз сохарый капчыгының авырлыгыннан зарланса да, кичкә шәһәрдә булырга тиеш булганлыклары өчен, аны-моны уйламыйча, бик ашыгып алга баралар. Капчыкны кутюмкалап[1] олы кырчын[2] күтәреп барган вакытта, кутюмка бавы өзелеп төшеп, җиргә бәрелеп авыртканлыктан, Кече Таз чүт акырып җибәрми. Ничек тә түзә, югыйсә сизсәләр, Олы Таз белән Уртанчы Таз кирәген бирәләр бит аның!

Кичкә, хәлдән таеп ару дәрәҗәсендә, шәһәргә барып керәләр. Шәһәрнең үзләре барып кергән башында гына олы юл буеннан бер зимләнкә эзләп табып, шунда кунарга урнашалар. Бераз тамак ялгап алмакчы булып, дәү Тазлар капчык авызын чишеп сохарый алмакчы булсалар, капчык эченнән Кече Таз килеп чыга.

Тегеләрнең күзләре шар була, нәрсә дияргә дә белмиләр. Соңыннан хәйләне сизеп алалар да менә тотыналар Кече Тазны кыйнарга, ләкин, ач булгач, тиз хәлдән таеп туктыйлар. Нишләсеннәр, берни эшләп булмый, ач көенчә йокларга яталар. Иртәгесен шәһәрдә зур базар икән. Олы юл тулып сәүдәгәрләр шәһәргә агыла башлыйлар.

Иртән торгач, Олы таз белән Уртанчы Таз: «Теләсәң ничек ашарга табып кайт»,— дип, Кече Тазны куалап чыгарып җибәрәләр. Кече Таз аптырап калмый, Олы Тазның ике сыңар яхшы гына күн итеген ала да чыгып китә.

Итекнең бер сыңарын шәһәрдән ерак илтеп, икенчесен шәһәргә кергән урынга гына юл өстенә утыртып куя. Итекнең сыңарын иң элек күрәләр, ләкин аны, сыңар гына булгач, алучы булмый. Алдан баручы сәүдәгәр, килә торгач, шәһәр янындагы итекне күрә һәм, уйлап та тормастан, җитәкләп барган кәҗәсен ташлап, кире йөгерә башлый. Тазга шул гына кирәк тә, качып торган урыныннан чыга да, кәҗәне һәм бер сыңар итекне алып, шул итек белән кәҗәне кыйный-кыйный чаба. Бер сазлык буена барып, аны суя һәм тиресен, нәкъ кәҗә формасында итеп, сазлык эченә кертеп куя. Үзе итне теге Таз-

[1] *Кутюмка* (*урысча*: *котомка*) — биштәр.
[2] *Кырчын* — тире авыруы йоктырган кеше, таз.

лар янына алып кайта. Шулай итеп, көне буе ит пешереп, рәхәтләнеп ашап яталар.

Ә теге сәүдәгәр, сыңар итекне алып, кәҗәсен һәм кәҗәсе янында калган сыңар итекне алыйм дип килсә, алардан җилләр искән була. Эч пошуына чыдый алмыйча елап җибәрә дә, бераз күңеле бушангач, кәҗәсен эзләргә китә. Йөри торгач, кичкә каршы сазлык янына барып чыга, һәм, кәҗә тиресен күрү белән, кәҗәмне таптым дип шатланып йөгереп барганда үзе дә сазлыкка бөтенләй кереп чума.

Кичен Кече Таз, төрле хәйләләр белән, бер каз алып кайта. Аны суеп-тазартып, шулпасын өчәүсе бергә эчеп, каз итен казанда калдыралар. Шуннан Кече Таз мондый фикер әйтә:

— Кем бүген төнлә иң матур төш күрә, иртән казандагы казны шул кеше үзе генә ашый,— ди.

Бу фикерне телгә ике Таз да бик хуплап каршы алалар, чөнки алар да һәрберсе, үз нәүбәтендә, казны үзе генә ашарга өмет баглыйлар иде.

Иртәгесен торып тезелеп утыралар да төшләрендә күргәннәрен бик тәмләп сөйли башлыйлар.

Олы Таз болай ди:

— Мин төшемдә оҗмахта булдым, зәм-зәм сулары эчтем, Ходайга хәер бирдем.

Уртанчы Таз дәвам итә:

— Мин шәһәр базарында булдым. Тәмле җимешләр ашадым, бер сәүдәгәргә сату итәргә булыштым.

Ә Кече Таз болай әйтә:

— Мин төнлә төшемдә шушы зимләнкәдә идем, иркенләп бер бөтен казны ашап бетердем.

Шуннан соң ду кычкырышып бер-берсенә яшен тизлегендә карашып алдылар да, сикереп торып, казан янына атылдылар һәм аның чыннан да чип-чиста икәнлеген күрделәр. Тагын бераз Кече Тазга әләгеп алды. Аның тазын бераз кашыганнан соң, бу зимләнкәне ташлап китәргә булдылар.

Кече Таз чыгып киткәндә үзе белән бер чиләк су һәм зимләнкәнең зур калын агач ишеген алып китте.

Шәһәрдән бик еракта, елга буендагы яланда, бер зур агач үсеп утыра. Агач яныннан гына олы юл — сәүдәгәрләр йөри торган юл үтеп китә. Тазлар, җыелышып, шул агач башына менделәр. Агач ишекне



җайлап куеп, өстенә урнаштылар. Бервакытны төштән соң сәүдәгәрләр кайта башлый базардан. Бик күп сәүдәгәрләр бу урынга, елга буе — матур урын дип, чәй эчеп алырга туктыйлар. Агач астына күләгәгә кереп ут ягып, чәйләрен кайнаталар һәм, көмеш чәйнекләрдән алтын стаканнарга гына кытайский чәйләрне агызып, баллап-шикәрләп шапор-шопыр эчә башлыйлар.

Шуннан соң Кече Таз Олы Тазларга:

— Сибәм суны өсләренә,— ди.

— Сипмә, тоттырырсың,— ди Олы Таз.

Кече Таз:

— Сипкәч кенә әйтмиләр инде аны,— ди дә бер чиләк суны агач ботаклары аша сибеп җибәрә.

Астагы сәүдәгәрләр: «И, Алланың рәхмәте, кояшлы яңгырлар ява»,— дип, Алланы мактап бетерә алмыйча, чәйләрен эчә бирәләр.

Боларга карап эче пошып яткан Кече Таз:

— Ташлыйм шул ишекне башларына,— ди Олы Тазларга.

— Ташлама, тоттырырсың,— ди Олы Таз.

Кече Таз:

— Ташлагач кына әйтмиләр инде аны,— ди дә ишекне теге сәүдәгәрләр өстенә ташлый.

Ишек, агач ботакларын сындырып, дөбер-шатыр итеп сәүдәгәрләр өстенә оча. Котлары очкан сәүдәгәрләр, өсләренә агач ава дип уйлап, төрлесе төрле якка чабалар, күбесе суга ташлана һәм шунда батып үләләр, калганнарының куркудан йөрәкләре шартлый.

Өч Таз, агач башыннан төшеп, сәүдәгәрләрнең малларын алалар һәм хәзергә кадәр бик тату, бик дус яшиләр, ди.

III

32. Төлке, Керпе һәм Ана керпе

Берзаман Төлке белән Керпе узышырга булалар. Алар кая кадәр йөгерергә икәнен дә килешеп куялар. Керпе Ана керпегә алдан ук шул урынга барып ятарга куша. Төлке йөгереп барып җиткәч, Ана керпе аңа: «Мин әллә кайчан монда инде», дип әйтергә тиеш була.

Ярар. Хәзер болар йөгерә башлыйлар. Төлкенең аякларына күз иярми, ә Керпе артта калды бит инде. Керә дә кача бу шунда бер чокырга. Менә Төлке барып җитә чиккә, ә анда Ана керпе басып тора.

— Мин әллә кайчан монда инде,— ди ул Төлкегә.

Хәзер Төлке белән Ана керпе кирегә йөгерә башлыйлар. Ана керпе шулай ук бер чокырга кереп кача. Төлке ухылдап чиккә килеп җитсә, ни күзе белән күрсен, анда аны тагын Керпе көтеп тора.

— Ә мин әллә кайчан монда инде,— ди ул.

33. Май тапкан тычканнар

Ике Тычкан кисәкле май табалар да Маймылга баралар, бүлеп бирүен сорап. Маймыл майны үлчәү табагының бер ягына сала да, май басып төшә. Майны бернихәтле тешләп ала да үлчәүнең икенче ягына сала. Басып төшкәч, тагын тешләп ала. Шулай алмаш-тилмәш үлчәү табагына салып, басып төшкән саен тешләп алып, майны ашап бетерә. Тычканнар бернисез кайтып китә.

34. Сандугач оясы

Бер сандугачны тотып алтын читлеккә яптылар да патша йортына алып бардылар, ди. Сандугач: «Бу патшаның бәхете ни дә, тәхете ни, алтын оям, үз җирем»,— дип сайрады, ди. Сандугачның үз оясы нинди икән, дип, чыгарып җибәрделәр дә, артыннан карый бардылар, ди. Кечкенә генә агымсу уртасында тигәнәк үскән, ди. Шул тигәнәктә сандугачның оясы тирбәлеп тора, ди.

35. Мактанчык Каз

Бер Каз суда коена да, ди, як-ягына карап:

— Мин нинди булган кош: суда йөзә беләм, корыда йөри беләм, һавада оча беләм,— дип, мактанырга тотынды, ди.

Аны Торна күреп:

— Һәй ахмак нәрсә, син Чуртан хәтле суда йөзә аласыңмы, Куян шикелле корыда чаба аласыңмы, Карчыга шикелле һавада оча аласыңмы? Син төрлесен әз-мәз белгәнче, берсен яхшылап өйрән,—дип әйтте, ди.

36. Зирәк Карга

Бер Хатын уракка тар авызлы чүлмәк белән салкын су алып бара. Чүлмәк тулы булмый. Хатын чүлмәкне җир башында калдыра да урак ура башлый.

Шул тирәдә йөргән бер Карга, эчәсе килеп, әлеге чүлмәккә үрелә, ләкин суга буе җитми. Шуннан соң ул аяк астыннан ташлар җыеп, чүлмәккә тутыра да, чүлмәкнең суы өскә күтәрелә. Шулай итеп, Карга рәхәтләнеп эчеп китә.

37. Төлке, Бүре һәм Аю

Бервакыт Төлке, Бүре һәм Аю, чанага ат җигеп, урманга утынга киткәннәр икән.

Барып җиткәннәр болар урманга, Бүре белән Аю утын кисәргә урман эченә кереп киткәннәр, ә Төлке атны сакларга шунда калган. Бүре белән Аю утын кискән арада Төлке атның эчен ашап та куйган. Бу эшне ул атның арт саныннан башлаган, ә соңыннан шул урынга салам тыгып куйган.

Бүре белән Аю урманнан утын кисеп кайткач, Төлке үзе дә урманга кереп киткән, янәсе, утын кисәргә, ә боларга үзе урманнан кайтканчы көтеп торырга кушкан.

Бүре белән Аю Төлкенең урманнан әйләнеп кайтуын көткәннәр, көткәннәр дә, күренмәгәч, үзләре генә кайтырга уйлап, атны әйди башлаганнар, ә ат кузгалып та карамый икән. Ни булганын кочкә аңлаганнар болар.

38. Бабай, Аю һәм Төлке

Бер карт кеше Аю белән дуслашкан икән. Менә бервакыт болар шалкан чәчкәннәр. Аннары кем кайсы өлешен алу турында сүз куешканнар, ди. Бабай әйткән:

— Мин астын алам,— дигән.

Ә Аю:

— Мин өстен алам,— дигән.

Шалкан өлгергәч, Бабай үзенә шалканны алган да Аюга бер йөк шалкан яфрагы китереп биргән, ди.

Көзен Бабай Аюны кунакка чакырган һәм шалкан белән сыйлаган. Шалканның яфракларын алып, Бабайдан алданганын белгәч, Аю бик ачуланган, ди.

Шуннан соң алар бодай чәчәргә уйлаганнар. Бу юлы Аю үзенә астын алырга булган, ә Бабайга өсте булачак икән.

Бодай өлгергәч, Бабай Аюга бер йөк салам илтеп аудара, ә үзенә бөртеге кала.

Көзен Бабай бодайдан күмәч пешергән дә Аюны кунакка чакырган. Аю элеккегә караганда да ныграк ачуланган. Бабайны, урманга утынга барса, ашыйм дип куркыткан, ди.

Менә кыш җиткән. Бабай урманга барырга курка икән. Ул утынга өй кыегын, өй почмакларын ватып яккан, ахыр чиктә аңа барыбер урманга барырга туры килгән.

Барган бу урманга. Шунда аның каршысына Төлке килеп чыккан. Бабай аңа үзенең кайгысын сөйләп биргән, ди. Төлке исә Бабайны бу бәладән коткарырга булган. Ул бабайдан кыңгырау сорап алган да, кыңгырау тавышына Аю килсә, аңа нәрсә әйтергә икәнен Бабайга өйрәтеп куйган:

— Аю кыңгырауның нигә чылтыраганын сораса, аңа «патша килә» дип әйт,— дигән.

Шуннан соң Төлке урман эченә кереп киткән дә кыңгырауны чылтырата башлаган. Аю урманнан йөгереп чыккан да Бабайдан кыңгырауның нигә чылтыраганын сорый икән. Бабай әйткән:

— Хәзер патша килә,— дигән.

Аю куркуыннан җиргә үк сузылып яткан һәм әйткән Бабайга:

— Патша минем турыда «бу ни?» дип сораса, син аңа «бу — бүкән» дип әйт,— дигән.

Ярар, Төлке, кыңгыравын чылтыратып, йөгереп килгән дә Бабайдан сорый икән:

— Бу ни? — дип.

Бабай:

— Бүкән,— дигән.

Төлке аңа:

— Әгәр бу бүкән булса, ул чанада булыр иде,— дигән.

Аю пышылдап кына үзен чанага күтәреп салуын үтенгән. Бабай шулай эшләгән дә. Шуннан соң Төлке әйткән икән:

— Әгәр дә бу бүкән булса, аңа балта чабып куелган булыр иде,— дигән.

Аю тагын Бабайга пышылдаган, үзенә балта чабып куйсын дип.

Бабай Аюга балтаны чабып куйган. Шулай итеп, ул Аюны үтергән, ди.

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

Сагындырган әкиятләр

I

39. Бәһадиршаһ вә гөмбә хикәясе

Әүвәл заманда бер мәмләкәттә бер бик бай вә олуг падишаһ бар иде. Ул падишаһның Гөлбикә исемле бер генә кызы бар иде. Ир баласы һич юк иде.

Падишаһ үзеннән соң үз урынына падишаһ булырга угылы булмавына бик хафаланыр иде. Падишаһ бик күп нәзерләр әйтте, суфи вә дәрвишләргә бик күп догалар кыйлдырды. Үзе дә Ходай Тәгаләдән, бик ихлас белән дога кыйлып, бер углан сорады. Ходай Тәгалә падишаһның догасын кабул кыйлды: берзаман падишаһның хатыны дөньяга бер ир бала китерде. Падишаһ бик сөенде, Ходай Тәгаләгә бик шөкерләр кыйлды, барча нәзерләрен әда кыйлды[1], бик күп фәкыйрь-фокрага ингам ихсан кыйлды[2].

Падишаһ бик күп халык зыяфәт кыйлып[3] мәҗлес ясады. Шаһзадәгә Бәһадиршаһ дәю[4] исем куйдылар.

---

[1] *Әда кыйлу* — үтәү.
[2] *Ингам ихсан кыйлу* — яхшы нигъмәтләр бирү.
[3] *Зыяфәт кыйлу* — чакыру.
[4] *Дәю* — дип.

Падишаһның сарайлары бик зур вә солтанәт[1] иде. Сарайларының артында бер зур бакчасы бар иде. Бакча артында бер зур агымсу да бар иде.

Берзаман җәйнең бик матур кояшлы көне иде. Падишаһның кызы Гөлбикә хезмәтче кызлар илә уйнашып-көлешеп йөргәндә:

— Һай, бик кәефем китте, эчем поша башлады,— диде.

Хезмәтче кызлар:

— Безнең дә әллә нишләп эчебез поша башлады, әллә нәрсәдән курыккан шикелле булабыз,— диделәр.

Падишаһ кызы, бераз кәефебез килмәс микән вә күңелебез ачылмас микән дип, хезмәтче кызларга бакчага аш хәзерләргә кушты.

Бәс, хезмәтче кызлар су буенда бакчаның күшәгенә[2] бик ләззәтле тәгамнәр[3] хәзерләделәр. Уенчы кызлар мөхкәмә[4] күшәк янына килеп, төрле уеннар уйный башладылар. Падишаһның кызы мәҗлескә утырды.

Берзаман, кәеф берлә хозур кыйлып мәҗлес корып утырганда, бик каты җил вә давыл чыкты. Бакча буендагы су шулкадәр дулкынланды ки, тәмам бакчаны су баса язды.

Бу вакыйгадан соң мәҗлестәге кызлар һәркайсы һушсыз булып егылдылар. Шул арада давыл берлә бик зур тау кеби бер гыйфрит (ягъни диюләр падишаһы) очып төште дә падишаһ кызы Гөлбикәне күтәреп алып китте.

Бакчаның сакчылары тиз генә падишаһка барып, вакыйганы бәян кыйлдылар, ягъни бер зур гыйфрит килеп падишаһның кызын алып киткәнлеген хәбәр бирделәр. Падишаһ вә хатыны, бу хәбәрне ишетеп хәйран калдылар. Ышаныр-ышанмас тиз генә егълый-егълый[5] бакчага төштеләр. Күрделәр ки, күшәк эчендә хезмәтче кызлар һушсыз булып яталар. Падишаһның үз кызы юк. Падишаһ вә хатыны вакыйганың растлыгын белгәч, һәр икесе биһуш[6] булып егылдылар.

Берничә сәгатьтән соң бу хәбәр Баһадиршаһка ирешге. Баһадиршаһ тизрәк бакчага йөгерде. Килсә, күрде ки, атасы-анасы егылышып яталар, тутасы Гөлбикә юк. Баһадиршаһ та кайгырып бик күп егълады.

Бу хәбәр бөтен шәһәргә җәелде. Бу төн шәһәр халкы кайгырышып

---

[1] *Солтанәт* — мәһабәт.
[2] *Күшәк* — аулак урын, беседка.
[3] *Тәгам* — ашамлык.
[4] *Мөхкәмә* — таза, нык.
[5] *Егълау* — елау.
[6] *Биһуш* — һушсыз.

матәм тоттылар. Падишаһ вә хатыны берничә көн авыру булып яттылар, кызлары һич исләреннән чыкмады. Сагына-сагына икесе дә тәмам саргайдылар.

Бу вакыйга булган заманда Баһадиршаһ унҗиде яшенә җитмеш иде. Исеменә муафыйк[1] бик баһадир егет иде. Мөгаллимнәренең тәртип вә назыйм[2] берлә укытулары сәясендә[3] күп гыйлем тәхсил кыйлмыш[4] иде. Җеннәр вә диюләрнең зарарыннан саклый торган догаларны үгрәнмеш[5] иде.

Баһадиршаһ туталарын бик сагыныр иде һәм ата-аналарын да бик кызганыр иде. Падишаһның шәһәреннән берничә йөз чакрым диңгез тарафында бер бик зур урман бар иде. Ул урманда җеннәр вә диюләр вә һәртөрле гаҗәеп хайваннар барлыгы халык арасында бик мәшһүр иде. Һәркем падишаһның кызын шул урмандагы диюләрнең берсе алгандыр диеп сөйләр иде. Баһадиршаһ та тутасын шул урманда диер иде.

Берзаман Баһадиршаһ, шул урманга барып, диюләр кулыннан тутасын алып кайтмак хәтеренә килде. Баһадиршаһ, яшь булса да, җен вә диюдән һич курыкмас иде. Үзенең батырлыгына вә догасына бик ышаныр иде. Баһадиршаһ ошбу фаразын[6] ата-анасына әйтеп, рөхсәт сорады.

Падишаһ вә хатыны һич рөхсәт бирмәделәр:

— Юк фаразларны кыйлма инде, Гөлбикә кеше алырлык җирдә генә түгелдер. Инде без сине дә ул урманга җибәреп, бердәнбер балабыздан да аерылыр хәлебез юк,— диделәр.

Баһадиршаһ бик ялынып-ялварып бакты. Ләкин ата-анасы һич разый булмадылар:

— Зинһар, газиз балабыз, мөмкин булмаган эшкә рөхсәт сорап безне борчыма, Ходай сакласын, әгәр дә без синнән дә коры калсак, син урманда бер сәбәп берлә һәлак булсаң, без ничек дөньяда торырбыз,— диделәр.

Мондый сүзләр илә һәр икесе угылларын фаразыннан кире сөрергә бик тырышып бактылар. Ләкин Баһадиршаһ һич сүзеннән кайтмады:

— Зинһар, мине күңелем төшкән эштән тыймагыз, әгәр дә мин чык-

---

[1] *Муафыйк* — тиң килгән.
[2] *Назыйм* — оешканлык.
[3] *Сәясендә* — нәтиҗәсендә.
[4] *Тәхсил кыйлу* — казану, алу-үзләштерү.
[5] *Үгрәну* — өйрәнү.
[6] *Фараз* — уй-фикер.

мый калсам да, бу җирдә рәхәт тора алмасмын, уйлана-уйлана авыруга сабышып бетәрмен,— диде.— Бәлки, сез рөхсәт бирмәсәгез дә, мин үзем бервакыт табып чыгып китәрмен,— диде.

Баһадиршаһ күп ялвара торгач, атасы да, анасы да риза булдылар. Баһадиршаһ бик сөенеп юл кирәкләрен хәзерләргә тотынды. Атасы күп акча вә бик кыйммәтле кораллар бирде дә янына Тимерҗан исемле бер куәтле вә батыр солдатны җибәрәчәк булды.

Бәс, берничә көннән соң, тәмам юл кирәкләрен хәзерләп бетереп, баһадиршаһ вә солдат һәр икесе бөтен шәһәр халкы илә бәхилләшеп юлга чыктылар. Берничә чакрым җиргә кадәр падишаһ үзе вә барча вәзирләр һәм гаскәрләр вә шәһәр халкы боларны озата бардылар. Баһадиршаһ ата вә анасыннан хәер-фатиха алып, тәмам бәхилләшеп, күрешеп аерылды. Падишаһ вә хатыны һәр икесе егълашып калдылар.

Берничә көн барганнан соң, әлеге дию пәриләре күплеге илә мәшһүр мәзкүр[1] зур урманга барып җиттеләр. Ходага тапшырып, төрле догалар укып, урманга кереп киттеләр. Урман бик куркыныч иде, һич адәм заты керми торган бер урман иде. Юллары вә агачлары да бик куркынычлы иде. Төрле ерткыч җанварлар вә ерткыч кошлар тавышлары ишетелмәктә иде. Урман эчендә бик озак бардылар. Берзаман кич булды, урман кап-караңгы булды, бик каты җил чыкты, агачлар шауламага башлады. Әллә нindәен гаҗәеп тавышлар ишетелә башлады. Төрле тарафтан ялт-йолт утлар вә ялкыннар һәм итсез сөякле генә адәм гәүдәләре күренә башлады. Тимерҗан солдат бик курка башлады. Ләкин Баһадиршаһ һич курыкмады. Чөнки һаман диюләрнең зарарыннан саклый торган доганы укыр иде. Җеннәр күзгә күренсәләр дә, зарарлары ирешмәслекне белер иде. Һаман кап-кара урман эчендә бик күп заман бардылар. Бара торгач, юлсыз җирләргә килеп чыктылар. Тимерҗан бик арыды. Туктап ашап-эчеп, бераз ял итмәкче булдылар. Үз яннарында тәгамнәре, бераз сулары бар иде. Ашадылар-эчтеләр, атларын үләнгә җибәрделәр.

Тимерҗан бер агач төбенә ятып йокламакчы булды. Баһадиршаһ, бер юл табып булмас микән дип, җәяүләп тарафны тәфтиш кыйлмага[2] чыгып китте. Төрле тарафка барып бакты,— һич яхшы юл таба алмады. Йөри торгач, адашып, Тимерҗан калган җирне җуйды. Йөрде, йөрде, һич таба алмый гаҗиз булды. Ул арада таң да атмыш иде. Егет ике зур

[1] *Мәзкүр* — әйтеп үтелгән.
[2] *Тәфтиш кыйлу* — тикшерү.

дию янына килеп чыкты. Диюләр бик иләмсез кыяфәтле иделәр, күзләре ут янып тора иде. Икәүләшеп зур агачларны тамырларыннан куптарып алып, бер-берсе берлә агачлар илә шау килеп сугыша иделәр. Баһадиршаһ боларны күргәч, бераз хәвефкә калды, ни кыйлырга да белмәде. Шул арада диюләр Баһадиршаһны күрделәр дә сугышларыннан туктадылар: «Әйдә, шул кешегә барып хәлебезне әйтик, шул кеше арабыздагы низагны киссен, ул ни дип хөкем кыйлса, шул хөкемгә һәр икебез разый булыйк»,— диештеләр. Шуннан соң, тапкан нәрсәләрен кулларына алып, йөгерешеп Баһадиршаһ янына килделәр. Баһадиршаһ, куркып, ни кыйлырга белмичә тора иде, һаман үзенең догасын укый иде.

Диюләр Баһадиршаһның шикләнебрәк торганлыгын белделәр:

— И әфәнде, бездән һич курыкма, без сиңа зарар итәргә килмәдек, син безнең низагыбызга бер хөкем кыйлсана,— диделәр.

Баһадиршаһ боларга ни дип җавап бирергә дә белмәде, җавап бирмәсә дә хәвефләнде:

— Ни низагыгыз бар? — диде.

Диюләрнең берсе:

— Без икебез урманда сәер кыйлып[1] йөргәндә ошбу нәрсәләрне таптык,— диеп, кулларындагы паласны, эскәтер вә бүрекне күрсәтте.— Ошбу нәрсәләрне мин үзем әүвәл күреп кулыма алдым. Ошбу иптәшем: «Мин әүвәл күрдем, ул нәрсә миңа тиеш»,— ди. Инде без бик күп сугыштык, аннан файда чыкмады, инде син һичберебезне якламыйча вә җәберләмичә гаделлек берлә хөкем кыйл,— диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Бу нәрсәләрдә ни хасият[2] бар? — диде.

Диюләр әйттеләр:

— Бу нәрсәләр бик хасиятле нәрсәләрдер,— диделәр,— кем дә кем ошбу паласны җәеп өстенә менеп утырса, кай тарафка баруны теләсә, шул тарафка очыртып алып китәдер; вә дәхи ошбу эскәтерне җәеп куйсаң, ниндәен тәгам теләсәң, шул тәгам хәзер буладыр; вә дәхи ошбу бүрекне кигән кеше һичбер кеше күзенә күренми йөри аладыр. Мондаен гаҗәеп хасиятле нәрсәләр диюләрнең дә күбесендә юктыр,— диде.

Баһадиршаһ ошбу нәрсәләрнең хасиятләренә бик кызыкты, бер хәйлә илә үзенә калдырмакчы булды. Диюләргә әйтте:

---

[1] *Сәер кыйлу* — гизү.
[2] *Хасият* — үзенчәлек.

— Сез бу нәрсәләрне уртак тапкан икәнсез, минем хөкемем шул ки, йөгергәндә сезнең кайсыгыз узса, бу нәрсәләр шуңар булыр,— диде.

Диюләр һәр икесе бу хөкемне бик мәгъкуль[1] күрделәр, йөгерешеп-узышып карамакчы булдылар.

Баһадиршаһ әйтте:

— Ун чакрым чамасы җирдән йөгерешеп килегез, мин ошбу агач төбендә сезне көтеп торыйм,— диде.

Диюләр лапыр-лопыр килеп йөгерешеп киттеләр.

Баһадиршаһ ошбу нәрсәләрне кулына алып калды. Инде ни кыйлыргә белмәде. Паласка утырып очып китсә, Тимерҗан ялгыз кала, яки эзләп йөрсә, диюләрнең чабышып килеп җитү ихтималлары бар. Бераз уйлап торды да, Ходага тапшырып, паласка утырып, туталары янына китүне мәгъкуль тапты. «Шаять, Тимерҗанны да Хода үзе саклар»,— диеп, бүрек илә эскәтерне кулына тотып, паласны җәеп, өстенә менеп утырды да:

— И палас, син мине тутам янына илтеп куй,— диде.

Шул сәгать палас югары күтәрелеп, Баһадиршаһны алып бер тарафка очып китте.

Диюләр, бик каты пыр-пыр килеп, дөньяны туздырып чабышып килеп җиттеләр, икесе дә бертигез килде. Кайсы элек килгәнлеге мәгълүм булырлык булмады. Килеп җиткәч тә: «Мин элек килдем» дә, «мин элек килдем»,— дәю янә сугыша башладылар. Баһадиршаһның юклыгын сизмичә бик күп сугыштылар да, арып туктагач, күрделәр ки: агач төбендә Баһадиршаһ юк һәм хасиятле нәрсәләр дә юк. Бөтен урманны туздырып шау-шу килеп, Баһадиршаһны эзләп йөри башладылар. Әгәр тапсалар, бик каты кыйнап үтермәкче иделәр.

Берзаман, урман арасында йөргәндә, Тимерҗанны күрделәр. Тимерҗан бик гаҗиз булып, аптырап, Баһадиршаһны эзләп йөрер иде. Диюләр, Тимерҗанны күрү берлә, икәүләшеп килеп ябыштылар, һәр икесе аны, Баһадиршаһ диеп, таныр-танымас бик каты кыйный башладылар, чөнки таң вакытында Баһадиршаһны бик яхшы танып калмаган иделәр. Тимерҗан бик курыкты. Бик ялынып, аякларына егылып ялвара башлады:

Зинһар, кыйнамагыз, мине ни өчен бу кадәр кыйныйсыз, минем ни гаебем бар? — диде.

---

[1] *Мәгъкуль* — урынлы.

Диюләр:

— Безне алдап ник качтың, безнең нәрсәләребезне ник яшердең? — диделәр.

Тимерҗан әйтте:

— Ул ниндәен нәрсәләр, мин һичбер нәрсә алганым юк, мин сезне әүвәл күрешем,— диде.

Шуннан соң диюләр, текәлебрәк карагач, Баһадиршаһ түгел икәнлеген белделәр дә кыйнаудан туктадылар:

— Инде, зинһар, гафу ит, без сине үзебезне алдаган кеше диеп белдек,— диделәр.

Тимерҗан әйтте:

— Ул сезне алдаган кеше кем иде, ни кыяфәтле иде? — диде.

Диюләр әйттеләр:

— Фәлән кыяфәтле, фәлән киемле бер егет,— диделәр.

Тимерҗан боларга тугры килгән кешенең Баһадиршаһ икәнлеген белде. Һәм диюләр дә Тимерҗанга:

— Син нинди кеше, кая барасың? — диделәр.

Тимерҗан әйтте:

— Мин бер мосафирмын, ошбу урманны күргәч, бу ниндәен урман икән, дәю тамаша кыйлырга кергән идем; йөри торгач, адашып юлымны саташтым, урманнан чыгыйм-чыгыйм, ди-ди никадәр йөрдем, һәнүз[1] урман кырыена чыгып җиткәнем юк,— диде.

Диюләр Тимерҗанны бик кызгандылар, юлны да күрсәттеләр, янә бер хасиятле алма да бирделәр:

— Ни максудың булса да, ошбу алманы бераз кап,— ни теләсәң, шул сәгать максудың хасыйл булыр,— диделәр дә үз юлларына киттеләр.

Тимерҗан: «Инде бу алманы ни максуд берлә кабыйм икән»,— дип, байтак уйланып торды. Ахырында, Баһадиршаһка юлыкмак максудына ният кыйлып, бераз капты. Шул сәгать җир астыннан бер ишәк чыгып, каршында торды. Тимерҗан белде ки, ошбу ишәк Баһадиршаһ янына алып барачак. Ходага тапшырып, ишәккә атланды. Атлануы берлә ишәк чабып алып китте. Ишәк илә Тимерҗан бик күп барды, кая барам икән, ди-ди хәвефләнә-хәвефләнә бара иде. Берзаман ишәк, урманның бер җиренә барып җиткәч, тып туктады. Тимерҗан атланып килә-килә бик

---

[1] *Һәнүз* — һаман да.

армыш иде. Ишәк туктагач, җиргә төшеп бераз ял итмәкче булды. Җиргә төшүе берлә ишәк күздән гаип булды[1].

Тимерҗан: «Баһадиршаһ ошбу җирдә микәнни?» — диеп уйланып як-ягына каранып торганда, алпан-тилпән эштеренә-эштеренә бер бик зур гөмбә килгәнен күрде. Тимерҗан карап тора иде, акрын-акрын гөмбә аның янына килеп җитте:

— И агай, син нинди зат, синнән адәм исе киләдер, бу җиргә һич адәм заты килгәне юк иде, син ничек монда килдең? — диде.

Тимерҗан:

— Синең ни эшең бар, үзем килдем! — диде.

Гөмбә әйтте:

— Минем ник эшем булмасын, мин ошбу сәйранлыкның[2] каравылчысымын, син ник рөхсәтсез килдең? Мин сине падишаһыбызга барып әйтермен. Безнең падишаһыбыз бик куәтле падишаһтыр, ошбу урмандагы җеннәр, диюләр, пәриләр һәм һәртөрле хайваннар вә гөмбәләр аның кул астында торалар. Әгәр дә сине күрсә, һич ашамый калмас, ул адәм ите бик яратадыр,— диде.

Тимерҗанның бу гөмбәгә бик ачуы килде; кулы-аягы юклыгы мәгълүм булганлыгыннан, куәтсезлеген белеп, гөмбәне кыйнамакчы булды. Янына таба барып, башына йодрык берлә бер генә мәртәбә орган иде, гөмбәнең эшләпәсе өзелеп төште. Шул сәгать гөмбә, чыр-чыр килеп кычкырып, җан бирә башлады. Тимерҗан кызыксынып гөмбәнең эшләпәсен алып кигән иде, шул сәгать үзе дә тышкы яктан гөмбә кыяфәтле булды да китте. Бу хәлне күреп, Тимерҗан бик гаҗәпсенде, алманы кабып иске хәленә кайтмакчы да булды, ләкин капмады, чөнки уйлый торгач, гөмбә көенчә торуны мәгъкуль күрде: «Фаразан[3], диюләрнең падишаһлары килә калса, тотар да ашар. Әгәр дә гөмбә кыяфәтле булса, бәлки, адәм икәнлеген танымас, ихтимал, әүвәлге каравылчы дип белер».

Шул арада бик каты бер җил вә давыл чыкты, бераз соңра бик күп гөмбәләр килә башладылар, гөмбәләр артыннан диюләрнең патшасы гыйфритне күтәреп китерделәр. Янә гыйфрит янында Баһадиршаһның тутасы бара иде. Курку вә хафа сәбәпле, ул бик ябыккан вә саргайган иде. Бу халыклар падишаһны гөмбәләр шәһәренең сәйранлыгына тамаша

---

[1] *Гаип булу* — югалу.
[2] *Сәйранлык* — гизеп, тамаша итеп йөри торган урын.
[3] *Фаразан* — уйлап караганда.

кыйлдыру өчен кунак итеп алып килмешләр иде. Гөмбәләр дә һәркайсы урманның зур падишаһы гыйфриткә табигъ[1] иделәр.

Сәйранлыкка килеп җиткәч тә, берничә гөмбә Тимерҗан янына килделәр:

— Нихәл, яхшы сакладыңмы, хәвеф-хәтәр юкмы? — диделәр.

Тимерҗан:

— Бик яхшы сакладым, һичбер хәвеф-хәтәр юк, һәрбер нәрсә сәламәт, — диде.

Тимерҗанның кеше икәнлеген һич танымадылар, әүвәлге каравылчы гөмбә диеп белделәр, чөнки Тимерҗан тышкы яктан бигайниһи[2] чын гөмбә кыяфәтле иде.

Гөмбәләр бик гаҗәеп ашлар пешереп, диюләрне бик сыйладылар, һәркайсы берничә сәгать кәеф-сафа кыйлдылар. Падишаһ кызы дию вә гөмбәләрнең кыйланышына күңелсез генә карап, карап торыр иде. Аңа да берәр төрле тәгам биреп ашаттылар.

Тимерҗан падишаһ кызын күреп таныды, хәлне күреп бик кызганды һәм, шаять, бер җай табып алып кайтып булмас микән диеп, эченнән бераз сөенде; кызга үзенең Тимерҗан икәнлеген белдермәде, чөнки аның берлә сөйләшеп торса, гөмбәләр кеше икәнлеген белүләре дә ихтималдыр.

Кичкә таба барча диюләр вә гөмбәләр Гөмбә шәһәренә кайтып киттеләр. Гөмбәләрнең башлыгы каравылчы Тимерҗанга, сәйранлыкны яхшы сакламага кушып, бераз чәйлек биреп калдырды.

Тимерҗан янә урман эчендә ялгыз калды. Тимерҗан гөмбә булуына бик кайгырыр иде, ләкин алмасын адәм кыяфәтенә кайту нияте берлә капса, диюләрдән куркыр иде; әүвәлге шәһәренә кайту нияте берлә капса, Баһадиршаһтан башка кайткач, падишаһ үлтерер дип куркыр иде. Һәм Баһадиршаһ илә күрешеп булмасмы, бәлки кызны да кулга төшереп булмасмы, диеп тә фикерләр иде.

Берзаман ялгыз уйланып йөргәндә күккә таба караган иде, еракта бер зур карамчык[3] очып килгәнне күрде. Бераздан соң карамчык якынлашты. Карап тора торгач, күрде ки, бер палас өстендә Баһадиршаһ очып киләдер. Шул арада Баһадиршаһ җиргә килеп тә төште. Палас өстендә очып килә-килә бик армыш вә ялыкмыш иде. Килеп төшкәч,

---

[1] *Табигъ* — иярүче, буйсынучы.
[2] *Бигайниһи* — нәкъ.
[3] *Карамчык* — кара тап.

тарафына карады, күрде ки, төшкән җире һичбер кешесез бер урмандыр. Як-ягына каранып торганда күрде ки, бер тарафтан бер зур гөмбә селкенә-селкенә үзенә таба киләдер. Гөмбәнең йөрүен күргәч, Баһадиршаһ бик гаҗәпкә калды. Янына килеп җитә башлагач, гөмбәне үлтермәкче булып кылычны хәзерли башлаган иде, Тимерҗан кычкырып сәлам бирде. Баһадиршаһ Тимерҗан тавышын ишеткәч бик сөенде. Ләкин Тимерҗан тавышы гөмбә эченнән ишетелүенә бик гаҗәпсенде. Сәламне алды да сораша башлады.

Баһадир:

— Син кем буласың?

Тимер:

— Мин синең юлдашың Тимерҗан әфәнде буламын.

Баһадир:

— Син ни сәбәп берлә бу кыяфәткә кердең?

Тимер:

— Бу урман гөмбәләр урманы икән. Каравылчы гөмбә берлә низаглашкан идек, ул мине диюләргә әйтеп үтертмәкче булды. Шуннан соң мин аны үтердем дә эшләпәсен алып башыма кидем. Аны кию берлә шул сәгать үзем дә гөмбә кыяфәтендә булдым.

Баһадир:

— Син монда ни эшләп торасың?

Тимер:

— Бу җир гөмбәләрнең сәйранлык җирләре икән. Мин ошбу җирне каравыллап торам.

Баһадир:

— Гөмбәләр синең кеше икәнлегеңне белмиләрме?

Тимер:

— Юк, алар һич сизмиләр, алар һаман мине әүвәлге каравылчылары диеп белеп йөриләр.

Тимерҗан Баһадиршаһ берлә кул биреп күрешмәк өчен һаман якын килер иде, ләкин Баһадиршаһ кылычы берлә үзенә бик якын китермәс иде, чөнки һаман гөмбәнең Тимерҗан икәнлегенә ышанып бетмәгән иде. Ихтимал, диюләрнең бер хәйләсе түгел микән, дәю һаман шөбһәләнер иде.

Шуннан соң Тимерҗан әйтте:

— Ник куркасың, әллә минем Тимерҗан икәнлегемә ышанмыйсыңмы?

Баһадир:

— Ышанамын, ышансам да, бик якын килми торуың мәгъкуль,— диде.

Тимер:

— Син кая югалдың?

Баһадир:

— Мин юл эзләп йөри торгач, адаштым да сине таба алмадым, йөри торгач, бик гаҗәп ике диюгә очрадым, алардан ошбу палас илә ошбу бүрекне һәм дәстәрханны[1] алдым да, паласка утырып, монда очып килдем.

Сөйләшә торгач, Баһадиршаһ гөмбәнең Тимерҗан икәнлегенә ышанды. Шуннан соң һәр икесе башларына килгән вакыйгаларын бер-берсенә бәян кыйлыштылар. Тимерҗан Баһадиршаһка тутасының бу җиргә килгәнлеген дә сөйләде. Аны ишетеп, Баһадиршаһ бик шатланды. Ул көнне көн буенча һәм төн буенча сөйләшеп вә киңәшеп чыктылар.

Иртәгәсен, кояш чыгып бераз күтәрелгәч, янә гөмбәләр килә башладылар. Алар күренә башлагач, Тимерҗан Баһадиршаһка бер агач башына менеп качып торырга кушты.

Берзаман берничә дию пәрие Баһадиршаһның тутасын тәхет берлә күтәреп китереп төшерделәр. Ул тәхеттә гыйфрит үзе юк иде, чөнки ул үзе һәр заман берәр сәгать соң килер иде.

Баһадиршаһ тутасын күргәч, янына барып күрешмичә чыдый алмады. Үзенең котына вә догаларына ышанып, Ходага тәвәккел кыйлып[2], агачтан төште дә тутасы янына барды. Тутасы кардәшен күреп шаккатты, бик куанды. Һәр икесе сөенешеп сөйләшә башладылар. Тутасы Баһадиршаһтан ни өчен вә ни рәвешчә килгәнлеген сөаль кыйлды. Баһадиршаһ һәрбер кыйссасын бәян кыйлды. Тутасы кардәше үзен дию кулыннан алу максуды берлә килүенә бик рәхмәт укыды:

— Ләкин мине ала алырсың микән, мине моннан алып китү бик мөшкел булыр,— диде.

Яхшы гына сөйләшеп торган заманда: «Гыйфрит килә»,— диделәр. Баһадиршаһ гыйфрит килеп җиткәнче хасиятле бүрекне киде дә күздән гаип булды.

Гыйфрит янә бер зур тәхет берлә очып килеп төште. Кыз янына барып утырды. Килеп утыргач та:

---

[1] *Дәстәрхан* — ашъяулык.
[2] *Тәвәккел кыйлу* — таяну.

— Бу ни гаҗәп, бу җирдә бер адәм исе бар,— диде.

Кыз әйтте:

— Ник монда адәм исе булмасын, мин үзем адәм ич!

Гыйфрит әйтте:

— Юк инде, син, асылда, адәм нәселеннән булсаң да, хәзердә дию хатыны булдың, хәзер син дию хөкемендә,— диде.— Бу җирдә синнән башка бер адәм исе килә,— диде.

Шул арада Баһадиршаһ бүрекне салды да гыйфритнең каршысына килеп чыкты. Һич курыкмыйча:

— Хуш, ни кыйлмакчы буласың? Ул адәм мин буламын,— диде.

Баһадиршаһның бу рәвешчә батырлануын күргәч, тутасы егълый башлады, ачу берлә кардәшен гыйфрит һәлак кыйлыр диеп, бик курыкты. Баһадиршаһка күз кысып, юашлык берлә сөйләшергә кушты.

Гыйфрит әйтте:

— Ни кыйлмакчы булыйм? Сине пешертеп, майга кыздырып ашамакчы буламын,— диде.

Баһадиршаһ һич каушамыйча:

— Яхшы, кулыгыздан килсә, тәҗрибә кыйлып карагыз,— диде.

Баһадиршаһ бу сүзләрне әйткәндә тутасының тәмам төсе китте. Шул арада гыйфрит Баһадиршаһны тотып бумакчы булды. Ләкин тотарга һич кулы бармады, чөнки Баһадиршаһ һаман догасын укып тормакта иде. Падишаһ кызы, энесенә гыйфритнең көче җитмәгәнлеген күреп, бик сөенде. Гаскәрләре вә хезмәткәрләре алдында бер кешегә куәте җитмәвенә гыйфритнең бик кәефе китте вә бик гарьләнде. Шулай булса да, сиздермәскә тырышып, Баһадиршаһ илә йомшак кына сөйләшә башлады вә әйтте:

— Син кем буласың? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Мин фәлән мәмләкәт падишаһының угылы буламын,— диде.

Гыйфрит Баһадиршаһның бу сүзләрен ишеткәч, эшнең кая барачагын сизенде, ягъни Баһадиршаһның дога илә тутасын алыр өчен килгәнлеген белде вә әйтте:

— Син монда ни өчен килдең? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Мин газиз тутамны алмага килдем,— диде.

Гыйфрит әйтте:

— Ул тутаңны ник алып китәсең? Инде ул безнең җиргә бик ияләнде. Мин аны бик кадерләп тотамын,— диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Бик яхшы, рәхмәт. Моңарчы кадерләп тоткансың икән. Ләкин мин атамның әмере илә килдем. Атам әйтте: «Ни кыйлсаң да кыйл — кызымны алып кайт»,— диде. Мин тәнемдә җаным бар кадәр атамның сүзен җиренә китерергә тырышамын,— диде.

Гыйфрит ни җавап бирергә белмәде; чөнки каты җавап бирсә, ихтимал, Баһадиршаһ бик тәэсирле догалар укып, гаскәрләре алдында хур итәр диеп курыкты. Шулай булса да, Баһадиршаһны гаҗиз кыйлыр өчен, әйтте:

— Мин сиңа тутаңны бирермен, ләкин бик зур бер шарты бар,— диде.— Әгәр дә шул шартны кыйла алсаң, тутаңны хәзер, бүген алып китәрсең,— диде.

Падишаһ кызы, бу сүзләрне ишеткәч, бер яктан куанды. Ләкин шарты ни икән дәю бик уйга калды.

Баһадиршаһ әйтте:

— Ни шартыгыз бар? — диде.

Гыйфрит әйтте:

— Мине ошбу җирдә фәлән төрле ашлар — нигъмәтләр берлән туйганчы сыйла, шуннан соң мин сиңа тутаңны бирермен,— диде.

Гыйфрит теләгән ашлар бик гаҗәеп ашлар иде. Ул ашларны адәм баласы хәзерләмәк һич мөмкин түгел иде, вә дәхи гыйфрит бик күп ашар иде. Үзен Баһадиршаһ һич туйдыра алмас диеп гөман[1] кыйлыр иде.

Баһадиршаһ бик сөенеп: «Ярый, бик яхшы, рәхим итегез»,— диеп, дәстәрханны падишаһ алдына китереп җәйде. Шул сәгать дәстәрхан өстендә падишаһ теләгән ашлар хәзер булды. Бу эшкә гыйфрит бик тәгаҗҗеб кыйлды[2], һәм шул мәҗлестә булган башка кешеләр дә бик гаҗәпсенделәр. Гөлбикә дә бик сөенде. Гыйфрит, ашап бетерим дип, бик күп ашады, янындагы кешеләр дә ашадылар, һәркайсы туйдылар. Дәстәрханда аш һаман бетмәде. Гыйфрит туйгач та бераз ашап бакты, ләкин ашны һич бетерә алмады. Ахры, гаҗиз булып, ашаудан туктады.

Гыйфрит туктагач, Баһадиршаһ әйтте:

— Тагы ниндәен тәгамнәр телисез? Сорагыз, без тиз хәзер кыйлырбыз,— диде.

Гыйфрит янә бик гаҗәеп, дөньяда һич булмый торган тәгамнәр өстәде.

---

[1] *Гөман* — уй, фикер.

[2] *Тәгаҗҗеб кыйлу* — гаҗәпләнү.

Шул сәгать дәстәрханда ул тәгамнәр дә хәзер булды. Ләкин аларны гыйфрит ашый алмады, чөнки карыны бугазына кадәр тулган иде.

Гыйфрит дәстәрханның хасиятен аңлады һәм ул дәстәрханны үзенә алырга бик кызыкты, Баһадиршаһтан сорады:

— Син бу дәстәрханны кайдан алдың? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Бер урманда ике диюдән алдым,— диде.

Гыйфрит әйтте:

— Ул кулыңдагы палас илә бүрек нинди нәрсәләр? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Алар да дәстәрхан кеби хасиятле нәрсәләр,— диде.

Гыйфрит әйтте:

— Нindәen хасиятләре бар? — диде.

Баһадиршаһ паласның да, бүрекнең дә хасиятләрен бәян кыйлды. Гыйфрит бу нәрсәләргә дә бик кызыкты. Янә сорады:

— Син бу нәрсәләрне кайдан алдың? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Боларны да шул диюләрдән алдым,— диде.

Гыйфрит әйтте:

— Ул диюләр бу нәрсәләрне ничек сиңа бирделәр? — диде.

Баһадиршаһ әйтте:

— Дога укып, әүвәл аларның һушларын җибәрдем дә аннан соң алып качтым,— диде.

Гыйфрит, бу сүзләрне ишеткәч, үзе дә бик каушады, Баһадиршаһ илә тагы да йомшаграк сөйләшә башлады.

Гыйфрит әйтте:

— Инде мин сиңа тутаңны бирәмен, ләкин синнән үтенәмен: хасиятле өч нәрсәңне дә миңа бирсәнә,— диде.

Баһадиршаһ һичберсен бирәсе килмәде. Чөнки һәркайсы юлда үзенә кирәк булачак иде. Сөйләшеп торган арада гыйфрит тиз генә очып китте. Баһадиршаһ илә Гөлбикә инде: «Шаять, котылдык бугай, гыйфрит догадан куркып качып китте бугай,— диештеләр.— Тиз генә паласка утырып очып китәек»,— диеп хәзерләнә башладылар.

Шул арада Тимерҗан да килеп җитте:

— Зинһар, мине дә алып кайтыгыз, монда ялгыз калдырмагыз,— диде.

Өчәүләшеп утырып китәрбез диеп торганда, күктән бер кош килде

дә Баһадиршаһны биленнән күтәреп алып китте. Палас, дәстәрхан, бүрек — һәркайсы шул җирдә калдылар. Гөлбикә илә Тимерҗан куркышып, гаҗәпсенеп калдылар. Гөлбикә, кайгырып, бик елады. Алар икесе паласка утырып китәргә киңәшкәнче, гыйфрит үзе дә килеп җитте. Гыйфрит шул сәгать хасиятле нәрсәләрне алды да, гаскәр вә хезмәткәрләренә әмер кыйлып, кызны вә үзен күтәреп йортларына алып кайтырга кушты. Һәркайсы киттеләр. Тимерҗан ялгыз аптырап калды.

Йортына кайткач та гыйфрит Гөлбикәне бик мәхкәм[1] бер сарайга бикләп куйды.

Тимерҗан, ялгыз калгач, бик хафаланып кычкырып елады. Баһадиршаһтан тәмам өметен кисте. Чөнки ул кош аны, әлбәттә, үлтермәк, һәлак кыйлмак өчен алып киткәнлеге мәгълүмдер. Тимерҗан акрынлап урманнан чыгып, шәһәр тарафына кайтуны фарыз[2] кыйлды.

Гөмбәләрнең сәйранлыгыннан бер читкәрәк китеп, алмасын кабып кеше кыяфәтенә кайтты, кулында алмасы бары бер генә кабарлык калды. «Инде ни рәвешчә шәһәргә кайтырмын икән?» — дәю уйланауйлана, урман эченнән бик озак барды. Бара торгач, бер су буена барып чыкты. Су буена утырып су эчеп, балык пешереп ашап, бераз ял итмәкче булып утырды. Бераз йокламакчы булып яткан иде, өстеннән бер зур кош очып барганын күрде. Яхшылабрак карагач күрде ки, ул кошның аягында бер кеше дә асылып барадыр. Тимерҗан: «Әлбәттә, бу кош Баһадиршаһны алып киткән кош булырга кирәк»,— диде. Инде ничек Баһадиршаһны ул кош кулыннан коткармак кирәк? Алманы капса, бәлки кош ташлар иде — алмасы бары бер генә кабарлык калган, шәһәргә кайтмак өчен үзенә кирәк иде. Әгәр дә алма бетсә, һәр икесе урманда аптырашып гаҗиз булып калмак кирәк. Әгәр дә алманы кызганып капмый калса, Баһадиршаһ һәлак булмак кирәк. Бераз вакыт уйлап торды, торды да, Ходайга тапшырып, кош кулындагы кешенең сәламәт килеп төшүен адарынып[3], калган алмасын кабып бетерде. Ул капканчы кош байтак җир узып китмеш иде.

Тимерҗан алманы капкач та кош кире борылып килде дә Баһадиршаһны җиргә куеп, очып китте. Баһадиршаһның тәмам һушы киткән иде. Тагы берәр сәгать кош кулында йөрсә, җан бирер дәрәҗәгә килеп

---

[1] *Мәхкәм* — нык.
[2] *Фарыз* — тиешле.
[3] *Адарыну* — теләү.

җиткән иде. Бер-ике сәгать җирдә һушсыз булып ятты. Айныгач, күзен ачып карагач, янында Тимерҗанны күреп бик сөенде. Икәүләшеп егъ-лашып күрештеләр. Тимерҗан тиз генә Баһадиршаһка балык пешереп ашатты.

Ашап-эчеп бетергәнче кич булды, урман тәмам караңгыланды. Урман эчендә су буйларында ялт-йолт утлар күренә башлады. Су өстеннән зур хайваннарның башлары күренә башлады, төрле ерткыч хайваннарның тавышлары вә елан сызгырган тавышлар ишетелә башлады. Төн уртасы җиткәч, бик каты бер җил чыкты. Агачлар вә сулар дулкынланып шау иттеләр.

Баһадиршаһ илә Тимерҗан урманның шаулавыннан вә ишетелгән тавышлардан бик куркыштылар. Урман эчендә бу кадәр куркынычлы хәл күргәннәре юк иде. Бу су буе бигрәк куркынычлы җир икәнлеген белделәр. Төн уртасы авышкач, җил вә давыл бераз басылды. Таң алдыннан Баһадиршаһ илә Тимерҗан йокыга киттеләр.

Кояш чыгып күтәрелгәч, һәр икесе йокыдан тордылар. Киңәшә-киңәшә су буе белән су агымына таба киттеләр. Икесенең дә кулларында һичбер хасиятле нәрсә юк иде. Чөнки Баһадиршаһның палас, бүрек, дәстәрханы гөмбәләр янында калмыш иде. Тимерҗанның алмасы да беткән иде. Шул сәбәптән Тимерҗан Баһадиршаһка кайтыйк дип киңәш бирер иде, ләкин Баһадиршаһның тутасын алмыйча шәһәргә кайтасы килмидер иде. Үзенең куәтенә вә догаларына ышанып, һаман ничек булса да тутамны алырмын, диеп фараз кыйлыр иде.

Көн буенча су буе берлә бардылар. Юлда гаҗәеп агачлар вә төрле-төрле җимешләр күрделәр. Урманның ул тирәсенә һич адәм заты кергәне юк иде. Бара торгач, кич булды. Үткән кичтәге кеби урман вә су янә куркыныч хәлгә керде. Төн уртасы җитте. Янә бик каты җил вә давыл чыкты. Төн уртасы авышканчы һаман акрын-акрын алга таба бардылар.

Төн уртасы авышып давыл басылгач, бер җиргә ял итмәкче булып утырдылар. Шул арада агач арасыннан су буенда бер тәрәзә яктысы күренде. Яхшылабрак карасалар, күрделәр ки: су буенда кечкенә генә бер йорт бар икән. Икесе дә куркырга да, курыкмаска да белмәделәр. Икәүләшеп акрын гына өйнең янына барып, тәрәзәсеннән эченә карадылар. Күрделәр ки: өй эчендә сачлары[1] агарган, тешләре төшеп беткән, күзләре ут шикелле ялт-йолт итеп тора торган арык вә ямьсез бер кар-

---

[1] *Сач* — чәч.

чык утырадыр. Сачларын туздырып, күзләрен челәйтеп, күккә таба карап, сихер укып утырадыр. Тәрәзәдән бик күп карап тордылар. Карчык һаман укый да укый. Укый торгач, бик ямьсез тавыш берлә кычкырып җибәрә. Бик күп укыгач, башын шап итеп җиргә бәреп, сәҗдәгә китте. Берничә мәртәбә сәҗдә кыйлды да, дога кыйлып, үзенең гамәлен тәмам итте. Ул арада таң да якынлашкан иде.

Гамәле тәмам булгач, карчык, бик каты кычкырып, кулына бер яулык тотып селкеде. Шул сәгать урман арасыннан берничә пәри килеп чыкты. Су эченнән янә бер-ике пәри чыкты. Һәркайсы йөгерешеп карчык янына керделәр. Карчык аларга берничә төрле эшләр боерды: кайсына он вә ярма китерергә кушты, кайсына ит вә май китерергә кушты. Су пәриләренә су вә балык китерергә кушты. Шуннан соң пәриләр, пырылдашып карчык өеннән чабышып чыгып, төрлесе төрле тарафка йөгерешеп киттеләр.

Пәриләр өйгә кергәч, йорт янында ике кеше торганлыгын карчыкка сөйләгәннәр булырга кирәк; чөнки пәриләр чыккач та, карчык, ишеген ачып:

— Әйдәгез, кунаклар, хуш килдегез, йортыбызга рәхим итегез,— диде.

Баһадиршаһ илә Тимерҗан куркыр-курыкмас, Ходайга тапшырып, догаларын укып, карчыкның өенә керделәр. Өй эчендә бер карават, бер-ике озын эскәмия вә бер өстәл бар иде. Мич эчендә ут та янып торадыр иде. Карчыкны тәгъзыйм кыйлып[1] кулын үбеп күрештеләр.

Карчык:

— Утырыгыз,— диде.

Һәр икесе эскәмиягә барып утырдылар. Карчык сораштыра башлады. Баһадиршаһ үзләренең кем икәнлекләрен вә һәрбер башларыннан кичкән вакыйгаларны берәм-берәм бәян кыйлды.

Карчык әйтте:

— Мин үз пәриләремнән: «Гыйфрит бер адәм падишаһының бер кызын урлап килгән, имеш»,— дәю ишеткән идем һәм, ул кызны вә ата-анасын кызганып, бик хафаланган идем. Ләкин ул кызның үзен һич күргәнем юк. Чөнки ул гыйфрит бездән бик ерак булмаса да, дуслыгыбыз юктыр, шуның өчен һич йөрешмибез,— диде.

Асылда, бу карчык үзе дә адәм баласы булган икән. Яшь вакытында аны да бер дию урлап, ошбу урманга алып килмеш икән. Шул дию

---

[1] *Тәгъзыйм кыйлу* — олылау.

үлгәнче бу карчык аның кулында тормыш иткән. Ул дию үлгәннән бирле үз алдына көн күрә башламыш икән. Шул сәбәптән карчык Баһадиршаһ илә Тимерҗанны үз җенесе[1] итеп бик якты чырай илә кабул итте һәм кулыннан килгән кадәр ярдәм кыйлачак булды.

Баһадиршаһ карчык илә бер-ике сәгать чамасы сөйләштеләр. Тимерҗан һич сүзгә катышмады, карыны бик ачкан иде, ашыйсы киләдер иде. Карчыкның бик күп сөйләвенә эче пошты вә үзенең тупаслыгы, вә мәҗлес күрмәгәнлеге сәбәпле әйтте:

— Абыстай, син бик күп сөйләшәсең икән. Бу кадәр күп сөйләшкәнче, кунакларыңны туйдырсаң, бигрәк яхшы булыр иде,— диде.

Тимерҗанның бу сүзләренә карчыкның бик ачуы килде. Ачуы килсә дә заһирән[2] һич белгертмәде. Яулыгын селкеп бер төрле тавыш берлә кычкырган иде, морҗадан маймыл төсле берничә вак пәри сикерешеп төштеләр. Һәрберсе икешәр генә карыш буйлы вә бик зур башлы иделәр. Карчык аларга коймак пешерергә кушты. Бер савытта коймакка диеп хәзерләнеп куелган камыр бар иде, шул сәгать пәриләр, берничә табага камыр салып, мич эченә кереп киттеләр. Мичнең түренә кереп, яна торган күмернең өстенә аякларын ерып утырып, куллары белән табаларын тотып, коймакны кыздыра башладылар. Янә бер-ике пәри пешкән коймакны майлап бер савытка салып, мәҗлескә китереп куя башладылар. Һәркайсы ашый башладылар. Баһадиршаһның да бик карыны ачкан иде. Урманда күп йөрү сәбәпле, мич ашын бик сагынган иде. Тансык аш диеп, Баһадиршаһ шактый ашады.

Карчык илә Баһадиршаһ туйды, ләкин Тимерҗан һич туймады. Коймак бик күп иде, пәриләр һаман пешерә торалар иде. Тимерҗан кызарабүртенә һаман ашый да ашый, һич туя алмый. Бара торгач, коймаклар Тимерҗанның авызына очып-очып керә башладылар. Тимерҗан авызын гына ачып торды. Акрын-акрын Тимерҗанның корсагы үсә башлады. Үсә-үсә өстәлне этә башлады. Тимерҗан һаман туймады, авызын ачып чәйни-чәйни генә торды. Пәриләр көлешә башладылар, камыр беткәнче коймакны пешерделәр. Коймакларның һәркайсы Тимерҗанның авызына кереп беттеләр. Тимерҗан бу эштән бик курыкты. Баһадиршаһ та, бер хикмәт булмаса ярар иде дип, бераз каушады. Асылда, бу эш Тимерҗанның әдәпсез сөйләвенең җәзасы иде. Тимерҗан хәле китеп

---

[1] *Җенес* — бу урында: кавем.

[2] *Заһирән* — ачык итеп.

егылды. Шуннан соң аны пәриләр, аунатып, тәгәрәтеп, ишектән чыгардылар.

Тимерҗан, елап, карчыкка ялына башлады:

— Зинһар, мине бу хәлдән коткарсана,— диде.

Баһадиршаһ та карчыктан үтенде:

— Зинһар, аның тупаслыгын вә мәҗлес күрмәгәнлеген гафу итсәнә,— диде.

Карчык көлемсерәп:

— Ярый алай булса, синең хәтереӊ өчен гафу итәм,— дип, гафу итте. Пәриләргә Тимерҗанны аунатырга кушты.

Пәриләр кычкыра-кычкыра Тимерҗанны тәгәрәттеләр. Тимерҗан көчкә сулу алды.

Баһадиршаһ карчыктан тутасын алырга бер хәйлә өйрәтүен үтенде. Шуннан соң карчык ошбу сүзләрне сөйләде:

— Әгәр дә минем нәсыйхәтем белән йөри алсаң, шаять, тутаңны гыйфрит кулыннан алып шәһәрегезгә кайтырсың, ләкин минем бер шартым бар. Шартым шул ки: син тутаңны шәһәрегезгә алып кайткач, мин ошбу урманнан күчеп, сезнең шәһәргә барырмын. Сез шәһәрегездә миңа бер йорт бирерсез, вә һәм үлгәнче гыйбадәт кылып ятарлык мал бирерсез, вә һәм бер-ике хезмәткәр бирерсез. Әгәр дә ошбу шартларны кабул итәрлек булсагыз, мин сезгә бик яхшы хәйлә өйрәтермен. Мин инде ничә еллар бу урманда тордым, адәмнәрне бик сагындым, кайтасым киләдер, инде бу җеннәрдән, сихер гамәлләренән бик туйдым,— диде.

Баһадиршаһ:

— Баш өсте,— диде.— Үзең сораганнардан артыграк итеп кадер итәрбез, гомерең буенча безнең кадерле кунагыбыз булырсың,— диде.

Дәхи әйтте:

— Гаҗәеп, син моңарчы ни өчен адәмнәр арасына кайтмый тордың? — диде.

Карчык әйтте:

— Яшь чагымда дию җибәрмәде. Дию үлгәндә бик картайган идем, кулымнан һичбер эш килер хәлем калмаган иде, адәм арасына кайтып хәер эстәп йөрисем килмәде. Чөнки минем туганнарым һәркайсы үлеп беттеләр, тәрбия кыйлыр кешем юк, мин бу җирдә ничек булса да җеннәремне хезмәт иттереп, көн күрә алам. Адәмнәр арасына кайтсам, ул җеннәр миңа һич хезмәт итмиләр. Шуның өчен бу көнгә кадәр адәм арасына кайтмадым,— диде.

Карчык Бәһадиршаһка бер кылыч, Тимерҗанга бер сөңге бирде дә әйтте:

— Сез, ошбу коралларны кулларыгызга тотып, ошбу юл белән төн ягы тарафына китегез, берничә чакрым баргач, бер күпергә очрарсыз. Ул күперне тиз генә чыгарга тырышыгыз, чөнки сез чыгып җиткәнче ул күпер җимерелә башлар. Мөмкин кадәр җимерелгәнче чыгып калырга тырышыгыз. Ул күперне чыккач, янә барырсыз, бара торгач, сезгә юлда ике башлы бер бик зур елан очрар. Ул елан сезне үтерергә касд[1] кыйлыр. Сез аны тиз ошбу коралларыгыз илә үтерегез. Ләкин бик саклана күрегез, бер сукканда башын өзәрлек булыгыз. Бер башына ике мәртәбә суга күрмәгез. Әгәр дә бер башына ике мәртәбә суксагыз, яңадан терелер дә үзегезне һәлак кыйлыр. Ул еланны үтергәч, янә бераз барырсыз. Бер бик зур таш-таулар арасына килеп чыгарсыз. Шул таулар урталыгында бер бик зур мөхкәм[2] сарай булыр. Синең тутаң шул сарай эчендә булыр. Ул сарай янына барып җиткәнче янә бер зур күпер чыгарсыз, ул күпер дә сез чыгып җиткәнче җимерелер. Сез мөмкин кадәр тизрәк чыгарга тырышыгыз. Ул күпердән чыгып җиткәч тә, күктән ике башлы янә бер зур елан килеп төшәр. Ул елан да сезне үтерергә касд кыйлыр. Ул еланны да ошбу коралларыгыз илә берәр сугып, һәлак кыйлырсыз. Сарай янына барып җитәрсез. Сарай янында бер зур бакча булыр. Ул бакча янында бер зур күл булыр. Сез шул күл янына барып карап торыгыз. Көндез өйлә вакытында шул күл янына берничә аккош очып килеп төшәрләр. Сез шуларны яхшы билгеләп карап торыгыз: ул аккошларның арасында берсенең башы бүрекле булыр, шуны бик билгеләп калыгыз. Чөнки ул кош гыйфритнең үз кызыдыр. Янындагы кошлар иптәш вә хезмәтче кошлардыр. Алар һәркөн, гыйфрит йоклагач, шул күлгә килеп коеналар. Ул кошлар күл буена килеп төшкәч тә адәм кыяфәтенә, ягъни кызлар кыяфәтенә керерләр. Һәркайсы чишенешеп киемнәрен күл янында калдырып, күлгә кереп китәрләр. Алар бер сәгать чамасы шул күлдә уйнашып коенырлар. Син, Бәһадиршаһ, шул арада, үзең күренмичә генә, бүрекле аккошның чишенгән киемнәрен алып үз кулыңда тот. Тимерҗан, син дә, теләсәң, арадан бер кошның киемен ал. Кызлар, коенып туйгач, күлдән чыгып, киенмәкче булырлар. Сез киемнәрен алган кызлар, киемнәрен таба алмыйча, аптырашып йөрерләр. Сез

---

[1] *Касд* — ният.
[2] *Мөхкәм* — нык.

шул арада ул кызларны тотарга тырышыгыз. Алар, киемнәре булмагач, сезгә һичбер зарар кыйла алмаслар. Сез алардан һич курыкмагыз. Ул кызларны сез һич җибәрмәгез, киемнәрен бирмәгез. Алар сезгә бик ялынып багарлар, сез һич аларны кызгана күрмәгез, чөнки, әгәр дә аларны өчәр мәртәбә ант иттермичә җибәрсәгез, алар сезне хәзер һәлак кыйлдырырлар. Сез аларның һәрберсен өчәр мәртәбә ант иттерегез. Беренче: «Мин синеке булдым»,— диеп ант итсеннәр. Икенче: «Мин сиңа һич зарар итмәм, зарар иттермәм»,— дип ант итсеннәр. Өченче: «Син ни кушсаң, мин шуны эшләрмен»,— дип ант итсеннәр. Һәркайсы ошбу рәвешчә ант иткәннән соң, алар гүя сезнең колыгыз хөкемендә булырлар, һәрвакыт тагать кыйлып[1] мөмкин кадәр сезнең өчен хәер хаһ[2] булырлар. Шулай булса да, сез ашыгып җибәрмәгез: «Ошбу җиргә Гөлбикәне вә палас илә бүрек һәм дәстәрханны китер»,— диегез. Шуннан соң гыйфрит кызы юлдаш кызларының берсенә әмер кыйлыр. Шул сәгать Гөлбикәне вә хасиятле нәрсәләрне китерерләр. Алар килгәч тә, паласны җәеп, бишәүләшеп өстенә менеп утырыгыз да паласка үз шәһәрегезгә алып кайтырга боерыгыз. Шул рәвешчә икегез өйләнеп, Гөлбикәне алып кайтырсыз. Кайтып җиткәч, гыйфрит кызы сиңа даими итагатьтә булыр, һич каршы килмәс, адәм кызларыннан артыграк хатынлык хезмәтен итәр. Әгәр дә мәхәббәтегез булмаса, һәр икесен азат кыйлып җибәрерсез. Зинһар, бу эшләрне ошбу атна эчендә башкара күрегез, чөнки бу атна гыйфритнең йоклый торган атнасыдыр. Гыйфрит уяу чагында сез һич Гөлбикәне ала алмассыз,— диде.

Карчык, ошбу сүзләрне сөйләп бетергәч, кылыч илә сөңгене өшкереп бирде дә:

— Инде сезгә вакыт җитте, тизрәк юлга чыгыгыз, Хода хәерле юл бирсен! — диде.

Баһадиршаһ илә Тимерҗан, карчык илә күрешеп-бәхилләшеп, юлга чыктылар. Карчык бер-ике пәрине озатып юл күрсәтергә җибәрде. Берничә чакрым баргач, карчык сөйләгән күпергә килеп җиттеләр. Карчык әйткән рәвешчә ул күпердән тиз генә чыктылар. Чыгып җитәм дигәндә күпер җимерелә башлады. Ничек булса да, күпер тәмам җимерелгәнче сәламәт чыгып җиттеләр. Күпердән чыгып җиткәч тә каршыларына сызгырып, авызларыннан утлар чәчеп, ике башлы бер елан килде. Баһа-

---

[1] *Тагать кыйлу* — буйсыну.
[2] *Хәер хаһ* — теләктәш.

диршаһ кылычы белән бер башына, Тимерҗан соңге илә икенче башына сукты. Шул сәгать елан җан тәслим кыйлды[1]. Икенче күперне дә чыктылар һәм икенче еланны да үтерделәр. Икенче елан бигрәк куркыныч кыяфәтле иде.

Сарай янына килеп чыктылар. Бакча артына барып, күл буена килеп утырдылар. Карчык әйткәнчә, сәгать уникедә күл буена унике аккош очып килеп төште. Килеп төшү белән, һәркайсы бик гүзәл кызлар кыяфәтенә керделәр. Һәрберсе чишенеп, суга кереп киттеләр. Баһадиршаһ бүрекле аккошны билгеләп калды. Тимерҗан аның белән янәшә очып килеп, икесе бер җиргә чишенгән кызны яратты. Ул кыз гыйфрит кызының дусты иде. Башкалары хезмәтче кызлар иделәр. Кызлар суга кергәч тә, Баһадиршаһ бүрекле аккошның киемен, Тимерҗан аның янында чишенгән кызның киемен кулларына алдылар.

Коенып бетергәч, киенешергә чыктылар. Чыккач, ике кыз киемен таба алмады. Бик кайгырышып, кычкырышып елаша башладылар. Шул арада Баһадиршаһ илә Тимерҗан үзләре билгеләгән кызларын барып тоттылар. Кызлар бик ялына башладылар. Киемнәрен алып егетләрнең кулларыннан ычкынмакчы булдылар. Ләкин егетләр һич җибәрмәделәр, һәр икесе ант итәргә куштылар. Ләкин кызлар бик күп заманга кадәр кабул итмичә тыпырчындылар. Ничек булса да, ахырында һәр икесе өчәр мәртәбә ант иттеләр. Баһадиршаһ үз кызына тутасы Гөлбикә илә паласны һәм бүрек илә дәстәрханны китертергә кушты. Гыйфрит кызы хезмәтче кызларының берсенә Гөлбикәне вә палас илә бүрекне һәм дәстәрханны алып килергә кушты. Биш минут эчендә һәркайсын китереп җиткерделәр. Гөлбикәнең һич вакыйгадан хәбәре юк иде. Бакчада энесен күреп, бик гаҗәпкә калды. Һәм, энесе гыйфрит кызын тотканлыгын вә аңа теләгәнчә хөкем кыйлганлыгын күреп шаккатты. Гыйфрит кызы Гөлбикәгә әүвәлдә һич яхшылап илтифат кыйлмыйдыр иде. Хәзер бик тәгъзыйм кыйлып күреште, гүя үз тутасы кебек якын күргәнлеген белгертте.

Гөлбикә Баһадиршаһтан ни вакыйга булганлыгын, ни рәвешчә килгәнлеген сорашмакчы булды. Баһадиршаһ:

— Апа, туктале, күп сорашма, өйгә кайткач сөйләшербез, тизрәк палас эченә кереп бас,— диде.

Паласның уртасына гыйфрит кызы Ләүлияне бастырдылар. Кал-

---

[1] *Җан тәслим кыйлу* — җан бирү.

ганнары, ягъни Баһадиршаһ, Гөлбикә, Тимерҗан вә аның кызы — дүртесе, дүрт почмакка басып, һәркайсы паласның бер почмагын тоттылар.

Баһадиршаһ паласка:

— Тиз әткәй вә әнкәйләребез янына фәлән шәһәргә алып барып, сәламәт җиткез! — диеп әмер кыйлды.

Палас күтәрелеп китте. Ләүлиянең хезмәтче кызлары елашып калдылар. Ләүлия дә, палас күтәрелә башлагач, елап, хезмәтче кызларына әйтте:

— Инде сез миннән бәхил булыгыз, бәлки, шаять, берничә елдан соң мин бирегә киявем белән кайтырмын. Әткәй-әнкәйгә ни вакыйга булганлыгын тәфсыйлән[1] бәян кыйлыгыз, мине гаеп итмәсеннәр,— диде.

Шуннан соң Баһадиршаһ та кычкырды:

— Каенатайга әйтегез: һич зарар касд кыйлмыйча, дуслык белән парлап кунак булып барсыннар. Әгәр дә алар безгә килсәләр, һәр елда без дә бу җиргә килербез,— диде.

Бу сүзләрне ишеткәч, Ләүлиянең дә бик кәефе килде.

Палас, биек күтәрелгәч, Баһадиршаһның аталарының шәһәренә таба алып китте.

Болар палас белән һавадан болытлар арасыннан бара торсыннар, без Баһадиршаһның атасы илә анасының хәлләрен языйк.

Баһадиршаһның атасы вә анасы, угылларын озатканнан соң, бик хафага калдылар. Ахыры һичбер баласыз калдык бугай, дәю бик хафаландылар, күп еладылар. Ашаулары-эчүләре һәм йокылары качты. Һәр икесе бик ябыктылар. «Үзебез картайдык, дөньяда һичбер варисыбыз калмый»,— диеп, һаман икәүләшеп бакчага чыгып моңаешып утыра башладылар. Кызының һәм улының бакчада йөргәннәрен уйлап, сагынышып утырыр иделәр. Кызлары да, угыллары да һаман төшләренә керер иде. Бәгъзы[2] көнне бик шат кыяфәттә керер иделәр. Бер ай чамасы узды, һаман улларыннан да, кызларыннан да һич хәбәр юк. Беркөнне падишаһ үзе кызы илә угылын икесен бер җирдә бик шатланышып утырганнарын күрде. Хатыны бакчаларына һавадан биш аккош очып төшкәнен күрде. Шул көнне иртә белән кофе эчәргә бакчага чыгып утырдылар. Бик шатланышып, бер-берсенә төшләрен сөйләделәр. Ша-

---

[1] *Тәфсыйлән* — җентекләп.

[2] *Бәгъзы* — кайбер.

ять, сәламәт кайтмаслар микән дәю, төшләрен хәерлегә юрашкан булдылар.

Берзаман ак болытлар арасыннан бер карамчык күрделәр. Бу ни икән дәю, бик гаҗәпсенеп күп заман карап тордылар. Карамчык һаман зурая иде. Берәр сәгатьтән соң карамчык боларның бакчаларына якынлашты. Бу ни икән диеп гаҗәпсенеп торганда, бер палас илә биш кеше килеп төште. Карасалар: кызлары Гөлбикә һәм уллары Баһадиршаһ, Тимерҗан һәм янә башка ике бик гүзәл кыз.

Баһадиршаһ бер кулына Гөлбикәне җитәкләп, икенче кулына Ләүлияне җитәкләп, атасы вә анасы каршына барды. Һәркайсы әүвәл падишаһ илә, аннан соң хатыны илә, кулларын үбеп, кочаклашып күрештеләр. Бакчада шундый бер шатлык мәҗлесе булды ки, һич сөйләп вә язып бетермәк мөмкин түгелдер.

Иртәгесен падишаһ җәмигы[1] вәзирләрен вә шәһәрнең могтәбәр[2] кешеләрен чакырып, вә голәмасын[3] чакырып, зур мәҗлес ясады. Һәм шул мәҗлестә Баһадиршаһ илә Ләүлиягә вә һәм Тимерҗан илә үзенең алып кайткан кызына никах укытты. Шуннан соң һәркайсы шатлык илә тереклек кыйла башладылар. Берничә көннән соң, зур туй кыйлып, Гөлбикәне вәзирнең угылына кияүгә бирделәр.

Берәр айдан соң Баһадиршаһларның урманда күрешкән карчыклары килде. Падишаһ аны да бик кунак итеп, үзенә махсус йорт вә хезмәтчеләр бирде.

Алты айдан соң гыйфрит, кызын күрергә килмәкче булып, илчелеккә бер дию юллады. Ләкин падишаһ ул диюнең йөзен күрәсе килмәде:

— Күрәсе килсә, кызын кунак итеп җибәрербез, берәр ай торып кайтыр, үзенең килүен мәгъкуль күрмимен,— диде.

Шул дию илә Ләүлиягә бер айга рөхсәт биреп җибәрделәр. Ләүлия бу җиргә һәм киявенә бик ияләнгән иде, бик елап, һәркайсы илә күрешеп китте. Бер айдан соң, атасының ризалыгы берлә янә килде.

Шуннан соң һәркайсы гомерләре буенча бик рәхәт тереклек кыйлдылар. Падишаһ үлгәннән соң, тәхеткә Баһадиршаһ утырды. Баһадиршаһ, падишаһ булгач, бик рәхәт гомер сөрде.

Инде хикәя тәмам булды. Вәссәлам..

---

[1] *Җәмигы* — барлык.
[2] *Могтәбәр* — хөрмәтле.
[3] *Голәма* — галимнәр.

40. Тимеркендек

Бар икән бер патша, аның бар икән, ди, өч улы. Бер улын мал көтәргә чыгарган. Ул, малларын көтә алмыйча, йоклап калган, ди. Ул йоклаганда, күп маллары югалган. Өйгә кайтып, атасына әйтте, ди:

— И әти, мал көткәндә йоклап калганмын, белмәдем: ни-нәрсә безнең малларыбызны алып киткәндер.

Атасы малларын көтәргә икенче улын җибәрде, ди. Уртанчы улы тагын йоклап калды, тагын да күп кенә маллары югалды. Уртанчы улы да әтисе янына килеп:

— И әти, мин дә йоклап калганмын, күп малыбыз югалды, кая киткәннәрен белмим,— диде.

Өченче көндә малларын көтәргә атасы үзе китте, ди. Кече улы Тимеркендек әйтте:

— Мин дә барамын,— диде.

Атасы:

— Син монда кал, син әле кечкенәсең,— диде.

Шулай дисә дә, кече улы калмады, бергә барды. Төнлә атасы да йоклап китте. Кече улы, йокламыйча, карап ятты. Төн уртасында, караңгы төндә, күрә бу: өч йилбегән[1] килә. Йилбегәннәрнең авызларыннан ялкыннары чыгып тора. Бу йилбегәннәр боларның малларын куып алып китәләр.

Иртә белән аталары йокысыннан торып караса: маллары юк. Атасы әйтте:

— Мин дә йоклап калганмын икән, малларның кая киткәнен белмим,— ди.

Улы әйтте:

— Ә мин беләм, аларны төн уртасында өч йилбегән килеп алып китте,— ди.

Өйгә кайттылар. Атасы улларын янына чакырып алып әйтте:

— Әй улларым, безнең югалган малларны эзләргә кирәк,— диде.

Малларын эзләргә ике улын чыгарып җибәрде. Кече улы әйтте:

— Әти, миңа да рөхсәт бир, кече булсам да, абзыйларым белән бергә барыйм, аш пешерергә булса да ярармын шунда,— ди.

Өч улы да малларын эзләргә киттеләр. Бер җиргә килеп кунды-

---

[1] *Йилбегән* — диюгә охшаган мифик зат.

лар. Ул җирдә бер җиз күпер бар икән. Абыйлары ике үрдәк атып алдылар.

Кече малай әйтте:

— Сез ятып йоклагыз, мин бу үрдәкләрне йолкып пешерермен,— ди.

Болар йоклап киттеләр, ә кече улы үрдәкне йолыкты. Аш пешерергә дип су алырга төште. Күпер астына төшүе булды, күпер өстеннән бик күп мал үтеп китте, ди. Маллар үтеп китү белән, алар артыннан өч башлы бер йилбегән күпергә килеп җитте. Йилбегәннең аты күпергә кермәде. Йилбегән, атыннан төшеп, атын кыйный башлады:

Атым, син ник бармыйсың?
Тимеркендек тумаган,
Туса да, монда килмәгән.

Егет күпер астыннан чыгып әйтте моңа:

Ничек атың курыкмасын?!
Тимеркендек туган да,
Каршыңа килеп торган да.
Ук атышмак кирәкме,
Сиңа көрәш кирәкме?

— Йилбегән әйтте:

— Өч мәртәбә көрәшергә кирәк, ук — атаң бавырына кадалсын,— ди.

Тотындылар алышырга, көрәшергә. Көрәштеләр, көрәштеләр дә, ди, болар, теге егет йилбегәнне күтәреп бәрде, ди. Өч башын кисеп, күпер янына салып куйды, ди, бу. Шуннан соң абыйлары янына кайтып, аш пешерде.

Абыйларын уятты:

— Торыгыз, аш пеште,— диде.

Абыйлары торып, юынып, ашадылар-эчтеләр, ди. Энеләре атларын алып килеп, иярләп менеп киттеләр. Әлеге күпергә килеп җиттеләр. Күпер аркылы чыгып, йилбегәннең башлары янына килеп җиттеләр. Абыйлары:

— Бу нәрсәнең башы? — дип сорыйлар тегеннән.

Энеләре бер сүз дә дәшмәде.

Яңадан киттеләр болар юл белән. Барып, барып, бер көмеш күпер янына барып җиттеләр. Күпер янына килеп җитеп, кунарга туктадылар. Абыйлары янә үрдәк атарга дип киттеләр. Шул арада болар ике үрдәк атып алып килделәр, ди. Энеләре әйтә боларга:

— Сез ятып йоклагыз, мин бу ике үрдәкнең йонын йолкып, аш пешерермен, — ди.

Абыйлары йокларга яттылар. Энеләре үрдәкне йолкып, аш пешерергә дип су алырга төшеп китте. Бу күпер астына барып керү белән, күпер өстеннән тагын бик күп мал үтте. Маллар күпердән үтеп бетү белән, алар артыннан алты башлы йилбегән күпергә килеп җитте, ди. Йилбегәннең аты күпергә кермәде. Йилбегән, атыннан төшеп, атын бик каты кыйнады:

Атым, син ник бармыйсың?
Тимеркендек тумаган,
Туса да, монда килмәгән.

Егет күпернең астыннан чыгып:

Ничек атың курыкмасын?!
Тимеркендек туган да,
Каршыңа килеп торган да.
Ук атышмак кирәкме,
Сиңа көрәш кирәкме?

Йилбегән әйтте:

— Өч мәртәбә көрәшергә кирәк, ук атыш кирәкми, угың бавырыңа, йөрәгеңә кадалсын, ди.

Көрәштеләр, ди, болар. Көрәшә торгач, Тимеркендек алты башлы йилбегәнне алып бәрде. Алты башын чабып өзеп, күпергә салып куйды, ди. Абыйлары янына кайтып, казанга су салып, үрдәкләрне пешерде, ди.

— Аш пеште, аш ашарга торыгыз, — дип, абыйларын уятты.

Абыйлары торып, юынып, ашап-эчтеләр. Энеләре атларын алып килеп, иярләп, яңадан юлга чыгып киттеләр. Баягы көмеш күпергә җиттеләр. Йилбегәннең башларын күреп:

— Бу нинди башлар, моны кем үтергән? — дип сорадылар, ди.

Энеләре бер сүз дә дәшмәде.

Киттеләр болар янә юл белән, барып, барып, бер алтын күпергә барып җиттеләр. Шул күпер янында кунып китәргә дип туктадылар. Ике абыйсы янә ике үрдәк атып алып килде. Алар йокларга яттылар, энеләре үрдәкне йолкып аш пешерергә дип су алырга төште, ди. Бу тагын күпер астына төште. Күпер өстеннән янә бик күп мал узды. Бу боларның узганын күпер астыннан карап ятты. Малларның күпер өстеннән үтеп кенә бетүләре булды, болар артыннан унике башлы йилбегән күпергә килеп җитте. Унике башлы йилбегәннең аты да күпергә кермәде, ди. Йилбегән, атыннан төшеп, атын бик каты кыйнады:

Атым, син ник бармыйсың?
Тимеркендек тумаган,
Туса да, монда килмәгән.

Егет, күпер астыннан чыгып, йилбегәнгә әйтте, ди:

Ничек атың курыкмасын?!
Тимеркендек туган да,
Каршыңа килеп торган да.
Ук атышу кирәкме,
Сиңа көрәш кирәкме?

Йилбегән әйтте:

— Өч мәртәбә көрәшергә кирәк. Угың бавырыңа, йөрәгеңә кадалсын,— ди.

Көрәштеләр: Тимеркендек унике башлы йилбегәнне күтәреп алып бәрде, унике башын чабып өзеп, башларын күпергә өеп куйды, ди. Абыйлары янына кайтып, казанга су салып, үрдәкләрне пешерде, ди.

Шуннан соң абыйларын уятты, ди, бу:

— Аш пеште, аш ашарга торыгыз,— дип.

Абыйлары торып, юынып, ашадылар-эчтеләр, ди. Энеләре атларын алып килеп иярләде дә, болар яңадан юлга чыгып киттеләр, ди.Алтын күпергә җитеп, күпер өстенә керү белән, болар йилбегән башларын күреп:

— Бу ни-нәрсә, моны кем үтерде икән? — дип сорадылар, ди.

Энеләре бер сүз дә дәшмәде.

Киттеләр болар юл белән. Бара, бара торгач, барып җиттеләр, ди, болар бер җиз сарайга. Энеләре әйтте:

— Абыйларым, сез шушында торып торыгыз, мин бу сарайга кереп карыйм,— ди.

Атыннан төшеп, сарайның ишеген эзли, ди, бу. Сарай ишеген таба алмады, тик стенада өч кыл күрде, ди, бу. Шул өч кылны тартып җибәрүе дә булды, ди, өч ишек ачылып та китте, ди. Сарай эченә керде. Сарай эчендә йилбегәннең хатыны бишектәге өч башлы йилбегән малаен тирбәтеп утыра икән, ди. Тимеркендек йилбегән баласын аягыннан тотып стенага сукты, ди. Шуннан соң олы абыйсын чакырды.

— Бу синең хатының булыр, син монда кал,— диде.

Кече абыйсы белән Тимеркендек китте. Бара, бара, болар бер көмеш сарайга барып җиттеләр. Тимеркендек атыннан төшеп, теге сарай янына барып, сарайның ишеген эзләде, таба алмады. Шуннан соң стенада алты кыл күреп, шул алты кылны тартуы булды, алты ишек берьюлы

ачылып китте, ди. Сарай эченә керсә, бер хатын бишектәге алты башлы йилбегән баласын тирбәтеп утыра икән, ди. Бу баланы да аягыннан тотып стенага сукты да абыйсын чакырып кертте.

— Менә син монда кал, бу синеӊ хатыныӊ булыр,— диде. Бу агасын да хатын янында калдырып китте.

Үзе янә юл белән китте. Бара, бара, барып җитте, ди, бу бер алтын сарайга. Сарай янына барып ишеген эзләп карады, ди, ишек юк. Шуннан соӊ стенада унике кыл күреп, шуларны тарткан иде, ди, бу, унике ишек берьюлы ачылып китте, ди. Тимеркендек сарай эченә кереп караса, анда бер хатын бишектәге унике башлы баланы тирбәтеп утыра икән, ди. Янә бу унике башлы баланы аягыннан тотып стенага сукты. Шуннан соӊ теге хатынга әйтте:

— Син минем хатыным булырсыӊ,— дип.

Бу хатынны атка атландырып, икәүләп малларын эзләргә киттеләр, ди болар. Малларын таптылар. Куалап алып кайтып киттеләр. Уртанчы агалары янына кайтып җиттеләр.

— Абый, чык әле, малларны алып кайттык бит без,— дип, Тимеркендек абыйсын чакырып чыгарды.

Абыйсы хатынын алып чыгып, атка атландылар да дүртәүләшеп малларны куып алып кайтып киттеләр. Берничә вакыттан соӊ олы агалары янына кайтып җиттеләр.

— Абый, чык, без малларыбызны алып кайттык,— дип, олы абыйларын да чакырып чыгардылар.

Инде болар алтау булып, малларын куып алып кайтып киттеләр. Юлда барганда бер җиргә туктап кундылар.

Тимеркендек әйтте:

— Әниемнән туганнан бирле йоклаганым юк, минем бик каты йокым килде. Мин йоклап алыйм әле,— дип.

Абыйлары:

— Йокла,— диделәр.

Тимеркендек әйтте:

— Алай-болай мине уята алмасагыз, көтеп тормагыз, хатынымны янымда калдырып китегез,— диде.

Тимеркендек йокларга ятты. Абыйларына бер уй керде: «Әтиебез патшалыгын Тимеркендеккә бирер, малларны бу тапты бит»,— дип уйладылар болар.

Берсе әйтте:

— Моны без үтерик,— диде.

Икенчесе:

— Юк, үтермик, аягын тубыгыннан кисеп, аяксыз итеп калдырыйк, — диде.

Тимеркендекнең аягын тубыгыннан кистеләр, ул уяна алмый ятып калды. Тимеркендекнең аякларын үзләренең ияр сумкаларына салып, хатынын үзләре белән алып кайтып киттеләр.

Өйгә кайтып җитү белән этиләренә:

— Энебез үлде, менә аякларын алып кайттык,— диделәр.

Тимеркендекнең хатынын кол итеп көтүче итеп куйдылар.

Тимеркендек уянды, аты да юк, хатыны да юк, ике аягы да юк. Елады Тимеркендек, торды, киселгән аягы белән йөреп китте. Бара, бара бер сукырга очрады бу:

— Йә, сукыр дус, азыгың бармы, минем ашыйсым килә,— диде.

Сукыр әйтте:

— Булган азыгымны сиңа бирсәм, үзем соңыннан ни ашармын? — диде.

Егет әйтте:

— Хәзергә ашыйк, синеке беткәннән соң бер рәте чыгар,— диде.

Сукыр:

— Ярый,— диде.

Булган азыкларын пешереп ашап, юл белән киттеләр болар. Бара, бара бер кулсыз кешегә очрадылар.

— Йә, кулсыз, азыгың бармы, булса ашыйк,— диделәр.

Булган азыкларын ашадылар да бу өч гарип юл белән киттеләр, ди. Аксак кулсызга менде. Болар бара-бара барып җиттеләр бер урманга. Урманда болан, кондыз, төлке, бүре, киек үтерделәр. Шул җирдә өй салып, амбар төзеп, тора башладылар, ди, болар.

Боларның малын убырлы карчык урлый башлаган, ди. Тимеркендек әлеге ике гарипне ауга җибәрде, ди. Ул үзе өйдә калып, бер тимер ыргак ясады. Теге убырлы карчык, мал урларга килеп, өйгә керде, ди. Ул килеп керү белән, аксак ыргакны карчыкның авызына эләктереп, аны ишеккә бәйләп куйды, ди, чылбыр белән.

Гарипләр аудан кайту белән, аларның табышларын өйгә кертеп куйдылар, ди. Тимеркендек ашатып-эчертеп туендырды. Шуннан соң теге убырлы карчыкка башта сукырны йоттырдылар. Аксак камчы белән карчыкны бик каты кыйнады, ди. Шуннан соң убырлы карчык сукырны

кире косып чыгарды, ди, теге күзле булган, ди. Аннан соң кулсызны йоттырдылар, ди. Аксак теге убырлы карчыкны янә бик каты кыйнады, ди. Убырлы карчык кулсызны да кире косып җибәргән иде, ди, кулсыз куллы булып чыкты, ди. Аксак әйтте:

— Инде мине йоттырып карагыз,— диде.

Аксакны да йотып җибәрде, ди, убырлы карчык. Теге ике иптәше кыйный башладылар, ди, карчыкны. Кыйнадылар, кыйнадылар, ди, убырлы карчык аксакны бер дә кире чыгармый, ди. Үтергәнче кыйнадылар. Убырлы карчыкны үтереп, корсагын ярып карадылар, аксакны таба алмадылар. Сөякләрен ярып эзләделәр, бармак җелекләрен ярып карадылар, таба алмадылар. Бик каты эзли торгач, Тимеркендекне убырлы карчыкның чәнчә бармагы эченнән эзләп таптылар. Теге шул бармак эчендә җәя угы юнып утыра икән, ди.

Тимеркендек әйтте:

— Нигә бик тиз таптыгыз, әле мин тагын берничә ук юнган булыр идем,— диде. Шуннан соң: — Әйдәгез, малларны бүлешик,— ди дусларына.

Булган малларны бүлештеләр. Шуннан соң сукыр күзле булып, кулсыз куллы булып, Тимеркендек аяклы булып, болар өчесе дә өйләренә кайтып киттеләр, ди.

Тимеркендек, әтисе шәһәренә җитеп, үзенең бертуган апасына керде, ди.

— Бар, апа, әтигә барып: «Тимеркендек улың кайтты»,— дип әйт,— ди.

Апасы барып әйтте:

— Әтием, улың Тимеркендек кайткан,— дип.

Атасы әйтте:

— Карап карыйк, алып кил,— ди.

Тимеркендекне атасы янына алып барды, күрештеләр, ди, болар.

Тимеркендек әйтә:

— Минем хатыным бар иде бит, ди, ул кайда? — ди.

Атасы әйтте:

— Мин синең хатыныңны белмим, улым, агаларың бер кол хатынны алып кайтканнар иде, ул хәзер ат көтә,— диде.

Көтүче хатынны алып килделәр. Тимеркендек хатыны белән елаша-елаша күреште. Үзенең әтисенә әйтте:

— Әти, халыкны җыйдыр, агаларым белән без уенга чыгабыз,— диде.

Әтисе шәһәр халкын җыйдырды, ди. Кырга уенга чыктылар. Тимеркендек абыйларына берәр янук[1] бирде. Шуннан соң әйтте:

— Миңа яхшылык белән йөргән булсагыз, аткан угым күземне тишеп чыксын, усал уй белән йөрсәгез, түбәгездән кереп, аягыгыздан тишеп чыксын,— диде. Бер савытка бер көмеш акча салды да әйтте: — Иң әлек мин атып җибәрим, әгәр дә мин усал ният белән йөрсәм, түбәмнән керсен, яхшылык белән йөрсәм, шушы акчаны тишеп чыксын,— диде.

Тимеркендек угын атып җибәрде, бер көн буе көткәннән соң, акчаның уртасына килеп төште. Олы абыйсына әйтте:

— Инде син ат,— диде.

Ул атып җибәрде, ук аның түбәсенә килеп төште, үлде олы абыйсы. Кече агасы атып җибәрде, аның угы да түбәсенә килеп төште, аягыннан чыкты. Ике абыйсы да үлде, ди, моның.

Тимеркендек абыйларының хатыннарын азат итте. Үзе патша булды.

41. Мичтә туган Камыр батыр

Әүвәлге заманда минем кебек улсыз-кызсыз бер кеше булган. Аларга бер саилче[2] кергән дә сораган:

— Улыгыз, кызыгыз юкмы? — дигән.

— Юк шул, дигәннәр.

— Алай булса, ипигә камыр изегез, өшкереп бирим әле,— дигән.

Камыр изгәннәр. Теге саилче шуннан әйткән:

— Йодрык кебек камыр бир әле, әби,— дигән.

Әби бирә моңарга камырны. Бу өшкерә-өшкерә дә әбигә кире бирә:

— Менә шушыны ипи уртасына тыгып калдыр. Ипи пешкәндә малай тавышы ишеткәч, мичтән алырсың,— ди.

Бервакыт әби ипине мичкә куйган. Тыңлый торгач, ул мичтәге ипиләр арасыннан малай тавышы ишеткән. Шуннан соң мичтән малайны алган. Карт белән карчык гаҗәпкә калганнар.

Бу малай көннән-көн үсә. Ел үсәсен ай үсә. Бик тә куәтле була. Ул малайлар белән уйный, аларга солдат уены өйрәтә, үзе командир була.

---

[1] *Янук* — җәя.
[2] *Саилче* — хәерче, теләнче.

Бер оста малайдан арба ясата. Начальник булып, үзен тарттырып йөртә. Малай шулхәтле таза була: малайлар арасында сугышлар була бит, шундый чакта кайсы малайның аягын сындыра, кайсының кулын борып ала. Моның бабасына: «Синең малай шулай, синең малай болай»,— дип, жалу[1] белән киләләр. Карт аптыраган инде.

Беркөнне ул карчыгы белән киңәш итә:

— Кое казытыйк та шунда төшереп үтерик. Бу безнең башка бәла инде, ди.

Киңәш итәләр дә, шул малайның үзенә кое казырга кушалар. Малай кое казырга төшкән чагында, картлар күршеләренә әйтеп куялар: «Теге коега төшкәч, өстенә таш төшерегез»,— дип. Бәладән котылырга телиләр инде шулай.

Шул арада малай куәт белән тиз генә коены казып:

— Бабай, коены казып бетердем,— дип, өйгә килеп керә. Белми дә калалар.

Карт чыгып карый да:

— Улым,— ди,— төшеп тагын бераз казыйсы иде, саерак булган,— ди.

— Ярар, бабай,— ди, коега төшеп китә.

Теге төшеп киткәч, күршеләрне дәшеп чыгып, малайның өстенә зур-зур ташлар ташлыйлар. Малай, шул ташларны тотып ала да, кое янындагы бөтен кешеләрне кырып бетерә. Бабай белән әби генә исән кала. Шуннан чыга бу коедан. Бабасына үпкәли бу:

— Сез мине үтерергә йөрисез икән,— ди. Ризалык сорыйдыр бу: — Миңа,— ди,— кайдан булса да тимер табып, унике потлы чукмар ясат, мин чыгып китәм, бабай,— ди.

Бабасы шул чукмарны ясаткач, егет бәхилләшеп чыгып китә:

— Миннән куркасыз икән, җаныгыз тынсын, юлымда булыйм,— ди.

Бара, бара, аңарга бер кеше очрый юлда. Бу кеше сорый моңардан:

— Син кая барасың, син кем? — ди.

— Мин Камыр батыр булам,— ди.

Теге кеше әйтә:

— Мине дә ияртсәнә, мин Имән батыр булам,— ди.

— Ярый,— ди, аны ияртеп китә.

Алар икәү китәләр. Бара торгач, янә бер кеше очрый. Ул да сораша:

---

[1] *Жалу* (*урысча: жалоба*) — зар, шикаять.

— Кая барасыз, мине дә алып барсагыз иде. Мин Тау батыры булам,— ди.

Болар шуннан өчәү киттеләр.

Барып керделәр болар бер кара урманга. Шунда Тау батыры тибеп таш чыгарды да, өй ясадылар. Имән батыр имән йолкып өй өстенә өя. Болар мич чыгаралар, казан куялар да шунда тормакчы булалар. Камыр батыр белән Тау батыры Имән батырга әйтәләр:

— Имән батыр, син өйдә калып тор, ашарга хәзерләп куй.

Без нәрсә очраса шуны нәфкалек[1] алып кайтырбыз,— диләр.

Тегеләр чыгып киткәч, Имән батыр ашны пешерә дә җырлап утыра. Ул да түгел, ишектән дөп-дөп иткән тавыш килә.

— Улым, ишегең ач,— ди.

Имән батыр ишеген ачкан иде, үзе бер карыш, сакалы биш карышлы җанвар пошкырып килеп керде.

— Улым,— ди,— күтәреп утырт сәкегә,— ди.

Имән батыр аны күтәреп утырта. Теге бик тә авыр нәрсә икән. Шуннан теге әйтә:

— Улым, казаныңда нәрсә? — ди.

— Аш пешердем иптәшләремә,— ди.

— Улым, ашыңны ашат,— ди.

Ашны ашап бетерә. Ашап бетергәч әйтә:

— Улым, көрәшик инде,— ди.

Көрәшкәч, теге Үзе бер карыш, сакалы биш карыш Имән батырны күтәреп бәрә дә, мич астына кыстырып чыгып китә.

Имән батыр бервакыт, исенә килеп хәл җыйгач, урынына чыгып утыра. Ул да түгел, иптәшләре кайтып керә.

— Ник аш пешермәдең? — ди тегеләр.

— Авырыйм,— ди.

— Алай булса, үзебез пешерик инде,— диләр. Пешерәләр дә ашыйлар.

Икенче көнне ризык эзләргә Имән батыр белән Камыр батыр китә. Бу юлы аш пешерергә Тау батыры кала. Бу ашны пешергәч, янә дә дөп-дөп итеп Үзе бер карыш, сакалы биш карыш килә:

— Улым, ишегең ач,— ди.

Бу бит белми, Имән батыр бер сүз дә әйтмәде. Өйгә кергәч теге әйтә:

---

[1] *Нәфка* (*гарәпчә: нәфәка*) — яшәү өчен кирәк булган мал (азык).

— Улым, сәкегә утырт,— ди. Сәкегә утырта.

— Казаныңда нәрсә бар, улым? — ди.

— Аш,— ди,— иптәшләргә хәзерләдем,— ди.

Ашны ашап бетергәч, баягы кебек көрәшергә сорый. Тау батыры белән көрәшә дә, аны да мич астына кыстырып чыгып китә.

Харап инде Тау батырының эше. Бераз хәл җыйгач, бу да чыга, сәкегә йөзтүбән ята.

Ике батыр тагын кичен кайталар. Ашарга азык та алып кайталар. Кайтсалар, казандагы аштан җилләр исә. Ашарга бернәрсә дә юк.

— Ник бернәрсә дә пешермәдең? — ди Камыр батыр.

— Авырыйм,— ди теге.

Камыр батыр: «Бу нинди авыру икән,— дип тә уйлый,— ялкау түгелме икән»—, дип тә уйлый.

Шуннан өченче көнне Камыр батыр әйтте:

— Сездән булмады инде, үзем калыйм,— диде.

Бу да, ашны пешереп куя да, сәкегә менеп җырлап ята. Җырлап ятса, әлеге дөпелдәгән тавыш. Бу да сискәнеп китә. Тегеләр бит моңарга әйтмәделәр. Әйтсәләр бит кечелеккә калалар.

— Улым, ишегеңне ач,— ди моңарга теге җанвар.

— Безгә килгән кунак үзе ачар,— ди Камыр батыр, җиңәсен беләдер инде.

Теге азапланып керә дә:

— Сәкегә күтәреп утырт,— ди.

— Безгә килгән кунак үзе утыра,— ди Камыр батыр.

Теге азапланып үзе менеп утыра.

— Казаныңда нәрсә бар? — ди.

— Аш,— ди.

— Улым, миңа ашат син аны,— ди.

— Безгә килгән кунак сорап ашамый,— ди Камыр батыр, ашны да бирми.

Шуннан соң теге әйтә:

— Әйдә, улым, көрәшик,— ди.

Көрәшә башлагач, Камыр батыр тегенең сакалыннан чорнап тота да Үзе бер карыш, сакалы биш карышны ташка бәрә. Теге бөтенләй канга бата. Аннары өйдән өстерәп чыга да, имәнне бөгеп, тегене сакалыннан шул имәнгә асып куя. Тегенең башыннан кан тама, тама тора.

Берзаман иптәшләре кайтып керәләр. Казанны карасалар, аш та әзер, бар да әзер.

Камыр батыр иптәшләренә әйтә:

— Сезне,— ди,— Үзе бер карыш, сакалы биш карыш харап итеп яткан икән, мин аны сәер иттем[1],— ди.

Тегеләрнең исләре-акыллары китә.

— Әйдәгез, күрсәтим әле. Имәнне бөгеп, сакалыннан асып куйдым мин аны,— ди.

Чыксалар, теге нәрсә имәнне йолкып алып өстерәп киткән. Сабан сукалаган кебек итеп, җирне ертып барган. Артыннан баралар болар. Теге бер ташландык коега төшкән, имәне кое өстенә эләгеп калган. Юкә кисәләр дә өч батыр бергәләп җеп ишәләр. Шуннан соң, унике потлы чукмарны биленә бәйлиләр дә, Камыр батырны коега төшерәләр. Төшсә, коеның төбендә бер тотка тора, ишек тоткасы кебек. Тоткага ябыша да тартып ача бу.

Бер яп-якты дөнья. Бер ызбаның янына бара Камыр батыр, тәрәзәдән карый. Караса, бер карчык төкерә-төкерә камыр баса.

— Әби, ник болай итәсең, су юкмыни сездә? — ди Камыр батыр.

— Суыбыз бар да, улым, җиде башлы җылан чолгап алган, якын барып булмый. Шуның аркасында менә шулай, төкерек белән камыр басабыз,— ди.

— Әби, бир әле чиләгеңне, үзем су алып кайтып бирәм, болай эшләмә,— ди.

Камыр батыр чиләк алып китә. Бу килгәнне күргәч, җылан моны суыра башлады. Бу тезенә хәтле җиргә чумды. Шуннан тиз генә чыкты да, тимер чукмар белән сыптырып, тегенең җиде башын да өзде. Бөтен су буе кып-кызыл кан булды. Чүмәлә кебек турап өйде.

Шуннан чиләккә су алды да әбигә алып кайтып бирде. Шулай иткәннән соң әби:

— Бер батыр килгән, җиде башлы җыланны турап ташлаган. Суга барыгыз,— дип, урамга чыгып акырды.

Шуннан бөтен кеше суга агылды.

Батыр янына халык җыелды.

— Бу нихәл тамаша,— дип, исләре китеп карап торалар.

Камыр батыр әйтте:

---

[1] *Сәер иту* — тамаша итү.

— Монда Үзе бер карыш, сакалы биш карыш кайда тора? — диде.

Бер карт кеше моңа әйбәтләп тегенең кайда торганын сөйләп биргәч:

— Улым, үзеңне ашамасын, саклан, бик куәтле ул. Көн дә бер матур кыз урлап кайта, көн дә бер кеше ашый,— диде.

Шуннан бу сорашып бара, бара, тегенең яткан урынын таба. Үзенә бер кырда кечкенә генә йортка кереп йоклаган теге. Ишеген ачты да Камыр батыр, тегенең артына типте. Теге чәчрәп сикереп торды. Ул әйтә:

— Әй, улым, әле үзем барып ашамакчы идем, ярый, үзең килгәнсең икән,— ди.

— Ашый алмассың, сөягем каты минем,— ди Камыр батыр.

Тотындылар болар сугышырга. Камыр батыр, унике потлы чукмар белән сугып, тегенең миләрен агызып бетерде, сакалыннан тотып ташка да бәреп карады. Шулай да теге үлми.

Шул чагында бер матур гына кыз кычкыра:

— Син аны үтерә алмассың, аның җаны монда, минем янга кил,— ди.

Камыр батыр йөгереп барды кыз янына. Кыз әйтә:

— Читлектә яшел кош бар, шул аның җаны,— ди.— Аны үтермәсәң, ул үлмәс,— ди.

Камыр батыр барадыр да шул кошны үтерәдер, теге кыймылдый да алмый.

Ярар. Бу кыз — патша кызы була. Ул әйтә:

— Без,— ди,— өч патшаның өч кызы идек. Ата-анабызның бердәнбер балалары идек. Безне бакчада йөргәндә шушы нәрсә урлап китте,— ди.

Камыр батыр, кызларның өчесен дә алды да, дөньяга чыгар өчен кое төбенә барды.

— Җепне салындырыгыз,— дип, иптәшләренә кычкырды.

Җепне җибәрделәр өстән. Камыр батыр җепкә бер патша кызын бәйләп җибәрә. Тегене тартып алалар. Янә кычкыра:

— Җепне салындыр,— дип.

Салындыралар. Янә бәйләп җибәрә бер кызны. Янә шулай кычкыра, янә салындыралар. Янә кызны бәйләп җибәрә. Кызлар берсеннән-берсе матур булалар.

Янә кычкыра. Җепне салындыргач, бу юлы үзен бәйли, үзе менә. Чыгып җиткәндә генә: «Кызларның яхшысын безгә бирмәс»,— дип, җепне иптәшләре кисеп җибәрәләр. Камыр батыр яңадан кое төбенә килеп төшә.

Имән батыр белән Тау батыры кызларны өйгә алып киттеләр, бу кое төбендә калды.

Нишләсен, Камыр батыр уйга кала. Ул теге җыланны үтергән җиргә кире китте. Бик калын бер агач төбенә барып утырды. Шул чагында агач башыннан бер кош баласы кычкыра:

— Син нинди кеше, безнең әни кеше ашый,— ди.

Бу егет әйтә:

— Җиде башлы җыланны үтергән Камыр батыр булам мин,— ди.

— Алай булса, безнең янга үрмәләп мен. Без сине әни кайтканчы ничек тә яшереп торырбыз,— ди.

Камыр батыр менде, кош балалары арасына керде. Менә бервакыт кош килеп кунды, балаларына азык алып кайтты. Кош балалары әйтә:

— Әни, тыңласаң бер сүз әйтер идек,— ди.

— Тыңлыйм, ни гозерегез бар? — ди.

— Әни, сиңа гозеребез шул: җиде башлы җылан безне йон чыкканчы ашап бетерәдер иде. Менә шуны үтергән батыр хәзер безнең оябыз төбендә. Шуңарга тимисеңме? — ди.

Камыр батыр оядан чыкты да кырыйга басты. Сөйләшәләр инде кош белән. Кош әйтә:

— Сиңа бик рәхмәт,— ди.— Ни телисең, хәлемнән килгәнен барысын да эшлим,— ди.

— Теге дөньяга чыгар идем,— ди, Камыр батыр әйтә,— теге дөньяга чыкканда мине кисеп калдырдылар, ди.

— Әйдә, егет,— ди,— чыгарам,— ди кош.

Кое төбенә бардылар. Камыр батыр кошның ике канат төбенә утырды, чукмарын кулына алды. Шуннан кош аны өскә чыгарды да саубуллашып кире төшеп китте.

Инде Камыр батыр үзләре ясаган ызбага кайта. Килеп керде. Тегеләр, икесенә ике кызны кочаклап йоклаганнар. Кызларның берсе идән себереп ята. Бу зур кыз егет кайткач куанды:

— Сине күрергә дә насыйп икән,— ди.

Шуннан Камыр батыр тегеләрне йолкып уята:

— Тыныч йокладыгызмы, егетләр? — ди.

Тегеләр ни дә әйтә алмыйлар, кызарыштылар.

Бу әйтә:

— Мине чыга алмас дип белдегез идемени? — ди.

Тегеләр, сыннарын катырып, ни дә әйтә алмыйча торалар.

Камыр батыр әүвәл Имән батырны алып чыга тышка. Аны һавага чөерә. Уникe потлы чукмарын тота да, теге шуңарга бәрелеп көлгә әйләнә. Аннары Тау батырын алып чыгып чөерә. Анысы да, чукмарга бәрелеп, көл була. Аннары кызларны ияртә дә юлга чыга.

Барып җитәләр идән себерә торган кызның атасына. Авылына кергәч:

— Сөенеч сорагыз, патшага кызын китердем,— ди.

Бер кеше бик каты чабып китә. Теге барып әйткәч, патша белән патша хатыны урам буенча чаптылар куанычтан. Кызны күргәч, икесе дә диванa булдылар. Ничә еллар югалып торган кыз бит! Шатлыктан патша, бик каты тәрбияләп, бөтен халыкны сыйлады, зур бүләкләр бирде.

Патша әйтә Камыр батырга:

— Кабул итсәң, бу кызны үзеңә бирәм,— ди.

Камыр батыр әйтте:

— Син теге ике патша кызының аталарына илче җибәр, алар да шатлансыннар,— диде. Әле ул чагында телеграмм булмаган.

Камыр батыр:

— Алдан шушы кызларны тапшырыйм, аннары сүзеңне кабул итәрмен,— дигән патшага.

Ул кызларны аталарына илтеп биргән. Теге патшалар Камыр батырга төрле машиналарда йөрер өчен льготалар биргәннәр, зур бүләкләр белән бүләкләгәннәр.

Шуннан кайткач, Камыр батыр патша кызына өйләнеп җибәргән. Әле дә булса гомер итәләр, ди, болар.

Бүген бардым, кичә кайттым. Ике телем чәй эчтем. Өч чынаяк икмәк ашадым. Аш та су, баш та сыйрак пешергәннәр. Тозга манып, бәрәңгене көйрәттем генә.

42. Мөгезле патша белән егет

Борын заман бер патша була. Бу патша, чәчен-башын кырдыргач, чәч алучыларның башын кистерә торган була. Калада чәч алучылар бетә. Кала бер егет. Патшаның чәчен-башын кырырга моңа чират җитә. Патша чакырта үзен. Бу егетнең җитмеш яшьлек әнисе була. Егет, патшадан кире чыкмасын белеп, әнисе белән бәхилләшә.

— Үтерер инде мине дә,— ди.

Килә патша янына, чәчен-сакалын кыра. Шулвакыт патшаның мөгезен күрә. Патша шуңа күрә дә чәч алучыларның башын кистерә икән, халык белмәсен дип. Бу малайны патша кызгана. Моның да башын кистерсәм, чәч алырга бер кешем дә калмый, ди.

— Сине җибәрмим,— ди,— син минем мөгезне күрдең, халыкка сөйләрсең,— ди.

— Сөйләмәм, миндә андый акыл юк,— ди егет.

— Миңа сүз бир, ант ит, мин бу серне беркемгә дә сөйләмәм дип,— ди патша.

Малай ункуллап риза инде!

— Кемгә дә сөйләмәм, ант итәм,— ди.

Егет шулай дигәч, патша үтертми, әйтә:

— Һәр өч көндә минем янга сакалымны-башымны кырырга килерсең,— ди.

Бу кайтып китә өенә. Шуннан һәр өч көнгә патша янына килеп йөри, серне кемгә дә әйтми.

Беркөнне малайның анасы сорый:

— Нинди сер ул? — ди.

— Син сорама, мин әйтмим, мин патшага әйтмәскә сүз бирдем,— ди егет.

Малае шулай дигәч, әнисе сорамый инде. Шулай бер ай үтә, бер ел үтә, малайның эче зурая башлый. Малайның эчендә сер бар бит, ул аны кемгә дә сөйләми, ә сер һаман үсә, корсакны шештерә. Чирли бу малай.

Әнисе сорый:

— Ни бар, ни булды, улым? — ди.

— Әни, үзем дә белмим,— ди бу.

Ахырда малай әйтә әнисенә:

— Эчемдә сер бар, кемгә дә сөйләргә ярамый, ә сөйләргә, бушанырга кирәк, юкса үләм мин,— ди.

Әнисе утырып елый да, киңәш бирә улына.

— Бар син,— ди,— карурманга, кер урманның кеше йөрми торган бер җиренә,— ди,— куе гына урынга,— ди.— Казы шунда чокыр тирән генә иттереп,— ди,— төш шул чокыр төбенә,— ди,— шунда чокыр төбенә ят та өч мәртәбә сереңне әйт,— ди.

Икенче көнне малай ала көрәк, китә карурманга. Керә урманның эченә, куаклыкка. Кош та үтә алмый торган җир. Шунда тирән итеп чокыр казый. Казып бетергәч, төшә чокыр төбенә дә ятып өч мәртәбә кычкыра:

— Патшаның мөгезе бар! Патшаның мөгезе бар! Патшаның мөгезе бар! — дип.

Аннан чыга да чокырны күмеп куя, үзе китә. Бу киткәч, бу чокыр өстенә үсә өч камыш. Бик тиз үсә, зур булып. Ә малайның өенә кайтуга шеше бетә. Берникадәр вакытлар үткәч, бер көтүче бу өч камышның берсен кисеп ала да курай ясый. Сызгырта башласа, курае кычкырта моның: «Патшаның мөгезе бар! Патшаның мөгезе бар!» — дип.

Бу көтүче һаман сызгырта, курае һаман шуны кычкыра. Бусын ташлый да икенче камышны кисеп ясый. Икенчесе дә шуны кычкыра. Хәзер камышның өченчесеннән ясап карый. Анысы да шуны ук кычкыра. Китә бу көтүен куып, «Патшаның мөгезе бар!» дип кычкыртып. Урамнан кайтканда моны халык та ишетә.

— Бу ни хикмәт, бу ни тамаша? — диләр.

Бу хәбәр хәзер ишетелә патшага.

— Халык сөйләп йөри синең мөгезең бар дип,— диләр.

Патша уйлый: «Минем мөгеземне кем дә күрмәде. Күргән беренең башын кистердем. Сөйләсә сөйләгәндер теге егет»,— ди. Чакырта бу егетне. Сорый:

— Йә, мин сине үлемнән коткардым, ә син сүзеңдә тормадың,— ишетәмсең, халык ни сөйли,— ди.

Малай әйтә:

— И падишаһым-солтаным, мин кемгә дә синең мөгезең турында сөйләмәдем. Серемне үзем генә беләм. Ул хәбәрне каян ишеткәннәрдер, белмим,— ди.

— Ярар, тикшерербез, белербез,— ди патша.

Шуннан кем беренче килеп әйткән, шуны чакырта.

— Каян ишеттең? — ди.

— Фәлән-фәлән кешедән,— ди теге.

Патша ул кешене таптыра. Хәзер аңардан сорый:

— Каян ишеттең син? — ди.

— Фәлән-фәлән кешедән,— ди бу да. Әйткән кешесен күрсәтә.



Шулай чакырта-чакырта көтүчегә җитәләр. Көтүче килә калтыранып, дерелдәп: «Нәрсә булыр икән?» — дип.

Көтүче килгәч, патша сорый көтүчедән:

— Каян күрдең минем мөгезне? — ди.

— Гафу итегез, падишаһым, мин күрмәдем,— ди бу.

— Соң, халык каян алып сөйли? — ди патша.

— Мин әйтмәдем аны, курай кычкырды шулай дип,— ди көтүче. Шуннан курай турында сөйләп бирә.— Артык берни белмим,— ди.

— Кая кураең? — ди патша.

Көтүче курайны патшага бирә.

— Сызгырып карагыз, ышанмасагыз,— ди.

Патша курайны ала да сызгыртып җибәрә. Курай: «Патшаның мөгезе бар!» — дип кычкыра.

Патша, ачуы килеп, курайны атып бәрә дә көтүчене куып чыгара. Инде егетне чакыртып сорый:

— Син беләсеңме, ни өчен болай булган? — ди.

Егет сөйли:

— Сезнең серне саклый-саклый эчем шеште, эчне бушатырга кирәк булды да карурманга барып шулай, шулай итеп әйттем мин, курай шул чокыр өстенә үскәндер алайса,— ди.

Патша уйлый, уйлый да бу егетне нишләтергә белми. Халык патшаның мөгезе барын белә бит инде.

— Бар, ычкын, күземә күренмә,— дип, патша бу егетне дә куып чыгара.

Ә халык көлә патшадан. Патша шулай итеп, хурлыкка чыдый алмыйча, кайгысыннан җүләрләнеп үлә. Аның урынына патша итеп чәч алучы егетне куялар.

II

43. Шәйдулла

Әлек бер ярлы кеше булган. Исеме Шәйдулла икән. Бала-чагасы күп булып, аларны көчкә асрап тора икән, ди. Хатыны, балалары туйганчы ашый-эчә, юньле кием кия алмый авыр көн күрәләр. Шәйдулла исә Ходаның биргәненә разый булып, «Ходай үзе насыйп бирер»,— ди дә йөри бирә.

Шулай, беркадәр көн үткәннән соң, ачтан балалары елап, хатыны орыша башлаган:

— Иренчәк син, ризык табалмыйсың,— дип.

Шунда мескен Шәйдулла, уйланып, күңеленә бер уй төшеп, куанып хатынына әйтә:

— Туп-туры Ходайдан сорагым килде,— дип.

Хатыны куанып:

— Бар! — дип җибәрә.

Шәйдулла өч көн, өч төн баргач, арыклыктан бәрелеп йөргән бүрегә юлыга.

— Кая барасың, яхшы кеше? — дип сорый бүре.

Шәйдулла җавап бирә:

— Ходайдан ярдәм сорарга барамын,— дип.

Шунда бүре әйтә:

— Ходайдан минем өчен дә сора әле: өч елдан бирле эчем авыртып, көн-төн мазам[1] юк. Ходай, рәхим кылып, миңа үлем бирсен, үңгә итмәсә[2],— дип.

Шәйдулла:

— Ярар, әйтермен,— дип, тагын өч көн, өч төн барып, алма агачына юлыга.

— Кая барасың, яхшы кеше? — дип сорый алма агачы.

Шәйдулла:

— Ходайга ярдәм сорарга барамын,— диде.

Шунда алма агачы әйтте:

— Ходайга минем арзым-диләнә[3] әйт әле. Мин үзем үсеп чыкканнан бирле үз җимешемне күргәнем юк. Әвәрә булып һәр даим җимеш чыгарсам, җимешләрем уңылып[4] төшәләр, өлгермиләр. Ходай Тәгалә миңа булышмаса, үлем бирсен,— диде.

Шәйдулла «ярар, әйтермен» дип, тагын өч көн, өч төн барып, бер зур күлгә җитте. Шул күлдән мәеленчә[5] бер зур балык судан томшыгын чыгарып, кояшта җылынып ята икән.

— Кая барасың, яхшы кеше? — дип сорады балык.

Шәйдулла:

— Ходайга ярдәм сорап барам,— диде.

Балык:

— Минем дә утенечемне әйт әле: җиденче ел булды, тамагым авыртып, мазам юк. Ходай рәхим кылып үңгә итмәсә, үлем бирсен,— диде.

— Ярый, әйтермен,— дип, Шәйдулла янә өч көн, өч төн барып, аннан соң бер агачлы сайга[6] килеп җитте. Шул агачларның уртасында бер зур агач тора иде, аның буе бик әйбәт гөлчуптар[7] белән тулган. Шул

---

[1] *Маза* — рәт, юнь.
[2] *Үңгә итмәү* — башкача итмәү.
[3] *Арзым-диләнә* — күңел теләгемне.
[4] *Уңылу* — коелу.
[5] *Мәеленчә* — үзе теләгәнчә.
[6] *Сай* — елга.
[7] *Гөлчуптар* — гөлле ботак.

агачтан бер ялкын рәвешле нәрсә чыгып, маңгаен[1] яп-якты кылып тора иде. Шунда Шәйдулла, тамаша кылып хәйран булып, шул агачның алдында, исе китеп, үзенең нигә килгәнен онытып торганда, ялкынның эчендә бер тавыш чыкты.

Диде:

— Ни кирәк, Шәйдулла?

Шәйдулла, шашып:

— Йа Алла, синең үзеңне ишетеп торамынмы? — диде.

— Сиңа ни кирәк, әйт,— дип икенче тапкыр кабатлады тавыш.

Шунда Шәйдулла, әдәп белән тезләнеп, үз үтенечен, бүренең, алма агачының, балыкның гозерләрен әйтте.

Шуннан соң баягы агачтан өченче тапкыр аваз чыкты:

— Балыкның тамагында кадалган асыл таш бар, шуны суырып алса, уңалыр[2], алма агачының төбендә күмелгән зур кумда[3] бар. Алтын тутырган шул кумданы алса, алма агачы гөлли[4], бүрегә эче авыртканыннан котылыр өчен бер ахмак адәмне ашау җитә. Синең үз теләгәнеңне бирдем, бар,— дип куя.

Өч көн, төн барып, балыкка килеп җитте. Зарыгып көтеп торган икән балык, ни булыр дип. Күргәч та сорады.

Шәйдулла балыкка Ходайның әйткәнен әйтеп, китим дигән икән, балык:

— Тукта әле, яхшы кеше, минем тамагымнан шул ташны алып ташла, һәм үзең баерсың,— диде.

Шәйдулла:

— Юк, миңа синең байлыгыңның кирәге юк, Ходаем үзе бирә,— дип җавап бирде дә янә өч көн, өч төн барып, алма агачына килеп җитте. Алма агачы да зарыгып көтеп торган икән. Дулкынлануыннан: «Ни булды?» — дип көчкә сорый алды.

Шәйдулла алма агачына сүзен әйтеп, китим дип торганда, алма агачы:

— Яхшы кеше, тукта әле, минем төбемдәге кумданы казып ал, үзең баерсың,— диде.

---

[1] *Маңгай* — өске өлеш.
[2] *Уңалу* — төзәлү.
[3] *Кумда* — тартма.
[4] *Гөлләү* — гөлләнү, рәтләнү.

Шәйдулла:

— Юк, миңа синең байлыгыңның кирәге юк, миңа Ходаем үзе бирә,— диде дә юлына китте.

Тагы өч көн, өч төн барып, бүрегә килеп җитте. Бүре дә зарыгып көткән икән, ашыгып:

— Әйтә күр, Ходай миңа ни боерык кылды? — диде.

Шәйдулла бүрегә дә тиешле сүзләрен әйтте.

Бүре Шәйдуллага: «Тәңре ярлыкасын!» дип әйтеп, Шәйдулладан, тансык итеп, күргәннәрен сорады. Шәйдулла юлда алма агачына, балыкка очрап барганын әйтте. Шунда бүре, элеккедән дә каты куанып, Шәйдуллага баш салып сөйләде:

— Ант итеп әйтәмен, бу дөньяда синнән дә ахмак һичкемне табалмамын,— дип.

Шуннан соң ахмак Шәйдулланы рәхимсез бүре ашап та куйды.

44. Эшлексез кеше

Була әүвәл заманда бер ярлы кеше. Бик тә рәтсез ярлы кеше инде, теләнеп кенә яши бу. Моның була ике улы. Улларын да теләнеп кенә туйдыра.

Карт белән карчык бер көнне үлеп китәләр. Болардан малайларга һичбер нәрсә калмый. Йорт кисәкләре бар да, эчендә бернәрсә дә юк, бары бер чуеннары гына бар. Аталары үлгәч, ике малай сүзгә киләләр:

— Болай торып булмый, бүленик,— диләр.

Олысы әйтә:

— Алып кил сельскийне,— ди.

Энесе алып килә сельскийне.

Сельский әйтә:

— Нәрсәгез бар бүленергә, әйдә бүләбез,— ди.

Абзасы әйтә:

— Менә бер ызба да бер чуен, бүтән бернәрсә дә юк,— ди.

Сельский әйтә:

— Ызба бүленми, ди. Чуен — абзаңа,— ди.

Абзасы әйтә:

— Бүген бергә йоклыйк, иртәгә мин чыгып китәрмен,— ди.

Кечесе шул төнне төш күрә. Абзасын уята да:

— Тор, абый, төш күрдем,— ди.

— Төшеңдә нәрсә күрдең? — ди абзасы.

— Әти каберләр өстенә чыккан иде, ди, акбүз атка атланган иде, ди, челәеп-челәеп челем тарта иде,— ди.

Тегесе әйтә:

— Иманлы икән, чукынган,— ди.

Шуннан кечесе әйтә:

— Абый, әйдә ягага[1] эшкә китик,— ди.

Агасы риза була. Болар ягага китәргә булалар.

Чыгып китәләр. Бара-бара, барып җитәләр бер су буена. Су буенда яталар болар йокларга. Олысы йокламый, пошыргалана, исәпли. Кечесе йоклап китә.

Менә төнлә ике пәри егете чыга су буена. Икәү сөйләшәләр болар. Берсе әйтә:

— Иптәш, ди, бу дөньяда адәм балалары бик зиһенсезләр. Һичбер нәрсә белмиләр алар,— ди.

Икенчесе әйтә:

— Ник алай әйтәсең? — ди.

Тегесе әйтә:

— Менә шушы елгага бер тәңкә алтын китереп салсалар, аннан бер мичкә алтын чыга,— ди.

Иптәше әйтә:

— Дөрес шул. Менә су башында бер карчык бар. Ул дөньяда нинди бәхет барын әйтә дә җибәрә. Күзге белән дә карый, карта белән дә карый. Адәм балалары бәхет эзләп йөриләр, үзләре шуңарга бармыйлар,— ди.

Болар тагын сөйләшә башлаганнар иде дә әтәч кычкырды. Әтәч кычкыргач, тагын сөйләшә алмадылар, суга төшеп киттеләр, ди.

Абыйсы энесен уятты:

— Тор, бер хикмәт күрдем, син ишеттеңме? — ди.

— Юк, мин йокладым,— ди.

Абыйсы әйтә:

— Монда ике пәри егете сөйләште,— шушы елгага бер тәңкә алтын китереп салсалар, бер мичкә алтын чыга,— дип. Әйдә теге чуенны сатып, шунда салып карыйк әле, ди. Тагын икенче пәри егете әйтте, су

---

[1] *Яга* — чит җир.

башында бәхетне белә торган карчык бар икән, ул бөтен дөнья хәлен белеп ята икән,— ди.

Абзасы китте чуен сатарга. Чуенны бер тәңкәгә сатты. Бер тәңкәне болар елгага китереп салдылар, бер мичкә алтын чыкты. Абыйсы әйтә:

— Әйдә, алтынны алып кайтыйк,— ди.

Кечесе әйтә:

— Син олы кеше. Алып кайт та авыл кешесе булып кал, яхшылап йорт сал. Мин су башына бәхет эзләргә барам. Шул син ишеткән карчыкны күреп булмасмы,— ди.

Абзасы китә кайтып авылга. Кечесе китә су буйлап.

Ай китә, ел китә, бармак буе җир китә. Бара-бара моңарга зур гына аждаһа-елан очрый. Елан әйтә:

— И егет, кая барасың? — ди.

Теге әйтә:

— Елан агай, бәхет эзләп барам. Шушы су башында бар икән бер карчык. Шул бәхетнең кая икәнен белә икән. Туганнан бирле рәхәт күргәнем юк әле,— ди.

Елан әйтә:

— Ярый, егет, мин дә элек тук идем, бака ашый идем. Хәзер миңа да авыр. Минем дә бәхетем бар микән, юк микән, шуны да сорап кайт әле,— ди.

— Ярар,— ди бу әйтә.

Бара-бара, бер авылга барып җитә бу. Шул авылда моңарга бер бөлгән алпавыт очрый. Алпавыт әйтә:

— Егет, нишләп йөрисең? — ди.

— Мин барам бәхет эзләргә. Мин бик ярлы кешенең баласы булам. Бәхет кая икән? — ди.

Теге әйтә:

— Бик яхшы булды әле, ди. Мин элек бай алпавыт идем, хәзер бөлдем. Минекен дә сорап кайтсана, буш итмәс идем,— ди.

— Ярар,— ди, аннан да китә бу.

Бара-бара, җитә бер авылга. Бик зур бер сарайдан бер хатын кычкыра:

— Егет, егет, кил әле,— ди. Егет хатын янына бара.— Егет, кая барасың? — ди.

Егет әйтә:

— Шушы су башында бәхет белүче бар икән, шуның янына барам,— ди.

Теге әйтә:

— Зинһар минекен дә белеп кайт әле. Дәүләтем дә бар, ирдән бәхетем юк. Иргә барам да ирем үлә. Сора әле, ирдән бәхетем бар микән минем, ди. Минем, ди, әлегә хәтле һичкем белән сөйләшкәнем юк иде, синең белән генә сөйләштем,— ди.

— Ярар, сорармын,— ди, моңардан да китә бу.

Барып җитә су башына. Менә утыра теге карчык, пәри карчыгы. Егет әйтә:

— Әби, мин сиңа бер гозер белән килгән идем,— ди.

— Нинди гозер, бәбкәм? — ди.

— Син, ди, адәм балаларының бәхетен беләсең икән. Һич тә бәхетем юк минем,— ди.

Әби әйтә:

— Бер дә аптырама, кайтканда ук баерсың,— ди.

Егет әйтә:

— Аннары миңа килгән чагында аждаһа-елан очраган иде. Элек ризыгым бар иде, хәзер юк, ди. Шул ризык турында сорашып кайтырга кушкан иде,— ди.

— Ул, ди, эшсез йөрүчене ашасын,— ди.

Егет әйтә:

— Аннары бер бөлгән алпавыт очраган иде. Кая китте икән малларым, дип, синнән сорарга кушкан иде,— ди.

Әби әйтә:

— Аның бар икән бер бакчасы. Бакчасында бар икән бер чыршы. Аның малларын хезмәтчесе шул чыршы төбенә күмеп киткән. Әйт, шуны алсын,— ди.

Егет әйтә:

— Бер хатын очраган иде, ирдән бәхетем булыр микән, дип сорады,— ди. — Һичкем белән сөйләшкәнем юк, дип әйтә ул,— ди.

— Кем белән сөйләшсә, шул сөйләшкәненә барсын,— ди.

Егет:

— Ярар, әби, гозерем бетте,— дип, әби белән саубуллашып кайтырга чыга.

Теге хатынга кайтып җитә. Хатын әйтә:

— Нәрсә әйтте? — ди.

— Кем белән сөйләшкән булса, шул сөйләшкәненә барсын, дип әйтте,— ди.

Хатын әйтә:

— Синнән башка кеше белән сөйләшкәнем юк. Ал мине,— ди. Егетнең муенына асылына.

— Юк,— ди егет,— мин сине алмыйм,— ди,— мин үз бәхетемне эзлим,— ди.

Егет бу хатынны алмый. Нинди бәхет эзләп йөргәндер инде. Аннан чыгып китә.

Килеп җитә бөлгән алпавытка. Алпавыт әйтә:

— Нәрсә дип әйтте? — ди.

— Синең бакчаңда бер чыршы бар икән. Малың шуның төбендә ята икән,— ди.

Алар икәү казырга ук китәләр. Чыгаралар алтынны казып. Алпавыт үзенә бер өлешен ала, моңарга ике өлешен бирә. Бу алмый.

— Мин үз бәхетемне эзлим әле,— ди. Кача бу алпавыттан.

Алпавыт моңардан көлеп кала: «Бу нинди юләр икән»,— дип.

Егет еланга килеп җитә. Елан әйтә:

— Сорадыңмы? — ди.

— Сорадым. Кем эшсез йөри, шуны ашарга кушты сиңа,— ди.

— Тукта,— ди елан,— мин суырып карыйм,— ди. Елан суыра, суыра да: — Синнән башка эшсез йөрүче юк икән. Шундый дәүләтләрне ташлап качкач, сиңа нинди бәхет кирәк? — ди, моны каба да йота.

45. Дага

Бер кеше, улын ияртеп, шәһәргә барырга чыккан икән, ди. Баралар, баралар икән, юл өстендә бик яхшы бер ат дагасы ятканлыгын күргәннәр.

Бу кеше, улына күрсәтеп:

— Улым, әнә бер бик яхшы дага ята. Файдасы тияр иде, ал аны! — дигәч, малай:

— Юлда күренгән бер тимер-томырны җыя китсәң, бар икән бер эш. Иренмичә аны иелеп аласым юк әле,— дип әйтте, ди.

Улы алмагач, бу кеше үзе алып, куенына кыстырып киттеләр, ди. Барып җиттеләр, ди, бер тимерчелеккә. Әлеге кеше тимерчегә кереп, даганы егерме биш тиенгә сатты, ди, һәм шул акчага гөрәңкә[1] ярым чия җимеше сатып алды, ди. Киттеләр, ди, малай — арттан, әтисе алдан бара, ди. Ә әтисе,

[1] *Гөрәңкә* — 409,5 грамм.

малайга сиздермичә генә, чияләрне берәм-берәм юлга ташлап бара башлаган. Малай юлда яткан чияләрне берәм-берәм чүпләп бара, ди.

Инде әтисе, чияләрне ташлап бетергәч, һәм малай иң соңгы чияне дә юлдан үрелеп алып авызына капкач, артына борылып, улына:

— Менә шулай, улым. Акылны хезмәт түкмичә генә алып булмый аны. Әгәр дә даганы үрелеп алырга иренмәсәң, бер үрелүдә эш беткән булыр иде. Менә син шул бер дага бәһасенә сатып алынган чияләрне ике йөз дә егерме биш тапкыр үрелеп алдың инде. Моннан соң, бер иелергә иренеп, ике йөз егерме биш мәртәбә иелергә вакытыңны да кызганырсың,— дип әйткәч, малайның йөзе чия кебек кызарды, ди.

46. Акыллы бабай һәм бай

Бик борын заманда, мин дә булмаганда, син дә тормаганда, әбиләр дә яшәмәгәндә, торган-булган, ди, акыл иясе бер карт бабай. Бу бабайны һәркем яраткан, һәркем хөрмәт иткән, һәркем бу бабай кебек булырга тырышкан, ди.

Көннәрнең бер көнендә бу бабай янына бер бай килә дә:

— Йә, бабай, мине үзеңә эне ит,— ди.

Шунда бабай моңа каршы әйтә:

— Юк, улым, мин бай кеше белән агай-эне була алмыйм. Бай кеше үлгәнче малдан туймый, шуңа күрә син минем сүземне тота алмассың,— ди.

Бай әйтә:

— Юк, бабай, мин сүз бирәм, синең сүзеңнән беркайчан да чыкмам,— ди.

— Ярар алайса, без синең белән агай-эне булышабыз, тик минем әйткән сүзләремне үтәрсең,— ди бабай.

— Әйт, бабай, мин синең боерыгыңны үтәргә әзер,— ди теге бай.

— Алай булса, бар өеңә,— ди бабай.— Хатыныңнан, балаларыңнан аерыл, бөтен малыңны үзара тигез иттереп, дөрес кенә бүл. Синең өлешкә төшкән малны көмеш акчага әйләндер дә аннан минем яныма килерсең,— ди.

Шуннан теге бай өенә кайта да карт-корыны җыя, мулланы китерә дә хатыны белән балаларыннан аерыла. Аннары бөтен малын, дәүләтен тигез иттереп бүлә дә, үзенә төшкән өлешне акчага әйләндереп, акчаны бер капчыкка тутырып, теге бабай янына китә.

Байның бу эшенә бөтен халыкның исе китә. Кайберәүләр, мескен бай акылдан язды дип, кызганалар, кайберәүләр аңа шулай күптән кирәк иде дип сүгәләр. Дөньяда төрле халык бар бит, төрлесе төрлечә уйлый инде.

Йә, алар шулай сөйләсеннәр, без китик теге бай белән.

Бу бай, капчык белән акчасын җилкәсенә күтәреп, бабай янына килә дә:

— Йә, бабай, мин син әйткәннәрнең бөтенесен үтәдем, хәзер мин сиңа эне була аламмы инде? — ди.

— Юк әле, бу бөтенесе түгел әле,— ди бабай.— Менә хәзер синең бөтен акчаңны икебезгә тиененә кадәр тигез итеп урталай бүләбез,— ди.

Бай бераз уйлап торгач, моңарга да ризалашып, бер җиргә утыралар да бабай белән бөтен акчаны ике җиргә тигез иттереп бүләләр. Аннары бабай үз өлешен, бу бай үз өлешен җыеп алалар да бер агым су янына киләләр. Шунда бабай бу байга әйтә:

— Әйдә, син дә капчыгыңнан бөтен акчаңны суга сип, мин дә сибәм,— ди.

Бу бай: «Әй бу бабайны халык бик акыллы бабай дип белмичә әйтә икән, әгәр моның акылы булса, акчаны суга ташлатмас иде»,— дип уйлый. Шулай да, ни булса шул булыр инде ди дә, акчаны суга сибеп бетерә. Бабай да үз өлешен сибеп бетерә дә байга әйтә:

— Менә бусы әйбәт булды, ди. Инде хәзер икебез дә чишенәбез дә һәркем үзе сипкән акчаларны җыйсын,— ди. Бабай, шулай дип, суга кереп тә китә. Бу бай да өс-башын чишенеп суга акча җыярга чума.

Бай бервакыт су читенә чыкса, күзе белән ни күрсен, бабай да юк, киемнәре дә юк. Су чите дә таныш булмаган бер җир булып чыга. Ерак түгел бер җирдә ниндидер бер ят авыл күренә. Бай шәрә көе су эченнән ярга чыга алмый. Шулай ни эшләргә белмичә торган вакытта бу күрә: шул авылдан ике кыз-хатын, көянтә-чиләк күтәреп, моңа таба киләләр. Бу, оятыннан ни эшләргә дә белмичә, су эчендә генә тора. Бу хатыннар килеп, моны күргәч:

— Ни эшлисең, абый, монда? — дип сорыйлар.

Бай үзенең киемнәрен югалтуын әйтә. Шул вакыт суга килүче апалар әйтәләр моңа:

— Хәзер, абый, без сиңа киемнәр җибәрербез,— диләр.

Болар чиләкләренә су тутырып алып киткәч, озак та үтми, бер малай моңа киемнәр китерә. Бу бай киемнәрне киенә дә, оялып кына булса да,

киемнәр китергән малай белән авылга китә. Бу авылда моны вакытлыча яшәргә бер өйгә урнаштыралар. Берничә көн яшәгәч, авыл халкы җыела да:

— Йә, дус кеше, сиңа йорт-җирсез яшәргә безнең җирдә дөрес түгел, үзеңә өй салырга, өйләнергә кирәк,— диләр.

Бай болардан бу сүзләрне ишеткәч, минем бу көнгә калганлыгымнан көләләр дип, боларга ачулана да:

— Минем йортлар салырга, өйләнергә акчам юклыгын бөтенегез бик яхшы беләсез, шулай да оялмыйча, Алладан курыкмыйча көләсез,— ди.

— Юк, дус кеше, син ялгышасың. Безнең җирдә кешедән көлү дә юк, бездә бай-ярлы да юк. Без синең бернинди дә малың юк икәнен беләбез. Шуңа күрә без сиңа өй салабыз, үзең теләгән кызны хатынлыкка алып бирәбез. Шулай итеп, без сине үз арабызга алабыз, тик синең ризалыгың гына кирәк,— диләр.

Бу бай ризалык биргәч, моңа өч көн эчендә өй салып куялар, бер карт үзенең кызын да бирә. Шулай итеп, бу бай бу авылда әйбәт кенә яши башлый.

Боларның эше: иртә торгач, кибеткә барып бер көнлек ризык алалар да шуны пешереп ашыйлар. Бу байның яңа хатыны моңа:

— Безнең илдә байлык җыярга ярамый. Кара, беркайчан да бер көнлек ризыктан артык ризык ала күрмә, югыйсә харап булырбыз,— ди.

Бу бай берничә вакытлар шулай рәхәт кенә яши, эшкә дә теләсә бара, теләмәсә юк. Тамагына да нәрсә теләсә шуны ашый, өстенә дә ни теләсә шуны кия — беркем бер сүз әйтми.

Шулай яхшы гына яшәгәндә, бу бай беркөнне уйлый: «Мин бит бай идем. Мондый халык миндә кол булып эшли иде. Ә мин аларга кычкыра идем, сүгә идем. Мин алардан олы идем, миңа дөньяда яшәве рәхәт иде. Ә монда бөтен халык бер хокукта, кем каршында горурланырга да юк, ди. Бу хатыннарның сүзен тыңлап тору ярамый, аларның чәче озын, акылы кыска. Мин әкрен-әкрен генә мал җыйыйм да, шулай итеп баермын, малым күп булыр. Шуннан соң бу җирдә дә мин хуҗа булырмын»,— ди. Бай, шулай дип, мал җыярга керешә. Хатыны, иренең бу эшен сизгәч, әйтә:

— Әй, карт, безнең илдә мал җыярга ярамый, җыйма, югыйсә харап булабыз,— ди.

Хатыны күп сөйли, ире аз ишетә, мал җыюын дәвам итә. Шулай көннәрнең бер көнендә бу бай җәй эссесендә елгага су керергә китә. Су читендә өстен чишенә дә суга чума.

Судан чыкса, күзе белән ни күрсен, су читендә әлгәреге, бай вакытындагы киемнәре ята. Ерак та түгел үз туган авылы күренә. Бу бай бу эшкә хәйран калып торган арада, теге бабай килеп чыга да:

— Йә улым, синең күзең дөнья малыннан туймый, тамагың кеше канынннан туймый, ә кул-аягың кеше җәберләүдән туймый икән. Шуңа күрә син минем белән агай-эне була алмыйсың. Мин үз кул көчем белән дөньяда яшим, кеше канын эчмим, байлык җыймыйм. Мә, бөтен акчаң исән-сау, бер тиененә кадәр төгәл. Сиңа тагы ни кирәк иде? Өең юк иде, өй салып бирделәр, хатының юк иде, үз кызымны биргән идем. Күңелең нәрсә теләсә шуны ашый-эчә идең, эшне дә теләгән чаклы, теләгән вакытта эшли идең. Бүрене күпме генә халык арасында асрасаң да, ул урманга кача, үзенең ерткычлыгын онытмый, диләр. Бар да бик дөрес,— ди.

Шулай ди дә, бабай үз юлына китә.

47. Тапкыр кеше

Әлекке заманда фәкыйрь генә бер карт белән карчык яшәгәннәр. Карт кечкенә чанасын тарта да урманга утынга китә. Утын кисеп яткан вакытында моның янына бер дию килеп чыга.

Дию әйтә:

— Нишлисең, карт? — ди.

— Менә утынга килдем әле, ягарга утыным юк,— ди.

— Мине туйганчы бер сыйласаң, ди, дию әйтә, мин сиңа утынны үзем илтеп бирермен, ди. Тик синең бу чанаң бик кечкенә, ди, икенчене ясарга кирәк, ди.

Пәри ике имәнне аудара да трактор артына тага торган чана шикелле иттереп зур чана ясый. Колач җитмәслек имәннәрне тота да шатор-шотыр сындыра, сындыра да төйи. Әллә нихәтле агачны төяп бетерә бу шулай иттереп.

Ярар, кайталар инде болар. Кайталар, утынны бушаталар. Менә дигән ике йорт салырлык агач кайткан.

Карт әйтә диюгә:

— Селкен! — ди.

Дию селкенгән иде, моның сакал-мыегыннан дөбер-шатыр килеп яңадан бер йорт салырлык агач коелды.

Ярар. Утыннарны бушаттылар. Шуннан соң карт әйтә диюгә:

— Әнә комган, син бит-кулларыңны юа тор, мин карчык янына кереп, ашарга-эчәргә хәзерләтим,— ди.

Карчык янына керә дә әйтә карт:

— Хәзер мин диюне ашарга-эчәргә дип алып керермен дә сиңа әйтермен: «Карчык, ашарга хәзерлә, кунакны сыйлап җибәрик әле»,— диярмен. Син: «Нәрсә генә пешерик икән, бернәрсәбез дә юк бит»,— дип әйтерсең. Шуннан мин сиңа: «Соң бит, карчык, карт диюнең башы бар, яшь диюнең түше бар, анысы гына җитмәсә, монда тагын берсе бар»,— дип әйтермен,— ди.

Хәзер карт ишегалдына чыга да диюне өйгә чакыра. Өйгә керделәр.

Карт әйтә:

— Карчык, ашарга-эчәргә хәзерлә әле, кунакны сыйлап җибәрик,— ди.

Карчык әйтә:

— Карасана, нәрсәләр генә пешерим икән соң,ниләр белән генә сыйлыйм икән, бернәрсәбез дә юк лабаса,— ди.

— Ник булмасын,— ди карт, гайрәтләнеп,— карт диюнең башы бар, яшь диюнең түше бар, алары гына җитмәсә, монда тагы берсе бар! — ди.

Шул сүзләрне ишетүе була, диюне син күр дә мин күр, чыга да чаба бу урманга.

Шулай итеп, бу карт ничә елга җитәрлек утынлы булып кала.

48. Һөнәрле югалмас

Борын заманда бер картның унбиш яшьлек малае була.

Башка кешеләргә карый да, өйдә ятуына малайның эче поша башлый:

— Әти, ди, безнең өч йөз сум акча бар, йөз тәңкәсен бир, читтә йөреп кайтам,— ди.

Әби-бабай әйтәләр:

— Синең өчен саклаган акча ул, сату башласаң, бирәбез,— диләр.

Малай, йөз тәңкәне алып, бер калага китә.

Бакчага чыга бу, карый: ике катлы йорт. Тәрәзәдән күрә: бик матур егетләр өстәл янында утыралар. Шунда сорый:

— Бу нинди йорт, нишлиләр монда? — ди.

Бер кеше әйтә:

— Монда язуга өйрәтәләр.

Бу егет керә, башлыкларын күрә. Башлык сорый:

— Ни йомыш белән килдең? — ди.

Малай әйтә:

— Язуга өйрәнергә килдем,— ди.

— Килүен килгәнсең дә, без буш өйрәтмибез бит, елга йөз тәңкә, акчаң бармы соң синең? — ди.

Бу егет йөз тәңкәсен бирә дә язу өйрәнергә керешә. Бу, ел тулганчы, шундаен оста язучы булып чыга, һәртөрле рәвештә яза ала: тегенеңчә дә, монынча да, аныңча да.

Елы тулгач, өенә кайта. Атасы-анасы сорый:

— Бер ел йөрдең, алган малың кая? — ди.

— Әти, мин быел йөз тәңкә биреп язуга өйрәндем, язусыз сату башлап булмый икән, шуны уйладым,— ди.

— Их улым, язу өйрәнеп губернатор буласыңмы, йә булмаса, писер буласыңмы? Акылсыз икәнсең,— ди атасы.

— Әти, алай түгел ул, язудан башка булмый, менә хәзер бир миңа йөз тәңкә, барам икенче калага, кибет ачып, эшне ходка җибәрәбез,—ди.

Атасы тагын йөз тәңкәне бирә, бу юлы малай икенче калага китә.

Анда да бакчага чыга: өч катлы йорт, ишетелә колагына уен тавышы. Берәүдән сорый:

— Монда нишлиләр? — ди.

Теге кеше әйтә:

— Монда скрипка өйрәнәләр,— ди.

Күрә башлыкларын.

— Нигә килдең? — ди башлык.

— Скрипкага өйрәнергә килдем,— ди.

— Без буш өйрәтмибез, бер елга йөз тәңкә.

Йөз тәңкәне чыгарып бирә дә өйрәнә башлый бу егет. Ел тулганчы менә дигән уенчы булып чыга.

Өенә кайтса, ата-анасы сорый:

— Алган малың кая? — ди.

— Быел, әти, мал алмадым, скрипкага өйрәндем,— ди.

— Бик шәп иткәнсең,— ди атасы,— болай булса, мин гомер буе җыйган акчаны өч елда бетерәсең икән,— ди.

— Әти, алай түгел, дөнья булгач, уен да кирәк була торган, ди, менә бир тагын йөз тәңкәне, бу юлы мал алып кайтам,— ди.

— Актык йөз тәңкә,— ди,— алсаң да ал, алмасаң да ал, моннан соң миннән акча кайтып сорама.

Малай, йөз тәңкәне алып, китә икенче бер калага. Чыга бакчага, анда да шулай ук өч катлы йорт, анда да матур егетләр уйнап утыралар. Берәүдән сорый:

— Монда нишлиләр?

Теге кеше әйтә:

— Монда шахмат уйнарга өйрәтәләр,— ди.

Бу тагын керә инде. Башлык сорый моннан:

— Нигә килдең? — ди.

— Менә шушы уенны өйрәнергә килдем,— ди.

— Буш уйнатмыйбыз без, бер елга йөз сум, акчаң булса, керерсең,— ди.

Бу йөз тәңкәне бирә дә уен өйрәнергә керешә. Моны һичкем дә җиңәрлек түгел — бер ел тулганчы шундый оста уенчы булып чыга бу.

Елы тулды. «Әти-әнигә кайтмыйм, анда ни белән кайтып керим»,— ди инде малай. Бу шәһәрдән ерак-ерак илләргә кәрван чыгып бара икән күп мал белән. Малай кәрванбашка бара:

— Сезгә бер хезмәтче малай кирәк түгелме? — ди.

Кәрванбаш әйтә:

— Безгә бик кирәк, әйдә, өс-башыңны карарбыз, тамагыңны туйдырырбыз,— ди. Моны алалар.

Бара торгач, боларның атлары арый, үзләренең дә эчәсе килә, ә су юк. Табалар бер ташландык кое. Моның суы бик тирән, йолдыз шикелле елтырап кына күренә. Озын бауга чиләк тагып, коега төшерәләр. Тарталар — су керми. Күп маташа торгач, бавы өзелә дә кала. Малайга әйтәләр:

— Син җиңел кеше, сине бәйләп төшерик, нишләп су керми икән, белеп менәрсең,— диләр.

Малайны бәйләп төшерәләр. Караса, коеда су юк, әлеге ялтыраган — алтын икән. Малай алтын тутырып менгерә. Шулай итә-итә, ун-унбиш чиләк алтын чыгаргач, коеның төбе чистара. Хәзер инде актык чиләккә үзе бәйләнеп менә. Байның көнеләнә китә: «Бу алтынны барыбер безгә калдырмас, үзенә алыр»,— ди. Бай тота да бауны кисә, малай мәтәлгәләп кое төбенә төшеп китә.

Бераз хәл җыйганнан соң, караңгыда капшана башлый бу. Капшана торгач, кулына бер ишек тоткасы эләгә. Тартуы була, ачыла. Кечкенә өй

21 Б–504

икән, караватта бер карт үләргә ята. Шүрлек бар, шүрлектә — скрипка. Малай, бу скрипка төзек микән дип, ала, карася — төзек. «Бу кое төбендә мин барыбер үләрмен, ичмасам, белгәнемне бер уйнап калыйм»,— дип, скрипканы көйләп, уйнап торып җибәрә. Моның уйнавы була, карт сикереп торып утыра.

— Эх бала, ди, каян килдең, әгәр скрипка тавышы ишетмәсәм, мин шушы минутта үлгән кешемен, ни теләгең бар, барысын эшлим,— ди.

Малай әйтә:

— Бабай, мин синнән алтын сорамыйм, көмеш сорамыйм, үтенәм: шушы коедан гына чыгар.

Карт, моны коедан чыгарып, бераз кәрван киткән юл белән илтеп куя. Болар бер-берсенә рәхмәтләр әйтеп аерылышалар.

Бу егет кәрванга барып кушыла, һич ачу юк, мине ник коеда калдырдың дип әйтү юк, элеккечә эшли бирә. Бай тагын явыз уйларын уйлый башлый: «Бу малай монда җәфаланса да, шәһәргә баргач, алтыннарны барыбер миндә калдырмас»,— ди. Кайтырга ике көнлек юл калгач, малайны атка атландыра да алдан җибәрә.

— Менә хатны абыстаеңнарга илтеп бир, сиңа сөенче бирерләр,—ди.

Малай китә. Калага якынлангач, малайның уена килә: «Бу байда әдәп, оят дигән нәрсә юк ие, мине кое төбендә калдырган ие»,— дип, хатны ачып укырга була. Бай хатынына сәлам язган, буй җиткән кызына сәлам язган: «Быел бик баеп кайтабыз, дигән, ләкин бу малайны, мин кайтканчы, ничек тә булса, хәйлә белән юк итегез»,— дип язган.

Малай шушы ике-өч юлны боза да үзенчә язып куя: «Бу малай аркасында бик баеп кайтам. Мин кайтканчы, бу егет кызымның куенында булсын, ди, бәхетле бала икән»,— ди.

Хатны алып кайтып бирә бай хатынына, чәй эчәргә утыралар, кыз да шунда була.

Хатны ачып укыйлар. Анасы кызын бүлмәгә алып керә дә әйтә:

— Менә, кызым, атаң шулай язган, мин кайтканчы, кызымны шушы егеткә бир дигән, син ни уйда соң? — ди.

Кыз әйтә:

— Ата-әни сүзеннән баш тартып булмый, ризамын,— ди.

Бервакытны кәрван кайтып төшә, мал белән. Кеше белән ишегалды тула. Кәрванбаш, тегесен — тегендә, монысын — монда куегыз дип, үзе өйгә керә. Хатыны самавырлар куеп, ашамлык-эчемлекләр китереп утырта.

Кәрванбаш сорый:

— Кызым кая, бер-бер җиргә кунакка киттеме әллә? — ди.

— Кая китсен, үзеңнең язуың буенча, мин кызны хат алып килгән егеткә бирдем. Хәзер кызың шуның белән,— ди.

— Ни сөйлисең, юләр,— ди кәрванбаш,— мин «юк итегез», дип язган идем,— ди.

Хатыны:

— Менә, ышанмасаң, үзеңнең язган хатың,— дип, хатны чыгарып күрсәтә инде.

Бу язуны карый: үз кулы, үз мөһере.

— Минем кылган явызлыгым бу егеткә яхшылык булып авышкан икән, нишләмәк кирәк,— дип эчен уа да, инде эш узган була.

Әби белән бабай кереп, кияү-кызның хәлен белә:

— Кияү, ди, мин хата эшләдем, ди, гафу итә күр,— ди.

Кияү әйтә:

— Син, ди, комсызлыгыңа буйсындың, коега кисеп төшергән идең, ди, мине бер бабай коткарды, ди, сүзем сүз булсын дип әйтәм мин,— ди.

Кыз белән егет, иртәгесен яхшы ат җигеп, якындагы калага китәләр. Шулай бик матур урамнан узганда, килеп җитәләр бер сарай турысына, күрәләр: һәртөрле төстә утлар янып тора, кеше җыелган. Кияү кыздан сорый:

— Бу нинди йорт, нигә җыелган халык монда? — ди.

Кыз әйтә:

— Бу патша сарае. Патша үзенең кызын, кем дә кем шахмат уйнарга оста, шул кешегә бирә, монда, патша кызын алабыз дип, бик күп кеше һәлак булды инде,— ди.

— Алайса мин дә керәм монда, күреп чыгам,— ди.

Кыз елый башлый:

— Анда керсәң, харап буласың, асыласың,— ди.

Шулай да егет керә. Керсә, вәзирләр утыра, патша утыра өстәл янында. Патша сорый:

— Нигә килдең? — ди.

— Синең белән шахмат уйнарга килдем,— ди.

— Егет, мин сине барыбер отам, астырам бит,— ди патша.

— Асылсам, асылам,— ди егет,— килүем бушка китмәсен, әйдә уйныйбыз,— ди.

Патша әйтә:

— Сине өч мәртәбә отсам, асамын, син мине отсаң, кызымны бирәмен,— ди.

Болар икесе ике яктан, вәзирләр алдында кул куеп, уйнарга тотыналар. Патша бер мәртәбә ота, ике мәртәбә дә ота, егеткә әйтә:

— Әйттем бит мин сиңа һәлак буласың дип, менә хәзер бер генә оттырасың калды,— ди.

— Әйдә, уйныйк әле,— ди егет,— барыбер мин үләргә килгән,— ди.

Өченче мәртәбә тезгәндә, егет патшаны ота. Икенче тезәләр — ота, өченче тезәләр — тагын ота.

— Хәзер кызым синеке,— ди патша,— әйдә, күңелдә калмасын, тагын бер уйныйк, ярты патшалыгымны бирәм,— ди.

Тагын уйныйлар — егет ота.

— Әйдә, тагын бер уйныйк, бөтен патшалыгымны бирәмен,— ди патша.

Уйныйлар — егет ота. Шулай итеп патшалыгын да ала, кызын да ала.

Үз янына ата-анасын да чакырып, бергә гомер кичерәләр.

49. Тапкыр егет

Бер фәкыйрьнең өч улы була. Моның зур улы эш эзләп читкә чыгып китә. Атасы әйтә:

— Фәлән авылга барсаң, Мусага кермә,— ди.

Малай китә, теге авылга керә, Мусаның нәкъ үзенә очрый.

— Бабай, сиңа хезмәтче кирәк түгелме? — ди.

— Кирәк,— ди теге.

— Исемең кем?

— Муса.

— Юк,— ди, егет әйтә,— әти Мусага керергә кушмады, ди.

Малай туры урамнан барганда, Муса карт, астагы урамнан әйләнеп, тагы моның каршысына килеп чыга. Малай әйтә:

— Мин эш эзләп йөрим, кеше кирәк түгелме? — ди.

Муса әйтә:

— Кирәк,— ди.

— Исемең кем?

— Муса.

Теге егет:
— Бу авылда Мусадан башка кеше юктыр, ахры, ялланам инде,— ди. Бу яллана шул шарт белән: ачу китерештән.
Муса әйтә:
— Сиңа ашаган саен бер чынаяк чәй белән бер телем икмәк булыр, ашыйсың да торып китәсең. Шуңа ачуың килсә, аркаңнан бер телем каеш телеп алырмын. Минем ачуым килсә, син минем аркадан телеп алырсың,— ди.
Ни булса булды, егет кереп эшкә тотынды. Кайтып ашарга утыра: бер чынаяк чәй, бер телем икмәк моңа. Дүрт-биш көн эшләгәч үк чыдарлык хәле калмады моның. Бер көнне егет эштән кайтып чәй эчте дә чынаякны ныграк каплады. Муса әйтә моңа:
— Әллә, улым, ачуың киләме бер чынаяк чәй эчеп, бер телем икмәк ашаганга? — ди.
Егет әйтә:
— Эшләп-эшләп туйганчы ашамагач, нишләп ачуың килмәсен? — ди.
Малайның аркасын ачып, бер телем каеш кисеп ала да җибәрә моны Муса.
Уртанчы малай да барып, шулай ук булып кайта.
Инде кече малай китә. Тагын карт туры килә.
— Бабай, сиңа хезмәтче кирәк түгелме? — ди.
Бабай әйтә:
— Кирәк,— ди.
Егет әйтә:
— Исемең кем?
— Исемем Муса.
Егет әйтә:
— Миңа шул Муса кирәк иде дә инде, минем эзләп йөргәнем син идең,— ди.
Кереп эш башлый бу. Бер, ике, өч көн бик яхшы хезмәт итә. Бер телем икмәкне ашап, бер чынаяк чәйне эчә дә әйбәт кенә чынаягын каплый.
Муса әйтә:
— Бер телем икмәк ашап, бер чынаяк чәй эчкәнгә бер дә ачуың килмиме? — ди.
Егет әйтә:
— Юк, ачуым килми,— ди.

— Иртәгесен,— ди Муса,— күрше малайлар белән сарык көтәргә барырсың, бик яхшы эшлисең икән,— ди.

Болар сарык көтәргә баралар. Елгага төшеп, Мусаның бер симез сарыгын суялар да иптәшләре белән бергә пешереп ашыйлар.

Кич кайта бу, өстәл арасына кереп утыра, бер чынаяк чәй эчә, чынаягын каплый да кузгала.

— Улым,— ди Муса,— бер телем икмәк ашап, бер чынаяк чәй эчкәнгә ачуың киләме әллә? — ди.

Егет әйтә:

— Юк-юк, бабай, ачуым килми,— ди.— Теге тирән елгада синең бер симез сарыгыңны суеп ашадык, бабай, синең ачуың килмиме? — ди.

Муса:

— Юк-юк,— дигән була. Үзе хатынына әйтә бу:

— Бу малайны сарык көтәргә җибәрмик, ди, бу өйрәтер, ахрысы, безне,— ди.— Бүген ат көтәргә бар, балам,— ди егеткә.

Икенче көнне ат көтәргә баралар. Мусаның бер симез биясен суялар да рәхәтләнеп тамакларын туйдыралар, тиресен сатып, чәй-шикәр алалар.

Кич кайта егет, өстәл кырыена утыра, бер чынаяк чәй эчә дә чынаягын каплый, бер телем икмәкне ашый да торып китә.

Муса әйтә:

— Улым, әллә бер телем икмәк ашап, бер чынаяк чәй эчкәнгә ачуың киләме? — ди.

— Юк-юк,— ди егет,— бүген синең бер симез бияңне суеп ашадык әле. Синең ачуың килмиме? — ди.

— Юк-юк,— дигән була Муса, үзе «уһ-уһ» ди.— Алайса моннан соң йорт эше эшләрсең син, улым,— ди.

Беркөнне Мусага кунаклар килә.

— Улым,— ди,— кунаклар килде, бер сарык суй,— ди.

— Бабай, кайсын суйыйм? — ди.

Муса моңа күн бияләй чыгарып бирә:

— Шушыны ки дә шапылдат, кайсы сиңа караса, шунысын суй,— ди.

Малай, күн бияләйне киеп, абзарга кереп кулын шапылдаткан иде, сарыклар өркеп, абзар почмагына җыелдылар да барысы да моңар карап тора башладылар. Тотынды бу сарыкларны кырырга. Бер сарыкны тунап алып керде. Муса әйтә:

— Ник озак маташтың, мал суйганың юк иде мәллә? — ди.

— Анда эш күп булды,— ди егет.— Сарыклар барысы да миңа карадылар, мин аларның барысын да суйдым, ачуың килмиме? — ди.

Муса:

— Юк-юк,— дигән була: үзе «аһ-ваһ» килә. Хатынына әйтә бу:

— Безне бетерде бу, маллардан да аерды, моны диюләргә җибәреп үтерергә кирәк, шунсыз котылып булмас моннан,— ди. Моңа әйтә: — Фәлән урманда, фәлән күлдә безнең су атларыбыз бар, шуларны алып кайтып күрсәт,— ди.

Егет чыгып китә, күлгә барып җитә. Күл читендә һәйбәт яшь юкәләр үсә икән, юкә төшереп ала да тотына бу аркан ишәргә. Бер дию килеп чыга.

— Нишлисең? — дип сорый.

— Нишләгәнне күрәсең,— ди егет әйтә,— аркан ишәмен, күлегезне күккә күтәрәмен,— ди.

Дию күлгә чума да алып чыга бер зур ишәк.

— Менә шушыны күтәреп күлне әйләнеп кил,— ди,— шуннан соң күлне күккә асуыңа ышанырмын,— ди.

— Әүвәл үзең күтәреп әйлән,— ди егет.

Дию ишәкне күтәреп китә дә, күлне әйләнеп, егет янына килә.

— Хәзер син күтәр инде,— ди.

Егет, аркаппан нукта ясап, ишәккә кигезеп ала, өстенә сикереп менә дә — әйдә күл әйләнәсеннән чабарга! Биш минут эчендә күлне әйләнеп, дию янына килеп җитә бу. Дию күлгә чума, абыйсына төшеп әйтә:

— Абый, күл читенә бер адәм баласы килгән, күлегезне күккә асам дип әйтә, котым очты,— ди.

Агасы да чыга. Егеткә әйтә:

— Монда нишлисең?

— Нишләгәнне күрерсең, күлегезне күккә асам,— ди егет.

Дию күлгә чума да егерме потлы чуен алып чыга.

— Менә шушыны күккә атып җибәр, төшкән чагында җиргә төшермиенчә кулга тотып, җиргә куй,— ди.

Егет әйтә:

— Әүвәл үзең атып күрсәт,— ди.

Дию тотып чөя чуенны, бик югары менеп китә. Төшкән чагында кулы белән тотып җиргә куя.

— Йә, син атып җибәр инде,— ди.

Егет чуен гернең тоткасыннан тота да, башын кыйшайтып, бер болытка карап тора.

— Йә, ни карап торасың, нишләп җибәрмисең? — ди дию.

Егет әйтә:

— Мин җибәрсәм, төшәрлек итмәмен, әнә болыт киләме, шуңа кыстырып җибәрермен мин,— ди.

Дию әйтә:

— Дөньяда бар геребез шушы безнең, зинһар җибәрә күрмә,— ди.

Бу болытка карап тагы якланган була:

— Җибәрәм булгач, җибәрәм, калдырмыйм,— ди.

Дию ялына:

— Җибәрә күрмә, ни теләгең бар? — ди.

Егет әйтә:

— Минем теләгем шул: син энеңне дә алып чык та, мин, сезгә атланып, Мусага сезне күрсәтеп килим,— ди.

Дию энесен алып чыга, бу, абыйсына атланып, тегесен җитәкләп, Муса авылына кайтырга чыга.

Урманнан чыкканда юл буенда ауган имән бар икән. Егет әйтә диюгә:

— Әни җиләккә килгәндә орчыгымны югалттым дип әйткән иде, монда икән, моны күтәреп кайт инде син,— ди.

Диюнең коты оча: «Әнисенең орчыгы болай булгач, безне бер генә кабып йотар ул»,— ди.

Бер су буеннан узганда ташландык тегермән ташы күрделәр.

— Менә,— ди егет әйтә,— минем әнинең орчык башы монда төшеп калган икән, ди, моны да алыйк,— ди.

Берсе имәнне күтәрде, берсе тегермән ташын, кайталар болар.

Авылга да якынлашалар. Муса егеттән котылдык дип, капка төбенә чыгып карап йөри икән инде. Менә ул бер түбәдән диюләр белән егетнең килеп чыкканын күрә. Коты чыга моның. Егет диюләрне ишегалдына алып керә, имән белән тегермән ташын куялар.

— Бабай, менә айгырларыңны алып кайттым,— ди егет,— кая куйыйм? — ди.

— Җибәр, улым,— ди Муса,— исәннәр икән, шуны гына беләсем килгән иде, рәхмәт сиңа,— ди.

Муса бик курыкты инде моннан.

«Ничек котылырга инде»,— ди. Моны хәзер туйганчы ашата, ачуың киләме дип сорамый да. Кич белән моңа әйтә:

— Балам, син түбән өйдә йокларсың,— ди.

Хатыны белән киңәшеп, бер зур казан су кайнаталар. Егет йоклагач, өстенә кайнар су коеп үтермәк булалар. Егет төшеп ята. Кайнар су коя башлаганда, читкәрәк китеп тора. Тегеләр түгеп беткәч, тагын урынына килеп ята.

— Инде үлгәндер,— ди Муса,— иртәгә җыештырырбыз,— ди.

Иртә белән Муса төшә дә:

— Улым, нихәл? — ди. Бу йоклап яткан була.— Тынычсыз булмадымы, монда кеше кунганы юк иде,— ди.

— Юк-юк, бабай,— ди егет,— бер болыт килеп җылы гына яңгыр яуды, рәхәтләнде тәннәрем,— ди.

Муса хатынына менеп әйтә:

— Ул, ди, җылы гына яңгыр яуды дип әйтә, гомердә үләсе юк икән аның, башыбызга җитәр, ахрысы,— ди.

Иртә торып, хатыны юл азыгы пешерә башлый, йортны ташлап качыйк дип уйлашалар болар. Шул көнне кич, ат җигеп, китәргә хәзерләнәләр. Юл азыкларын бер капчык белән тарантас артына бәйлиләр, бүтән әйберләрен дә салалар. Егет моны сизә дә, капчыкның азыгын бушатып, анда үзе кереп ята.

Муса белән хатыны атка утырып чыгып китәләр. Бик каты чабалар, барып-барып, ничә чакрымнар киткәч, бер су буена килеп җитәләр. Ай яктысы якты. «Котылдык тегеннән» дип, атларын туарып, ашап-эчеп, йокларга яталар. Егет капчыктан чыга да байның атын җигәргә тотына, алып китәргә җыена. Ара-тирә атка кычкыргалап та куя. Муса башын калкытып караса, егет атын тарантаска җигеп китәргә тора.

Егет әйтә:

— Бабай, атың белән тарантасыңны алып киткәнгә ачуың килмиме? — ди.

Муса кычкыра башлый:

— Мал-туарыңны да бетереп, актык атыңны да алгач, нигә ачуың килмәсен? — ди һәм сикереп тора.

Егет Мусаның аяк-кулын бәйли, үткен пычак алып, күлмәген күтәрә дә аркасыннан бер телем каеш ала:

— Бусы абзый өчен,— ди. Икенчене телеп ала: — Бусы уртанчы абзый өчен,— ди. Өченчене телеп ала: — Менә монысы үзем өчен,— ди.

50. Убыр-Таз

Әүвәле булган, ди, өч агай-эне кеше. Боларның икесе акыллы, ди, өченчесе тиле, ди. Убыр-Таз атлы, ди.

Убыр-Таз бер эш тә эшли белми, ди. Моңа агалары әйттеләр, ди:

— Убыр-Таз, син тик торганчы киеккә тозак кор,— диделәр, ди.

Убыр-Таз тозак корды, ди. Корганның икенче көнендә барып караса, эләккән, ди, бер бик зур аю. Убыр-Таз аюны ычкындырып җибәрде дә, ди, өенә кайтып китте, ди. Өйгә кайткач, агалары моннан сораганнар, ди:

— Ни эләккән тозагыңа? — дип.

Убыр-Таз әйтте, ди:

— Попның кара сыеры эләккән,— диде, ди.

Иртәгесен Убыр-Таз тагын барган, ди, тозагын карарга; эләккән, ди, бик олы бүре. Убыр-Таз бүрене ычкындырып җибәрде дә, ди, өенә кайтып китте, ди. Кайткач агалары:

— Тозагыңа ни эләккән? — дигәч, бу тагы:

— Попның кара танасы эләккән,— диде, ди.

Өченче көнне тагы барды, ди, Убыр-Таз тозагын карарга. Тозагына эләккән, ди, төлке. Бу төлкене ычкындырган да, ди, өенә кайткан, ди. Агалары моннан тагы:

— Ни эләккән? — дип сорадылар, ди.

Убыр-Таз әйтте, ди:

— Эләккән попның кызыл бозавы,— диде, ди.

Дүртенче көнне эләккән, ди, куян. Убыр-Таз барып аны да ычкындырып кайтты, ди. Агалары:

— Ни эләккән? — дигәч:

— Попның ак көчеге эләккән,— диде, ди.

Ялан поп малы эләккән дигәч, агаларының моңа ачулары килде, ди.

— Моннан болай барсаң, эләккән нәрсәне өйгә алып кайт,— дип, кисәтеп җибәрделәр, ди.

Убыр-Таз барган, ди: тозакка шүрәле эләккән, ди. Убыр-Таз шүрәлене тотты да, ди, өйгә алып кайтырга теләи, ди. Шүрәле моңа:

— Җибәрсәнә,— дип әйтә, ди,— җибәрсәң, күп мал бирермен,— дип әйтә, ди.

Убыр-Таз шүрәлене җибәрде, ди. Шүрәле моны кунакка чакырды, ди.

Убыр-Таз өйгә кайткач, агалары сорадылар, ди:

— Ни эләккән тозагыңа? — дип.
Убыр-Таз әйтте, ди:
— Шүрәле эләккән иде, «бик баетырмын» дигәч, җибәрдем, иртәгә үземне кунакка чакырды,— диде, ди.
Иртәгесен китте, ди, Убыр-Таз кунак булып. Барып җитүе белән, шүрәле моны бик сыйлады, ди. Киткән чагында бер бик олы кап белән мал биреп җибәрде, ди, иртәгесен тагы чакырды, ди.
Убыр-Таз, өйгә кайткач, капны киштәгә куйды да, ди, үзе чыгып китте, ди. Үзе кайтканчы, җиңгәләре, кап эчендәге бар малын алып, җыеп куйдылар, ди.
Убыр-Таз иртәгесен тагы барды, ди, шүрәлегә. Шүрәле моңа тагы бер кап бирде, ди.
— Кайтып җиткәнче ачып карама,— дип әйтте, ди.
Убыр-Таз юлда ачып караган иде, ди, үзалдына тукмаклый торган тугыз тукмак сикерде дә, ди, Убыр-Тазны тукмаклый башлады, ди. Убыр-Таз: «Кап, ябыл!» — дип кычкырган иде, ди, тукмаклар капка кереп киттеләр дә, ди, кап ябылды, ди. Өйгә кайтып җиткәч, Убыр-Таз кабын ян сәкегә куйды да, ди, чыгып китте, ди.
Җиңгәләре ачып караганнар икән, тугыз тукмак чыгып, җиңгәләрен тукмакларга ябышты, ди. Әзрәк торгач, кайтты, ди, Убыр-Таз, болар Убыр-Тазга әйтәләр, ди:
— Тукмакларыңны тыйсаң, бар малыңны кире бирербез,— диделәр, ди.
Убыр-Таз, «Кап, ябыл!» — дип кычкырды, ди, тукмаклар бары да кереп беттеләр, ди, кап шап итеп ябылды, ди.
Шуннан соң Убыр-Таз, агалары белән бергә, бик баеп тора башладылар,ди.

51. Хикмәтле усак

Яшь вакытта әтәй белән урманга барып, усак кисеп, чанага салып торадыр идек, килеп чыкты урман хуҗасы.
Инде нишләргә? Безгә хәзер хәл чамасы юк качарга да. Бары мөмкин булды атыбызга утырып чабарга гына авылга. Тотындык әтәй белән чабарга. Кем күрсен, бураннар гына уйнап тора безнең арттан!
Урман хуҗасы безнең арттан чаба, ну аты бик начар булгачтын, безнең арттан җиталмый.

Кайтабыз да усакны яшереп базга ыргытабыз. Урман хуҗасы килеп, безне тикшереп карый да табалмый кире кайтып китә.

Бик күп вакытлар үтә, онытабыз теге агачны, усакны. Бу тегендә тамыр җәеп үсәргә керешә. Үсә-үсә тишеп чыга сайгакны, өйдә үсеп утыра, түшәмне тишеп чыга, аннары түбәне дә тишеп чыга.

Моны нишләтәбез инде хәзер? Мин карап торам-торам бу усакка: «Туктале, мәйтәм, менеп карыйм әле, моның очы ерак микән?» Карасам — ул һаваны да тишеп чыгып киткән. Менсәм — анда бер чебенгә бер сыер бирәләр. Мин сөенечтән бик тиз генә төшеп, бер чирекле шешәгә тутырып, чебеннәр алып менәм дә һәрбер чебенгә бер сыер алышып алам. Чебеннәрне алышып беткәннән соң, яллыйм бер ун-унбиш көтүче, бу сыерларны куып төшерергә усак буенча.

Килсәм, усакны екканнар, калдым бит мин һавада. Хәзер нишләргә? Әйтәм көтүчеләргә:

— Суеп тунагыз да, ите үзегезгә булыр, тиресе — миңа.

Бу сыерларның һич санын да, хисабын да белмим. Надан чак, минем мөмкинлек юк санына чыгарга. Һәр чебенгә сыер алгач...

Сыерларны суйдырып тунатам да, тиреләрен машинага илтеп ярдырам да, берсенә берсен ялгап, бер башын бәйләп, җибәрәм җиргә төшереп. Аннары шул каеш буйлап тотынып төшеп китәм. Очына төшеп җиттем: каеш җиргә җитмәгән.

Ерак түгел бер карт тары җилгәрә, җил миңа кибәкне очырып тора, мин шуларны тотып аркан ишә башладым. Бер-ике метр иштем дә: «Туктале, беркадәр төшкәч, күбрәк тә ишәрмен»,— дип тотынганыем — өзелде китте минем кибәк арканым. Килеп төштем дә тездән хәтле баттым,— сазлык урынга туры килгәнмен. Шунда килде дә бер бүдәнә башыма күкәй салып китте.

Хәзер нишләргә? Килә бер бүре. «Йа Хода, мәйтәм, бу бүре белән мин нишләрмен инде? Мине ашый бит хәзер».Һич кузгала алмыйм. Бу бүре килә дә, бүдәнә күкәен кабып йота да борылып китеп бара. Койрыгын эләктереп, «һайт» дип кычкырган идем, мин дә чыктым, бүре дә, тиресеннән чыгып, торды да чапты. Тары илəгән карт та, теге бүредән куркып, торды да йөгерде өенә таба. Мин артыннан йөгерәм, ул миннән куркып йөгерә. Ул миннән курыкмый икән — бүредән.

Шул көе мин, кайтып, өйгә керәм.

Шуның белән әкият тәмам.

III

52. Кәҗәле Салам-Торхан

Әүвәл заманда булган бер ярлы. Моның киеме дә, өе дә булмаган. Салам җәеп, шул саламлыкта гына көн күреп тора икән бу. Шулай да аның булган бер кәҗәсе. Бер дә бер көнне шул кәҗәне ашарга дип Төлке килгән. Теге ярлы Төлкегә әйткән:

— Син минем кәҗәмне ашама, минем бүтән терлегем юк,— дигән.

Төлке моны, фәкыйрь булгач, кызганган. Төлке моңарга әйткән:

— Җәмәгатең бармы? — дигән.

— Юк,— дигән теге ярлы.

Төлке әйткән:

— Мин сине өйләндерәм, сиңа патша кызын алып бирәм. Кәҗәңне миңа ашатырсың, дигән. Мин, дигән, фәлән патшаның кызына яучыга барам,— дигән.

Ярлы мескен куанычыннан елаган да, көлгән дә. Ул әйткән:

— Миңа, патша түгел, фәкыйрь дә кызын бирми, мин шулкадәр ярлы,— дигән.

Төлке әйткән:

— Мин үзем белермен,— дигән.

Төлке саубуллашып чыгып китте. Барып җитте бер шәһәргә. Әкрен генә керде, бер дә чапмый. Күрүчеләрнең кайсы әйтә:

— Төлке бит бу,— ди.

Кайсысы әйтә:

— Эттер, Төлке булса, шәһәр эчендә йөрмәс иде,— ди.

Бар халык карап кала.

Ярар, Төлке бер заман патшаның капка төбенә барып утырды. Сакчыларның исләре китте:

— Бу бер гаҗәп, Төлке килеп утырган,— диделәр.

Сакчылар патшага хәбәр иттеләр: «Монда бер Төлке утыра, гаҗәп»,— дип. Патша чыкты. Патшаны күргәч, Төлке баш иде. Патша гаҗәпләнде. Кулы белән «кер» дип изәде. Шулай дигәч, Төлке телгә килде. Ул әйтә:

— Мин илче, ди. Мине Салам-Торхан атлы бер патша баласы синең кызыңа яучыга җибәрде,— ди Төлке тәмам сөйләшеп.

Шуннан патша Төлкене сыйлый. Төлке әйтә:

— Син, бирерлек булсаң да әйт, бирмәслек булсаң да әйт, мин эшне бетереп китәм,— ди.

Патша вәзирләре белән киңәш итә. Вәзирләр һәммәсе дә:

— Бирик, Төлке яучыга килерлек булгач, бу ни җитте патша түгелдер,— диләр.

Төлкегә әйтә патша:

— Кияүгә бүләккә нәрсә бирик,— ди.

Төлке әйтә:

— Мин әйбер күтәреп йөри алмыйм. Син аңарга алтын тәңкә җибәр. Ул алтынга мохтаҗ түгел-түгелен, шулай да күргәч ышаныр. Минем дә бик күп сулар кичәсем бар,— ди.

Патша, кулъяулыгына бәйләп, күп кенә алтын бирде. Кияүгә хат язып, хатын да шунда куйды.

Ярар, Төлке саубуллашып чыгып китте. Эзләп, теге фәкыйрьне тапты. Салам-Торхан, салам җәеп, шунда ятып тора инде. Байлыгы шул салам гына моның. Төлке әйтә:

— Мин эшне бетереп кайттым,— ди, алтынны Салам-Торханга бирә.

Алтынны аладыр да ярлы, ышанып бетми. Төлке әйтә:

— Син мин әйткәнне тыңла, әйдә минем белән. Кәҗәңне соңыннан ашармын,— ди.

Төлке Салам-Торханны ияртеп китте. Баралар, баралар, бер су буена барып җиттеләр. Шул суда бер зур күпер бар. Төлке бер авылга керде дә, шуннан кеше яллап чыгып, күперне ваттырып куйды. Шуннан Салам-Торханга әйтә:

— Син шунда суга төш тә, пычракка буялып бер баганага ябыш,— ди.

Салам-Торхан Төлке кушканны эшләде. Төлке моны калдырып китте патша йортына.

Төлке барып җитте. Бер килгән булгач, патшаның сакчылары моны таныйлар инде. Патшага керәдер дә Төлке, әйтә:

— Киявең харап булды, күпер җимерелеп төшеп, тройкасы да китте, әйберләре дә китте. Үзе бер баганага ябышып калган иде, үзе дә китмәгәе,— ди.

Патша вәзирләренә әйтә:

— Тиз генә тройка җигегез дә кияүне алып килегез,— ди.

Ярар. Тиз генә җигәләр дә күпер янына китәләр. Бик яхшы киемнәр дә алалар болар.

Барып җитсәләр, Салам-Торхан баганага ябышып тора, үзе пычранып беткән. Моны вәзирләр тартып алып, юындырып, киендереп, тиз генә тройкага утырталар. Патша музыкалар кактырып, ике күзе шикелле итеп көтеп тора.

Ярый. Кияү килеп керде. Аш-су хәзер. Салам-Торханга күлмәк китерделәр, җөйсез күлмәк. Салам-Торхан як-ягына карый, гомердә андый күлмәк кигәне юк аның. Кигәне түгел, күргәне дә юк.

Патша әйтә Төлкегә:

— Нигә кияү болай як-ягына карана? — ди.

Төлке әйтә:

— Суга аккан киемнәре болай гына түгел иде. Ул өстендәге киемнәрен яратып бетерми, шуңарга як-ягына карана,— ди.

Китереп җиткерделәр моңарга төрле-төрле күлмәкләр.

Патша әйтә:

— Алай булса, үзең теләгәнне, үзең эстәгәнне ки,— ди.

Төлке сузылды да:

— Аның үз күлмәге шуның төсле иде,— дип, Салам-Торханга бер атлас күлмәк алып бирде.

Салам-Торханны бер залга яптылар. Йокысы килсә дә, йокламый Салам-Торхан. Мондагы байлыкка аның исе китте. Киенгәч — әйбер иткәч, Салам-Торхан беренче кеше булды. Хатыны белән яратыштылар.

Болар бик әйбәт, тату торалар. Патша да яратты, әбисе дә яратты, Салам-Торхан бик акыллы булып чыкты.

Бервакыт Салам-Торхан Төлкенең үзенә генә әйтә:

— Өйгә кайтасы килә, кайтыйк инде,— ди.

Төлке әйтә:

— Сабыр ит, кунак булыйк әле. Минем тамагым сыйлы,— ди.

Болар тагын кунак булдылар. Алай да булса, Салам-Торханның кайтасы килә. Шулай да болар тагын бер ай тордылар. Аннары Салам-Торхан бабасына хат язып бирде: «Кунак булдык, кайтыр идек инде»,—дип.

Патша Салам-Торхан янына килде. Ул әйтә:

— Ярар, ди. Артыннан кунаклар җибәрикме, әллә үзегез генә кайтып, тагын килерсезме? — ди.

Тегене Төлке өйрәтеп куйды: «Үзебез генә кайтырбыз дип әйт»,— дип. Тегендә бернәрсә дә юк бит. Салам-Торхан әйтә бабасына:

— Үзебез генә кайтабыз, кунаклар киләсе юлы барырлар,— ди.

Шулай дигәч, патша моңарга тройка хәзерләтте. Китәргә хәзерләнәләр.

Ярар. Хәстәрләнгәннән соң, болар утырдылар да кайтырга юлга чыктылар.

Кучерга әйтә Төлке:

— Син бик куып кайтма, әкренрәк кайтыгыз, атлар өшәнмәсен,— ди.

Шулай ди дә, Төлке үзе алдан чабып китә. Төлке, бара торгач, бер авылга җитте. Бик яхшы гына йортка керде дә фатир сорады. Алтынны алдан ук авызына кабып килгәнгә, шуннан гына алтын алып, фатир бәясен өзде. Янә кире Салам-Торханга каршы чыгып китте. Барып җитеп, аларга әйтте:

— Мин кая керсәм, сез дә шунда керерсез,— диде.

Төлке хәзерләп куйган фатирга керделәр. Боларны каршы алдылар. Фатир шәп. Бөтен теләгән әйберләр бар. Ашадылар, эчтеләр, ял иттеләр. Чыгып та киттеләр. Хәзер үз туган якларына баралар. Бервакыт төркем-төркем куй көтүләре күренә. Төлке йөгереп барып әйтә көтүчегә:

— Синнән, кем көтүе, дип сорасалар, Салам-Торхан көтүе, дип әйтерсең,— ди. Көтүчегә алтын бирә.

Килеп җиттеләр дә, кучер көтүчедән сорый:

— Бу кем көтүе? — ди. Белми бит инде ул.

— Бу, ди, Салам-Торхан көтүе,— ди, көтүче әйтә.

22 Б–504

Исе китә инде кучерның, бигрәк бай икән бу, ди.

Янә дә шәһәр кебек бер авылга җитәләр. Төлке алдан барып керә дә, шундагы бер бай йортка кереп, «кайттыгызмы» дип каршы алырсыз, дип, бик күп алтын бирә. Җәлләми инде, күзен чыгарып бирә. Болар монда атларын тугарып җибәрәләр. Кыз кайттык дип белә инде. Салам-Торхан да, үз малларым дип, таралып йөри.

Ярты төн җитә дә, Төлке атларны җиктереп куя. Салам-Торхан белән хатыны карета эчендә йоклыйлар. Әкертен генә кырга барып, атларны бик әкертен генә йөртеп, каретаны печән кибәннәре арасына кертә дә, Төлке кибәннәргә ут төртә. Печән кибәннәре дөрләп яна. Янып бетәрәк кенә Төлке кычкыра:

— Янабыз! Әйдәгез, үзебез чыгып котылыйк, мин атны җиктердем,— ди.

Болар тиз генә чыгып китәләр. Патша кызы: «Харап булдык»,—ди, Салам-Торханның сарайлары, авылы янып бетте, дип белә. «Бәхетсез дип әйтерләр инде мине»,— дип курка. Ул бит әле яңа төшкән килен!

Ул чагында телефон, телеграмма булмаган. Патша кызы атасына хат яза: «Әткәй, мин барып җиткәч тә яндык. Бәхетсезлеккә төштем»,— ди. Шул хат барып җиткәч, атасы үзләренә чакыра. Төлке, саубуллашып, болардан аерылып кала:

— Кәҗә минеке инде,— ди.

Тегеләр патша йортына киттеләр инде.

Бу патша шул үз шәһәрендә торгидан бик зур йорт алып бирә. Йорт әсбапларын да, барын да алып куя. Салам-Торхан хатыны белән шул шәһәрдә кала.

53. Кола ат

Яшәгән, ди, булган, ди, карт белән карчык. Аларның булган, ди, бер Кола атлары. Яхшы ат инде — көчле дә, матур да. Бервакыт карт бу атны кырга утларга чыгарып җибәргән. Кырда йөргәндә бер заман күрә Кола ат: аның каршысына бер барс йөгереп килә. Кола ат куркып кала инде, әмма сиздерми — барстан сорый:

— Син кем буласың? — ди.

— Мин — Ала барс, барлык җәнлекләрнең башлыгы булам,— ди.— Ә син кем?

— Мин — Кола ат,— ди бу,— барлык терлекләрнең башлыгы булам.

Ала барс бүтән башлыкны очраткач, куркып кала һәм әйтә моңа:

— Ә шулай да мин — синнән зуррак башлык,— ди.

— Юк, мин синнән зуррак! — ди ат.

Алар шулай озак кына бәхәсләшкәч, ниһаять, Кола ат әйтә:

— Әйдә, синең белән көч сынашыйк,— ди.

— Әйдә,— ди барс.— Ләкин без көчебезне ничек сынашырбыз соң?

— Менә ничек,— ди Кола ат,— кем дә кем таштан очкын чыгара — шул көчлерәк була.

Барс килешә һәм беренче булып көчен күрсәтә башлый. Ташка ул аяклары белән бәрә-тибә, әмма файдасыз: очкын чыкмый да чыкмый.

Шуннан соң Кола ат ташка үзенең дагаланган тояклары белән китереп типкән икән, таштан бер көлтә очкын чәчелеп киткән.

Барс очкыннарны күргән, элеккедән дә катырак куркып, бар көченә йөгереп, качып киткән, ди.

54. Балыкчы Аю

Беркөнне Аю Төлкенең балык ашаганын күргән дә бик кызыккан.

— И Төлке дус, балык тотарга мине дә өйрәтсәнә! — дигән.

Төлке Аюга әйткән:

— Ярар, Аю дус, өйрәтермен,— дигән. Аюның койрыгына бер кәрзин бәйләгән дә аны бәкегә төшергән. Аюга әйткән:

— Шунда кузгалмый гына утыр, кузгалсаң, кәрзингә балык кермәс,— дигән. Шулай дигән дә үзе качкан.

Әй утыра, ди, Аю, әй утыра, ди, балыклар качып бетмәсен тагын дип, бер дә селкенеп карамый, ди. Шулай төн буе утырган, ди. Утыра торгач, койрыгы бәке кырыена ябышып каткан, ди.

Иртә белән хатыннар суга килсәләр, бәке өстендә Аю утыра.

— Ник монда килеп утырдың? — дип, менә тотынганнар Аюны кыйнарга.

Аю, бичара, куркуыннан сикереп торган икән, койрыгы шарт итеп өзелгән, ди.

Аюның койрыгы шул вакытта кыскарып калган, ди.

55. Ялганчы Кәҗә һәм батыр Әтәч

Борын-борын заманнарда бер авылда яшәгән икән, ди, бер бабай. Бу бабайның бер кызы, бер Кәҗәсеннән башка бернәрсәсе дә булмаган, ди. Бик ярлы булган бу.

Көннәрдән бер көнне бабай үзенең кызын болынга Кәҗәсен көтәргә җибәргән. Кыз Кәҗәне көн буена болында көтеп йөргән дә, кичкырын гына алып кайтып, ишегалдына кертеп япкан, ди.

Бабай, Кәҗә янына чыгып:

— Йә, Кәҗәкәем, көне буена болында булып, ни ашадың, ни эчтең? — дип сорый икән.

Кәҗә моңа:

— Бер яфрак ашадым да бер кашык чамасы су эчтем,— дип җавап биргән, ди.

Картның моңа ачуы килеп:

— Бер Кәҗәне дә туйганчы ашатып кайта алмагансың,— дип, кызын бик каты ачуланган, ди.

Икенче көнне карт болынга Кәҗәне үзе алып киткән. Кәҗә көне буена болында йөреп туйганчы ашаган, ял иткәләп алган да, ди, тагын торып ашарга тотынган. Бабай моны күреп бик шатланган: «Ярый, үзем алып килгәч, бик рәхәтләнеп, туйганчы ашады әле бу»,— дип уйлый икән бабай. Шулай дип уйлаган да теге бабай, кич булганны да көтеп тормаган, кәҗәсен калдырып өенә кайтып киткән, ди.

Кич булып караңгы төшүгә, Кәҗә дә болыннан кайтып кергән, ди. Бабай сорый инде бу Кәҗәдән:

— Нихәл, Кәҗәкәем, көне буена болында йөрдең, ни ашадың, ни эчтең? — ди.

Кәҗә аңа:

— Бер яфрак ашадым да бер кашык чамасы су эчтем,— дип җавап биргән, ди.

Картның моңа бик ачуы килә. «Гаеп кызда түгел, бу Кәҗә үзе бик ялганчы хайван икән»,— ди. Шуннан соң бабай: «Бу ялганчы Кәҗәдән барыбер бер рәхәт тә күрмәссең»,— дип уйлый да Кәҗәсен суеп ашарга була.

Икенче көнне бабай Кәҗәне ике мөгезеннән тотып алып, аякларын бәйләп сала. Бабай пычак алырга дип өенә кереп киткән арада Кәҗә аякларын ычкындыра да чыгып сыза.

Китә бу. Бара-бара барып җитә бу кечкенә генә бер өйгә. Бу — Куян йорты икән. Барып керә. Өй эчендә беркем дә юк. Бу барып кергәндә, Куянның чыгып киткән вакыты булган икән, ди.

Кояш баеп караңгы төшә башлауга, Куян үзенең өенә кайтып керә. Керсә, ни күзе белән күрсен, теге Кәҗә түр башына менеп, мөгезләрен тырпайтып, сакалын селкетеп утыра икән, ди. Куян моны күреп бик каты курыккан да, алдына-артына карамастан, урманга таба торып чапкан, ди.

Урманга барып керүгә, бу Куянга очраган, ди, бер Бүре. Бүрене күрү белән Куян акырып елый башлаган. Моны күреп, Бүре:

— Нигә елыйсың, сиңа ни булды? — дип сорый икән.

Куян моңа:

— Нигә еламаска, көне буена урманда йөреп, өемә әйләнеп кайтсам, түр башында бик куркыныч бер нәрсә утыра, күрү белән йөрәгем ярыла язды,— ди.

Моны ишетү белән Бүре батырланып:

— Әйдә киттек, без аны хәзер куып чыгарабыз,— ди.

Китәләр. Куян өенә барып җитү белән, Бүре үзе дә курка-курка гына ишекне ача. Караңгы өйдә зур мөгезле, озын сакаллы Кәҗә башын күрү белән Бүренең дә котлары чыга. Бүре тиз генә өй ишеген яба да урманга карап сыза. Куян аның артыннан китә. Куянның урманга барып керүе була, моның каршысына лап-лап басып килә икән, ди, бер Аю. Аюны күрүгә, Куян тагын кычкырып елап җибәрә:

— Коткарыгыз, харап булдым, өемә куркыныч бернәрсә кергән,— ди.

Аю бик батырланып:

— Ташла әле, юкка-барга елап күз яшеңне әрәм итмә, без аны хәзер куып чыгарырбыз,— ди икән.

Китәләр. Караңгы төшүгә Куян өенә барып җитәләр. Аю бик батырланып өй ишеген ачып җибәрүгә, сәке өстенә менеп утырган зур мөгезле, озын сакаллы Кәҗәне күрү белән, бик каты куркуга төшә. Аю да куркуыннан алдына-артына карамый урманга чаба. Куян — аның артыннан.

Куянның урманга барып керүе була, очрый инде моңа бер Төлке. Төлке дә бик батырланып бара. Караңгы бүлмәдә кукыраеп утырган Кәҗәне күрү белән, Төлкенең дә котлары чыга: кача бу.

Куян нишләсен, йорт-җирен калдырып чыгып китә урманга.

Таң атып яктыра башлауга, барып җитә бу бер урман каравылчысының йортына. Бу йортның койма башында утыра икән, ди, бер Әтәч. Әтәчне күрү белән, Куян, гадәтенчә, тагын да кычкырып елап җибәрә, ди.

— Нигә елыйсың соң син, Куянкай? — ди Әтәч, моннан сорый инде.

— Нигә еламаска,— ди Куян,— менә минем өемә бер куркыныч нәрсә кереп утырды, аны үзем дә, Бүре белән Аю да, хәтта Төлке дә куып чыгара алмады,— ди.

— Юкка елама, Куянкай, әйдә киттек, менә мин үзем сиңа ярдәм итәрмен,— ди Әтәч.

Киттәләр. Куян өенә барып җитүгә, Әтәч әйтә инде Куянга:

— Миңа өй ишеген ачу гына кыен булыр, син ишекне ачып мине кертеп җибәрерсең, калганын үзем белермен,— ди.

Өй янына барып җитү белән, Куянның ишекне ачып җибәрүе була, Әтәч, өй эченә кереп, Кәҗә мөгезләре арасына барып кунуы була. Кәҗә башына куна да бу, чукый башлый Кәҗәнең күзләрен. Кәҗә бернәрсә эшли алмый. Чыгып кача Куян өеннән. Әтәч аны бик еракка хәтле куып бара.

Шулай итеп, батыр Әтәч Куянны ялганчы Кәҗәдән коткарган, ди.

56. Кодрәтле Әтәч

Борын-борын заманда бик матур, бик батыр бер Әтәч булган. Әтәч бервакыт урамда йөргәндә алтын балдак таба да муенына кия. Моны бер бай күреп:

— Алтын балдагыңны бер атнага миңа биреп тор, мин сиңа тары бирәмен,— ди.

Әтәч тиз күнә. Байга бер атнага балдакны биреп, тары алып кайтып китә.

Бер атна үткәч, Әтәч байдан барып балдакны сорый, ә бай бирмичә куып кайтарып җибәрә. Әтәч ике көн үткәч бай янына тагын бармакчы була. Бара-бара Әтәчкә бер зур Аю очрый.

— Әтәч, кая барасың? — ди.

— Мин байга алтын балдагымны сорарга барам,— ди Әтәч.

Аю:

— Мин дә барыйм әле,— ди.

— Әйдә кер эчкә,— ди Әтәч.

Аю Әтәчнең авызыннан эчкә керә. Тагын китә бу, бара-бара Бүре

очрый моңа. Шулай сөйләшкәннең соңында, Бүре дә Әтәч эченә керә. Әтәч тагын үз юлына китә. Шуннан Әтәчкә Төлке очрый. Төлке дә, Әтәч белән сөйләшеп, шулай ук Әтәчнең эченә кереп, Әтәч белән китәләр.

Байга барып җиткәч, Әтәч капка башына менә дә:

— Бай абый, алтын балдакны бир! — дип берничә мәртәбә кычкыра.

Бай, хезмәтчеләренә әйтеп, Әтәчне тотарга куша. Шуннан Әтәчне тотып, атлар тибеп үтерсен дип, атлар абзарына ябалар. Әтәч, абзарга ябу белән:

— Аю, чык эчтән! — ди.

Аю чыгып, бөтен атларны кыйнап үтерә дә Әтәч эченә яңадан керә.

Икенче көнне, казлар талап үтерсен дип, Әтәчне казлар янына ябалар. Абзарга ябу белән, Әтәч:

— Төлке, чык эчтән! — ди.

Төлке, Әтәч эченнән чыгып, бөтен казларын үтереп, ашап бетерә дә Әтәч эченә керә.

Болай да булмагач, өченче көнне Әтәчне сарыклар, тәкәләр абзарына ябалар. Ябу белән, Әтәч тагын:

— Бүре, чык эчтән! — ди.

Бүре, Әтәч эченнән чыгып, бөтен сарыкларны буып үтерә дә Әтәч эченә керә.

Инде болай булмый икән дип, Әтәчне дүртенче көнне коега ташлыйлар. Коега төшү белән, Әтәч:

— Су, кер эчкә! — ди.

Коедагы бөтен су Әтәч эченә кереп бетә. Әтәч үлми кала.

Бишенче көнне мичкә бик көчле ягып, янып үлсен дип, мичкә аталар. Әтәч мичкә керү белән:

— Су, чык эчтән! — ди.

Су Әтәч эченнән чыгып мичне сүндерә дә яңадан Әтәч эченә керә.

Болай да булмагач, шул көнне, пешереп ашарга дип, Әтәчне казанга салалар. Казанга салгач, Әтәч:

— Су, чык эчтән! — ди.

Бөтен кое суы Әтәч эченнән чыгып кайный торган казанны суындыра. Су казаннан ташып учакка кереп, учакны сүндерә. Шуннан соң Әтәч:

— Аю, Төлке, Бүре, чыгыгыз эчтән! — ди.

Аю, Бүре, Төлке чыгып, байны семьясы белән кыйнап үтерәләр. Балдакны, байның бөтен малын алып, көлешә-көлешә кайтып китәләр, ди.

— Менә, алтын балдакка кызыксаң, шулай була ул! — ди Әтәч.

Искәрмәләр

Татарстан һәм башка республика, өлкәләрнең район һәм авыл исемнәре әкият язып алынган вакыттагы административ бүленештә күрсәтелде.

Файдаланылган чыганакларның исемнәре түбәндәге шартлы кыскартулар белән бирелде:

АББ — Акыл белән бәхет: Татар халык әкиятләре /Төзүчесе З.Мөхәммәтҗанов.— Казан, 1963.

Әкиятләр — Әкиятләр /Төзүчесе Х.Ярми.— Казан, 1947.

Балинт — Balint Gabor. Kazani-tatar nyelvtanulmanyok I. füzet Kazani-tatar szövegek.— Budapest, 1875.

Җамалетдин — Яшәгән, ди, булган, ди: Әкиятләр /Төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы Л.Җамалетдин.— Казан: Мәгариф, 2000.

Золотая арба — Золотая арба: Татарские народные сказки /Пересказал В.Бояринов.— М.: Малыш, 1987.

Идель — «Идель» — Яшьләр журналы. Татар һәм урыс телләрендә 1989 елдан бирле чыга (Казан).

Касыймов — Абага чәчәге: Татар халкының сатирик әкиятләре /Төзүчесе Э.Касыймов.— Казан, 1962.

КУ — «Казан утлары» — әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал. 1922 елдан бирле чыга (Казан).

Кунош, 1989 — Kazantatarische Volksmärchen. Auf Grund der Sammlung von Ignác Kúnos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk und Imre Baski (Oriental Studies 8).— Budapest, 1989.

Кунош, 1996 — Mischärtatarische Texte mit Wörterverzeichnis. Auf Grund der Sammlung von Ignác Kúnos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk.— Szeged, 1996.

Мирас — «Мирас» — бөтендөнья татарларының халыкара фәнни-популяр, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис айлык журналы. 1991 елдан бирле чыга (Казан).

Өмет — Ульяновски өлкәсе татарларының атналык газетасы. 1989 елдан бирле чыга (Ульяновски шәһәре).

Радлов — Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен.— Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар.— СПб, 1872.

Рамазанова — Рамазанова Д. К истории формирования говора пермских татар.— Казань, 1996.

РГО — Русское географическое общество — Рус география җәмгыяте архивы — (С.-Петербург).

Сабыйга — «Сабыйга» — балаларның әдәби-нәфис журналы. Татар һәм урыс телләрендә 1994 елдан бирле нәшер ителә (Казан).

Сказки — Сказки сибирских инородцев /В обработке для детей К.Дубровского.— Вып. 1.— Иркутск, 1919.

ТӘҺСИ — Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсе (Казан).

ТНС, 1992 — Татарские народные сказки /Составитель Л.Замалетдинов.— Казань, 1992.

ТНТ, I — Татарское народное творчество: В 14-ти томах. Том I. Сказки о животных и волшебные сказки/ Составитель тома, автор вступительной статьи и комментариев Л.Замалетдинов.— Казань: Раннур, 1999.

Туган як — Түбән Новгород өлкәсе татарларының иҗтимагый-сәяси газетасы. 1990 елдан бирле чыга (Сергач шәһәре).

ТХӘ, 1946 — Татар халык әкиятләре.— [Беренче китап] /Төзүчеләре Г.Разин [Г.Бәширов] һәм Х.Ярми.— Казан, 1946.

ТХӘ, 1956 — Татар халык әкиятләре.— Икенче китап /Төзүчеләре Г.Бәширов, Х.Ярми.— Казан, 1956.

ТХӘ, 1964 — Татар халык әкиятләре /Мөхәррире Ф.Гайнанова.— Казан, 1964.

ТХӘ, 1974 — Татар халык әкиятләре /Төзүчесе Х.Гатина.— Казан, 1974.

ТХӘ, 1989 — Татар халык әкиятләре /Төзүчесе, кереш мәкалә авторы һәм искәрмәләр әзерләүче Л.Җамалетдинов.— Казан, 1989.

ТХӘ, 1994 — Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр /Төзүче, кереш мәкалә авторы һәм искәрмәләр әзерләүче Л.Җамалетдин.— Казан, 1994.

ТХИ, 1954 — Татар халык иҗаты: Икенче басмасы /Төзүчеләре Г.Бәширов, А. Шамов, Х.Ярми һәм Х.Госман.— Казан, 1954.

ТХИӘ, III — Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Өченче китап /Төзүчесе, кереш мәкалә язучы һәм искәрмәләр әзерләүче Л.Җамалетдинов.— Казан, 1981.

ХИ, 1940 — Халык иҗаты /Төзүчеләр Х.Ярми, А.Әхмәт.— Казан, 1940.

Шәһри Казан — «Шәһри Казан» — иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни газета. 1990 елдан бирле чыга (Казан).

Шомбай — Шомбай: Татар халык әкиятләре /Төзүчесе һәм мөхәррире К.Котдусова.— Казан, 1960.

Башка төрле кыскартулар:

б.— бит.
колл.— коллекция.
оп.— опись.
п.— папка.
разр.— разряд.
р-н — район.
сак.бер.— саклау берәмлеге.

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

ӘСИРЛЕКТӘН КАЙТКАН ӘКИЯТЛӘР

Венгр галиме Игнац Куношның беренче бөтендөнья сугышы чорында әсирлектәге татар солдатларыннан язып алган әкиятләре ике тупламда урнашкан. Алар Венгрия Фәннәр академиясе архивында саклана. Тупламнарның берсендә — Казан татарлары фольклоры, ә икенчесендә — мишәр-татар фольклоры. Дөньяга әлеге тупламнардагы әкиятләр, диалектологик материал сыйфатында, ике мөстәкыйль җыентыкта чыкты (шартлы кыскартулар исемлеген кара). Түбәндә, текстларга искәрмә рәвешендә, шул тупламнарга ишарә ителәчәк.

I

1. Патшаның өч улы. И.Куношның Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош, 1989.— №1. Соңгы басмасы: Мирас.— 1993.— №2.— 88—90 б.

2. Батман бабай. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.—№2. Соңгы басмасы: Мирас.— 1993.— №3.— 114—124 б.

3. Карт бабай. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №3. Соңгы басмасы: Мирас.— 1993.— №4.— 121—126 б.

4. Айсылу. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №5. Соңгы басмасы: Мирас.— 1993.— №7.— 92—93 б.

5. Алтын чәчле кыз. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №6. Соңгы басмасы: Мирас. 1993.— №7.— 93—94 б.

6. Әби белән бабай. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №8. Соңгы басмалары: Мирас.— 1993.— №10.— 114—117б.; Туган як, 1996.— 9 нояб.

7. Әбекәй. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №9. Соңгы басмасы: Мирас.— 1993.— №11.— 122—125 б.

8. Патша улы. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №10. Соңгы басмасы: Мирас.— 1993.— №12.— 113—119 б.

9. Мөгезле кеше. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №12. Соңгы басмасы: Мирас.— 1994.— №2.— 98—100 б.

10. Кол малай. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №13. Соңгы басмасы: Мирас.— 1994.— №3. 96—101 б.

11. Ак бүре. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Әмма хәзерге вакытта әкиятнең кульязмасы бу тупламда юк. Аны И.Кунош, нәшер итү өчен алгач, ни сәбәптәндер, кире үз урынына куймаган булса кирәк. Ләкин бу әкият безгә моңарчы да яхшы таныш иде. Аңа бары тик, И.Кунош үзе бастырып чыгарган «Төрек халык әдәбияты» (Истанбул, 1925) дигән китабына кушымта итеп урнаштырган «Ак бүре әкияте» тексты белән чагыштырып, төзәтүләр генә кертелде. Камил вариант соңгы мәртәбә 1994 елда басылды (ТХӘ, 1994, 6—30 б.) Бу китапка кабат кертелүенең сәбәбе — И.Кунош тупламнарындагы әкият репертуарының шушы басмада тулылыгын тәэмин итәргә омтылу.

12. Дию патшасы әкияте. Мишәр-татар фольклоры тупламыннан. Кунош.—1996.— №2. Соңгы басмалары: Өмет.— 1997.— 29 нояб.; КУ.— 1999.— №9.—54—157 б.

13. Бер байның әкияте. Мишәр-татар фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1996.— №3. Соңгы басмалары: Өмет.— 1997.— 6 дек.; КУ.— 1999.— №9.— 157—159 б.

14. Патша малае әкияте. Мишәр-татар фольклоры тупламыннан.. Кунош.— 1996.— №4. Соңгы басмалары: Өмет.— 1997.— 10 дек.; КУ.— 1999.— №9.— 159—162 б.

15. Өч аргамак әкияте. Мишәр-татар фольклоры тупламыннан. Кунош..— 1996.— №6. Соңгы басмасы: Өмет.— 1997.— 26 дек.

16. Җил-пәри әкияте. Мишәр-татар фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1996.— №7. Текст тулы түгел.

II

17 Таз әкияте. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош, 1989.— №4. Соңгы басмасы: Мирас.— 1993.— №7.— 90—92 б.

18. Беләк буе кайрак. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №11. Соңгы басмасы: Мирас.— 1994.— №1.— 94—96 б.

19. Салтыкай. Казан татарлары фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1989.— №7. Соңгы басмасы: Мирас.— 1993.— № 9.— 117—118 б.

20. Патша улы һәм дию. Мишәр-татар фольклоры тупламыннан. Кунош.— 1996.— №1.— «Патша улы диюсе». Соңгы басмалары: Өмет.— 1997.— 22 нояб.; КУ.—1999.— №9.— 153—154 б.

21. Юсып Минулин әкияте. Мишәр-татар фольклоры тупламыннан. Кунош.—1996, №5. Соңгы басмалары: Өмет.— 1997.— 26 дек.; КУ.— 1999.— №9.— 162—165 б.

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

КӨТТЕРЕП КИЛГӘН ӘКИЯТЛӘР

I

22. Гали, Вәли һәм Гәрәй солдатлар. Татарстанның Баулы р-ны Бәйрәкә авылында Әнвәр Яхиннан (1923 елда туган) Л.Җамалетдин язып алды. 1988. Бердәнбер басмасы: Мирас.— 1995.— №7/8.— 102—106 б.; №9.— 69—76 б.

23. Булдыклы егет һәм Сәмрук патша. Ырынбур өлкәсенең Северный районы Якты Күл авылыннан Сәйдә Сафина (1920 елда туган) язып җибәрде. 1990. Бердәнбер басмасы: Мирас.— 1996.— №10.— 57—61 б.

24. Җен кызы Гөлбану. Ырынбур өлкәсенең Северный р-ны Якты Күл авылыннан Сәйдә Сафина (1920 елда туган) язып җибәрде. 1990. Бердәнбер басмасы: Мирас.— 2000.— №2.— 153—155 б.

25. Сәйфелмөлек һәм Фәтхелҗамал. Омски өлкәсенең Тара р-ны Шыклар авылында Сара (Зөһрә) Гыйзәтуллинадан (1926 елда туган) Н.Ибраһимов язып алган. 1969. Кулъязманың саклану урыны: ТӘҺСИ, колл.81, п.1, сак.бер.25. Бердәнбер басмасы: Мирас.— 1996.— №1/2.— 86—89 б.— «Сәйфелмөлек».

26. Гармунчы егет һәм пәриләр. Пермь өлкәсенең Орда р-ны Олы Көек авылында Насретдин Нуретдиновтан (56 яшь) Д.Рамазанова язып алган. 1966. Диалектологик материал буларак, беренче басмасы: Рамазанова, с.312—314 — «Гармунчы егет әкияте».

II

27.Гөлфарига. Башкортостанның Караидел р-ны Уразбахты авылында Гыйндулла Шаһәюповтан (82 яшь) Р.Риян язып алган. 1970. Беренче мәртәбә басыла.

28. Сәгъди бабай. Татарстанның Лениногорски районы Мөэмин-Каратай авылында Минҗамал Гуловадан (74 яшь) Л.Җамалетдинов язып алды. 1976. Беренче мәртәбә басыла.

29. Салам-Торхан һәм алтын пароход. Омски өлкәсенең Тара р-ны Шыклар авылында Сара (Зөһрә) Гыйззәтуллинадан (1926 елда туган) Н.Ибраһимов язып алган. 1969. Кулъязманың саклану урыны: ТӘҺСИ, колл.81, п. 1, сак.бер. 25. Беренче басмасы: Мирас.— 1996.— №1/2.— 84—86 б.

30. Бай һәм нужа. Татарстанның Әтнә р-ны Кече Әтнә авылында Хәнифә Фәхретдиновадан (1909 елда туган) Казан дәүләт педагогика университеты студенты Р.Яруллина язып алган. 1988. Р.Ягъфәров тарафыннан эшләнгән бердәнбер басмасы: Шәһри Казан.— 1996.— 5 гыйнвар.

31. Өч Таз. Татарстанның Минзәлә р-ны Күзкәй авылында Галимҗан Вәлиев (59 яшь) дәфтәреннән (1937 елда язылган) С.Гыйлаҗетдинов күчереп алган. Беренче мәртәбә басыла.

III

32. Төлке, Керпе һәм Ана керпе. Вятка губернасында (хәзер Киров өлкәсе) яшәүче татарлардан XIX гасыр азагында яисә XX гасыр башында А.Бессонов язып алган. Кулъязманың саклану урыны: РГО, разр. 10, оп.1,№13 — «Лиса, Еж и Ежиха». Текстның татарчасы югалган. Урыс теленнән Л.Җамалетдин тәрҗемәсе. Беренче мәртәбә татар һәм урыс телләрендә «Сабыйга» журналында басылды (1995, № 11/12).

33. Май тапкан тычканнар. Татарстанның Столбище р-ны Хәерби авылыннан Гариф Вафин (1920 елда туган) язып җибәргән. 1959. Кульязманың саклану урыны: ТӘҺСИ, колл. 66, п.1, сак.бер. 3. Беренче мәртәбә басыла.

34. Сандугач оясы. Гариф Вафин тупламыннан. 1959. Кульязманың саклану урыны: ТӘҺСИ, колл. 66., п. 1, сак.бер. 3 — «Сандугач». Беренче мәртәбә басыла.

35. Мактанчык каз. Гариф Вафин тупламыннан. 1959. Кульязманың саклану урыны: ТӘҺСИ, колл. 66, п. 1, сак.бер. 3. Беренче мәртәбә басыла.

36. Зирәк Карга. Гариф Вафин тупламыннан. 1959. Кульязманың саклану урыны: ТӘҺСИ, колл. 66, п.1, сак.бер. 2 — «Зиһенле Карга». Беренче мәртәбә басыла.

37. Төлке, Бүре һәм Аю. А.Бессонов тупламыннан. Кульязманың саклану урыны: РГО, разр. 1, оп.10, оп. 1, №15 — «Лиса, Волк и Медведь». Текстның татарчасы югалган. Урыс телендә беренче басмасы: Идель.— 1999.— №4.— С.37. Татар телендә беренче мәртәбә басыла (Л.Җамалетдин тәрҗемәсе).

38. Бабай, Аю һәм Төлке. А.Бессонов тупламыннан. Кульязманың саклану урыны: РГО, разр. 10, оп.1, №10 — «Мужик, Медведь и Лиса». Текстның татарчасы югалган. Урыс теленнән Л.Җамалетдинов тәрҗемәсе. Беренче мәртәбә басыла.

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

САГЫНДЫРГАН ӘКИЯТЛӘР

I

39. Баһадиршаһ вә гөмбә хикәясе. Бу әкият беренче мәртәбә 1899 елда Казан шәһәрендә аерым китап булып чыккан. Безнең көннәрдә аны Л.Җамалетдин кабат бастырды: КУ.— 1996.— №7.— 135—148 б.

40. Тимеркендек. XIX гасырның 70 нче елларында Төмән татарларыннан В.Радлов язып алган һәм 1872 елда, диалектологик материал буларак, дөньяга чыгарган (Радлов, 319—325 б.). Х.Ярми тарафыннан эшкәртелгән соңгы басмасы: ТХӘ.— 1956.—14—20 б.

41. Мичтә туган Камыр батыр. Татарстанның Апас р-ны Танай-Турай авылында Кәлимулла Әхмәдишиннан (1868 елда туган) Г.Толымбай язып алган. 1936. Бердәнбер басмасы: ТХӘ.— 1946.— 236—243 б.— «Камыр батыр».

42. Мөгезле патша белән егет. Татарстанның Азнакай р-ны Азнакай поселогында яшәүче Заһри Мөхәммәтҗанов (1919 елда туган) язмасы. Бердәнбер басмасы: АББ.— 30—33 б.— «Мөгезле патша».

II

43. Шәйдулла. Шемаха шәһәреннән укытучы Александр Калашев язмасы. 1888. Омски шәһәрендә басыла торган «Особое «Прибавление» к «Акмолинским областным ведомостям» дигән гәзиттә гарәп шрифтындагы оригиналы белән бергә урысча тәрҗемәсе дә дөнья күргән (1891.— №5.— С.2—7) һәм «нугай әкияте» дип куелган. Мәгълүм ки, казакълар татарны нугай дип атыйлар. Кирилл хәрефләре белән бердәнбер басмасы: Мирас, 1996.— № 1/2.— 83—84 б.

44. Эшлексез кеше. Татарстанның Буа р-ны Толымбай авылында Хәйретдин

Хөсәеновтан (62 яшь) Г.Толымбай язып алган. 1940. Соңгы басмасы: Касыймов.— 145—148 б.

45. Дага. Татарстанның Мөслим р-ны Теләнче авылыннан Зариф Мөэминов (1893 елда туган) язып җибәргән. 1940. Татар телендәге бердәнбер басмасы: ТХИӘ.— III.—43—44 б.— «Тәрбия эше». Бу әкиятнең әдәби эшкәртелгән варианты урыс телендә дә дөнья күрде: Золотая арба.— С.11—14 — «Подкова».

46. Акыллы бабай һәм бай. Татарстанның Азнакай р-ны Азнакай поселогында яшәүче Заһри Мөхәммәтҗанов (1919 елда туган) язмасы. Бердәнбер басмасы: АББ.— 37—39 б.— «Этнең башы табакта тормый».

47. Тапкыр кеше. Татарстанның Әлки р-ны Иске Салман авылында Миңлегали Фәхретдиновтан (1882 елда туган) Х.Гатина язып алган. 1953. Бердәнбер басмасы: ТХИ.— 1954.— 530—531 б.— №19.

48. Һөнәрле югалмас. Татарстанның Теләче р-ны Максабаш авылында Минһаҗ Хәмидуллиннан (1878 елда туган) Г.Бәширов язып алган. 1939. Соңгы басмасы: ТХӘ.— 1964.— 202 — 206 б.

49. Тапкыр егет. Татарстанның Теләче р-ны Максабаш авылында Минһаҗ Хәмидуллиннан (1878 елда туган) Г.Бәширов язып алган. 1939. Соңгы басмасы: Шомбай, 140—145 б.

50. Убыр-Таз. Казан губернасында керәшен татарларыннан венгр галиме Габор Балинт язып алган һәм 1875 елда үзенең «Казан татарлары телен тикшерү» дигән китабында бастырып чыгарган: Балинт, №26 — «Әкият». Соңгы басмасы: ТХӘ.— 1989.— 399—400 б. Биредә шуны әйтергә кирәк: бу әкият бездә 1938 елдан басыла башлаган. Әмма, беренче чыганакка мөрәҗәгать иткәч, текстның бер өлеше төшеп калганлыгы ачыкланды. Бу китапта ул тулысынча бирелә. Тулы текстның урыс телендәге бердәнбер басмасы: ТНС.— 1992.— С. 229—230.

51. Хикмәтле усак. Иркутски өлкәсенең Чуна районы Тәрәй авылында Фәтхетдин Гыйләҗетдиновтан (1908 елда туган) Л.Җамалетдинов язып алган. 1971. Беренче басмасы: ТХИӘ.— III.— 471—472 б.— «Урман буры». Соңгы басмасы: Җамалетдин, 134—135 б.— «Хикмәтле усак».

III

52. Кәҗәле Салам-Торхан. Татарстанның Апас р-ны Танай-Турай авылында Кәлимулла Әхмәдишиннан (1908 елда туган) Г.Толымбай язып алган. 1936. Беренче басмасы: ТХӘ.— 1956.— 275—278 б.— «Саламторхан». Соңгы басмасы: Саламторхан: Татар халык әкияте /Әдәби эшкәртүче Л.Хәмидуллин.— Казан, 1989.

53. Кола ат. Текстның чыганагы: Сказки.— С. 19-20 — «Савраска». Л.Җамалетдин тәрҗемәсе. Урыс телендәге соңгы басмасы: ТНТ, I с. 56. Татар телендәге бердәнбер басмасы: Сабыйга, 1995, №9/10.

54. Балыкчы Аю. Текстның чыганагы: Әкиятләр.— 57—58 б. Соңгы басмасы: ТХӘ.—1974.— 116 б.— «Аю белән Төлке».

55. Ялганчы Кәҗә һәм батыр Әтәч. Татарстанның Кукмара р-ны Янил авылында Кәримә Шигаевадан (40 яшь) Х.Гатина язып алган. 1951. Соңгы басмасы: ТХӘ.— 1989.— 85—87 б.— «Батыр Әтәч».

56. Кодрәтле Әтәч. Текстның чыганагы: ХИ.— 1940.— 204-205 б. Соңгы басмасы: ТХӘ.— 1989.— 88—89 б.— «Хәйләкәр Әтәч».

ЭЧТӘЛЕК

Әкиятләрнең дә үз язмышы. *Ленар Җамалетдин* 3

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

ӘСИРЛЕКТӘН КАЙТКАН ӘКИЯТЛӘР

I

1. Патшаның өч улы 12
2. Батман бабай 16
3. Карт бабай 36
4. Айсылу 74
5. Алтын чәчле кыз 75
6. Әби белән бабай 77
7. Әбекәй 83
8. Патша улы 92
9. Мөгезле кеше 106
10. Кол малай 110
11. Ак бүре 120
12. Дию патшасы әкияте 143
13. Бер байның әкияте 148
14. Патша малае әкияте 151
15. Өч аргамак әкияте 157
16. Җил-пәри әкияте 166

II

17. Таз әкияте 169
18. Беләк буе кайрак 172
19. Салтыкай 177
20. Патша улы һәм дию 181
21. Юсып Минулин әкияте 182

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

КӨТТЕРЕП КИЛГӘН ӘКИЯТЛӘР

I

22. Гали, Вәли һәм Гәрәй солдатлар 190
23. Булдыклы егет һәм Сәмрук патша 214
24. Җен кызы Гөлбану 223
25. Сәйфелмөлек һәм Фәтхелҗамал 228
26. Гармунчы егет һәм пәриләр 233

II

27. Гөлфарига 236
28. Сәгъди бабай 239
29. Салам-Торхан һәм алтын пароход 242
30. Бай һәм нужа 245
31. Өч Таз 246

III

32. Төлке, Керпе һәм Ана керпе 251
33. Май тапкан тычканнар 252
34. Сандугач оясы 252
35. Мактанчык Каз 252
36. Зирәк Карга 252
37. Төлке, Бүре һәм Аю 253
38. Бабай, Аю һәм Төлке 253

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

Сагындырган әкиятләр

I

39. Баһадиршаһ вә гөмбә хикәясе 256
40. Тимеркендек 280
41. Мичтә туган Камыр батыр 287
42. Мөгезле патша белән егет 294

II

43. Шәйдулла 299
44. Эшлексез кеше 302
45. Дага 306
46. Акыллы бабай һәм бай 307
47. Тапкыр кеше 310
48. Һөнәрле югалмас 311
49. Тапкыр егет 316
50. Убыр-Таз 322
51. Хикмәтле усак 323

III

52. Кәҗәле Салам-Торхан 325
53. Кола ат 330
54. Балыкчы Аю 331
55. Ялганчы Кәҗә һәм батыр Әтәч 332
56. Кодрәтле Әтәч 334

Искәрмәләр 336

Литературно-художественное издание

Сказки из неволи

(*на татарском языке*)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Л.К.Җәләлетдинова*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Р.К.Харисов, И.Г.Ногманов, М.Ш.Хайруллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 30.10.2002.
Форматы $70 \times 90^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Академия» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы-басма табагы 25,15+ф.029. Шартлы буяу-оттиск 101,19.
Нәшер-хисап табагы 31,93+ф.0,24. Тиражы 5000. Заказ Б–504.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066.
Казан, Декабристлар ур., 2.